Россия Фәннәр академиясе
Россия Мәгариф академиясе
«Просвещение» нәшрияты

Мәктәпләр өчен академик дәреслек

ҖӘМГЫЯТЬ БЕЛЕМЕ

11 сыйныф



ПРОСВЕЩЕНИЕ
издательство

ТаРИХ

ҖӘМГЫЯТЬ БЕЛЕМЕ 11

Россия Фәннәр академиясе
Россия Мәгариф академиясе
«Просвещение» нәшрияты

А

Мәктәпләр өчен академик дәреслек

Җәмгыять белеме

11 сыйныф

ГОМУМИ БЕЛЕМ БИРҮ УЧРЕЖДЕНИЕЛӘРЕ ӨЧЕН ДӘРЕСЛЕК

База дәрәҗәсе

Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан тәкъдим ителгән

Тәрҗемә Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан расланган

Москва
«Просвещение»
2010

Казан
«ХӘТЕР»
2010

УДК 373.167.1:3
ББК 60я72
Җ85

Обществознание. 11 класс: учеб. для общеобразоват. учреждений: базовый уровень/ [Л.Н.Боголюбов, Н.И.Городецкая, А.И.Матвеев и др.]; под ред. Л.Н.Боголюбова [и др.]; Рос. Акад. наук, Рос. акад. образование, изд-во «Просвещение».— 5-е изд.— М.: Просвещение, 2010.— 349 с. (Академический школьный учебник).

ISBN 978-5-09-023426-9

Җ85 **Җәмгыять белеме.** 11 с-ф: гомуми белем бирү учреждениеләре өчен д-лек: база дәрәҗәсе / русчадан Ә.М.Камалов тәрҗ.— Казан: Татарстан Республикасы «ХӘТЕР» нәшрияты, 2010.— 335 б. (Академик мәктәп дәреслеге).

ISBN 978-5-94113-328-4

Дәреслек өлкән сыйныфлар өчен җәмгыять белеме курсы кыскача вариантының икенче өлешен тәшкил итә. 10 нчы сыйныф дәреслеге белән бергә ул җәмгыять белеменең база дәрәҗәсе Дәүләт стандарты Федераль компонентына тулысынча туры килә.

ISBN 978-5-09-023426-9
ISBN 978-5-94113-328-4

© «Просвещение» нәшрияты, 2010
© Татарстан Республикасы «ХӘТЕР» нәшрияты ЖЧҖ, 2010

Эчтәлек

Авторлардан 5

I БҮЛЕК. Кеше һәм икътисад

§ 1. Икътисад: фән һәм хуҗалык 6
§ 2. Икътисади күтәрелеш һәм үсеш 16
§ 3. Икътисадта базар мөнәсәбәтләре 29
§ 4. Икътисадта фирмалар 42
§ 5. Эшмәкәрлек эшчәнлегенең хокукый нигезләре 53
§ 6. Бизнеста уңыш нигезләре 64
§ 7. Икътисад һәм дәүләт 75
§ 8. Икътисадта финанслар 87
§ 9. Мәшгульлек һәм эшсезлек 99
§ 10. Дөнья икътисады 112
§ 11. Кеше икътисади мөнәсәбәтләр системасында . . . 123
Бүлеккә кыскача йомгак 133
Йомгаклап кабатлау өчен сораулар 134

II БҮЛЕК. Социаль-сәяси һәм рухи тормыш проблемалары

§ 12. Кеше эшчәнлегендә ирек 135
§ 13. Иҗтимагый аң 143
§ 14. Сәяси аң 153
§ 15. Сәяси тәртип 166
§ 16. Сәяси элита һәм сәяси лидерлык 175
§ 17. Хәзерге Россиядә демографик вазгыять һәм тулы булмаган гаиләләр проблемасы 186
§ 18. Россия Федерациясендә дини берләшмәләр һәм оешмалар 194
Бүлеккә кыскача йомгак 205
Йомгаклап кабатлау өчен сораулар 207

III БҮЛЕК. Кеше һәм закон

§ 19. Хокукны аңлауга заманча якын килү 208
§ 20. Россия Федерациясе гражданы 219
§ 21. Экологик хокук 229
§ 22. Гражданлык хокукы 240
§ 23. Гаилә хокукы 252
§ 24. Мәшгульлекне һәм эшкә урнаштыруны хокукый җайга салу 263
§ 25. Процессуаль хокук: гражданлык һәм арбитраж процессы 275
§ 26. Процессуаль хокук: җинаять процессы 287
§ 27. Процессуаль хокук: административ юрисдикция, конституциячел суд эше 298
§ 28. Кеше хокукларын халыкара яклау 308
Бүлеккә кыскача йомгак 318
Йомгаклап кабатлау өчен сораулар 320
Йомгаклауы урынына 321
§ 29. Киләчәккә караш 332
Йомгаклап кабатлау өчен сораулар һәм биремнәр 332

Авторлардан

Дәреслек сез 10 нчы сыйныфта өйрәнгән база дәрәҗәсендәге җәмгыять белеме курсының дәвамы булып тора. Курсның төп эчтәлеге, шулай ук дәреслеккә кертелгән документлар, сораулар, биремнәр чыгарылыш сыйныф укучыларын әзерләү дәрәҗәсенә заманча таләпләргә туры килүче кирәкле белем һәм күнекмәләр алырга мөмкинлек бирә. Гамәли йомгаклар алынган белемнәрне тормышта ничек куллану юнәлешен күрсәтер.

10 нчы сыйныфта сез өйрәнгән күп кенә мәсьәләләр курсның бу өлешендә тулырак һәм тирәнрәк ачылыр. Беренче чиратта бу икътисад, сәясәт, хокук мәсьәләләренә кагыла. Яңа материалны үзләштергәндә, 10 нчы сыйныфта алынган белемнәргә таяну зарур. Яңа белемнәрнең элеккеләре белән бәйләнеше аларны дөрес аңлау, бөтен бер системада үзләштерү шарты булып тора.

Аңлашыла ки, дәреслек материалы җәмгыятьтә әлеге курсны өйрәнгәндә бара торган вакыйгаларны чагылдыра алмый. Агымдагы вакыйгалар белән һәрдаим кызыксыну һәм, курс биргән белемнәрдән файдаланып, аларны мөстәкыйль аңларга өйрәнү мөһим.

Мәктәпне тәмамлап чыкканнан соң, сезнең планнарыгыз нинди генә булмасын, җәмгыять белеме сезгә үз гражданлык позициягезне булдырырга һәм якларга, иҗтимагый һәм шәхси проблемаларны белеп һәм җаваплылык тоеп чишәргә сәләтле компетентлы кеше булырга ярдәм итәр.

I бүлек

Кеше һәм икътисад

§ 1. Икътисад: фән һәм хуҗалык

Икътисад кешеләрнең барлык ихтыяҗларын да үтәргә сәләтлеме? Икътисади эшчәнлекне үлчәп буламы? Икътисад ничек үсә — стихияле төстәме, әллә үз кануннары буенчамы?

Икътисад — кеше тормышының гаять катлаулы өлкәсе. Аның күпсанлы һәм күптөрле чагылышлары «икътисад» төшенчәсенә төгәл билгеләмә бирүне кыенлаштыра. Иҗтимагый тормышның бу өлкәсе турында галим-теоретиклар һәм практикларның карашларын чагылдырган иң гомуми күзаллауларны карыйк әле.

«Икътисад» төшенчәсе белән сез төп мәктәптә үк таныштыгыз. Аны *ике төрле мәгънәгә* бүлеп карарга кирәклеген исегезгә төшерик. Бу сүз белән хуҗалык эшчәнлеген дә, шундый эшчәнлекнең закончалыклары турындагы фәнне дә атыйлар. Бер «икътисад» сүзен ачыклау өчен, файдаланылучы ике билгеләмәне чагыштырып карагыз.

Икътисад — кирәкле тормыш уңайлыклары булдыру һәм алардан файдалану юлы белән кешеләр һәм җәмгыять ихтыяҗларын канәгатьләндерүне тәэмин итүче хуҗалык системасы.

Икътисад — хуҗалык, аны алып бару һәм идарә итү ысуллары, товар җитештерү һәм алмашу процессында кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләр, хуҗалык итү процесслары барышы закончалыклары турындагы фән.

Һәр билгеләмәнең мәгънәсен яхшырак аңлау һәм үзләштерү өчен, икенчесеннән башлап, аларны җентекләбрәк карыйк.

ИКЪТИСАД ФӘНЕ НӘРСӘНЕ ӨЙРӘНӘ

Икътисади проблемалар турында кешеләр безнең эрага кадәр үк уйлана башлаганнар. «Икътисад» («экономика») сүзе грекларда барлыкка килгән һәм борынгы грек авторы Ксенофонт (б.э. кадәр 430–355 яисә 354 еллар тирәсе) тарафыннан үз трактатының атамасы сыйфатында кулланылган. Һәм нибары моннан өч йөз елдан аз гына күбрәк ел элек икътисади чынбарлык хакындагы белемнәрне гомумиләштерүче һәм системалаштыручы галимнәр барлыкка килә. Бу базар икътисады аякка басу чоры була.

Икътисад фәне нигә нәкъ менә шул вакытта барлыкка килә?

Бу кешелек тарихының күпчелек өлеше дәвамында икътисадның төп мәсьәләләре (нәрсә, ничек һәм кем өчен җитештерергә) еш кына йә гореф-гадәтләр нигезендә, йә дәүләт башлыгы фәрманы буенча хәл ителү белән бәйле. Шуңа кешеләрнең гамәлләре алдан ук билгеләнгән һәм белеп торырлык була, икътисад фәненең кирәге чыкмый. Базар икътисады барлыкка килгәч, төп икътисади мәсьәләләрне ирекле һәм мөстәкыйль җитештерүче үзе хәл итә башлый. Галимнәрне бу «ирекле һәм үзен-үзе җайга салучы» икътисади системаның ничек эшләве, анда икътисади процессларның ничек баруы кызыксындыра. Икътисад фәне, профессиональ галимнәр шөгыле буларак, базар икътисады белән бергә барлыкка килә.

Икътисадчы галимнәр базар хуҗалыгының эре элементлары бәйләнешен дә (мәсәлән, эш белән тәэмин ителеш, тышкы сәүдә, дәүләтнең икътисади сәясәте), аерым проблемаларны да (мәсәлән, ихтыяҗ һәм тәкъдим, базар конкуренциясе) өйрәнергә тырышалар.

Галимнәр игътибары үзәгендә нәрсәләр тора соң? Беренче чиратта — икътисадның ресурслар чикләнгәнлеге һәм икътисади сайлап алу кебек универсаль проблемалары (икътисад фәненең бу төп төшенчәләре белән сез төп мәктәпнең җәмгыять белеме курсында таныштыгыз).

Халык саны арту, фәнни-техник прогрессның тизләнүе, мәдәни багланышларның тирәнәя баруы, аларны алмашу белән бәйле рәвештә җәмгыятьнең ихтыяҗлары даими үсә бара һәм, гамәлдә, чиксезгә әверелә. Икътисади мөмкинлекләр исә — җәмгыять ихтыяҗларын канәгатьләндерүгә юнәлтә ала торган реаль ресурслар — һәрчак, һәр мәгълүм чорда чикләнгән була. Җәмгыять һәрчак бу каршылыкны хәл итү зарурлыгына юлыга

һәм икътисади сайлап алу проблемасына килеп терәлә. Булган ресурслар күләме белән үсә барган ихтыяҗларны ничек итеп тулырак канәгатьләндерергә мөмкин? Икътисад — сайлап алу турындагы фән — шушы проблеманы хәл итәргә тырыша да инде.

Икътисад фәне хуҗалыкның төрле өлкәләрен һәм төрле дәрәҗәләрдәге үсеш законнарын өйрәнә. Әйтик, икътисадны бербөтен буларак өйрәнүче өлеше — **макроэкономика.** Аның предметлары булып, мәсәлән, эшсезлек, ярлылык, икътисади үсеш проблемалары, икътисадны җайга салуда һәм җәмгыять мәнфәгатьләрен яклауда дәүләтнең роле тора.

Микроэкономика — икътисад фәненең хуҗалык итүче аерым субъектлар (кулланучылар, хезмәткәрләр, фирмалар) арасындагы икътисади мөнәсәбәтләрне, аларның эшчәнлеген һәм милли икътисадка йогынтысын өйрәнүче өлеше. Ул икътисади эшчәнлекнең аерым катнашучылары юлыга торган сайлап алу проблемасын өйрәнә. Мәсәлән, товарлар һәм хезмәт күрсәтүләр базарында кулланучылар һәм җитештерүчеләрнең үзара йогынтысын, хезмәт базарында эшмәкәрлекнең һәм ялланучы хезмәткәрләр мөнәсәбәтләрен һ.б. Шул ук вакытта микроэкономика аерым базарларның һәм тармакларның ничек эшләвен дә өйрәнә. Ул аерым товарларга бәяләр ничек урнашуын, яңа предприятиеләр төзүгә, сәнәгать тармакларын үстерүгә нинди акчалар һәм ни өчен җибәрелүен, тармаклар һәм базарлар эшчәнлегенә дәүләт сәясәте ничек йогынты ясавын аңлата.

Чикләнгән ресурслардан файдалануга икътисади анализның ике дәрәҗәсе дә (макро- һәм микроэкономика) үзара бәйләнештә. Мәсәлән, нефть эшкәртүче завод продукциясенә бәяләр үсү проблемасы анализланса, бу — микроэкономик проблема. Нефть чыгару тармагы предприятиеләренә карата дәүләтнең монополиягә каршы сәясәте турындагы карарын анализлау — макроэкономика предметы. Бу чакта икътисади эшчәнлекнең аерым катнашучыларының (җитештерүчеләрнең, фирмаларның) үз-үзен тотышы башлыгча бөтен ил икътисадында эшләрнең торышына бәйле.

Икътисади үсешнең хәзерге этабы бөтендөнья масштабында милли икътисадларның үзара бәйлелеге белән үзенчәлекле. Шуңа да икътисади теория милли икътисадларның бөтендөнья хуҗалыгы белән үзара бәгланышлары проблемаларын карауны күздә тота. Дөнья хуҗалыгы үсеше законнарын икътисад фәненең мөстәкыйль өлеше — **бөтендөнья (халыкара) икътисады** өйрәнә. Аның тикшеренү предметы товарлар һәм хезмәт күрсәтүләр белән халыкара сәүдә итү, капитал хәрәкәте, фән һәм техника өлкәсендә алмашу, халыкара валюта мөнәсәбәтләре һ.б. булырга мөмкин.

Икътисад фәне шулай ук дәүләт, предприятие, гаилә һәм йорт хуҗалыгы кебек икътисади институтларның эшләвен һәм үзара хезмәттәшлеген тикшерә.

Икътисади күренешләр, процесслар, мөнәсәбәтләр арасындагы галимнәр ачыклаган тотрыклы, җитди үзара бәйләнешләр гамәлдә икътисади бурычларны нәтиҗәлерәк хәл итәргә мөмкинлек бирә.

Әлеге бүлекнең моннан соңгы параграфларында сез икътисад фәненә зур өлеш керткән А.Смит, Д.Рикардо, К.Маркс, Д.Кейнс, А.Маршалл кебек бөек акыл ияләре, шулай ук хәзерге заман галимнәре, шул исәптән икътисади фикернең Россия мәктәбе вәкилләренең төп фәнни идеяләре һәм хезмәтләре белән танышачаксыз. (Монда сезгә уку тексты гына түгел, һәр параграф ахырындагы документларга мөрәҗәгать итү дә булышыр.)

ИКЪТИСАД һӘМ ИКЪТИСАДИ ЭШЧӘНЛЕК

Киң мәгънәдә алганда, икътисад ул — кешелекнең яшәеше һәм прогрессы өчен шартлар булдыру ысуллары җыелмасы. Моннан, икътисади эшчәнлек кешеләрнең үз ихтыяҗларын канәгатьләндерү һәм тормышның матди шартларын тәэмин итү өчен хуҗалык эшчәнлегенең барлык төрләрен тәшкил итә, дигән нәтиҗә ясарга мөмкин.

Икътисади эшчәнлек ресурсларны кирәкле икътисади уңайлыклар — кешенең теге яки бу ихтыяҗын канәгатьләндерүче һәм җәмгыять карамагында чикле күләмдә булган товарларга һәм хезмәт күрсәтүләргә әверелдерү өчен кирәк. Табигать объектларын куллану әйберләренә әйләндерүнең схематик процессын болай күз алдына китерергә мөмкин:

Ресурслар → Җитештерү → Бүлү → Куллану

Икътисади эшчәнлекнең төрле тармаклары арасында тыгыз элемтә яшәп килә. Әйтик, җитештерү һәм бүлүне аерып карап булмый, җитештерелгән мал кулланучыга барып җиткәндә генә файдалы нәтиҗә бирергә мөмкин. Куллану җитештерүнең максаты гына түгел, аның үсешен кызыксындыру чарасы да. Ул җитештерү күләмнәре артуга, теге яки бу тармак үсешенә җитди йогынты ясый.

Икътисади эшчәнлекнең җитештерүне бүлү һәм куллану белән бәйләп торучы тагын бер өлеше — ул алмашу.

Алмашу — бер зат икенчесенә әйбер, товар биреп, аның урынына акча яисә башка әйбер алу белән бара торган икътисади операция ул.

Матди байлыкларны җитештерү һәм бүлү процессында барлыкка килүче төрле мөнәсәбәтләр «җәмгыятьнең икътисади даирәсе» дигән төшенчәгә керә. (Җәмгыятьне тагын нинди даирәләргә бүлеп карауларын, аларның икътисад белән ничек бәйләнгәнлеген исегезгә төшерегез.)

Икътисадның төп проблемасын хәл итүнең, чикләнгән ресурслардан файдалануның иң нәтиҗәле ысулларын билгеләүнең уңышы күп очракларда эшчәнлекне оештыруның кагыйдәләреннән, принципларыннан тора. Мәсәлән, икътисад дөньясы белән менә берничә гасыр инде төп принципларның берсе — рациональлек принцибы идарә итә, ул иң югары икътисади нәтиҗәләргә моның өчен кирәк булган барлык ресурсларны минималь чыгымнар тотып ирешүгә нигезләнгән карарлар сайлап алырга мөмкинлек бирә. (Тарихтан сезгә инде билгеле булган хуҗалыкны алып бару рәвешләрен: натураль һәм товар хуҗалыкларын чагыштырып карагыз. Аларның кайсы рациональлек принцибын тулырак исәпкә ала? Кайсы нәтиҗәлерәк?)

Икътисади эшчәнлек нәтиҗәләре аны оештыруның гомуми принципларына гына түгел, *икътисади механизмнар* дигән нәрсәгә, ягъни тормышны тәэмин итү бурычларын хәл иткәндә кешеләр тарафыннан үз көчләрен берләштерү ысулларына һәм рәвешләренә дә бәйле. Икътисадның шундый иң мөһим механизмнары булып, мәсәлән, хезмәтне бүлешү һәм махсуслашу, сәүдә тора. (Сезгә инде таныш булган бу хезмәттәшлек ысулларының икътисади эшчәнлек эчтәлегенә һәм нәтиҗәләренә ничек тәэсир итүен исегезгә төшерегез.)

Кешеләр товарларга һәм хезмәт күрсәтүләргә ихтыяҗларын йә аларны үзләре мөстәкыйль җитештереп, йә җитештерелгән продуктларны кирәкле товарларга һәм хезмәтләргә алмашып канәгатьләндерәләр. Шуңа күрә, халыкның тормыш дәрәҗәсен күтәрү өчен, җитештерү күләмнәрен арттыру юлларын табу зарур. Андый юллар икәү: икътисади ресурслардан файдалану *күләмнәрен арттыру* яисә алардан файдалануның *нәтиҗәлелеген күтәрү*. Мөмкин булган ресурслардан нәтиҗәле файдалануның күрсәткече яисә үлчәве булып җитештерүчәнлек тора (хезмәт җитештерүчәнлеге белән бутамагыз). Шул ук ресурслар белән сыйфатлы товарлар күбрәк җитештерелгәндә, җитештерүчәнлек үсә.

Җитештерүчәнлек — чыгымнар берәмлегенә булдырылучы товарлар һәм хезмәт күрсәтүләр күләме. Җитештерү процес-

сында эшкә җигелгән теләсә нинди ресурс — җир, ягулык, җиһазларга чыгымнар һ.б. — барысы да чыгым була ала. Җитештерүчәнлеккә *хезмәт ресурсларының* сыйфаты (һөнәри әзерлек, хезмәткәрләрнең квалификациясе), кулланылучы технологияләр һәм идарәче карарларның нәтиҗәлелеге турыдан-туры йогынты ясый.

ИКЪТИСАДИ ЭШЧӘНЛЕКНЕҢ ҮЛЧӘГЕЧЛӘРЕ

Икътисади эшчәнлекне үлчәү өчен икътисадның торышын, үзенчәлекләрен, сыйфатын, аның объектларын, процессларын характерлаучы төрле икътисади зурлыклар һәм күрсәткечләр кулланыла. Бу зурлыклар җитештерү, бүлү, куллану процессларының ничек баруын, аның нәтиҗәләрен белергә мөмкинлек бирә.

Икътисади зурлыкларны һәм күрсәткечләрне *күләм* (продуктның санын күрсәтә) һәм *сыйфат* (ике зурлыкның нисбәтен характерлый) берәмлекләренә бүлеп карарга мөмкин. Мәсәлән, сез Россиянең дөнья базарында 130 миллион тонна ташкүмер сатуы хакында мәгълүмат очратасыз — бу күләм күрсәткече. Әгәр дә икътисадчылар бу елда җитештерү күләменең узган елдагыга карата 90% ка төшүен билгеләп үтсәләр (моның өчен ике зурлыкны чагыштырырга кирәк),— бу сыйфат күрсәткече мисалы.

Ил икътисады җитештерүе һәм үсеше дәрәҗәсен бәяләү өчен кулланылучы кайбер икътисади күрсәткечләр белән танышыйк.

Күпчелек илләрдә милли икътисадның еллык җитештерүе күләмен **тулай милли продукт** (ТМП) күрсәткече белән үлчиләр. 1988 елдан Россиядә дә шушы күрсәткеч кулланыла.

ТМП әлеге ил җитештерүчеләре тарафыннан бер ел дәвамында *ил эчендә* һәм *чит илләрдә* җитештерелгән *барлык ахыргы продуктларның* (товарларның һәм хезмәт күрсәтүләрнең) *базар бәяләре суммасы* буларак билгеләнә.

Нигә сүз фәкать ахыргы продуктлар турында гына бара соң? Милли продукт күләме дөрес билгеләнсен өчен, барлык продуктларны тик бер кабат исәпләргә кирәк. Күпчелек товарлар һәм хезмәт күрсәтүләр, ахыргы кулланучыга барып җиткәнче, җитештерү процессының байтак стадияләрен үтә. Мәсәлән, укучылары кулына эләккәнче, китап, автор тарафыннан эчтәлеген эшләүдән алып, кәгазь әзерләү һәм басудан аны сатуга кадәр берничә технологик этап үтә.

ТМПга тик ахыргы продуктны (безнең очракта — китапны) сату бәясе генә керә, ягъни ахыргы продуктлар әзерләгәндә файдаланылучы арадаш продуктларны (безнең очракта — кәгазь, типография эшләре, нәшрият чыгымнары) сату төшереп калдырыла. Бу исә икеләтелгән исәпне булдырмаска һәм ТМПны арттырып бәяләүгә юл куймаска мөмкинлек бирә.

ТМП бербөтен буларак икътисад үлчәгече дип санала, чөнки ел дәвамында җитештерелгән барлык товарлар һәм хезмәтләр бәясен чынбарлыкта үз эченә ала. ТМП нигезендә тагын берничә күрсәткеч: тулай эчке продукт; саф милли продукт; милли керем исәпләнә.

ТМП белән охшаш һәм шулай ук еш кулланылучы күрсәткеч — **тулай эчке продуктка** (ТЭП) тукталыйк. Милли җитештерү күләменең бу күрсәткече *ил территориясендә бер ел дәвамында* җитештерелгән *барлык ахыргы продуктларның базар бәяләре суммасы* буларак билгеләнә.

ТЭПны ил гражданнары санына бүлеп, без **җан башына ТЭП** дип аталган күрсәткечне беләбез. Бу күрсәткеч буенча төрле илләрнең икътисади үсеш һәм тормыш дәрәҗәсен чагыштырырга мөмкин. Җан башына ТЭП *милләтнең тормыш дәрәҗәсенең* төп күрсәткечләреннән берсе булып тора. Җитештерү тизрәк үскән саен, илдә яшәүчеләрнең һәркайсына товарлар һәм хезмәт күрсәтүләр күбрәк туры килә, һәм тормыш дәрәҗәсе күтәрелә. Әгәр дә халык саны җитештерүгә караганда тизрәк артса, уртача тормыш дәрәҗәсе түбәнәя.

Тулай эчке продуктның үсүе турында нинди күрсәткечләр нигезендә фикер йөртергә мөмкин булуын ачыклап үтү зарур. Икътисадчылар ике күрсәткечне аерып карый: күләме җитештерелгән продуктларның үзгәрешсез бәяләрендә күрсәтелгәндә, *реаль ТЭП*; күләме агымдагы бәяләрдә үлчәнгәндә, *номиналь ТЭП*.

ТЭПның реаль күрсәткечен исәпләгәндә, кагыйдә буларак, *инфляция* (бәяләрнең күтәрелүе) *дәрәҗәсенә* төзәтмә ясала, һәм ул фәкать реаль продукция чыгару үзгәрешләренә генә бәйле була.

Товарларга һәм хезмәт күрсәтүләргә бәяләр күтәрелгәндә, хәтта җитештерү дәрәҗәсе үзгәрешсез калса яисә төшсә дә, номиналь ТЭП (агымдагы бәяләргә нигезләнгән) та күтәрелергә мөмкин.

Әйтик, ел дәвамында номиналь ТЭП 200 миллиард сумнан 500 миллиард сумга кадәр үсте ди. Ләкин шул ук чорда бәяләр ике тапкыр арткан һәм 1 сумның сатып алу сәләте элеккенең яртысы кадәр генә калган. Монда ТЭП 250 миллиард сумга кадәр генә (500 миллиард сум : 2) күтәрелде дип әйтә алабыз. Мәсәлән, 1990 елдан 1999 елгача ТЭП күрсәткече 7 меңнән

күбрәк тапкырга артты. Шул чорда исә бәяләр 13750 тапкыр (ягъни ике тапкырга диярлек күбрәк) артты. Шулай итеп, реаль ТЭП ике тапкырга диярлек төште.

ТЭП күләме һәм динамикасы күрсәткечләре нигезендә гадәттә илдәге икътисади үсеш турында фикер йөрткәнлектән, реаль тулай эчке продукт күрсәткечләреннән файдаланырга кирәк.

Төрле үлчәгечләр ярдәмендә алынган икътисади мәгълүмат ил икътисадының үсешен анализлау, икътисади фаразлар эшләү өчен башлангыч материал булып тора. Әйтик, соңгы елларда Россиядә ТЭП үсешенең күзәтелгән уңай динамикасы (2001 елдан 2003 елгача бу күрсәткеч 5 тән 7,2%ка кадәр үсте) хөкүмәткә аннан соңгы ун елда ТЭПны ике тапкыр арттыру бурычын куярга мөмкинлек бирде.

Йомгаклап шуны билгеләп үтәргә кирәк: икътисади эшчәнлектә төп эш күрсәтүче затлар булып җитештерүчеләр һәм кулланучылар тора. Алар үз гамәлләре белән ничек итеп икътисади эшчәнлекнең максатларын һәм нәтиҗәлелеген тәэмин итүләре хакында сез киләсе параграфлардан белерсез.

ГАМӘЛИ ЙОМГАКЛАР

1 Икътисади белемнәр һәр кешегә кулланучы буларак та, хезмәткәр буларак та кирәк. Икътисади яктан белемле кеше товарлар сатып алу турында да, эшкә яллау турында да ничек карар кабул итәргә, бәяләр күтәрелү нәтиҗәләреннән ничек сакланырга, үзенең саклык акчаларыннан ничек файдаланырга, соңыннан эшсез калмас өчен нинди һөнәр сайларга кирәклеген дә белә.

Икътисади белемнәр һәм шул нигездә рациональ карарлар кабул итү осталыгы җитмәү икътисади эшчәнлектә катнашучы өчен муллык дәрәҗәсе төшүгә әверелә, финанс югалтуларына, һөнәри эшчәнлектән канәгатьсезлек тоюга, үзенең икътисади хокукларын белеп яклау мөмкинлекләре кыскаруга китерә.

2 Илебездә базар мөнәсәбәтләренең үсеше анда катнашучылардан яңа икътисади белемнәр үзләштерүне таләп итте, алардан башка уңышлы гамәли эшчәнлек, ресурсларның чикләнгәнлеге шартларында дөрес икътисади сайлау мөмкин түгел. Икътисад функцияләренең гомуми характерын аңлау анда катнашучыларга үз хуҗалык сәясәтен дөрес билгеләргә, предприятие эшчәнлегенең иң җайсыз чорларында да уйланылган хуҗалык карарлары кабул итәргә булыша.

3 Россиянең хәзерге заман икътисади үсеше сизелерлек дәрәҗәдә чиновниклар яисә сәяси эшлеклеләр эшчән-

легенә түгел, ә ил белән идарә итүдә гражданнарның актив катнашуына бәйле. Сайлаучы буларак, сезнең тавыш илнең икътисади сәясәтенә йогынты ясарга мөмкин, ә эшче яки кулланучы сыйфатындагы сайлап алуыгыз сезнең мул тормышыгызны гына түгел, тирәгездәге кешеләрнең ничек яшәвен дә билгеләячәк.

ДОКУМЕНТ

РФА академигы ***Л.И.Абалкинның*** Россия икътисади фикерләү мәктәбе үзенчәлекләре турында уйланулары (РФА Икътисад институты һәм Россия Ирекле икътисади җәмгыяте фәнни конференциясендәге нотыктан).

Дөнья үсешенең әйдәүче тенденциясенә әверелгән глобальләштерү икътисади, социаль һәм сәяси прогресс проблемаларын бетермәү генә түгел, күп очракта аларны кискенләштерә бара. Ул цивилизацияләрнең яисә формацияләрнең югары һәм түбән, алдынгы һәм артта калган принциплары буенча каршы куелуын юкка чыгара. Аларның һәркайсының үз уңайлыклары һәм өстенлекләре, үзкыйммәтләр системасы һәм прогрессны үзләренчә аңлаулары бар... Шуңа бәйле рәвештә фәндә Россия икътисади фикерләү мәктәбе аерым ролен һәм урынын уйдан кичерүгә тагын бер кабат әйләнеп кайтырга кирәк... Россия икътисади фикерләү мәктәбенең илебез фәнендә дә, бөтендөнья фәнендә дә үзбилгеләнешенә безнең илдә барлыкка килгән цивилизациянең үзенчәлеге һәм кабатланмаслыгы гаять зур йогынты ясады. Башка бер генә цивилизация дә, әлегә кадәр аз өйрәнелгән Азия цивилизациясе үзенчәлеген төшереп калдырып, Көнбатыштан шулкадәр аерылган карашларга, әхлакый кыйммәтләргә, әйләнә-тирә дөньяны һәм анда кешенең урынын кабул итүгә ия булмады. Моның мәдәнияттә һәм фәндә, бигрәк тә гуманитар фәндә чагылыш тапмый калуы мөмкин түгел иде. Көнбатышта әһәмиятсез буларак бөтен чикләүләрне бетерүче ап-ачык хакыйкать дип кабул ителгән нәрсә Россия икътисади фикерләвендә бөтенләй башкача, еш кына принципиаль үзгә яктан кабул ителә.

Хуҗалык дөньясы үз муллыкларын оптимальләштерүче индивидларның мәңгелек көрәше итеп түгел, ә бер-берсен тулыландыручы һәм шуның белән үзара баетылучы процессларның, оештыру рәвешләренең һәм идарә ысулларының катлаулы, баштан ук күп төсле комплексы буларак аңлатыла... Дәүләт базар тарафыннан кире кагылмый, ә аның

белән органик тәстә үрелеп бара, гомуми социаль муллык индивидуаль уңыштан югарырак куела.

Фән болай якын килүне үзенә сеңдерергә тиеш иде, һәм ул моны эшләгән урында аңа уңыш юлдаш булды. Әлеге кагыйдәдән читләшкәндә аны (һәм илне) уңышсызлык көтте. Соңгы унъеллыгын да кертеп, XX гасыр — моның ачык дәлиле.

Документка сораулар һәм биремнәр

1. Нигә автор Россия икътисади фикерләү мәктәбенең фәндәге ролен һәм урынын яңадан карарга кирәк дип саный? Бу фәнни мәктәпнең үзенчәлеге нәрсә белән билгеләнә? 2. Л.И.Абалкин фикеренчә, Россия цивилизациясен Көнбатыштан аермалы нинди карашлар, әхлакый кыйммәтләр, дөньяда кешенең урынын билгеләү характерлый? 3. Әлеге якын килүләрне икътисад фәне тарафыннан файдалану илнең икътисади үсешендә уңыш тәэмин итә алуы турында автор фикере белән килешергә мөмкинме? 4. Иң яңа тарих белеменнән һәм соңгы унъеллыкта Россиянең иҗтимагый-икътисади тормышы фактларыннан файдаланып, галимнең Россия галим-икътисадчылары эшләгән карашлардан һәм кыйммәтләрдән тайпылуның уңышсызлыкка китерүе турындагы фикерен раслаучы мисаллар китерегез.

ҮЗ-ҮЗЕҢНЕ ТИКШЕРҮ ӨЧЕН СОРАУЛАР

1. Икътисад фәненең барлыкка килүе ни белән бәйле? 2. Икътисад фәненең төп проблемалары нинди? Аларны атагыз һәм характерлагыз. 3. Макроэкономика һәм микроэкономика нәрсәне өйрәнә? 4. Табигать объектлары куллану әйберләренә әверелсен өченниләр кирәк? Әлеге процесста икътисади эшчәнлекнең роле нинди? 5. Тулаем эчке продуктны ничек үлчәргә һәм билгеләргә мөмкин? 6. Ресурслар чикле булганда, җитештерелүче продукция күләмен нинди ысуллар белән арттырырга мөмкин?

БИРЕМНӘР

1. Кытайда ТМП Франция ТМПыннан югарырак. Шул нигездә аның икътисадында хәлләр яхшырак диярге буламы? Җавабыгызны аңлатып бирегез.
2. «Икътисад фәне бүлекләре» таблицасын тутырыгыз.

Микроэкономика	Макроэкономика	Дөнья икътисады

Икътисад фәненең төрле өлешләре өйрәнә торган түбәндә санап кителгән проблемаларны таблицаның тиешле графасына язып куегыз: эшмәкәрлек килешүе төзү шартлары, халыкара валюта базары әйләнеше, җитештерүчеләр конкуренциясе, икътисади үсеш темпларының кимүе, товар базарында кулланучылар һәм җитештерүчеләрнең үзара хезмәттәшлеге, халыкара хезмәт бүленешенең тирәнәюе, халыкның эш белән мәшгульлеге, предприятиенең чыгымнары һәм рентабельлелеге, илләрнең тышкы сәүдә сәясәте, инфляция дәрәҗәсе һәм темплары, икътисади кризис сәбәпләре, нефть чыгару тармагында хезмәт хакының үсеше сәбәпләре.

3. Икътисадны җайга салуның нинди механизмы ресурсларны куллану күләменә һәм структурасына тиңдәш рәвештә, аның тармаклары буенча бүлүдә иң яхшы нәтиҗә бирә: базар (ирекле) бәяләр барлыкка килүме яисә бәяләрне директив (үзәкләштерелгән) рәвештә куюмы? Җавабыгызны дәлилләгез.

4. Икътисад фәне предметының иң төгәл билгеләмәсен сайлап алыгыз:

— матди байлыклар җитештерү һәм алмашу процессында кешеләрнең үз-үзен тотышын тикшерү;

— икътисади системаларның эшләве нәтиҗәлелеген күтәрү юллары турындагы фән;

— кешеләрнең даими үсә барган ихтыяҗлары шартларында матди байлыклар җитештерү өчен җәмгыятьнең чикләнгән ресурсларыннан файдалануны өйрәнүче фән;

— кешеләрнең көндәлек эшлекле тормыш эшчәнлеге һәм яшәү өчен чаралар булдыруы турындагы фән;

— җитештерелүче икътисади байлыкларны бүлү ысулларын һәм критерийларын тикшерү.

ЗИРӘКЛӘР ФИКЕРЕ

«Икътисад — чиксез ихтыяҗларны чикле ресурслар ярдәмендә канәгатьләндерү сәнгате ул».

Л.Питер (1919–1989), Америка язучысы

§ 2. Икътисади күтәрелеш һәм үсеш

Икътисади күтәрелеш җәмгыять һәм кеше үсешенә ничек йогынты ясый? Икътисади үсеш икътисади күтәрелештән ничек аерыла? Нигә икътисад цикллап үсә?

ИКЪТИСАДИ КҮТӘРЕЛЕШ ТӨШЕНЧӘСЕ

Менә инде берничә гасыр буена икътисадчы галимнәр икътисади күтәрелеш проблемалары белән якыннан кызыксыналар. Нигә? Чөнки икътисади үсешкә илнең бай булуы һәм чәчәк атуы гына түгел, һәр кешенең керемнәре һәм муллыгы да бәйле.

Икътисади күтәрелеш — бу теләсә-кайсы дәүләтнең төп максатларыннан берсе, шул ул вакытта икътисад һәм җәмгыять прогрессының иң мөһим критерие.

Нәрсә соң ул икътисади күтәрелеш?

Икътисади күтәрелеш — реаль ТЭПның абсолют күрсәткечләрдә дә, илнең һәр кешесенә исәпләгәндә дә озак вакытлар буе арта баруы.

Бу билгеләмәдә бик мөһим өч нәрсәне ассызыклап күрсәтергә кирәк:

беренчедән, фәкать реаль ТЭПны гына күздә тоту зарур, чөнки номиналь ТЭП үсә барса да, инфляция, димәк, бәяләр дә тизрәк үсәргә мөмкин; нәтиҗәдә, инде белгәнегезчә, реаль ТЭПның хәтта кимүе дә ихтимал;

икенчедән, ТЭПны абсолют күрсәткечләрдә генә түгел, җан башына да исәпләргә кирәк, чөнки халык саны ишәйгәндә ТЭПның абсолют күләме арта барса да, һәр кешегә исәпләгәндә ул кимрәк туры килергә мөмкин;

өченчедән, ТЭПның озак вакыт эчендә артуын гына икътисади күтәрелеш дип санап була. Мәсәлән, XX гасырның 90 нчы елларында базар мөнәсәбәтләренә күчү барышында реаль ТЭП кимеде (бер елга 75 % чамасы), ләкин 1997 елда ул үсә төште, ә 1998 елда яңадан кимеде. Мондый сикерешләрне икътисади күтәрелеш дип атап булмый. Россиядә икътисади күтәрелеш 1999 елда башланды һәм хәзергәчә дәвам итә, дип исәпләргә мөмкин. Әмма аның темплары тигез түгел әле: әйтик, 1999 елда ТМП 5,4 % ка калыкты, 2000 елда — 9 % ка, 2001 елда — 5,1 % ка, 2002 елда — нибары 4,3 % ка, 2003 елда — 7 % ка үсте.

Икътисади күтәрелеш процентларда чагылдырылган уртача еллык ТМП үсеш темплары белән үлчәнә. Кыскача әйткәндә, бу күрсәткечне еш кына ТЭПның үсеш темплары, дип атыйлар. Билгеле бер елга үсеш темпын исәпләп чыгару өчен бу елга реаль ТЭПны алырга, аңардан алдагы ел реаль ТЭПын алып ташларга кирәк — шул елга реаль ТЭП үсеше килеп чыга. Хәзер аны алдагы ел ТЭПына бүләбез дә, 100% ка тапкырлыйбыз.

Мәсәлән, бу елда реаль ТЭП 210 миллиард доллар булды ә аннан алдагы елда — 200 миллиард доллар иде, димәк

$\frac{(210 - 200)}{200} \cdot 100\% = 5\%$. Бу елда икътисади күтәрелеш 5% тәшкил итте.

Ләкин күтәрелеш темпы үзе генә берни хакында да сөйләми. Әйтик, бу елда реаль ТЭП 2010 миллиард доллар тәшкил итте, ә аннан алдагы елда — 2000 миллиард доллар иде, ягъни арту шулай ук 10 миллиард булды. Әмма ул елда икътисади күтәрелеш $\frac{(2010 - 2000)}{2000} \cdot 100\% = 0,5\%$ кына була.

Хәтта бу шартлы мисалдан да ил никадәр бай булган саен, аның еллык үсеш темплары шулкадәр ким булуы күренә. Әгәр безнең икенче мисалда еллык үсеш темпы 5% булса, ТЭПның еллык үсеше 10 миллиард түгел, ә 100 миллиард доллар булыр иде.

Шулай да тарихта күтәрелә баручы икътисадлы һәм югары үсеш темплы илләрнең иң бай илләрне дә узып китүе мәгълүм. XVIII гасырда Англия — ул чактагы «дөнья остаханәсе» — иң бай ил була, әмма XIX гасыр башына АКШ аны җан башына реаль милли керем күрсәткече буенча куып җитә, ә соңрак узып та китә.

Хәзерге вакытта нык үскән илләрнең күтәрелеш темплары 2–3% тәшкил итә, ә кайбер үсә баручы илләрдә ул — 5–7%. Үсә баручы илләр ТЭП дәрәҗәсе буенча бай илләрне узып китәргә мөмкинме?

ТЭПның абсолют зурлыгы күрсәткечен алып карасак, узарлар кебек, ә җан башына исәпләгәндә — бик шикле. Мәсәлән, ТЭП күләме буенча Һиндстан Даниядән 1,7 тапкыр алдарак, ә җан башына исәпләгәндә Даниядә ТЭП 84 тапкыр күбрәк. Һиндстанда ТЭПның үсеш темплары узган гасырның 90 нчы елларында уртача 6,5% булды, Даниядә исә ул 2,4 % кына тәшкил итте. Дания халкының саны ун елда үзгәрмәде, шул ук вакытта Һиндстанда бу чорда халык 20%ка артты. Бу, әлбәттә, тормыш дәрәҗәсендә һәм сыйфатында чагылыш тапты. Мәгариф, керемнәр (ТЭП) һәм гомер озынлыгы индексларыннан уртача арифметик зурлык буларак билгеләнүче кеше индексы 1999 елда Дания өчен 0,921 булды, ә Һиндстанда ул 0,571 тәшкил итте (чагыштыру өчен: Россиядә — 0,775, АКШта — 0,934).

Ахыр чиктә икътисади күтәрелешнең максаты — кешеләрнең, һәркемнең тормышын яхшырту, анда да тормышның дәрәҗәсен генә түгел, сыйфатын да күтәрү.

Хәзер, икътисади күтәрелеш төшенчәсен, аның максатларын һәм төп күрсәткечләрен билгеләгәч, безгә икътисади күтәрелешнең тизләнүенә ничек ирешеп булуын, илне ничек баетырга икәнлеген ачыкларга кирәк. Башкача әйткәндә, икътисади күтәрелешкә нинди факторлар йогынты ясый.

ИКЪТИСАДИ КҮТӘРЕЛЕШ ФАКТОРЛАРЫ

Барыннан да элек җитештерү факторларын искә төшерик. Болар — *җир* (киңрәк алганда — барлык табигать ресурслары), *хезмәт* һәм *капитал* — һәм аларның җитештерүне үстерүгә, димәк, икътисади күтәрелешкә дә ничек этәргеч бирүләрен карыйк.

Табигать ресурсларыннан башлыйк. Алар — авыл хуҗалыгы өчен файдаланылучы җирләр, файдалы казылмалар һәм бигрәк тә энергетика ресурслары; болардан башка икътисад үсә алмый. Әлбәттә, дөньяда мондый ресурслары шактый булган илләр бар (Россия, АКШ, Кытай һ.б.), табигать ресурслар бирмәгәннәре дә бар (Япония, Европаның Дания, Нидерланд кебек кечкенә илләре һ.б.). Бу — илләрнең беренчеләре чәчәк ата, ә икенчеләре хәерчелектә яши дигән сүзме? Алга таба күрербез — һич тә алай түгел.

Хезмәт — җитештерүнең бик мөһим факторы; башка факторларның ничек кулланылуы аңа бәйле. Җәмгыятьтә хезмәткә сәләтле күпсанлы, ләкин түбән квалификацияле халык булырга мөмкин, димәк, эшләүчеләрнең хезмәте аз җитештерүчән булачак (югары квалификацияле хезмәт һәрчак күбрәк җитештерүчән).

Җитештерү факторы буларак, капитал җитештерү процессында кулланылучы җиһазлардан, бина һәм корылмалардан, запаслардан тора. Икътисадта нинди тармакларга өстенлек бирелә, алар ничек коралланган, алдынгы технологияләрдән файдаланалармы, хезмәтне оештыруның алдынгы ысуллары кертелгәнме — ахыргы нәтиҗәләр шуларга бәйле.

ЭКСТЕНСИВ ҺӘМ ИНТЕНСИВ ҮСЕШ

Икътисади күтәрелешкә ике юл белән ирешергә мөмкин: экстенсив һәм интенсив үсеш.

Экстенсив үсеш — ТЭПны ресурслардан файдалану масштабларын киңәйтү исәбенә арттыру.

Бу җитештерүгә илдә булган, әмма әле файдаланылмаган ресурслар җәлеп ителә дигән сүз. Җир кебек җитештерү факторын алып карыйк. Мәгълүм ки, уңдырышлы җирләр чикле генә. Ләкин алар барысы да авыл хуҗалыгы әйләнешенә кертелмәгән. Тарихтан билгеле, АКШта, мәсәлән, җирләрне басып алу шактый озак барган, бу илнең икътисади күтәрелешенә этәргеч биргән. XX гасырның 50 нче елларында СССРда чирәм һәм яткын җирләрне үзләштерү алып барылды.

Файдалы казылмаларның иске ятмалары ахыргача файдаланылмый, әмма булган техника аларны тулы эшкәртергә

мөмкинлек бирми, әйләнешкә яңа ятмалар кертелә. Болар икътисадның экстенсив ысул белән үсүен күрсәтә.

Хәзер болай дип күз алдына китерик: безнең бер заводыбыз бар, ләкин без ниндидер товар җитештерүне ике тапкыр арттырырга телибез. Моның өчен без яңа завод төзибез, аңа шундый ук җиһазлар куябыз, шул ук кадәр сандагы эшчеләр хезмәтеннән файдаланабыз һәм, иске завод продукциясенә өстәп, шулкадәр үк продукция алабыз. Күргәнебезчә, берни дә үзгәрми: шундый ук җиһазлар кала, җитештерү һәм капиталны кайтарыш шул ук дәрәҗәдә, ләкин, алдан уйланылганча, товарның саны ике тапкыр арта (җитештерүне гади киңәйтү исәбенә). Монысы да — җитештерүне экстенсив үстерү. Ләкин хезмәт һәм капитал — шулай ук чикләнгән ресурслар, шуңа күрә икътисади күтәрелешнең яңа юлын эзләргә кирәк, һәм мондый юл бар. Ул — интенсив икътисади күтәрелеш.

Интенсив үсеш — ТЭПны җитештерү факторларын сыйфат ягыннан яхшырту һәм аларның нәтиҗәлелеген күтәрү исәбенә арттыру. Бу җитештерү факторлары фәнни-техник прогресс, хезмәткәрләрнең квалификациясен күтәрү, хезмәт җитештерүчәнлеген үстерү һәм ресурсларны рациональ бүлү йогынтысы астында сыйфат үзгәрешләренә дучар ителергә тиеш дигән сүз.

Интенсив үсешнең беренче, иң мөһим факторы — *фәнни-техник прогресс* (ФТП), ул икътисадның һәм җәмгыять тормышының бөтен якларына кагыла. Узган гасырның 80 нче елларында ФТП аеруча нык үсте, электрон революция булды (аны XVIII—XIX гасырлардагы сәнәгать борылышы һәм электр революциясе белән чагыштырыгыз). Электроника һәм информатика кешенең мөмкинлекләрен кискен күтәрә, хезмәт җитештерүчәнлеген арттыра, технологияләрне үзгәртә, табигатьтә булмаган яңа продуктлар һәм хәтта яңа ресурслар булдыра.

ФТП җитештерүнең башка факторларына да йогынты ясый.

Җитештерү факторы буларак, җиргә яңадан әйләнеп кайтыйк. Моннан 100–150 еллар элек авыл хуҗалыгында халыкның күпчелек өлеше (70%ка кадәр һәм аннан артык) мәшгуль була, ә хәзер нык үскән илләрдә авыл хуҗалыгы белән шөгыльләнүче 2–3% халык бөтен илне азык-төлек белән тәэмин итә.

Бу ни турында сөйли? Барыннан да элек хезмәт җитештерүчәнлегенең гаять зур үсеше хакында. Хәтта Европаның чагыштырмача кечкенә сөрү җирләренә ия илләре дә авыл хуҗалыгы продуктларын экспортка чыгара.

Россия кебек зур илне Европаның кечкенә бер иле, мәсәлән, Дания белән чагыштырыйк. 2002 елда без җан башына 237 кг бодай җитештердек, ә Дания — 878 кг; бодай уңышы бездә гектардан 19,6 центнер булды, ә Даниядә — 70,3 центнер.

Дөньяда бу культураның иң югары уңышы — гектардан 87,4 центнер — Нидерландта. Россия авыл хуҗалыгында хезмәт җитештерүчәнлегенең аларныкыннан нибары 1,3% тәшкил итүе бер дә гаҗәп түгел. Моннан күренгәнчә, бездә авыл хуҗалыгында хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрергә, агротехниканың алдынгы ысулларыннан, нык үскән илләрдә тупланган тәҗрибәдән файдаланырга кирәк.

ФТП физик капиталга, ягъни җитештерү чараларына гаять зур йогынты ясый. Теләсә нинди предприятиенең уңышлы эшләве җиһазлардан, технологиядән, чималдан, энергетикадан тора, ә сәнәгать предприятиеләре икътисадның нигезен тәшкил итә. Күп кенә чимал һәм энергетик продукция төрләре җитештерү буенча без дөньяда алдынгы урыннарда. Әйтик, 2000 елда без табигый газ җитештерү буенча беренче урында; нефть, соры күмер чыгару, төзелеш кирпече җитештерү буенча — икенче; электр энергиясе, чуен коюю, корыч, тимер рудасы һәм киҗе-мамык тукымалар җитештерү буенча дүртенче урында идек. Чимал тармакларында шундый күрсәткечләребезнең очраклы булмавы аңлашыла — илебез табигать ресурсларына бай. Ләкин без ФТП белән тыгыз бәйләнештәге иң яңа, югары технологияле өлкәләрдә сизелерлек калышабыз әле (безнең экспортта югары технологияле продукция өлеше, АКШта 44% булганда, нибары 3 % тәшкил итә).

Интенсив үсешнең икенче мөһим факторы — *хезмәткәрләрнең квалификацияләрен күтәрү*. Хезмәткәрнең белеме бик зур роль уйный башлады. Әгәр конвейер җитештерүендә берничә сәгать эчендә хәтта белемсез кешене дә иң гади операциягә өйрәтеп булса, хәзер андый хезмәткәрне заманча җитештерүгә һәм кыйммәтле, югары технологияле җиһазларда эшләргә тартып булмый.

Хәтта «кеше капиталы» дигән категория дә барлыкка килде, ягъни кешеләрнең уку барышында һәм эшләгәндәге тәҗрибәсе нәтиҗәсендә тупланган белемнәре һәм осталыклары үзе бер байлыкка әверелә. Шуңа да кеше капиталына акча салу хәзер физик капиталга (җиһазлар һәм инструментларга) инвестицияләрдән дә мөһимрәк. Һәм бу дөрес тә, чөнки югары технологияле җиһазларда яхшы белем алган кешеләр генә эшли ала. Шуны исәпкә алып, күп кенә нык үскән илләрдә мәктәпләрдә укыту унике ел алып барыла, ә кул көчен күп таләп итүче һәм «пычрак» (экология күзлегеннән караганда) производстволар хезмәткәрләре түбән квалификацияле, үсешендә артта калган илләргә чыгарыла.

Интенсив үсешнең өченче факторы — *ресурсларны рациональ булу* — икътисади күтәрелеш барышында капитал һәм эш көче аз нәтиҗәле тармаклардан югары нәтиҗәле

өлкәләргә күчә. Икътисадның структур үзгәртеп корылуы бара: фәнне күп кулланган тармаклар икътисадта әйдәп баручы урынга чыга, ә традицион тармаклар җиһазларны һәм технологияләрне камилләштерү аркасында зуррак җитештерүчәнлеккә ирешә, һәм нәтиҗәдә бу тармакларның уңышлы эшләве өчен кирәк булган ресурслар күләме кыскартыла.

Дүртенче фактор — *эш масштабында экономияләү*. Моның асылы шунда ки, эре предприятие берничә вак предприятиедән нәтиҗәлерәк эшли. Димәк, сатуны яхшыртуга, рекламага һәм башка ихтыяҗларга чыгымнарны күбрәк тотарга мөмкин, нәтиҗәдә җитештерү арта бара.

Интенсив икътисади күтәрелешнең төп факторлары шундый.

ИКЪТИСАДИ ҮСЕШ

Мәгълүм булганча, илләр төрлечә үсә, шуңа да аларны төркемнәргә бүләргә мөмкин: нык үскән илләр, икътисади күчештә булган илләр, үсә баручы илләр. Үсеп баручы илләр арасында үсештә артта калган илләр төркемен аерып карыйлар. Бай һәм ярлы илләр арасындагы аерма бик зур. XXI гасыр башына нык үскән илләрдә җан башына ТЭП күрсәткече елга уртача 25 мең доллардан күбрәк тәшкил итте, ә иң аз үскән илләрдә ул 255 доллардан бераз гына күбрәк булды. Күргәнебезчә, аерма 100 тапкыр диярлек.

Шундый раслама яшәп килә: «Ярлы илләр үзләренең ярлылыгы аркасында ярлы булып кала бирә». Нәрсә дигән сүз бу? Халыкның кереме түбән булу (бер кешегә көнгә 1 доллардан да кимрәк) ихтыяҗның түбән булуын гына түгел, саклык акчаларының бөтенләй булмавын күрсәтә, димәк, физик һәм кеше капиталына инвестицияләр кертелми, шуның нәтиҗәсендә җитештерүчәнлек дәрәҗәсе түбән булып кала. Хәтта ТЭПның үсүе күзәтелсә дә, халыкның керемнәре артмый, чөнки халык саны тагын да тизрәк темпларда үсә. Мондый вазгыять *«ярлылыкның котылгысыз даирәсе»* дигән исем алды.

Шуңа да без, икътисади күтәрелеш һәм аның интенсив үсеше турында сөйләгәндә, нык үскән илләрне күздә тотабыз. Үсеп баручы илләр өчен «икътисади үсеш» термины кулайрак.

Икътисади үсеш — ул илнең хуҗалык тормышындагы тамырдан үзгәрешләр, икътисад структурасындагы үзгәртеп корулар. Күпчелек очракларда үсеп килүче илләрдә авыл хуҗалыгы җитештерүе өстенлек итә, сәнәгать юк диярлек, халыкның күпчелеге авыл җирләрендә яши. Бу илләрнең икътисади үсеш максатлары һәм бурычлары икътисади

күтәрелеш максатларыннан аерылып тора. Алар әле сәнәгать, инфраструктура булдырырга, шәһәрләр салырга, ә иң мөһиме — күпчелеге укый-яза белмәгән халыкны укытырга тиеш булалар.

Дөрес, XXI гасырда бу халыклар ялгыз түгел, аларга Бөтендөнья банкы, Халыкара валюта фонды һ.б. халыкара оешмалар ярдәм итә. Соңгылары икътисади үсеш максатларын гамәлгә ашырырга финанс ресурслары юнәлтәләр, акчаларның башка максатларда кулланылуына юл куймыйлар. Халыкта әйтелгәнчә, кешегә ярдәм итәргә теләсәң, аңа балык түгел, кармак бир, шулай итсәң, ул ачка үлми.

Үсеше зәгыйфь булган илләр ярлылык богавын өзә алалармы? Әгәр дә илнең икътисади үсеш максатларын аңлап, үз эчке чыганаклары нигезендә керемнәрнең, саклык акчаларының, инвестицияләрнең һәм хезмәт җитештерүенең артуына ирешергә омтылсалар, ә үзләрен «бай агайлар» ашатканны көтеп кенә ятмасалар, хәерчелектән котыла алалар.

ИКЪТИСАДИ ЦИКЛ

Икътисади күтәрелеш билгеләмәсеннән күренгәнчә, ул озакка сузылган булырга, ягъни иң яхшысы — ТЭП даими арта барырга тиеш. Ләкин реаль икътисадта болай булмый: җитештерүнең һәм эш активлыгының күтәрелеше җитештерүнең төшүе, ТЭПның кимүе белән алмашына, аннары икътисад яңадан үсә. Шулай итеп, икътисад цикллап үсә. Җитештерүнең кискен төшүе, инде үзегез белгәнчә, «икътисади кризис» дип атала.

Тәүге икътисади кризис 1825 елда Англиядә булды, ә 1857 елгы цикллы кризис, беренче буларак, дөньяның барлык әйдәп баручы илләренә кагылды, бөтендөнья кризисына әверелде. Аннан соң кризислар даими төстә булып торды. Алар җитештерүнең кискен кимүе, күп кенә предприятиеләрнең бөлгенлеккә төшүе, эшсезлек дәрәҗәсенең үсүе, халыкның сатып алу сәләте төшү белән характерланды. Иң түбән ноктага җиткәч, икътисад акрынлап кризистан чыга башлый: җитештерү үсә, эшсезлек кими, керемнәр, ихтыяҗ һәм тәкъдим арта, икътисад яңадан «кыза башлый» (ягъни җитештерү һәм куллану үзенең максимумына җитә), һәм бу янәдән чираттагы кризиска китерә. Икътисад шундый цикллар белән үсә.

Нәрсә соң ул икътисади цикл?

Икътисади цикл — реаль ТЭП хәрәкәтендә күтәрелүләрнең һәм төшүләрнең чиратлашып баруы ул.

Икътисади цикл эзлекле төстә бер-берсен алмаштыручы дүрт фазадан тора.

Беренче фаза — *икътисади күтәрелеш*, ул актив халыкның тулысынча диярлек эш белән мәшгульлеге, барлык товар һәм житештерүнең хезмәт күрсәтүләрнең даими киңәюе, керемнәрнең артуы, димәк, ихтыяжларның да киңәюе белән характерлана. Житештерүнең барлык күрсәткечләре иң югары ноктага житә. Кайсыдыр бер мизгелдә тулай тәкъдим тулай ихтыяжны уза башлый. Житештерүчеләр үз товарларын сата һәм кредиторлары чимал куючылары белән исәп-хисап ясый алмыйлар, банкротлыкка чыгу башлана. Кулланучылар эшсез калудан курка һәм үз чималларын киметәләр. Сәүдә сату өчен яңа товарлар алмый, сәнәгать житештерүне киметә һәм ресурсларга ихтыяж күрсәтми. Бу — артка китүнең башы.

Икенче фаза — *икътисади төшү* яисә *рецессия*, ул житештерүнең һәм куллануның, керемнәр һәм инвестицияләрнең кимүе ТЭП дәрәжәсенең тагын да төшүе белән үзенчәлекле. Ниһаять, барлык күрсәткечләр иң түбән ноктага житә — кризис башлана.

Өченче фаза — *депрессия*; монда инде икътисад төпкә төшеп, бер урында таптана башлый, чөнки ул акрынлап көч җыйсын өчен вакыт кирәк була.

Дүртенче фаза — *терелә башлау*, ул житештерүнең акрынлап арта баруы белән характерлана, чөнки ихтыяж үсә, сәнәгать өстәмә эш көче җәлеп итә башлый, сәүдә һаман саен күбрәк товарлар сорый, халыкның һәм эшмәкәрләрнең керемнәре үсә. Бу фаза барлык күрсәткечләр элеккеге күтәрелеш фазасының иң югары ноктасына житкәнче дәвам итә, аннан соң яңа күтәрелеш һәм яңа икътисади цикл башлана.

Икътисади циклның дәвамлылыгы нинди соң?

Бу бик мөһим сорау һәм ул икътисадчы-теоретикларны гына түгел, сәясәт эшлеклеләрен, һөнәр берлекләре лидерларын һәм эшмәкәрләрне да кызыксындыра. Әгәр дә кризис башлануын алдан белеп торсаң, аны әзерләнеп каршыларга мөмкин булыр иде. Әмма, кагыйдә буларак, кризислар кискен генә башланып китә.

XIX гасырда цикл якынча сигез–ун елны тәшкил итте: кризислар 1825, 1836, 1847, 1857, 1866, 1877, 1882 һәм 1890 елларда күзәтелде. К.Маркс циклларның мондый чорларга бүленүенең нигезендә төп капиталны алмаштыру ята, дип саный. Соңгысы ул чорда якынча ун ел хезмәт итә. Кризис, бер яктан, төп капиталны яңартуга этәргеч бирә, ә икенче яктан, яңартылган нигездә күтәрелеш фазасына кызыксындыра. Шуның өстенә ун ел буе техник прогресс бер урында гына тормый, димәк, җиһазлар физик яктан гына түгел, мораль яктан да тузган, ягъни искергән була, техниканың яңа дәрәҗәсенә туры килми.

XX гасырда цикллар кыскара, кризислар, бигрәк тә Икенче бөтендөнья сугышыннан соң, — кискенлеген киметә.

XX йөздә иң дәвамлы һәм җимергеч кризис 1929—1933 елларда булды һәм «Бөек депрессия» дигән исем алды. АКШта җитештерүнең төшүе дүрт ел рәттән дәвам итте, реаль ТЭП 40 % ка төште, җан башына керем 30 % ка кимеде, һәр дүртенче кеше эшен, ә күпләр, түләргә мөмкинлеге булмаганга, торакларын да югалтты. Сәнәгать тармагы бигрәк тә зур зыян күрде. Мәсәлән, чуен җитештерү буенча иң түбән ноктада АКШ 42 елга (1890 ел дәрәҗәсенә), Англия — 76 елга (1856 ел дәрәҗәсенә), Германия 45 елга (1887 ел дәрәҗәсенә) артка чигенде.

Хәзерге заман кризислары алай ук тирән түгел: җитештерүнең төшүе уртача 10–12 ай дәвам итә, ә реаль җитештерүнең кыскаруы 1,5 % тан 5 % кача тәшкил итә (АКШ күрсәткечләре). АКШта икътисади чигенүләр 1973–1975, 1979–1980, 1981–1982, 1990–1991 елларда булды. АКШта иң озын күтәрелеш чоры 1982 елдан 1990 елга кадәр барды, ә иң кыскасы — 1980 елдан 1981 елгача булды.

Икътисадның циклы үсү сәбәпләре нидә соң? Икътисадчылар арасында бу сорауга да анык кына җавап юк.

Кайбер галимнәр икътисади циклларны *тышкы (экзоген) сәбәпләр* белән аңлата:

сугышлар — алар аркасында икътисад хәрби продукция җитештерүгә яраклаша, өстәмә ресурслар һәм эшче көчләр җәлеп ителә, ә хәрби хәрәкәтләр тәмамлангач, түбән төшү башлана;

ниндидер башка тышкы факторлар йогынтысы — мәсәлән, «нефть шогы» дип аталган нәрсә аркасында, ул чакта нефть чыгаручы илләр бер картель — ОПЕКка берләште һәм нефтькә бәяне кискен күтәрде, шуның белән сугыштан соңгы чордагы иң зур — 1973—1975 еллардагы бөтендөнья кризисын китереп чыгарды, бу вакытта АКШта җитештерүнең төшүе 16 ай дәвам итте һәм 5 % тирәсе булды;

инвестициягә, җитештерүгә, кулланууга, бәяләр дәрәҗәсенә зур йогынты ясаучы эре яңалыклар (тимер юл барлыкка килү, автомобильләр, электроника);

хәтта Кояштагы таплар да — алар авыл хуҗалыгы культуралары уңышына йогынты ясый, ә уңыш булмау бөтен икътисадта кризиска китерергә мөмкин.

Башка икътисадчылар икътисади циклларны *эчке (эндоген) факторлар* белән аңлата:

хөкүмәтнең монетар (акча) сәясәте белән; акчаның күп булуы инфляция ыргылышы тудыра, ә аның аз булуы инвестицияләрне кыскарта һәм җитештерүнең төшүенә китерә;

тулаем тәкъдим һәм тулаем сорау чагыштырмасының үзгәрүе белән; бу очракта бөтенләй башка төр товарлар (мәсәлән, персональ компьютерлар) барлыкка килә, һәм ихтыяҗ аларга күчә, ә иске товар җитештерүчеләргә (бу очракта — язу машинкалары) производствоны ябарга һәм ресурсларны башка тармакларга юнәлтергә туры килә;

җитештерүне товар продукциясен кирәгеннән артык җитештерү аркасында килеп чыккан кыскарту белән; сорау аз булу яки бәяләр югары куелу аркасында зур запаслар туплана; сәүдә, аларны сата алмаганлыктан, бу товарлардан баш тарта, ә тулай тәкъдим тулай сораудан артып китә.

Икътисади циклларның сәбәпләре нидә генә булса да, алар икътисадка йогынты ясауларын дәвам итә. Дөрес, бу йогынты хәзерге заман базар икътисадында элеккеге кебек җимергеч түгел. Дәүләт һәм эре бизнес икътисади циклга тәэсир итәргә өйрәнде. Нык үскән илләрнең хөкүмәтләре циклларга каршы ярашу ысулларын куллана, шуның белән үсешнең иң югары нокталарын тигезли һәм икътисадка төпкә төшеп җитәргә ирек бирми. Эре бизнес маркетинг ярдәмендә теге яки бу товарга сорауның озакка исәпләнгән тенденцияләрен ачыклый һәм кирәгеннән артык җитештерүгә юл куймый.

Икътисади цикллар, бигрәк тә кризис фазасы эшсезлек һәм инфляция кебек тискәре күренешләргә китерсә дә, уңай яклар да бар: нәкъ менә кризис тулаем ихтыяҗны һәм тулаем тәкъдимне туры китерергә, яшәүгә иң сәләтле фирмаларны ачыкларга һәм икътисадны үстерүне яңа техник нигездә дәвам итәргә мөмкинлек бирә.

ГАМӘЛИ ЙОМГАКЛАР

1 Сезнең киләчәк керемнәрегез һәм мул тормышыгыз башлыча илдәге икътисади күтәрелеш темпларына бәйле, ә соңгысы шактый дәрәҗәдә «кеше капиталы» сыйфаты, ягъни кешеләрнең уку һәм гамәли тәҗрибә өстәү барышында тупланган белемнәре һәм осталыгы белән билгеләнә. Шуңа да хезмәтне камилләштерү, аның җитештерүчәнлеген һәм нәтиҗәлелеген арттыру өчен үз белемнәреңне һәм осталыгыңны киңәйтү зарурлыгы күренеп тора.

2 Илдәге базар икътисадының үсеше, аның цикллы характеры һәм килеп чыгучы икътисади кризисларның сәбәпләре белән бәйле икътисади процессларның мәгънәсен аңлау сезгә икътисади эшчәнлектә белеп катнашырга гына түгел, дәүләтнең икътисади сәясәтенә дөрес бәя бирергә,

аның икътисадка, җәмгыятьнең социаль тормышына йогынтысын аңларга да мөмкинлек бирер.

3 Базар икътисадының цикллы үсешен, аның тискәре нәтиҗәләрен белеп, реаль вазгыятьтә социаль-һөнәри яраклашуга әзер булырга кирәк.

ДОКУМЕНТ

Беренче икътисади кризислар замандашы, *немец философы һәм икътисадчысы* **Фридрих Энгельсның** «Анти-Дюринг» дигән хезмәтеннән.

...Беренче гомуми кризис башланган 1825 елдан башлап бөтен сәнәгать һәм сәүдә дөньясы, барлык цивилизацияле халыкларның теге яки бу дәрәҗәдәге җитештерүе һәм алмашуы үзенең кыргый өстәмәләре белән бергә якынча ун елга бер тапкыр рельслардан чыгып ычкына. Сәүдәдә торгынлык башлана, базарлар сатылмаган продуктлар массасы белән тула, кулдагы акчалар әйләнештән юкка чыга, кредит бирү туктатыла, фабрикалар туктап кала, эшчеләр барлык яшәү чараларыннан мәхрүм ителә, чөнки алар әлеге чараларны кирәгеннән артык җитештергән була; бөлгенлек арты бөлгенлек килә, аукцион арты аукцион уздырыла. Торгынлык еллар буена сузыла, җитештерүче көчләр массасы исраф ителә һәм юкка чыгарыла; бу исә тупланган товар массасы түбәнәйтелгән бәяләр буенча биреп бетерелгәнгә, ниһаять, җитештерү һәм алмашу хәрәкәте акрынлап яңартылганга кадәр дәвам итә. Аз-азлап әлеге хәрәкәт тизләнә, адымнар юыртуга әверелә, сәнәгать юыртуы сикертеп чабуга күчә, ул үз урынын котырган чабышка, сәнәгатьне, сәүдәне, кредитны һәм алыпсатарлыкны эченә алган чын бәйгегә әйләнә, ахыр чиктә янәдән төпсез чокырга барып төшә. Һәм һаман шулай кабатлана. 1825 елдан соң без инде бу әйләнешне биш тапкыр кичердек һәм хәзер (1877 елда) моңа алтынчы кат кердек.

Документка сораулар һәм биремнәр

1. XIX гасыр кризислары нәрсә белән характерлана? **2.** Ул кризисларның эзлеклелеге нинди? **3.** Параграф текстында искә алынган икътисади цикл фаразларын исегезгә төшерегез. Автор аларны, ат чабышы белән чагыштырып, ничек образлы характерлый?

ҮЗ-ҮЗЕҢНЕ ТИКШЕРҮ ӨЧЕН СОРАУЛАР

1. «Илнең икътисади күтәрелеше» нәрсә ул, һәм аны ничек үлчиләр? **2.** Экстенсив һәм интенсив үсеш факторларын атагыз. **3.** Икътисади күтәрелеш икътисади үсештән ни белән аерыла? **4.** Нәрсә ул «ярлылыкның котылгысыз даирәсе»? **5.** XIX гасыр кризислары XX гасыр кризисларыннан нәрсә белән аерыла? **6.** Дәүләт икътисади циклга ничек йогынты ясый ала?

БИРЕМНӘР

1. Түбәндә китерелгән таблицада сез Советлар Союзының элеккеге республикалары халкының тормыш дәрәҗәсен характерлаучы индексларны табарсыз. Бу илләрнең кеше үсеше индексын исәпләп чыгарыгыз һәм Россия күрсәткечләре белән чагыштырыгыз.

Ил	Гомер озынлыгы индексы	Белем дәрәҗәсе индексы	ТЭП индексы	Кеше үсеше индексы
Россия	0,69	0,92	0,72	0,775
Латвия	0,75	0,93	0,69	
Молдавия	0,69	0,90	0,50	
Украина	0,72	0,92	0,59	
Азәрбайҗан	0,77	0,88	0,56	
Кыргызстан	0,71	0,87	0,54	

(Россия һәм дөнья илләре. М.: Госкомстат, 2002. 100 б.)

2. Икътисади күтәрелеш нәтиҗәләрен тикшерүчеләр аның мондый нәтиҗәләрен билгеләп үтәләр:

а) илнең оборона сәләте ныгый;
б) тормыш дәрәҗәсе яхшыра;
в) икътисад уңышлы үсә;
г) экология начарлана;
д) квалификация дәрәҗәсе үсә.

Кайсы раслама дөрес түгел һәм нигә?

3. Түбәндә Яңа Зеландиянең 10 еллык ТЭП динамикасы китерелә (аннан алдагы елга карата процентларда). Әлеге күрсәткечләр буенча циклның нинди фазалары турында фикер йөртергә мөмкин һәм аларның озынлыгы нинди?

1990 ел	1995 ел	1996 ел	1997 ел	1998 ел	1999 ел	2000 ел
100,0	103,7	103,1	102,6	99,6	104,1	102,0

4. Дөрес җавапны сайлап алыгыз. Циклның озынлыгын түбәндәгечә санарга кирәк:

а) алдагы күтәрелешнең иң югары ноктасыннан аннан соңгы күтәрелешнең иң югары ноктасына кадәр;
б) күтәрелеш башланудан рецессия ахырына кадәр;
в) күтәрелешнең иң югары ноктасыннан кризисның иң түбән ноктасына — төпкә кадәр;
г) рецессия башыннан аның иң түбән ноктасына кадәр.

ЗИРӘКЛӘР ФИКЕРЕ

«Иң ярлы кеше — үзендә булган әйбердән файдалана белмәүче кеше».

П.Буаст (1765–1824), француз лексикографы

§ 3. Икътисадта базар мөнәсәбәтләре

Базар игелекме яисә явызлыкмы? Базарның «күзгә күренмәс кулы» нәрсә эшли? Россиядә инде базар икътисадымы яки юкмы әле?

Җәмгыятьнең үсеше икътисади тормышның (икътисади системаларның) төрле вариантлары яшәп килүе мөмкинлеген күрсәтте.

Традицион икътисадта нинди товарлар һәм хезмәтләр кем өчен һәм ничек итеп җитештерелүе буыннан-буынга тапшырылучы гореф-гадәтләр нигезендә хәл ителә.

Команда икътисадында җитештерү һәм бүлү буенча барлык карарлар үзәк (дәүләт) органнары тарафыннан кабул ителә. Бу карарлар икътисади үсешнең дәүләт планнарында чагылыш таба, товар җитештерүчеләр аларны төгәл үтәргә тиеш. Команда системасын еш кына «үзәкләштерелгән», «директивачыл» яисә «планлы» дип тә атыйлар.

Базар икътисадында нәрсә, кем өчен һәм ничек җитештерергә кирәклекне, базарда сорау һәм тәкъдим нисбәтенә ка-

рап, житештерүче үзе хәл итә. Базар икътисады — ул милекчелекнең шәхси рәвеше өстенлек иткән хуҗалык, икътисади эшчәнлек хуҗалык итүче субъектлар тарафыннан үз хисапларына тормышка ашырыла, барлык төп карарларны алар үзләре тәвәккәлләп кабул итә.

Күп кенә илләрдә **катнаш икътисад** яшәп килә, анда базар һәм команда икътисады системалары, житештерүчеләрнең икътисади ирекe һәм дәүләтнең җайга салу роле үрелеп бара.

БАЗАР ҺӘМ ИКЪТИСАДИ ТОРМЫШТА АНЫҢ РОЛЕ

Көндәлек тормышта «базар» дип сәүдә иткән аерым бер урынны (базар, ярминкә) атыйлар. Фәндә «базар» товарлар (хезмәт күрсәтүләр) сатып алу яисә сату максатында сатып алучылар һәм сатучылар бер-берсе белән бәйләнешкә керүче шартлар җыелмасын белдерә.

Базар механизмында сорау һәм тәкъдим нисбәте аерым әһәмияткә ия. Ул базарда барлыкка килгән акча һәм товар агымнарының чагыштырмасын билгели.

Сорау — ул аерым бер товарны яки хезмәтне анык бәядән мәгълүм бер вакыт чорында сатып алу теләге, бу сатып алынучы нәрсә өчен түләргә әзер булу белән ныгытыла. Бу вакытта *индивидуаль сорауны* (бер затның яисә аерым бер товар буенча) һәм *җыелма сорауны* (барлык базарларда әлеге товарга сорауны яки барлык житештерелүче яки сатылучы товарларга сорауны) аерып карыйлар.

«Сорау» һәм «ихтыяҗ» төшенчәләре тәңгәл килми. Сатып алучы нинди дә булса продуктны сатып алырга тели дә ди, ләкин кирәк кадәр суммада акчасы булмый. Бу очракта ихтыяҗ бар, әмма сатып алу мөмкинлеге юк. Әгәр товарның бәясе түбәнрәк булса, ул аны сатып алыр иде. Сатып алучының реаль соравы — ул түләү сәләте булган сорау. Базар шартларында товар берәмлегенең бәясе төшә барган саен, аңа сорау арта бара. Һәм киресенчә: бәя үскән саен, сорау кими. Менә шуннан сорау законы килеп чыга, аның нигезендә *сорауның зурлыгы товар берәмлегенең бәясе үзгәрүгә тискәре бәйлелектә була.*

Сорауның зурлыгына төрле факторлар йогынты ясый. Әйтик, халыкның керемнәре зурлыгы сорауга тәэсир итүе күренеп тора. Халык саны арту да сорауның үсүенә, ә аның кимүе сорауның кимүенә китерә. Кулланучылар зәвыгының үзгәрүе (мода) шулай ук сорауга йогынты ясый. Киләчәктә бәяләрнең артачагы турында шөбһәләнү дә сорауны арттырырга мөмкин.

Тәкъдим — ул җитештерүченең мәгълүм бер вакыт дәвамында мөмкин булган бәяләр рәтеннән анык бәя буенча үз товарын җитештерү һәм базарда тәкъдим итү теләге. Бәясе югарырак булган саен, сатучы күбрәк товар сатырга тели, чөнки ул үзенең керемен арттырырга омтыла. Шуңа күрә тәкъдим ителүче товарлар саны товар бирәмлеге бәясенә турыдан-туры бәйле. Тәкъдим законы шундый, аның буенча *тәкъдим бәяләр артканда үсә һәм кимегәндә төшә.*

Тәкъдим байтак факторлар йогынтысында үзгәрергә мөмкин. Әгәр җитештерүченең җир, биналар арендалауга, банк кредитлары өчен, производство хезмәткәрләре һәм оештыручылары хезмәтенә түләүләргә чыгымнары артса, продукция җитештерү һәм аны инде урнашкан бәяләр буенча тәкъдим итү кыскарачак. Кулланыла торган технология шулай ук җитештерүгә йогынты ясый: технология яхшырак булган саен, ресурсларның бер үк күләменнән күбрәк товар җитештерергә мөмкин. Товарга бәя күтәрелүне көтү сату өчен отышлырак шартлар барлыкка килгәнгә кадәр товарны «тоткарлап тору» теләге тудыра.

Сорау һәм тәкъдим чагыштырмасы үзгәреп торганга күрә, бәяләр дә үзгәрә. Бәяләрнең тирбәлүе җитештерүчеләр эшчәнлегенә йогынты ясый. Җитештерүнең котылгысыз чыгымнары аркасында бәяләр арткан саен, керемнәр дә үсә бара; бәяләр төшсә — керем кими. Әгәр дә, мәсәлән, яшелчәләргә бәяләр үсә икән, аларны җитештерү отышлы: бу җитештерүне киңәйтүгә этәрә. Базарга бик күп яшелчә китерелү тәкъдимнең үсүен күрсәтә, һәм әгәр сорау артмаса, бәяләр төшә, ягъни сорау һәм тәкъдим түбәнрәк бәяләр дәрәҗәсендә тигезләшә, һәм яшелчә үстерү файдасызга әверелергә мөмкин. Товар җитештерүчеләр отышлырак продукт җитештерү мөмкинлекләрен эзли башлый.

Шулай итеп, базар үзе җитештерүне җайга сала, бәяләр аша җитештерүчегә нәрсә, ничек һәм кем өчен җитештерү турында «сигнал бирә». Базар җитештерү чыгымнарын киметүгә этәргеч бирә (хуҗалыкны экономияле алып барырга мәҗбүр итә), шулай ук техниканы камилләштерүгә, хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрүгә китерә. Икътисади законнар җитештерүнең индивидуаль чыгымнары әлеге тармакта уртачадан түбәнрәк чыгымлы җитештерүчеләрне кызыксындыра. Алар хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрүгә, техника һәм технологияләрне камилләштерүгә әйди, теге яки бу товарлар җитештерү өчен ресурсларны бүлешүне җайга сала, нәтиҗәдә кирәкле товарлар җитештерүне отышлы итә. Киресенчә, эшләрне экономияле алып бармау, хезмәт җитештерүчәнлегенең түбән булуы җитештерүне файдасыз (түбән керемле), ә балки

зыянлы да итә. Бу очракта бөлгенлек яный. *Җитештерүне базар механизмы белән җайга салу* менә шул инде. Шул ук вакытта товар җитештерүчеләрнең дифференциациясе бара: берәүләр байый, икенчеләре ярлылана яки бөлгенлеккә төшә.

БАЗАР СТРУКТУРАСЫ ҺӘМ ИНФРАСТРУКТУРАСЫ

Базар структурасы төрле критерийлар: *объектлар буенча* (товарлар һәм хезмәт күрсәтүләр базары, хезмәт базары, капитал базары, мәгълүмат базары һ.б.); *субъектлар буенча* (сатып алучылар базары, сатучылар базары һ.б.); *географик урнашуы* буенча (җирле базар, төбәк базары һ.б.); *законнарга туры килүе* (легаль базар, легаль булмаган, кайчакта «кара базар» дип йөртелгән базар һ.б.) буенча характерланырга мөмкин. Базар структурасын анализлауның башка нигезләре дә бар.

Товар биржасы — бу зур партияләр белән, кагыйдә буларак, үрнәкләр буенча сатылучы товарлар базары рәвеше. *Валюта биржасы* чит ил валютасын сату-сатып алу операцияләрен тормышка ашыра. *Хезмәт биржасы* хезмәт базарында арадашлык итә, эшсезләрне терки, аларның эшкә урнашуына ярдәм итә.

Базар икътисады инфраструктурасында *банклар* аерым бер урын тота, алар базар мөнәсәбәтләрендә катнашучылар арасындагы үзара түләүләрдә һәм исәп-хисап ясауда арадашчы ролен башкаралар. (Базар икътисадында банкларның роле турында сез алдагы параграфларда җентекләбрәк танышырсыз.)

Шушы параграфның беренче бүлегендә сез инде күргәнчә, сүз товарлар базары турында барды. Без монда тагын бер базар структурасын: фондлар базарын тасвирлап үтәрбез.

Фондлар базары (кыйммәтле кәгазьләр базары) кыйммәтле кәгазьләрне чыгаручы һәм сатучылар белән аларны сатып алучылар һәм аларга хуҗа булучылар арасындагы икътисади мөнәсәбәтләр системасы ул. Товарлар базары кебек үк, ул тәкъдимне һәм сорауны белдерә, ләкин базарның барлык башка төрләреннән үз товарының үзенчәлеге белән аерылып тора, аның товары — эмиссияле (латинча *emissio* — чыгару) кыйммәтле кәгазьләр. Кыйммәтле кәгазьләр эмиссиясе (чыгару) шәхси (акция һәм облигацияләрне акционерлык компанияләре чыгара) һәм дәүләтнеке (дәүләт займы облигацияләрен чыгару) булырга мөмкин.

Кыйммәтле кәгазьләр — ул махсус рәвештә рәсмиләштерелгән финанс документы, монда алар хуҗасының яки кәгазьне күрсәтүченең хокуклары беркетелгән. Мөлкәткә

хокукны һәм кыйммәтле кәгазьләр буенча аларның иясенә акчалата түләүне кыйммәтле кәгазьләрне чыгарган һәм саткан оешмалар тәэмин итә. *Кыйммәтле кәгазь* — үзенең бәясе булмаса да, югары базар бәясенә сатылырга мөмкин булган товар ул. Бу үз номиналы (ягъни, мәгълүм бәясе) булган кыйммәтле кәгазьнең, мәсәлән, сәнәгать предприятиесенә салынган билгеле бер реаль капитал зурлыгын гәүдәләндерүе белән аңлатыла. Әгәр дә кыйммәтле кәгазьгә сорау тәкъдимне узып китә икән, аның бәясе номиналдан югарырак булырга мөмкин. Кыйммәтле кәгазь базар бәясенең номиналдан мондый аермасы аның иясенә керем китерергә мөмкин.

Иң киң таралган кыйммәтле кәгазьләргә акцияләр һәм облигацияләр керә.

Акция — аның иясенә (акционерга) акционерлар җәмгыятеннән керемнәрнең бер өлешен дивидендлар рәвешендә алуга, акционерлар җәмгыяте белән идарә итүгә һәм аны япканнан соң калган мөлкәтнең бер өлешенә хокукларны беркеткән кыйммәтле кәгазь ул. Предприятиенең эшләре яхшы барса һәм аның керемнәре югары булса, акциягә ихтыяҗ зур һәм ул номиналь бәясеннән югарырак бәягә сатыла: мәсәлән, мең долларлык акция 1100 долларга сатыла. Һәм киресенчә, әгәр дә акционерлык компаниясе зыянга эшләсә һәм акцияле затлар алардан котылырга омтылса, аларның бәясе номиналдан түбәнрәк төшә. Акция — «исемле» кыйммәтле кәгазь.

Облигация — аның иясенә облигация эмитентыннан (латинча *emittens (emittentis)* — чыгаручы) алдан каралган вакытта аның номиналь бәясен яисә башка мөлкәт эквивалентын алу хокукын беркетүче кыйммәтле кәгазь. Облигация шулай ук аның иясенең анда беркетелгән облигациянең номиналь бәясеннән процент алу хокукын, йә башка мөлкәти хокуклар хокукын күздә тотарга мөмкин. Облигация буенча керем булып аннан процентлар алу тора. Облигация озак вакыт гамәлдә булган кыйммәтле кәгазьләрнең иң киң таралганнарыннан берсе. Бу документ — аны күрсәтүченеке (аның иясе беркетелми). Предприятиенең гомуми керемлегенә бәйле керем китерүче акциядән аермалы буларак, облигация, күрәнегезчә, беркетелгән процентлы ставка нигезендә керем бирә. Облигация алдан ук килешенгән мәгълүм бер вакытта кайтарылырга (сатып алынырга) тиеш.

Икътисадта кыйммәтле кәгазьләр базарының роле аның функцияләре белән билгеләнә. Беренчедән, бу — *инвестиция функциясе*, ул кыйммәтле кәгазьләр ярдәмендә инвестицияләр — сәнәгатькә, төзелешкә, транспортка һәм хуҗалыкның башка тармакларына озак вакытка капитал салу өчен кирәк булган акчалар барлыкка килү һәм бүленү тормышка ашы-

рылуда чагылыш таба. Ягъни кыйммәтле кәгазьләр базары җитештерүне финанслау, аның техник коралланышы өчен милекчеләрнең ирекле акчаларын һәм саклык малларын үзәкләштерүгә булышлык итә.

Икенчедән, кыйммәтле кәгазьләр базары функцияләренең берсен *милекне яңадан бүленүе өчен шартлар тудыруы* тәшкил итә. Ул яңа милекчеләр кыйммәтле кәгазьләрнең эре пакетларын сатып алганда була.

Өченчедән, дәүләт кыйммәтле кәгазьләр чыгару ярдәмендә *агымдагы бюджет дефицитын каплый.*

Кыйммәтле кәгазьләр базарының нигезе булып *фонд биржасы* — аларны сату-алу башкарыла торган учреждение тора. Бу — махсус оештырылган аукцион, ягъни халык алдындагы сәүдәдә сату; монда кыйммәтле кәгазьләрне иң югары бәяне тәкъдим иткән зат сатып ала. Биржа арадашчылары (аларны брокерлар яки маклерлар дип атыйлар) кыйммәтле кәгазьләр сатып алырга яисә сатарга теләүче клиентлардан заказ алалар. Биржада барлык алыш-биреш ачыктан-ачык сәүдә ысулы белән ясала.

Россиядә кыйммәтле кәгазьләр базары формалашуның беренче этабы үзенчәлеге анда катнашучыларның бик тиз үсүеннән гыйбарәт иде. Бу вакытта дәүләтнең фонд базарын җайга салудагы роле базарның тотрыклылыгы һәм куркынычсызлыгы өчен кирәкледән зәгыйфьрәк булды. Бу хәлне 1996 елда кабул ителгән «Кыйммәтле кәгазьләр базары турында» Федераль закон төзәтергә тиеш иде. Анда фонд базарын дәүләтнең җайга салуы юллары төгәл билгеләнгән.

Базарның эшчәнлегендә аның *инфраструктурасы* зур роль уйный. Бу — базарга хезмәт күрсәтүче институтлар, хезмәтләр, предприятиеләр. **«Биржа»** дип аталган махсус учреждениеләр дә шуларга керә. Биржа сәүдәсе билгеле бер товарны сатучыларга һәм сатып алучыларга бер-берсен әллә кайдан эзләгәнгә караганда тизрәк табу мөмкинлеге бирә.

КОНКУРЕНЦИЯ ҺӘМ МОНОПОЛИЯ

Икътисад фәнендә конкуренция дип товарлар һәм хезмәт күрсәтүләр җитештерүчеләр арасында керемне арттыру мөмкинлеге өчен үзара көрәшне, көндәшлекне атыйлар. Конкуренция көрәшендә күпчелек мөстәкыйль товар җитештерүчеләр (кәсепчеләр, фермерлардан алып эре фирмаларга кадәр) катнаша. Аларның һәркайсы үзләре тәвәккәлләп нәрсә һәм ничек итеп җитештерү мәсьәләсен хәл итә. Базарда аның

товарлары башка җитештерүчеләрнең шуңа охшаш товарлары белән очраша һәм һәркайсы кулланучыны үзенә җәлеп итәргә тырыша. Кулланучы исә яхшы сыйфатлы товарны арзанрак бәягә сатып алырга тели, чөнки аның мөмкинлекләре чикле. Образлы итеп әйткәндә, товар җитештерүчеләр арасында кулланучының «акча янчыгы» өчен көрәш бара. Кулланучы үз акчасын кайсы фирмага бирер? Күлмәкне, аяк киемен яисә радиоалгычны кемнән сатып алуны өстен күрер?

Җитештерүне дәвам итү өчен товарны сатарга һәм алынган акчаларны яңа партия товарлар булдыру өчен тотарга кирәк. Конкурентларны узып китәр өчен күп кенә җитештерүчеләр рекламадан файдаланалар, товарларына күркәм төс бирергә тырышалар, еш кына көндәшләрендә булмаган яңа товар тәкъдим итәләр. Кайчакта товарны сату өчен бәяне төшерергә дә туры килә. Чыгымнары зур булганнар бәяне төшерә алмый. Аның товары сатылмый яки зыян китерерлек бәягә генә сатыла. Кече җитештерүчеләргә конкуренциягә түзү бик кыен. Эреләре исә җиңүгә сәләтлерәк, чөнки аларның җитештерүне камилләштерү мөмкинлеге зуррак.

Конкуренция чикле ресурслардан рациональ файдалануга булышлык итә, җитештерү һәм реализация чыгымнарын киметүгә, җитештерүнең нәтиҗәлелеген күтәрүгә, товарларның куллану сыйфатларын яхшыртуга этәргеч бирә; шул ук вакытта ул җитештерүчеләрнең һәм кулланучыларның керемнәрен дифференциацияләүгә, ә ахыр чиктә бөлгенлеккә төшүгә китерә.

Белгәнегезчә, XIX гасыр ахырында кайбер илләрдә эре җитештерүчеләр төрле берлекләргә (картель, синдикат, трестларга) берләшә башлый. Мәгълүм бер тармакларда бу берлекләр товарлар җитештерүнең зуррак өлешен туплый, башкача әйткәндә, монополиячеләргә әвереләләр. **Монополиянең** асылы — монополь югары керем алу өчен монополь югары (яисә түбән) бәяләр урнаштыру юлы белән икътисади диктатка ирешү.

Икътисади тормыш үз эченә конкуренция элементларын да, монополияне дә ала. Капиталистлар берлекләре барлыкка килү конкуренцияне бетерми: ул берлекләрнең үзләре арасында да, монополист берлекләр белән монополист булмаган предприятиеләр арасында да бара. Әмма монополия югары бәяләргә, сорау һәм тәкъдимнең туры килмәвенә юл ача. Менә шуңа да, мәсәлән, АКШта XIX гасыр ахырында ук трестларга каршы законнар барлыкка килә, дәүләт аларны базар системасын яхшырту өчен куллана.

Россиядә монополиягә каршы законнар XX гасырның 90 нчы елларында кабул ителде. Россия Федерациясе Конституциясенең 34 статьясында түбәндәге норма беркетелгән:

«Монополияләштерүгә һәм намуссыз конкуренциягә юнәлтелгән икътисади эшчәнлек рөхсәт ителми». 1995 елда инде 1991 елда ук кабул ителгән «Товар базарларында конкуренция һәм монополистик эшчәнлекне чикләү турында» Законның яңа редакциясе үз көченә керде. Россия Федерациясе Граждан кодексы (10 статья) гражданнар хокукларыннан конкуренцияне чикләү максатларында файдалануга һәм базарда өстенлекле хәлне явызларча куллануга юл куймый. 1999 елда «Финанс хезмәтләре базарында конкуренцияне яклау турында» Закон кабул ителде. Монополиягә каршы законнарда тыелган монополистик эшчәнлек төрләре индивидуаль хокук бозуларга һәм килешенгән гамәлләргә бүленә. Аларда шулай ук конкуренцияне үстерүгә ярдәм итү һәм кабул ителгән законнарның үтәлешенә дәүләт контроле, монополистик эшчәнлекне кисәтү, чикләү һәм туктату каралган.

ХӘЗЕРГЕ ЗАМАН БАЗАРЫ

Хәзерге заман базары ирекле конкуренция чоры базарыннан һәм хәтта аерым тармакларда картель һәм трестлар өстенлек иткән XX гасыр базарыннан да сизелерлек аерылып тора. *Нык үскән илләрдә катнаш икътисад* яшәп килә, аларда күзгә күренми торган *базар механизмы* һәм *дәүләт җайга салуы бер үк вакытта* эш итә. Чит илләрдә яхшы мәгълүм бер «Икътисад» дигән дәреслектә истә калырлык итеп әйтелгәнчә, теге яки бу як булмаганда, икътисад белән идарә итү — бер кул белән алкышларга маташу ул. (Хәзерге заман икътисадында дәүләтнең роле моннан соңгы параграфларда ачылган.)

Базарга шулай ук *компанияләр дәрәҗәсендәге җайга салулар* да йогынты ясый. Алар товарлар, бәяләр, сорау үзгәрү һ.б. турында икътисади мәгълүмат җыюның, эшкәртүнең һәм таратуның заманча техникасын кулланалар. Товарларны һәм хезмәт күрсәтүләрне сатып алучыга җиткерүгә юнәлтелгән, базар таләпләренә, сатып алучыларның товарларга һәм хезмәт күрсәтүгә ихтыяҗын һәм реаль сорауларына, базар таләпләренә йөз тоткан эшчәнлек — *маркетинг* үсеш алды (бу хакта сез моннан соңгы параграфлардан белерсез).

Хәзерге заман базар системасы хаос та, анархия дә түгел. Базар икътисады — товар җитештерүчеләр һәм кулланучылар эшчәнлеген координацияләү өчен җайланган механизм; ул җәмгыять белән бергә үсә. Цивилизация үсә барган саен, базар да цивилизациялегә әверелә.

Башта товар җитештерә, аннары сатып алучыны эзли торган «сукыр конкуренция» элементлары чикле күләмнәрдә генә

сакланып килә. Хәзерге заман базарларында продукциянең саны, сыйфаты, номенклатурасы (исемлеге) турында алдан ук шартнамә (контракт) төзегән һәм үзләренә мәгълүм кулланучыларга йөз тоткан эре фирмалар өстенлек итә. Бу хәзерге базарны *оешкан* (контрактлы) базар дип атарга нигез бирә.

Контрактлы базарда массакүләм сорау, аның үзгәреп торуы җентекләп өйрәнелә. Эре фирмалар һәм дәүләт органнарының уртак гамәлләре белән базар стихиясе чикләнә, икътисади мөнәсәбәтләр чагыштырмача оешкан төс ала. Шуның белән бергә теләсә нинди икътисади хәлләр өчен бер тапкыр һәм даими билгеләнгән планлы һәм базар җайга салу элементлары (ягъни, аларның кайсы һәм нидә өстенлек итәргә тиешлеге), Көнбатыш илләре тәҗрибәсе күрсәткәнчә, икътисадның балансы югалудан һәм диспропорция барлыкка килүдән коткармый. Һәр аерым тарихи вазгыять өчен икътисадны җайга салуның базар һәм дәүләт механизмнарының оптималь нисбәтен эзләү зарур.

РОССИЯДӘ БАЗАР ИКЪТИСАДЫ УРНАШУ

1992 елда башланган базар реформалары нәтиҗәсендә Россия заманча базар икътисадына юлның бер өлешен узды. Түбәндәге үзгәрешләр сизелде.

Беренчедән, күпсанлы коммерция банклары, товар биржалары, кыйммәтле кәгазьләр базары, валюта базары, ягъни базар хуҗалыгының алардан башка нормаль эшләве мөмкин булмаган элементлары барлыкка килде.

Икенчедән — икътисадның шәхси секторы, шәхси эшмәкәрлек сизелерлек үсте. 1990 елларда үткәрелгән хосусыйлаштыру моңа этәргеч бирде. Тулаем эчке продуктның 70 % ы чамасы дәүләтнеке булмаган секторда җитештерелә. 1990 еллар ахырында кече һәм урта эшмәкәрлек даирәсендә 860 меңнән күбрәк предприятие эшләде, аларда 6,5 миллион кеше мәшгуль булды.

Өченчедән, куллану товарлары һәм җитештерү чараларының кискен җитмәүчелеге бетерелде, кибет киштәләре тулды; тәкъдим ителүче товарлар аларга сораудан артып китте, бу конкуренция өчен шартлар тудыра.

Дүртенчедән, Россия Федерациясе Конституциясендә икътисади эшчәнлек иреге, милекчелекнең (шәхси милекне дә кертеп) төрле рәвешләренең тулы хокуклылыгы беркетелү нәтиҗәсендә базар мөнәсәбәтләре институтлаштырылды; Граждан кодексы, шулай ук базар институтларының эшләвен җайга салучы башка законнар кабул ителде.

Ләкин базар реформалары тискәре процесслар белән дә бергә барды. Базарны товарлар белән тутыру авыл хуҗалыгының, җиңел сәнәгать, азык-төлек сәнәгатенең озак файдаланудагы товарлар җитештерүнең күтәрелеше нәтиҗәсендә түгел (киресенчә, илебездә җитештерү түбәнгә тәгәрәде), ә исә чит илдә җитештерелгән товарларны кертү исәбенә барды. Шул ук вакытта илнең күпчелек халкында реаль керемнәрнең төшүе аркасында сатып алу соравы җитди кимеде.

Хосусыйлаштыру нәтиҗәсендә икътисади хакимият (белгечләр белешмәләре буенча) халыкның милекчеләрнең дүрт төркемен эченә алган 5–6 % ы кулында калды. Алар: яшерен икътисад вәкилләре һәм 1990–1992 елларда байлык туплаган белгечләр; иң югары идарә аппараты вәкилләре; хосусыйлаштыру чекларын сатып алу аша «акчаларын юу» мөмкинлеге алган җинаятьчел структуралар; акцияләр сатып алуда өстенлекләре булган «директорлар корпусы».

Дәүләт милкен хосусыйлаштыру җитештерүне модернизацияләү белән бергә алып барылмады. Күпчелек хосусыйлаштырылган предприятиеләрдә базар стимуллары эшләп китмәде. Түләмәү кризисы килеп чыкты, ягъни предприятиеләр, банклар, дәүләт бер-берсе белән исәп-хисап ясый алмады. Шәхси эшмәкәрлек чамасыз салымнар, бюрократик киртәләр, рэкет (җинаятьчеләр ягыннан янаулар һәм көч куллану юлы белән мөлкәтне яисә акча алу) кысрыкланды. Дәүләт икътисадны, үзендә калган милекне җайга салу ысулларыннан файдалана алмады. Бу процессларның социаль нәтиҗәләре авыр булды: халыкның байтак өлешенең тормыш дәрәҗәсе төшү, эшсезлек арту, социаль бүленүнең көчәюе.

Әлге шартларда илнең икътисади үсеш юллары турында бәхәсләр кискенләште. Берәүләр команда икътисадына, дәүләт милкенә кире кайтырга кирәк дип санады. Икенчеләр, киресенчә, дәүләтне икътисадтан кысрыклап чыгарырга тәкъдим итте. Икътисадны савыктыру реформалардан баш тарту юлы белән түгел, ә аларны дәвам итеп, эзлекле төстә хуҗалык итүнең булган рәвешләрен, дәүләтнең икътисади һәм социаль процесслардагы мөһим ролен саклаган хәлдә, социаль юнәлеш тоткан һәм җайга салынучы икътисад юнәлешендә үзгәртеп кору юлы белән генә мөмкин дип санаган икътисадчы галимнәрнең карашлары дөресрәк булып күренде.

2000–2003 елларда икътисади хәл акрынлап яхшыра башлады. ТЭП өчтән бергә диярлек үсте. Меңләгән предприятиеләр нәтиҗәле эшләде. Эчке базар үсте. Россия икътисады инвестицияләр өчен кулай була барды. Халыкара оешмалар рәсми төстә Россияне базар икътисады булган ил дип таныдылар.

Шулай да илебезнең үсеш темплары әле һаман җитәрлек түгел. Икътисадның структурасы әлегә балансланмаган. Анда чимал чыгаручы тармаклар өстенлек итә. Россия икътисадының югары технологияле, югары керемле өлкәләргә йөз тотуы зарур. Хезмәт күрсәтү базары акрын формалаша. Хезмәт күрсәтүләр сыйфаты түбән, ә алар өчен түләү арта. Россия икътисадының шушы һәм башка проблемалары киләсе елларда хәл итүне алга куя.

ГАМӘЛИ ЙОМГАКЛАР

1 Безнең чорда һәр кеше төрле товарлар сатып алучыролендә дә, нинди дә булса товар яисә хезмәт күрсәтү җитештерүче хезмәткәр буларак та базар мөнәсәбәтләренә керә. Теләсә нинди икътисади роль оста башкаруны таләп итә. Базар икътисады законнарын белү вазгыятьне дөрес бәяләргә һәм һәр очракта дөрес карар кабул итәргә булыша. Базар механизмының ничек эшләвен аңламаган кеше үз уңҗышына ышанып бетә алмый.

2 Теләсә нинди эшчәнлектә конкуренциягә сәләтле булу зур әһәмияткә ия. Теләсә кайсы базарда, товарлар базарымы ул, хезмәт күрсәтүнекеме, хезмәт базарымы яисә мәгълүматныкымы, уңыш башка шартлар тигез булганда, вакытны һәм акчаны азрак сарыф итеп, сан күрсәткечләре буенча да, сыйфат буенча да яхшырак нәтиҗә бирергә сәләтлене көтә. Гомуми культура, һөнәри белемнәр һәм осталык белем алу турында документ алу өчен түгел, үзеңнең конкуренциягә сәләтеңне күтәрү өчен кирәк.

3 Безнең илдә базар икътисадының тагын да үсүе, реформалар үткәрүдәге хаталарның тискәре нәтиҗәләрен бетерү икътисади тормышта турыдан-туры катнашучылар һәм закон чыгаручылар составын формалаштыручы сайлаучылар буларак, гражданнарга нык бәйле. Базар икътисады турындагы белемнәр үз икътисади проблемаларыңны дөрес чишәргә ярдәм итеп кенә калмый, ә партияләр һәм кандидатлар программаларының икътисади өлешен белеп бәяләү мөмкинлеген исәпкә алып, сайлауларда дөрес карар кабул итәргә дә булыша.

ДОКУМЕНТ

Академик ***С.С.Шаталинның*** базарга күчү алшартлары турында 1990 елда чыккан «Базарга күчеш. Концепция һәм Программа» китабыннан.

Базар икътисадының нәтиҗәле эшләве өчен күчеш чоры дәвамында булдырылырга тиешле алшартлар булу зарур...

1. Икътисади субъектның (предприятие, эшмәкәрнең) максималь ирекле булуы...

2. Икътисади субъектның хуҗалык эшчәнлеге нәтиҗәләре өчен барлык төр милекнең, шул исәптән шәхси милекнең дә, юридик тигез хокуклылыкка таянучы тулы җаваплылыгы...

3. Хуҗалык активлыгын кызыксындыруның, кулланучылар сораулары нигезендә продукциянең төрлелеген арттыруның һәм сыйфатын күтәрүнең, чыгымнарны төшерү һәм бәяләрне тотрыклыландыруның иң мөһим факторы буларак, җитештерүчеләр конкуренциясе... Сәламәт конкуренцияне үстерү икътисадны демонополизацияләүне, базарда һәр төр товар җитештерүчеләрнең җитәрлек санда катнашуын тәэмин итүче тиешле производство структуралары формалаштыруны, теләсә кайсы икътисади субъектның базарга ирекле керүен, дәүләт конкуренциясен һәм монополиячел гамәлләрне кисәтүне таләп итә.

4. Бәяләрнең ирекле куелуы... Бәяләргә дәүләт контроле фәкать чикләнгән даирәләрдә һәм базар бәяләр куелуы законнарын һичшиксез дефицитка китерүче тупас бозуларсыз гына рөхсәт ителә.

5. Базар мөнәсәбәтләрен дәүләти һәм башкача рәвештәге җайга салу белән чагыштырганда югарырак нәтиҗәләргә китергән өлкәләрдә тарату. Товар базарын эшче көчләр базары һәм финанс базары белән тулыландыру зарурлыгы шуннан килеп чыга, алар җәмгать ресурсларының югары хәрәкәтчәнлеген, аларның иң рациональ кулланыш даирәсенә тиз күчүен тәэмин итәләр, туплануны һәм фәнни-техник прогрессны кызыксындыралар. Бер үк вакытта икътисадта коммерциячел критерийларга гына буйсындырылырга мөмкин булмаган эшчәнлек төрләрен үз эченә алган шактый зур базарсыз сектор (оборона, сәламәтлек саклауның, мәгариф, фән, мәдәниятнең бер өлеше) сакланып кала.

Документка сораулар һәм биремнәр

1. Параграфтагы төп текстның кайсы нигезләмәләре документ идеяләренә туры килә? **2.** Нигә автор базарның алшартлары арасында икътисади ирекне иң беренче атый? **3.** Сез ничек уйлыйсыз: нигә базар икътисады милекчелекнең барлык рәвешләренең тигез хокуклылыгын күздә тота? **4.** Автор фикеренчә, конкуренцияне үстерү өчен нәрсә

эшләргә кирәк? **5.** Бәяләр ясалуның базар законнарын бозу нигә дефицитка китерүен аңлатыгыз. **6.** Кайсы даирәләрдә базар мөнәсәбәтләре иң югары нәтиҗәләргә китерә? Нигә? **7.** Параграфның эчтәлеге һәм башка чыганаклар нигезендә ачыклагыз: хәзерге вакытта Россиядә базар икътисады эшләве өчен кирәкле алшартлар бармы?

ҮЗ-ҮЗЕҢНЕ ТИКШЕРҮ ӨЧЕН СОРАУЛАР

1. Базар икътисады үзәкләштерелгән, планлы команда икътисадыннан ни белән аерыла? **2.** Ирекле базар билгеләрен санап үтегез. **3.** Базар хуҗалыгында икътисади законнар ничек эшли? **4.** Базарның структурасы һәм инфраструктурасы нинди? **5.** Фонд базарының үзенчәлекләре нидән тора? **6.** Базар икътисадында конкуренция нинди роль уйный? **7.** Хәзерге заман базары нәрсә белән үзенчәлекле? **8.** Россия икътисадының базар рәвешендә булуы турында нәрсә сөйли?

БИРЕМНӘР

1. Газета битләрендәге ике фикерне чагыштырыгыз:

«Базар «каһарманнары» — эшмәкәр, коммерсант, бизнесмен — һич тә гади хезмәт ияләре түгел. Аларның максаты — байлык, аларның ысулы — «кагыйдәсез уен», әхлакый тотнаксызлык. Эшмәкәр «көчлеләр» кануны буенча яши, ул «зәгыйфькә» карата рәхимсез. Аның җаны табынса да — уңыш идеалларына гына. Аның куражы — тәвәккәллек, аның рәхәте — теләсә нинди бәягә җиңү. Димәк, бизнес кануннары — әхлакның кире ягы. Конкуренция — ерткычлар көрәше».

«Эшмәкәр, сәүдәгәр, банкир, менеджер — базарның төп фигуралары. Алар һич тә мафиози түгел, алыпсатар, «яшерен цехчы», коррупцияче дә түгел. Базар таләпләре эшлекле мөнәсәбәтләрнең нәтиҗәлелеге шартлары сыйфатында намуслылыкның, тәртипле һәм ышанычлы булуның тайпылмас нормаларын раслый. Ә бу тулаем алганда тормышның барлык өлкәләрендә халыкның торышына уңай тәэсир итә. Конкуренция — катгый көрәш, ләкин бу «кагыйдәләр буенча уйнау», аны үтәүне җәмәгать фикере уяу күзәтеп тора».

Сез кайсы карашны яклыйсыз? Җавабыгызны дәлилләгез.

2. Икътисад өлкәсендә Нобель премиясе лауреаты М.Фридмен болай яза: «Адам Смитның даһилыгы товарларга сатып алучылар һәм сатучылар арасындагы алыш-биреш нәтиҗәсендә килеп чыгучы бәяләр, — башкача әйткәндә, ирекле базар кануннары нәтиҗәсендә барлыкка килүче бәяләр, — һәркайсы үз файдасын

эзләүче миллионлаган кешенең эшчәнлеген көйли ала, шул ук вакытта бу алыш-бирештә катнашучы һәркем отышлы калырлык итеп көйли, дигән фактны аңлавында чагыла».

Базар шартларында үзара файдалы алмашуның ничек башкарылуын аңлатыгыз.

3. Җитештерүгә конкуренция һәм монополия ясаган йогынтыны чагыштырып карагыз. Теге яки бу тармакта товар җитештерүчеләр конкуренциясе һәм мәгълүм бер тармакта монополия кулланучыларда ничек чагыла?

4. Күпчелек икътисадчыларның ни өчен команда яки ирекле базар икътисадларын түгел, ә катнаш икътисадны «оптималь» дип санавын аңлатып бирегез.

ЗИРӘКЛӘР ФИКЕРЕ

«Мул тормышка ирешү һәм аны тәэмин итү өчен иң нәтиҗәле чара — конкуренция».

Л.Эрхард (1897–1977), немец дәүләт эшлеклесе

§ 4. Икътисадта фирмалар

Ни өчен бериш фирмалар уңышка ирешә, ә икенчеләре бөлгенлеккә төшә? Бар нәрсәне җитештерү дә файдалымы? Банкротлыктан дәва бармы? Базар системасында зыянга эшләүче предприятиеләр яши аламы?

Эре автомобиль заводын һәм кечкенә генә аяк киеме ремонтлау остаханәсен, туристлык агентлыгын һәм рестораннар челтәрен бер сүз белән — «фирма» дип атарга мөмкин. Нәкъ менә фирмалар товар һәм хезмәт күрсәтү базарларында үз продукциясен тәкъдим итүче сатучылар сыйфатында чыга.

Икътисадта **фирма** (предприятие) — базарда реализацияләнүче товарлар һәм хезмәт күрсәтүләр булдыру өчен икътисади чыгымнар тотучы коммерциячел оешма ул.

Фирманың хуҗасы аның эшчәнлеген керем рәвешендә товарлар яисә хезмәт күрсәтүләр сатудан файда алырлык итеп оештырырга тырыша. Бу максатка ирешү күпчелек очракта җитештерелүче байлыкларның төрен һәм күләмен рациональ сайлап алуга, җитештерү технологиясенә, производствоның төп ресурсларын оста тоташтыруга һәм алардан ничек файдалануга, җитештерү процесслары һәм әзер продукцияне базарда сату белән белеп идарә итүгә бәйле.

Күргәнебезчә, бурычлар җыелмасы гаять киң һәм төрле, һәм аларны һәркем дә уңышлы хәл итә алмый. Күп кенә эшмәкәрлек башлангычлары уңышсызлыкка юлыга. Нык үскән

базар икътисады илләрендә ел саен уннарча яңа фирмалар туып кына калмый, шул кадәре диярлек бөлгенлеккә дә төшә.

Нәтиҗәле производство булдыру һәм фирманың тормышчанлыгын дәвам итүдә җитештерүчегә нәрсә ярдәм итә ала соң? Шушы һәм аннан соңгы ике параграф материаллары бу сорауга җавап эзләүгә багышлана.

ҖИТЕШТЕРҮ ФАКТОРЛАРЫ һӘМ ФАКТОР КЕРЕМНӘРЕ

Җитештерү процессы икътисади ресурсларны (җитештерү факторларын) товарларга һәм хезмәт күрсәтүләргә әверелдерүдән гыйбарәт. Җитештерү факторлары түбәндәгеләр: хезмәт (хезмәткәрләр һәм аларның квалификациясе), җир (предприятие урнашкан җир кишәрлеге, чимал), капитал (производство бинасы, станоклар, инструментлар).

Теләсә кайсы фирманың икътисади яктан чәчәк атуы атап үтелгән ресурслар — хезмәт, табигать, капитал ресурслары белән тәэмин ителүеннән генә тормый. Барлык башка факторларны берләштергән тагын берсе — эшмәкәрлек сәләте булу бик мөһим. Эшмәкәрләр үзләренең оештыру һәм идарә итү тырышлыгын булган производство ресурсларын иң яхшы итеп файдалануга юнәлтәләр. Бу аларга югары нәтиҗәләргә ирешергә (яхшы сыйфатлы күп продукция алырга) һәм, уңыш юлдаш булганда, керемне арттырырга мөмкинлек бирә.

Инде белгәнегезчә, икътисадта барлык ресурслар чикләнгән, ягъни барча кешеләр теләгән кадәр сандагы товарлар җитештерү өчен җитәрлек түгел. Икътисадның нормаль эшләве өчен җитештерүчеләр чикләнгән ресурслардан сайлап алырга өйрәнергә тиешләр. Әгәр дә фирма үз хезмәткәрләре өчен торак йорт төзи икән, аңарда булган ресурслар (төзелеш материаллары, хезмәткәрләр, төзелеш техникасы) бер үк вакытта аның административ бинасын төзекләндерүдә дә файдаланыла алмый. Бюджеты чикләнгән хөкүмәт интенсив хәрәкәтле юлларны төзекләндерү хакына берничә мәктәп төзүне кичектереп торырга мөмкин. Сайлап алу нәтиҗәсендә, нәрсәгәдер тулырак күләмдә ирешү өчен, нидәндер баш тартырга туры килә.

Һәр җитештерү факторының үз хуҗасы бар. Җитештерү факторының иясе аның факторыннан аның ризалыгы белән файдаланган өчен түләү алырга тиеш. Һәркайсыбызның бер генә булса да җитештерү факторы (хезмәт, җир, капитал, эшмәкәрлек сәләте) бар, һәм ул керем китерә ала. Әлеге кеременең зурлыгы сез хуҗа булган җитештерү факторының санына һәм сыйфатына бәйле. Әгәр дә сез мәгълүм бер

белгечлеккә һәм сәламәтлеккә ия икәнсез, эшегез өчен кызыксындыруны **хезмәт хакы** рәвешендә аласыз. Хәзерге заман икътисадында катнашучылар арасында керемнең бу төре — иң киң таралганы.

Әйтик, сез эшмәкәрлек сәләте кебек җитештерү факторына гына ия ди. Җитештерүне оештыру өчен, сезгә башкалар факторларыннан файдаланырга туры килә: җирне, станок һәм җиһазларны арендага аласыз, эшчеләр яллыйсыз, акча ресурсларын кредитка җәлеп итәсез. Җитештерелгән продукцияне саткач, сез алынган керемнең бер өлешен җитештерү факторлары ияләре белән исәп-хисап ясауга тота аласыз. Алынган керемнең бер өлеше сездә табыш рәвешендә кала. **Табыш** сезнең тырышлык һәм эшмәкәрлек сәләтегез өчен түләү була да инде.

Җир кебек җитештерү факторы китергән керем **рента** дип атала. Җир хуҗасы эшмәкәрлек эшчәнлеге алып бармаска, аннан файдалану буенча өстәмә тырышлык куймаска да мөмкин. Мәсәлән, сез, җир кишәрлеге хуҗасы буларак, аны башка затларга шартнамә нигезендә, билгеле бер түләү бәрабәренә вакытлыча файдалануга биреп тора аласыз. Бу түләү җирдән файдаланудан алынган керемегез була.

Капитал (латинча *capitalis* — төп) — керем китерүгә сәләтле мөлкәт. Капитал — җитештерү чарасы рәвешендә эшкә салынган керем чыганагы ул. Әгәр фирма хезмәтне ялласа, җирне арендага алса, капитал гадәттә аныкы була.

«Капитал» төшенчәсенең берничә мәгънәгә ия булуына игътибар итегез: *физик капитал* (җитештерү чаралары), акча яисә *финанс капиталы* (физик капитал сатып алу өчен кулланылучы акча), *инвестицияләр* (матди һәм акча чараларын җитештерүгә салу).

Реаль, төп капитал — машиналар, инструментлар һәм башка производство җиһазлары рәвешендәге җитештерү чаралары. Акчалар үзләре генә берни дә җитештерми, алар төрле җитештерү чаралары сатып алу өчен кулланылырга гына мөмкин. Физик капитал сатып алу өчен билгеләнгән (җитештерүгә салынган) акчалар киләчәктә үз иясенә керем китерергә тиеш.

Җитештерү процессында түбәндәгеләр исәбенә вакытлыча ирекле акча барлыкка килә: тузган хезмәт чараларын төзекләндерүгә һәм алмаштыруга акча күчерүләр; товарлар сатудан алып эш хакы түләүгә кадәрге вакыт аралыгы нәтиҗәсендә тупланган акчалар; табышның җитештерүне киңәйтү өчен тупланган өлеше һ.б. Вакытлыча ирекле акчаларның хәрәкәтсез ятуы базар икътисадының табигатенә үк каршы килә, «эшсез акчалар» җитештерүнең нәтиҗәлелеген төшерә, капиталның керемлелеген киметә. Алар *ссуда капиталы* буларак — кире

кайтару һәм файдаланган өчен түләү шартларында вакытлыча ирекле акчаны ссудага биреп торып — кулланылырга мөмкин. Ссуда капиталына керем булып **процент** — акча алып торучы тарафыннан чит кеше акчаларыннан файдаланган өчен түләү тора.

Тулаем алганда әлеге бүлекнең эчтәлеген түбәндәге схема белән сурәтләргә мөмкин:



Җитештерү факторлары милекчеләренең керемнәре — бер үк вакытта предприятие (фирма) хуҗасының чыгымнары ул. Шуңа фирманың җитештерү эшчәнлеге нәтиҗәлелеге күп очракта җитештерүнең читтән җәлеп ителүче һәм үз факторларының рациональ кушылуына һәм файдаланылуына бәйле.

Фирманың хуҗалык эшчәнлеге никадәр нәтиҗәле булуын ничек билгеләргә соң? Моның өчен, аерым алганда, эш нәтиҗәләрен чыгымнар белән чагыштырып карарга кирәк.

ИКЪТИСАДИ ҺӘМ БУХГАЛТЕРЛЫК ЧЫГЫМНАРЫ ҺӘМ ТАБЫШ

Инде билгеләп үтелгәнчә, фирма эшчәнлеге аның хуҗасы өчен фәкать табыш алганда гына ниндидер мәгънәгә ия. Исегезгә төшерик, табыш продукция сатудан керемнең барлык җитештерү факторлары буенча бу эшчәнлеккә чыгымнар суммасыннан югарырак булуы нәтиҗәсендә барлыкка килә. Шулай итеп, теләсә нинди фирма, продукция чыгарганда, үз чыгымнарын капларга тиеш. Башкача булганда, аның хуҗасын зыян күрү һәм бөлгенлек көтә.

Җитештерү чыгымнары — бу җитештерүнең (фирма хуҗасының) җитештерү факторлары алуга һәм алардан файдалануга тоткан акчасы.

Предприятие (фирма) өчен **икътисади чыгымнар** — кирәкле ресурслар (хезмәт, матди, энергетик һ.б.) куючыларга, әлеге

ресурсларны башка производстволарда файдаланудан аерып алу өчен, фирма түләргә тиешле акчалар. Алар эчке һәм тышкы түләүләргә бүленә, аларны санауга төрлечә якын киләләр.

Эчке (яисә күренеп тормаучы) чыгымнар — болар фирма милекчесенеке (хуҗасыныкы) булган ресурсларга чыгымнар. Мәсәлән, фирма урнашкан бина аның хуҗасы милке булып тора; фирма хуҗасы үз хезмәтен идарәче сыйфатында эшкә җигә. Бу ресурслар фирманың үзенеке булганлыктан, монда тышкы чыгымнар (биналарны арендалаган өчен түләү, яллаган идарәче хезмәте өчен түләү) юк, ләкин фирма күзлегеннән караганда, әлеге эчке чыгымнар аларны альтернатив файдаланганда (мөмкин булганның иң яхшысы) үз ресурслары өчен алынырга мөмкин булган акчалата түләүләргә тиң. Әйтик, үз биналары арендага бирелергә мөмкин иде, ә фирма хуҗасы, үзен канәгатьләндерүче керем алмыйча гына, табышны эш хакы рәвешендә алыр иде.

Нәкъ менә эшмәкәрлек функцияләрен үтәгән өчен түләү *нормаль табыш* дип атала һәм эчке чыгымнар составына керә. Эчке чыгымнар еш кына яшерен, күренеп тормаган характерда була, ләкин аларны икътисади карарлар кабул иткәндә һичшиксез исәпкә алырга кирәк. Әгәр дә бухгалтер продукция җитештерүнең фирмага күпмегә төшүен исәпләргә тырышып, башкарылган чыгымнарны билгеләсә, фирма хуҗасы икътисади сайлау бурычын хәл итә: үз бизнесыңны дәвам итәргәме, яисә ресурсларыңнан файдалануның отышлырак башка вариантын табаргамы.

Тышкы чыгымнар — бу фирма хуҗасы милкендә булмаган җитештерү факторлары өчен түләү. Аларга материаллар, энергия, хезмәт күрсәтүләр һ.б. алуга чыгымнар керә. Тышкы чыгымнар күренеп тора һәм бухгалтерлык документларында чагылыш таба, шуңа аларны **бухгалтерлык** яисә **күренеп торган чыгымнар** дип атыйлар.

Шулай итеп, **икътисади чыгымнар** тышкы (бухгалтерлык яисә күренеп торган) һәм эчке (күренеп тормаган) чыгымнарны эченә ала, соңгысына нормаль табыш та керә. Бу — ресурсларны эшчәнлекнең әлеге төренә җәлеп итү һәм шунда тоту өчен кирәк булган өчен түләү.

Икътисади һәм бухгалтерлык чыгымнары арасындагы аерма табышны төрлечә билгеләүгә китерә.

Икътисади табыш — ул фирманың гомуми кереме һәм икътисади чыгымнар арасындагы аерма.

Болай якын килү предприятиенең яши алу-алмавын бәяләргә мөмкинлек бирә (керемнәр тышкы, бухгалтерлык чыгымнарын гына түгел, эчке, нормаль табышка кергәннәрен дә каплыймы?). Акчалата керемнәрнең икътисади чыгымнар

суммасыннан артып китүе предприятиенең саф табышы булуын, аның хаклы яшәвен, уңышлы үсә алуын күрсәтә.

Бухгалтерлык табышы — бу гомуми керем һәм бухгалтерлык чыгымнары арасындагы аерма.

Икътисади табыш эшмәкәрне керем алуга гына түгел, шул керемне булган ресурсларны альтернатив кулланганда алырлык керемнәр белән чагыштыруга да этәрә. Мәсәлән, эшмәкәр җитештерүне оештырып, 3000 сум бухгалтерлык табышы алды ди. Ә акчаларын банкка салса, ул процент рәвешендә 4000 сум алган булыр иде. Моннан, әгәр бухгалтерлык табышы альтернатив чыгымнарны исәпкә алган икътисади табыштан кимрәк булса, эшмәкәр күзлегеннән караганда, ресурстан файдалануны нәтиҗәсез дип санарга кирәк.

Фирманың табышын икътисадчылар һәм бухгалтерлар тарафыннан төрлечә аңлау фирмада эшнең торышы турында төрле нәтиҗә ясауга китерә.

Эшмәкәр үз производствосының нәтиҗәлелеген генә түгел, аны үстерү перспективасын анализлаганда чыгымнарны санауның кайсы ысулын — бухгалтерлыкнымы яисә икътисадинымы — сайласа яхшырак соң? Күрәсең, чыгымнарның һәм табышның чынбарлыктагы зурлыкларын исәпләү өчен бухгалтерлык ысулын кулланырга кирәк. Ресурсларны салуның альтернатив вариантларыннан берсен сайлау турында карар кабул иткәндә, чыгымнарны санауның бары тик икътисади ысулы гына ярашлы.

Теләсә кайсы предприятие хуҗасы табыш күләмен арттырырга омтыла. Шул хакка ул җитештерү технологиясен һәм оештыру алымнарын камилләштерә, хезмәткәрләрне җитештерүчәнлекне күтәрү белән кызыксындыра, ресурсларны экономияләү режимы кертә. Бу барлык чыгымнарның зурлыгын киметүгә китерә һәм табышны күтәрүгә этәргеч бирә.

Җитештерү чыгымнарын санап чыгарганда, фирма иясенә аның күп төрләрен исәпкә алырга кирәк. Җитештерүче өчен иң әһәмиятле чыгымнар белән танышыйк.

ҖИТЕШТЕРҮНЕҢ ДАИМИ ҺӘМ АЛМАШЫНУЧАН ЧЫГЫМНАРЫ

Җитештерүдә файдаланылучы ресурсларның төренә карап, чыгымнар төрлечә формалаша. Аларны кер юу машиналары ясау предприятиесендә материаллар һәм производство б162 бе162 биналары мисалында карыйк. Продукция бермлеге күбрәк әзерләнгән саен, материал күбрәк тотыла; димәк, материаллар (металл, пластмасса, резина) куллану белән бәйле чыгымнар арта бара. Бер үк вакытта бина һәм цех күләмнәре, җиһазлар саны

үзгәрми; димәк, бинаны һәм цехларда урнаштырылган җиһазларны куллану белән бәйле чыгымнар элеккечә үк калырга мөмкин. Производство ресурсларыннан файдаланудагы мондый аерма икътисадчыларны чыгымнарның даими һәм алмашынучан төрләрен аерып карарга мәҗбүр итә.

Даими чыгымнар — гомуми чыгымнарның бу вакыт аралыгында чыгарылучы продукция күләменә бәйсез өлеше.

Даими чыгымнар мисалы булып фирманың бина өчен аренда түләве, бинаны тотуга чыгымнары, кадрлар әзерләүгә һәм яңадан укытуга чыгымнары, идарәче персоналның эш хакы, коммуналь хезмәтләргә чыгымнар, амортизация тора.

Амортизация — җитештерүдә файдалану процессында туза баруына карап, капиталь ресурсларның бәясе төшү. Биналарның, җиһазларның, транспорт чараларының тузуын каплау өчен акча туплана (амортизациягә акча күчерүләр), алар тузган хезмәт чараларын төзекләндерүгә яисә яңаларын әзерләүгә тотыла. Бу сумма даими чыгымнарга керә.

Предприятие эшләмәгәндә дә аның даими чыгымнары бара. Мәсәлән, икмәк заводы продукция чыгаруны вакытлыча туктатты ди; коммуналь хезмәт күрсәтү, идарәче кадрларның эш хакы барыбер чыгымнар таләп итә.

Алмашынучан чыгымнар — гомуми чыгымнарның бу вакыт аралыгындагы зурлыгы җитештерү күләменә һәм аны реализацияләүгә турыдан-туры бәйле өлеше.

Алмашынучан чыгымнар мисалы булып чимал сатып алуга, хезмәт өчен түләүгә, энергия, ягулык, транспорт хезмәтләре, тарага һәм төрүләргә чыгымнар тора.

Алмашынучан чыгымнар җитештерү күләме арту белән үсә һәм ул кимегәндә төшә.

Даими һәм алмашынучан чыгымнар арасындагы аерма һәр эшмәкәр өчен зур әһәмияткә ия. Алмашынучан чыгымнар белән ул идарә итә ала, чөнки аның зурлыгы җитештерү күләме үзгәрү нәтиҗәсендә кыска гына чорда да үзгәрә. Даими чыгымнар фирма администрациясе контроленнән читтә, чөнки алар җитештерү күләменнән бәйсез рәвештә мәҗбүри төстә түләнергә тиеш.

Җитештерү чыгымнарының чыгарылучы продукция күләменә бәйле рәвештә үзгәрүен анализлау бик мөһим. Фәкать шуның нигезендә генә фирмалар ничек карар кабул итүен, товар җитештерү һәм хезмәт күрсәтүләр күләмен билгеләвен, шулай ук базарда тәкъдим ителүче товарларга бәя куюын аңларга мөмкин. Производство чыгымнарын чагыштыру фирма белән идарә итү, җитештерүнең оптималь күләмнәрен билгеләү һәм тотрыклы керем алу мөмкинлеген ачыклау өчен гаять мөһим.

Шулай итеп, үз бизнесларын нәтиҗәле итеп күрергә омтылучы эшмәкәрлек эшчәнлеге белән шөгыльләнүчеләргә

табышны арттыру һәм чыгымнарны кимету хакында уйларга туры килә. Югарыда бәян ителгәннәр тагын бер сорауга җавап табарга ярдәм итәр: нәрсә ул нәтиҗәле бизнес, нәтиҗәле предприятие (фирма)? Нәтиҗәлелек (эффектлылык) төшенчәсе инде кулланылса да, аны җентекләбрәк карыйк.

Икътисадта нинди дә булса эшчәнлекнең анык бер уңай нәтиҗәсен эффект, дип атыйлар (мәсәлән, фирма узган елгы белән чагыштырганда күбрәк алган табыш, яки экономияләнгән чаралар суммасы). Эффектлылык эффект зурлыгын аны алуны тәэмин итүче чыгымнар белән чагыштырганда ачыклана.

Эффектлылык — процессның нәтиҗәлелеге, ул эффектның, нәтиҗәнең чыгымнарга карата чагыштырмасы буларак билгеләнә.

Предприятиенең нәтиҗәлелеген, табышлылыгын анализлау өчен *рентабельлелек* күрсәткече кулланыла. Рентабельлелек предприятие мәгълүм бер чорда алган табышның шул ук чорда ясалган чыгымнарга нисбәте буларак исәпләнә (рентабельлелек $= \frac{\text{табыш}}{\text{чыгымнар}}$). Фирма эшенең югары нәтиҗәлелегенә ирешү өчен нәрсә эшләргә кирәклекне уйлагыз.

ПРЕДПРИЯТИЕЛӘР ТҮЛИ ТОРГАН САЛЫМНАР

Предприятие табышының зурлыгына производство чыгымнары гына түгел, алар түли торган салымнар суммасы да йогынты ясый. Салымнар — җитештерүче чыгымнарының сизелерлек өлеше, ул үз эшен оештырганда һәм алып барганда моны исәпкә алырга мәҗбүр.

Салым системасы белән сез төп мәктәптә таныштыгыз. Салымнарның турыдан-туры һәм читләтелгән булуын исегезгә төшерәбез. Турыдан-туры салымнар гражданнар кеременнән ачыктан-ачык алына (мәсәлән, керем башыннан салым, табышка салым, милкәт салымы). Читләтелгән салымнар билгеле бер гамәлләр кылганда (әйтик, товар сатып алганда, валюта алмаштырганда, чит илләрдән товар кайтарганда) түләнә һәм товарлар, хезмәт күрсәтүләр бәясенә кертелеп (мәсәлән, сатуга салым, таможня пошлинасы), кулланучылардан түләтелә.

Хәзерге заман предприятиеләре салымнарның нинди төрләрен түли соң?

Фирмадан турыдан-туры салым — табышка салым дөньяда киң кулланыла. Россиядә закон белән барлык предприятие һәм оешмалар табышына салым каралган, ә кайбер илләрдә бу салымны фәкать акционер компанияләре генә түли, кече предприятиеләр һәм ширкәтләргә керем салымы салына. Күпчелек очракларда табышка салым тулай табыштан, ягъни фирманың

барлык керемнәре һәм барлык чыгымнары арасындагы аермадан 35% тәшкил итә. Табышка салым ставкасы эшчәнлек төренә карап төрлечә булырга мөмкин. Әйтик, банклар, иминиятләштерү компанияләре, биржалар һәм арадашчылык эшчәнлегеннән керемнәргә салым 43% ставкасыннан салына, ә казино һәм уен бизнесына — 90% ставкасыннан. Әмма хөкүмәткә җәмгыять өчен файдалы гамәлләрне кызыксындырырга мөмкинлек бирүче салым ташламалары да бар. Россиядә, мәсәлән, табышның җитештерүне үстерүгә, фәнни тикшеренүләргә, хәйрия чараларына инвестицияләр өчен файдаланылучы өлеше салымнан өлешчә азат ителә. Авыл хуҗалыгы продукциясе җитештерүдән һәм реализацияләүдән алынган табышка салым салынмый.

Фирмадан читләтелгән салым — өстәмә бәягә салым (ӨБС). Ул икътисадчылар тарафыннан чагыштырмача күптән түгел уйлап чыгарылган (беренче тапкыр XX гасырның 60 нчы елларында кертелә), әмма бүген аңардан инде 50 ләп ил файдалана. Россиядә бу салым 1992 елда кертелгән һәм ул салым системасының нигезен тәшкил итә. Бу салым керү исәбенә федераль бюджетның керем өлешенең өчтән бере формалаша.

Өстәмә бәягә салым товарның ахыргы кулланучыга хәрәкәте буенча җитештерүнең барлык стадияләрендә (чималдан — куллану әйберенә кадәр) барлыкка килүче товар бәясенең үсүенә салына. Һәр фирма өчен, чималга, материалга, җиһазларга һәм башка матди чыгымнарга сарыф ителгән сумманы алып ташлап, продукция сатудан файдага салым билгеләнгән.

Россиядә 2004 елда өстәмә бәягә салым ставкасы 18% дәрәҗәсендә, ә аерым товарларга (иң беренче кирәк булган азык-төлек товарлары, балалар өчен товарлар) — 10% дәрәҗәсендә билгеләнгән. Бу күрсәткечләрне башка илләрдәге ӨБС дәрәҗәсе белән чагыштырыгыз (Франциядә — 18,6%, Англиядә — 15%, Германиядә — 14%, Люксембургта — 12%). Бу күрсәткечкә илнең икътисади үсеш дәрәҗәсе, дәүләтнең икътисади сәясәте ничек тәэсир итүен уйлагыз.

Эшмәкәрләргә төрле бюджеттан тыш фондларга (пенсия, социаль иминиятләштерү, мәҗбүри медицина иминиятләштерүе һ.б.) түләргә туры килә. Эшмәкәр күзлегеннән караганда, бу кертемнәр дә салым булып тора.

Практика раслаганча, салымнарның югары булуы актив хезмәт белән кызыксынуны киметә, тулаем эшлеклелек активлыгын төшерә. Америка икътисадчысы Лаффер керемгә салым ставкасы 59% тан югары булганда эшмәкәрлек эшчәнлегенең кискен төшүен теоретик яктан исбатлады.

Һәр хөкүмәт предприятиеләргә салым салуның, аларның җитештерүен үстерү һәм киңәйтү өчен тиешле акчалары калсын

өчен, мөмкин булган оптималь вариантын эзләү проблемасын хәл итәргә мәҗбүр.

ГАМӘЛИ НӘТИҖӘЛӘР

1 Җитештерү эшчәнлеген эффектлы оештыру шартларын һәм ысулларын белү сезгә анда актив һәм нәтиҗәле катнашу мөмкинлеге бирә. Шуны истә тотарга кирәк, бу эшчәнлекнең уңышы сезнең оештыру, интеллектуаль сәләтегездән генә тормый, ә булган чикле ресурслардан оста файдалануга да бәйле.

2 Сезнең һәркайсыгыз бер яки берничә җитештерү факторына ия. Алардан нәтиҗәле файдалану юлларын һәм ысулларын табарга һәм керем алырга тырышырга кирәк.

3 Үз эшеңне оештыру турында карар кабул итү өчен киләчәк эшчәнлекнең чыгымнарын һәм мөмкин булган керемнәрен анализлау һәм чагыштыру зарур. Бу исә булган ресурслардан файдалануның икътисади дөрес юлын сайларга һәм зыян күрү, бөлгенлек ихтималын кисәтергә мөмкинлек бирер.

ДОКУМЕНТ

Базар ничек итеп производство чыгымнарын һәм нәтиҗәләрен җайга сала. *Хәзерге заман Россия икътисадчысы* ***В.И.Данилов-Данильянның*** «Базарга качу» китабыннан

Базар чыгымнар һәм нәтиҗәләрне шулай итеп җайга сала ки, гомумиләштерелгән күрсәткечләрдә алар һәр максатка яраршлы производство өчен якынча пропорциональ була. Нинди дә булса җитештерүченең нәтиҗәләре чыгымнарны узып китсә, классик схема буенча, бу эшчәнлек тармагына башкалар омтыла. Бу тәкъдим артуга, продукциягә бәяләр кимүгә китерә һәм чыгымнар белән нәтиҗә арасында стандарт чагыштырма урнаша. Әгәр дә, киресенчә, барлык чыгымнар нәтиҗәне узып китсә, ул җитештерүче бөлгенлеккә төшә, аның производствосы ябыла. Рентабельле булмаган нәрсә яши алмый, артык зур рентабельле булса, яңа көчләр куллану өлкәсенә әверелә, чыгымнар һәм нәтиҗәләр тигезлеге ике очракта да торгызыла. А.Смит тарафыннан ук эшләнгән бу классик схема реаль процессларны һәркайчан төгәл чагылдырмаса да, принципта дөрес булып кала. Хәтта җитештерүче монополист булганда да, тасвирланган типтагы үзгәрешләргә, аерым эффектлылыкның уртачадан югарылыгын киметүгә китерүче көчле басым килеп чыга.

Документка сораулар һәм биремнәр

1. Әлеге фрагмент текстына таянып, базарның чыгымнарны һәм житештерү нәтиҗәләрен ничек итеп җайга салуын аңлатыгыз. Базар шартларында үзенең производствосы уңышлы эшләве белән кызыксынган җитештерүченең эшчәнлеген характерлагыз. Аның табыш алуы нәрсәгә бәйле? 2. Австриянең танылган икътисадчысы Йозеф Шумпетер базар тарафыннан иске товарларны, табыш китермәүче технология, идеяләрне кысрыклап чыгару һәм аларны яңалары белән алыштыруны «иҗади җимерү системасы» дип атый. Ни өчен шулай булуын уйлагыз. 3. Документ текстын һәм параграф материалын кулланып, мондый механизм тәэсиренең сәбәпләрен һәм нәтиҗәләрен тикшерегез. 4. Базарны «җитештерү чыгымнары һәм нәтиҗәләрен объектив иҗтимагый үлчәүнең бердәнбер инструменты» дип атарга мөмкинме? Җавабыгызны дәлилләгез.

ҮЗ-ҮЗЕҢНЕ ТИКШЕРҮ ӨЧЕН СОРАУЛАР

1. Предприятие эшчәнлегенең уңышы нәрсәгә бәйле? 2. Җитештерү факторлары иясе булып нинди керемнәр алырга мөмкин? 3. Капиталың булмый торып керем алып буламы? 4. Җитештерүче чыгымнарны һәм табышны ни өчен исәпләп карый? 5. Нәрсә ул «эффектлы предприятие»? 6. Фирмалар нинди салымнар түли?

БИРЕМНӘР

1. Түбәндәгеләрне эшләү өчен кирәк булган чыгымнар исемлеген төзегез: көнкүреш техникасын ремонтлау остаханәсе ачарга; кафеда 30 кешегә кичке аш мәҗлесе оештырырга; спорт инвентарен прокатка бирү пункты ачарга.

2. Полиграфия комбинаты продукциясенә сорау арту җитештерү күләмен арттыруны таләп итә. Җитештерүнең нинди чыгымнары — даимимы, әллә алмашынучыларымы — хәлиткеч әһәмияткә ия булачак?

3. «Конус» фирмасы товар ассортиментын киңәйтү исәбенә җитештерүне арттырырга булды. Продукция эшләп чыгару түбәндәге гомуми чыгымнарны таләп итте: чимал — 500 мең сум, эшчеләргә хезмәт хакы — 100 мең сум, ягулык — 70 мең сум, транспорт хезмәтләре — 7 мең сум, кадрлар әзерләүгә һәм яңадан әзерләүгә чыгымнар — 6 мең сум, мөлкәтне иминиятләштерү буенча акча күчерү — 1 мең сум. Даими һәм алмашынучан чыгымнар суммасын исәпләп чыгарыгыз.

4. Предприятие табышының зурлыгы бер елда 100 миллион сум, ә җитештерү чыгымнары — 60 миллион сум булды. Аның эшчәнлеге рентабельлелеген санап чыгарыгыз. Хуҗалык итү күзлегеннән караганда бу производствоны максатка ярашлы дип буламы, һәм ни өчен шулай икәнлеген аңлатыгыз.

ЗИРӘКЛӘР ФИКЕРЕ

«Эшмәкәрнең оптимизмы — хуҗалык эшлеклелегенең этәргеч көче, ә исәплән карау хирыслыгы — аның үз-үзен саклау көче».

Г.К.Гинс (1887—1971), рус язучысы, хокук белгече

§ 5. Эшмәкәрлек эшчәнлегенең хокукый нигезләре

Кеше нигә үз эшен ача? Эшмәкәр нәрсәсен югалтырга мөмкин? Тәвәккәлләми генә табыш алып буламы? Ә табышсыз гына тәвәккәлләргә? Һәркем дә эшмәкәр була аламы?

Әгәр дә сез мөстәкыйль, тәвәккәл икәнсез, эшкә иҗади якын киләсез ди, бу сыйфатлар сезгә, бәлки, үз бизнесыгызны булдырырга ярдәм итәр. Тормышта үз бизнесыңны булдыру нәрсә соң ул? Шул хакта җентекләбрәк сөйләшик.

ЭШМӘКӘРЛЕКНЕҢ ХОКУКЫЙ НИГЕЗЛӘРЕ

Үз эшләрен башларга, бизнес белән шөгыльләнергә теләүче кешеләр еш кына юристларга консультация сорап мөрәҗәгать итәләр, һәм бу гаҗәп тә түгел. Бизнес (яки эшмәкәрлек) төшенчәсе безнең тормышка әле күптән түгел генә, әмма ныклап кереп китте.

Эшмәкәрлек — табыш алуга юнәлтелгән мөстәкыйль инициативалы икътисади эшчәнлек ул. Россиядә базар мөнәсәбәтләренең үсүе байтак кешене икътисади үзешчәнлеккә этәрде. Күпчелек очракта бу эшмәкәрлек эшчәнлеге белән шөгыльләнә башлаучыларның ничек тә булса яшәргә, үзгәргән тормышның катлаулы шартларында югалып калмаска, социаль-икътисади мөнәсәбәтләрнең яңа структурасында үз урынын алырга омтылышы белән бәйле иде. Барысы да уңышка ирешә, һәр эшмәкәр үз бизнесын саклап кала һәм ишәйтә алмады. Хәзер эшмәкәрлекнең әһәмияте арта бара: эшмәкәрлек ирекле җитештерүчеләрнең иҗади көчләрен уңышлы хәл итеп кенә калмый, ил икътисадының нәтиҗәле үсешен дә тәэмин итә.

Икътисадчылар эшмәкәрлек сәләтен «җитештерүнең дүртенче факторы» дип атыйлар, башка барлык факторларны (җир, хезмәт, капитал) уңышлы берләштерү һәм алардан файдалану өчен аның әһәмиятен ассызыклап күрсәтәләр. Эшмәкәр җитештергән бар нәрсә (товар, хезмәт күрсәтү) җәмгыять куллануы өчен билгеләнгән. Эшмәкәрлектә икътисади һәм социаль аспектларның тыгыз бәйләнешен аерып күрсәтү зарур. Эшмәкәр продукция җитештерә һәм, табыш алуга омтылып, җитештерүнең яңа мөмкинлекләрен эзләп таба (икътисади аспект), хезмәт эшчәнлеге процессында кешеләрнең тормыш эшчәнлеге шартлары һәм иҗтимагый мөнәсәбәтләр яңартыла (социаль аспект).

Илдәге эшмәкәрлек климаты нәрсәгә бәйле соң? Эшмәкәрлеккә ярдәм итүдә һәм аны үстерүдә дәүләтнең роле нинди? Дәүләт масштабында эшмәкәрлек эшчәнлеген уңышлы үтәүнең берничә шартын санап үтәргә була: икътисади ирек, икътисадта көндәшлек (конкуренция) мохитен хуплау, эшмәкәрлекне үстерү өчен хокукый нигез булдыру. «Цивилизацияле» эшмәкәрлекне «кыргый»дан эшмәкәрлекнең һәм кулланучыларның хокукларын *закон белән яклау дәрәҗәсе аерып тора*. Хәзерге заман Россия законнарында эшмәкәрлек хокукы мөстәкыйль хокук тармагы булып тора.

Эшмәкәрләрнең хокукый мөнәсәбәтләре — эшмәкәрлек өлкәсендә иҗтимагый мөнәсәбәтләр, шулай ук алар белән бәйле коммерциячел булмаган мөнәсәбәтләр һәм базар икътисадын дәүләт җайга салуы буенча булган мөнәсәбәтләр — шактый киң законнар даирәсе һәм хокукый актлар белән җайга салына. Эшмәкәрлек хокукының чыганакларын Россия Федерациясе Конституциясе, Россия Федерациясе Кодекслары: Граждандлык, Салым, Бюджет, Административ хокук бозулар турындагы, җинаять кодекслары тәшкил итә. Эшмәкәрлек эшчәнлегенә дәүләт таләпләрен билгеләүче законнар булып, мәсәлән, «Юридик затларны һәм индивидуаль эшмәкәрлекне дәүләт теркәве турында», «Эшчәнлекнең аерым төрләрен лицензияләү турында» Россия Федерациясе законнары тора. Эшмәкәрлек эшчәнлегендә катнашучы кайберәүләрнең хокукый хәлен «Акционер җәмгыятьләре турында», «Җитештерү кооперативлары турында», «Финанс-сәнәгать төркемнәре турында» Федераль законнар урнаштыра. Закон актлары исемлеген тагын да дәвам итеп булыр иде.

Россия Федерациясе Граждан кодексының 2 нче статьясындагы 1 пункты нигезендә эшмәкәрлек эшчәнлеге дип «мөстәкыйль, үзең тәвәккәлләп мөлкәттән файдаланудан, товарлар сатудан, эшләр башкару яисә законнар белән билгеләнгән тәртиптә шул сыйфатта теркәлгән затлар тарафыннан хезмәт

күрсәтүдән системалы рәвештә табыш алуга юнәлтелгән эшчәнлек» танылa. Эшмәкәрлекне хокукый җайга салуның нигезенә берничә төп хокукый принцип салынган. Аларның кайберләрен билгеләп үтик.

Ирекле икътисади эшчәнлек принцибы Россия Федерациясе Конституциясенең 34 статьясында игълан ителә, аның текстында болай диелә: «Һәркем үз мөмкинлекләрен һәм мөлкәтен эшмәкәрлек һәм закон белән тыелмаган башка төрле икътисади эшчәнлек өчен ирекле файдаланырга хокуклы». Шул ук вакытта, әгәр конституциячел стройны, әхлакны, саулыкны, экология иминлеген яклау һ.б. таләп итсә, бу ирек чикләнергә дә мөмкин. Эшмәкәрлек эшчәнлеге сыйфатында нәрсә белән шөгыльләнергә ярамавы турында уйлагыз.

Намуслы конкуренциягә ярдәм итү һәм базарны монополизацияләүгә юнәлтелгән эшмәкәрлек эшчәнлегенең рөхсәт ителмәве принцибы байтак законнарда үсеш алды. Базарны монополияләштерү проблемасы базарга күчү белән бер үк вакытта диярлек барлыкка килде. (Нинди законнарның конкуренцияне яклауга юнәлтелүен искә төшерегез.)

Милекчелек рәвешләренең күптөрлелеге, аларның юридик тигезлеге һәм аларны яклау тигезлеге Россия Федерациясе Конституциясенең 8 статьясында беркетелгән: «Россия Федерациясендә хосусый, дәүләти, муниципаль һәм милекчелекнең башка рәвешләре бер үк дәрәҗәдә танылa һәм яклана». Теге яки бу милек рәвешен яклауда өстенлекләр билгеләнә алмый. Милек рәвешенең күптөрлелеге эшмәкәрлек эшчәнлегенең төрле оештыру формаларында үсеш алды.

ЭШМӘКӘРЛЕКНЕҢ ОЕШТЫРУ-ХОКУКЫЙ РӘВЕШЛӘРЕ

Эшмәкәрлек хокукый мөнәсәбәтләрендә катнашучыларны **«эшмәкәрлек хокукы субъектлары»** дип атыйлар. Кем эшмәкәрлек хокукы субъекты була ала соң? Үз эшеңне нинди рәвештә ачу яхшырак? *Гражданнарның* эшмәкәрлек эшчәнлеге йә индивидуаль эшмәкәрлек, йә фермер хуҗалыгы буларак рәсмиләштерелә ала. *Коммерция оешмалары* яши алган оештыру-хокукый формалар гаять күптөрле: бу хуҗалык ширкәтләре (тулы ширкәтләр һәм ышаныч ширкәтләре) хуҗалык җәмгыятьләре (җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятьләр, өстәмә җаваплылыктагы җәмгыятьләр, акционер җәмгыятьләре), җитештерү кооперативлары, Дәүләт эшмәкәрлек эшчәнлегендә дәүләт һәм муниципаль унитар предприятиеләр, акционер җәмгыятьләр аша катнаша ала. Эшмәкәрлекнең иң киң танылган рәвешләренә тукталып үтик.

«Юридик зат булдырмыйча теркәлгән индивидуаль эшмәкәр» (ЮЗБТИЭ) төшенчәсе бүген шактый киң кулланыла. Россия Федерациясе Граждан кодексының 23 статьясы, гражданин дәүләт теркәве мизгеленнән юридик зат булдырмыйча эшмәкәрлек эшчәнлеге белән шөгыльләнә ала, дип билгели. Индивидуаль эшмәкәр хокукларның киң спектрына ия: үзенең товар билгесен яисә хезмәт күрсәтү билгесен терки, фирма исеме астында эш йөртә ала. Теләсә нинди коммерция оешмасы кебек үк, ул гамәлдәге законнар нигезендә яллаулы хезмәттән файдаланырга хокуклы. «Индивидуаль эшмәкәр» дигән рәсми статус аны дәүләт тануын һәм аның эшмәкәрлек эшчәнлеге өчен уңай шартлар тудырылуын белдерә (эшенә тыкшынмау, хокукый яклау), ләкин шул ук вакытта аңа мәгълүм бер таләпләр куелуны да (хисаплылык, салым салу) күздә тотыла. Эшмәкәргә, мәсәлән, ул хосусый саклау эшчәнлеге, укытучылык һ.б. белән шөгыльләнсә, квалификация таләпләре дә куелырга мөмкин. Эшмәкәрлекнең бу рәвешендә җитди уңайлыклар да бар: кеше үзенә-үзе хуҗа (шуңа ул индивидуаль эшмәкәрлек та инде), дәүләт теркәве иң гади вариантта уза, зур старт капиталы таләп ителми. Әмма «яну» куркынычы да зур: индивидуаль эшмәкәр тулы мөлкәти җаваплылык тота — үзенең йөкләмәләренә барлык мөлкәте белән җавап бирә. Мөгаен шуңадыр да, еш кына эшмәкәрлек эшчәнлеге белән рәсми теркәүсез шөгыльләнергә маташалар — әйтик, кулдан гына гади әйберләр ясыйлар, рөхсәтсез генә сәүдә итәләр — ләкин мондый эшчәнлек законсыз!

Юридик зат оештыруның бер рәвеше булып **ширкәтләр** тора. Ул оешмада капитал аны гамәлгә куючыларның өлешләренә (кертемнәренә) бүленгән; ширкәтне гамәлгә куючылар фәкать индивидуаль эшмәкәрләр (гади гражданнар гына түгел) һәм коммерция оешмалары була ала; Россия Федерациясе Граждан кодексы ширкәтләрнең ике рәвешен: тулы ширкәт һәм ышанычлылык ширкәтен аерып карый.

Тулы ширкәттә анда катнашучылар ширкәт бурычлары өчен үз мөлкәте белән җавап биреп кенә калмый, солидар рәвештә бер-берсе өчен дә җавап бирәләр: «берәү барысы өчен һәм барысы да берәү өчен». Тулы ширкәт булдыру өчен кирәк булган капиталның минималь күләме билгеләнми, бу аңлашыла да: анда катнашучыларның җаваплы булуы җитә. Ширкәттән чыккан зат аның йөкләмәләре буенча тагын ике ел дәвамында җаваплы була.

Ышанычлылык ширкәтендә аның йөкләмәләре буенча үзләренең барлык мөлкәте белән җавап бирүчеләрдән тыш, тагын берничә катнашучы — кертемчеләр бар, алар зыян күрү куркынычы өчен үзләренең кертемнәре чикләрендә генә җавап

бирә һәм ширкәтнең эшмәкәрлек эшчәнлегендә катнашмый. Ышанычлылык ширкәте кертемчесе үз өлешенә тиешле табышны алу хокукына ия. Кертемче (ширкәттә катнашучыдан аермалы буларак) теләсә кайчан ширкәттән чыгарга һәм үз кертемен алырга мөмкин.

Ширкәтләрдә (алар нинди рәвештә булуга карамастан) көчле һәм йомшак якларны табып карыйк. Оештыру кыенлыкларыннан башлыйк: ширкәт булдыру өчен гражданга иң элек индивидуаль эшмәкәр сыйфатында теркәлергә кирәк. Ширкәт партнерлар арасында максималь ышаныч булуны таләп итә. Җаваплылыгы да зур: үзең өчен генә түгел, иптәшең өчен дә, ә бәлки бөтен мөлкәтең белән җавап бирергә туры килә. Әмма ширкәт рәвеше, башка эшмәкәрлек формаларына караганда, клиентларда да, кредиторларда да күбрәк ышаныч тудыра.

Җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятьне (ҖЧҖ) гражданнар да, юридик затлар да гамәлгә куя ала (анда катнашучыларның минималь саны — 1, максимале — 50). ҖЧҖнең устав капиталы анда катнашучылар керткән кертемнәр бәясеннән тора һәм төзелүче оешма мөлкәтенең минималь күләмен билгели. Ул кимендә 100 минималь хезмәт хакы күләмендә булырга тиеш. Капитал ҖЧҖдә катнашучылар арасында гамәлгә кую документлары нигезендә өлешләргә бүленә (өлешләр ҖЧҖне төзүчеләр санынча булачак, бер үк вакытта аларның өлешләре тигез булмаска да мөмкин). Устав капиталына кертемнәр акчалата да, кыйммәтле кәгазьләр дә, матди байлыклар да була ала. Әгәр дә ҖЧҖ әгъзаларының берсе җәмгыятьтән чыгарга теләсә, оешма аның белән исәп-хисап ясарга, ягъни аның өлеше бәясен түләргә тиеш. Җәмгыятьтә катнашучылар аның йөкләмәләре буенча җавап бирми һәм ҖЧҖ эшчәнлеге белән бәйле зыянны үзләре кертемнәре бәясе чикләрендә генә каплау өчен җаваплы була. Эшмәкәрлекнең нәкъ менә шушы рәвеше иң еш очрый — күп нәрсә кызыктыра: булачак ҖЧҖдә катнашучыларны билгеләгәндә киң мөмкинлекләр; җәмгыятьтән чыгуның чагыштырмача гади формасы; мәгълүм бер «җавапсызлык» — максималь тәвәккәллек эшмәкәр кертеме күләменә туры килә. Дөрес, шунысын да онытмаска кирәк, ҖЧҖ төзү өчен минималь күләме алдан ук билгеләнгән устав капиталы теләп ителә.

Акционерлар җәмгыяте — коммерция оешмасының тагын бер рәвеше. Җәмгыятьнең устав капиталы акционерлар җәмгыятенең үз акционерлары алдындагы йөкләмәләрен ачыклаган акцияләр санына бүленә. ҖЧҖдәге кебек үк, гамәлгә куючылар гражданнар да, юридик затлар да була ала. Акционерлар җәмгыяте *ачык* була ала (ААҖ), ул чакта чыгарыла торган акцияләргә ачык язылу уздырырга, акцияләрне ирекле

сатарга мөмкин. *Ябык* акционерлар җәмгыятендә (ЯАҖ) акцияләр, кагыйдә буларак, акцияләр җәмгыятьтә катнашучылар арасында бүленә, чыгарыла торган акцияләргә язылу һәм аларны ирекле сату алып барылмый. Ачык акционер җәмгыятенең устав капиталы кимендә 1000 минималь хезмәт хакы күләмен тәшкил итәргә тиеш, ә ябык акционер җәмгыятенең — кимендә 100. Акционерлар җәмгыятеннән үз акцияләреңне сатып чыгарга мөмкин. Акционерлар җәмгыятендә катнашучылар (акционерлар) җәмгыять йөкләмәләре буенча җаваплы булмый, ә зыян күрү куркынычы аларда булган акцияләр бәясе чикләрендә генә була. Акционерлар җәмгыяте һәм җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятьнең уңай һәм тискәре яклары гаять охшаш.

Дәүләти һәм муниципаль унитар предприятиеләрнең статусы бөтенләй башка — бу үзенә беркетелгән мөлкәткә милек хокукы булмаган коммерция оешмалары. Унитар предприятие мөлкәте бүленми (шуңа исеме дә «унитар»). Андый предприятие җитәкчесе берүзе башкарма орган булып тора. Унитар предприятие җитәкчесен (директор, генераль директор) үз вазифасына билгеләп кую, аны эштән азат итү һәм башка мәсьәләләр предприятие Уставы белән билгеләнә. Унитар предприятиенең күчемсез мөлкәте сатыла, арендага бирелә һ.б. алмый, чөнки ул предприятие милке түгел, ә дәүләтнеке яисә муниципаль милек.

Эшмәкәрлек эшчәнлегенең башка төрле оештыру-хокукый рәвешләре дә бар. Сез эшмәкәр булырга уйладыгызмы — нидән башларга соң?

ҮЗ ЭШЕҢНЕ НИЧЕК АЧАРГА

«Үз эшемне булдырырга» дигән карар эшмәкәрдән җитди көч куюны таләп итә. Теләсә кайсы эшмәкәр үз идеяләрен гамәлгә ашыру юлында узарга тиешле этапларны аерып карыйк. Идея турында әйткәндә: үз эшеңне булдыруда хәлиткеч этап булып иң беренче адым — *эшмәкәрлек идеяләрен* нигезләү тора, чөнки нәкъ менә шул этапта икътисади мәнфәгать һәм булачак эшмәкәрлек эшчәнлегенең этәргече ачыклана. Бу вакытта акча эшләү теләге гади генә базар принцибына нигезләнә: ихтыяҗ табу һәм аны канәгатьләндерү. Мәсәлән, сезнең кәгазь очкычлар җитештерергә теләвегез, мөгаен, берәүне дә кызыксындырмас, аларны алмаслар. Нindидер оригиналь әйбер уйлап чыгарырга кирәк: мәсәлән, чит ил үрнәгендәге тиз укландыру предприятиеләре белән беррәттән, Россиядә төрле-төрле бөккән, белен кебек әйберләр белән сыйлау урыннары калкып чыкты.

Сез нәрсә белән шөгыльләнәчәгегезне хәл иттегез ди. Аннары нишләргә? Коммерция оешмасы төзергә булганнарга аны *гамәлгә куючылар составын* билгеләү һәм булачак оешманың *оештыру-хокукый рәвешен* сайлау зарур. Фирманың гамәлгә куючылары физик затлар да, юридик затлар да була ала. Әгәр гамәлгә куючылар фикердәшләр һәм үз эшләренең энтузиастлары булса, әлбәттә, яхшы — монда инде уңышка ирешү ихтималы арта. Гамәлгә куючылар составын һәм санын күздә тоткан кагыйдәләр барлыгын сез инде беләсез. Әйтик, хуҗалык җәмгыятен бер зат төзи ала; ябык җәмгыять акционерлары саны 50дән артык була алмый, ә ачык акционерлар җәмгыяте акционерлары саны чикләнмәгән. Башка чикләүләр дә бар: дәүләт хезмәткәре гамәлгә куючы була алмый. Мөмкин булган кайбер оештыру-хокукый рәвешләр белән сез инде таныш. Гамәлгә куючылар аларның теләсә кайсын сайлап алырга мөмкин.

Коммерция (сәүдә) оешмасының *исемен табу* да әһәмиятле. Россия Федерациясе Граждан кодексының 54 статьясы нигезендә юридик затның атамасы, анда мәҗбүри төстә аның оештыру-хокукый рәвеше булырга тиеш. Мәсәлән, «Ышаныч» ҖЧҖ. Фирма атамасы исем яки фамилия белән тәкъдим ителә ала, эшчәнлек характерын чагылдырырга мөмкин, ирекле дә була ала — монда фантазиягә урын чиксез диярлек. Атамалар кабатланмасын өчен, аны алдан тикшерү, оешманың исеме оригиналь булу тәртибе бар. Коммерция оешмалары атамаларында «Россия», «Россия Федерациясе» сүзләрен куллану өчен аерым тәртип урнаштырылган — моның өчен сезгә өстәмә рөхсәт алырга кирәк. Сез ничек уйлыйсыз — бу нигә шулай эшләнгән?

Аннан соңгы этап — *гамәлгә кую документларын рәсмиләштерү*. Әгәр дә икеләнсәгез, белгечләр белән киңәшү яхшы. Гамәлгә кую документларына килгәндә, кооперативлар, унитар предприятиеләр, акционер җәмгыятьләре өчен ул — Устав. Ширкәтләр өчен Гамәлгә кую шартнамәсе төзергә кирәк. Чикләнгән һәм өстәмә җаваплылыклы җәмгыятьләр өчен Устав та, Гамәлгә кую шартнамәсе дә рәсмиләштерү зарур. Боларның нинди документлар булуын ачыклап үтик.

Устав (нормалар һәм кагыйдәләр җыелмасы) гомуми нигезләмәләрне, эшчәнлек максатларын һәм предметларын эченә ала, предприятиенең матди-техник базасын һәм акчаларын, идарә һәм контроль органнарын барлый, җитештерү, финанс-хуҗалык эшчәнлеген тасвирлый, төзелүче оешманы үзгәртеп оештыру һәм аның эшчәнлеген туктату шартларын билгели.

Гамәлгә кую шартнамәсе (ике һәм аннан күбрәк якларның килешүе) төзелүче предприятиенең юридик статусын беркетә,

устав капиталын һәм аны формалаштыру тәртибен билгели, керемнәрне бүлешү тәртибен, якларның бурычларын урнаштыра. Күпьяклы документ буларак, шартнамә аны төзегән физик һәм юридик затлар тарафыннан имзалана. Сез сайлаган оештыру-хокукый рәвешләрдәге эшмәкәрлекнең кирәкле гамәлгә кую документларының якынча үрнәкләрен юридик белешмә басмаларында табарга мөмкин.

Үз эшеңне ачуда ахыргы этап булып *дәүләт теркәве* тора. Барлык юридик затлар да вәкаләтле дәүләт органы — Федераль салым хезмәтендә дәүләт теркәве узарга тиеш. Төзелгән һәр юридик зат турындагы мәгълүмат дәүләт реестрына керә, фирманы яңадан үзгәртеп оештыру яки ябу турындагы белешмә дә шул ук реестрга кертелә. Төзелүче оешманы теркәү өчен түбәндәге документлар кирәк:

— расланган форма буенча дәүләт теркәве турында гариза. Анда, башка мәгълүмат белән беррәттән, тапшырылган документларның Россия Федерациясе законнары билгеләгән таләпләргә туры килүе һәм аларда күрсәтелгән мәгълүматның дөрес булуы раслана. Гариза бирүченең имзасы нотариаль расланган булырга тиеш;

— юридик зат булдыру турындагы карар. Ул гамәлгә куючылар җыелышы беркетмәсе, гамәлгә кую шартнамәсе яисә Россия Федерациясе законнары нигезендә башка документ булырга мөмкин;

— юридик затның гамәлгә кую документлары (төп нөсхә яки нотариаль таныкланган күчермә);

— дәүләт пошлинасын түләү турында документ.

Индивидуаль эшмәкәрләр теркәүне яшәү урыннары буенча салым хезмәтендә уза. Моның өчен эшмәкәр шәхсән үзе дәүләт теркәве турында билгеләнгән формада гариза; аның шәхесен ачыклаучы төп документ (паспорт) күчермәсен; дәүләт пошлинасын түләү турында документ бирә.

Дәүләт теркәве процессы документлар бирүдән соң 5 эш көненнән дә күбрәк вакытны алырга тиеш түгел. Дәүләт теркәве турындагы карар нигезендә яңа төзелгән юридик зат яисә индивидуаль эшмәкәр хакында белешмәләр тиешле дәүләт реестрына кертелә; шуннан соң гариза бирүчегә бу фактны раслаучы документ — *Теркәү турында таныклык* бирелә. Теркәүдән баш тарта алалармы соң? Моңа җавапны Россия Федерациясе Граждан кодексының 51 статьясында табабыз, анда, теркәүдән баш тарту фәкать коммерция оешмасын төзүнең закон белән билгеләнгән тәртибен бозу яисә гамәлгә кую документларының законга туры килмәве белән нигезләнергә мөмкин, диелгән. Сезнең эшчәнлек «беркемгә дә кирәкми» дип кенә баш тарта алмыйлар.

Дәүләт теркәве узу гына да җитми икән әле. Эскизы шулай ук теркәлүче һәм тиешле реестрга кертелүче мөһер әзерләргә кирәк. Дәүләт гамәлдәге юридик затларның исәбен алып бара: барлык оешмалар статистика органнарында теркәлә, анда юридик затка тиешле код бирелә. Шуннан соң гына банкта исәп-хисап счеты ачарга мөмкин. Россия дәүләт статистика комитетына үз белешмәләрен индивидуаль эшмәкәрләр дә бирергә бурычлы. Россия Федерациясе Салым кодексы барлык юридик затлардан һәм индивидуаль эшмәкәрләрдән салымнарны үз вакытында түләп баруны таләп итә. Моның өчен сезгә салым хезмәтендә исәпкә басарга кирәк, бу турыда тиешле Исәпкә кую турында таныклык алачаксыз. Шулай ук дәүләт бюджеттан тыш социаль фондларына: пенсия, халыкны эш белән тәэмин итү, дәүләт социаль иминиятләштерүе, медицина иминиятләштерүе фондларына исәпкә басарга кирәк. Нәкъ менә шул фондлар аша пенсия күчерелә, авырган вакытта больничный лист түләнә.

Эшмәкәрлекнең аерым төрләре өчен дәүләтнең махсус контроле таләп ителә, ул чакта сезгә тагын бер документ — **лицензия** — таләпләрне һәм шартларны мәҗбүри үтәп, мәгълүм бер эшчәнлек төре башкаруга махсус рөхсәт кирәк булачак. «Эшчәнлекнең аерым төрләрен лицензияләү турында» Россия Федерациясе Законы буенча мәгариф, биржа, иминиятләштерү һәм башка эшчәнлек төрләре лицензияләнергә тиеш.

Һәм менә дәүләт теркәве турында документлар җыелды, кирәк булганда, лицензия дә алынды — димәк, тынычлап эшли башларга мөмкин. Катлаулымы? Мәшәкатьлеме? Әйе! Әмма, әгәр уйлап карасаң, эшмәкәрлек эшчәнлегенә дәүләт ягыннан шундый җитди контроль кулланучыларны сыйфатсыз продукциядән, намуссыз хезмәт күрсәтүдән һәм алдаулардан сакларга тиеш. Бәлки, гамәлдәге законнар да камил түгелдер. Үз эшеңне башлау өчен кирәк булган кәгазьләр саны бик күп булып тоела. Һәм бүген ул Россиядә эшмәкәрлекне тагын да үстерү өчен бер киртә булып тора. Ләкин искә төшерик әле: кайчан гына «бизнес» төшенчәсе нииндидер ярамаган бер нәрсә кебек иде, ә эшмәкәрлек хокукы бөтенләй булмады. Барысы да бик тиз үзгәреп тора.

Башка бер мәкерле уй килергә мөмкин: дәүләт теркәвеннән башка гына булмыймы соң?

Гамәлдәге законнарга күз төшерик: эшмәкәрлек эшчәнлеген дәүләт теркәвеннән башка тормышка ашыру хокук бозу булып тора һәм административ яки җинаять җаваплылыгына китерергә мөмкин. Үз эшчәнлегегезне дөрес рәсмиләштерү, бу өлкәне хокукый җайга салу нечкәлекләрен белү сезгә җәмгыятьтә тиешле статус алырга мөмкинлек биреп кенә калмый, эшмәкәрлек эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген күтәрүгә дә китерер.

ГАМӘЛИ ЙОМГАКЛАР

1 Американың уңган бизнесмены М.Смолл, үз тәҗрибәсеннән чыгып, эшмәкәрлек максатына (идеясенә) ирешүнең биш кагыйдәсен формалаштырган. Бәлки, алар сезгә дә ярдәм итәр:

— «Мин акча эшли алам» дигән карар кабул итегез. Безнең заманда безнең илдә кеше бай булырга мөмкин.

— Акча эшләү өчен сез бу хакта даими — ашаганда, һавада йөргәндә, хәтта төнлә йоклаганда да уйлагыз.

— Сез уңышка ирешә алырлык эшчәнлек өлкәләре күп. Эзләсәгез, сез аларны табарсыз.

— Сез хаталар да ясарсыз. Ләкин рухыгызны төшермәгез. Үзегезнең һәм башкаларның хаталарында өйрәнегез. Абынган җирдән башлагыз. Алга барыгыз!

— Нинди дә булса идеягә килсәгез, аны даими үстерә барыгыз һәм уңышка ирешмичә туктамагыз.

2 Әлеге киңәшләргә тагын берне өстәргә кирәк: эшмәкәрлек эшчәнлеген җайга салуның хокукый нормалары турында онытмагыз, законнардагы үзгәрешләрне күзәтеп барыгыз. Бу сезнең бизнесны уңышлы үстерү өчен чыннан да әһәмиятле: эшмәкәрлек эшчәнлегендә хокукый мәсьәләләрдә ялгышу сезгә бик кыйммәткә төшәргә мөмкин.

ДОКУМЕНТЛАР

Россия Федерациясенең Административ хокук бозулар турында кодексыннан (*2001 елның 30 декабре*).

14.1 статья. Эшмәкәрлек эшчәнлеген дәүләт теркәвеннән башка яисә махсус рөхсәттән (лицензиядән) гайре тормышка ашыру

1. Эшмәкәрлек эшчәнлеген индивидуаль эшмәкәр сыйфатында дәүләт теркәвеннән башка яисә юридик зат сыйфатында дәүләт теркәвеннән гайре тормышка ашыру — биштән алып егермегә кадәр минималь хезмәт хакы күләмендә административ штраф салуга китерә <...>

Россия Федерациясе Җинаять кодексыннан (*2003 елның 8 апрелендәге редакциядә*).

171 статья. Законсыз эшмәкәрлек

1. Эшмәкәрлек эшчәнлеген теркәүдән тыш яисә теркәү кагыйдәләрен бозып башкару, шулай ук юридик затларны дәүләт теркәвен тормышка ашыручы органга ачыктан-ачык

ялган белешмәләре булган документлар бирү, яки эшмәкәрлек эшчәнлегенең мондый рөхсәт (лицензия) һичшиксез кирәк булган очракларда махсус рөхсәтсез (лицензиясез) яисә лицензия таләпләрен һәм шартларын бозып башкару, әгәр бу эш гражданнарны, оешмаларны яисә дәүләтне зур күләмдә зыян күрүгә яки зур күләмдә* керем алуга китерсә, — өч йөздән алып биш йөзгә кадәр минималь хезмәт хакы күләмендә штраф, ... яки йөз сиксәннән алып ике йөз кырык сәгатькә кадәр мәҗбүри эшләр ... яки өч елга кадәр вакытка ирегеннән мәхрүм итү белән җәзага тартыла.

---

* «Зур күләмдә керем алу» дип суммасы ике йөз минималь хезмәт хакы күләменнән артык керем таныла.

Документка сораулар һәм биремнәр

1. Китерелгән документларга бәя бирегез. **2.** Ни өчен бер үк хокук бозу (эшмәкәрлек эшчәнлеген теркәүсез башкару) өчен төрлечә хокукый эзәрлекләү күреләә? **3.** Россия Федерациясенең Административ хокук бозулар турында кодексының 14.1 нче статьясына туры килә торган мисал китерегез. **4.** Россия Федерациясе җинаять кодексының 171 нче статьясына туры килгән мисал китерегез.

ҮЗ-ҮЗЕҢНЕ ТИКШЕРҮ ӨЧЕН СОРАУЛАР

1. Эшмәкәрлек хокукый мөнәсәбәтләренә билгеләмә бирегез. Эшмәкәрлек хокукый мөнәсәбәтләрен нинди законнар җайга сала? **2.** Җитештерү эшмәкәрлеген үстерүгә нәрсә комачаулый? **3.** Эшмәкәрлек хокукы нигезендә нинди принциплар ята? Аларны шәрехләгез. **4.** «Эшмәкәрлек идеясен дәлилләү» дигәндә нәрсә күздә тотыла? Анык бер мисал китерегез. **5.** Гамәлгә кую шартнамәсеннән Устав нәрсә белән аерыла? **6.** Нәрсә ул лицензия? Лицензияләүнең максаты нинди? **7.** Эшмәкәрлек эшчәнлеген дәүләт теркәвеннән башка тормышка ашыру нәрсәгә китерә?

БИРЕМНӘР

1. Эшмәкәрлек эшчәнлегенең оештыру-хокукый рәвешләре чагыштырма таблицасын тутырыгыз.

№№	Оештыру-хокукый рәвеше	Катнашучылар	Гамәлгә кую документлары	Капитал	Җаваплылык

2. Үзегез нинди эш башлый алуыгызны уйлагыз. Параграф материалларына таянып, эшмәкәрлек эшчәнлеген башкаруның оештыру-хокукый рәвешен сайлап алыгыз. Үз сайлавыгызны нигезләгез.

3. «Башлаучы эшмәкәр өчен» дигән ярдәмлек төзегез. Анда үз эшеңне ачар өчен нинди документлар җыярга кирәклеген, теркәүне кайда узып булуын күрсәтегез.

4. Николай Р. һәм Петр С. эшмәкәрлек белән шөгыльләнергә — үзләренең саклау агентлыгын булдырырга карар бирде. Алар гражданин Николай Р. белән гражданин Петр С. арасында ышанычлылык ширкәте төзү турында Гамәлгә кую шартнамәсе төзеделәр, ә аны теркәү... барып чыкмады.

Булачак эшмәкәрләр нәрсәне исәпкә алмады?

5. Американың хәзерге заман икътисадчысы П.Друкер болай яза: «Фирманың үз продукциясе турында ни уйлавы иң төп нәрсә түгел, бигрәк тә киләчәк бизнес өчен һәм аның уңышы өчен. Үзе сатып алган әйбер турында кулланучы нәрсә уйлый, аның кыйммәтен нидә күрә — менә нәрсә хәлиткеч әһәмияткә ия, бизнесның асылын, аның юнәлешен һәм уңыш мөмкинлеген билгели».

Галим әйткәнне шәрехләгез.

ЗИРӘКЛӘР ФИКЕРЕ

«Эшмәкәр — теләсә нинди мөмкинлектән максималь отышлы файдаланучы кеше ул».

П.Друкер, Америка галиме

§ 6. Бизнеста уңыш нигезләре

Үз бизнесыңны үстерү өчен акчаны кайдан алырга? Бизнес белән идарә итү җиңелме? Менеджмент — ул фәнме яки идарә итү сәнгатеме? Җитештергән әйберне һәрвакытта да сатып буламы?

БИЗНЕСНЫ ФИНАНСЛАУ ЧЫГАНАКЛАРЫ

Теләсә кайсы эшмәкәр, инде белгәнегезчә, икътисадның теге яки бу тармагында үз эшен оештырганда барыннан да элек түбәндәге кагыйдәгә таяна: керемнәр чыгымнардан күбрәк булсын, ягъни ул үз товарларын җитештерүгә яисә хезмәт күрсәтүгә барлык чыгымнарны капларга һәм табыш алырга тиеш.

Әйтик, эшмәкәрнең эшләре әйбәт бара ди: кулланучыларга аның товары ошый, аңа сорау арта бара, җитештерүне киңәй-

тергә кирәк. Мәсәлән, ул чыгарылучы продукция күләмен арттырырга, югарырак квалификацияле хезмәткәрләр ялларга яки заманча җиһазлар алырга тели. Ләкин боларга акча кайдан табарга?

Икенче бер вариант. Эшмәкәрнең эшләре начар бара: чыгымнар керемнәрдән күбрәк, ә эшчеләргә хезмәт хакы бирергә, чимал куючылар белән исәп-хисап ясарга кирәк. Монда да шул ук проблема — акча кайдан алырга соң?

Предприятиенең акчалары «финанс» дип атала, ә аны тулыландыру — финанслау. Югарыда тәкъдим ителгән мисаллардан күргәнебезчә, ике эшмәкәр да, бизнесларының нинди хәлдә булуына карамастан, өстәмә финанс чыганаклары эзләргә мәҗбүр. Бу чыганаклар нинди булырга мөмкин?

Финанслау чыганаклары эчке һәм тышкыга бүленә.

Эчке чыганаклар булып фирманың кереме һәм амортизациягә күчерелгән акчалар хезмәт итә ала.

Алардан файдалану «үз-үзеңне финанслау» дип атала, ягъни үз акчалары исәбенә финанслану. Үз-үзеңне финанслау нигездә кече предприятиеләргә хас; аларга, әле без алга таба күрербез, акчаны башка чыганаклардан табу кыен. Әлеге предприятиеләрнең кереме зур түгел, шуңа аның ярдәмендә производствоны киңәйтә алу — бик сирәк күренеш. Үз-үзеңне финанслауның тагын бер чыганагы кала — амортизацияләүгә күчерелгән акчалар. Аларны куллану мөмкинлеген шартлы мисалда карыйк.

Әйтик, эшмәкәр хезмәт итү вакыты 5 ел булган станокны 150 000 сумга сатып алды ди. Димәк, амортизациягә күчерүләр елга 30 мең сум тәшкил итә (150 000 : 5). Амортизациягә күчерелгән акчалар товар бәясенә керә, шуңа да әгәр предприятие елга 300 әйбер эшләп чыгарса, һәр эшләнмәнең бәясенә 100 сум керә (30 000 : 300). 5 елдан соң эшмәкәр 150 000 сум акча туплый һәм яңа станок алырга тиеш була. Әмма техник прогресс бер урында гына тормый, 5 елдан шуңа охшашлы яңа буын станок кыйммәтрәк торырга мөмкин һәм акча өстәргә кирәк булачак.

Дөрес, тагын бер вариант — «тизләтелгән амортизация» дип аталган ысул бар. Бу ысулда җиһазның бәясен тизрәк, әйтик, 2,5 елда капларга була, ләкин болай эшләгәндә, амортизациягә акча күчерү елга 60 000 сум тәшкил итә (150 000 : 2,5) һәм, әгәр елга шул ук кадәр товар җитештерелсә, бәягә инде 200 сум керә (60 000 : 300). Әмма кече предприятиенең конкурентлары күп, һәм ул бәяне 200 сумга күтәрсә, кулланучылар товарны аның конкурентларыннан элекке бәягә сатып алуны өстен күрәчәк, ә безнең эшмәкәр үз товарын бөтенләй сата алмау яки үзе өчен зыянга сату куркынычы астында калачак.

Шулай итеп, үз-үзен финанслау уңышлы кече предприятиегә үз бизнесын саклап калырга ярдәм итә, ләкин эшмәкәр үз җитештерүен киңәйтергә теләсә, ул финанслауның тышкы чыганакларына барырга мәҗбүр була.

Эре бизнес тизләтелгән амортизацияне уңышлы куллана, чөнки югары җитештерүчән җиһазлар сатып ала, җитештерүне арттыра һәм хәтта югары амортизация күчерүләрен дә арта барган продукция санына бүлә, бу исә бәянең күтәрелүенә китерми. Базарда конкуренциягә сәләт саклана.

Эре фирманың табышы да күпкә зуррак. Кагыйдә буларак, эре корпорацияләр юридик яктан акционерлар җәмгыяте рәвешендә була; димәк, акция ияләре табышның бер өлешен — дивидентлар алырга тиеш. Шуңа табыш ике өлешкә — бүленүче (аңардан дивидентлар түлиләр) һәм бүленми торган (ул предприятиенең төрле ихтыяҗларына, шул исәптән производствоны киңәйтүгә юнәлтелә, өлешләргә бүленә). Шулай итеп, эре фирмалар үзләренең эчке финанслау чыганакларыннан уңышлы файдалана.

Ә хәзер бизнесны финанслауның тышкы чыганакларына мөрәҗәгать итик. *Тышкы чыганаклар* банк кредитларыннан, төрле финанс учреждениеләре (иминиятләштерү һәм инвестиция комиссияләре, пенсия фондлары һ.б.) акчаларыннан, дәүләт һәм төбәкнең кече эшмәкәрлеккә булышу фондларыннан гыйбарәт.

Шулай итеп, фирмалар банкларның финанс хезмәтләреннән файдалана ала. Башка финанс-кредит учреждениеләренең төп функцияләре һәм башкарылучы операцияләре белән сез киләсе параграфларда танышырсыз. Без монда банк кредитларына гына тукталабыз.

Банк кредиты — банк тарафыннан билгеле бер вакытта кире кайтару һәм мәгълүм процент түләү шарты белән бирелүче акча суммасы.

Кредитлар ике төрле була — кыска сроклы һәм озак сроклы. Кыска сроклы кредитлар, күп дигәндә бер елга, ә озак сроклысы бер елдан күбрәккә бирелә.

Бер генә банк та кредитны болай гына бирми: ул бу чараларның нинди максатка булуын һәм предприятие ссуданы кайтару гарантиясе сыйфатында нәрсә тәкъдим итүен белергә тели. Банк үз кертемчеләре акчалары белән эш итә, шуңа кредитларның кире кайтачагына инанырга тиеш.

Кыска вакытлы кредит мисалын карап үтик. Эшмәкәр товарны күмәртәләп сәүдә итүчегә сатты ди, тик аның өчен кулдагы акчалар түгел, ә вексель — билгеле бер вакыттан (әйтик, 3 айдан) билгеле бер сумма түләнәчәге турында йөкләмә кәгазе генә алды. Әмма безнең эшмәкәргә башка чыгымнарны каплау

өчен акча кирәк. Шул чакта ул банкка бара һәм, вексельне залогка салып, 30 дан 60 көнгәчә вакытка кыска сроклы ссуда ала.

Кыска сроклы ссуда товар сатудан кергән акча исәбеннән автоматик рәвештә каплана һәм хәтта кече предприятиеләргә гарантияләр тәэмин итмичә дә бирелергә мөмкин (мәсәлән, әгәр фирма банкның даими һәм ышанычлы клиенты булса).

Озак сроклы кредит озаграк вакытка бирелә һәм нигездә производствоны модернизацияләү яисә киңәйтү максатларында файдаланыла. Бу кредит банкка ссуданы кире кайтаруны саллырак гарантияли алган эре предприятиеләргә бирелә. Гарантия сыйфатында әлеге предприятие мөлкәте (җир, бина һәм корылмалар, машина һәм җиһазлар) хезмәт итә ала, шулай ук бизнес буенча уңышлы партнерлар яки дәүләт учреждениеләре гарантияләре дә булырга мөмкин.

Озак сроклы ссудалар предприятиенең киләчәк керемнәреннән каплана.

Шулай итеп, эре предприятиеләрнең бизнесны эчке чыганаклардан да, тышкыларыннан да каплау өчен мөмкинлекләре шактый зуррак.

Ә эшләре яхшы барган һәм үз производствосын киңәйтергә теләгән эшмәкәр нишләргә тиеш соң? Банклар аңа озак сроклы кредит бирми, чөнки аның залогы һәм саллы гарантияләре юк. Туганнарыннан һәм дусларыннан бурычка акча алды инде, болар гына җитми. Аңа бер генә юл кала — үзенең индивидуаль предприятиесен ширкәткә әверелдерү өчен партнерлар табу. Партнерлар үз пайларын акчалата кертә, һәм хәзер бергәләшеп алар җитештерүне киңәйтә. Ләкин партнерлары белән бергәләп җитештерүне тагын да киңәйтү өчен яңадан акча табарга тиешле эшмәкәрләрнең товарларын базар янә «йотып бетерә». Тагын бер адым — ширкәтне ябык акционерлар җәмгыяте итеп үзгәртеп оештыру. Партнерлар акцияләр чыгара, аларны бу предприятиедә катнашуның мәгълүм бер өлешенә алмашка үз капиталы белән «уйнарга» әзер үзләренә мәгълүм кешеләр арасында тарата. Ләкин, сез инде беләсез, акционерлар хәзер үз акцияләренә дивидендлар рәвешендә фирма кеременең бер өлешенә хокуклы була.

Йомгаклап шуны әйтергә кирәк: барлык нык үскән илләрдә дәүләт кече бизнеска салым ташламалары биреп кенә түгел, финанслау өчен акчалар алырга булышып та ярдәм итә. Мәсәлән, кече эшмәкәрлекка ярдәм күрсәтүнең төрле фондларыннан файдалана. Мондый фондлар Россиядә дә бар. Алар ташламалы кредитлар биреп кенә калмый, шундый кредитларны шәхси коммерция банкларында кредитлар алу өчен гарантия дә бирә.

МЕНЕДЖМЕНТНЫҢ ТӨП ПРИНЦИПЛАРЫ

Күргәнебезчә, финанслау өчен акча табу җиңел түгел, ә аны рациональ файдалану тагын да авыррак. Моның белән кем шөгыльләнә? Товар җитештерүне һәм аның сыйфатын кем күзәтеп тора? Бөтен предприятиенең уңышлы эшләве өчен кем җавап бирә?

Әгәр дә предприятие зур булмаса, санап үтелгән барлык функцияләрне аның хуҗасы — милекчесе үзе башкара. Предприятие үсә икән, хуҗа үзе генә барлык эшләргә дә өлгерә алмый, аңа ярдәмче кирәк була. Эре фирмада исә эшне менеджер алып бара.

Менеджер — производство һәм товар әйләнеше белән идарә итүче белгеч, ялланган идарәче ул.

Әмма эре предприятиеләрдә менеджерларның вазифалары бүленә, үзенә күрә бер пирамида хасыйл итә — аның нигезендә түбән буын менеджерлары, аннан өстәрәк — урта буын, ә иң өстә — иң югары менеджерлар.

Түбән буын менеджерлары — участок, цех башлыгы яки бригадир — турыдан-туры эшчеләр белән җитәкчелек итә һәм үз бүлекчәсе эше өчен җавап бирә.

Урта буын менеджеры — директорның җитештерү яки финанс, яисә тәэминат һәм сату һ.б. буенча урынбасары — түбән буын менеджерлары эшенә җитәкчелек итә һәм үз участогын контрольдә тота.

Ниһаять, иң югары менеджер, инглизчә топ-менеджер — вазифасы буенча генераль директор, президент (яисә вице-президент) яки компания идарәсе рәисе — урта буын менеджерларына җитәкчелек итә һәм бөтен предприятие эше өчен җавап бирә.

Инде предприятие эшенә кем идарә итүен белгәч, менеджментның нәрсә икәнлеген ачыклап үтик.

Менеджмент — предприятие эшен оештыру һәм координацияләү эшчәнлеге ул.

Киң мәгънәдә «менеджмент» дигәннән оешмага турыдан-туры җитәкчелек итү дә, идарә турындагы фән дә, идарә белән шөгыльләнүче кешеләр — команда да аңлашыла.

Менеджментның функцияләре нинди соң?

Франциянең эре сәнәгатьчесе һәм менеджмент тәгълиматчысы Генри Файоль 1914 елда менеджментның стадияләре, этапларына караган идеяләрен бастырып чыгара. Ул биш шундый этапны бүлеп карый — планлаштыру, оештыру, командалык итү, координация һәм контроль. Тора-бара командалык итү һәм координация берләштерелә һәм «җитәкчелек» дип атала.

Хәзер менеджментның *дүрт функциясен* аералар — оештыру, планлаштыру, җитәкчелек һәм контроль. Аларны кыскача карап үтик.

Оештыру — кешеләр яисә аерым төркемнәр арасында эшләрне бүлү һәм алар эшчәнлеген координацияләү. Башкача әйткәндә, бу — предприятие структурасын билгеләү, аерым бүлекчәләр, бүлек яисә цехлар төзү һәм, квалификацияләренә туры китереп, хезмәткәрләрне әлеге бүлекләр буенча бүлеп урнаштыру.

Предприятиенең зурлыгына карап һәм башкарылучы эшләрнең катлаулылыгыннан чыгып, идарәнең оештыру структурасы гади дә, бик катлаулы да булырга мөмкин. Кагыйдә буларак, кече предприятиеләр өчен идарәне оештыруның иң гади, сызыкча структурасы хас. Аның башында бер җитәкче тора, барлык бүлекчәләрнең башлыклары аңа буйсына. Төрле продукция җитештерүче, шулай ук яңа төр әйберләр әзерләү белән шөгыльләнүче эре корпорацияләр өчен идарәнең катлаулырак структурасы кирәк. Анда түбәнрәк менеджерлар югарыдагыларына буйсындырыла, бүлекләр үзләре дә төрле билгеләр (җитештерү, функциональ, төбәк) буенча төркемләнә.

Планлаштыру — максат кую һәм аңарга ирешү юлларын билгеләү ул. Планлаштыру өзлексез бара. Кыска сроклы һәм озак сроклы планлаштыруны аерып карыйлар. Озак сроклы планлаштыруны еш кына «стратегик» дип атыйлар, чөнки ул фирманың максатларын һәм бурычларын перспективага билгели. Моның белән иң югары, предприятие эшчәнлеген тулы күзаллаган менеджерлар шөгыльләнә. Озак сроклы планнар нигезендә агымдагы (кыска сроклы) — бер-ике елга исәпләнгән планнар һәм оператив планнар (кварталга, айлык, үнкөнлек) эшләнә. Соңгыларын төзегәндә инде барлык дәрәҗәдәге менеджерлар да катнаша.

Җитәкчелек — кешеләрдә компания максатларына ирешү буенча уртак эш өчен шартлар һәм теләк булдыру ул. Яхшы җитәкчелек хезмәткәрләрдә үз эшләренә кызыксыну тудыра, иң яхшыларына уңай бәя бирә һәм карьера буенча үсеш тәэмин итә. Кайчакта менеджерлыкның бу функциясен «мотивация» дип атыйлар, чөнки хезмәткә кызыксындыру яки теләк тудыру күптөрле булырга мөмкин: югары эш хакы, яхшы хезмәт шартлары, хезмәте буенча күтәрелү мөмкинлеге, өйгә якын булу һ.б. Җитәкчелек бу этәргечләрнең барысын да фирма алдында торучы бурычларны үтәргә сәләтле коллектив төзегәндә исәпкә алырга тиеш.

Контроль — максатына таба барганда фирма эшчәнлеген тикшереп тору һәм тайпылышларны корректировкалау. Барыннан да элек барлык дәрәҗәдәге менеджерлар проблема-

ларның киң даирәсе — продукциянең сыйфаты, матди һәм акча ресурсларыннан рациональ файдалану һ.б. буенча үз күрсәтмәләренең төгәл үтәлешен контрольдә тота. Менеджментның төп функцияләре шундый.

Хәзер фирмада җитештерү бик әйбәт җайга салынды, сыйфатлы продукция чыгарыла дип күз алдына китерик. Тагын сорау туа: товарны кайда һәм ничек сатарга? Кулланучыга кирәкме ул? Продукция күп җитештереләме яки азракмы әле? Бәяне ничек куярга? Бу һәм башка мөһим сорауларга җавапны киләсе бүлектән табарсыз.

МАРКЕТИНГ НИГЕЗЛӘРЕ

Маркетинг — алмашу аша кешенең ихтыяҗларын формалаштыруга һәм канәгатьләндерүгә юнәлтелгән эшчәнлек ул. Маркетингның төп максаты — ихтыяҗларны яхшырак канәгатьләндерү һәм керем алу хакына производствоны базар таләпләренә җайлаштыру. Маркетингның асылын аңларга ярдәм итүче формула да бар: «Сатарга мөмкин булган әйбер җитештерергә, ә җитештерергә мөмкин булган әйберне сатарга маташмаска».

Маркетинг XX гасырның 20 нче елларында АКШта базар тикшеренүләре уздыру һәм базар соравына актив йогынты ясау мөмкинлеге булган эре бизнес тарафыннан киң кулланыла башлады. Хәзер исә маркетингның нәрсә икәнлеген белмәгән һәм ниндидер дәрәҗәдә аны кулланмаган бер генә эшмәкәр да юктыр.

Гадәттә *маркетингның өч төп принцибын* аерып карыйлар: базарны өйрәнү, аңа үтеп керү һәм сату, базарга йогынты ясау стратегиясен эшләү.

Базарны өйрәнү — теләсә нинди маркетинг эшчәнлегенең таяну ноктасы. Һәр эшмәкәр нинди дә булса товар җитештерү алдыннан аның кулланучыга кирәклеге, гомумән, ул базарда бармы, нинди бәядән сатыла, аны ничә конкурент җитештерә, алар күчлеме-юкмы икәнлеген ачыкларга тиеш. Кирәк булган мәгълүматны җыеп анализлаганнан соң гына теге яки бу продукт җитештерү турында карар кабул итәргә була.

Базарны өйрәнүнең, ә аннары шунда үтеп керүнең бер ысулы булып *сегментлау* — ягъни базарны төрле параметрларга — географик, демографик, психографик, тәрбияви һ.б. якларына карап, аерым өлешләргә бүлү тора. Бу параметрларны бүлү кулланучыларның ихтыяҗларын исәпкә алырга, рекламаны дөрес урнаштырырга, сатуның иң яхшы шартларын сайларга мөмкинлек бирә.

Кыскача гына әлеге сегментларны карап узыйк.

Географик сегментлау климатны, җирлекне, табигать ресурсларын, халык күплеген, шәһәрләр һәм авыллар булуны һ.б. исәпкә алып, төбәк билгеләре буенча башкарыла. Болар барысы да кешеләр ихтыяҗына, теге яки бу товарга сорауга йогынты ясый. Әйтик, төньяк районнарда кышның озынлыгы һәм салкын булуы кышкы кием, җылыткычлар һ.б. сатуны арттыра.

Һәр җирлек спорт товарлары, аяк киеме, өс киеменә ихтыяҗга тәэсир итә. Таулы районнарда яшәүчеләр ихтыяҗы диңгез буендагы кешеләрнекеннән, ә авыл кешеләре ихтыяҗы шәһәр халкыныкыннан аерыла.

Демографик сегментлау кешеләрнең җенесенә, яшенә, гаилә зурлыгына, керемнәр дәрәҗәсенә, шөгыленә һ.б. бәйле. Күп товарлар кешенең яшенә бәйле. Мисал өчен уеннар һәм уенчыкларны гына алыйк: өч яшьлек бала бер яшьлек нәнинең шалтыравыгы белән уйнамый, ә өлкән сыйныф укучыларын беренче сыйныфтагылар уены кызыксындырмый. Кием, ашамлык та шулай. Байларның ихтыяҗлары аз керемле кешеләрнекеннән аерыла һ.б.

Психографик сегментлау яшәү стиле, кулланучыларның шәхси сыйфатлары, аларның теге яки бу товарга реакциясе кебек факторларны эченә ала. Бер төркем кешеләрнең сатып алуга кызыксынуы бик күп төрле булырга мөмкин: берәүләр, башкалардан аерылып торырга теләп, модалы, оригиналь әйберләр сатып ала; икенче берәүләр кием-салымга әллә ни игътибар бирми, әмма үзенең конкүрешен җиңеләйтүгә хезмәт иткән товарларны даими алып тора; өченчеләре, экономия максатында, ташламалар алу өчен товарны күпләп сатып ала.

Тәрбияви сегмантлау сатып алуга кызыксыну һәм кулланучының үз-үзен тотышы, тәртибе, аның төрле товарларга мөнәсәбәте белән бәйле. Чит ил галимнәренең төрле кулланучылар төркемнәре тарафыннан иң яңа товарлар сатып алгандагы мотивациясен өйрәнүләре аеруча кызыклы. Сатып алучыларның биш категориясе аерып күрсәтелә:

— суперноваторлар (яңалык сөючеләр) — шәһәрдә яшәүче һәм яңа товарларны теләп алучы югары табышлы кешеләр;

— новаторлар — шулай ук шактый бай, ләкин тәвәккәллекне бик өнәп бетермәүче кешеләр;

— гадәтиләр — тәвәккәллекне яратмаучы, авыл җирендә яшәүче төпле кешеләр;

— консерваторлар — каршылыклы кешеләр: бер яктан алар суперноватор һәм новаторларны хупламыйлар, икенче яктан — гадәти кешеләргә охшарга тырышалар. Бу төркемдә өлкәннәр, керемнәре аз булган һәм түбән абруйлы эштәге кешеләр күп;

— суперконсерваторлар — үзләре яшь чактагы гадәтләр һәм мода яклы кешеләр, алар бөтен үзгәрешләргә каршы чыга һәм җәмгыятьнең теләсә нинди катлавында булырга мөмкиннәр.

(Сез үзегезне һәм әти-әниләрегезне иң яңа товарларны сатып алучыларның кайсы категориясенә кертер идегез? Шуны уйлагыз һәм сәбәбен аңлатыгыз.)

Шулай итеп, базарның төрле сегментлары үзенчәлекләрен исәпкә алу эшмәкәрләргә тиешле базарларга уңышлырак үтеп керергә мөмкинлек бирә.

Базарга үтеп керү һәм сату стратегиясен эшләү — иң мөһим принцип, чөнки продуктның яки хезмәт күрсәтүнең характеристикасын эшләүне һәм аларга бәяләр билгеләүне генә түгел, ә аларны сату юлларын һәм реклама төрләрен сайлап алуны да күздә тота. Америка әдәбиятында әлеге принцип «дүрт пи» исемен алды, чөнки әлеге принципны чагылдыручы төп сүзләр инглизчә «п» хәрефенә башлана — продукт *(product)*, бәясе *(price)*, тарату *(place)*, сатуны стимуллаштыру *(promotion)*.

Продукт кешене ихтыяҗи сыйфаты буенча да, тышкы кыяфәте, тартмасы белән дә, әгәр сүз техник яктан катлаулы товар турында бара икән — сатып алганнан соң аңа хезмәт күрсәтү дәрәҗәсе белән дә канәгатьләндерергә тиеш.

Бәя әлеге товарны җитештерүгә чыгымнарны һәм табышны, шулай ук базар факторларын — сорау һәм тәкъдимне, әлеге товарның кулланучыга кирәклеген, мәгълүм бер маркага ияләшүне һ.б. исәпкә алырга тиеш. Әгәр дә эшмәкәр инде базарда булган товарларны җитештерә икән, ул бәяне дә якынча шундый итеп куя. Кыйммәтрәк итсә, аңардан бу товарны сатып алмаячаклар. Әмма ул югарырак сыйфатлы товар җитештерсә, югарырак бәя үзен аклый. Ә элек базарда булмаган яңа товар бәясе белән нишләргә? Югары бәя куеп, аннары аны төшерергә дә, киресенчә, зур булмаган бәя куеп, сорау артса, күтәрергә дә мөмкин. Бу мәсьәләләрнең ничек хәл ителүенә карап, яңа товарларга бәяләр урнаштыруның ике ысулы бар — «каймагын җыю» һәм «үтеп керү бәясе».

«Каймагын җыю» ысулы — техник яктан катлаулы, фәнни өйрәнүне күп таләп иткән продукциягә югары бәя кую, чөнки эшмәкәр аны эшләүгә һәм җитештерүгә сарыф иткән зур чыгымнарны акларга тели. Җитмәсә, бу продукция базарда сорау таба алуын белмичә, ул акчасын куркыныч астына куйган. Беренче персональ компьютерлар, видеомагнитофоннар, микродулкынлы мичләр гаять кыйммәт иде, ләкин тора-бара бәяләр төште, һәм хәзер бу товарларны күпләр ала.

Ә «үтеп керү бәясе» ысулы, киресенчә, базарны яулау өчен башта түбән бәя куюны, ә аннан соң аны күтәрүне күздә тота.

Түбән бәяләр мөмкин булган конкурентларны куркыта һәм кулланучыларны җәлеп итә. Гадәттә бу ысул базарга кондитер әйберләрен, конфет, шоколад, сагыз ише нәрсәләрне кертеп җибәрү өчен кулланыла. Безнең базарда «Марс» һәм «Сникерс» шоколадлары пәйда булганда, алар 3 сум тора иде, кулланучылар аларны яраткач һәм тотрыклы сорау тугач, аларның бәясе күпкә артты.

Тарату — эшмәкәр сайлаган сату юллары ул. Гадәттә яңа эш башлаучы эшмәкәр үз продукциясен реализацияләү өчен аны арадашчыларга бирә, ләкин ул һәрвакыт үз сәүдә ноктасын булдырырга тели, бу аңа продукцияне кулланучылар белән турыдан-туры аралашырга һәм алар теләгән исәпкә алырга мөмкинлек бирә. Эре корпорацияләр үз продукцияләрен сатуның яхшы җайга салынган (ерактагы базарларга ташуны һәм товар запасларын саклауны да кертеп) системасына ия була.

Сатуны стимуллау нигездә реклама белән бәйле.

Җәмгыятьтә рекламага караш төрле, шуңа күрә сезгә аның әһәмиятенә ике карашны чагыштырырга тәкъдим итәбез.

Беренчесе: реклама файдасыз гына түгел, ул кулланучыларның фикерен бутый, еш кына дөрес булмаган мәгълүмат бирә, товарны кыйммәтләндерә, шулай ук сатып алучыларны түбән сортлы товар өчен югары бәя түләргә мәҗбүр итә.

Икенчесе: реклама кирәк, чөнки ул сатыла торган продукт һәм аның бәясе турында файдалы мәгълүмат бирә, кулланучыга рациональ сайлап алуда ярдәм итә, яңа товарларны базарга чыгарырга булыша.

Ә сез кайсы позицияне хуплыйсыз?

ГАМӘЛИ ЙОМГАКЛАР

1 Әгәр дә сез үз эшегезне ачарга телисез икән, финанслауның төрле чыганакларыннан файдалана белүнең уңыш өчен мөһим шарт булуын истә тотыгыз. Бу үз бизнесыңны саклап калу гына түгел, аны даими үстерә бару һәм башка эшмәкәрләр белән уңышлы көндәшлек итү мөмкинлеге бирер.

2 Үз бизнесың белән белеп идарә итү өчен кирәкле белемнәр һәм тәҗрибә тупларга кирәк, юкса махсус идарәче-менеджер эзләү һәм тотуга өстәмә чыганаклар күрергә мәҗбүр буласың.

3 Эш табышлы булсын өчен, кулланучылар соравы үзгәрүне, базардагы вазгыятьне һәм теләкләрне күзәтү, базар соравына йогынты ясау юлларын эзләү зарур. Мәсәлән, үз товарыңны тәкъдим итү һәм рациональ сайлауда кулланучыга булышу өчен рекламадан файдаланырга кирәк.

ДОКУМЕНТ

Маркетинг буенча белгеч, Америка профессоры ***Ф.Котлерның*** «Маркетинг нигезләре» китабыннан (1990 елдан бирле Россиядә берничә тапкыр басылды).

Балигъ булган яшь кулланучылар. Алар (18–24 яшьлекләр) базары өч төркемчәгә бүленә: көллият студентлары, яшь ялгызаклар, яңа өйләнешүчеләр. Балигъ булган яшь кулланучылар китапларга, грампластинкаларга, стереоаппаратурага, модалы киемгә һ.б. пропорциональ булмаганча күп акча тузсыралар. Алар өчен маркаларга җитди карамау һәм яңа товарларга югары игътибар хас. Балигъ булган яшьләр берничә сәбәп аркасында җәлеп итәрлек базар тәшкил итә: 1) алар яңа товарларны сынап карау идеясе яклы; 2) акчаларын җыеп барганчы, күбрәк туздырырга хирыс; 3) сатып алучы ролендә озак булачаклар әле...

Мәгълүмат эзләү. Мәгълүмат эзләүдә кулланучы түбәндәге чыганакларга мөрәҗәгать итәргә мөмкин:

— шәхси чыганаклар (гаилә, дуслар, күршеләр, танышлар);

— коммерция чыганаклары (реклама, сатучылар, дилерлар, тартма, күргәзмә);

— гомуми чыганаклар (массакүләм мәгълүмат чаралары, кулланучыларны өйрәнү һәм классификацияләү белән шөгыльләнүче оешмалар);

— эмпирик тәҗрибә чыганаклары (тою, өйрәнү, товардан файдалану).

Мәгълүматның әлеге чыганакларының чагыштырма йогынтысы товар категориясенә һәм сатып алучылар үзенчәлегенә карап үзгәрә. Гомумән алганда, кулланучы товар турында иң күп мәгълүматны ... базар эшлеклесенең көчле йогынтысы астында булган коммерция чыганагыннан ала. Ә иң нәтиҗәлесе булып шәхси чыганаклар тора.

Документка сораулар һәм биремнәр

1. Балигъ булган яшь кулланучыларны нинди сегментларга кертергә була һәм ни өчен? **2.** Сезнең карашка Россиядә иң киң таралган мәгълүмат чыганакларын күрсәтегез. **3.** Сезнең гаилә нинди мәгълүмат чыганакларыннан файдалана һәм ни өчен шулай?

ҮЗ-ҮЗЕҢНЕ ТИКШЕРҮ ӨЧЕН СОРАУЛАР

1. Нәрсә ул финанслау һәм аның чыганаклары нинди? **2.** Эре һәм кече бизнес өчен нинди финанслау чыганаклары харак-

терлы? **3.** Россиядә кече эшмәкәрләргә коммерция банкларыннан озак сроклы кредит алырга мөмкинме? **4.** Топ-менеджер кем ул һәм фирмада нинди вазифа били? **5.** Һәр предприятие дә стратегик планлаштыру белән шөгыльләнергә тиешме? **6.** Базарны өйрәнми торып, үз эшеңне башлап буламы? **7.** Сезнең туганнар һәм танышлар арасында суперконсерваторлар һәм суперноваторлар бармы?

БИРЕМНӘР

1. Фирма 300 миллион сумга җитештерү линиясе сатып ала. Бу линия 5 ел хезмәт итсә, амортизациянең еллык нормасы нинди? Әгәр дә беренче елда амортизацияләүнең икеләтелгән нормасы капланса, калган сумманы шул ук норма саклангандa ничә елда гамәлдән чыгарырга мөмкин?

2. Яңа фирма сагыз сату-алу базарына үтеп керергә тели, ә анда мондый товарлар тулы инде. Фирма нинди бәяләр куярга тиеш: базарда булганнан югарыракмы әллә түбәнрәкме — һәм ни өчен шулай?

3. Сез Россиядәге нинди эре фирмаларны беләсез? Илебезнең эре эшмәкәрләрен һәм топ-менеджерларын атагыз.

ЗИРӘКЛӘР ФИКЕРЕ

«Бизнес — сугыш һәм спорт кушылмасы ул».

А.Моруа (1885–1967), француз язучысы

§ 7. Икътисад һәм дәүләт

Дәүләт базар мөнәсәбәтләренә нигә катыша? Китапханәләр, светофорлар һәм маяклар эше өчен кем түләргә тиеш? Базар икътисадында ни өчен дәүләтне «җәмгыять мәнфәгате попечителе» дип атыйлар? Икътисадка кайсы отышлы: салымнарның үсүеме яисә төшүеме?

ДӘҮЛӘТНЕҢ ИКЪТИСАДИ ФУНКЦИЯЛӘРЕ

Сез инде белгәнчә, хәзер реаль хәрәкәттә булган барлык икътисади системаларга диярлек базар мөнәсәбәтләренең дәүләт контроле һәм җайга салуы элементлары белән тыгыз үрелеп баруы хас. Бөтендөнья тәҗрибәсе күрсәткәнчә һәм күпсанлы фәнни тикшеренүләр раслаганча, дәүләтнең актив җайга салу роленнән башка нәтиҗәле базар икътисады булырга мөмкин

түгел. Шул рольне тормышка ашыру өчен, ул икътисадка йогынты ясауның төрле юлларын куллана.

Төрле илләрдә дәүләт җайга салуының масштаблары, аның конкрет рәвешләре һәм ысуллары җитди аерыла. Алар илнең тарихын да, традицияләрен дә, масштабларын да чагылдыра. Базарның ролен абсолютлаштырып һәм арттырып, дәүләт ролен бәяләп бетермәүчеләр һәм хәзерге заман дәүләте мөмкинлекләрен күтәреп, базарның үз-үзен җайга салу ролен танымаучылар арасында күптәннән бирле бәхәс бара. Бу ике карашның рациональ нисбәтен эзләү хәзер дә дәвам итә. Базар икътисадында дәүләтнең роле һәм функцияләре нинди соң?

Дәүләтнең икътисади сәясәте мәгълүм бер максатларга ирешү өчен икътисади процессларга йогынты ясауның төрле дәүләт чаралары күрү юлы белән аның икътисади функцияләрен гамәлгә ашыру процессын тәшкил итә. Базар икътисадында дәүләтнең иң гомуми икътисади **максатлары** түбәндәгеләр: икътисади үсеш тәэмин итү; икътисади ирек шартлары тудыру (хуҗалык итүче субъектларның икътисади эшчәнлек рәвешен һәм тармагын, аны тормышка ашыру ысулларын һәм аннан керемне файдалануны үзләре сайлап алу хокукы); икътисади куркынычсызлык һәм икътисади нәтиҗәлелек (бөтен икътисадның булган чикле ресурслардан максималь нәтиҗә алу сәләтен) тәэмин итү; эш белән тулы тәэмин ителеш турында кайгырту (эшли алган һәм эшләргә теләгән һәркемнең хезмәт урыны булырга тиеш); үзен тулы тәэмин итә алмаучыларга ярдәм күрсәтү һ.б.

Икътисади сәясәт перспективалы һәм агымдагы максатларны оста чиратлаштырып алып баруга корыла. *Россия икътисади сәясәтенең* перспектив максатларына, мәсәлән, икътисадның социаль юнәлеш торткан базар вариантын формалаштыру керә. Агымдагы максатларга, әйтик, дәүләт бурычлары проблемасын хәл итүне, халыкның керемнәре артык дифференциациялөнү һәм ярлылык белән көрәшүне, бизнеска салымнарны киметүне һ.б. кертергә мөмкин.

Икътисади сәясәттә, аерым алганда, финанс, инвестиция, аграр, фәнни-техник, тышкы икътисади сәясәтне аерып карыйлар. (Икътисади сәясәт төшенчәләре исемлеген үзегез дә тулыландырырга тырышып карагыз.)

Хәзерге заман җәмгыятендә дәүләт нинди икътисади функцияләр башкара соң? Икътисадны тотрыклыландыру; милекчелек хокукын яклау; акча әйләнешен җайга салу; керемнәрне яңадан бүлү; эш бирүчеләр һәм ялланган хезмәткәрләр арасындагы үзара мөнәсәбәтләрне җайга салу; тышкы икътисади эшчәнлеккә контроль; иҗтимагый уңайлыклар җитештерү кебек **классик функцияләр** һәрвакытта да дәүләтнеке булып килде.

Санап үтелгән функцияләрнең соңгысына тулырак тукталыйк. Дәүләткә ни өчен иҗтимагый уңайлыклар булдыру белән шөгыльләнергә туры килә?

Иҗтимагый уңайлыклар — дәүләт тарафыннан аның гражданнарына тигез башлангычларда бирелә торган товарлар һәм хезмәт күрсәтүләр. Мондый уңайлыклар аерым затларга гына, аны башкаларга да бирми торып, тудырыла алмый. Иҗтимагый уңайлыкларга, мәсәлән, оборона, түләүсез белем бирү, муниципаль поликлиникаларның бөтен кешегә күрсәтелүче хезмәтләре, китапханәләр, парклар һ.б. керә. Бу уңайлыклар һәркемгә дә бер үк төрле рөхсәт ителә, аннан файдаланган өчен түләү алынмый. Мондый уңайлыклар үрнәкләрен сез үзегез дә китерә аласыз.

Иҗтимагый уңайлыклар булдыруны дәүләт үз кулына ала, чөнки аларның күбесе шәхси җитештерүчеләр өчен отышсыз, ә, мәсәлән, сәламәтлек саклау, мәгариф, фундаменталь фәннәр, әйләнә-тирә мохитне саклау кебек өлкәләрне үстерү шәхси эшмәкәрлек нигезендә генә була алмый. Иҗтимагый уңайлыклар булдыру өчен байтак финанс чаралары кирәк, һәм дәүләт аларны салымнар рәвешендә җыеп ала. Шулай итеп, иҗтимагый уңайлыклар өчен түләүгә барлык гражданнар үз өлешен кертә.

Базар законнары буенча эш йөртүче шәхси предприятиеләр генә эшли торган өлкәләрдә дә дәүләтнең роле зур. Әлеге даирәләргә дәүләтнең катнашуы тышкы (өстәмә) эффектлар яисә йогынтылар проблемасыннан килеп чыга.

Тышкы эффектлар — уңайлыклар җитештерү һәм куллану белән бәйле чыгымнар һәм өченче затлар өчен файда. Бераүләрнең икътисади эшчәнлеге әлеге товарлар җитештерүдә һәм куллануда турыдан-туры катнашмаучы затларда чагылыш таба торган нәтиҗәләргә китерергә мөмкин.

Тискәре һәм *уңай* тышкы эффектлар бар. Тискәре эффект товар җитештерү яисә куллану нәтиҗәсендә башка затларда (искә төшереп үтик, җитештерүдә катнашмаучы) чыгымнар барлыкка килү очрагында килеп чыга, ә уңай эффект — әлеге затларда файда барлыкка килү очрагында була, ул товар җитештерүчеләргә бу затлар тарафыннан компенсацияләнми. Анык мисалларны карыйк.

Елга ярында урнашкан агач эшкәртү комбинатын күз алдына китерик, ул җитештерү калдыклары белән әлеге елганы агым уңаена күп чакрымнарда пычрата. Бу — елга ярында яшәүче кешеләр өчен производствоның тискәре тышкы эффекты мисалы. Шул ук вакытта мондый кире эффект комбинат продукциясе бәясендә чагылмаска да мөмкин. Җитештерүче товар җитештерү белән бәйле чыгымнарның бер өлешен (әлеге

очракта ул җитештерү калдыкларын әшкәртүгә яисә чистарту корылмалары төзүгә чыгымнар булырга мөмкин), бу чыгымнарны берничек тә компенсацияләмичә, халыкка күчерә. Бу кешеләргә производствоның тискәре нәтиҗәләрен җиңәргә кем ярдәм итәр соң? Дәүләт суны чистарту, кешеләрнең сәламәтлеген саклау һ.б. буенча өстәмә чыгымнар тотарга мәҗбүр. Ул комбинат эшчәнлегенең тышкы эффектын компенсацияли. Ә кулланучылар эшчәнлегенең тискәре эффекты мисалы булып җәмәгать урыннарында тәмәке тарту, ял паркларында чүп-чар ташлап китү һ.б. торырга мөмкин.

Хәрби заводлар эшчәнлеге исә уңай тышкы эффект мисалы булырга мөмкин. Халыкка оборона һәм куркынычсызлык кебек дәүләт хезмәтен (аның өчен кулланучы салымнар түли) тәэмин итәргә омтылып, җитештерүчеләр бер үк вакытта фәнни-техник прогресска да этәргеч бирә, аның нәтиҗәләреннән без барыбыз да түләүсез файдаланабыз. Хәрби предприятиеләргә мондый тышкы эффектны компенсацияләү өчен дәүләт хәрби продукциягә бәяләрне күтәрергә яисә аларга субсидия бирергә мөмкин.

Тышкы эффектларны компенсацияләү — базар икътисадында дәүләтнең мөһим функциясе.

Җәмгыять үсеше белән бергә дәүләт функцияләре дә киңәя, ачыклана бара. Бу процесс түбәндәге юнәлешләрдә бара: икътисадны җайга салуның турыдан-туры (административ) ысулыннан читләтеп (икътисади) җайга салу ысулына әзлекле төстә күчү; социаль проблемаларны хәл итүдә дәүләт ролен көчәйтү (халык керемнәре дифференциациясен киметү, җәмгыятьтә тотрыклылык тәэмин итү, хезмәт мөнәсәбәтләрен җайга салу). Дәүләтнең постиндустриаль җәмгыять урнашу белән бәйле сыйфат ягыннан яңа функцияләре дә барлыкка килә. Бу — фундаменталь фәнгә ярдәм итү, экологик кризисны һәм аның нәтиҗәләрен җиңү, «өченче дөнья» илләренең Көнбатыш державаларыннан икътисади артта калуын бетерү, коралларны киметү, кешелекнең глобаль проблемаларын хәл итүдә катнашу.

Базар икътисадында дәүләтнең иң мөһим вазифасы — базар системасына ярдәм һәм аның эшләвен тәэмин итү. Гадәттә дәүләткә икътисадта базарның җитешсезлекләрен компенсацияләү ролен бирәләр. Әмма аның фәкать үзенең генә компетенциясенә кергән функцияләре бар. Дәүләт һәм эшмәкәрлек арасында мөнәсәбәтләр катлауланганда хәзерге дәүләтнең икътисади бурычлары базарның эшләвенә шартлар булдыруга гына бәйләнеп калмый. Аның роле җәмгыять мәнфәгатьләре балансын, социаль тотрыклылыкны саклауда һәм гомуммилли мәнфәгатьләрне яклауда да танызла.

Базар нигезләрендә яңаручы Россия дәүләте җитештерүне

оештыру һәм җайга салу белән генә шөгыльләнми. Ул әлеге бурычларны үтәүне башлыча базарга калдырып, икътисадка контрольне тормышка ашыру һәм икътисади сәясәтнең өстенлекле юнәлешләрен сайлау белән мәшгуль.

Икътисади сәясәтне гамәлгә ашыру билгеле бер инструментарий (ысуллар, җайга салу формалары) куллануны күздә тота. Аның сайлавы милли икътисадның торышы, икътисади сәясәтнең өстенлекле юнәлешләре, әлеге мизгелдә хакимлек иткән җайга салуның теоретик концепциясе белән билгеләнә.

ИКЪТИСАДНЫ ҖАЙГА САЛУНЫҢ КАЙСЫ ИНСТРУМЕНТЫН САЙЛАП АЛЫРГА?

Дәүләт икътисади сәясәтендә ике төп юнәлешне аерып карарга мөмкин: *тотрыкландыручы* һәм *структур* юнәлешләр. Әгәр тотрыкландыручы сәясәт күбрәк «авыру» икътисадны савыктыруга юнәлгән булса, структуры исә аның балансланган үсешен тәэмин итүгә йөз тота.

Беренче юнәлеш нигездә бюджет-салым (фискаль) һәм кредит-акча (монетар) сәясәтне эченә ала. Икенче структур юнәлеш икътисадка йогынты ясауның илнең бөтен хуҗалыгын үстерү өчен аеруча мөһим тармакларга дәүләт ярдәме, иҗтимагый уңайлыклар булдыру, хосусыйлаштыру, конкуренциягә булышлык итү һәм монополияләрне чикләү һ.б. кебек ысулларыннан файдалана.

Базар механизмына дәүләт йогынтысы турыдан-туры һәм читләтеп җайга салу юлы белән тормышка ашырыла. Турыдан-туры җайга салу башлыча административ ысуллар куллануны, ә читләтеп җайга салу икътисади ысулларны күздә тота.

Турыдан-туры җайга салу барыннан да бигрәк дәүләтнең закон чыгару эшчәнлегендә, дәүләт заказларын арттыруда, икътисадта дәүләт секторын үстерүдә чагыла. Базарны читләтеп җайга салу фискаль һәм монетар сәясәт ярдәмендә тормышка ашырыла. Базар икътисадында нәкъ менә шуңа өстенлек бирелә. Базар икътисадын дәүләт җайга салуы механизмнарын схематик төстә түбәндәгечә күзаллап була:

Икътисадчы галимнәрнең дәүләтнең икътисадта катнашуы ысуллары һәм масштаблары турындагы бәхәсләрендә ике карашны аерып карарга мөмкин; алар икътисади теориянең ике юнәлешен — монетаризмны һәм кейнсианчылыкны чагылдыра.

Монетаристлар (Д.Юм, М.Фридмен) позициясе: икътисадны дәүләт кайгыртуыннан мөмкин кадәр күбрәк азат итәргә, салымнарны һәм дәүләт чыгымнарын кыскартырга, базар механизмына тотрыклы икътисади система тәэмин итү мөмкинлеге бирергә.

Инглиз икътисадчысы Дж. Кейнс (1883–1946) исеме белән бәйле *кейнсианчылык* юнәлеше вәкилләре бер базар механизмы гына икътисадта күптөрле проблемаларны хәл итә алмый дип исәпли. (Уйлап карагыз әле: әйтик, җәмгыять тормышының фән, мәгариф, экология кебек даирәләрен сорау һәм тәкъдим законнары тәэсиренә генә ышанып уңышлы хәл итеп буламы?) Кейнс «дәүләтнең ихтыяҗны кызыксындыручы актив финанс сәясәте генә массакүләм эшсезлекне җиңәргә сәләтле» дигән нәтиҗәгә килә. Аның дәвамчылары да җәмгыятьнең хәзерге заман ихтыяҗын канәгатьләндерү өчен хөкүмәт чаралары кирәк һәм котылгысыз, дип саный.

XX гасырның 70 нче елларына кадәр күп кенә дәүләтләрнең икътисади сәясәтендә кейнсианчылык юнәлеше хәлиткеч роль уйнады. Аннан соң монетаризм таралды. Гамәлдә күпчелек дәүләтләрнең хөкүмәтләре монетар характерда да, кейнсианчылык буенча да тотрыкландыру чараларының киң җыелмасын кулланалар.

Россия икътисады шартларында базар үзгәртеп коруларына старт монетар сәясәт ысулларыннан актив файдалану исәбенә бирелде, ә хәзер дәүләт икътисади үсешнең тотрыклылыгын ныгыту, дефицитсыз бюджет саклау максатларында икътисадка йогынты ясауның ике механизмын да кулланырга омтыла.

АКЧА-КРЕДИТ (МОНЕТАР) СӘЯСӘТЕ

Монетар сәясәт икътисадта акча массасына контрольне аңлата. Аның максаты — икътисадның тотрыклы үсешенә булышу. Гадәттә дәүләт икътисади түбәнәю чорында акча күләмен арттыра һәм күтәрелештә акча саны үсешен акрынайта.

Дәүләтнең акча-кредит сәясәтен үткәрүче булып (коммерция банклары белән хезмәттәшлектә) үзәк банк тора. Акча-кредит сәясәтенең төрле вариантларын карыйк.

Үзәк банк коммерция банкларына акча бирә, ә соңгылары — үз клиентларына «кредит өчен процент» дип аталган билгеле

бер түләү хакына бирә. Әгәр дә фирма банктан 50% еллык түләү исәбеннән 20 мең сум акча алса, аңа 30 мең сум итеп кайтарырга туры килә. *Процент исәп ставкасы* — үзәк банк коммерция банкларына кредит бирүнең процент нормасы. Исәп ставкасын күтәрә яисә төшерә барып, үзәк банк кредитны кыйммәтрәк яисә арзанрак итә ала.

Кредитлар кыйммәтләнсә, аны алырга теләүчеләр саны кими. Бу әйләнештәге акча санының кимүенә китерә һәм инфляцияне төшерергә ярдәм итә (инфляция акча массасының күләме җитештерелүче товарлар һәм хезмәтләр санынннан артып киткәндә килеп чыга). Әмма шул ук вакытта җитештерү кими, чөнки фирмалар кредит алу мөмкинлегеннән мәхрүм кала.

Процент исәп ставкасын төшереп һәм кредитны арзанландырып, дәүләт заем алучылар санын арттыра, аларның икътисади активлыгына этәргеч бирә, бу исә җитештерүнең күтәрелешенә булышлык итә. Ләкин әйләнештәге акча массасының артуы инфляцияне көчәйтә.

Шулай итеп, дәүләт барлык икътисадка процент исәп ставкасын үзгәртү юлы белән, җитештерүне һәм куллануны кызыксындырып яки чикләп, йогынты ясый ала.

Закон буенча коммерция банклары үз акчаларының бер өлешен, үз исәпләрендәге акчаларны алырга теләгән клиентларга түләү өчен, үзәк банкта резерв рәвешендә тотарга тиешләр. *Мәҗбүри резерв нормасын* билгеләп, үзәк банк башка банкларның кредитлар бирү мөмкинлегенә йогынты ясый, шуның белән әйләнештәге акчаның гомуми күләмен үзгәртә.

Мәҗбүри резерв нормасын арттыру банкларның кредитлау өчен акча күләмен киметүгә китерә, заем алучылар санын кыскарта һәм, димәк, әйләнештәге акча массасын киметә.

Резервлау нормасын киметү, киресенчә, фирмаларны кредитлау күләмнәрен арттырырга мөмкинлек бирә, ә бу акча массасының үсешенә алып бара. Моның икътисадта нинди нәтиҗәләргә китерүен сез беләсез.

Шулай итеп, акча-кредит сәясәтенең ике ысулы да, дәүләткә әйләнештәге акча массасына йогынты ясап, икътисадка тотрыклы үсәргә ярдәм итә.

БЮДЖЕТ-САЛЫМ (ФИСКАЛЬ) СӘЯСӘТЕ

Дәүләтнең салым салу, дәүләт чыгымнарын көйләү һәм дәүләт бюджеты өлкәсендәге эшчәнлеге «фискаль сәясәт» дип атала. Ул икътисадның тотрыклылыгын тәэмин итүгә, инфляцияне булдырмауга, халыкның эш белән тәэмин ителүенә юнәлгән.

Дәүләт бюджеты — дәүләт керемнәренең һәм алынган акчаларны дәүләт чыгымнарының барлык төрләрен каплауга файдалануның җыелма планы. Бюджет парламент тарафыннан раслана, ә хөкүмәт аның үтәлеше өчен җавап бирә. Россия хөкүмәте чыгымнарында төп урыннарны түбәндәгеләр били: милли оборона, хокук саклау эшчәнлеге, куркынычсызлыкны тәэмин итү һәм суд хакимияте, дәүләт идарәсе, хуҗалыкның төрле тармаклары икътисади үсеше, дәүләт бурычына хезмәт күрсәтү, социаль тәэминат. Дәүләт керемнәренең төп чыганаклары — салым керемнәре.

Бюджет аша дәүләт җәмгыять булдырган муллыкны җитештерүчеләрдән башка төркемнәргә яңадан бүлә. Дәүләт, бюджеттан файдаланып, икътисадка җитди йогынты ясарга, җитештерүне һәм социаль процессларны кызыксындырырга мөмкин. Бу йогынтының төп этәргече — салым салуны һәм дәүләт чыгымнарын көйләү.

Салымнар дәүләт бюджеты керемнәренең төп чыганагы булып тора. Салымнарның төрләре (туры, читләтеп) һәм гражданнар түли торган төгәл салымнар белән сез төп мәктәптә таныштыгыз. Салым керемнәрендә төп урынны предприятиеләр түли торган: өстәмә кыйммәткә салым, табышка салым, тышкы сәүдә салымы һ.б. алып тора. Законлы билгеләнгән салымнарны түләү бурычы Россия Федерациясе Конституциясендә беркетелгән. Россиянең кайбер эшмәкәрләре үз бизнесыңны саклауның бердәнбер мөмкинлеге — салым түләүдән тайпылу, үз керемнәреңнең бер өлешен исәпкә алудан яшерү дип саныйлар. Гражданнарның, бигрәк тә югары керем алучыларның байтагы салымны үз вакытында һәм тулысынча түләми. Бу дәүләтнең җәмгыятьтәге үз икътисади функцияләрен авырлаштырып кына калмый, Россия икътисадының торышы турындагы мәгълүматны бозып күрсәтә, аны үстерү программаларын эшләүне катлауландыра.

Теләсә кайсы дәүләтне алып караганда да, салым сәясәте икътисадка ничек тәэсир итә соң? Әгәр дә икътисад югары инфляциядән зыян күрсә, аны киметү өчен, сезнең инде белүегезчә, әйләнештәге акча массасын киметергә кирәк. Моның өчен дәүләт салымнарны арттыра, шуның белән фирмаларның һәм халыкның икътисади активлыгын кимәтә.

Әгәр ил икътисадында җитештерү һәм куллануның төшүе күзәтелә икән, дәүләт салым йөген киметергә омтыла. Бу икътисадның җанлануына ярдәм итә. Фирмаларның товар чыгару өчен өстәмә акчасы пәйда була, ә халыкның түләү сәләте үсү нәтиҗәсендә куллану активлыгы арта.

Дәүләтнең үз чыгымнарын көйләве дә җитештерүдәге төшүне туктатырга ярдәм итәргә мөмкин. Шулай итеп, икъ-

тисадтагы кризис вазгыятендә дәүләт хуҗалыкның ярдәмгә аеруча мохтаҗ предприятиеләренә һәм тармакларына булышу чыгымнарын арттырырга тырыша, товарларны һәм хезмәт күрсәтүләрне дәүләт сатып алуын (мәсәлән, оборона предприятиеләренә дәүләт заказы) киңәйтә, җитештерүчеләрне производствоны үстерүгә һәм эшсезлекне кыскартуга кызыксындыра.

Бюджет сәясәте шулай ук керемнәрне һәм чыгымнарны баланслауга (сан ягыннан тигезлеккә ирешүгә) юнәлтелә, чөнки дәүләт чыгымнарының сизелерлек үсеше һәм салымнар җыеп бетермәү **бюджет дефицитына** — тискәре икътисади күрсәткечләрнең берсенә китерә. Бу хәлдә дәүләт үз чыгымнарын каплау өчен кредитлар алырга мәҗбүр була, ә аларны фирмалар файдалана алган булыр иде, бу исә икътисади үсешне тоткарлый. Дәүләт — бюджет дефицитын әйләнешкә өстәмә акча чыгарып яисә халыктан бурычка алып та каплый ала. Әмма халык тарафыннан дәүләтне кредитлау мөмкинлеге гадәттә чикләнгән була, ә дәүләтнең товар белән тәэмин ителмәгән яңа кәгазь акчалар чыгаруы инфляциягә илтә.

Күпчелек хөкүмәтләр дәүләт бюджеты шартларында гражданнардан, хуҗалык һәм финанс оешмаларыннан (үз иле һәм халыкара) акча алып торуны өстенрәк күрә. Дәүләтнең тышкы һәм эчке кредиторларына бурычы суммасы *«дәүләт бурычы»* дип атала. *Тышкы* һәм *эчке* дәүләт бурычларын аерып карыйлар.

Бурычка алуның иң еш кулланылучы рәвеше — дәүләт кыйммәтле кәгазьләрен сату. Дәүләтнең әлеге кыйммәтле кәгазь ияләренә бурычы суммасы дәүләт бурычының бер өлешен тәшкил итә. Дәүләт кыйммәтле кәгазьләре белән эшне оста үткәрү дәүләт бюджетына акчаларны отышлы җәлеп итәргә генә түгел, бөтен икътисадның үсешенә йогынты ясарга да мөмкинлек бирә. Әйтик, дәүләт кыйммәтле кәгазьләрен сатып алу һәм сату юлы белән үзәк банк дәүләтнең кредит системасына резервларны салырга да, аннан кире алырга да мөмкин. Икътисадта моның нинди нәтиҗәләргә китерергә мөмкин булуын, дәүләт акча-кредит сәясәтенең төп механизмнары эше белән танышканнан соң, сез инде беләсез.

Бюджет дефициты һәм дәүләт бурычының зурлыгы — икътисад торышының иң мөһим күрсәткечләре.

Күргәнебезчә, икътисадка йогынты ясауның теге яки бу механизмнарын көчәйтеп яисә йомшатып, дәүләт фискаль сәясәттә, монетарын да уздыра ала. Көйләү вариантларын сайлап алу югарыда бәян ителгән материалда характерланган төрле факторлар белән билгеләнә.

БАЗАРГА ДӘҮЛӘТ ЯРДӘМЕ КИРӘКМЕ?

Параграфның беренче бүлегендә без дәүләтнең базар системасы эшләвенә булышлыгы һәм аны тәэмин итүе кебек икътисади функциясен аерым карадык.

Базарның хосусый милек, эшмәкәрлек иреге һәм икътисади сайлап алу иреге кебек мөһим институтлары гамәлгә ашырылсын өчен махсус законнар эшләү зарур. (Мәсәлән, Россия дәүләтенең эшмәкәрлек эшчәнлеген нинди законнар белән җайга салуын исегезгә төшерегез.)

Дәүләт конкуренциягә булышлык итүдә һәм аны яклауда, икътисадта монополистлык тенденцияләрен йомшартуда актив роль уйнарга тиеш. Дәүләтнең болай катнашуы, сезнең белүегезчә, монополиягә каршы төрле чаралар, аңа каршы законнар эшләү аша тормышка ашырыла.

Базар икътисадын дәүләт җайга салуы эшмәкәрлеккә ярдәм рәвешендә чагылыш таба. Бу безнең илдә аеруча зур әһәмияткә ия, чөнки бизнес әле базарда аякка басуның катлаулы юлын үтеп кенә килә. Эшмәкәрлеккә ярдәмнең беренче елларда фирма эшенә ташламалы салым салу, аларны теркәү кагыйдәләрен гадиләштерү, кече предприятиеләргә субсидияләр бирү кебек формалары бар.

Тагын бер кат исегезгә төшерәбез: базар икътисадында өстенлек дәүләт йогынтысының базар мөнәсәбәтләре системасын җимермәүче һәм аларга каршы килмәүче читләтелгән (икътисади) ысулларына бирелә.

ГАМӘЛИ ЙОМГАКЛАР

1 Үз икътисади һәм социаль хокукларыгызны һәм мәнфәгатьләрегезне компетентлы яклау өчен Россия хөкүмәте икътисади сәясәтенең тенденцияләрен күзәтеп барырга, икътисадта базар мөнәсәбәтләрен үстерү проблемаларын анализларга тырышыгыз.

2 Илдә социаль-икътисади үзгәртеп коруларның сәбәбен һәм нәтиҗәләрен анализлау сезгә икътисади тормышта рациональ һәм цивилизацияле катнашу ысулларын һәм рәвешләрен табарга, кулланучы, җитештерүче, хезмәт базарында катнашучы, милекче һ.б. рольләрне башкарганда дөрес карарлар кабул итәргә мөмкинлек бирер.

3 Дәүләтнең икътисади сәясәте мәсьәләләре буенча үз позицияңне, икътисади процессларны җайга салуда ул кулланган ысулларның нәтиҗәлелеген бәяләүне формалаштыру бу сәясәткә йогынты ясау рәвешен һәм аның ысулларын

(закон чыгаручыларны сайлауда катнашу, протест яисә социаль-икътисади сәясәтне хуплау акцияләре, җәмәгать берләшмәләрендә, партияләрдә эшләү һ.б.) сайлап алу өчен кирәк.

4 Сез киләчәктә салым түләүчеләр. Шуны исегездән чыгармагыз, сезнең салымнарны намус белән (тулы һәм үз вакытында) түләвегезгә дәүләт тарафыннан бирелүче җәмәгать уңайлыкларыннан тулы файдалануыгыз, шулай ук үзегезнең дә, тирә-юнегездәге кешеләрнең дә шәхси муллыгы бәйле.

ДОКУМЕНТ

Базар икътисады шартларында дәүләт роле турында. *Хәзерге заман икътисадчы-галиме **А.Н.Пороховскийның*** «Россиянең базар моделе: гамәлгә ашыру юлы» дигән хезмәтеннән.

Икътисадның барлык агентларын илнең бердәм базар киңлеге берләштерә, анда һәркем өчен бертөрле уен кагыйдәләрен дәүләтнең махсус институтлары күзәтеп тора һәм саклый... Базар үзе генә конкуренцияне яклап-саклап бетерә алмый. Икътисади өлкәдә конкуренцияне хуплау һәм кызыксындыру — дәүләт функциясе. Монополиягә каршы көрәшеп, конкуренцияне яклап, дәүләт, тулаем базар системасының тотрыклылыгын гарантияләп, үзе базар моделе кысаларында да, аннан читтә дә була. Тотрыклылыкны саклау конкуренцияне яклау кебек үк мөһим роль. Тиешле дәүләт институтларының уйланылган, актив роленә илдәге социаль климат та, финанс системасының тотрыклылыгы да, ... иҗтимагый уңайлыклар җитештерүне — бигрәк тә хезмәт күрсәтү өлкәсендә, мәгариф, фән, сәламәтлек саклау, мәдәният өлкәләрендә, — киңәйтү, эшмәкәрлек даирәсендә хокукый мәйдан булдыру бәйле... Шуңа күрә хәтта теоретик базар моделендә дә дәүләткә гаять мөһим — гомуми яисә иҗтимагый мәнфәгатьләрне чагылдыру юлы белән базар системасының үзен саклау роле бирелә. Бер генә хосусый бизнес та, нинди генә гигант зурлыкка ирешсә дә, үзенең табигате буенча үз мәнфәгатьләрен читкә куеп, бөтен җәмгыять мәнфәгатьләрен үз җилкәсенә алмый. Әмма мондый бурычларны дәүләт үзе дә демократик җәмгыятьнең бер өлеше булса гына үти ала. Мондый җәмгыятьтә, базар механизмы белән беррәттән, сайлаучыларның дәүләт аппаратына контроле демократик механизмы җайга салынган, ә суд системасы законнар нигезендә барлык гражданнарны хокукый яклауны тәэмин итә.

Документка сораулар һәм биремнәр

1. Документ авторы бердәм базар киңлегендә дәүләт институтлары ролен ничек бәяли? Галим фикере буенча, дәүләтнең нинди функцияләре базар системасының тотрыклы үсешенә этәргеч бирә?
2. А.Н.Пороховский җәмгыять тормышындагы дәүләтнең актив роленә турыдан-туры бәйле берничә социаль-икътисади күренешне атый. Мәгълүм фактларга таянып, аларның берсен сурәтләгез.
3. Документ авторы конкуренцияне саклауда һәм үстерүдә дәүләт ролен басым ясап күрсәтә. Текстка һәм җәмгыять белеменә таянып, базар икътисады өчен конкуренциянең әһәмиятен аңлатыгыз.
4. Икътисадчы фикеренчә, ни өчен демократик җәмгыятьнең булуы базар икътисадында дәүләт тарафыннан үз функцияләрен үтәү шарты булып тора? Базар белән демократия арасында элемтә бармы? Моны раслаучы мисаллар китерергә тырышыгыз.
5. Автор җәмгыятьтә, базар механизмы белән беррәттән, суд системасының да җайга салучы ролен күрсәтә. Икътисади эшчәнлектә катнашучыларны хокукый яклауның әһәмиятен ачып бирегез.

ҮЗ-ҮЗЕҢНЕ ТИКШЕРҮ ӨЧЕН СОРАУЛАР

1. Икътисади сәясәт үткәреп, хөкүмәт нинди максатларга ирешә? Дәүләтнең икътисадка йогынтысының төп ысулларын атагыз. **2.** Дәүләт нигә иҗтимагый уңайлыклар җитештерү белән шөгыльләнә? **3.** Базарның икътисадны «җайга салу» мөмкинлекләренең чикләнгәнлеге нидән гыйбарәт? **4.** Дәүләтнең икътисадка катнашуы чикләре булырга тиешме? Булса, нигә? **5.** Дәүләт базар икътисадына ничек ярдәм итә?

БИРЕМНӘР

1. Россиянең шактый дәүләт бурычы бар. Аны каплауның нәтиҗәле юлларын ничек табарга? Тәкъдимнәрегезне дәлилләгез.

2. Соңгы елларда Россия дәүләте дефицитсыз бюджетка ирешә. Бюджет дефицитының икътисадка тискәре йогынтысын тасвирлагыз һәм үзегезнең карашка илдә бюджет дефицитын булдырмау буенча эшлекле, дәүләтчел чаралар тәкъдим итегез.

3. Түбәндәге әйтемнең мәгънәсен аңлатыгыз: «Салымнар — дәүләт хезмәтләре өчен без түли торган бәя ул». Фикерегезне мисаллар белән ныгытыгыз.

4. XX гасырның 90 нчы еллары реформалары чорында дәүләт икътисади сәясәтенең уңай нәтиҗәләргә китергән, шулай ук өметләрне акламаган юнәлешләрен атагыз. Шул чор Россия икътисади сәясәтен аңа теге яки бу теоретик икътисади концепция йогынтысы позициясеннән чыгып анализлагыз.

ЗИРӘКЛӘР ФИКЕРЕ

«Акыллы дәүләт үз гражданнарына акча эшләргә комачауламый, салымнар рәвешендә табыш алып, моны күзәтеп кенә тора».

Дж. Фейлан, хәзерге заман Америка икътисадчысы

§ 8. Икътисадта финанслар

Икътисадта акча кулланудан баш тартырга мөмкинме? Акчаның бәясе бармы? Кредит кемгә файдалы? Дәүләт ни өчен «уртак кассир» ролен башкарырга мәҗбүр?

Алдагы параграфтан сез базар икътисадын дәүләт җайга салуының төрле юллары: административ, хокукый, акча-кредит һәм бюджет-салым ысуллары турында белдегез. Дәүләт тарафыннан алардан файдалануның максаты — икътисадка тотрыклы, тирән кризислардан, чамадан тыш күтәрелү һәм төшүләрдән башка үсәргә булышу. Базар мөнәсәбәтләре структурасында һәм аларны дәүләт көйләве механизмында финанслар гаять зур роль уйный.

Финанс (киң мәгънәдә) — акчадан файдалану процессында икътисади мөнәсәбәтләр җыелмасы.

Мәсәлән, банктан кредит алганда, хезмәткәргә эш хакы түләгәндә, бюджетка түләүләр күчергәндә, иминиятләштерү кертемнәре түләгәндә тиешле оешмалар белән финанс мөнәсәбәтләре барлыкка килә.

Икътисадта финанслар уртак җәмгать продуктын һәм милли керемне бүлү һәм яңадан бүлү инструменты буларак кулланыла. Мәсәлән, матди җитештерү тармакларында алынучы керем өлешчә предприятиедә (табышның бер өлеше) һәм аның хезмәткәрләрендә (эш хакы) кала, өлешчә бюджетка (төрле салымнар) керә. Дәүләттә акча ресурслары туплана, аннары ул

хуҗалыкның җитештерүчән булмаган тармакларына, идарә ихтыяҗларына h.б. бүлеп бирелә.

Йорт хуҗалыклары акчаны, тулаем алганда, туздырганнан күбрәк ала һәм, кагыйдә буларак, беркадәр саклык акчасына ия була. Фирмалар һәм хөкүмәт органнары уртача алганга караганда күбрәк туздыралар һәм үз эшчәнлекләрен киңәйтү өчен акчага мохтаҗлык сизәләр. Әйтик, предприятие табышы — финанс ресурсларының эчке чыганагы исәбенә гадәттә акчага ихтыяҗның 70% ы чамасы каплана. Җитмәгәнен фирма эзләргә мәҗбүр була.

Шулай итеп, бериш хуҗалык итүче субъектларда акча керәгеннән артык, ә икенчеләрендә ул җитми. Әлеге төп икътисади субъектларның финанс мәнфәгатьләрен кайчан һәм ничек итеп канәгатьләндерергә мөмкин була?

БАНКЛАР СИСТЕМАСЫ

Йорт хуҗалыкларына, фирмаларга, хөкүмәт органнарына үзләренә кирәк булган акчаларны алуда яисә артык акчаларыннан отышлы файдаланырга банклар һәм башка финанс институтлары ярдәм итә. Алар саклык акчалары ияләре белән аны бурычка алучылар арасында арадашчы булып хезмәт итә.

Банклар системасы — илдә гамәлдә булган банклар һәм башка кредит учреждениеләре, оешмалары җыелмасы.

Банк — ирекле акчаларны җәлеп итү һәм аннан соң аны кредитка бирү, гражданнар һәм оешмалар арасында акча исәп-хисабы ясау белән шөгыльләнүче финанс учреждениесе ул. Банк бездән алган кертем өчен өстәмә акча бирә, яки алган кредит өчен банкка үзебез түлибез. Бу өстәмә суммалар процент ставкалары, ягъни акчадан файдаланган өчен түләү булып тора. Ул кертем яисә кредит суммасына процентларда акчадан файдаланган вакытка исәпләп билгеләнә. Мәсәлән, сез бер елга банктан еллык 25% лы 10 мең сум кредит аласыз. Аны 12,5 мең сум итеп кайтарырга туры килә, ягъни кредиттан файдаланган өчен түләү 2,5 мең сум була. Банк эшчәнлегенең төп принцибы — кертемчеләр акчасын саклау һәм аның зуррак өлешен башка затларга бурычка биреп тору, шуның белән керем алу.

Барлык илләрдә хәзерге заман банк системасы ике дәрәҗәдә итеп оештырылган. Югары дәрәҗә — үзәк банк, түбән дәрәҗә — коммерция банклары һәм башка финанс-кредит оешмалары (инвестиция һәм финанс компанияләре, иминиятләштерү компанияләре, пенсия фондлары h.б.). Банк системасы схемасын түбәндәгечә сурәтләп була:

Үзәк банкның роле нинди, һәм башка банклардан төп аермасы нидә?

Бериш илләрдә **үзәк банк** хөкүмәткә буйсындырылган, ә икенчеләрендә — ул бәйсез, әмма һәркайда базар икътисады эшләве өчен зур әһәмияткә ия. Россиядә үзәк банк икътисади яктан бәйсез учреждение булып санала һәм хәтта парламент каравына яңа законнар тәкъдим итү хокукына да ия.

Илдә милли валюта булган акча билгеләрен фәкать үзәк банк кына чыгарырга (эмиссияләргә) мөмкин. Аңарда иң эре акча ресурслары бар, халыкара резервлар (башлыча чит ил валютасы, алтын) һәм эчке резервлар (коммерция банкларының мәҗбүри резервлары) да аның карамагында. Шуңа күрә үзәк банк барлык башка банкларга булышлык күрсәтә һәм алар эшчәнлеген контрольдә тота ала. Барлык илләрдә дә ул «хөкүмәт банкиры» ролен үти, ягъни дәүләтнең финанс эшчәнлегенә хезмәт күрсәтә һәм шулай итеп икътисадны җайга салу буенча дәүләт функциясенең бер өлешен үтәүдә катнаша. (Исегезгә төшерегез: дәүләт финанс җайга салуының нинди механизмнарыннан файдалана?)

Үзәк банкның *төп функцияләре*: дәүләтнең акча-кредит сәясәтен тормышка ашыру, коммерция банкларына кредит бирү, банк һәм финанс системаларының тотрыклы эшчәнлеген тәэмин итү, милли акча берәмлегенең тотрыклы булуына булышу, акча һәм алтын запасларын саклау.

Банклар системасының икенче дәрәҗәсе — **коммерция банклары.** Аларны еш кына финанс системасының «эш атлары» дип атыйлар. Базар икътисадында коммерция банкы үз бизнесын оештыручы эшлекле предприятие булып тора. Ул табыш алу максатында клиентларга түләүле хезмәт күрсәтеп (кертемнәр алып һәм кредитлар биреп), турыдан-туры предприятиеләргә, оешмаларга һәм халыкка хезмәт күрсәтә. Коммерция банклары акчалардан файдаланган өчен заемчылардан күбрәк түләү ала (процент ставкасы югарырак), ә кертемчеләргә азрак түли (монда исә процент ставкасы түбәнрәк). Бу процентлар

арасындагы аерма банкның табышы була да инде. Шул ук вакытта коммерция банклары хуҗалык эшчәнлегендә төп катнашучыларның вакытлыча ирекле акчаларын яңадан бүлү өлкәсендә, алар арасында түләүләрне тормышка ашыруда мөһим финанс арадашчылары ролен уйный.

Россиядә беренче банклар XVIII гасыр уртасында ук барлыкка килә — Мәскәү дворян банкы, Петербург сәүдәгәрләр банкы, 1860 елда Дәүләт банкы оештырыла. Аларның максаты сәүдәгә ярдәм итү һәм илдә акча әйләнешен җайга салу була. XIX гасырның икенче яртысында коммерция банклары барлыкка килә. Шул вакыттан башлап банклар финанс базарында өстенлекле урын били. Бу нигә шулай килеп чыга соң? Банклар эшлекле даирәләрдә киң танылу ала, репутацияләре тотрыклы була. Банк операцияләренә акча кертү башка кредит оешмаларына һәм хәтта эре предприятиегә (мәсәлән, бердәнбер предприятие акцияләренә) акча салуга караганда куркынычсызрак дип санала. Банклар, кагыйдә буларак, төрле тармаклардан бик күп клиентларга хезмәт күрсәтә һәм хезмәтләрнең киң даирәсен тәкъдим итә.

Хәзерге Россиядә коммерция банклары 1988 елдан үсеш алды һәм, банк эшчәнлегенә дәүләт монополиясен юкка чыгарып, базар реформаларында мөһим роль уйнады. Аларның күптөрлелеге финанс өлкәсендәге әһәмиятләре һәм урыннары турында фикер йөртергә мөмкинлек бирә: *тармак банклары* (икътисадның билгеле бер тармагына хезмәт күрсәтә, мәсәлән, Газпромбанк); *тармакара* (икътисадның барлык тармакларына хезмәт күрсәтә, мәсәлән, Рус милли банкы), *төбәк* (илнең аерым төбәкләренә хезмәт итә, мәсәлән, Мосбизнесбанк), *Саклык банкы* (илнең барлык төбәкләрендә филиаллары бар һәм халык кертемнәрен кабул итү һәм саклау буенча махсуслаша) һ.б.

Коммерция банкының традицион операцияләре пассив һәм актив операцияләрдән гыйбарәт.

Банкның пассив операцияләре — акча ресурслары мобилизацияләү операциясе ул: кертемнәр кабул итү (депозит); башка банклардан һәм үзәк банктан кредитлар алу; үзкыйммәтле кәгазьләрен чыгару. Бурычка алган бу акчалар — коммерция банкы эшчәнлегенең нигезе.

Банкның актив операцияләре — акчаларны урнаштыру операцияләре: вакыты һәм күләме буенча төрле кредитлар бирү. Белгәнегезчә, банклар бирелгән кредит өчен заемчыдан процент рәвешендәге түләү ала. Кредит операцияләре банк бизнесында иң керемле статья булып тора, ләкин бер үк вакытта ул тәвәккәллек сорый. Ссуданы кире кайтармау, процентлар түләмәү, кредитны кайтару вакытын бозу куркынычы бар. Мондый

шөбһә коммерция банкларын заемчының кредит каплау сәләтен бәяләүнең нәтиҗәле алымнарын эзләргә мәҗбүр итә.

Хәзерге заман эре коммерция банклары үз клиентлары өчен 300 гә кадәр төр операция үткәрә һәм хезмәт күрсәтә, моңа алдарак атап кителгәннәрдән тыш кыйммәтле кәгазьләр һәм валюта сатып алу һәм сату, сейфта кыйммәтле әйберләр саклау һ.б. керә.

БАШКА ФИНАНС ИНСТИТУТЛАРЫ

Коммерция банкларыннан башка, XIX йөз ахырыннан инвестиция компанияләре, пенсия фондлары, иминиятләштерү компанияләре, фонд биржалары һ.б. кебек финанс һәм кредит институтлары (учреждениеләре) үсеш алды. Аларның эшчәнлеге коммерция банклары операцияләрен тулыландыра. *Финанс-кредит учреждениеләре* ирекле акчаларны туплыйлар һәм аларны өстәмә капиталга яисә финанс ярдәменә мохтаҗ булучыларга бирәләр.

Пенсия фонды — әлеге фондка пенсия кертемнәре ясаган затларга пенсия һәм пособиеләр түләү өчен хосусый һәм дәүләт компанияләре, предприятиеләр төзегән фонд.

Шәхси пенсия фондлары хезмәткәрләрдән, киләчәктә аларга пенсия түләү шарты белән, аларның эш хакының бер өлешен җыя. Алардан турыдан-туры билгеләнеше буенча файдаланганга кадәр җыелган акчаларны эре корпорацияләрнең кыйммәтле кәгазьләрен сатып алуга тоталар, соңгыларыннан алынган керем пенсия фондын арттыруга китә.

Әйтик, АКШта ел саен йөзләрчә миллиард доллар җыючы дәүләт пенсия фондлары акчаны финанс министрлыгы облигацияләренә кертә (дәүләт кыйммәтле кәгазьләренең бу төре турында нәрсә белүегезне искә төшерегез).

Россия Федерациясе пенсия фонды — пенсия тәэминаты финанслары белән дәүләтнең идарә итүен тормышка ашыручы мөстәкыйль финанс-кредит учреждениесе.

Инвестиция компанияләре — хосусый инвесторларның акчаларын аларга үзләренең кыйммәтле кәгазьләрен сату юлы белән җыючы финанс-кредит институты. Инвестиция компаниясе акчаны бурычка алучы белән хосусый инвестор арасында, соңгысы мәнфәгатьләрен чагылдырып, арадашчылык итә. Компания җәлеп ителгән акчаларны үз илендә яисә чит илдә предприятиеләр акцияләрен һәм облигацияләрен сатып алу юлы белән урнаштыра. Кыйммәтле кәгазьләрнең күптөрле җыелмасы бу компанияләргә капитал югалту куркынычын киметергә һәм кертемчеләр керемнәренең тотрыклылыгын һәм ыша-

нычлылыгын тәэмин итәргә мөмкинлек бирүе белән мөһим, чөнки кризис яисә финанс тынгысызлыгы төрле тармакларга төрлечә кагыла.

Атап үтелгән финанс институтлары эшчәнлегендә кредит операцияләре һәм фонд базары операцияләре үрелеп бара, аларның механизмы белән сез инде таныш.

Иминиятләштерү компанияләре — иминиятләштерү хезмәте күрсәтүче оешмалар. Алар махсус иминиятләштерү фондларының (предприятиеләр, гражданнар күчергәннәрнең) уңай килмәгән вакыйгалар, бәхетсезлек очраклары китергән зыян, югалтуларны каплауга билгеләнгән акчаларыннан файдалана. Мәсәлән, сез су басканда яки янгын вакытында зыян күрсәгез (мөлкәт юкка чыкса яки физик сәламәтлегегез зарарланса), сезгә, әгәр мөлкәтегезне һәм исәнлегегезне алдан ук иминиятләштергән булсагыз, билгеле бер күләмдә акча түләнә.

Финанс компанияләре индивидуаль заемчыларга куллану кредиты һәм кечкенә ссуда бирүдә махсуслаша. Әйтик, сез магазинда рәсмиләштереп, озак вакыт файдаланыла торган товарларны (суыткыч, кер юу машинасы, мебель) кредитка аласыз.

Фонд биржалары, инде белүегезчә, кыйммәтле кәгазьләр сату һәм сатып алу буенча махсуслаша. Коммерция банклары аларда үз клиентларының акция һәм облигацияләрен урнаштыра. Фонд биржалары акчаларны икътисадның югары керемле тармакларына салу процессында актив катнаша, шуның белән аларның үсешенә ярдәм итә.

Хәзерге заман бөтендөнья икътисадында *дәүләтара финанс-кредит институтлары:* Бөтендөнья банкы, Халыкара валюта фонды, Европа реконструкцияләү һәм үсеш банкы, Халыкара икътисади хезмәттәшлек банкы хәрәкәт итә. Алар төрле илләрне финанслау һәм кредитлау белән шөгыльләнә, бөтендөнья сәүдәсенә булыша, үсеп килүче илләрнең финанс системасын тотрыклыландыруда кирәкле ярдәм күрсәтә h.б.

Дәүләт һәм хосусый финанс институтлары эшчәнлеге ссуда капиталы формалаштыруга, аннан нәтиҗәле файдалануга, шулай ук дәүләтнең гомум-икътисади һәм финанс сәясәтенә сизелерлек йогынты ясый.

ИНФЛЯЦИЯ: ТӨРЛӘРЕ, СӘБӘБЕ ҺӘМ НӘТИҖӘСЕ

Алдагы параграфтан сез дәүләт финанс сәясәтенең төп инструменты акча булуын белдегез инде. Акча-кредит сәя-

сәтенең төрле механизмнарын кулланып, дәүләт ил территориясендә әйләнештәге акча санын — акча массасын җайга салырга омтыла. Ил икътисадының торышы акча хуҗалыгындагы хәлгә, акча массасының зурлыгына ничек бәйле?

Икътисадта акчаның үз бәясе, яисә сатып алу сәләте бар. Ул анык бер вакыт аралыгында аңа никадәр товар һәм хезмәт күрсәтү сатып алырга мөмкин булса, шулкадәр тора. Соңгы унъеллыкларда россиялеләр товар һәм хезмәт күрсәтү бәясе даими арта барган вазгыятьтә яши. Товарлар бәясе генә үзгәреп калмый, аларның кыйммәтен үлчәгечнең — ягъни акчаның бәясе дә үзгәрә. Бер үк кадәрле сандагы сумнарга без торган саен азрак товар алабыз. Акчаның сатып алу сәләте төшә. Шул ук вакытта куллану товарларына бәяләр эш хакыннан тизрәк үсә.

Югарырак бәяләр вакытында элеккеге тормыш дәрәҗәсен саклау өчен кешеләргә күбрәк акча таләп ителә. Дәүләт әйләнешкә өстәмә акча чыгаруга бара, ягъни акча массасын арттыра. Бу товарларга һәм хезмәтләргә сорауны күтәрә һәм, шуның нәтиҗәсе буларак, аларга бәя янәдән арта төшә.

Акчаның бәясе төшү процессы (ә ул товарларга һәм хезмәтләргә озак вакыт бәя күтәрелүдә чагыла) инфляция (латинчадан — *inflatio* — кабарту) дип атала. Бу сүзнең мондый мәгънәсе әлеге икътисади күренешнең, кагыйдә буларак, акча массасы күләме шактый артса да, товарлар һәм хезмәт күрсәтүләр санының үсмәвеннән килеп чыгуы белән бәйле.

Инфляция төрле рәвешләрдә һәм төрләрдә чагыла. Бәяләрнең үсеш зурлыгына бәйле темплары буенча инфляция «шуышучы», «сикертеп чабучы» һәм «гипераинфляция»гә бүленә. *«Шуышучы»* инфляция — товарларга һәм хезмәт күрсәтүләргә бәяләр үсеш темплары елга 10–15% тан артмаганда була. *«Сикертеп чабучы»* инфляция бәяләрнең сикереп-сикереп китүе белән характерлы. *«Гиперинфляция»* — бәяләрнең айга 50% ка, ә елга 130 тапкырга артуы. Акчаның бик тиз очсызлануы акча-кредит системасының җимерелүенә китерә (заемчылар бу вазгыятьтә бурычка акча алырга курка, ә кредиторлар кредит процентын күтәрергә мәҗбүр), шуның нәтиҗәсе буларак, җитештерү һәм эш белән мәшгульлек кими. Гиперинфляция — икътисади кризисның иң авыр формасы.

Россия базар икътисадына күчкәндә, инфляция гаять зур күләмгә җитте. Әйтик, Халыкара валюта фонды бәяләве буенча 1992 елда инфляция темпы 1353% булды, 1993 елда — 800%, 1994 елда — 204%. 1997 елга гына аның темплары сизелерлек төшә башлады һәм яңа гасырның беренче елларында

(2001–2003) бәяләр үсеше темплары — 8,7%, 8,9% һәм 12% булды. (Тарих курсларыннан инфляция турында китерелгән бу белешмәләр XX гасырның 90 нчы елларында Россия икътисады үсешенең нинди үзенчәлекләрен чагылдыруын исегезгә төшерегез.)

Инфляциянең ике гасырлык диярлек тарихы бар һәм XX гасырның 40 нчы елларыннан башлап ул дөньяның барлык илләрен чолгап алды. Хәзерге заман инфляциясенә берничә үзенчәлек хас: әгәр элегрәк ул локаль (җирле) характерда булса, хәзер — һәр җирдә, бар нәрсәне чолгап ала; әгәр элек ул күбрәк һәм азрак чорда, ягъни периодик төстә булса, хәзер — даими төстә. Мәсәлән, 1991–2000 елларда дөньяның кайбер илләрендә инфляциянең уртача дәрәҗәсе түбәндәгечә булды: АКШта — 2,7%, Японияда — 0,9%, Германиядә — 2,3%, Франциядә — 1,7%, Англиядә — 3,2%, Италиядә — 3,6%. Бу илләрдә инфляция икътисадчылар тарафыннан хуҗалык итү механизмының аерылгысыз элементы буларак карала. Зур булмаган инфляцияне (елга 5% тан артык түгел) табигый, ягъни нормаль күренеш, диләр. Бәяләр күпкә үсмәсә, инфляция икътисадка хәтта уңай йогынты ясарга мөмкин: инвестициягә этәргеч бирә (акчаны саклап ятканчы, аны производство үсешенә салу отышлырак), эш белән тәэмин итүне яхшырта, эшсезлекне киметә.

Исегезгә төшерәбез: бәяләрне барлык күтәрүләр дә инфляция чагылуы түгел әле. Бәяләр продукциянең сыйфаты яхшырганда да, ягулык, чимал ресурслары чыгару шартлары начарайганда да, иҗтимагый ихтыяҗ үзгәргәндә дә, товарларга сезон соравы үзгәреп торганда да күтәрелә ала. Ләкин болар, кагыйдә буларак, инфляция түгел, ә мәгълүм бер мәгънәгә ия, аерым товарларга үз-үзен аклый торган күтәрелеш. Инфляция бәяләр күтәрелүдә генә түгел, дефицитта, товарлар сыйфатының начарлануында да чагылыш таба. Инфляциянең сәбәпләре нәрсәдә соң?

Инфляция китереп чыгаручы сәбәп төрләре буенча икътисадчылар **сорау инфляциясен** һәм **чыгымнар инфляциясен** аерып карыйлар. Сорау тәкъдимнән артып киткәндә, сорау инфляциясе барлыкка килә, бу бәяләрнең артуына этәрә. Инфляциянең бу төре халык һәм предприятиеләр кереме товарлар һәм хезмәт күрсәтүләрнең реаль күләменнән тизрәк үскәндә була. Әлеге процессның асылын бер әйтем белән аңлатырга мөмкин: «Бик күп акча бик аз сандагы товарны аулый». Артык зур сорау чыганаклары түбәндәгеләр булырга мөмкин: дәүләт бюджеты дефициты (ул еш кына товар белән тәэмин ителмәгән акча чыгару, ягъни «басу машинасын» кул-

лану исәбенә каплана), ә бу акча массасының артуына һәм, нәтиҗә буларак, инфляциягә китерә; җитештерүнең артуы һәм хезмәт җитештерүчәнлегенең үсүе белән чагыштырганда эш хакының тизрәк үсүе һәм башка факторлар.

Чыгымнар (тәкъдимнәр) инфляциясе продукция бирәмлегенә чыгымнарның артуы нәтиҗәсе буларак барлыкка килә. Җитештерү чыгымнары дәрәҗәсе күтәрелү сәбәбе, мәсәлән, производство ресурсларына бәя арту булырга мөмкин. Соңгы унъеллыкларда инфляциянең иң зур еллык проценты (25,5%) 1975 елда Бөекбританиядә күзәтелде. Ул 1973 елгы «нефть шогы» (гарәп илләренең Израильгә ярдәм иткән Көнбатыш илләренә нефть сатудан баш тартуы нәтиҗәсендә аның бәясе кискен кыйммәтләнү) нәтиҗәсендә килеп чыкты. Россиялеләр соңгы еллардагы икътисади вазгыять белән яхшы таныш: әгәр дә монополист фирмалар үз тарифларына (электр, газ) бәяләр күтәрелү турында белдерсә, куллану товарларына бәяләр артуын көт тә тор. Нигә шулай килеп чыга соң? Энергоресурслардан файдаланучы җитештерүчеләр, чыгымнары үсешен компенсацияләү һәм табышларын элеккеге дәрәҗәдә саклап калу өчен, үз продукцияләренә бәяләрне күтәрергә мәҗбүр. Ресурс бәяләреннән башка җитештерү чыгымнары дәрәҗәсенә җитештерүгә салымнарның зурлыгы үзгәрү, хезмәт хакының артуы яисә тышкы сәбәпләр, әйтик, су басу, җир тетрәү, социаль тетрәнүләр тәэсир итәргә мөмкин.

Инфляция тулаем икътисадка, халыкның тормыш дәрәҗәсенә нинди йогынты ясый соң? Инфляция — килеп чыккан финанс таркаулыкларына икътисади организмның сәламәт каршы торуы, аны җиңәргә тырышу, товарлар һәм акча арасында тигез нисбәтне сакларга омтылу ул. Шул ук вакытта теория инфляциянең милли керемне һәм милли байлыкны яңадан бүлешү, салым ставкалары системасының бозылуы, хезмәткәрләрнең реаль эш хаклары төшү кебек тискәре нәтиҗәләренә күрсәтә. Инфляция нәтиҗәләре катлаулы һәм күптөрле. Темплары арта барган саен, инфляция икътисад өчен чын-чынлап куркынычка әверелә: саклык акчалары очсызлана, җитештерүчеләрдә сыйфатлы товарлар булдыруга кызыксыну бетә, башлыча керемнәре дәүләт бюджеты исәбенә формалашкан социаль төркем (пенсионерлар, хезмәткәрләр, студентлар һ.б.) вәкилләренең тормыш шартлары начарлана. Мәсәлән, инфляция пенсионерлар өчен һәлакәт булырга мөмкин. Ул аларның гомер буе җыйган саклык акчаларын «ашап бетерә», аларның пенсияләренең сатып алу сәләтен нык киметә. Заемчыларга (мәсәлән, кредит алучыларга) уңай булса да, инфляция кредит бирүчеләрне һәм инвесторларны куркыта. Инфляция югары

булганда, бурычка акча бирергә һәм җитештерүне үстерүгә капитал салырга омтылмыйлар, аларның реаль бәясе төшүдән шикләнәләр.

Инфляция белән идарә итү һәм аны төшерү өчен көрәш максатында, дәүләткә инфляциягә каршы сәясәт эшләргә туры килә. Бер үк вакытта инфляциянең күп факторлы характерын да исәпкә алырга туры килә. Инфляциягә каршы стратегиянең мөһим компоненты булып озак вакытка исәпләнгән акча сәясәте тора. Аның үзенчәлеге — акча массасының еллык артуына катгый чикләүләр кертү. Тагын бер стратегик бурыч — бюджет дефицитын кыскарту, ә киләчәктә аны бөтенләй бетерү. Аны хәл итүгә ике юл белән хәрәкәт итеп була — керемнәрне арттыру һәм дәүләт чыгымнарын киметү.

Дәүләтнең инфляциягә каршы чаралар комплексы түбәндәгеләрне эченә алырга мөмкин: җитештерүне тотрыклыландыру һәм кызыксындыру, салым системасын камилләштерү, бәяләрне һәм керемнәрне җайга салу чаралары.

ГАМӘЛИ ЙОМГАКЛАР

1 Төрле дәүләт һәм хосусый финанс институтларының эшләү үзенчәлекләре турында белемнәрегезне киңәйтергә тырышыгыз. Бу сезгә алар хезмәтеннән рациональ файдаланырга һәм әлеге учреждениеләр белән финанс мөнәсәбәтләрен икътисади яктан оста рәсмиләштерергә ярдәм итәр.

2 Икътисадта бу вакыт аралыгында инфляция төрләрен һәм сәбәпләрен билгеләргә кирәк. Бәяләр үсүнең сәбәпләрен һәм характерын (көтелгән, көтелмәгән) аңлап куллану һәм алмашу процессында үз-үзегезне рациональ тоту алымнарын эшләргә мөмкинлек бирер.

3 Инфляция арту шартларында булган саклык акчаларыгызны саклап калу яисә аларның бәясен арттыруның мөмкин булган ысулларыннан файдаланыгыз. Ул банкта счет ачу да, кредитка озак вакытка исәпләнгән товарлар алу да, мөлкәтне, сәламәтлекне иминиятләштерү һ.б. да булырга мөмкин.

4 Ирекле акчаларны банкта урнаштыру турында карар кабул итү өчен аларны саклау шартларын (ышанычлылык, кертем буенча ставка, кертемне иминиятләштерү мөмкинлеге һ.б.) анализлау зарур. Бу исә югалту куркынычын булдырмаска, кертемнәрегезне саклап калырга һәм арттырырга мөмкинлек бирер.

ДОКУМЕНТ

Классик политэкономиягә нигез салучы, XVIII йөз инглиз икътисадчысы ***У.Петтиның*** «Салымнар һәм җыемнар турында трактат» дигән хезмәтеннән.

Мин Европаның төрле илләрендә күзәткән акча җыеп алуның кайбер алымнарын санап үтәм.

Беренчедән, кайбер урыннарда дәүләт барлык акчалар иясә аларның күпчелек өлеше өчен уртак кассир булып тора, бу банклар булган урыннардагы кебек, аның кулына тапшырылган барлык акчадан үз файдасына процент алу.

Икенчедән, кайчакта дәүләт уртак кредитор булып тора: бу ссуда банклары һәм ломбардлар булган урындагы кебек.

Өченчедән, кайчакта дәүләт ... дошман гамәле, һава торышы, диңгез ... нәтиҗәсе булган бәхетсезлек очрагыннан ... уртак иминиятче булып тора.

Дүртенчедән, кайчакта дәүләт билгеле бер товарлар сатуга һәм шуның белән бәйле файда алуга фәкать аныкы гына булган хокукка ия.

...Кайбер илләрдә дәүләт уен йортлары һәм күңел ачу предприятиеләре оештыра һәм тота, актерларга эш хакы түли һәм табышның төп массасын үзендә тотып кала.

Кайбер илләрдә дәүләт йортларны янгыннан иминиятләштерә, ел саен һәр йорттан зур булмаган рента ала.

...Кайбер илләрдә дәүләт исәбенә төзелгән һәм тотылучы күперләрдән, буалардан һәм паромнардан файдаланган өчен акча алына.

...Хәзерге вакытта халык мөлкәтенең мәгълүм бер өлешен, мәсәлән, аларның күчемсез мөлкәтенең, хәтта эш вазифалары һәм һөнәрләренең бишенче яки егерменче өлешен алу юлы белән салым салу ысуллары кулланылды.

Документка сораулар һәм биремнәр

1. Дәүләт тарафыннан акча алуның документ авторы язган ысулларын күрсәтегез. Алар финанс мөнәсәбәтләренең кайсы даирәләрен характерлый? Хәзерге заман дәүләтенә мондый мөнәсәбәтләр хасмы? **2.** Автор дәүләт һәм гражданнар арасында финанс арадашчыларын атый. Акчаны яңадан бүлешкәндә аларның функциясе һәм роленә бәя бирегез. **3.** Документка һәм җәмгыять белеме курсына таянып, дәүләтнең ничек итеп «уртак кассир», «уртак

кредитор» һәм «уртак иминиятләштерүче» ролен башкара алуын аңлатып бирегез. Хәзерге заман җәмгыятенең нинди финанс институтлары дәүләткә бу функцияләрне тормышка ашыруда ярдәм итә?

ҮЗ-ҮЗЕҢНЕ ТИКШЕРҮ ӨЧЕН СОРАУЛАР

1. Финанслар икътисадта нинди роль башкара? **2.** Илнең банк системасы ничек төзелгән? **3.** Коммерция банклары нигә кирәк? **4.** Төрле финанс институтлары кемгә хезмәт күрсәтә? **5.** Инфляция нилектән килеп чыга? **6.** Инфляция икътисадка уңай тәэсир итә аламы? **7.** Инфляциянең социаль-икътисади нәтиҗәләре нинди? **8.** Инфляциягә каршы көрәшергә кирәкме?

БИРЕМНӘР

1. Үз саклык акчаларыңны урнаштыру өчен банк сайлаганда нәрсәләрне истә тотарга кирәк? Банкларның кертемнәр буенча процентлар түләү өчен кайдан акча алуын аңлатыгыз.

2. «Акчалар элеккедән күбрәк агып килә башлаган һәр корольлектә барысы да яңара: хезмәт һәм сәнәгать җанлана, сәүдәгәр эшлеклерәк була... Башта бернинди дә үзгәрешләр булмый. Аннары бәяләр үсә башлый: элек бер товарга, соңрак — икенчесенә, ахыр килеп барлык товарларның да бәяләре корольлектә булган металл акчалар санына пропорциональ үскәнчегә кадәр».

XVIII гасыр инглиз философы һәм икътисадчысы Д.Юм (1711–1776) акча дөньясындагы нинди процесс турында яза? Ни өчен күп кенә хәзерге икътисадчылар соңгы 30 елда цивилизацияле илләр «инфляция гасырына» керделәр дип саный? Дәүләт илдәге инфляция дәрәҗәсенә ничек йогынты ясый ала? Озакка сузылган инфляциянең икътисад өчен нәтиҗәләре нинди?

3. Газета һәм журнал материаллары буенча банклар, иминиятләштерү компанияләре һәм башка финанс арадашчылары рекламасы белән танышыгыз. Алар нәрсә рекламалый? Нинди хезмәтләр тәкъдим итә? Аларның клиентлары кемнәр һәм нинди шартларда була ала?

4. «Дәвамлы инфляция ярдәмендә хөкүмәт (яшерен һәм сиздермичә) үз гражданнары муллыгының байтак өлешен конфискацияли ала» дип саный инглиз икътисадчы галиме Дж.Кейнс.

Бу фикергә сез ничек карыйсыз? Мондый конфискациянең ничек булуын аңлатыгыз. Инфляциядән кем оттыра һәм кем ота? Үз керемнәреңне ничек якларга?

ЗИРӘКЛӘР ФИКЕРЕ

«Акча ул тирес кебек: таратмасаң, бернинди файдасы да юк».

Ф.Хайек (1899–1992). Австрия икътисадчысы, сәясәт белгече

§ 9. Мәшгульлек һәм эшсезлек

Хезмәт базарында эш бирүченең һәм ялланган хезмәткәрнең мәнфәгатьләре туры киләме? Эшсезлек: базар икътисады өчен явызлыкмы яисә игелекме? Дәүләт эшсезлекне бетерә аламы? Ничек итеп эшсез калмаска?

Сез инде базар, аның төп структуралары һәм эшләү законнары белән таныштыгыз. Төрле базарларның механизмнары төрлечә буламы? Базар механизмы товарга сорау һәм тәкъдим тигезлеге урнаштыру аша нинди икътисади проблемаларны хәл итәргә сәләтле? Әлеге механизмның хезмәт базарындагы гамәлен карап бу сорауларга җавап бирик.

ХЕЗМӘТ БАЗАРЫ

Хезмәт базары — җитештерү факторларының (ресурсларының) иң мөһим базарларыннан берсе. Исегезгә төшерик: җитештерү факторларының төп төрләре булып хезмәт, җир һәм капитал тора. Җир базарында сату-алу объекты җир кишәрлегеннән гыйбарәт, ә капитал базарында — производство биналары, станоклар, җиһазлар, ягъни җирле капитал. Җитештерү факторы буларак хезмәт икътисади муллык булдыру процессында кулланылучы физик һәм акыл сәләтләре булган кешеләрне эченә ала. Әмма базар икътисады шартларында шәхси юридик ирекка ия булган хезмәткәрнең үзе кебек үк, аның сәләтләре дә үзләре генә сатыла алмый. Хезмәт базарында нәрсә сатыла һәм сатып алына соң?

Бу сорауга җавап бирер өчен җитештерү факторларының һәм алар күрсәтә торган хезмәтләрнең үзләрен аерып карарга кирәк. Барлык җитештерү факторлары да сатылмый, ягъни үз милекчеләрен бөтенләй алыштырмый. Аларның үз милекчеләрен билгеле бер вакытка алыштыру очраклары бар, ул чакта әлеге факторларның хезмәтләре сатыла. Мәсәлән, җир хезмәтләре базарында җир кишәрлеге төгәл бер вакытка арендага

бирелә, ә хезмәт күрсәтү базарында хезмәткәр алдан сөйләшенгән вакыт дәвамында яллана. Шулай итеп, хезмәт күрсәтү базарында икътисади муллыкның аерым бер төрен булдыру өчен беркадәр вакытка хезмәткәрнең сәләтеннән файдалану хокукын сатып алырга мөмкин.

Житештерү факторлары базары башка базарлардан, әйтик, товарлар һәм хезмәт күрсәтү базарыннан аерыла. Төп аерма шунда ки: бу базар — икенчел, беренчедән килеп чыга торган. Әлеге базарларда сорау һәм тәкъдим бу факторлар ярдәмендә житештерелүче товарларга сорау һәм тәкъдим белән билгеләнә. Мәсәлән, әгәр кайсыдыр бер шәһәрдә пиццага ихтыяж артса, пиццерия хуҗасы, үсә барган сорауны канәгатьләндерү өчен, өстәмә хезмәткәрләр яллый. Факторлар базарының икенче бер үзенчәлеге булып аның әлеге фактор җитештерүчәнлеге үсешенә бәйлелеге тора. Әйтик, әгәр без җирне яхшы ашласак, уңыш артачак, һәм без кечерәк мәйданнарда чәчәбез. Хезмәт базарында да шулай. Пиццерия хуҗасы, сорау арту сәбәпле, камыр басу машинасы сатып алса, камырны кулдан изгән хезмәткәрләрнең бер өлешен кыскарта ала.

Хезмәт базары икътисадның состав өлеше, аның төп элементларының берсе булып тора. Аның аркасында кешеләрнең күпчелеге, хезмәт күрсәтүләр рәвешендә үз сәләтләрен, күнекмәләрен һәм тәҗрибәләрен сатып, керем алалар.

Хезмәт базары — базарның фирмаларга кешеләр тарафыннан эш хакына һәм башка файдага күрсәтелүче хезмәтләргә ихтыяҗларын канәгатьләндерергә мөмкинлек бирүче социаль-хезмәт мөнәсәбәтләре системасын характерлаучы төре. Хезмәт базарында төп катнашучылар — ялланган хезмәткәрләр һәм эш бирүчеләр. Алар сорау һәм тәкъдим нигезендә алмашу аша үзара хезмәттәшлекне тормышка ашыра. Хезмәт күрсәтүгә сорауны эшмәкәрләр куя (алар сатып алучы буларак катнаша), ә ялланган хезмәткәрләр үз хезмәтләрен тәкъдим итә (алар — сатучы).

Хезмәт базарында хезмәт күрсәтүнең төре һәм катлаулылыгы буенча күп төрләре үз бәясен ала, хезмәткәрне яллау шартлары, шул исәптән эш хакының зурлыгы, эш шартлары, белем алу, һөнәри үсү мөмкинлеге, мәшгульлек гарантиясе билгеләнә.

Шулай итеп, без хезмәт базарында нәрсә сатылуын һәм сатып алынуын белдек. Ә базар үзе ничек эшли соң, аның төп механизмнары: сорау, тәкъдим, базар бәясе (тиң булырлык) кую ничек формалаша һәм үзара йогынты ясаша?

Хезмәт базарында төп этәргечләр сыйфатында сорау һәм тәкъдим буенча конкуренция, хезмәт бәясе катнаша. Хезмәт

күрсәтүләр бәясе ролен хезмәт хакы башкара. Исегезгә төшерәбез, **хезмәт хакы** — ялланган хезмәткәрләрне аларның эше өчен матди бүләкләү рәвеше ул. Аның зурлыгы *хезмәт хакы ставкасына* — хезмәткәргә билгеле бер вакыт дәвамындагы эше өчен *(вакытка карап түләү)* яисә билгеле бер эш күләме башкарган өчен *(эш башыннан түләү)* түләнүче бәягә бәйле. Планлы, үзәкләштерелгән икътисадлы илләрдә хезмәт хакы ставкалары хөкүмәт тарафыннан билгеләнә; базар икътисадлы илләрдә фирмалар эш хакын җайга салуның, түләүне шартнамәчел нигездә формалаштыруның киңрәк мөмкинлекләренә ия.

Хезмәт базарында сорау һәм тәкъдимнең үзара йогынтысы базар процессларының уртак закончалыкларына буйсына, сез алар белән «Икътисадта базар мөнәсәбәтләре» дигән 3 нче параграф материаллары буенча таныш. Хезмәт базарында сорау да, тәкъдим дә, белгәнегезчә, анык факторлар тәэсирендә була.

Әйтик, сорауның зурлыгы (сизелерлек дәрәҗәдә) кулланучыларның чыгарылучы товар һәм күрсәтелүче хезмәтләргә соравы, аларга бәяләр, хезмәт хакы ставкалары, эшнең сыйфаты, хезмәт җитештерүчәнлеге, кулланылучы технология, илдәге тулаем икътисади вазгыять һ.б. факторлардан тора. Хезмәт базарында сорау эшчеләр риза булган эш хакы ставкасына кире бәйлелектә. Мәсәлән, әгәр югары хезмәт хакы җитештерү чыгымнарын арттыра һәм шуның белән табышны киметә икән, эшмәкәрләр хезмәткә сорауны төшерергә мәҗбүр. Әгәр эшмәкәр яисә дәүләт, үзенең монополиячел хокукыннан файдаланып, хезмәт хакы күләмен киметсә, хезмәт дефициты күзәтелә һәм аңа сорау арта.

Индивидуаль хезмәт яисә теге яки бу эшне башкарырга әзер аерым бер кеше хезмәте тәкъдиме түбәндәге факторлар: хезмәт хакы дәрәҗәсе, гаилә муллыгы торышы, хезмәтнең иҗтимагый дәрәҗәсе, эшнең катлаулылыгы, хезмәткәрнең буш вакытка ихтыяҗы йогынтысында үзгәрә. Әгәр кешегә акча бик кирәк икән (әйтик, ул кредитка машина алган), ул күбрәк эшләячәк. Ләкин кредитны түләп бетергәч һәм аның тормышы гадәти эзенә кайткач, ул эш сәгатьләрен кыскартачак һәм буш вакытыннан башкача файдаланачак, чөнки эштән гайре аның башка социаль-мәдәни ихтыяҗлары да бар, ә тәүлектә 24 сәгать кенә. Хезмәт базарында тәкъдим хезмәт хакы ставкасына турыдан-туры бәйле. Эш хакының югары дәрәҗәсен билгеләп, эшмәкәр хезмәт тәкъдимен арттыра, ягъни югары түләүле эш урыны өчен берничә хезмәткәр көрәшә. Нәтиҗәдә хезмәт тәкъдиме сораудан артып китә һәм аның кирәгеннән артык булуы күзәтелә.

Хезмәт базарында тигезлек хезмәткәрләрнең үз хезмәтен сатарга әзер булган хезмәт хакы ставкасы белән эш бирүчеләрнең шул ук сандагы хезмәтне сатып алырга риза булган ставкасы туры килгәндә күзәтелә. Бу — идеаль вазгыять. Чынлыкта исә базар формалаштырган эш хакы товар бәясе кебек үк үзгәреп тора, хезмәт дефицитын яисә хезмәтнең артык булуын китереп чыгара. Эш хакының тигезлек хәленнән тайпылуы товарлар базарындагы вазгыять үзгәрү нәтиҗәсендә (товарга бәя күтәрелү җитештерүчегә күбрәк табыш алырга һәм хезмәткәрләргә зуррак эш хакы тәкъдим итәргә мөмкинлек бирә, ә продукциянең бәясе төшү — киресенчә), яхшырак эш шартлары тәкъдим ителүче яңа тармаклар барлыкка килгәнлектән була.

Дәүләт статистика комитеты мәгълүматлары буенча, 2003 елда уртача россияле айга 5546 сум хезмәт хакы ала. Шул ук вакытта иң зур эш хакы нефть һәм газ сәнәгате хезмәткәрләрендә була (27 мең сум тирәсе), банк хезмәткәре ике тапкыр кимрәк ала, шахтер айга якынча 8 мең сум эшли. Бер үк вакытта табиб, педагог, сатучы уртача 3 мең сум ала, ә авыл хезмәтчәннәренең эш хакы 2 мең сумнан аз гына күбрәк була. (Уйлап карагыз: төрле һөнәр ияләренең эш хакы күләме нәрсәгә бәйле?)

Монда хезмәт базарының тагын бер үзенчәлеген билгеләп үтү зарур — анда товарның бәясе төшү чиге куелган, ягъни ул тагын да түбәнрәк тора алмаучы минималь бәя бар,— ул эш хакының минималь күләме. Соңгысы **яшәү минимумы** — кешенең төп яшәү ихтыяҗларын канәгатьләндерү өчен кирәк булган керем дәрәҗәсе белән билгеләнә. Яшәү минимумы туклануга, кием-салымга, торакка, минималь социаль-сәяси ихтыяҗларны канәгатьләндерүгә киткән чыгымнарны эченә ала.

Күп илләр, шул исәптән Россия дә, хезмәт өчен түләүнең минималь күләмен һәм аның барлык эш бирүчеләр өчен мәҗбүри булуын законнар белән билгели. Бу хәерчелекне бетерү һәм барлык эш белән мәшгуль кешеләргә әлеге җәмгыятьтә кабул ителерлек тормыш дәрәҗәсен тәэмин итү өчен кирәк. Әмма Россиядә хәзерге икътисади вазгыять шартларында (инфляциянең яшәп килгән дәрәҗәсендә җитештерү темпларының төшүе) минималь эш хакы яшәү минимумыннан түбәнрәк булды. Мәсәлән, 2002 елның маенда, яшәү минимумының зурлыгы 1577 сум булганда, минималь эш хакы 450 сум күләмендә билгеләнде, ә 2003 елның октябрендә яшәү минимумы 2137 сум булганда — ул 600 сум иде. Күргәнебезчә, минималь эш хакы 3,5 тапкыр кимрәк булды. Базар механизмы гамәлләре, икътисади үсеш, шулай ук ярлылыкка каршы

Россия хөкүмәте алган курс бу тигезсезлекне акрынлап бетерергә мөмкинлек бирә.

Хезмәт хакы зурлыгыннан тыш, төрле илләрдә хезмәт базарында сорау һәм тәкъдимгә түбәндәге факторлар йогынты ясый: хезмәт ресурсларының мобильлеге — кешеләрнең эш алыштыру мөмкинлеге һәм бу мөмкинлектән файдалану; хезмәт даирәсендә җенесе, яше, милләте, инанулары буенча дискриминация; ялланган хезмәткәр хокукларын яклау, хезмәт шартларын яхшырту һәм аның өчен түләүне арттыру буенча һөнәр берлекләре ярдәме.

ЭШСЕЗЛЕКНЕҢ СӘБӘПЛӘРЕ ҺӘМ ТӨРЛӘРЕ

Хезмәт базарының мөһим функциясе — хезмәт ресурсларын иҗтимагый җитештерү даирәләре һәм тармаклары буенча бүлү һәм яңадан бүлү. Хезмәткә сорау һәм аны тәкъдим итү нисбәте буларак, хезмәт базары халыкның мәшгульлеге үсешендәге тенденцияне чагылдыра.

Мәшгульлек — гражданнарның шәхси һәм иҗтимагый ихтыяҗларын канәгатьләндерү белән бәйле, законнарга каршы килмәүче һәм, кагыйдә буларак, керем китерүче эшчәнлеге ул. Россия өчен барча халыкның да, аның аерым бер төркемнәренең дә (беренче чиратта хатын-кызларның) озак еллар буе формалашкан кирәгеннән артык мәшгульлеге (хезмәт эшчәнлегендә гомуми, мәҗбүри катнашу) үзенә күрә бер үзенчәлек булып торды. Социализмның лозунгы — «Кем эшләми, шул ашамый» иде.

Базар мөнәсәбәтләренә күчү, хезмәт базары, хосусый эшмәкәрлек барлыкка килү дәүләтнең хезмәттән файдалануга һәм эш бирүгә монополь хокукыннан баш тартуын белдерде. Хезмәт иреге мәшгульлек өлкәсендә базар мөнәсәбәтләрен үстерүнең төп шартына әверелде, эшләү ихтыярый характер, ә кеше исә икътисади ирек алды. Шул ук вакытта мәшгульлек, без инде карап узганча, базар законнары белән билгеләнә башлады. Хәзер хезмәткә сәләтле кеше һәрвакытта да эш таба алмый, ә бу мәшгульлек белән бәйле эшсезлек кебек күренешкә китерде.

Хезмәт ресурсларыннан файдалануның нәтиҗәлелеге җәмгыятьтә эшсезлек дәрәҗәсе белән бәяләнә. **Эшсезлек** — эшләргә теләгән икътисади актив халыкның бер өлеше эш таба алмауда чагылучы социаль-икътисади күренеш. Икътисади актив кешеләргә хезмәт активлыгы күрсәтүче (хезмәт тәкъдимен тәэмин итүче) гражданнар керә, монда эшләүчеләр дә, эшсезләр дә санала. Мәсәлән, Россия дәүләт статистика комитеты мәгъ-

луматлары буенча 2000 елда Россия Федерациясенең икътисади актив халкы 71,5 миллион кеше (барлык халыкның 50%ыннан кимрәк) булды, аларның 90,2% ы халык хуҗалыгында эшли иде, ә 9,8% ы эшсез булды. Бу күрсәткеч эшсезлекнең табигый нормасы дәрәҗәсеннән югарырак, икътисади яктан нык үскән илләрдә ул 5–6% тәшкил итә. (Тарихтан моның икътисадтагы, аерым алганда җитештерүдәге нинди процесслар белән бәйле булырга мөмкин икәнлеген исегезгә төшерегез.)

Икътисадчылар билгеләп үткәнчә, икътисадның төшүе чорында эшсезлек арта, күтәрелеше вакытында — кими. Россия Федерациясендә 1992–1999 елларда эшсезлек дәрәҗәсе 4,7 дән 12,6%ка кадәр үсте, ә 2001–2003 елларда ул 8,9%ка кадәр кимеде.

Базар мөнәсәбәтләре шартларында һәрвакыт эш эзләүче кешеләр бар. Базар икътисадына, гадәттә, эшсезлекнең мәгълүм бер уртача дәрәҗәсе хас, халыкның мәшгульлеге шуның тирәсендә тирбәлә. Әлеге дәрәҗә «табигый» дип атала һәм котылгысыз дип санала. (Моның ни өчен базар икътисадлы барлык илләр өчен характерлы булуы турында уйлагыз. Мәшгульлек һәм эшсезлек дәрәҗәсе икътисадның циклны үсеше белән ничек бәйле?)

Эшсезләргә, кагыйдә буларак, квалификацияләрен, социаль статусларын югалту һәм тормыш дәрәҗәсенең төшүе яный. Эшле булуга ышанычын кем алданрак югалта?

Илнең социологик тикшеренүләре күрсәткәнчә, кагыйдә буларак, бер генә белгечлеккә ия, базар икътисады нигезләрен, яңа һөнәри таләпләрне белмәүче, озак вакытлар үз квалификациясен күтәрмәүче, үзлегеннән белемен арттырмаучы, аралашмаучы кешеләр эшләрен тизрәк югалта һәм озак вакыт яңадан урнаша алмыйча эш эзләп йөри. Тәҗрибә булмау, һөнәрилекнең түбәнлеге, белем дәрәҗәсе җитмәү яшьләрнең эш табу шансларын киметә.

Эшсезлекнең тискәре нәтиҗәләрен бетерү, аның дәрәҗәсен киметү өчен аның килеп чыгу сәбәпләрен, икътисад үсешенә комачаулаучы эшсезлекнең төрен белергә кирәк.

Сәбәпләре буенча эшсезлек фрикцион, структур һәм цикллыга бүленә. Аларны аерым-аерым карап узыйк.

Фрикцион эшсезлек тору урынын алмаштыру, хезмәт законнарының камил булмавы, хезмәткәрләрнең мобильлеге түбән булу, кешеләрнең үзләрен канәгатьләндерүче түләүле эш табу мөмкинлеге турында хәбәрдар булмаулары, эшсезлек буенча пособиенең эш хакы белән чагыштырганда югары дәрәҗәдә булуы аркасында килеп чыга. Һәрвакытта да беркадәр хезмәткәрләр «ике эш арасында» була — берәүләрнең үз һөнәрлә-

реннән көнеле кайткан, икенчеләре яхшырак эш шартлары һәм түләү эзли, өченчеләрен эштән азат иткәннәр. Эшсезлекнең бу төре аның озакка сузылмавы белән үзенчәлекле.

Структур эшсезлек, кагыйдә буларак, фәнни-техник прогресс нәтиҗәсендә аерым тармакларда һәм төбәкләрдә хезмәткә сорау үзгәрү белән бәйле. Эшсезлекнең бу төре житдирәк проблема булып санала, чөнки тотрыклы характерда һәм озакка сузыла. Структур эшсезлек икътисадта структур үзгәрешләр, фәнни-техник прогресс йогынтысы белән бериш тармакларның юкка чыгуы, икенчеләренең барлыкка килүе аркасында килеп чыга. Товарларның күп төрләре бетә, алар белән бергә һөнәрләр дә «үлә». Мәсәлән, хәзер язу машинкалары һәркайда диярлек компьютерлар белән алмаштырылды; димәк, машинистка һөнәре дә, әлеге машинкаларны җитештерү һәм аларны ремонтлау белән шөгыльләнүчеләр дә кирәкми. Яңа технологияләр куллану, җитештерүне автоматлаштыру һәм компьютерлаштыру нәтиҗәсендә эшчеләр саны кими. Шундый үзгәрешләр аркасында кайбер һөнәрләргә сорау кими, ә икенчеләренә, яңаларын да кертеп, арта бара. Хезмәткәр, әгәр аның таләп ителгән һөнәре яисә квалификациясе булмаса, аның тәҗрибәсе искерсә, структур эшсезлек шартларына эләгә. Тагын бер ихтимал сәбәп — халыкара конкуренция. Илнең продукциясен базардан чит ил товарлары кысрыклап чыгарырга мөмкин. Әйтик, Россия базарында чит ил туклану продуктлары, кием-салымы барлыкка килү илебезнең азык-төлек, җиңел сәнәгать предприятиеләрендә хезмәткәрләр санын кыскартуга китерде.

Әгәр икътисадта җитештерү төшә, товар һәм хезмәт күрсәтүләргә базар соравы кискен кими икән, хезмәткәрләрнең бер өлеше җитештерү өлкәсен ташлап китә, ягъни хезмәт ресурслары файдаланып бетерелми. Бу циклы эшсезлекнең үсүенә китерә, икътисадта тәртип җитенкерәмәү күрсәткече булып тора. Тарих дәресләреннән Бөек депрессия чорын (1929–1933) исегезгә төшерегез. Ул чакта Германиядә, АКШта һәм Бөекбританиядә ялланган хезмәткәрләрнең 15 тән алып 25%ына кадәрен циклы эшсезлек чолгап алды.

Циклы эшсезлек — циклы төшү чорында барлыкка килүче һәм циклы күтәрелеш чорында юкка чыгучы яисә кимүче эшсезлек төре. Мондый эшсезлекнең иң зурысы — икътисадның кризис чорына, ә минимумы аның күтәрелешенә туры килә.

Эшсезлекнең структур һәм фрикцион төрләре суммасы аның *табигый дәрәҗәсен* тәшкил итә. Табигый эшсезлек булу — базар икътисады өчен нормаль хәл, чөнки аны китереп чыгаручы сәбәпләр даими булып тора. Бу дәрәҗәдә мәшгульлек

тулы, табигый дип санала. Әмма хезмәт базарын җайга салу һәм эшсезлекнең икътисадка, социаль өлкәгә уңайсыз йогынтысын киметү өчен, дәүләт халыкны мәшгульлеккә кызыксындыру чараларын тормышка ашырырга омтыла.

МӘШГУЛЬЛЕК ӨЛКӘСЕНДӘ ДӘҮЛӘТ СӘЯСӘТЕ

Халыкны эш белән тәэмин итү проблемасы хезмәт базарында дәүләт җайга салуының состав өлеше булып тора. Инфляциягә каршы актив сәясәт һәм мәҗбүри эшсезлеккә каршы тору, хезмәт ресурсларын бүлүдә тигезсезлекне бетерү, аларның нормаль яңарышы өчен шартлар тудыру һәм җәмгыятьтә социаль киеренкелекне йомшарту дәүләт эшчәнлегенең мөһим элементлары була. *Дәүләт мәшгульлек сәясәтенең төп максаты* булып халык мәшгульлеге һәм икътисади тотрыклылык аша предприятиеләрне хезмәткәрләр белән тәэмин итү өчен шартлар булдыру, хезмәткәрләрнең әзерлек сыйфатын һәм конкуренциягә сәләтен күтәрү, кадрларны укыту системасын үстерү, мәшгульлек мәсьәләләре буенча дәүләт органнары гамәлләре тора.

Хезмәт базарының торышы — күптөрле икътисади һәм социаль факторлар йогынтысы нәтиҗәсе. Шуңа күрә мәшгульлек сәясәтенең нәтиҗәлелеге аның гомуми социаль-икътисади сәясәтенең төрле юнәлешләрендә (пенсия, яшьләр, социаль, белем бирү) дәүләт гамәлләренең эффектлылыгыннан тора. Дәүләт *икътисади, административ, законнар белән һәм оештыру ягыннан җайга салу рәвешләрен* куллана. Дәүләтнең шундый гамәлләренә мисаллар: инвестицияләр, салым ташламалары, эшмәкәрлекне үстерү аша эш урыннары җитмәүне бетерү; эш мохитенең сыйфатын яхшырту (эш шартлары, хезмәт хакы, эш урыннарыннан нәтиҗәле файдалану); халыкны социаль яклауны камилләштерү, мәшгульлек мәсьәләләре һәм һөнәри әзерлек системасы буенча дәүләт органнары аша гамәлгә ашырылучы программаларны һәм хезмәт күрсәтүләрне үстерү.

Россия Федерациясе хөкүмәте мәшгульлек сәясәтен «Россия Федерациясендә халыкны эш белән тәэмин итү турында» Закон нигезендә тормышка ашыра. Ул башта Дәүләт мәшгульлек фонды акчаларыннан, ә 2001 елдан — федераль һәм җирле бюджетлардан финансланды. Мәшгульлек сәясәтен тормышка ашыруның төп инструментлары булып халыкара практикага һәм Россия законнарына туры килүче актив һәм пассив ысуллар тора.

Мәшгульлекнең актив сәясәте — эшсезлекне аның минималь (табигый) дәрәҗәсенә кадәр төшерүгә булышлык итүче

чаралар. Нык үскән елларда мондый сәясәтнең төп чаралары булып һөнәри әзерлек һәм кадрларны яңадан әзерләү танылa. Мәшгульлекнең актив сәясәте чараларына түбәндәгеләр керә: хезмәт базары турында мәгълүмат, эшкә урнаштыруда ярдәм, эшсезләрне һөнәри өйрәтү, җәмәгать эшләре һәм яшүсмерләрнең вакытлыча мәшгульлеген оештыру, эшсезләрнең эшмәкәрлек активлыгын һәм мөстәкыйль мәшгульлеген хуплау.

Мәшгульлекнең пассив сәясәте — эшсезлекнең тискәре нәтиҗәләрен киметүгә, эшсезләргә матди ярдәм итүгә һәм мәшгульлек буенча дәүләт органнары аша эш урыны сайлауда иң гади хезмәт күрсәтүгә юнәлтелгән чаралар.

Дәүләт органнары һөнәри юнәлеш бирү һәм халыкка психологик ярдәм үзәкләре, уку-укыту, социаль-эшлекле һәм мәгълүмати-консультатив үзәкләр, яшьләр биржалары һ.б. төзиләр.

Мәшгульлек мәсьәләләре органнары эшчәнлегенең норматив-хокукый нигезләре булып Россия Федерациясе Конституциясе, Россия Федерациясе Хезмәт кодексы, «Россия Федерациясендә халыкны эш белән тәэмин итү турында» Закон, Халыкара хезмәт оешмасы (ХХО) конвенцияләре тәкъдимнәре һ.б. тора.

Хезмәт мөнәсәбәтләрен җайга салуның бөтендөнья тәҗрибәсе күрсәткәнчә, аерым бер хезмәткәр — иң йомшак һәм зыян күрүче объект; законнар аның якланганлыгын югарырак дәрәҗәдә тәэмин итәргә тиеш. Мәшгульлек сәясәтен формалаштыру табигый дәрәҗәдән артып киткән эшсезлекне кисәтү буенча чаралар системасына юнәлтелергә һәм эшен югалткан гражданнарның иң тиз арада мәшгульлек даирәсенә кире кайтуына ярдәм итәргә тиеш.

ГАМӘЛИ ЙОМГАКЛАР

1 Һөнәр сайлаганда һәм квалификацияне күтәрү ысуллaрын билгеләгәндә хәзерге заман мәгълүмати җәмгыятен һәм хезмәткәргә яңа һөнәри таләпләр үзенчәлекләрен белү эшкә урнашканда сезгә зуррак ышанычка ирешергә мөмкинлек бирер. Әйтик, социологик тикшеренүләр күрсәткәнчә, 15 тән 28 яшькәчә яшьләр, бу таләпләргә йөз тотып, югары белем алырга (49,5%), бизнес алымнарына өйрәнергә (28,0%), компьютерда эшләүне үзләштерергә (26,0%), чит тел өйрәнергә (25,0 %), хокукый әзерлек алырга (13,0 %), машина йөртүче таныклыгына ия булырга (9,5%) омтыла.

2 Хезмәт эшчәнлеге даирәсен рациональ сайлау максатларында үзегез сайлаган тармакка туры килүче хезмәт базарындагы вазгыятьне (буш урыннар булу, теге яки бу һөнәрнең популярлыгы, хезмәт өчен түләүнең уртача дәрәҗәсе, квалификациягә таләпләр, эш шартлары һ.б.) күзәтеп барырга тырышыгыз.

3 Базар шартларында сезгә бирелгән икътисади ирекне үзегезнең сәләтегезгә һәм мөмкинлекләрегезгә иң кулай хезмәт кую вариантын сайлаганда файдаланыгыз. Сезнең төбәктәге (шәһәр, район, өлкә) эшкә урнаштыруның һәм яшьләрнең һөнәри үзбилгеләнүенең төбәк үзенчәлекләре белән таныштыруда ярдәм итүче дәүләт органнары эшчәнлеге турында белешегез. Бу исә сезнең шәхси теләкләрегезнең һәм хезмәт базары ихтыяҗлары нигезендә эшчәнлек төрен һәм мәшгульлек рәвешен сайлап алуның нигезлелеген күтәрер.

4 Әгәр сез эшкә урнашканнан соң хезмәтегезнең бәясе сез көткәннән кимрәк булса, бу аерманың икътисади сәбәпләрен анализларга тырышыгыз һәм ул хәлдән чыгуның дөрес вариантын табыгыз: эшчәнлек өлкәсен алыштырыргамы, өстәмә белемнәр һәм күнекмәләр алыргамы һ.б.

5 Хезмәт базарында сорау үзгәрүгә һәм эшегезне алыштыру зарурлыгына әзер булыгыз (мәсәлән, Америка эшчеләре үз гомерләрендә ун һәм аннан да күбрәк тапкыр эш алыштыралар һәм моны рациональ дип саныйлар). Моның өчен үз һөнәрегез буенча берничә янәшә белгечлек үзләштерергә тырышыгыз, хезмәткәргә яңа һөнәри таләпләрне белегез, квалификациягезне күтәрегез һәм үзлегегездән белем алу тәҗрибәсен үстерегез.

ДОКУМЕНТ

Россия икътисадчы галиме ***И.Заславскийның*** «Хәзерге заман Россиясендә хезмәт характеристикасына» дигән хезмәтеннән.

Россиядә социализмдагы хезмәтнең гомуми һәм мәҗбүрилегенә туры килүче иҗтимагый производствода тулы һәм һичсүзсез мәшгульлектән базар икътисады критерийларына җавап бирүче икътисади активлык системасына күчеш тәмамланды. Икътисади актив кешеләрнең яртысыннан күбрәге дәүләт структураларына түгел, үзләренә эшли, хосусый-корпоратив типтагы предприятие һәм оешмаларга

хезмәт куя. Аларның 15% ы кече бизнеста мәшгуль. ХХО методикасы буенча, 9% ы чамасы эшсезләр буларак квалификацияләнә...

Эш белән мәшгульләрне бүлү пропорцияләре исә эш активлыгы базар үзгәртеп корулары белән бәйле рәвештә үскән тармаклар: сәүдә һәм җәмәгать туклануы, матди-техник тәэминат һәм сәүдә арадашчылыгы, кредитлау, финанслар һәм имиңиятләштерү... файдасына үзгәрде. Икътисади актив кешеләрнең гомуми саныннан эшсезләр өлеше күрсәткече буенча безнең ил Бөекбританияне, Германияне, Нидерландны, Швецияне куып җитте диярлек.

Мәшгульлекнең күзгә күренгән метаморфозасы «турыдан-туры иҗтимагый хезмәт» характерындагы һәм эчтәлегендәге үзгәрешләрне чагылдыра. Планлы продукция һәм кушылган сандагы һәм ассортименттагы хезмәт күрсәтүләр җитештерү буенча күмәк-мәҗбүри эшчәнлектән хезмәт икътисади бәйсез товар җитештерүчеләрнең көн күрү ысулына әверелә. Иҗтимагый һәм күмәк хезмәткә алмашка хосусый индивидуаль хезмәт килә.

Милекчелектә революция һәм икътисадта аның юлдашы булган институциональ үзгәрешләр элек дәүләт өчен планлы рәвештә оештырылган һөнәри хезмәт белән шөгыльләнүче миллионлаган кешенең үз көчләрен моңа кадәр әзерләкләнеп килгән эшмәкәрлектә һәм хезмәт, милек, идарә (контроль) бергә кушылган кече бизнеста үз көчләрен һәм сәләтләрен сынап карауга китерә. Хосусый сектордагыларның дүрттән бер өлеше — ялланган хезмәттәге затлар түгел. Алар эшчәнлегендә төрле нисбәтләрдә һөнәри һәм яңача хезмәт, бер үк вакытта башкарма хезмәт белән идарә итү эше бергә үрелеп бара.

Документка сораулар һәм биремнәр

1. Автор Россия җәмгыяте тормышының нинди социаль хезмәт өлкәләре проблемаларын аерып карый? *2.* Иҗтимагый хезмәт эшчәнлегендә һәм характерында, базар үзгәртеп корулары нәтиҗәсендә ялланган хезмәткәр хәлендә булган үзгәрешләрне атагыз. **3.** «Россиядә социализмда хезмәтнең гомуми һәм мәҗбүрилегенә туры килүче иҗтимагый производствода тулы һәм һичсүзсез мәшгульлектән базар икътисады критерийларына җавап бирүче икътисади активлык системасына күчеш тәмамланды» дип раслаганда, И.Заславский нәрсәне күздә тота? Текстка таянып, бу расламага аңлатма табыгыз. **4.** Икътисадта базар мөнә-

сәбәтләре үсеше барышында россиялеләр мәшгульлегенең тармак структурасында нинди үзгәрешләр булды?

ҮЗ-ҮЗЕҢНЕ ТИКШЕРҮ ӨЧЕН СОРАУЛАР

1. Хезмәт базары ни өчен кирәк? **2.** Хезмәт базарында сорау һәм тәкъдим ничек эшли? **3.** Хезмәт базарында нигә тигезлеккә ирешү кыен? **4.** Эшсезлекнең төрле рәвешләре үзенчәлеге нинди? **5.** Халыкны эш белән тәэмин итүне дәүләт ничек җайга сала?

БИРЕМНӘР

1. Планлы (командалы) икътисадта хезмәткә сорау һәм тәкъдим законы эшли аламы? Фикерегезне дәлилләгез.

2. Америка корпорацияләре үз хезмәткәрләрен укытуга ел саен 30 миллиард доллар тота, бу көллиятләр чыгымының өчтән берен тәшкил итә. Ә япон заводларының һәр эшчесе ел саен эштән аерылып 1–3 ай дәвамында киләчәктә производствога кертелергә мөмкин булган техника һәм технология яңалыкларын өйрәнә.

Җитештерү ресурсы буларак, кешегә акча салуның эффектлылыгы нидән гыйбарәт? Россия җәмгыятен реформалау өчен эш бирүчеләрнең мондый сәясәте әһәмиятлеме? Җавабыгызны аңлатыгыз.

3. «Забастовка — хезмәт ияләрен дә, эш бирүчеләрне дә җәрәхәтли торган ике яклы пычак ул»,— дигән әйтемне ничек аңлыйсыз? Забастовкаларның сәбәпләрен һәм нәтиҗәләрен атагыз. Профсоюзлар берлеге һәм эшмәкәрләр мәнфәгатьләре компромиссы булырга мөмкинме?

4. Дәүләт ни өчен хезмәткә түләүнең минималь күләмен билгели? Бу ярлылык чигендә яшәүчеләр санын киметергә ярдәм итәрме? Илдә әлеге социаль проблема белән көрәш буенча тәкъдимнәрегезне формалаштырыгыз.

5. Массакүләм мәгълүмат чараларындагы материалларда икътисадның төрле тармак хезмәткәрләре, шулай ук дәүләти һәм дәүләтнеке булмаган секторлар һөнәрләре хезмәте өчен түләү турында материал табыгыз. Аларның эш хакындагы аерманың сәбәбен күрсәтегез.

6. Таблицада китерелгән мәгълүматны чагыштырыгыз һәм йомгак ясагыз. Теге яки бу һөнәрнең иҗтимагый абруена нинди факторлар йогынты ясавын аңлатыгыз. Россиядә нинди яңа һөнәрләр барлыкка килде һәм бу ни белән бәйле?

Иң популяр һөнәрләр рейтингы

Илләр	*Һөнәрләр*
Россия	1. Сату һәм сатып алулар буенча менеджерлар 2. Программистлар, web-дизайнерлар, телекоммуникация белгечләре 3. Банк хезмәткәрләре, бухгалтерлар 4. Бүлек җитәкчеләре, идарәчеләр 5. Рекламачылар, маркетологлар, бренд-менеджерлар
Германия	1. Табиблар 2. Руханилар 3. Университет укытучылары 4. Адвокатлар 5. Эшмәкәрләр
США	1. Интернет-сайт менеджерлары 2. Статистиклар 3. Компьютер аналитиклары, программ тәэминат өлкәсендә инженерлар, программистлар 4. Математиклар 5. Бухгалтерлар
Яңа Зеландия	1. Суыту җиһазлары механиклары, автомеханиклар 2. Өлкәннәрне караучылар 3. Компьютер техниклары 4. Программистлар

(Вокруг света. 2003. Июнь. 16 б.)

7. Классташларыгыз белән бергә «Эшкә урнашу мәсьәләләре буенча яшьләргә киңәшләр» дигән кулланма эшләгез. Хезмәт базарының төбәк үзенчәлекләрен исәпкә алырга тырышыгыз.

ЗИРӘКЛӘР ФИКЕРЕ

«Конкуренцияле строй — кеше бу дөньяның көчлеләренә түгел, ә үзенә генә бәйле булган һәм аның максатка ирешү омтылышларына берәү дә комачаулый алмый торган бердәнбер строй».

Ф.Хайек (1899–1992), Австрия икътисадчысы, политолог

§ 10. Дөнья икътисады

Илләр нигә сәүдә итә? Бер-береңнән койма белән бүленеп буламы? Глобальләшү процессының уңай һәм тискәре яклары нинди?

Без әлегәчә милли икътисадны карадык һәм тышкы дөнья белән элемтәләр турында берни дә сөйләмәдек. Әмма безнең тормышта мондый бәйләнешләр бик күп. Без кибеткә барабыз һәм анда үз илебезнеке белән беррәттән төрле илләрдән бик күп товарлар күрәбез. Фирмаларда, оешмаларда һәм күбебезнең өйләрендә чит ил компьютерлары, төрле илләрдән кайтарылган җиһазлар һәм көнкүреш техникасы бар. Россия кешеләре чит илләргә эшләргә яки укырга бара, ә башка илләрдән, киресенчә, укырга һәм эшләргә дип, Россиягә киләләр.

Болар барысы да төрле илләрнең бөтендөнья хуҗалыгы кысаларында бер-берсенә бәйлелеге хакында сөйли.

НӘРСӘ УЛ ДӨНЬЯ ИКЪТИСАДЫ?

Дөнья икътисады — халыкара икътисади мөнәсәбәтләр белән үзара бәйләнгән аерым илләр икътисадлары җыелмасы ул.

Нинди мөнәсәбәтләр күз алдында тотыла соң? Барыннан да элек — халыкара эш бүлешү, ул товарлар һәм хезмәт күрсәтүләр белән халыкара сәүдәнең нигезен тәшкил итә, капитал һәм эш көченең халыкара хәрәкәте, валюта мөнәсәбәтләре. Күп кенә илләр, гомумән, блокларга берләште һәм товар, капитал һәм эш көче хәрәкәте юлында барлык киртәләрне диярлек алып ташлады. Әлеге күренеш «интеграция» дигән исем алды. Әмма дөнья икътисадындагы барлык бу процессларның башлангычы — халыкара эш бүлешү.

Халыкара эш бүлешү — илләрнең теге яки бу продукция җитештерүдә махсуслашуы ул. Махсуслашуның алшартлары булып түбәндәгеләр тора:

1. Илнең табигать шартлары — климаты, географик торышы, файдалы казылмалар һәм башка табигать ресурсларының булуы. Мәсәлән, теге яки бу файдалы казылмалары булган илләр (географиядән файдалы казылмаларның урнашуын исегезгә төшерегез) аларны әлеге казылмалары булмаган илләргә саталар, ә алмашка үзләре җитештермәгән продукцияне сатып алалар.

2. Икътисади һәм фәнни-техник үсеш дәрәҗәсе. Икътисади күтәрелеш турындагы бүлектән сез инде илләрнең тигез үсмәвен

беләсез. Икътисади яктан нык үскән илләр, кагыйдә буларак — әзер эшләнмәләр җитештерү буенча, ә үсеп килүче илләр чимал җитештерүдә махсуслаша.

3. Теге яки бу товар җитештерүдә урнашкан традицияләр. (Мәсәлән, Франция — үзенең косметикасы белән, ә Бразилия кофесы белән данлыклы.

ХАЛЫКАРА СӘҮДӘ

Әгәр халыкара эш бүлешү бар икән, димәк, халыкара сәүдә дә яшәп килә. Ил нинди генә зур булса да, үзенә кирәкле барлык товарларны да җитештерә алмый. Шулай да эре һәм бай илләр кирәкле уңайлыклар белән үзләрен яхшырак тәэмин итә ала. Шуның өстенә, әгәр ул илдә халык саны да зур булса, аның эчке базары гаять зур һәм башка илләргә чыгарырга кирәк булган артык товарлар азрак кала дигән сүз.

Халыкара сәүдәнең төп терминнары — экспорт, импорт һәм сәүдә балансы сальдосы.

Экспорт — дөнья базарында сату максатында чит илләргә чыгарылучы товар һәм хезмәт күрсәтүләр.

Импорт — эчке базарда сату максаты белән илгә кертелүче товарлар һәм хезмәт күрсәтүләр.

Сәүдә балансы сальдосы — билгеле бер чорга экспорт һәм импорт бәяләре арасындагы аерма. Мәсәлән, АКШ — дөньядагы иң бай һәм нык үскән ил — сәүдә балансының даими тискәре сальдосына ия, ягъни АКШта импорт экспорттан сизелерлек күбрәк. Россия, киресенчә, товарны керткәнгә караганда күбрәк чыгара, яисә аның сәүдә сальдосы уңай.

Халыкара сәүдәнең тарихы бик борынгыдан килә. Ул илләр арасындагы икътисади мөнәсәбәтләрнең беренче формасы. Сез тарих фәненнән белгәнчә, XVII—XVIII гасырларда иң зур сәүдә державасы Нидерланд була, аңардан соң — Бөекбритания.

XVII йөздә үк икътисадчы галимнәр «Нигә илләр бер-берсе белән сәүдә итә?» дигән сорау белән кызыксына. Ул вакытта алар тышкы сәүдә алтынны гәүдәләндергән байлык булдыра дип уйлыйлар һәм хөкүмәтләрне ил өчен күбрәк алтын керсен дип күбрәк товар чыгарырга, ә алтынның читкә китүен булдырмастан, әзрәк товар кертергә чакыралар.

Әмма сәнәгать революциясе булган һәм төрле мануфактуралар, фабрикалар үсеш ала башлаган XVIII гасырда ук сәүдәгә караш үзгәрә. Шотландия галиме Адам Смит «күп күләмдә алтынга ия буларак, байлык турында»гы идеяне тәнкыйтьли һәм «как государство богатеет, и чем живет, и почему не нужно

золота ему, когда простой продукт имеет» *(А.С. Пушкин)* — гади продуктлар булганда дәүләткә алтын кирәк булмавын күрсәтә.

А.Смит эш бүленешен югары бәяли һәм теләсә кайсы ил гражданы өчен чит ил товарларын сатып алу, бигрәк тә әгәр алар арзанрак булсалар, отышлы дип саный. Галим тышкы сәүдәдә абсолют өстенлек теориясен эшли, аның асылы шунда ки: бериш илләр товарларны икенчеләренә караганда нәтиҗәлерәк җитештерә ала, ди ул; шуңа да башка илләр белән ирекле сәүдәдә абсолют өстенлеккә ия. Россия, мәсәлән, газ буенча абсолют өстенлеккә ия, чөнки ул аны башкаларның барысыннан да күбрәк җитештерә. Безнең ил газны Европаның нык үскән илләренә җиһазларга алыштыру бәрабәренә җибәрә, чөнки соңгысын җитештерү бездә начаррак бара.

XVIII гасырда Англиянең башка бер икътисадчысы Давид Рикардо *тышкы сәүдәдә чагыштырмача өстенлек теориясен* эшли. Аның асылы шунда: ил уртача чыгымнары шундый ук товарны башка илдә җитештергәндәгедән чагыштырмача кимрәк булган товарлар чыгару буенча махсуслашырга тиеш. Д.Рикардо мисал сыйфатында Англия белән Португалия арасында постау белән (исегездәме, Англия ул чакта «дөнья остаханәсе» була) шәраб алмашуны китерә, чөнки Португалия Англиядән көньяктарак, һәм анда йөзем үстерү өчен шартлар уңайрак.

Хәзерге вакытта барлык илләр диярлек дөнья сәүдәсенә җәлеп ителгән. Әмма аерым илләрнең дөнья экспорты һәм импортындагы чагыштырма нисбәте нык аерыла. 2000 елда алдынгы илләрнең дөнья сәүдәсендәге өлеше экспорт буенча 72%, ә импорт буенча 75,8% булды.

Дөнья экспортында һәм импортында иң зур өлеш АКШка туры килә — тиңдәшле рәвештә 13 һәм 20,3%; икенче урында Германия — 8,9 һәм 8,1%; өченчедә — Япония — 8,0 һәм 6,1%. Россия өлеше бик тыйнак: дөнья экспортында — 1,7%, ә дөнья импортында — 0,5%.

Ә хәзер Россия тышкы сәүдәсенең нидән торуын карыйк. Россия экспортының үзенчәлеге аның иң зур өлешен ягулык-энергетика чималы һәм җир астыннан чыгару сәнәгате продукциясе тәшкил итүеннән гыйбарәт. 2001 елда бу продукция экспортына 60,4% туры килде, ә эшкәртүче сәнәгать продукциясе (мәсәлән, машина төзелеше, приборлар ясау һ.б.) өлеше 37,8% булды; авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек сәнәгатенеке 1,8 процент тәшкил итте. 2001 елда импорт буенча беренче урынны машиналар һәм җиһазлар алды — 34,1%, икенче урында куллану товарлары — 33,2%, өченчедә исә авыл хуҗалыгы продукциясе һәм азык-төлек булды — 22%.

Хәзерге Россиянең төп партнерлары: экспорт буенча — Германия (9,3%), Италия (7,5%), Кытай (5,6%), Украина һәм Белоруссия (5,3 әр процент); импорт буенча — Германия (13,9%), Белоруссия (9,5%), Украина (9,2%), АКШ (7,7%), Казакъстан (4,8%).

Дәүләт өчен тышкы сәүдә отышлымы? Бер яктан караганда, җавап уңай — әйе, отышлы, чөнки кулланучы түбәнрәк бәяләрдән югары сыйфатлы товар ала. Ләкин, икенче яктан, безнең ил җитештерүчеләре товары конкуренциягә түзә алмый; сорау булмагач, аларны җитештерү кими, кешеләр эш хакын югалта, димәк, түләү сәләте дә төшә. Тышкы сәүдәнең тискәре күренешләре шул.

Бу хәлдән чыгуда халыкара сәүдә өлкәсендә дәүләт сәясәте ярдәм итә.

ХАЛЫКАРА СӘҮДӘ ӨЛКӘСЕНДӘ ДӘҮЛӘТ СӘЯСӘТЕ

Халыкара сәүдәдә менә берничә гасыр инде бер-берсенә бәйле ике тенденция яисә дәүләтнең ике икътисади сәясәте яшәп килә. Болар — протекционизм һәм ирекле сәүдә (фритредерлык).

Протекционизм (лат. *protectio* — «каплап тору») — дәүләтнең эчке җитештерүчеләр мәнфәгатьләрен чит ил конкурентларыннан яклауга юнәлтелгән сәясәте ул.

Ирекле сәүдә — халыкара сәүдәнең ирекле үсешенә йөз тоткан дәүләт сәясәте.

Протекционизм бик күптәннән, XVII—XVIII гасырларда ук барлыкка килгән һәм илгә кертелүе бик кирәкле булмаган товарларга дәүләт тарафыннан импорт пошлиналары урнаштырылуда чагылган. Пошлина товар бәясенең билгеле бер процентын тәшкил иткән, импорт товарын шактый кыйммәтләндергән һәм ул җирле товарлар белән чагыштырганда конкуренциягә әзрәк сәләтлегә әверелгән. Россиядә таможня тарифлары беренче тапкыр Петр I тарафыннан кертелә.

Англиядә ирекле сәүдә сәясәте XIX гасыр уртасында кулланыла башлый. Тик ул Икенче бөтендөнья сугышыннан соң, ягъни XX гасыр уртасыннан гына киң таралды.

Хәзерге вакытта бу сәясәт ирекле сәүдәнең либеральләшуында, күп кенә илләрнең ачык икътисадка күчүендә чагылыш тапты. Әмма ирекле сәүдә сәясәтенең үз уңай һәм тискәре яклары бар.

Уңай якларга барыннан да элек милли базарны арзанлы һәм югары сыйфатлы товарларга баетуны кертергә кирәк. Димәк, халык дөнья базарының отышлы бәяләре буенча күбрәк

товар алырга мөмкин. Дәүләт чит ил компанияләреннән ил чикләре аша товар йөрткән өчен һәм үз гражданнарыннан бу товарларны күбрәк сатып алган өчен күбрәк салым җыячак. Моннан тыш чит ил фирмалары башка илләрдә үз товарларын сатар өчен үз филиалларын ачарга тиеш булачак, ә бу — җирле халык өчен өстәмә эш урыны.

Ләкин ирекле сәүдәнең *тискәре яклары* да җитәрлек. Халык сыйфатлы чит ил товарларына өстенлек биргәнлектән, үз иле продукциясенә сорау кими, җитештерүчеләр эшләп чыгаруны кыскарта, эшчеләрне азат итә, дәүләткә салымны кимрәк түли. Әгәр чит ил конкуренциясе безнең җитештерүчеләрне продукцияләрен яхшыртырга, чыгымнарны киметергә, бәяләрне төшерергә мәҗбүр итсә, бик яхшы; ә итмәсә? Ул чакта илнең чит ил товарларына бәйлелеге арта барачак, бәяләр күтәреләчәк, халыкның күпчелеге аларны сатып алмаячак.

XX гасырның 80 нче елларында Россиядә барлык куллану товарлары диярлек җитмәде, бәяләр түбән булды, гаҗәеп зур чиратлар җыелды. 1992 елда тышкы сәүдәгә дәүләт монополиясе юкка чыгарылды һәм чит ил товарлары ташкын булып безнең базарларга агылды. Сәүдә үсә башлады, «челнок» дип аталган сәүдәгәрләр барлыкка килде, алар Төркия һәм Кытайдан арзанлы товарлар кайтарды, аларны базар һәм кибетләр янында ук урамда сата башлады. Хәзер бу этап узды. Кулланучының сайлап алу мөмкинлеге бар: чит ил товары аласыңмы, үзебезнең илдә җитештерелгәннеме. Мәсәлән, азык-төлек товарлары буенча безнең продуктларның өстенлеге бар — алар натураль (табигый), күпчелек очракта зарарлы өстәмәләрсез, яңа җитештерелгән. Әмма, кызганычка каршы, алар кыйммәтрәк тора һәм тышкы яктан матур чит ил продуктларыннан ямьсезрәк. Безгә әле кулланучыларны үзебезнең ил товарлары белән мөмкин кадәр яхшырак канәгатьләндерү өчен күп нәрсәгә өйрәнү зарур.

Нәкъ менә шуңа да Россия, башка бик күп илләр, хәтта иң нык үскәннәре кебек үк, протекционизм сәясәтеннән баш тартмады, тышкы сәүдәне җайга салуның күптөрле ысулларыннан файдалана.

Протекционизм сәясәте алымнарын карап үтик; аларны ике зур төркемгә бүләргә мөмкин — тарифлы һәм тарифлы булмаган.

Җайга салуның тарифлы ысулларына импортка таможня тарифы һәм экспорт тарифлары, шулай ук таможня берлекләре керә.

Импортка таможня тарифлары — илгә кертелүче импорт товарларына дәүләт чиген узганда таможня ведомстволары ала

торган пошлиналар ул. Гадәттә, әзер әйберләргә тарифлар шактый зур, чимал һәм материалга — түбәнрәк. Мондый сәясәтнең максаты — импорт товарына үзебезнең ил бәясен дөньядагы бәясеннән югарырак күтәрү һәм шулай итеп илебез җитештерүчеләрен чит ил конкурентларыннан яклау.

Экспорт тарифы — эчке базарда тәкъдимне киметми тоту өчен (бигрәк тә әгәр әлеге продуктка бәяләр дәүләт тарафыннан дөньядагы дәрәҗәдән түбәнрәк итеп сакланганда) экспортны чикләү максатларында илебез җитештерүчеләре товарына тариф ул. Мондый ысулларга үсеп килүче һәм күчеш икътисадлы илләр таяна. Шуның өстенә билгеләнгән экспорт пошлиналары дәүләт бюджетына өстәмә керем бирә.

Таможня берлекләре — үзләре арасында барлык таможня чикләүләрен бетергән, ләкин аларны өченче илләр өчен урнаштырган илләр берләшмәсе ул. Мисал итеп элеккеге СССРның Балтыйк буе республикалары (Латвия, Литва, Эстония) кергән Европа берлеген яисә Россия кергән Азия-Тын океан бергәлеген алырга мөмкин.

Җайга салуның тарифлы булмаган ысулларына квота билгеләү, экспорт кредитлары, икътисади санкцияләр (эмбарго), демпинг һ.б. керә.

Квота билгеләү — билгеле бер товар кертүне яки чыгаруны күләм ягыннан чикләү. Мәсәлән, АКШ, үз җитештерүчеләрен конкуренциядән саклау өчен, япон автомобильләрен һәм электроникасын кертүне чикләргә тырыша. Россия импорт автомобильләрен кертүгә квота билгеләмәде, ләкин аларны, бигрәк тә 5–7 ел эшләгән, шуңа бәясе бик түбән булганнарын кертүгә тарифларны күтәрде, шул юл белән автомобильләр кертүне чикләп, үз җитештерүчеләрен яклады.

Квота лицензияләү юлы белән урнаштырыла, моны дәүләт уздыра. Чит ил компанияләре товар кертүгә лицензия алу өчен бу илгә товарларның үрнәкләрен җибәрергә тиеш була. Вакытны күп алуы һәм бу процедура белән бәйле билгесезлек тышкы сәүдәгә тискәре йогынты ясый.

Чит илләрдән товар кертүгә яшерен протекционизмның тагын бер алымы — теге яки бу продукциягә стандартлар урнаштыру. Стандартлар продукцияне классификацияләү, маркировкалау, сынау үткәрүләр белән бәйле һәм еш кына халык куркынычсызлыгын һәм сәламәтлеген яклау сылтавы белән үткәрелә. Әйтик, маркировкада продуктның составы, әгәр ул туклану продукты булса — азык-төлек өстәлмәләре күрсәтелергә тиеш. Әгәр алар Россия стандартларына туры килмәсә, бу продуктларны кертү тыелачак.

Икътисади санкцияләр — эмбарго — дәүләт тарафыннан урнаштырылган башка бер ил белән сәүдә итүне тулысынча тыю

ул. Эмбарго, нигездә, бу илгә сәяси яктан басым ясау өчен кулланыла. Мәсәлән, үзе белән янәшә генә коммунистлар яклы илне түзеп тормыйча, АКШ Кубага тулы эмбарго игълан итте. Кайчакта эмбарго аерым бер товарларга белдерелә. АКШ 1980 еллар башында СССРга компьютерлар сатуга эмбарго игълан итте, янәсе, бу Советлар Союзының икътисади потенциалын ныгытырга мөмкин.

Халыкара сәүдә бик тиз үсә һәм шуңа да ул халыкара оешма ягыннан көйләүгә мохтаҗ. Шундый оешма 1948 елда төзелде һәм эшли башлады. Ул — Тарифлар һәм сәүдә буенча генераль килешү. 1995 елда ул Бөтендөнья сәүдә оешмасы (БСО) итеп үзгәртелде. БСО дөньядагы сәүдәнең 90% ы чамасын җайга сала (2009 елның октябренә аңа 153 дәүләт керде). Бу оешманың максаты — үз әгъзалары өчен сәүдәдә иң кулай режим булдыру, дискриминацияне бетерү һәм анда катнашучылар өчен тигез шартлар тудыру. БСО гомуми тарифлар урнаштыру һәм сәүдәдәге тарифлы булмаган чикләүләргә — квоталарга, экспорт тармакларын дәүләт субсидияләвенә, экспорт предприятиеләре өчен салым ташламаларына каршы көрәшә.

Россия, әлеге оешмага керергә гаризаны әле СССР чагында бирсә дә, БСО әгъзасы түгел. Сөйләшүләр нәкъ менә тарифлы булмаган инструментларга кагыла, Россия аларны үз сәнәгатен яклау өчен куллана. Безнең икътисадчылар бәяләве буенча, әлегә Россия БСО әгъзасы булмаган илләр өчен металлургия, химия, текстиль һәм башка тармаклар экспорты буенча кулай булмаган тарифлардан ел саен 1 дән алып 4 миллиард долларга кадәр югалтып бара.

ИКЪТИСАДНЫҢ ГЛОБАЛЬ ПРОБЛЕМАЛАРЫ

Төрле илләрне бердәм дөнья хуҗалыгына халыкара сәүдә генә бәйләп тормый. Мондый бәйләнеш тормышның күп кенә башка өлкәләрендә: җитештерүдә, финансларда, валюта һәм мәгълүмати даирәләрдә күренә. Кыскача әйткәндә, без *глобальләшү* процессын күзәтәбез.

Бу процесс фәнни-техник прогресс тизләтелгән үсеш алгач, XX гасырның 60 нчы елларында башланды, ә узган гасыр ахырында глобальләшү процессы үзенең өлгерү стадиясенә керде, дөньяны бердәм киңлеккә әверелдерде һәм дөнья хуҗалыгының барлык якларына кагылды.

Сәнәгатьтә глобальләшү процессы халыкара эш бүлешүнең тирәнәюендә һәм җитештерүнең интернациональләшүендә

чагыла. Әгәр без телевизор, компьютер, автомобиль кебек техник яктан шактый катлаулы әйберләрне алсак, кайчакта аларның кайда җитештерелүен белүе дә кыен, чөнки төрле детальләр төрле илләрдә генә түгел, хәтта төрле континентларда эшләнә. Бу үз филиалларын бөтен дөньяга тараткан трансмилли корпорацияләр (ТМК) «эше». «Экономист» журналы бәяләве буенча, иң эре 5 ТМК озак вакыт файдаланылучы товарлар, самолетлар, электрон җиһазлар, автомобильләр һәм дөньядагы башка продукция җитештерүнең яртысыннан артыгын контрольдә тота.

Халыкара сәүдә үзенең үсеш темплары буенча күптән инде сәнәгать үсешен узып китте, ә милли чикләрне белмәгән электрон сәүдәне алып карасак, аның күтәрелеше тагын да дәвам итәр дип фаразларга мөмкин. 2002 елда ук электрон сәүдәгә дөнья сәүдәсе күләменең 10% ы туры килде.

Электрон һәм мәгълүмати революция дөнья икътисадының глобальләшүенә этәргеч бирде. Бөтендөнья мәгълүмат челтәре — Интернет — илләрне бер-берсенә якынайтты һәм финанс глобальләшүенә ярдәм итте. 2003 елның башында ук дөньяда Интернеттан файдаланучылар саны 1 миллиардтан узып китте. Хәзер санаулы мизгел эчендә күп миллионлы акча суммасын дөньяның бер кырыеннан икенчесенә күчерергә, товарлар сатарга һәм сатып алырга була. Ләкин, кызганычка, хәзерге технологияләрнең бу күркәм казанышлары игелеккә генә түгел, явызлыкка да хезмәт итә. Тормышта яңа криминаль структуралар (әйтик, хакерлар) барлыкка килә, алар компьютер кодларын җимереп акча урлыйлар яисә криминаль ялган фирмалар тыелган товар (корал, наркотик) саталар.

Дөнья икътисадын глобальләштерү процессы гади нәрсә түгел: аның уңай һәм тискәре яклары бар. Бер яктан карaганда, глобальләшү төрле илләр арасында хезмәттәшлекне җиңеләйтә, икътисади күтәрелешнең тизләнүенә китерә; икътисади, фәнни-техник һәм интеллектуаль өлкәләрдә кешелекнең алдынгы казанышлары белән алмашу колачын киңәйтүгә этәргеч бирә. Болар барысы да, һичшиксез, хуҗалыкның бөтендөнья системасы прогрессына этәргеч бирә. Хәзер белемнәргә нигезләнгән «яңа икътисад» турында һаман күбрәк сөйлиләр. Һичшиксез, киләчәктә мәгарифкә торган саен күбрәк игътибар биреләчәк, фәкать зур белемнәргә ия, яхшы укыган кешеләр генә алдынгы мәгълүмати технологияләргә керә алачак.

Әмма икенче яктан глобальләшү еш кына җитди тискәре нәтиҗәләргә китерә, проблема һәм шөбһәләр тудыра. Бу ниндидер системадагы чатаклыкларның бик тиз бөтен дөньяга таралуы белән бәйле. 1997–1998 елларда дөнья финанс

кризисына әверелгән Азия һәм Латин Америкасы финанс кризисы моңа ачык мисал булып тора.

Оешкан җинаятьчелек шулай ук милли чикләрне узып китә. Глобаль криминаллашу милли дәүләтләрнең зәгыйфьләнүе турында сөйли, хәтта Интерпол (халыкара полиция) дә әлеге өлкәдәге икътисади җинаятьләрне туктата алмый.

Глобальләшү тудырган тагын бер мөһим каршылык — үзәк һәм периферия арасындагы киртәләр. Үзәкне нык үскән илләр — АКШ, Бөекбритания, Германия, Япония һ.б. тәшкил итә, ә периферия ике дәрәҗәдән тора: югары темпларда үсеп килүче илләр — Көнчыгыш һәм Көньяк-Көнчыгыш Азия, Көнчыгыш Европа, Россия, Һиндстан, Латин Америкасы («ярымпериферия» дип аталган илләр) — һәм иң ярлы, хәерчелекне җиңә алмаучы илләр — Африка һәм гарәп-мөселман дөньясы илләре. Сез «Икътисади үсеш» дигән бүлекнең 2 нче параграфыннан «ярлылыкның бозык даирәсе» турында инде беләсез. Бай һәм ярлы илләр арасындагы аерма даими үсә бара. Әгәр 1960 елда Җир шарындагы иң бай илләрнең биштән беренең һәм иң ярлы илләрнең биштән бере керемнәре чагыштырмасы 30 : 1 тәшкил итсә, XX гасыр ахырына ул инде 74 : 1 булды. 2000 ел ахырына илләрнең беренче төркеме дөнья ТЭПның 86% ын җитештерсә, икенчесе нибары 1% ын булдырды.

Халыкара финанс оешмалары (Халыкара валюта фонды, Дөнья банкы һ.б.) үсеп килүче илләргә заем биреп, аларга үз икътисадларын үстерергә ярдәм итәргә тырыша кебек иде. Әмма бу илләрнең бурычлары арта бара, ә сизелерлек икътисади күтәрелеш күзәтелми. Африкада гына да бурычлар 350 миллиард АКШ долларына җитте. Нәтиҗәдә бурыч периферияне үзәккә бәйлелегенең яңа рәвешенә әверелде, бу исә алар арасындагы аерманы тагын да арттырды.

Россиягә килгәндә, безнең ил дөнья икътисадында лаеклырак урын алсын өчен, матди һәм интеллектуаль ресурслар да, шактый фәнни потенциал да бар.

ГАМӘЛИ ЙОМГАКЛАР

1 Базар нигезләрендә үсә баручы Россия икътисады җәмгыятьнең игътибарын түбәндәге мәсьәләләргә юнәлтергә мәҗбүр итте: тышкы сәүдәдә нинди сәясәтне — протекционизмнымы яки ирекле сәүдәнеме — өстен күрергә? Илебезгә БСОга керү отышлымы? Дәүләтнең тышкы икътисади эшчәнлеге турындагы мәгълүматны туплый

барырга һәм анализларга киңәш итәбез. Бу сезгә илнең икътисади үсеше перспективалары турында белеп фикер йөртергә һәм икътисади тормышта актив катнашу буенча үзегезнең мөмкинлекләрегезне бәяләргә, шулай ук сайлаучы сыйфатында икътисади сәясәткә йогынты ясау ысулларын сайларга мөмкинлек бирер.

2 Кулланучылар буларак, сез яхшы беләсез, иң яхшы кофены — Бразилиядә, радиоэлектрониканы — Японниядә, ә иң яхшы бизнес-белемнәрне Англиядә алырга була һ.б. Товарлар һәм хезмәт күрсәтүләр сайлаганда тышкы сәүдәдә илләрнең өстенлеген белеп куллану бик файдалы.

3 Кешелекнең икътисади, фәнни-техник, интеллектуаль өлкәләрендәге алдынгы казанышларын уңышлы үзләштерү өчен дөнья икътисады глобальләшү процессының уңай нәтиҗәләрен күзәтеп барыгыз. Киләчәкнең белемнәргә нигезләнгән икътисадтан торуын исегездән чыгармагыз.

ДОКУМЕНТ

Хәзерге заман икътисадчы галимнәре ***В.Автономов, Т.Субботинаның*** «Ирекле сәүдә сәясәтенең файдасы» хезмәтеннән.

Аерым илләр, шулай ук тулаем дөнья икътисады мәнфәгатьләре күзлегеннән караганда, глобальләшү процессының өстенлекләре һәм җитешсезлекләре турындагы мәсьәлә безнең чорда барлык икътисади бәхәсләрнең иң төп мәсьәләсенә диярлек әверелде.

«Ирекле», ягъни дәүләт чикләүләре белән минималь бәйле халыкара сәүдәнең төп өстенлекләре милли җитештерүчеләрнең товарлары, хезмәт күрсәтүләре һәм капиталының дөнья базарына чыгуы гадиләштерелүдән барлыкка килә. Нәтиҗәдә һәр аерым илнең икътисады, бер яктан караганда, дөнья эш бүленешү системасында катнашудан билгеле бер файда күрә...

Дөнья эш бүленешендә катнашу милли җитештерүчеләргә илдә үстерү өчен иң кулай шартлар булган тармакларда махсуслашырга мөмкинлек бирә, ә чит ил җитештерүчеләре ягыннан конкуренция көчәю аларны продукциянең сыйфатын яхшыртуга һәм производство чыгымнарын киметергә омтылырга мәҗбүр итә. Болар барысы да, ахыр килеп, ирекле сәүдә сәясәте яклы илләр икътисадының нәтиҗәлелеген күтәрүгә алып бара, ә бу исә илләрнең кул

ланучылары эчке җитештерүнең дә, импортның да товарларын һәм хезмәт күрсәтүләрен киңрәк ассортимент буенча чагыштырмача түбән бәяләрдә алу мөмкинлегенә ирешә.

Моннан тыш халыкара сәүдәдә актив катнашучы илләр үзләренең сәүдә партнерлары икътисадыннан иң яңа технологияләр килүеннән (мәсәлән, импортланучы машина һәм җиһазларда гәүдәләнгән яңа белемнәрне үзләштерү юлы белән) отыш ала...

Күптән түгел сәяси карашлары буенча базар икътисадлы илләрдән шактый аерымланган элеккеге социалистик илләр хәзер дөньяның барлык илләре белән сәүдәдән элек алынмыйча калган файданы кайтарырга тырышалар.

Документка сораулар һәм биремнәр

1. Ирекле сәүдә нәрсәне белдерә һәм аның төп сыйфатлары нинди? **2.** Сез ничек уйлыйсыз: нигә элеккеге социалистик илләр импорт товарларын үз базарларына кертмәгәннәр? **3.** Якындагы кибеткә кереп, импорт һәм үзебезнең ил товарларын түбәндәге параметрлар буенча чагыштырыгыз: бәясе, сыйфаты, тартмасы. Сез нинди товарларга өстенлек бирер идегез?

ҮЗ-ҮЗЕҢНЕ ТИКШЕРҮ ӨЧЕН СОРАУЛАР

1. Без, «халыкара икътисади мөнәсәбәтләр» турында сөйләгәндә, нәрсәне күздә тотабыз? **2.** Халыкара эш бүлешү сәбәпләре нәрсәдә? **3.** Сез ничек уйлыйсыз, халыкара сәүдәгә кайсы ил — АКШмы яки Нидерландмы күбрәк бәйле һәм ни өчен? **4.** Сәүдә балансының уңай сальдосы яхшымы яисә начармы? **5.** Россия нинди товарлар белән сәүдә итүдә абсолют өстенлеккә ия, ә кайсында — чагыштырмача? **6.** Ни өчен кайбер дәүләтләр протекционизм сәясәте куллана? Россиягә кертү чикләнгән товарларны атагыз. 7. Глобальләшү яхшымы яки начармы? Үз карашыгызны дәлилләгез.

БИРЕМНӘР

1. *А* иле, ресурсларының бер берәмлеген кулланып, 1 т дөге яисә 4 т ташкүмер җитештерә ала. *Б* иле, шулай ук бер ресурс берәмлегеннән файдаланып, 2 т дөге һәм 5 т ташкүмер җитештерә. *Б* иле нәрсәне экспортка чыгара, ә нәрсәне импортлый?

2. *А* иленең экспорты — 103 093 миллион долларга, ә импорты 33 879 миллион долларга тигез иде; *Б* иленең экспорты — шул ук елда 781 125 миллион доллар, ә импорты 1 257 640 миллион доллар булды. *А* һәм *Б* илләренең тышкы сәүдә балансы сальдосын санап чыгарыгыз һәм чагыштырыгыз.

3. Россиягә электрон революция кагылдымы? Ул нәрсәдә күренә? Мисаллар китерегез.

ЗИРӘКЛӘР ФИКЕРЕ

«Бөек милләтләр шәхси затлар исрафчылыгыннан һәм акылсызлыгыннан беркайчан да ярлыланмый, ләкин алар еш кына дәүләт хакимияте исрафчылыгы һәм акылсызлыгы аркасында бөлә».

А.Смит (1723–1790), Шотландия икътисадчысы һәм философы

§ 11. Кеше икътисади мөнәсәбәтләр системасында

Җитештерүчеләр конкуренциясе кулланучыга отышлымы? Кешеләр нигә кредиттан файдалана? Бурычка яшәү яхшымы? Чыгымнарыбыз керемнәрдән артып китмәс өчен ни эшләргә?

Әлеге параграф, элеккеге материалга таянып һәм билгеле бер күләмдә аны гомумиләштереп, «Кеше һәм икътисад» дигән бүлекне тәгәлли.

1 нче параграф материалларыннан сез кешенең икътисадта — җитештерүдә, бүлешүдә, алмашуда, куллануда — төп эшчәнлеге төрләрен белдегез. Җитештерү — икътисадның нигезе аның төп бурычын — кешеләр ихтыяҗын канәгатьләндерү өчен матди байлыклар булдыруны хәл итү чарасы. Шуңа да кешенең җитештерүче ролен үтәве бу бүлекнең барлык параграфларында карау предметы булды. Җәмгыять өчен төп проблема булган чикле ресурслардан нәтиҗәле файдалану бурычын хәл итүдә җитештерүче генә түгел, кулланучы да актив катнаша. Икътисадта катнашучылар файдалана торган үз-үзеңне рациональ тоту кагыйдәләрен карауга керешеп, кулланучыга күбрәк игътибар бирергә тырышырбыз.

«Үзеңне рациональ тотуның нәрсә икәнлеген исегезгә төшерәбез. *Рациональ тәртип* — эш-гамәл нәтиҗәләрен чыгымнар белән чагыштыруны күздә тотучы уйланылган тәртип ул.

КУЛЛАНУЧЫНЫҢ РАЦИОНАЛЬ ТӘРТИБЕ

Җитештерү куллану белән аерылгысыз бәйле, ул куллану өчен тормышка ашырыла һәм аның структурасын билгели. Кулланучы, товарлар һәм хезмәт күрсәтүне сайлап алып, җитештерүгә актив йогынты ясый, аның үсешенә этәргеч бирә. Ирекле базар һәм конкуренция шартларында кулланучыларның җитештерүчегә тәэсире шулкадәр зурайды ки, кайчакта хәтта «кулланучы диктаты» турында сөйлиләр.

Кулланучылар — үзләренең шәхси көнкүреш, табыш алу белән бәйләнмәгән ихтыяҗлары өчен товарлар сатып алучы һәм алардан файдаланучы, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләргә заказ бирүче кешеләр. Безнең һәркайсыбыз үз ихтыяҗларын нинди дә ысул белән канәгатьләндерергә теләүче кулланучы булып тора. Фирма, оешма, тулаем дәүләт тә кулланучы була.

Куллануның максаты — товарлар һәм хезмәт күрсәтүләр кулланудан максималь файда алу. Бу максатка бару юлында гаилә бюджеты, бәяләр, тәкъдим ителүче товарлар һәм хезмәт күрсәтүләр ассортименты кебек чикләүләр килеп чыга. Шуңа күрә кулланучы да, җитештерүче кебек үк, үзендә чикләнгән мөмкинлекләр йогынтысын тоя. Аның алдында шулай ук рациональ сайлау проблемасы тора.

Команда-административ икътисадлы илләрдә, кагыйдә буларак, кулланучының гамәлләре регламентлана. СССРда, мәсәлән, кулланучы торак, дәвалау учреждениеләре, кайбер кыйммәтле товарлар (автомобиль, йорт җиһазы һ.б.) сайлап алу ирегеннән мәхрүм иде. Базар икътисадында исә *кулланучы суверенитеты*, ягъни теләсә нинди ресурслар иясенең әлеге ресурслар белән эш итү һәм алардан файдалану белән бәйле карарларны мөстәкыйль кабул итү хокукы икътисади ирек тәртибенең алшарты булып тора.

Кешенең күптөрле ихтыяҗларын исегезгә төшерегез: физиологик, социаль, рухи, үз-үзләрен реализацияләү, иминлек. Әлеге ихтыяҗлар базарның төрлесендә гамәлгә ашырылырга мөмкин. Мәсәлән, товарларга һәм хезмәт күрсәтүләргә ихтыяҗ — товар һәм хезмәт күрсәтү базарында, үз-үзләрен реализацияләү — хезмәт базарында. Кулланучы сайлавын белеп һәм аны рациональ тормышка ашыру өчен һәркем мәгълүм бер белемгә һәм осталыкка ия булырга тиеш.

Үз ихтыяҗларын чикләнгән чараларны бик аз сарыф итеп канәгатьләндерүдә кызыксынган кулланучыга түбәндәге мәсьәләләр турында уйланырга туры килә: керемнәрне беренче чиратта нәрсәгә тотарга? Теләгән сыйфаттагы һәм сатып алу мөмкинлегенә туры килүче товарны яисә хезмәт күрсәтүне

ничек сайларга? Финанс югалтуларын ничек кыскартырга? Булган керемнәрне ничек итеп саклап калырга? Төрле базарларда үз-үзеңне ничек рациональ тотарга?

Әлеге мәсьәләләрне кулланучының товар һәм хезмәт күрсәтү базарындагы тәртибе мисалында карап үтик. Кулланучы — әлеге базарда төп хәрәкәт итүче затларның берсе; ул сорау тудыра, шуның аша товарларның ассортименты, сыйфаты һәм бәясе билгеләнә. Әмма бу базарда ул шундый көчлеме соң? Кирәкле товарны ничек итеп дөрес сайларга? Еш кына кулланучыларның товар турында мәгълүматы аның функцияләре яисә аны куллануда көтелүче уңай эффект турындагы белемнәр белән чикләнә.

Әйтик, сез заманча кер юу машинасы алырга телисе ди. Нәрсәдән башларга? Әлеге товар базарын бәяләү зарур. Иң элек реклама белдерүләрен өйрәнергә кирәк: товар ассортименты нинди, аны кайда һәм нинди бәягә сатып алырга була. Аннан соң махсуслашкан кибет сайларга кирәк, монда квалификацияле белгечтән (товар белгече, менеджер) товарның үзенчәлекләре һәм сыйфаты турында белешмә алырга мөмкин. Сезне товар максималь хезмәт күрсәтү гарантиясе белән сатылучы, куллану урынына китерү һәм урнаштыру тәэминителүче, гарантиядән соңгы хезмәт күрсәтүле кибет кызыксындырырга тиеш. Киңәйгән сату көннәре, товарга ташламалар турында белдерүләргә игътибар итәргә онытмагыз. Барлык факторларны анализлау сезгә рациональ, ягъни үзегез өчен иң файдалы сатып алуга ирешүдә булышыр.

Күргәнегезчә, кулланучының товар яки хезмәт күрсәтүләр сайлаганда рациональ тәртибе, кагыйдә буларак, гамәлләрнең билгеле бер эзлеклелеген күздә тота: сатып алу зарурлыгын аңлау, товар һәм хезмәт күрсәтү турында мәгълүмат эзләү, сатып алуның мөмкин булган вариантларын бәяләү, сатып алу турында карар кабул итү.

Шулай итеп, сез сайладыгыз. Ләкин теләгәнне һәрвакытта да сатып алып буламы соң? Без еш кына булган керемнәрнең чикләнгәнлеге кебек киртәгә юлыгабыз.

Инде белгәнегезчә, кеше берничә чыганактан керем алырга мөмкин. Кулланучы кеременең төп чыганаклары булып хезмәт хакы, аерым гражданнарга дәүләт пособиесе, пенсия, стипендия рәвешендәге социаль түләүләре, эшмәкәрлек эшчәнлегеннән керем, милектән керем (фатирыгызны яисә дачагызны арендага бирүдән алынган түләү, акча капиталыннан процент, кыйммәтле кәгазьләр буенча дивидентлар).

Күп кенә йорт хуҗалыкларында алынган керем ике өлешкә бүленә: берсе кешеләрнең шәхси ихтыяҗларын канәгатьләндерү

өчен кирәк булган товарлар һәм хезмәт күрсәтүләр сатып алу өчен билгеләнә; керемнең икенче өлеше саклык акчаларын тәшкил итә. Бу бүленеш керем рәвешләренә һәм чыганакларына бәйле түгел, әмма аның күләменнән тора. Кулланучы күбрәк керем алган саен, куллануга күбрәк акча тотарга сәләтле. Керем үсү белән, саклык акчасы суммасы да арта. Болар үзара күренеп торган бәйлелектә. Икътисадчылар керем һәм чыгымнарның башка бәйләнешләрен дә ачыклады: гаиләнең кереме зуррак булган саен, куллануга чыгымнар өлеше азрак һәм озак файдаланудагы товарлар өлеше күбрәк, шулай ук саклык акчаларының нисбәте зуррак.

Кешенең тормыш дәрәҗәсе аның хезмәт хакы яисә саклык акчалары күләменнән генә тормый, аның үз акчасын никадәр уйлап сарыф итүенә дә бәйле. Икътисадчылар куллану чыгымнарын мәҗбүри һәм ирекле гә бүлеп карыйлар. Мәҗбүри чыгымнарга минималь зарурилык итеп карарга була — бу туклануга, кием-салым, транспорт, коммуналь хезмәтләргә һ.б. чыгымнар. Әгәр дә сезнең шәхси керемнәрегез мәҗбүри чыганаклардан артык түгел икән, ирекле чыгымнарга юл кую мөмкинлегегез (мәсәлән, туристик юллама, китаплар, картиналар, машина һ.б. сатып алырга) бик чикле.

Төрле илләрдәге кулланучылар чыгымнары турындагы мәгълүматларны анализлап, галимнәр түбәндәге нәтиҗәгә килә: ил баерак булган саен, аның гражданнары шәхси кеременең азрак өлеше мәҗбүри чыгымнарга китә. Немец тикшеренүчестатистигы Э.Энгель (1821–1896), беренче тапкыр буларак, халыкның керемнәре һәм куллану структурасы арасындагы закончалыклы элемтәне ачыклады. «Энгель законы» нигезендә, гаиләнең керем дәрәҗәсе югарырак булган саен, аның азыктөлек товарларына чыгымнар өлеше азрак. Димәк, киң кулланыштагы сәнәгать товарларына сорау арта, ә керем дәрәҗәсе тагын да күтәрелгәндә, югары сыйфатлы товарларга һәм хезмәт күрсәтүгә чыгымнар сизелерлек үсә. Күргәнегезчә, куллануга чыгымнар структурасы керем күләменә турыдан-туры бәйлелектә үзгәрә.

Гаиләнең туклануга чыгымнары өлеше буенча бер ил халкының төрле төркемнәре муллык дәрәҗәсе турында фикер йөртергә һәм төрле ил гражданнары муллыгын чагыштырырга мөмкин. АКШта туклануга чыгымнар өлеше 10–15% чикләрендә үзгәрә, ә Россия гаиләләренең байтагы туклануга үз керемнәренең 40–48% ын тота. (Илдәге икътисади хәлнең бу күрсәткечкә ничек йогынты ясавы хакында уйлагыз.)

Акчаны бүген туздырыргамы яисә киләчәккә калдырыргамы? Үз керемнәреңне ничек сакларга һәм арттырырга?

Бу мәсьәләләр, гаиләме ул яки фирмамы, барлык кулланучыларны да борчый.

Рациональ кулланучыга үз акчасын оста тоту гына түгел, саклык акчаларын дөрес урнаштыру да мөһим. Шул максатларда кулланучы банктагы саклык счетыннан файдалана, кертем буенча керем ала яисә кыйммәтле кәгазьләр сатып алып, алар буенча дивидендларга ия була. (Әйтелгәннәрнең икътисади тотрыклылык шартларында гадел булуын билгеләп үтик.)

Илдә икътисади һәм финанс тотрыксызлыгы вазгыятендә, инфляция дәрәҗәсе югары булганда саклык акчаларын урнаштыруның тагын бер ышанычлы ысулы — күчемсез милек (фатир, йорт, дача) сатып алу; аларга бәяләр акча очсызланганга караганда тизрәк күтәрелә.

Саклык акчаларын урнаштыруның бер рәвеше булып гомерне, сәламәтлекне, мөлкәтне иминиятләштерү тора. Бүген Россиядә иминиятләштерү компанияләре һәм фондлары (нигездә — коммерциячел) эшләп тора, алар иминиятләштерүнең түбәндәге төрләрен башкара: ирекле медицина иминиятләштерүе, бәхетсезлек очракларыннан иминиятләштерү, бизнестәвәккәллекне иминиятләштерү, автоиминиятләштерү һ.б. Иминиятләштерү бу хезмәтне җитештерүчеләргә дә, аны кулланучыларга да файдалы.

Иминиятләштерү — мондый компанияләргә даими кертемнәр юлы белән сезне мөмкин булган зарардан яклау ул, иминиятләштерү компанияләре, шундый зарар күрелгәндә, аны акчалата каплый.

Саклык акчалары, әгәр дә алар дөрес урнаштырылса, кулланучыга өстәмә керем алырга гына түгел, кыйммәтле әйберләр сатып алырга да мөмкинлек бирә. Саклык акчасы эш сәләтен югалту очрагында да, белем алуны һәм һөнәрилек дәрәҗәсен күтәрүне түләү өчен дә һ.б. кирәк. (Йорт хуҗалыгында саклык акчаларының кирәклеген раслаучы мисаллар китерегез.)

Саклык акчаларын урнаштыру вариантларын сайлап алганда, кулланучыга аларны ышанычлылык, керемгә процент, ликвидлылык (саклыкны кулдагы акчага җиңел генә әверелдерү мөмкинлеге) күзлегеннән чагыштыру зарур.

ҖИТЕШТЕРҮЧЕНЕҢ ҮЗ-ҮЗЕН РАЦИОНАЛЬ ТОТЫШЫ

Җитештерүчеләр — кешеләр, фирмалар, предприятиеләр, ягъни товар әзерләүчеләр, хезмәт күрсәтүчеләр һәм аларны безгә сатучылар ул. Җитештерүче үз продукциясен сатканда

алган акча «тулай керем» дип атала. Җитештерүче производство ресурслары сатып алуга тоткан акча аның чыгымнарын тәшкил итә. Керем белән чыгымнар арасындагы аерма табыш булып тора.

Базар икътисадында җитештерүченең максаты — мөмкин кадәр күбрәк табыш алу. Моның өчен ул җитештерүгә чыгымнарны киметергә тырыша, чөнки чыгымнар түбән булган саен, керемнәр арта. Чыгымнарны киметергә ресурсларны экономиялерәк комбинацияләү, яңа техника кертү, чимал һәм энергияне сак тоту һәм башка күп нәрсә ярдәм итә. Производство ресурсларының чикләнгәнлеге аерым җитештерүчене, фирманы, тулаем җәмгыятьне нәрсә, ничек һәм кем өчен җитештерү проблемасын чишәргә мәҗбүр итә.

Нәрсә җитештерергә? Җитештерүчеләр «төрле продуктлар җитештерүгә ресурсларны ничек бүләргә, хәзерге вакытта җәмгыятькә һәм кулланучыларга кирәкле нинди уңайлыкларны һәм никадәр җитештерергә, әйтик, өстенлекне хәрби техника ясауга бирергәме, әллә көнкүреш техникасынамы» дигән карарлар кабул итә.

Ничек җитештерергә? Сайланган продукция күләмен җитештерүне төрлечә хәл итәргә мөмкин. Җирне кулдан эшкәртеп, уңышны бик күп хезмәткәр җәлеп итеп җыярга мөмкин, авыл хуҗалыгы техникасыннан файдаланып, азрак кеше катнашында да була. Яңа техника һәм технология куллану булган ресурслардан файдаланганда эшләп чыгарылучы продукциянең күбрәк күләменә ирешүне тәэмин итәргә мөмкинлек бирә. Әмма шунысын да истән чыгармаска кирәк: бу яңа техника һәм технология кулланудан керем аларны производствога кертү белән бәйле чыгымнардан артык булган очракта гына отышлы.

Кем өчен җитештерергә? Җәмгыять төрле керемгә ия, төрлечә сатып алу сәләтле кешеләрне берләштергәнлектән, җитештерүчеләргә товар һәм хезмәт күрсәтүләр җитештергәндә кемгә йөз тотарга икәнлеген, аларның потенциаль кулланучылары кем буласын хәл итәргә туры килә.

Ресурслардан нәтиҗәле файдалану алымнарын ачыклаганда, икътисад фәне икътисади эшчәнлек субъектларының рациональ тәртибеннән, ягъни аларның иң аз чыгымнар куеп, билгеле бер нәтиҗәләргә ирешергә омтылуыннан чыгып карый.

Икътисади эшчәнлекне рациональ оештыру җитештерүчедән байтак мәсьәләләрне чишүне таләп итә: чикле ресурсларга ия булып, ничек итеп үз производствоң максатларына ирешергә? Чыгымнар минималь булсын өчен, җитештерү ресурсларын ничек комбинацияләргә? Булган ресурслар белән чыгарылучы продукция күләмен ничек арттырырга?

Әйтик, соңгы проблеманы хәл итүнең, без инде билгеләп үткәнчә, ике ысулы бар: җитештерү күләмен ресурсларның санын үзгәртү исәбенә (производство куәтләрен, табигать ресурслары күләмен, хезмәткәрләр санын арттыру) һәм ресурсларның сыйфат күрсәткечләрен яхшырту, аларның продуктлылыгын яисә җитештерүчәнлеген күтәрү исәбенә киңәйтү.

Чимал кимү һәм аның кыйммәтләнүе проблемасына юлыгып, күпчелек илләр бүген җитештерү мөмкинлекләре чикләрен киңәйтүнең икенче ысулына басым ясыйлар. Бу **хезмәт җитештерүчәнлегенең үсүенә** китерә. Исегезгә төшерәбез: производство ресурсларыннан файдалану нәтиҗәлелегенең бу икътисади күрсәткече бер вакыт берәмлегенә бер хезмәткәр җитештергән продукция күләме белән характерлана.

Хезмәт җитештерүчәнлеге үсешен билгеләүче факторларны бер үк вакытта чыгарылучы продукция күләмен арттыру факторы буларак та карарга мөмкин. Бу факторлар нинди соң?

Барыннан да элек бу — эш бүлешү яисә җитештерүчеләрнең нинди дә булса эшчәнлек төрендә махсуслашуы. Аерым бер эшләнмәне яки кечкенә операцияне башкаруда эшче бик җитезгә әверелергә мөмкин, һәм аның җитештерүчәнлеге арта.

Фактор буларак, техник прогресс производствода яңа, җитештерүчәнрәк техника яисә технология куллануны күздә тота, бу исә шул ук вакыт аралыгында, кагыйдә буларак, азрак кеше катнашында җитештерү күләмен арттырырга мөмкинлек бирә.

Һәм, ниһаять, хезмәткәрләрнең белем дәрәҗәсе һәм һөнәри әзерлеге. Квалификацияле хезмәт күбрәк күләмдә продукция җитештерүгә ярдәм иткән өчен генә нәтиҗәлерәк түгел, хезмәткәрнең һөнәри осталыгы югарырак булган саен, әзерләнүче продукциянең сыйфаты әйбәтрәк. Димәк, ул ныграк, озаграк хезмәт итә, ә бу җитештерү белән бәйле ресурсларны янга калдырырга, аларны башка икътисади муллык җитештерүгә җибәрергә мөмкинлек бирә.

Бруклин университеты (АКШ) галиме Эдвард Денисон хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрүнең төрле факторларының җитештерү күләмнәре үсешенә йогынтысын сан ягыннан чагыштырырга тырышып карый. Аның бәяләве буенча, 1929 елдан 1982 елга кадәр чорда АКШта реаль милли керем үсешенең 28%ы — техник прогресс, 19%ы — капитал тоту (производствоны оештыру өчен матди чаралар һәм акча тоту), 14%ы — хезмәткәрләрнең белемнәре арту һәм һөнәри әзерлеге исәбенә булган.

ГАМӘЛИ ЙОМГАКЛАР

1 Кулланучының товарларга һәм хезмәт күрсәтүләргә үз ихтыяҗларын максималь канәгатьләндерү мөмкинлеге керемнәренең күләменнән генә түгел, аларны рациональ файдаланудан да тора. Үзегезнең сатып алуларыгызны планлаштырырга тырышыгыз. Бу исә ихтыяҗларны яхшырак уйлап карарга һәм әлегә кирәк булмаган әйберләргә акча тотмаска мөмкинлек бирер. Җитештерүче тәкъдим иткән шартлар белән товар һәм хезмәт күрсәтүләр сатып алу шартларын чагыштырыгыз.

2 Мөмкин булса, үз керемнәрегезне саклык акча сыйфатында калдыра барыгыз. Аларны күбрәк файда алу, ягъни акчаны арттыру өчен урнаштырырга тырышыгыз. Исегездән чыгармагыз: инфляция югары чорда саклыкны акча рәвешендә тоту рациональ түгел. Әгәр инфляция дәрәҗәсе процент ставкаларыннан югарырак икән, бу саклык акчасыннан алынган барлык керемне юк итә.

3 Саклык төрен сайлаганда аны тоту урыны һәм алымнарының (банк кредиты, кыйммәтле кәгазьләр, инвестиция) керемлелеге һәм ликвидлылыгы турында мәгълүмат тупларга һәм аны анализларга тырышыгыз. Бу сезгә үз акчаларыгызны тапшырырга теләгән кешеләрнең компетентлылыгы һәм ышанычлылыгы турында белергә ярдәм итәр.

4 Перспективада сезнең производство керемлелеген тәэмин итүгә чыгымнарны киметүнең төрле алымнарын куллану: техник яңалыклар һәм заманча технологияләр кертү, чимал һәм материалны экономияләү, һөнәри осталыкны күтәрү ярдәм итәр.

ДОКУМЕНТ

Капитал белән ничек эш итәргә. *Шотландия икътисадчы-галиме* ***А.Смитның*** «Халыклар байлыгының табигате һәм сәбәпләре турында тикшеренү» дигән хезмәтеннән.

Кешенең запаслары аны берничә көн яки атна дәвамында асрарлык кына булса, ул моннан нинди дә булса керем алу турында бик сирәк уйлый... Бу очракта аның кереме фәкать аның хезмәтеннән генә барлыкка килә... Әгәр дә әлеге затның запаслары берничә айлык яисә еллык булса, ул, табигый ки, әлеге запасларның зур өлешеннән керем алырга тырышачак. Шуңа да запаслар ике өлешкә бүленә.

Ул керем алырга уйлаган өлеш капитал дип атала. Икенче өлеше турыдан-туры куллануга китә...

Капитал үз хуҗасына керем китерсен өчен, аннан ике төрле ысул белән файдаланырга мөмкин. Беренчедән, ул товарлар җитештерүгә, эшкәртүгә яки керем алып яңадан сату өчен сатып алуга кулланыла ала... Мондый төр капиталны «әйләнеш капиталы» дип атау дөрес булыр. Икенчедән, капитал җирне яхшыртуда, файдалы машиналар һәм инструментлар яки башка әйберләр сатып алуда кулланыла ала, болар бер хуҗадан икенчесенә күчмичә дә, яки алга таба әйләнмичә дә керем яисә табыш китерә. Мондый капиталны «төп капитал» дип атарга мөмкин.

...Фермер капиталының игенчелек коралларына тотылган өлеше төп капитал булып тора, ә эш хакына һәм эшчеләр асрауга сарыф ителгән өлеше әйләнмә капиталны тәшкил итә. Ул беренчесеннән аны үз биләмәсендә калдырып керем ала, ә икенчесеннән аның белән аерылып табыш ясый.

...Җитәрлек кадәр тотрыклы тәртип булган барлык илләрдә камил акылга ия һәр кеше үзендә булган запасларны үз ихтыяҗларын хәзер канәгатьләндерү өчен яисә киләчәктән керем алуга тотарга тырыша.

Документка сораулар һәм биремнәр

1. Документ тексты гражданнарның нинди керем төрләре белән таныштыра? 2. Автор капитал ияләренә керем яки табыш алу ысулларын тәкъдим итә. Әлеге ысулларны атагыз. 3. Керемнәрнең кайсы өлеше капитал булып тора? Әйләнеш капиталы төп капиталдан нәрсәсе белән аерыла? 4. Галим, «тотрыклы тәртип»не «камил акылга ия» һәр кеше тарафыннан булган запаслардан керем алу өчен зарури шарт булып тора, дип фикер йөртә. Аның белән килешергә мөмкинме? Россия икътисадында кулланучыларга һәм җитештерүчеләргә үз капиталыннан керемнәр алу мөмкинлеген кызыксындыручы яисә катлауландыручы шартларны характерлагыз. 5. Үз керемнәреңне ничек итеп саклап калырга һәм арттырырга? Тәкъдимнәрегезне формалаштырыгыз.

ҮЗ-ҮЗЕҢНЕ ТИКШЕРҮ ӨЧЕН СОРАУЛАР

1. Чикләнгән ресурслар шартларында рациональ җитештерүчегә һәм кулланучыга нинди икътисади проблемалар хәл

итәргә туры килә? **2.** Үз керемнәреңне инфляциядән якларга мөмкинме? Мөмкин булса, ничек итеп? **3.** Акчаны ничек рациональ тотарга? Мәҗбүри чыгымнар ирекле чыгымнардан нәрсәсе белән аерыла? **4.** Хезмәт җитештерүчәнлегенә нинди факторлар тәэсир итә? **5.** Ресурслар чикле булганда, җитештерелүче продукция күләмен нинди алымнар кулланып арттырырга мөмкин?

БИРЕМНӘР

1. Техник прогресс производство чыгымнары һәм җитештерүче табышы үзгәрешенә йогынты ясый. Хәзерге заман производствосында фәнни-техник прогресс казанышларын хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрү факторы буларак куллануга мисаллар китерегез.

2. Америка предприятиеләрен тикшерү мәгълүматлары буенча, хезмәтне оештыруның төркем (бригада) ысулын куллану (бригаданың эшләнмәне башыннан ахырынача әзерләве) җитештерүчәнлекне 60 тан 600% ка кадәр күтәрергә мөмкинлек бирә. Моның сәбәпләрен аңлатыгыз. Хезмәткәрнең җитештерүчәнлегенә йогынты ясаучы факторларны атагыз.

3. Россиянең икътисади үсешендә гражданнар тарафыннан дәүләттән түләүсез ала торган матди уңайлыклар саны кимү һәм торак-коммуналь хуҗалыгы, сәламәтлек саклау, мәгариф, мәдәният, ял вакыты даирәсе хезмәтләрен түләп куллануга күчү тенденциясе сизелә. Бу тенденцияне социаль-икътисади процессларда фикерләгез һәм аның кулланучылар чыгымнары структурасына һәм тәртибенә йогынтысын аңлатыгыз.

4. Россиядә халыкның саклык акчасы дәрәҗәсе чагыштырмача югары, аны икътисадны үстерүнең мөмкин булган чыганагы итеп карарга була. Әмма саклык акчалары шактый күп булса да, инвестиция (акчаларны үз эшләрен оештыруга, җитештерүне үстерүгә салу) җитми. Сезнеңчә, мондый хәлнең сәбәпләре нидә?

ЗИРӘКЛӘР ФИКЕРЕ

«Бик күп уңай яклары булган кеше, әгәр ул акча эшләргә һәм аларны акыл белән сарыф итәргә сәләтле икән, шулар янына тагын икесен өстәр».

Э.Севрус (1948 елда туган), рус әдәбиятчысы

БҮЛЕККӘ КЫСКАЧА ЙОМГАК

1 Фән буларак икътисад җәмгыятьнең чикләнгән ресурсларын кешеләрнең ихтыяҗлары даими үсә баруы шартларында матди байлыклар җитештерү өчен файдалануны өйрәнә. Икътисади эшчәнлек җәмгыять өчен хәлиткеч булган чикләнгән ресурслардан нәтиҗәле файдалану проблемаларын хәл итүгә юнәлтелгән. Икътисадның төп субъектларының — җитештерүчеләр һәм кулланучыларның — үз-үзләрен рациональ тотуы бу проблеманы уңышлы хәл итү шартларының берсе. Икътисади эшчәнлекне үлчәү өчен төрле күрсәткечләр куллану җәмгыятьтә икътисади процессларның торышы, сыйфаты һәм нәтиҗәләре турында мәгълүмат алырга мөмкинлек бирә.

2 Икътисади үсеш — икътисад һәм җәмгыять прогрессының иң мөһим критерие; аның темплары кеше тормышының дәрәҗәсе һәм сыйфаты турында фикер йөртергә мөмкинлек бирә. Әгәр ярлы илләр икътисади үсешнең максатларын һәм алымнарын, хуҗалык тормышында һәм икътисад структурасында үзгәрешләр зарурлыгын аңласа, бай һәм ярлы илләр арасындагы аерманы кыскартырга була. Икътисади күтәрелешкә ирешү факторларын һәм юлларын анализлаганда, шулай ук икътисади процессларны фаразлаганда хәзерге заман базар икътисады үсешенең циклы рәвештә булуын исәпкә алу мөһим.

3 Базар җәмгыятьтәге икътисади процессларның мөһим көйләүчесе булып тора. Базарның икътисади законнары, конкуренция җитештерүнең эффектлылыгын күтәрүгә, чикләнгән ресурслардан рациональ файдалануга ярдәм итә. Хәзерге заман икътисады — социаль юнәлешле катнаш икътисад; анда икътисади тормышны җайга салуның дәүләт һәм базар механизмнары бер үк вакытта кулланыла.

4 Ирекле эшмәкәрлек — икътисадны һәм җәмәгать производствосын нәтиҗәле үстерүнең мөһим факторы. Дәүләт гражданнарның эшмәкәрлек эшчәнлеген хуплау һәм үстерү өчен уңайлы хокукый һәм социаль шартлар булдыруга кызыксына. Эшмәкәрнең уңышка ирешүенә бизнесны финанслауның төрле чыганаклары булу һәм алардан рациональ файдалану, менеджмент һәм маркетинг нигезләрен белү ярдәм итә.

5 Дәүләт, икътисадны тотрыклы үстерү, аның нәтиҗәлелегенә һәм икътисади үсешкә ирешү максатларында икътисади процессларга йогынты ясап, хәзерге җәмгыятьтә мөһим икътисади функцияләр башкара. Моның өчен ул, аерым алганда, фискаль һәм монетар сәясәт ысулларын куллана, илдә

җитештерелгән иҗтимагый продуктны һәм милли керемне яңадан бүлә, инфляциянең тискәре йогынтысын киметә. Базар механизмы үзенең булдыксызлыгын күрсәткән өлкәләрдә: халыкның мәшгульлеген җайга салу һәм эшсезлеккә каршы көрәштә, иҗтимагый уңайлыклар җитештерүдә, тышкы эффектларны компенсацияләүдә, халыкны социаль яклауда дәүләтнең роле зур.

6 Аерым илләр бер-берсе белән халыкара икътисади мөнәсәбәтләр системасы аша бәйләнгән. Илләрне бердәм дөнья хуҗалыгына берләштерүдә башка факторлар белән беррәттән халыкара сәүдә дә ярдәм итә. Дәүләт аны җайга салуның төрле ысулларыннан файдалана, протекционизм яисә ирекле сәүдә сәясәтен куллана. Хәзерге вакытта күп кенә илләрнең ачык базар икътисадына күчүе ирекле сәүдә сәясәтенең көчәюенә һәм дөнья икътисадының глобальләшү процессы тирәнәюгә булыша.

ЙОМГАКЛАП КАБАТЛАУ ӨЧЕН СОРАУЛАР

1. Җәмгыять тормышында икътисади эшчәнлекнең роле нинди?
2. Ни өчен икътисади күтәрелеш икътисад һәм җәмгыять процессы критерийларының берсе булып тора?
3. Икътисадны базар җайга салуы үзенчәлекләре нидә?
4. Җитештерүне ничек нәтиҗәле итәргә?
5. Бизнеста уңыш өчен нәрсә кирәк?
6. Хәзерге заман дәүләте нинди икътисади бурычларны хәл итә?
7. Икътисадта акча агымын кем һәм ничек җайга сала?
8. Икътисадка хезмәт базары нигә кирәк?
9. Илләр ни өчен бер-берсе белән сәүдә итәргә мәҗбүр?
10. Җитештерүчегә һәм кулланучыга рациональ икътисади сайлап алуны ничек башкарырга?

II бүлек

Социаль-сәяси һәм рухи тормыш проблемалары

§ 12. Кеше эшчәнлегендә ирек

Җәмгыятьтә яшәргә һәм җәмгыятьтән ирекле булырга мөмкинме?

Шәхес иреге хәзер төрле чагылышларда цивилизацияле кешелекнең иң мөһим кыйммәтен тәшкил итә. Кешенең үзен-үзе табуы өчен ирекнең әһәмияте борынгы заманнардан ук фикерләү үзәгендә булды. Азатлыкка, деспотлык богавыннан, гаделсезлектән котылуга омтылыш бөтен кешелек тарихын буеннан-буена үтеп килә. Яңа һәм иң яңа заманнарда ул аеруча көч алды. Барлык революцияләр дә байракларына «Азатлык» сүзен язды. Сәяси лидерлар һәм революция юлбашчыларының бик азлары гына үзләре җитәкчелек иткән массаларны чын азатлыкка китерергә ант итмәде. Аларның зур күпчелеге үзләрен һичшиксез шәхес иреге тарафдары һәм яклаучысы дип белдерсә дә, әлеге төшенчәгә салынган мәгънә төрлечә иде.

«Ирек» категориясе кешелекнең фәлсәфи эзләнүләрендә үзәк мәсьәләрнең берсен тәшкил итә. Сәясәтчеләр бу төшенчәне

үзләренең анык сәяси максатларына буйсындырып, төрле төсләргә манган кебек үк, фәлсәфәчеләр дә аны фикерләүгә төрлечә якын килә.

Әлеге аңлатмалар төрлелеген ачыкларга тырышып карыйк.

«БУРИДАН ИШӘГЕ»

Кешеләр иреккә ничек кенә омтылсалар да, абсолют, чиксез азатлык булуның мөмкин түгеллеген аңлыйлар. Барыннан да элек берәүнең тулы ирегe икенчеләргә карата башбаштаклык булыр иде. Әйтик, берәү төнлә музыканы кычкыртып тыңларга тели ди. Магнитофонны бар куәтенә җибәреп, ул үз теләген үти, үз иркендә була. Ләкин бу очракта аның ирегe башка ирекләрнең төнлә тынычлап йоклау хокукын боза.

Нәкъ менә шуңа тулысы белән шәхес хокукы һәм ирегенә багышланган Кеше хокуклары гомуми декларациясендә, аның кешенең бурычлары турында искә алынган соңгы статьясында, үз хокукларын һәм ирегeн тормышка ашырганда һәр кешегә *башкалар хокукын тану һәм хөрмәт итүне* тәэмин итү максатындагы чикләүләр куелырга тиеш, диелә.

Абсолют ирекнең мөмкин булмавы турында фикер йөртеп, мәсьәләнең тагын бер ягына игътибар итик. Мондый ирек кеше өчен берни белән чикләнмәгән сайлап алу ихтималы булыр, димәк, карар кабул иткәндә, аны бик кыен хәлгә куяр иде. «Буридан ишәге» дигән гыйбарә киң мәгълүм. Француз философы Буридан икесе дә бер үк төрле һәм бер үк ераклыктагы печән өеме арасына куелган ишәк турында сөйләп күрсәтә. Кайсы өемнән ашарга икәнлеген хәл итә алмыйча, ишәк ачтан үлә. Шундый ук хәлне тагын да алданрак, ишәк турында түгел, кешеләр хакында Данте тасвирлый: «Икесе дә үзенә тартып торган һәм бер үк якынлыктагы ризык янына куелган кеше, абсолют иреккә ия булып, аларның берәрсен авызына капканчы, ачка үләрдер, мөгаен».

Кеше абсолют ирекле була алмый. Ә чикләгечләрнең берсе — башка кеше хокуклары һәм ирекләре.

«ИРЕК — МӘГЪНӘСЕ АҢЛАНГАН ЗАРУРИЛЫК УЛ»

Бу сүзләр немец философы Гегельныкы. Инде афоризмга әверелгән әлеге формула нәрсәне аңлата соң? Дөньяда бар нәрсә котылгысыз тәэсир итүче көчләргә буйсына. Бу көчләр кеше эшчәнлеген дә үзенә буйсындыра. Әгәр бу *зарурилык* кеше

тарафыннан фикерләнмәгән, аңланмаган булса, ул аның колы; әгәр ул танылса, кеше «эшне белеп карар кабул итү сәләте» ала. Аның ихтыярый иреге шунда чагыла да инде. Ләкин алар нинди көчләр, зарурилыкның табигате нинди? Әлеге сорауга төрлечә җавап бирәләр. Берәүләр монда Ходай кушканны күрә. Ул барысын да алдан билгеләп куя. Ул чакта кеше иреге нидән тора? Юк ул. «Аллаһының алдан күрүе һәм куәте безнең ихтыяр ирегенә диаметраль төстә капма-каршы. Барысы да котылгысыз нәтиҗәне кабул итәргә мәҗбүр булачак: без үз ирегебез белән берни дә кыла алмабыз, барысы да зарурилыктан килеп чыга. Шулай итеп, без ихтыярый иркебез белән берни эшләмибез, барысы да Ходайның алдан язып куюына бәйле»,— дип раслый дин реформаторы Мартин Лютер. Абсолют алдан билгеләнгәнлек тарафдарлары шул позицияне яклый. Бу карашка каршы буларак, башка дин эшлеклеләре Ходай билгеләгәннең һәм кеше ирегенең нисбәтен түбәндәгечә аңлатуны тәкъдим итә: «Аллаһы бөтен дөньяны барлык җан ияләренең бөек бүләккә — иреккә ия булырлык итеп яраткан. Ирек барыннан да элек яхшылык белән явызлык арасында мөстәкыйль рәвештә үзең, үзеңнең карарың нигезендә сайлауны белдерә. Әлбәттә, Аллаһы күз ачып йомганчы явызлыкны да, үлемне дә бетерә ала. Әмма болай эшләгәндә ул дөньяны иректән дә мәхрүм итәр иде. Дөнья Аллаһыга әйләнеп кайтырга тиеш, чөнки ул Аңардан үзе тайпылды».

«Зарурилык» төшәнчәсе башка мәгънәдә дә булырга мөмкин. Байтак философлар, зарурилык табигатьтә һәм җәмгыятьтә объектив (ягъни кеше аңыннан бәйсез) кануннар рәвешендә яши, ди. Башкача әйткәндә, зарурилык вакыйгаларның закончалыклы, объектив шартлар кушканча барышы ул. Бу позиция тарафдарлары, фаталистлардан аермалы буларак, дөньяда бар нәрсә, бигрәк тә җәмгыять тормышында, катгый һәм бер генә мәгънәдә билгеләп куелган дип санамый, алар очраклыклар да булуын кире какмый. Әмма очраклылык тарафыннан теге яки бу якка тайпылдырылучы гомуми закончалыклы үсеш юлы барыбер үзенә юл ярачак. Мисалларга мөрәҗәгать итик. Мәгълүм ки, сейсмик яктан куркынычлы зоналарда эзлекле рәвештә җир тетрәүләр булып тора. Бу хәлләрне белмәүче яисә аларны санга сукмаучы кешеләр, әлеге җирләрдә үз торакларын төзеп, куркыныч бәла-каза корбаны булырга мөмкин. Әлеге факт, әйтик, сейсмик яктан тотрыклы биналар төзегәндә исәпкә алынса, куркыныч ихтималы күпкә кимер иде.

Бәян ителгән позицияне гомумиләштерелгән төстә Ф.Энгельс сүзләре белән тасвирлап булыр иде: «Ирек ул табигать законнарыннан уйлап чыгарылган бәйсезлектә түгел, ә бу

законнарны тикшереп аңлауда һәм шул белемнәр нигезендә табигать законнарын планлы рәвештә мәгълүм бер максат өчен эшләргә мәҗбүр итү мөмкинлегендә».

ИРЕК ҺӘМ ҖАВАПЛЫЛЫК

Тагын бер вазгыятьне карап үтик. Хәзерге җәмгыять кешегә изелгән, депрессив хәлдән котылырга ярдәм итүче төрле чаралар бирә. Алар арасында кеше организмын рәхимсез җимерүчеләр (алкоголь, наркотиклар) дә бар. Үз юлын сайлаганда кеше андый куркыныч турында уйланмаска да мөмкин, ләкин аны котылгысыз «түләү» көтә, әле акча белән генә түгел, ә иң кыйммәтле нәрсә — үз сәламәтлеге, кайчакта гомере белән дә түләргә туры киләчәк.

Чын-чынлап ирекле кеше үзенең бер минутлык рәхәтенең колы булмый. Ул сәламәт яшәү рәвешен сайлый. Әлеге очракта, куркынычны аңлаудан башка, кешене тегеләй яки болай эш йөртергә билгеле бер иҗтимагый шартлар да этәрә. Әхлак һәм хокук нормалары, гореф-гадәтләр һәм җәмәгать фикере бар. Алар йогынтысы астында «үз-үзеңне тиешенчә тоту» моделе барлыкка килә. Кеше бу кагыйдәләрне исәпкә алып эш йөртә һәм хәрәкәт итә, тегеяки бу карарга килә.

Кешенең инде урнашкан социаль нормалардан тайпылышы, үзегез белгәнчә, җәмгыять ягыннан билгеле бер реакция тудыра. Тискәре тайпылыш социаль санкциягә, ягъни хупланмаучы гамәл өчен җәзага китерә. Мондый җәза бирүне «кешенең үз гамәле һәм аның нәтиҗәсе өчен җаваплылык» дип тә атыйлар. (Нинди очракларда җинаять, административ һәм башка төр җаваплылык барлыкка килүен исегезгә төшерегез.)

«Җаваплылык» төшенчәсе кешегә йогынты ясауның тышкы рәвешләре белән генә бәйле түгел, җаваплылык аның эшчәнлеген җайга салуның иң мөһим механизмы да булып тора. Без ул чакта җаваплылык хисе, бурыч турында сөйлибез. Ул барыннан да элек кешенең билгеләнгән нормаларны аңлы үтәүче, үз гамәлләрен аларның тирә-юньдәгеләр өчен нинди нәтиҗәләргә китерүе күзлегеннән бәяләргә санкцияләр кабул итәргә әзер булуында чагыла.

Психологлар тикшеренүләре күрсәткәнчә, күпчелек кешеләр үз гамәлләре өчен җаваплылык алырга әзер. Әмма җаваплылык хисе кимегән вазгыятьләр дә килеп чыга. Әйтик, кеше төркем эчендә шундый гамәлләргә — мәсхәрәле кычкыруларга, хокук тәртибен саклау вәкилләренә каршы торуга, рәхимсезлек һәм агрессиянең төрле чагылышларына — сәләтле

ки, башка хәлләрдә ул моңа һичкайчан юл куймас иде. Әлеге очракта чыгышларның массачыл булуы гына түгел, кеше эшчәнлегенең аноним характерда булуы да йогынты ясый. Шундый мизгелдә эчке чикләүләр йомшара, җәмгыять бәяләвенә карата борчылу кими. Үзендә җаваплылык хисе тәрбияләп, кеше үзен деиндивидуализациядән, ягъни түбән узаңлы, үз йөзе-төсе булмаган бер адәмгә әверелүдән саклый.

КЕШЕ ДӨНЬЯНЫҢ БӨТЕН АВЫРЛЫГЫН ҮЗ ҖИЛКӘСЕНДӘ ЙӨРТӘ

Без сезнең белән ирекне тышкы чикләүдән кеше үзе өчен үзе урнаштыра торган эчке тыюларга күчәбез. «Әгәр җан омтылу һәм каршы тору сәләтенә ия булмаса һәм бозыклык ирексездән килеп чыкмаса, мактау да, шелтәләү дә, данлау да, җәзалау да гадел булмас иде»,— дип раслый II — III гасырларда яшәгән христиан дине тәгълиматчысы Климент Александрийский (Тит Флавий).

Кеше тормышының тышкы шартлары нинди булуы иң мөһиме түгел. Аның аңында бу шартлар ничек чагыла, кеше үзен дөньяга ничек күрсәтә, үз алдына нинди шартлар куя, әйләнә-тирә чынбарлыкка нинди мәгънә бирә — шунысы әһәмиятле. Үз-үзеңне тотуны мөмкин вариантлар төрлелегеннән сайлап алуны нәкъ менә шул билгели дә инде. Шуннан чыгып заманабызның кайбер философлары мондый нәтиҗә ясый: кеше эшчәнлеге үз максатларын тыштан ала алмый; аңа карата мөнәсәбәттә берникди тышкы нәрсә аны мотивацияли алмый, эчке тормышында кеше тулысынча ирекле. Чын ирекле кеше үзенең гамәлен генә сайлап калмый, аның нигезен, үз гамәлләренең гомуми принципларын да сайлый, алар исә инану характеры ала. Мондый шәхес хәтта кешелекнең бетә баруы шартларында яисә үз илендә деспотлык яки тоталитар режимның тулы тотрыклылыгы шартларында да рухи түбәнлек халәтенә төшми, ә ул үзе яклаган принциплар киләчәктә һичшиксез тантана итәр кебек эш итәчәк.

Мондый позицияне тәнкыйтьләүчеләр, әгәр һәркем үз тәртибе нигезләрен фәкать үз инанулары нигезендә, гомуми кабул ителгән чикләү һәм тыюларны исәпкә алмыйча эзләсә, җәмгыять үзенең бөтенлеген югалтачак, һәм кешеләрне хаос көтә: үзләре теләгән ирек урынына алар тулы башбаштаклыкка киләчәк, диләр.

(Ә сезнең карашыгыз нинди? Бу позицияләрнең кайсы һәм ни өчен дөрес булып күренә?)

НӘРСӘ УЛ ИРЕКЛЕ ҖӘМГЫЯТЬ

Шулай итеп, «ирек» төшенчәсе төрлечә шәрехләнә, ә кайчакта капма-каршы аңлатыла. Төрлечә якын килүләрне фикерләп, нәрсәнедер кабул итеп, нәрсәнедер һичсүзсез кире кагып, сайлап алу булмау шартларында чын ирекле эшчәнлек мөмкин түгеллеге белән килешик. Ирек — барлык мөһим эшләрдә сайлап алу нигезендә эш итәргә сәләтле кешенең халәте ул.

Мондый сайлауны нинди җәмгыять тәэмин итә ала?

Аерым затлар яисә кешеләр төркеме башбаштаклыгы һәм тиранлыгы хакимлек иткән, законлылык бозылган, дәүләт тарафыннан үз гражданнары тормышына тулы (тоталь) контроль урнаштырылган җәмгыятьне ирекләр рәтенә кертергә ярамавы күренеп тора.

Дәүләтнең аерым кеше тормышына катнашы минималь булган җәмгыять кенә ирекле дигән сүзме бу? Көнбатышта күпләр фәкать шундый җәмгыять кенә чынлап та ирекле булырга мөмкин дип саный.

Мондый җәмгыятьнең икътисад өлкәсендә конкуренциягә нигезләнгән ирекле эшмәкәрлек хакимлек итә, ә сәяси даирәдә сәяси фиркаләр, фикер төрлелеге, дәүләт тормышының демократик принциплары яши. Моның асылы һәркемнең теләсә нәрсә язарга һәм сөйләргә хокукы булуында түгел, ә теләсә нинди идеянең фикерләшүгә куелу мөмкинлегендә. Төрле белемнәргә ия һәм төрле карашлар яклы кешеләрнең бу үзара хезмәттәшлек процессы фикер үсешенең нигезе булып тора. Кеше тормышы демократик кабул ителгән законнар һәм гомумтанылган әхлак нормалары белән генә көйләнә.

«Җәмгыять һәм дәүләт эшли алган бар нәрсә — тормышның бер генә тармагында да монополиягә юл куймыйча, ирекне кызыксындыру ул. Дәүләт катнашуыннан азат, үз теләкләре буенча эш итәргә ирекле индивидлар чәчәк атачак һәм аларның тормышы бәхетле булачак»,— дип язды Американың бер сәяси эшлеклесе.

Әмма Көнбатышта күпләр ирекле җәмгыятьнең мондый моделен кабул итми. Халыкның билгеле бер өлеше карашын чагылдырып, кайбер галимнәр, сәясәтчеләр мондый чикләнмәгән индивидуальлек кешегә файдага түгел дип саный. Чын ирек дәүләтнең кеше тормышына гади генә катнашмавыннан зуррак нәрсәне күздә тота. Кешенең үз-үзен реализацияләве индивидуаль тәҗрибәгә генә түгел, хәл итү юлларын бергәләшеп эзләү, гомуми муллык булдыру белән берләштерелгән тәҗрибәгә дә таяна. Шуңа күрә ирекка тагын кооперацияләү, җаваплылык, гаделлек, ягъни җәмгыять тәэмин итәргә тиешле шундый барлык кыйммәтләр өстәлә. Шулай итеп, җәмгыятьнең роле

аны күз алдына китерергә тырышканнан әһәмиятлерәк дип саный әлеге концепция яклылар. Җәмгыятькә берләшеп, кешеләр яңа кыйммәтләр генә түгел, аларга кайчакта соң чиккәчә кирәкле коллектив яклау да алалар.

Дәүләт тә мәгълүм бер җайга салучы ролен үтәргә тиеш. Аерым алганда, социаль һәм икътисади өлкәләрдә дәүләт керемнәрнең бертигез бүленүе турында кайгыртырга, ярлылар белән байлар арасындагы упкынның тирәнәюенә юл куймаска мөмкин. Азатлык идеалы тигезлек идеалын капларга тиеш түгел.

Шулай итеп, сайлау вазгыяте һәр кешенең шәхси тормышы «киңлегендә» генә урнашмый. Ул тулаем җәмгыять дәрәҗәсендә дә барлыкка килә. Бигрәк тә бу «күчеш чоры» дип аталган борылышта ачык чагыла. Кайбер тикшеренүчеләр фикеренчә, мондый дәвер алга таба үсешнең бөтен бер юнәлеш (альтернатива) спектрын эченә ала. Аларның кайсы, әйтик, ил җитәкчелеге тарафыннан хуплануы әлеге дәүләтнең барлык халкы тормышына хәлиткәч йогынты ясарга мөмкин. Бу очракта юл сайлау гаять югары җаваплылык белән бәйле. Мондый вазгыять мисалларын һәм кабул ителгән карар нәтиҗәләрен безнең өчен ерак һәм күптән түгел үткән тарих саклап калган.

ГАМӘЛИ ЙОМГАКЛАР

1 Ирекле җәмгыять — хәзерге заман дөньясының төп кыйммәтләренең берсе. Төп ирекләр һәм хокуклар барлык демократик дәүләтләр конституцияләренә кертелгән. Бу ирекләрне һәм хокукларны белү, алардан оста файдалану иҗтимагый тормышның төрле өлкәләрендә шәхес мөмкинлекләрен тулы гамәлгә ашыруның зарури шарты булып тора.

2 Әгәр дә сез ирекне теләсә нишләп йөрү дип күз алдына китерәсез икән, мөгаен, моның киресенә — катгый зарурилыкка яисә башбаштаклыкка юлыгырсыз. Беренчесен, сезнең башка кешеләр ирекен һәм хокукын кысучы «ирекле» гамәлләрегезне үз санкцияләре белән законлы кисәтеп, дәүләт кулланыр. Ә сезгә карата башбаштаклыкны сезнең кебек үк үзләрен барлык нормалар һәм чикләүләрдән азат дип санаучы, фәкать үз ихтыяҗлары һәм теләкләрен генә бар дип белүчеләр кулланыр, алар үз гамәлләре белән һичшиксез сезнең мәнфәгатьләрегезне таптаячак.

3 Үзегез өчен әһәмиятле мәсьәлә буенча карар кабул иткәндә, кагыйдә буларак, берничә реаль альтернативадан

сайлап алырга мөмкин булуын истә тотарга кирәк. Бу гамәлләрнең ихтимал «сценарий»ларын, үсеш вариантларын билгеләгез. Аларның һәркайсын анализлагыз, үзегезнең максат, омтылышларыгыз белән чагыштырыгыз, якын кешеләрегез мәнфәгатен исәпкә алыгыз. Шулай якын килгәндә, сез ясаган адым үкенечле булмас.

ДОКУМЕНТ

Без үзебезнең азатлык тойгысын ничек яклыйбыз. *Америка социаль психологы* ***Э.Аронсонның*** «Иҗтимагый җан иясе» дигән китабыннан.

Әгәр дә инандыручы мәгълүмат бәйләнчек булса, алар индивидуаль сайлап алу ирегe даирәсенә бәреп керү буларак кабул ителергә һәм шуның белән алардан яклану ысулларын эзләүне активлаштырырга мөмкин. Әйтик, әгәр кирәгеннән артык бәйләнчек сатучы мине үз товарын сатып алырга инандыра башласа, минем беренче эшем үз бәйсезлегемне саклау булачак: мин магазиннан чыгып китү ягын караячакмын.

Мондый каршылык төрлечә һәм кызыклы рәвешләрдә чагылырга мөмкин. Әйтик, мин урам буйлап барам, һәм мине әдәпле генә итеп ниндидер петициягә кул куярга өндиләр. Мин үзем имзаларга тиешле нәрсәне бик белеп тә бетермим. Ләкин миңа моны аңлатып торганда гына бер кеше килеп баса һәм, минем бернәрсәгә кул куймавымны таләп итеп, ачыктан-ачык басым ясый башлый. Бу басымга каршы тору максатында һәм үземнең сайлау ирегемне саклап, мин, мөгаен, бу петициягә кул куярмын.

Азатлыкка һәм автономиягә ихтыяҗның тагын бер аспекты бар. Башка шартлар тигез булганда, үзләренең инануларына каршы мәгълүматка юлыгып, кешеләр, әгәр бу мөмкин булса, каршы дәлилләр табарга тырыша. Шулай итеп, алар үз фикерләрен башкаларның кирәгеннән артык йогынтысыннан саклый һәм үз автономиясе хисен яклый ала.

Документка сораулар һәм биремнәр

1. Психолог фикеренчә, кешеләр ничек итеп үзләренең эчке ирекләрен һәм автономиясен яклыйлар? **2.** Өземтәдә тасвирланган кебек вазгыять сезнең белән булганы бармы? Мондый очракларда сез нишләдегез?

ҮЗ-ҮЗЕҢНЕ ТИКШЕРҮ ӨЧЕН СОРАУЛАР

1. «Ирек» төшенчәсе ничек итеп Яңа һәм Иң яңа тарихта сәяси көрәш белән бәйләнә? **2.** Чикләнмәгән сайлау ирекгә нәрсәгә китерергә мөмкин? **3.** Христиан дине тәгълиматында ирек ничек аңлатыла? **4.** Табигать зарурлыгының кешеләрнең ирекле эшчәнлегенә йогынтысын күрсәтегез. **5.** Иҗтимагый зарурилык нәрсәдә чагылыш таба? **6.** «Ирек», «сайлау», «җаваплылык» төшенчәләренең үзара ничек бәйләнгәнен аңлатыгыз. **7.** Нинди җәмгыятьне ирекле дип санарга мөмкин?

БИРЕМНӘР

1. Кешенең җәмгыятьтә абсолют, берни белән дә чикләнмәгән ирекгә мөмкин булмавы турындагы нәтиҗәне раслаучы дәлилләр китерегез.

2. Түбәндә китерелгән ике әйтемнең кайсы сезгә дөресрәк булып күренә?

«Безнең тормыш — табигать кушуы буенча без Җир шары өслегендә узарга, аннан бер генә мизгелгә дә аерылмаска тиешле юл ул».

«Гомер агышы үз инануларына хыянәт итүчеләргә генә тайпылышсыз булып тоела. Тарих үзлегеннән кешене әшәке эшләргә мәҗбүр дә, җәлеп тә итә алмый. Кеше дөньяның бар авырлыгын үз җилкәсендә алып бара: ул дөнья өчен дә, үзе өчен дә җаваплы».

3. «Ирек — сайлау ул» дигән гыйбарәне сез ничек аңлыйсыз?

4. Ирекле җәмгыятьнең төрле модельләрен характерлагыз. Андый җәмгыять турында сезнең күзаллавыгыз нинди?

5. Кайчакта ирек теләсә нишләү буларак аңлашыла. Ирекне болай аңлату нинди нәтиҗәләргә китерергә мөмкин? Җавабыгызны мисаллар белән ачыклагыз.

ЗИРӘКЛӘР ФИКЕРЕ

«Ирек — әгәр үзегез бирмәсәгез,
сез ала алмаган бердәнбер әйбер ул».

У.Уайт (1886–1944), Америка язучысы

§ 13. Иҗтимагый аң

Акыллы кешеләр җәмгыяте үзен акылсыз тотарга мөмкинме? Иҗтимагый аңны кем формалаштыра? Иҗтимагый аң кеше аңы белән ничек бәйләнгән?

ИЖТИМАГЫЙ АҢНЫҢ АСЫЛЫ ҺӘМ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

Җәмгыять тормышын характерлаучы категорияләрнең берсе булып иҗтимагый аң категориясе тора. Шул ук вакытта бу категориягә карата галимнәр арасында бердәмлек юк. Монда проблема башлангыч төшенчә — *аң* төшенчәсен төрлечә аңлау белән бәйләнгән.

Классик фәлсәфәнең күпчелек вәкилләре аң турындагы күзаллауны «белем» төшенчәсе белән тәңгәлләштерә. Без белгәннәрнең барысы да — ул аң, һәм без аңлаган нәрсәләр — белем.

Шул ук вакытта хәзерге заман психологиясе шуңа юлыкты ки, белемгә караган һәрнәрсә дә аңлашылмый. Белем — мин белгән, әмма хәзерге мизгелдә мин уйламаган, шуңа күрә аңламаган нәрсә генә түгел, мин җиңел генә үз аңым казанышы итә алган (әйтик, минем Пифагор теоремасын белүемне, үз биографиям фактларын һ.б.) искә төшерү дә ул.

Байтак философлар аңның төп билгесе сыйфатында белемне түгел, ә билгеле бер объектка юнәлгәнлекне аерып карый. Моның асылы шунда ки: кеше ниндидер бер объект турында берни дә белмәскә мөмкин, әмма, әгәр ул аны аерып караса, аңа үз мәнфәгатен юнәлтсә, бу объект аң объектына әверелә.

Философиядә һәм психологиядә аңны үзаң, үзхисап буларак аңлау иң киң таралыш алды. Ул инглиз фәлсәфәчесе Дж. Локкның ике белем чыганагы: тышкы дөнья белән бәйле сиземләүләр һәм акылның үз эшчәнлеген күзәтеп торуы буларак рефлексиясе турында теориясе белән бәйле. Локк буенча, соңгысы — аң ул. Болай аңлаганда, аң субъектны аңлап белүче махсус чынбарлык, аерым эчке дөнья буларак чагыла. Аңлап белү алымы булып үз-үзеңне күзәтү рәвешендә чагыла алучы үз-үзеңне зиһенгә кабул итү тора.

Аңның асылына тагын бер караш булып аны индивидуаль яисә күмәк идеяләр җыелмасы дип аңлау тора. Г.Гегель һәм К.Маркс, иҗтимагый аң, сыйнфый аң турында сөйләгәндә, «аң» төшенчәсен нәкъ менә шул мәгънәдә кулланганнар. Иҗтимагый аң төшенчәсе марксизм философиясендә киң куллану тапты.

Философия белемнәрен үстерү иҗтимагый аңны бербөтен һәм катлаулы рухи күренеш буларак аңлауны киңәйтүгә ярдәм итте. Җәмгыятьнең рухи тормышы дәвамында төрле белемнәр, шулай ук табигатькә, объектив чынбарлыкка, җәмгыятьтә булган бар нәрсәгә төрле карашлар формалаша. Моннан тыш халыкларның кәефе, гореф-гадәтләре, шулай ук төрле социаль төркемнәрнең психик караш үзенчәлекләре тамыр җәя.

Мәсәлән, америкалыларның эшлеклелеге яисә немецларның төгәллеге турында әйтелә. Шул ук вакытта әлеге төркемнәрнең барлык вәкилләре дә әлеге сыйфатларга ия түгел. Шуңа да карамастан бөтен социаль җәмәгатьчелеккә мәгълүм бер сыйфатлар берегеп калган.

Иҗтимагый аң формалаштыру — катлаулы процесс, анда ике факторның көчле йогынтысы чагылыш таба.

Бер яктан караганда, иҗтимагый аңда, рухи тормышта, кешеләрнең яңа идеяләргә, фәнни белемгә, җәмгыять әгъзаларын әхлакый камилләштерүдә, гүзәл, югары хисләр тәрбияләүдәге ихтыяҗларын канәгатьләндерүгә юнәлтелгән мәнфәгатьләре һәм эшчәнлеге чагыла. Икенче яктан, идея, тәгълимат, карашлар, әхлак нормасы, фәнни белемнәрнең киң таралуы, бөтен җәмгыятькә йогынты ясавы зарур. Бу функцияне мәктәп, югары уку йортлары, массакүләм мәгълүмат чаралары, сәяси фиркаләр, иҗтимагый хәрәкәтләр һәм оешмалар башкара.

Шуны да билгеләп үтәргә кирәк: иҗтимагый идея һәм иҗтимагый аңның башка элементлары матди характерда булмаса да, җәмгыятьтә эшли, төрле тамгалар системасы ярдәмендә аерым кешеләр, төркем, берләшмәләр аңына йогынты ясый.

Галимнәр *иҗтимагый аңның чагыштырма характерда булуын* таный. Эш шунда ки: күп кенә идеяләр, кешеләрнең карашы, аларның әхлакый инанулары гаять тотрыклы, тормышчан һәм кеше аңында, аларның гамәлләрендә шактый озак саклана. Алар үзләре барлыкка килгән объектив шартлар, иҗтимагый мөнәсәбәтләр инде юкка чыккач та сакланып калырга мөмкин. Бу кешеләрнең карашы, инанулары, мәсәлән, икътисади көнкүреш яисә сәяси мөнәсәбәтләр үзгәрүгә үк башкача була алмаганга шулай. Кешеләрнең аңы, идеяләре, карашлары иҗтимагый көнкүрештә беркадәр артка кала һәм билгеле бер вакыт аңа туры килмәскә мөмкин. Мондый артка калу очрагында сүз йә кеше күңелендә үткәннәрнең «озак яшәве» турында, йә гореф-гадәтләрнең саклануы хакында бара. Әйтик, сезгә мәгълүм булганча, крепостной хокукны бетергәннән соң, крестьяннарның бер өлеше шактый вакыт яңа икътисади һәм социаль чынбарлыкка бик авыр күнегә. А.П.Чеховның «Чия бакчасы» пьесасы персонажы Фирсны гына искә төшерү дә җитә, ул әлеге вакыйганы бәхетсезлек, бәла дип атый. Кешеләр идеясе һәм карашлары реаль шартларны *узып китәргә* дә мөмкин, ул чакта мондый идеяләрнең социаль хыялны, фаразларны, алдан күрүне чагылдыруы хакында сөйлиләр. Социаль-утопиячеләрнең мондый фаразлары сезгә тарих курсыннан билгеле.

Иҗтимагый аң иске җәмгыятьнең рухи тормышында булган барлык яхшыны, файдалыны һәм кирәклене *дәвам итү* сәләтенә ия. Дәвамчанлык фәндә, әхлакта, халыклар гореф-гадәтләрендә ачыктан-ачык чагылыш таба. Иҗтимагый аңның күп кенә чагылышлары үзара хезмәттәшлек итә, бер-берсенә көчле йогынты ясый. Әйтик, кешеләрнең эстетик зәвыгы һәм омтылышы аларның әхлакый идеалы белән тыгыз бәйләнгән. Гүзәллек идеалы еш кына бер үк вакытта кешеләр өчен игелек идеалы да булып тора, һәм, киресенчә, әхлакый идеал белән бәйле нәрсә бик күркәм буларак кабул ителә.

Иҗтимагый аң җәмгыятьнең бөтен тормышына актив йогынты ясый. Әмма бу йогынты үзлегеннән генә булмый, ә кеше эшчәнлеге аша барлыкка килә. Кеше гамәле җәмгыять тормышына прогрессив йогынты да ясый ала, һәм, киресенчә, тоткарларга да мөмкин. Бу теләсә нинди җәмгыятьтә төрле идеяләр булуыннан килә — яңалары да, искеләре, алдынгы һәм консервативлары да; мондый хәл, һичшиксез, иҗтимагый аңның халәтендә чагыла.

ИҖТИМАГЫЙ АҢНЫҢ СТРУКТУРАСЫ

Иҗтимагый аң үзенең эчтәлеге буенча гына түгел, структурасы буенча да катлаулы. Шуңа бәйле рәвештә аны структур элементларга бүлү төрле нигездә үткәрелергә мөмкин. Шундый нигезләрнең берсе булып чынбарлыкның иҗтимагый аң чагылдырган яклары махсуслыгы хезмәт итәргә мөмкин, һәм ул чакта без аның рәвешләре хакында сөйлибез. Иҗтимагый аңның әлеге рәвешләренең һәркайсы махсус үзенчәлеккә ия, җәмгыять көнкүреше катлаулылыгын, аның аерым якларын, җәмгыять тормышы процессларын үзенчә чагылдыра, аларның үз иҗтимагый билгеләнеше һәм үз функцияләре бар.

Философия дөньяга караш, танып белү функциясен башкара. Ул кешеләргә абстракт, теоретик нигезләмәләр, иң гомуми төшенчәләр һәм категорияләр белән фикер йөртергә ярдәм итә.

Сәяси аң социаль төркемнәргә, җәмгыять әгъзаларына хезмәт күрсәтә, сәяси идея, максатларны нигезли, шулай ук сәяси һәм хокукый мәнфәгатьләргә, юридик норма, законнарга, максатка ирешү стратегиясе һәм тактикасына нигез булдыра.

Хокукый аң хокукны белүне генә түгел, аңа мөнәсәбәтне, аны социаль кыйммәт буларак хөрмәт итүне белдерүче күзаллаулар һәм тойгылар җыелмасы, шулай ук, хокук күзлегеннән караганда, хупланучы тәртип күнекмәсен үзләштерү ул.

Әхлак җәмгыятьнең әхлакый принципларын, үз-үзен тоту

нормаларын, кешедә әхлакый хисләр формалаштыру алымнарын эченә ала.

Сәнгать җәмгыятьтә эстетик аң, чынбарлыкка эстетик караш, гүзәллеккә, бөеклеккә мәхәббәт формалаштыра, аны иҗат итәргә һәм сакларга этәрә.

Фән иҗтимагый аңны законнар, теорияләр рәвешендә чагылдыра, кешеләрне фәнни белемнәр, чынбарлыкны, процессларны, вакыйгаларны дөрес аңлау белән коралландыра, фактлар туплау һәм аларны теоретик аңлату белән шөгыльләнә, кешеләрне фәнни гипотезалар белән коралландыра һ.б.

Дин дини аң, дини идеяләр, Аллаһыга, җанның үлемсезлегенә ышану, дини әхлак формалаштыра.

ИҖТИМАГЫЙ ПСИХОЛОГИЯ ҺӘМ ИДЕОЛОГИЯ

Иҗтимагый аң структурасы социаль иҗтимагый аңның чынбарлыкны чагылдыру дәрәҗәсе, тирәнлеге күзлегеннән каралырга мөмкин, шул чакта төп структур элементлар сыйфатында иҗтимагый психология һәм идеология аерылып чыга.

Иҗтимагый психология — әлеге җәмгыять өчен тулаем һәм зур социаль төркемнәрнең һәркайсы өчен характерлы хисләр, карашлар, гореф-гадәтләр, омтылышлар бергәлеге.

Иҗтимагый аң социаль көнкүрешнең анык тарихи шартлары йогынтысында үсеп чыга. Эре социаль төркемнәрнең һәркайсы өчен бу шартлар төрлечә булганлыктан, аларның социаль-психологик комплекслары да (мәсәлән, Урта гасырлардагы «затлы катлауларның» «кара халыктан» өстенлеге комплексы) һичшиксез аерылып тора. Аңлашыла ки, һәр илдә төрле социаль төркемнәр социаль-психологик комплексларында аларның тарихи үзенчәлекләре, милли традицияләре, мәдәни дәрәҗәсе белән бәйле уртак сыйфатлар бар.

Киңрәк мәгънәсендә **идеология** — кешеләрнең чынбарлыкка һәм бер-берсенә мөнәсәбәте, шулай ук социаль эшчәнлек максатлары булып аңлашылучы һәм бәяләнүче теоретик карашлар системасы. Ул иҗтимагый психология белән чагыштырганда югарырак иҗтимагый аң дәрәҗәсе — дөньяны теоретик чагылдыру дәрәҗәсен гәүдәләндерә. Әгәр социаль төркемнәр психологиясен анализлаганда, яшькә, һөнәргә һ.б. бәйле эпитетлардан аермалы буларак, еш кына «иҗтимагый» эпитеты кулланcалар, «идеология» төшенчәсе мондый эпитетка мохтаҗ түгел, чөнки индивидуаль идеология юк, ул һәрвакыт иҗтимагый характерда.

Шуны да күз уңында тоту зарур: «идеология» төшенчәсе социаль философиядә тагын бер, таррак мәгънәдә — бер зур социаль төркемнең төп мәнфәгатьләрен чагылдыручы теоретик карашлар системасы буларак кулланыла.

Әгәр иҗтимагый психология очраклы төстә, иҗтимагый төркем, сыйныф яшәгән тормыш хәлләре йогынтысында формалашса, идеология нигездә әлеге төркем, сыйныфның «аерым вәкаләтле» вәкилләре — аның идеологлары продукты буларак чыга.

Иҗтимагый психология һәм идеология арасындагы чагыштырманы иҗтимагый аңның эмоциональ, хисси һәм рациональ дәрәҗәләр арасындагы чагыштырмасы буларак карарга мөмкин. Мәгълүм ки, хисси танып белү аңның гомуми җитәрлек булмаган (өстән-өстән), әмма зарури дәрәҗәсе, чөнки фәкать шуның аркасында гына безнең баш мие дөнья турында башлангыч мәгълүмат ала һәм аңардан әйбернең асылы турында белем синтезлый. Иҗтимагый идеология — тиешле идеология килеп чыксын өчен үзенә күрә бер нигезне тәшкил итүче тышкы социаль чынбарлык күренешләренең турыдан-туры чагылышы ул. Идеология психология тарафыннан буталчык кына кабул ителгән нәрсәне ачыклый, күренешләренең асылына тирән үтеп керә. (Идеологиянең нәрсә икәнлеген без киләсе параграфта карарбыз.)

Фәлсәфи һәм тарихи әдәбиятта еш кына *гадәти аң* һәм *массачыл аң* төшенчәләре очрый. Аларның атамаларыннан күренгәнчә, бу төшенчәләр иҗтимагый аңның төрле якларын характерлау өчен билгеләнә. Гадәти аң турында, гадәттә, ул теоретик гомумиләштерүгә кадәр күтәрелмәгәндә сөйлиләр, массачыл аң турында — аның җәмгыятьтә таралу дәрәҗәсе хакында әйткәндә.

Тарихи үсешнең барлык этапларында социаль-психологик фактор актив роль уйный. Мәсәлән, иҗтимагый карашларның социаль революция өлгерүгә алып баруын төгәл күзәтергә мөмкин. Радикаль үзгәрешләрдән соң җәмгыятьне тотрыклыландырырга мөмкинлек бирүче нәкъ шундый ук психологик факторлар бар. Әйтик, колбиләүчелектән феодолизмга күчү процессын анализлап, Ф.Энгельс түбәндәгеләргә игътибар итә: «Коллык үзен акламый башлады һәм шуңа үлде. Ләкин үлеп баручы коллык ирекленәрнең җитештерүчән хезмәткә мәсхәрәле карашы рәвешендәге үзенең агулы угын калдырды. Бу Рим дөньясы килеп эләккән чыгу юлы булмаган тупик иде: коллык икътисади яктан мөмкин түгел, ә ирекләләр хезмәте әхлак күзлегеннән мыскыл булып саналды. Беренчеләре иҗтимагый җитештерүнең төп формасы булудан туктады, ә икенчесе әле була алмый иде» (Маркс К., Энгельс Ф. соч.—

21 т.— 149 с.) Коллыкка мөнәсәбәт бу очракта җәмгыятьтә мөнәсәбәтләр формалашуга йогынты ясаган психологик мизгелне характерлый.

ИНДИВИДУАЛЬ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ АҢ

Иҗтимагый аңның асылын һәм структурасын карап, аның аерым шәхес аңына нисбәте проблемасына мөрәҗәгать итик.

Иҗтимагый аң да, шәхси аң да — рухи эшчәнлек продукты, рухи мәдәният синонимы. Бу мәгънәдә аларның бердәмлеге турында сөйлиләр. Индивидуаль һәм иҗтимагый аң арасында *катгый чикләр юк*. Киресенчә, алар арасында даими үзара хезмәттәшлек булып тора.

Иҗтимагый аң аерым шәхесләр аңыннан башка була алмый. Шәхси идеяләр һәм инанулар гомуми байлык, гомуми кагыйдә яисә инануга әверелгәч, гомуми аңга, әхлакка, сәнгатькә, фәнгә, хокукка, үз-үзеңне тоту нормасына кергәч, иҗтимагый кыйммәт характеры социаль көч әһәмияте ала. Бу вакытта теге яки бу идея авторының индивидуаль биографиясе хәлиткеч роль уйнамый. Әйтик, мәгълүм бер шартларда тәкъдим ителгән «иҗтимагый килешү» яисә «хакимиятләр бүленүе» идеясе авторлыгын югалтмаган, әмма иҗтимагый аңның мөһим өлешенә әверелгән.

Ләкин җәмгыять индивидуаль аң эшчәнлеге нәтиҗәләренә сайлап кына мөрәҗәгать итә: нәрсәнедер кабул итә, нәрсәнедер читкә ташлый. Индивидуаль аңның барлык казанышлары да иҗтимагый аңның гомуми массивына керә алмый. Бу әлеге шәхеснең рухи эшчәнлеге тирәнлегенә һәм социаль әһәмиятенә, аның иҗатына замана рухы ихтыяҗы булуга бәйле.

Үз чиратында индивидуаль аң да шул рәвешле эш итә. Ул иҗтимагый аңның барлык элементларын да кабул итми. Җәмгыять тарафыннан тарихи эшләнгән аң нормалары шәхесне тулыландыра, әхлакый күрсәтмәләр, инанулар, эстетик хисләр һәм күзаллаулар чыганагына әверелә. Ләкин кешеләр иҗтимагый аңда яшәп килгән элементларны төрлечә кабул итә (шәхси, индивидуаль үзенчәлекләре аркасында), иҗтимагый аңга төрлечә йогынты ясый ала.

Дж. Бруно, Г.Галилей, Жанна д'Арк кебек тарихи шәхесләр, күп кенә замандашларыбыз язмышы шәхси һәм иҗтимагый аң арасында, җәмгыятьтә кабул ителгән рухи принциплар һәм теге яки бу җәмгыятьнең аерым гражданы идеяләре арасында каршылыклар булуы хакында сөйли. Шул ук вакытта үз чорларын узып киткән шәхесләр, вакыт каршылыгын җиңеп, иҗтимагый аң үсешенә үз өлешләрен кертәләр.

Иҗтимагый аң индивидуаль аңнарның санча суммасына гына кайтып калмаган кебек, индивидуаль аң да иҗтимагый аңның төгәл күчермәсе була алмый. Кеше иҗтимагый аң белән бәхәскә керә, һәм бу аңа каршы торучы аң — аның белән санашырга туры килерлек чынбарлык. Шәхси аң — аккумуляцияләнгән тәҗрибә ул. Кеше, индивид үз гаиләсе, иле, үз халкы тарихы белән бәйләнешләрен тоярга мөмкин. Һәр индивидуаль аңның үз үсеш чыганагы бар, шуңа күрә, аны интеграцияләүче кешелек мәдәниятенең берлегенә дә карамастан, һәр шәхес уникаль.

Индивидуаль һәм иҗтимагый аң белән беррәттән җәмгыятьнең рухи тормышын *массачыл аң* да чагылдыра. Бу төшенчә белән җәмгыять тормышының массалар кызыксынуын китереп чыгарырга сәләтле билгеле бер якларын чагылдыручы иҗтимагый аңның, идея, күзаллаулар, ә кайчакта хәтта иллюзияләр, хисләр, карашларның киң бергәлеген билгеләү кабул ителгән.

Социаль чынбарлык фактларына һәм вакыйгаларына төрле төркемнәр мөнәсәбәтен чагылдыручы (ачыктан-ачык яки яшертен) массачыл иҗтимагый аң халәтен *җәмәгатьчелек фикере* дип атыйлар. Җәмәгатьчелек фикере — нинди дә булса социаль төркем вәкилләренең күбесенең, хәтта күпчелегенең дә булырга мөмкин, ләкин барысының да түгел, фикере ул, дияргә мөмкин. Җәмәгатьчелек фикеренең асылы турында француз социологы Ж. Бурдо әйткәннәр кызыклы. Ул җәмәгатьчелек фикерен тышкы гәүдәләнешен үзен-үзе аңлау аша алып, «аерым бер мәсьәлә буенча күпчелек индивид чыгарган фикерләр охшашлыгы»ннан килеп чыгучы социаль көч дип атый. Хәзерге заман дөньясында иҗтимагый аң актив өйрәнелә; җәмгыятьтә танылу алырга һәм хуплауга ирешергә омтылып, аңа сәясәтчеләр дә игътибар бирә. Ә Америка иҗтимагый фикер институты җитәкчесе Джордж Гэллап, «җәмәгатьчелек фикере — социологик тикшеренүләр белешмәләре генә ул» дип раслый. Әлбәттә, соңгы әйтемне парадоксаль арттыру дип атарга мөмкин булыр иде, әмма анда өлешчә хаклык та бар, чөнки иҗтимагый аңны формалаштыруда түбәндәге этапларны бүлеп карыйлар: фикер туу, фикер буенча дискуссия, гомуми караш һәм бердәм позициянең барлыкка килүе. Социаль тормышның күп кенә күренешләре башта гаҗәпләнү, аннан соң җанлы фикер алышу китереп чыгара, инде килеп шундый гадәтигә әверелә, алар турында бәхәсләшү мәгънәсезлеккә кайтып кала. Мәсәлән, Америкада коллыкны бетерү һәм Россиядә крепостнойлык хокукыннан баш тарту белән шулай килеп чыга. (Бу мисалларны сез үзегез дә дәвам итә алыр идегез.)

ГАМӘЛИ ЙОМГАКЛАР

1 Иҗтимагый фикер йогынтысында гамәлләр кылып, тирә-юньдәгеләр йогынтысына бирелеп, иҗтимагый психология белән нинди иҗтимагый мәнфәгатьләр идарә итүен аңлау бик мөһим.

2 Иҗтимагый аңда төрле социаль төркемнәр, бергәлекләрнең каршылыклы мәнфәгатьләре чагыла. Билгеле бер төркем вәкилләре гамәлләрендә этәргеч бирүче көч һәм омтылышны күрү мөһим. Чынбарлыкны эмоциональ кабул итү еш кына аның асылын дөрес аңларга комачаулый. Бөек А.С.Пушкинның «Мактауны һәм тәнкыйтьне битараф кабул ит һәм тинтәк белән бәхәсләшмә» дигән сүзләрен онытмаска киңәш итәбез.

3 Шәхеснең индивидуаль аңында алдынгы идеяләр дә, иҗтимагый аңда яшәп килгән искергән фикер һәм ялгышулар да чагыла. Исегездә тотыгыз: яшь булу әле ул чынбарлыкны кабул итү сафлыгы гарантиясе түгел. Яшь кеше аңында да үткәннәр калдыгы булырга мөмкин.

4 Массачыл аң дәрәҗәсендә калсаң, бик җиңел генә популяр идеяләрдә манипуляция һәм спекуляция объектына әверелергә мөмкин. Моны булдырмас өчен, массачыл аңның табигатен аңлау, аның җитешсезлекләрен һәм каршылыкларын күрү һәм бәяләү бик мөһим.

ДОКУМЕНТ

*Француз психологы, социологы, тарихчысы **Г. Лебонның*** «Халыклар һәм массалар психологиясе» китабыннан.

Халык төркемендә акыл түгел, тинтәклек кенә тупланырга мөмкин...

Төркемгә хас булган һәм аның составына керүче аерым индивидларда очрамаган яңа махсус сыйфатлар... барлыкка килү төрле сәбәпләрдән тора. Аларның беренчесе шуннан гыйбарәт ки: кеше саны күп булганга, индивид үзендә җиңеп булмаслык көч сизә, һәм моны тою аңа үзе генә булганда беркайчан юл куймаслык инстинктларга рөхсәт бирә. Төркемдә ул бу инстинктларын йөгәнләми, чөнки төркем ул аноним һәм җаваплылыктан азат иткәндәй була. Аерым индивидларны тоткарлап килгән җаваплылык хисе төркемдә бөтенләй юкка чыга.

Икенче сәбәп — йогышлылык — шулай ук төркемдә махсус сыйфатлар барлыкка килүгә этәргеч бирә һәм аның юнәлешен билгели... Төркемдә хисләр, гамәлләр йога; бу шундый дәрәҗәгә җитә ки, индивид үзенең шәхси мәнфәгатьләрен күмәк мәнфәгатьләр хакына җиңел генә корбан итәргә мөмкин. Әмма үз-үзеңне болай тоту кеше табигатенә каршы килә, һәм кеше моңа үзе төркемнең бер өлеше булганда гына сәләтле.

Документка сораулар һәм биремнәр

1. Халык төркемендә кешенең үз-үзен тотышында нинди үзенчәлекләр ачыла? 2. Шәхеснең төркемдә текст авторы атаган үзенчәлекле тәртибе сәбәпләрен күрсәтегез. 3. Әлеге сәбәпләрнең асылын сез ничек аңлыйсыз? 4. Төркемнең аерым шәхес ия була алмаган сыйфатлары булуы турында автор фикерен раслаучы яки кире кагучы мисаллар китерегез. 5. Төркемдә иҗтимагый аң, җәмәгатьчелек фикере формалаша дип раслау дөресме? Җавабыгызны дәлилләгез.

ҮЗ-ҮЗЕҢНЕ ТИКШЕРҮ ӨЧЕН СОРАУЛАР

1. Аңның асылы дигәндә, төрле караш тарафдарлары нәрсә аңлый? 2. Иҗтимагый аң һәм рухи мәдәният үзара ничек бәйләнгән? 3. Иҗтимагый аңның төп сыйфатларын характерлагыз. 4. Иҗтимагый аңның төрле рәвешләренә характеристика бирегез. 5. Иҗтимагый аңда нинди дәрәҗәләрне аерып карыйлар? 6. Иҗтимагый психология һәм идеология ни белән аерыла? 7. Иҗтимагый аң һәм индивидуаль аң үзара ничек бәйле?

БИРЕМНӘР

1. Язучы В.Б.Шкловскийның: «Сәнгать дөньяга төрлечә карауны күздә тота. Дөньяны төрлечә кабул итүдән куркырга кирәкми. Дөнья, әлбәттә, берәү генә. Әмма без күбәү бит»,— дигән сүзләрендә, иҗтимагый аңның төрле формалары буларак, нинди үзенчәлекләре чагылдырыла? Сез язучы белән килешәсезме? Җавабыгызны аңлатыгыз.

2. Л.Н.Толстой сәнгатьне «образларда, тойгыларда тасвирланган шәхси тормыш тәҗрибәсе — гомумиләштерүгә дәгъва кылучы шәхси тәҗрибә» буларак характерлый. Л.НТолстой карашын В.Б.Шкловский позициясе белән чагыштырыгыз, нәтиҗә ясагыз.

3. Г.Гегель гадәти аң турында «бу кайсы да булса чорның шул вакыт өчен хас булган барлык карашлар яшәп килгән фикерләү сәләте» ди. Философ әйткәннәрне үз мисалларыгызда күрсәтегез.

4. Танылган халыкара журналист Вс.Овчинников фикеренчә, инглизләр «законнар халыкның тәртипсез өлешен дилбегәдә тотар өчен дә, хакимиятнең гаделсезлек күрсәтү очраганда кешеләр таяныр өчен дә кирәк» дип ышаналар. Авторның «үз хокукларын бик яхшы аңлау — инглизләрнең милли сыйфаты» дияе белән килешергә мөмкинме? Җавабыгызны дәлилләгез.

ЗИРӘКЛӘР ФИКЕРЕ

«Аң — шундый чара ки, аңардан тыш белем дә, тәҗрибә дә, кеше яшәеше дә юк...»

К.Ясперс (1883–1969), немец философы

§ 14. Сәяси аң

Кешеләр сәяси тормышта һәрвакыт аңлы рәвештә катнашамы? Нигә сәясәткә төрле карашлар яшәп килә? Сәяси тормышка анда катнашучыларның психологик үзенчәлеге йогынты ясыймы? Кешеләрнең аңы һәм тәртибе белән кем манипуляцияли ала?

Сезнең белүегезчә, сәяси аң — иҗтимагый аң рәвешләренең берсе. Ул — сәяси процесста катнашучының бу процесска һәм үзенең андагы роленә карата булган фикер һәм тойгылары. Сәяси тормыш, сәяси институтлар эшчәнлеге, сәяси вакыйга һәм сәяси карарлар социаль бергәлекләр — сыйныф, милләт, социаль төркем, шулай ук индивидлар тарафыннан төрлечә кабул ителә. Барлык сәяси күренешләр сәясәт турындагы күзаллауларда, хисләрдә, фикерләүдә чагылыш таба.

«Сәяси аң» төшенчәсе «сәяси белем» төшенчәсенә тәңгәл түгел. Бу кешеләрнең башындагы *сәяси чынбарлык чагылышы образы* гына түгел, аларның әлеге чынбарлыкка *мөнәсәбәте* дә. Бу — объектив сәяси шартларга һәм үз эшчәнлеге рәвешләренә, кешеләрнең тормышта үз функциясе һәм роленә субъектив эчке мөнәсәбәте, ул гына да түгел, кызыксынулы, хисси мөнәсәбәте. Аның нигезендә — сәяси процесста катнашучылар өчен сәяси мөнәсәбәтләрнең, институтларның, норма, вакыйгаларның уңай яисә тискәре әһәмияте (гамәли кыйммәте, актуальлеге). Сәяси аң төрлечә формалаша һәм дөньяны ике дәрәҗәдә — гадәти-гамәли һәм идеологик-теоретик дәрәҗәдә үзенчәлекле чагылдыра.

ГАДӘТИ ҺӘМ ТЕОРЕТИК АҢ

Гадәти сәяси аң бар кешедә дә очраклы рәвештә, көндәлек тормышта, гамәли эшчәнлектә формалаша. Төрле сәяси институтлар, социаль көчләр белән үзара мөнәсәбәткә кереп, сәяси процессларга тартылып, сәяси вакыйгалар аша үтеп, кешеләр сәяси тормышны танып белә, аларда сәяси күренешләргә, сәясәт эшлеклеләренә мөнәсәбәт формалаша, гамәли тәҗрибә, күзаллау, хис, гадәт барлыкка килә. Кеше аңында турыдан-туры күзәткән, сәяси тормышның өстендә генә булгандай тоелган нәрсәләр чагыла. Гадәти аңда сәяси психология сизелерлек урын ала. Бу — сәяси хисләр, кәеф, фикерләр, кыйммәти юнәлеш һәм бәяләү фикерләве; аларда сәяси тормышны, анда әлеге индивидның, билгеле бер кешеләр төркеменең ролен эмоциональ кабул итү чагыла.

Гадәтидән аермалы буларак, идеологик-теоретик аң күз белән күреп кабул итү чигеннән чыга, сәяси тормышның җитди факторларын һәм тенденцияләрен төшенчәләр, гомумиләштерүче нәтиҗәләр, сәяси идеяләр системасында эчке закончалыклы бәйләнешләрне чагылдыра. Гадәти аң очраклы барлыкка килсә, теоретик аң исә галимнәр, идеологларның квалификацияле эшчәнлеге нәтиҗәсе булып тора. Әгәр дә гадәти дәрәҗәдә аң эзлексез, мозаика сыман, каршылыклы булса, теоретик дәрәҗәдә ул сәяси күренешләрне яисә идеологик доктриналарны системага салынган фәнни-теоретик аңлату рәвешен ала. Сәясәтне фәнни тикшерену «сәясәт белеме» дигән фән барлыкка китерә. Сәясәтнең нинди дә булса субъектының (сыйныф, милләт, җәмгыять, иҗтимагый хәрәкәт, партия) төп мәнфәгатьләрен, дөньяга карашын, идеалларын гәүдәләндергән идеяләр һәм карашлар системасы «идеология» дип атала. Ул социаль-сәяси теорияләр, сәяси партияләрнең программ документлары, лозунглар рәвешендә чагыла.

Гадәти һәм теоретик аң арасында үтеп булмаслык чик юк. Ул бер үк сәяси аңның төрле баскычлары гына; алар үзара бәйләнештә тора, бер-берсенә йогынты ясый. Индивидларның гадәти аңы сәясәт фәнен өйрәнгәндә, идеологияне кабул иткәндә азмы-күпме дәрәҗәдә үзгәрә. Сәяси аң тулаем алганда сәясәтнең һәр субъекты сәяси тәртибен билгели.

ИДЕОЛОГИЯ НӘРСӘ УЛ

XVIII гасырда барлыкка килгән «идеология» термины башта «идеяләр турындагы фән»не аңлата (чагыштырып карыйк: геология — җир турындагы фән, зоология — хайваннар дөньясы турындагы фән һ.б.). Ә «идея» сүзе грекларда килеп

чыккан, тәрҗемәсе — төшенчә, күзаллау. Әмма тора-бара «идеология» сүзенең мәгънәсе үзгәрә. Хәзерге заман фәнендә сәяси идеология дип теге яки бу затлар төркеменең башлыча системага салынган, сәяси хакимият ярдәмендә яисә аңа йогынты ясап, аларның мәнфәгатьләрен һәм максатларын чагылдыручы, шуңа хезмәт итүче карашлары аңлашыла. Социаль мәнфәгатьләр халыкның теге яки бу төркеме җәмгыятьтә нинди урын алып торуга бәйле. Аларның һәркайсы рухи һәм матди байлыкларга үз ихтыяҗларын иң тулы канәгатьләндерелерлек иҗтимагый шартлар булдырырга тырыша. Төрле социаль төркемнәрнең җәмгыятьтәге урыны сизелерлек аерылып торганга, аларның мәнфәгатьләре дә туры килмәскә, ә еш кына капма-каршы булырга мөмкин. Димәк, җәмгыятькә һәм аның үсешенә төрле төркем мәнфәгатьләрен чагылдырган карашлар, иң яхшы иҗтимагый корылыш турындагы күзаллаулар бертөрле була алмый. Чыннан да, XVIII гасырда Франциядә «өченче катлау»ны тәшкил иткән кешеләр яшәп килгән иҗтимагый шартларга баштагы ике катлау — дворяннар һәм руханилар кебек үк карый алалар идеме? XIX йөздә ялланып эшләүчеләрнең фабрика тәртипләренә аларның хуҗасы кебек үк мөнәсәбәттә булуы мөмкин идеме?

Яшәп килүче хәлләргә үз әсәрләрендә төрле катлау, сыйныф, теге яисә бу социаль катлау позициясеннән чыгып бәя бирүче фикер ияләре барлыкка килә. Әлеге төркем мәнфәгатьләрендә, алар җәмгыятьтә мәгълүм үзгәрешләр кертергә тәкъдим итә. Башкача әйткәндә, мондый әсәрләрдә «идеология» дип атау кабул ителгән карашлар, идеяләр, идеаллар бәян ителә, ә аларның авторларын «идеологлар» дип атыйлар. Әйтик, XVIII гасырда Франциядәге «өченче катлау» мәнфәгатьләре Вольтер, Дидро, Монтескье әсәрләрендә чагылыш таба, ә XIX гасырдагы ялланган эшчеләр мәнфәгатен үз хезмәтләрендә К.Маркс яклый.

Безнең чорда җәмгыять күп социаль төркемнәрдән тора. Алар мәнфәгате төрле идеологияләрдә чагылыш таба. Сәяси идеология әлеге социаль төркемнең сәяси тормышка карашын күрсәтә, аның хакимияткә, төркем мәнфәгатьләрендә аннан файдалануга дәгъвасын нигезли. Ул түбәндәге сорауларга җавап бирә: дәүләт хакимияте нинди булырга тиеш? Ул нинди сәясәт үткәрергә тиеш? Бу — төшенчәләр һәм идеяләр системасы, анда сәясәтнең аерым бер субъекты үз аңында сәяси тормышны чагылдыра, үз сәяси позициясен аңлый һәм үз мәнфәгатьләре өчен көрәш юнәлешләрен күрә. Сәяси идеология эчтәлеген дәүләт хакимиятен аңлату, төрле партияләргә, массачыл хәрәкәтләргә, башка дәүләтләргә мөнәсәбәт тәшкил итә. Анда идеаллар, иң яхшы җәмгыять төзелеше, принциплары, социаль үзгәртеп кору ысуллары һәм чаралары турындагы күзаллаулар

беркетелә. Җәмгыять тормышы турында аерым-аерым күзаллаулардан торучы гадәти дөньяга караштан аермалы буларак, идеология системалаштырылган, бербөтен төшенчәләр, идеяләр, бәяләүләр җыелмасыннан гыйбарәт.

Заманабызның күп кенә тикшеренүчеләре идеологияне сәясәтнең мәгълүм субъектлары кыйммәтләре системасын теоретик нигезләү дип аңлыйлар. *Кыйммәт* — әйләнә-тирә дөнья объектларының кеше, төркем, сыйныф, җәмгыять өчен уңай яки тискәре әһәмияте ул. Бер кеше өчен зур кыйммәте булган нәрсә икенче кеше өчен бөтенләй кирәге булмаска, ә кайчакта тискәре мөнәсәбәт тудыручы «антикыйммәт»кә әверелергә мөмкин. Әйтик, берәүләр өчен монархияле дәүләт — зур кыйммәт, ә икенчеләргә республика гына кирәк. Кыйммәт — ул объектларның үзенчәлеге түгел, ә аның кешеләр эшчәнлеге даирәсенә, алар ихтыяҗлары һәм мәнфәгатьләренә кергәнлеге нәтиҗәсе. Мәсәлән, кешеләр, сайлауда катнашканда, үзләренең социаль күзаллауларын, ягъни нинди дә булса сәяси карарлар яклы булуларын билгеләүче үзкыйммәтләренә таяналар. Кыйммәтләр системасын алга чыгарып, идеология бурычлар, сәяси хәрәкәтләр өчен юнәлешләр куя.

Хакыйкатьне ачыкларга омтылучы фәннән аермалы буларак, идеология сәясәтнең билгеле субъектлары мәнфәгатьләрен чагылдыру һәм яклау өчен билгеләнә, бер үк вакытта ул фәнни белемнәрне дә эченә алырга мөмкин. Аңа теге яки бу күзлектән чыгып каралучы чынбарлыкны гадиләштерү, өлешчә генә күрсәтү хас. Шул ук вакытта идеология чынбарлыкның бер ягын тулы итеп сурәтләргә тырыша. Җәмгыятьне өйрәнеп белү барышында тикшеренүченең субъектив позициясе дә сизелә, ә җәмгыятьне өйрәнүче галимнәр ясаган йомгак теге яки бу төркем мәнфәгатенә кагыла. Әмма фән сәяси процессны һәрьяклап һәм мөмкин кадәр гадел өйрәнү нәтиҗәсендә ирешелүче объектив белемнәр бирергә тиеш. Идеологиягә килгәндә исә, сәяси күренешләргә үз мәнфәгатьләреннән чыгып карау, теге яки бу социаль төркем позициясеннән бәя бирү, белем белән беррәттән, аның эчтәлегенең җитди үзенчәлеге булып тора. Мәнфәгатьләренә мәгълүм бер идеология хезмәт күрсәтә торган социаль төркем аны кабул итү яклы, әлеге идеологияне сәяси тормышка, көтелә торган социаль үзгәрешләргә үз карашлары системасы буларак аңлый. Сәяси тормышны гадиләштереп аңлау масса тарафыннан фәнни исбатлауларның катлаулы системасына караганда җиңелрәк кабул ителә, иҗтимагый позициянең күркәм проектлары, аларны яклаучы дәлил кебек үк, инану итеп алына.

Сәяси тормышта катнашучы социаль төркемнәр, сәяси элита, сәяси фиркаләр, сәяси эшлекләләр үзләре кабул иткән

идеология куйган юнәлештә хәрәкәт итә. Билгеле бер идеология теләсә кайсы партиянең җитди үзенчәлеге булып тора. Кагыйдә буларак, партия бер идеология тарафдарларын берләштерә һәм аны башка сәяси партияләр идеологик позициясенә каршы куя, алар белән идеологик бәхәс, ә еш кына идеологик көрәш алып бара.

Сәяси идеология нинди рәвештә була соң? Барыннан да элек ул мәгълүм кыйммәтләргә һәм идеалларга нигезләмә бирүче социаль-сәяси теория рәвешендә гәүдәләнә, соңгысы исә тәкъдим ителүче сәяси курс нигезендә ята. Идеологлар идея һәм төшенчәләрне бер системага сала, үз бәяләре, принциплары, идеалларына тәртип һәм килешкәнлек бирә. Идеология мантыйк ягыннан төз, теоретик рәвештә килеп баса. Идеологиянең тормышка ашырылуының мөһим формасы булып социаль төркем, сәяси элита, сәяси оешма таләпләрен чагылдырган сәяси программалар, партия һәм дәүләт эшлеклеләре чыгышлары тора. Теоретик әсәрләрдән аермалы буларак, сәяси программалар (барыннан да элек партияләр программалары) турыдан-туры партия эшчәнлеге ихтыяҗлары өчен билгеләнгән, алар максатларны һәм аларга ирешү ысулларын, теге яки бу социаль төркемнәр мәнфәгатьләре өчен көрәшнең иң якын һәм аннан соңгы бурычларын ачып бирәләр. Куелучы бурычлар һәм игълан ителгән шигарьләр нигезендә әлеге идеология өчен хас булган кыйммәти юнәлешләр ята.

Идеология шулай ук гражданнар аңында да эшли, аларның сәяси тәртибен билгели. Ул кешеләрнең гамәлләрендә һәм эшләрендә тормышка ашырыла. Идеология сәяси хәрәкәтләргә үрелеп бара, аларны кыйммәти-рациональ итә. Идеологиянең көче аның гражданнар тарафыннан үзләштерелүе, сәяси эшчәнлектә аның тормышка ашырылуы белән үлчәнә.

Шулай итеп, сәяси идеология — ул тәгълимат та, программа да, сәяси гамәлдә аның тормышка ашуы да.

ХӘЗЕРГЕ ЗАМАН СӘЯСИ ИДЕОЛОГИЯЛӘРЕ

Күп кенә идея-сәяси агымнар арасында XX гасырда җәмгыятьнең сәяси үсешенә иң зур йогынты ясаучы идеологияләрне атарга мөмкин. Бу либераль, консерватив, социалистик һәм фашистик идеологияләр.

Либераль идеологиянең төп кыйммәте булып шәхес иреге тора. XVII—XVIII гасырларда барлыкка килгән классик либерализм шәхес иреген барыннан да элек шәхси милекчелек нигезендә икътисади, эшмәкәрлек эшчәнлеге иреге буларак аңлата. Сәясәт өлкәсендә либерализм демократияне, хокукый

дәүләт һәм хакимиятләр бүленеше идеяләрен, социаль мөнәсәбәтләрдә — мөмкинлекләр тигезлеген, закон алдында бертигез булуны, рухи тормышта — фикер һәм сүз иреген яклый.

XX гасыр урталарында либералларның иҗтимагый проблемаларны дәүләт катнашуыннан якланган базар, конкуренцияле икътисад ярдәмендә хәл итү мөмкинлегенә өметләре акланмавы билгеле булды. Либераль идеология корректировкалана, шуның нәтиҗәсендә яңа либерализм барлыкка килә. Азатлык, тигезлек, туганлык, милеккә, шәхси эшмәкәрлеккә хокук принципларын мирас итеп, неолиберализм дәүләтнең икътисади тормышта катнашуы, җәмгыятьнең иң түбәнге катлаулары файдасына социаль ярдәм сәясәте уткәрүе зарурлыгын таный.

Консерватив идеология озак вакытлар буена либеральлекнең *оппоненты* булып килә. Консерватизмның база принциплары — традициячелек, тотрыклылык, тәртип. Кешелек җәмгыятенең табигый иерархиясе, табигый тигезсезлеге, югары катлауларның өстенлеге таныла. Консерватив идеология һөнәри сәяси элита тормышка ашыручы көчле дәүләт хакимиятенә йөз тота. Либерализмнан аермалы буларак, дәүләт, милләт, җәмгыять мәнфәгатьләре аерым бер индивидныкыннан югарырак бәяләнә. Консервативлыкның иң мөһим кыйммәтләре — гаилә, дин, әхлак. Шул ук вакытта консерватизм, либерализм кебек ук, шәхси милекчелеккә, эшмәкәрлек ирегенә иң җитди әһәмият бирә.

Либерализм кебек ук, XX гасырда барган үзгәрешләр йогынтысыда консерватив идеология үзгәрде, — ул либерализмга якынайды. Неоконсерватизм аерым индивид ирегенә хөрмәт белән характерлана, чикле генә булса да, икътисади дәүләт җайга салуы зарурлыгын таный. Кеше бурычларына, шәхси инициативага, шәхси мөмкинлекләргә, аны һәркемнең дәүләт социаль ярдәменә исәп тотмыйча файдаланырга тиешлегенә игътибар юнәлтелә. Дәүләт түләүсез уңайлыкларны чыннан да моңа мохтаҗларга гына тудырырга тиеш. Иҗади хезмәт, хезмәткәрләрне предприятие керемнәрендә, продукциянең сыйфатын күтәрүдә катнашуга җәлеп итү идеяләре күтәрелә. Консерватизмның төп кыйммәтләре арасында — закон, тәртип, дисциплина, тотрыклылык, гаилә, милләт, хакимият.

Социалистик идеология изелгән сыйныфларның социаль гаделлек җәмгыяте турындагы гасырлар буена сузылган хыялы белән бәйле. Ул шәхси милекне бетерү, иҗтимагый җитештерү оештыру, тигезлек, һәркемнең сәләтенә карап бүлеп бирү һ.б. идеяләрне эченә алган утопия проектларында чагылыш таба. Индивидуальлек өстенлегенә нигезләнгән либерализмнан аермалы буларак, социалистик идеология күмәклек яисә җәмәгатьчелек башлангычына беренче дәрәҗә әһәмият бирә.

XIX гасырда *марксизм* (аңа нигез салучы К.Маркс исеменнән) иң тирән эшләнгән социалистик тәгълиматка әверелә. Ул алшартлары капитализм үсешеннән килеп чыгучы социалистик революциянең котылгысызлыгын исбат итте. Капитализм вакытында пролетариат үсә һәм революция ясап, пролетар диктатура дәүләте булдырып, социаль гаделлек җәмгыяте төзи. Коммунистик җәмгыятьнең беренче баскычы булып социализм тора, анда җәмәгать милке өстенлек итә, план хуҗалыгы һәм хезмәткә карап бүлү тормышка ашырыла.

XX гасырда иҗтимагый аңга һәм сәясәткә социалистик идеологиянең ике агымы: социал-реформизм һәм ленинизм зур йогынты ясый.

Социал-реформизм яисә **социал-демократик идеология** марксизмның күп кенә нигезләмәләрен ревизияләү (яңадан карау) һәм сыйнфый көрәш, революция, пролетариат диктатурасы идеяләреннән баш тарту нигезендә барлыкка килде. Капитализм үсешен анализлап, социал-реформизм идеологлары социализмга юл капиталистик җәмгыятьне эзлекле рәвештә үзгәртеп кору, реформалар аша ята дигән нәтиҗәгә киләләр. XX гасыр уртасында бу идея демократик социализм концепциясен эченә ала, ирек, гаделлек, теләктәшлек аның төп кыйммәтләренә әверелә. Сәяси өлкәдә ул — хокукый дәүләт, парламент демократиясе, шәхес хокукларын гарантияләү. Базар икътисадын дәүләт җайга салуы күздә тотыла. Социаль демократия кешегә лаеклы яшәү һәм эшләү шартлары булдыру, керемнәрне хезмәткә сәләтсезләр файдасына яңадан бүлү, мәгариф системасының һәм рухи кыйммәтләрнең һәркем ирешерлек булуы, әйләнә-тирә мохитнең торышын яхшырту буларак аңлатыла.

Социаль-демократлар күзлегеннән караганда, социализм — анык бер җәмгыять төзелеше түгел, ә социаль шартларны акрынлап яхшырта бару, җәмәгать тормышында социаль гаделлекне ныгыту ул.

Ленинизм яисә **коммунистик идеология** марксизм идеясендә революцион көч куллануга басым ясый. Бу идеологиядә җәмгыятьне тигезлек һәм социаль гаделлек принципларында үзгәртеп коруда сәяси партия җитәкчелегендәге пролетариат диктатурасы дәүләте роленә аеруча әһәмият бирелә. XX гасырның икенче яртысында байтак илләрдәге коммунистик идеология тарафдарлары пролетариат диктатурасы идеясеннән баш тарта һәм социализмга тыныч күчү механизмнары эшли, күп кенә позицияләр буенча социал-демократик идеяләргә якыная.

Башкалар, радикаль карашлы коммунистик юнәлеш тарафдарлары җәмгыятьне революцион үзгәртеп кору, мондый

үзгәрешкә каршыларны көч белән бастыру принципларына тугрылык саклыйлар.

Фашизм идеологиясе, либераль, консерватив һәм социалистик идеяләрдән аермалы буларак, XX гасырда барлыкка килә һәм төрле илләрдәге тирән кризис чагылышы була. Хәзерге заман тикшеренүчеләре аңа хас булган расалар тигезсезлеге һәм бер расаның икенчесеннән өстенлеге; раса-этник башлангыч белән чагыштырганда шәхеснең икенчеллеге; демократия һәм хокукый дәүләт принциплары яклы милли азчылыкка һәм сәяси партияләргә эчке дошман итеп карау; көчле диктатура хакимияте файдасына демократик системаны кире кагу; шәхесне һәм барлык җәмгыятьне тулы контрольдә тотуны тәэмин итүче фашистик партиянең сәяси хакимлеген нигезләү; юлбашчыда гәүдәләнгән дәүләт бердәмлеген белдергән һәм массаларның үз җитәкчесенә һичшиксез буйсынуын таләп иткән фюрерлык (юлбашчылык) принцибы идеяләрен билгеләп үтәләр. Бу идеология өчен милли милитаризмны, милләтне туплануга алып барырга тиешле сугыш культын хуплау хас.

Расистлык, шовинизм, көч куллану, кешене күралмау, агрессия — болар барысы да азмы-күпме дәрәҗәдә фашизмның барлык төрләренә хас. Фашистик идеология сыйфатлары арий расасының бөтен дөньяда хакимлеге максатын нигезләгән Германия милли социализмында иң тулы чагылды. Милли социализм идеясен гамәлгә ашыру Германия халкын гына түгел, бөтен Европа халыкларын авыр фаҗигагә китерде.

Хәзерге заман шартларында фашистик идеология XX гасырның беренче яртысы фашизмының караңгы чагылышыннан аерымланырга омтыла. Әмма неофашизм элеккечә үк көч куллану, милләтчелек һәм расизм культын алга сөрә, үзенең элгәрләре идеологиясе белән дәвамчылык бәйләнешын саклый.

СӘЯСИ ТОРМЫШТА ИДЕОЛОГИЯНЕҢ РОЛЕ

Билгеле бер идеология тарафдарлары буларак, сәяси партияләр аны үз әгъзаларын туплау чарасы итеп кулланалар. Бер үк идеология яклы кешеләр фикердәшләргә әверелә, шуның нәтиҗәсендә аларның бер сәяси оешмага берләшүе ныгый. Партия шулай ук үз идеологиясен халык арасында киң таратырга омтыла. Теге яки бу партия идеологиясен кабул итүчеләр, кагыйдә буларак, аның тарафдарларына әверелә, бу партия өндәүләренә буйсына, аның өчен сайлауларда тавыш бирә. Шуңа күрә *теләсә кайсы партия* кешеләр аңына *үз идеологиясен* кертү өчен көрәш алып бара. Төрле сәяси оешмалар җәмгыятьтә яисә халыкның билгеле бер өлешендә үткәндәгегә

һәм хәзергегә үз бәясен, сәяси вазгыятьне ничек аңлавын, киләчәк турында үз күзаллауларын таратырга омтыла. Һәр идеология нәкъ менә үзе реаль чынбарлык турында дөрес белем бирүгә дәгъва кыла, сәяси эшчәнлек юнәлешләрен билгели. Мәгълүм бер социаль төркем мәнфәгатьләрен чагылдырып, идеология сәяси активлык этәргеченә әверелә, мобилизацияләүче көч ролен уйный. (Сәяси эшчәнлекнең башка нигезләре арасында идеологиянең нинди урын тотуы хакында уйлап карагыз.)

Сәяси тормышта *гомуми милли-дәүләт мәнфәгатьләрен* чагылдыручы идеология *аерым роль* уйнарга мөмкин. Төрле социаль төркем мәнфәгатьләре белән беррәттән барча халык мәнфәгатьләре дә ачыла ала, ә бу гомуммилли идеологиянең үзәген тәшкил итә. Күп кенә демократик илләрдә төп кыйммәтләр турындагы мәсьәлә буенча уртак килешү яшәп килә. Мондый идеология җәмгыятьнең бөтенлеген ныгытуга, аның алга таба үсүенә булышлык итүче рухи кыйблага әверелә.

СӘЯСИ ПСИХОЛОГИЯ

Сәяси аң структурасында **сәяси психология** — сәяси хисләр, эмоция, кәеф, фикерләр һәм җәмгыятьнең сәяси тормышы психологик компонентлары һәм яклары мөһим роль уйный. Сәяси аңның теоретик дәрәҗәсенә керүче, идеологларның зур булмаган төркеменең махсус эшчәнлеге җимеше булып торучы идеологиядән аермалы буларак, сәяси психология көндәлек тормышта, гражданнарның хакимият институтлары белән хезмәттәшлеге процессында, ягъни гадәти аң дәрәҗәсендә формалаша. Шуңа күрә ул аңның гамәли тибы буларак характерлана, дөньяга карашның системага салынмаган, эчке каршылыклы җыелмасын гәүдәләндерә һәм рациональ дә, иррациональ, өстәмә аң элементларын да үз эченә ала.

Сәяси психологиянең *чагыштырмача тотрыклы өлеше* булып әхлак, менталитет, этносларның психологик барлыгы, сәламәт акыл тора; ә *үзгәрүчән өлешен* кәеф, хисләр, тойгылар, нидер көтү тәшкил итә. Сәяси психологиянең барлык бу компонентлары сәясәт субъектларының үз-үзләрен тотышына йогынты ясый.

Сәяси психологияне өйрәнүче галимнәр аның сәяси тормыштагы ролен берничә юнәлештә ачып бирә. Беренчедән, бу — сәясәттә шәхес психологиясе (лидер шәхесен дә кертеп). Икенчедән, кече төркем психологиясе (төркем эчендәге үзара мөнәсәбәтләр һәм аның тышкы даирә белән мөнәсәбәтләре). Өченчедән, зур социаль төркемнәр һәм милли-этник бергәлекләр

психологиясе. Дүртенчедән, массалар һәм массакүләм карашлар психологиясе. Мөһим юнәлеш — халыкның сәяси мәгълүматны кабул итүен өйрәнү.

МАССАКҮЛӘМ МӘГЪЛҮМАТ ЧАРАЛАРЫ ҺӘМ СӘЯСИ АҢ

Идеологияне тарату чарасы булып **сәяси пропаганда** тора. Бу исә җәмгыятьтә билгеле бер карашлар формалаштыруга, гражданнар аңында теге яки бу кыйммәтләрне, чынбарлыкның теге яки бу аспектларына тәнкыйть күзлегеннән карауны беркетүгә, башка идеологиягә ышанмауга, аны кабул итмәүгә юнәлтелгән эшчәнлек төре. Хөкүмәтне, мәгълүм бер сәяси оешмаларны хуплауга яисә, киресенчә, аларга каршы чыгыш ясауга халыкны этәрү максатында телдән, басма, шул исәптән күргәзмә агитация (плакатлар, карикатуралар һ.б.) киң кулланыла.

Идеология тарату өчен массакүләм мәгълүмат чараларыннан (ММЧ) киң файдаланалар. Массачыл аудиториядә мәгълүмати хәбәрләрне таратуның, аны булдыру һәм тиражлауның техник чараларын шулай атыйлар. Хәзерге заман сәяси тормышта ММЧ *гаять мөһим роль* уйный. Аларның *мәгълүмати функциясе* иң мөһим вакыйгалар турында хәбәр итүдән, аларны шәрехләүдән һәм аларга бәя бирүдән гыйбарәт. *Сәяси социализация* функциясе кешеләрне сәяси кыйммәтләргә, норма, үз-үзеңне тоту үрнәкләренә тартудан тора. *Тәнкыйть һәм контроль* функциясе гражданнарга хакимият органнары эшчәнлеген анализларга һәм бәяләргә мөмкинлек бирә. *Төрле иҗтимагый мәнфәгатьләрне*, фикерләрне, сәясәткә карашны күрсәтү — ММЧның тагын бер функциясе. Моңа шулай ук *җәмәгатьчелек фикерен формалаштыру* функциясе бәйле. Ә *мобилизацияләү* функциясе кешеләрне мәгълүм бер сәяси гамәлләргә этәрүдә чагылыш таба.

Иң киң таралган ММЧ — радио, телевидение, матбугат. Алар арасында үзенә күрә бер эш бүлешү яшәп килә. Сәяси вакыйга турында хәбәр иткәндә, радио нигездә *нәрсә булуын* белергә мөмкинлек бирә. Телевидение моның *ничек булуын* күрсәтә. Ә матбугат моның *нилектән булуы* турындагы сорауга иң тулы җавапны бирә. «Һәр йортка килү» мөмкинлеге, телевидениедә «катнашу эффекты» тудыручы видеосурәт булу, шулай ук тамаша кылу һәм ишетүнең үрелеп баруы, мәгълүматны кабул итүнең җиңеллеге электрон массакүләм мәгълүмат чараларын кешеләрнең сәяси аңына һәм үз-үзләрен тотышына йогынты ясауның иң нәтиҗәле чарасы итә. ММЧны очраклы гына «дүртенче хакимият» димиләр.

ММЧның сәяси тормыштагы ролен өйрәнүче галимнәр, әгәр дә *ММЧга барыннан да элек — электрон чараларга* керү мөмкинлеге булмаса, бер генә сәяси төркем дә сәясәттә сизелерлек уңышка ирешә алмаячак; хакимиятнең вәкиллекле органына кандидатларның берсе дә, әгәр телевидение һәм башка ММЧдан файдалана алмаса, сайлануга өмет итә алмаячак дигән нәтиҗәгә киләләр.

Гамәли тәҗрибә ММЧның демократия үсешенә, гражданнарның сәяси тормышта аңлап катнашуына булыша алуын, ләкин сәяси манипуляция өчен дә кулланылырга мөмкин икәнлеген күрсәтә. (Мәгълүм бер иҗтимагый көчләр өчен кирәкле якка юнәлтү өчен кеше аңы һәм тәртибе белән яшерен идарә итүне шулай атыйлар.)

ММЧның сәяси йогынтысы кешенең акылына да, хисләренә дә тәэсир итү юлы белән тормышка ашырыла. Пропагандада дөрес мәгълүмат белән бергә еш кына ярым дөреслек тә бирелә, шулай ук пропаганда алып баручы сәяси оешма характерына бәйле рәвештә, фальсификация — фактларны бутау, дезинформация дә кулланыла.

Әгәр һәр граждан мәгълүматны тәнкыйди бәяләп карарга, объектив хәбәрне бозып бирелгәненнән аерырга өйрәнсә, фәнни белемнәргә таянып, үзендә җәмгыятькә һәм аның үсешенә карата тотрыклы караш тәрбияләсә, теге яки бу сәяси көчләрнең, яңа чаралардан файдаланып, кешеләрнең үз-үзләрен тотышы белән манипуляцияләргә маташуы юкка гына булыр иде. Әмма әлегә кешеләрнең күп өлеше чынбарлыкны мөстәкыйль рәвештә анализларга әзер түгел, социаль танып белүнең фәнни ысулларын белми, шуңа да (аңа заманча мәгълүмати йогынты ясау нәтиҗәсендә) идеологиягә тулысынча инана. Ләкин кабул ителгән идеология, аны тәнкыйть күзлегеннән чыгып фикерләү нәтиҗәсеме яки инануга гына таянамы икәнлегенә бәйсез рәвештә, һәрвакыт теләсә нинди эшчәнлекнең мөһим ягы булып кала.

ГАМӘЛИ ЙОМГАКЛАР

1 Сәяси даирәдә нык үскән сәяси аңга ия, вакыйгаларның асылын, аларның сәбәпләрен һәм ихтимал нәтиҗәләрен аңлаган кеше генә уңышлы хәрәкәт итә. Сәяси аңның теоретик дәрәҗәсе үз сәяси тотышыңның юнәлешен дөрес билгеләргә, юлны аңлы һәм җаваплы рәвештә сайларга, сәяси бурычларны хәл итүнең нәтиҗәле алымнарын табарга мөмкинлек бирә. Мондый дәрәҗәдәге аң үзеннән-үзе генә килеп чыкмый. Сәясәт чытырманнарында адашырга телә-

мәүчеләр үзләренең фәнни-сәяси белемнәрен баетырга һәм аларны гамәлдә куллана белергә тиеш.

2 Үзеңдә сәяси идеологияләргә тәнкыйть күзлегеннән карау сәләте тәрбияләү мөһим. Идеология, сәяси программа һәм шигарьләр, кагыйдә буларак, төркем мәнфәгатьләрен чагылдыра һәм чынбарлыкны шул позициядән бәяли, сәяси көрәш максатларын һәм чараларын нигезли. Шуңа да гомумхалык ихтыяҗлары, шулай ук үз мәнфәгатьләреңне аңлау һәм идеология өлкәсендә шул позицияләрдән юнәлеш алу бик мөһим.

3 Сәясәт турындагы теоретик белемнәр агымдагы мәгълүмат океанында компас була ала. Әмма әлеге компас сәяси мәгълүматның хәзерге заман чыганакларыннан файдаланмаган кешегә файдасыз. Кирәкле мәгълүматны ала белү төрле ММЧ мөмкинлекләре һәм үзенчәлекләре турында белемнәргә таяна. Хәбәрләр ачышында юнәлеш алу сәләте төрле чыганакларга, чараларга, мәгълүмат тарату каналларына мөрәҗәгать итүне, төгәл фактлар турындагы белешмәләрне чагыштырып карауны, төрле фикерләүләргә тәнкыйть күзлегеннән карап бәя бирүне күздә тота.

ДОКУМЕНТ

Россия социологлары ***Л.А.Гегель, Р.Ш.Мамедбейли, Л.Н.Москвичеваның*** «Яшь россиялеләр аңында сәяси лидер образы формалаштыру» дигән мәкаләсеннән (1999 елда яшьләрнең сәяси аңын тикшерү нәтиҗәләре буенча).

Сайлауда үз тавышларын бирерлек Россия Президентына кандидат алар карашынча нинди булырга тиеш соң? Алынган җаваплар буенча яшьләрнең нәрсә көтүләре, алар аңында яңа сәяси лидерның образы формалашуы турында фикер йөртергә мөмкин. Яшь кешеләрнең иң өстен күргән позициясе — илдә тәртип урнаштыру зарурлыгы. Яшьләр моны дәүләтнең роле көчәю, көчле, коррупцияне дә йөгәнләрлек тәвәккәл шәхес хакимияте белән бәйли; яшь кеше хакимиятнең эш күрсәтмәвеннән, гомуми җавапсызлыктан туйган...

Әмма «илдә тәртип урнаштыру»ны төрле ысуллар белән башкарып була. «Сезнең өчен әлеге гыйбарә нәрсәне аңлата?» дигән сорауга җавап биргәндә фикерләр аерылды. Сораулучыларның фәкать 4%ы массачыл репрессияләр диктатурасын күздә тота (1999 елда илдә диктатура урнашу

мөмкинлеге яшь россиялеләрнең 2,5%ында гына зур шөбһә тудырды). Һәм шул кадәр үк (4%) «илдә тәртип» дип кеше хокукларын бозучы авторитар хакимиятне аңлый (5,4% — башка җавап бирде һәм 7,3% — җавап бирергә читенсенде). Яшьләрнең зур күпчелеге (79,3%) «Законнарны, тәртипнең элементар кагыйдәләрен үтәү» дип җавап бирде.

Шулай итеп, яшьләр көч кулланунның иң чын рәвешләрендәге катгый хакимияттә чагылыш табучы диктаторлык режимын да, кеше хокукларын бозучы авторитар хакимиятне дә кабул итми. Аларның симпатиясе — хакимият һәм җәмгыятьнең үзара мөнәсәбәте фәкать закон нигезендә генә билгеләнүче хокукый, демократик дәүләт ягында.

Документка сораулар һәм биремнәр

1. Сез ничек уйлыйсыз: китерелгән тикшеренү нәтиҗәләре сәяси аңның нинди дәрәҗәсен чагылдыра? Җавабыгызны дәлилләгез. 2. Галимнәр мәкаләсеннән китерелгән өзек нигезендә яшьләр аңында өстенлек иткән карашларны нинди дә булса хәзерге заман идеологиясенә кертеп карарга мөмкинме? Нәтиҗәгезне аңлатыгыз. 3. Илдә тәртип урнаштыру ысуллары турындагы мәсьәлә буенча фикерегез ничек? 4. Сез әлеге юлларны укыган көндә ил лидерының беренче чиратта күтәелгән гамәлләре турындагы мәсьәлә яңадан киселген куелса, яшьләрнең җавабы нинди булыр иде? Ни өчен болай уйлавыгызны аңлатыгыз.

ҮЗ-ҮЗЕҢНЕ ТИКШЕРҮ ӨЧЕН СОРАУЛАР

1. «Сәяси аң» төшенчәсенең «сәяси белем» төшенчәсеннән аермасы нидә? 2. Сәяси аңның ике дәрәҗәсе: гадәти-гамәли һәм идеологик-теоретик дәрәҗәләре нәрсә белән аерыла? Алар арасында нинди элемтә бар? 3. Нәрсә ул идеология? Ул сәяси тормышта нинди роль уйный? 4. XX гасырда вакыйгаларга йогынты ясаган һәр идеологиягә характеристика бирегез. 5. Сәяси психологиягә хас сыйфатлар нинди? 6. Хәзерге заман сәяси тормышында ММЧ урынын билгеләгез. Аларның функцияләре турында ниләр беләсез? ММЧ үзенең сәяси йогынтысын ничек тормышка ашыра?

БИРЕМНӘР

1. XX гасыр башында Россиядә нинди сәяси партияләр барлыкка килүен исегезгә төшерегез. Аларның сәяси программалары

нигезендә нинди идеология ята? (Бу биремне үтәгәндә тарих дәреслеген кулланыгыз.)

2. Поляк язучысы Богдан Чешко түбәндәге фикерендә нәрсәне истә тоткан дип уйлыйсыз: «Зур сәясәт иртәме, соңмы барыбер сине куалап тота. Ләкин ул сине эчке киемнәрдән генә булганда эләктермәсен өчен тырыша». Параграфның кайсы материалы куелган сорауга җавап бирергә булышыр?

3. Журналистларга киң хокуклар биргән «Массакүләм мәгълүмат чаралары турында» Закон әлеге хокуклардан явызларча файдаланырга, аерым алганда, иҗтимагый әһәмияте булган мәгълүматларны яшереп калырга яисә фальсификацияләргә, дөрес хәбәрләр рәвешендә имеш-мимешләр таратырга ярамавы хакында да әйтә. Бу хокукый норманың әһәмиятен аңлатыгыз.

4. Атналык йомгак ясаучы телевидение мәгълүмати-аналитик программасын карагыз һәм аның тамашачы сәяси аңына йогынтысына бәя бирегез.

ЗИРӘКЛӘР ФИКЕРЕ

«Идея үзе генә берни дә кыла алмый. Идеяләрне тормышка ашыру өчен гамәли көч кулланырга тиешле кешеләр таләп ителә».

К.Маркс (1818–1883), немец фикер иясе

§ 15. Сәяси тәртип

Кешенең сәясәткә мөнәсәбәте аның сүзләрендә генә күренәме? Сәяси эшчәнлектә рөхсәт ителгән чик кайдан уза?

10 нчы сыйныф дәреслегендә тасвирланган сәяси тормышта катнашу кешенең сәясәткә, анда катнашучыларга, үз-үзенә мөнәсәбәте күзлегеннән чыгып та каралырга мөмкин. Әлеге мөнәсәбәтнең тышкы чагылышы булып кешенең әхлак һәм хокук позициясеннән бәяләнергә мөмкин булган үз-үзен тотышы, тәртибе тора.

Катнашучылары бер үк эшчәнлек белән шөгыльләнгән, ләкин үз-үзләрен төрлечә тоткан сәяси җыелышны күз алдына китерик. Берәүләр чыгыш ясаучыны игътибар белән тыңлый. Икенчеләре нотыкчыны тавышланып, сызгырып туктатырга, кул чабып яки аяк тыпырдатып «авызын капларга» тырыша.

Монда беренчеләре сәяси эшчәнлекне җайга салучы норманы саклый, икенчеләре аннан тайпылу үрнәген күрсәтә.

СӘЯСИ ТӘРТИПНЕҢ КҮПТӨРЛЕ РӘВЕШЛӘРЕ

Сәяси тәртип — сәяси субъектның социаль мохит, төрле иҗтимагый-сәяси көчләр белән үзара мөнәсәбәтен характерлаучы гамәлләр һәм хәрәкәтләр ул. Бу — эшләрнең, нинди дә булса иҗтимагый әһәмиятле максатларга ирешүгә юнәлтелгән аңлы гамәлләр; традиция, кыйммәти юнәлешләр тудырган гамәлләр, шулай ук индивидның эмоциональ халәте китереп чыгарган аңсыз гамәлләр җыелмасы. Кеше гамәлләрендә сәяси тәртипнең кыйммәти аспектлары ачык чагыла. Реаль сәяси тәртиптә аңлап һәм аңламыйча кылынган, рациональ һәм эмоциональ компонентлар үзара катлаулы мөнәсәбәтләрдә була. Үз-үзеңне тоту интенсивлык дәрәҗәсе буенча корректлы, цивилизацияле мөнәсәбәтләрдән алып, ачулы һәм игелексез халәткә, сүз белән мыскыллауга, хәтта физик көч куюга кадәр үзгәрергә мөмкин.

Игътибарны сәяси эшчәнлек субъектларының берсе — шәхескә юнәлтик. Сәясәт өлкәсендә кеше башка кешеләр, сәяси оешмалар, дәүләт органнары һ.б. белән үзара мөнәсәбәткә керә. Болар ярдәмләшү, хезмәттәшлек, бердәмлек мөнәсәбәтләре яисә, киресенчә, каршы тору, көрәш, сәяси көндәшлек булырга мөмкин. Бу мөнәсәбәтләр анда катнашучылар мәнфәгатьләре, аларның туры килүе яисә каршылыгы белән билгеләнә.

Сәяси тәртиптә шәхеснең *аңлы сәяси мәнфәгатьләре һәм кыйммәтләре* булу хәлиткеч әһәмияткә ия.

Сәяси мәнфәгатьләр халыкның төрле төркемнәре хәлен чагылдырганга, әлеге төркем вәкилләре, кагыйдә буларак, үз мәнфәгатьләрен сәясәт аша гамәлгә ашырырга тырыша. Бу күзлектән караганда кече эшмәкәрләрнең сәяси тәртибе, әйтик, дәүләт аппараты хезмәткәрләре тәртибеннән аерылырга мөмкин.

Халыкның теге яки бу төркеме хуплаган кыйммәтләр дә бик мөһим. Кешеләр аңында демократик кыйммәтләрнең ныгып урнашуы күп очракта аларның демократик партиягә һәм демократик, хокукый формаларга йөз тотуын билгели.

Сәяси тәртип шәхеснең сәяси активлыгының аның гамәлләренең һәм гамәлсезлегенең *барлык рәвешләрен* үз эченә ала.

Сәяси демонстрациядә катнашу — бу мөмкин булган сәяси гамәл. Сайлауларда катнашмау — шулай ук гамәлсезлек рәвешендәге сәяси тәртипнең мөмкин булган варианты. Бу очракта гамәлсезлек сәяси вазгыятьнең үсеше өчен теге яки бу нәтиҗәгә ия булган эш булып тора. Сайлауларда, манифестацияләрдә, митингларда катнашуны, эш-гамәлнең күз алдында булуына карап, сәяси тәртипнең — *ачык*, ә сәяси пассивлыкны, сәяси тормыштан тайпылырга омтылуны *ябык рәвешенә* кертәләр.

Дәвамчанлык күзлегеннән караганда сәяси тәртип рәвешләре *традиционга* (әлеге сәяси культура өчен типик булган сәяси күзаллауларга, менталитетка туры килүче) һәм *инновационга* (сәяси тәртипнең яңа үрнәкләрен булдыручы, сәяси мөнәсәбәтләрнең яңа сыйфатын тудыручы) бүленә.

Үзенең максатчан юнәлеше буенча сәяси тәртип *конструктив* (сәяси системаның нормаль эшләвенә ярдәм итүче) һәм *деструктив* (сәяси тәртипне бозучы) булырга мөмкин.

Сәяси тәртип индивидуаль, төркемдәге һәм массачыл була. *Индивидуаль сәяси тәртип* — индивидның иҗтимагый-сәяси әһәмияткә ия (сәясәтчеләр һәм сәясәт турында фикерне чагылдырган гамәли эш яисә кеше алдында әйтелгән сүз) гамәле. *Төркемдәге сәяси тәртип* сәяси оешмалар яисә индивидларның очраклы барлыкка килгән сәяси яктан актив төркеме эшчәнлеге белән бәйле. *Сәяси тәртипнең иң массачыл формалары* булып сайлау, референдум, митинг, демонстрацияләр тора.

Төркемдә, ә тагын да күбрәк — массачыл сәяси тәртиптә башкаларга охшарга тырышу, эмоциональ йогынты, теләктәшлек, индивидуаль тәртипне төркем нормаларына буйсындыру күзәтелә.

Сәяси тәртипнең күптөрле рәвешләре сәясәтнең барлык субъектлары активлыгы чагылышыннан гыйбарәт булса, сәяси катнашу турында сөйләгәндә, без фәкать шәхеснең сәяси тәртибен күздә тотабыз. 10 нчы сыйныфлар өчен җәмгыять белеме курсында күрсәтелгәнчә, сәяси катнашу — гражданның дәүләт сәясәтенә яисә сәяси лидерлар сайлавына йогынты ясау максатындагы гамәлләре ул.

Сәяси катнашуның иң массачыл рәвеше сайлау булганлыктан, тикшеренүчеләрнең аерым игътибарын гражданнарның *электораль тәртибе* җәлеп итә: халыкның теге яки бу катламы вәкилләре кемгә һәм ни өчен тавыш бирә, гражданнарның бер өлеше сайлауларда катнашмауның сәбәбе нидә?

Электораль тәртип байтак факторлардан тора. Партия системасы күптәннән барлыкка килгән илләрдә сайлаучыларның билгеле бер партия белән элемтәсе тотрыклы. Алар күптәннән «үз партиясе» дип санап килгән фирка өчен сайлаудан сайлауга тавыш биреп килә. Сайлаучыларның байтак өлеше тавышларын булган проблемаларны үзләре өчен иң кулай хәл итәрлек карарлар тәкъдим итүче кандидатларга яисә партияләргә бирә. Һәм, ниһаять, билгеле бер кандидатларның индивидуаль һәм төркемдәге тарафдарлары бар. Бу очракта программадан бигрәк кандидат башкарган яки башкарырга җыенган эшләргә уңай бәядән чыгып, аның өчен тавыш бирәләр.

Атап үтелгән факторлар үзара тәэсир итешә, кайчакта берберсенә каршы килә, бер-берсен кабатлый.

Сайлауларда катнашу-катнашмау мәсьәләсенә әйләнеп кайтыйк. Мисал өчен, АКШта барлык дәрәҗәдәге сайлауларда яше җиткән халыкның 25%тан алып 35%ка кадәргесе эзлекле диярлек тавыш бирә; тагын 30–40% бик сирәк тавыш бирә яки сайлау участогына бөтенләй килми; 3 тән алып 7%ка кадәр сайлаучы сәясәт белән бөтенләй кызыксынмый. 95%ка кадәр сайлаучы тавыш бирүче илләр бар. Сезнең белүегезчә, сайлауларда катнашудан баш тарту *абсентеизм* (латинчадан турыдан-туры мәгънәдә «монда булмаучы») дип атала. Абсентеизм җитди нәтиҗәгә китерергә мөмкин: әгәр, әйтик, сайлауда катнашучылар сайлаучыларның 50 яисә 25%ы булса, сайлау булмаган дип танылa. Ә бу исә сәяси системаның иң мөһим буыннарын эштән чыгара ала. Шуңа күрә демократик дәүләтләрдә гражданнарга сәясәт һәм төрле сәяси көчләр турында мәгълүмат бирүче, битарафлыкны, сәяси апатияне җиңәргә ярдәм итүче массакүләм мәгълүмат чаралары зур роль уйный.

Хакимлек итүче нормаларга туры килү күзлегеннән карaганда, сәяси тәртипнең *норматив* (законнарга, сәяси әхлак таләпләренә туры килүче) һәм *тайпылышлы* (хокукый һәм әхлак нормаларын бозучы) рәвешләрен аерып карыйлар.

Сәяси тәртипнең *патологик* рәвешләре турында да сөйлиләр. Аларның чагылышы булып иң чик аффект халәте, дошманлыкка, агрессиягә, антагонизмга даими ихтыяҗ, паника халәте, маниакаль сәяси ышану калдыклары һ.б.тора ала. Патологик сәяси тәртип билгесе аның вазгыять таләпләренә яки шәхес максатларына туры килмәвеннән гыйбарәт. Әйтик, куркынычлы вазгыять килеп чыкканда, халык массасы зур курку кичерә, тетрәнә, паникага бирелә, тәртипсез гамәлләр кылып котылып калырга маташа, хаос китереп чыгара, шуның белән булган хәлнең куркыныч нәтиҗәләрен тагын да арттыра.

Сәяси тәртип структурасында *протест* формасы аерылып тора. Сәяси протест — сәяси системага тулаем яки аның аерым элементларына, норма, кыйммәтләренә, сәяси карарларга ачыктан-ачык күрсәтелүче рәвештәге тискәре мөнәсәбәт чагылышы ул. Митинг, демонстрация, пикетлау, забастовка еш кына шундый форма була. Алар, кагыйдә буларак, субъект омтылган хәл белән чынбарлык арасында аерма китереп чыгарган ризасызлык белән аңлатыла.

XX гасырның 90 нчы еллары сәяси тәртипнең *экстремаль* рәвешләрен дә күрсәтте. Экстремизм (латинча *extremus* — соң чик) — сәясәттә соң чик карашлар һәм чаралар, хокукый нигилизм тарафдары булу, хокукый һәм әхлакый нормаларны бозучы тәртип ул. Соңгы дистә елларда дөнья күп кенә уң һәм сул сәяси экстремизм чагылышлары шаһиты булды. Мәсәлән, үз таләпләренә игътибар җәлеп итәргә омтылып, үз-үзләрен күз

алдында яндыру очраклары. Яисә үз төркемнәре эшчәнлеген финанслау өчен файдаланылучы акча алу максатында тотыклар (заложник) кулга төшерү. Сәяси тәртипнең мондый рәвешләре массачыл тәртипсезлекләр китереп чыгарырга маташучы экстремистик оешмалар йогынтысыда бара. Очраклы, вакытлыча гына тупланган кешеләр: җыен яки митингта, демонстрациядә катнашучылар, урамдагы төркем мондый йогынтыга тиз бирешә.

Сәясәтләшкән төркемдә үз-үзеңне *аффектив, аңламаган килеш* тоту күренеше ихтимал. Аффектив (латинча *affectus* — рухи дулкынлану) тәртип субъектның көчле ярсыткычка кискен реакциясендә чагыла, бу очракта кешенең үз гамәлләренә контроле өлешчә яки тулысынча кысрыклап чыгарыла. Француз галиме Г.Лебон (1841–1931) болай яза: «...оешкан төркемнең бер өлешенә әверелгәч, кеше цивилизациянең берничә баскычына түбән төшә. Изоляцияләнгән килеш ул, бәлки, мәдәниятле кеше булыр иде; төркемдә — ул вәхши, ягъни инстинктлар колы. Аңарда башбаштаклык, буйсынмау, ерткычлык, шулай ук борынгы кешегә хас энтузиазм һәм куркусызлык сыйфатлары ачыла». Төркем өчен түземсезлек, импульсивлык, кызып китүчәнлек, үгетләүгә тиз бирешү, хисләрнең берьяклы булуы һәм тиз үзгәрүчәнлек характерлы. Кешенең үз гамәлләре өчен җаваплылыгы төркем эмоцияләрендә эреп беткәндәй була. Төркем үзендә аффектив тәртип, агрессивлык, масса төсендәге тәртипсезлекләр, көч куллану куркынычы саклый.

СӘЯСИ ТЕРРОР

Сәяси тәртипнең экстремалистлык тибына террор да керә. **Сәяси террор** — курку, паника, шөбһә, хакимияткә ышанычсызлык тудыру максатында корал кулланып (шартлаулар, ут төртү, һәлакәтләр оештыру һ.б.) яисә көч куллану, кешеләргә һәм мөлкәткә зарар китерү белән янап, системалы рәвештә яисә бер тапкыр көч куллану. Иң мөһиме — хөкүмәтне һәм халыкны куркыту. Гадәти җинаятьләрдән аермалы буларак, террор үзен киң җәмәгатьчелек резонансы алган, бөтен җәмгыятьне тетрәндерерлек сәяси вакыйгалар барышына һәм карар кабул итүгә йогынты ясарга сәләтле сәяси акцияләрдә күрсәтә. Европа Советының Парламент ассамблеясы белдергәнчә, сәяси террорның максаты «демократияне һәм парламент институтларын какшатудан гыйбарәт. Террорчылык демократик җәмгыятькә җитди куркыныч белән яный, аның әхлакый һәм социаль тукымасын җимерә».

Хәзерге заман террорчылыгын өйрәнүчеләр аны тудыруның байтак сәбәпләрен күрә. Алардан: аерым илләр эчендә һәм илләр арасында ресурсларның, керемнәрнең һәм байлыкларның тигез бүленмәве; ярлылык проблемасының кискенләшүе; халыкның шәһәрләрдә туплануы, ә моның артык тыгызлыкка һәм деградациягә китерү мөмкинлеге; этник төркемнәр һәм мәдәни катлаулар арасында каршы торуның көчәюе, моның үзләрен агрессив тотуга, законнарны санга сукмау һәм халыкның маргиналь өлеше тарафыннан җинаятьчел тәҗрибә үзләштерүгә китерү ихтималы; глобальләштерүгә каршы тору, милли (дини) үзенчәлекләрне сакларга омтылу.

Кагыйдә буларак, мәдәният нормаларын кире кагучы һәм көчләү контрмәдәни нормалар тотучы маргиналь катлау вәкилләре террорлык оешмалары әгъзалары булып әверелә. Социаль, милли, дини төркемгә керү, башка төркемнәр кыйммәтләренең кискен кимүе шартларында, иң зур кыйммәт буларак кабул ителә. Андый кешеләр өчен явызлык, түзеп тормаучанлык, әйләнә-тирә дөньяга дошман итеп карау, оешма кушканнарны сукырларча үтәү хас. Барлык террорчылар да кеше гомеренә түбәнсетеп карый, үзләре күзлегеннән караганда югары торучы максатларга ирешү өчен бернинди гаепсез кешеләрне корбан итәргә әзер. Террорчы-камикадзе (үз-үзләренә кул салучы) үзе дә үлемгә барырга әзер, моңа үзенекеләр арасында танылу китерүче һәм оҗмахка юл алучы аерым бер миссия итеп карый.

Террорчылык төркемнәре агрессиянең югары дәрәҗәсе белән үзенчәлекле. Аларның һөҗүм итү объектлары — сәяси эшлеклеләр, самолет, автобус, метро һәм тимер юл поездлары пассажирлары, зур кибетләрдә сатып алучылар. Кешеләрне урлап китү, янау һәм шантаж, җәмәгать урыннарында шартлатулар, бина һәм оешмаларны басып алу, тотык кулга төшерү — болар барысы да террорчылык ысуллары.

Сәяси террор XX гасыр ахырында халыкара төс алды. Аның кулында массачыл юк итү коралына кадәр иң заманча техник чаралар бар. Террорга каршы көрәшү бурычы *аерым дәүләтләр алдында да, бөтен дөнья җәмәгатьчелеге алдында да* тора. Бу заманабызның глобаль проблемаларыннан берсе.

СӘЯСИ ТӘРТИПНЕ ҖАЙГА САЛУ

Кешеләрнең сәяси тәртибе, башкалары кебек үк, җәмгыять һәм дәүләт тарафыннан төрле рәвешләрдә җайга салына.

Беренчедән, хокукый җайга салуның әһәмияте бик зур. Законнарда җәмгыять һәм дәүләт куркынычсызлыгы, әхлакый

саклау мәнфәгатьләрендә гражданнар ирекләре һәм хокукларыннан файдалануны чикләүче нормалар бар. Мәсәлән, митинг, демонстрация, пикетларга җыелу хокукы әлеге җыеннарның тыныч, коралсыз узарга тиешлеге турындагы күрсәтмә белән чикләнгән. Террор, массачыл тәртипсезлекләр оештыру һ.б. җинаятьчел гамәлләр санына кертелгән һәм җинаять җаваплылыгына китерә.

Икенчедән, җәмгыятьтә сәяси аренада цивилизацияле уен кагыйдәләрен билгеләүче демократик кыйммәтләрнең ныгып урнашуы мөһим. Сәяси һәм әхлакый кагыйдәләр сәяси тәртипкә алар җәмәгатьчелек фикере белән хуплаганда гына йогынты ясый ала.

Өченчедән, сәясәт субъектларының оешканлыгы зур әһәмияткә ия. Эшчәнлекләре закон таләпләренә туры килүче оешмалар булу сәяси тормышта очраклы хәлләрнең ролен киметә, сәяси тәртипне җаваплырак итә, аны җайга салу мөмкинлеген арттыра.

Дүртенчедән, сәяси белемнәр бирү һәм дөрес сәяси мәгълүмат тарату сәяси тәртипне рациональрәк итә, сәясәт субъектларына нәтиҗәле һәм бер үк вакытта сәяси максатка ирешүнең цивилизацияле ысулларын бирә.

Бишенчедән, күп нәрсә сәяси лидерлардан, аларның нормаларыннан, кирәгеннән артык сәяси киеренкелелекне һәм массалар ярсуын бетерү осталыгыннан, эш-гамәлләрнең рациональләшүенә ярдәм итә белүеннән, тарафдарларын хокукый, сәяси һәм әхлакый нормаларны үтәү юлы буйлап алып бару сәләтеннән тора.

Атап үтелгән факторларның нәтиҗәле эш итүе (сәяси субъектлар активлыгы югары дәрәҗәдә булганда да) сәяси тормышны җәмгыять һәм дәүләт таныган норма кысаларында тотарга мөмкинлек бирә.

ГАМӘЛИ ЙОМГАКЛАР

1 Сәяси тормышта катнашу сәяси процессның башка субъектлары белән үзара хезмәттәшлекне таләп итә. Моның өчен аларның сәяси тәртибен аңларга һәм дөрес бәяләргә кирәк. Ә иң мөһиме — үз тәртибеңне демократик җәмгыять принциплары һәм эталоны нигезендә кору.

2 Сәяси экстремизм сәясәттә деструктив роль уйный. Шулай да сәяси экстремистлар, экстремистик оешмалар еш кына яшьләргә таяна, аларның тәҗрибәсезлегенә, аларга хас активлык һәм хәрәкәтчәнлеккә исәп тота. Сәяси экстремизмның куркынычлылыгын ачык аңлау сезгә үз максатларына

законсыз ысуллар белән ирешүче эшлекләләр һәм оешмалар кулында корал булырга юл куймас.

3 Сәясәттә эмоцияләргә бирешергә ярамый. Сәяси хәлне җитди анализлау, максатны аңлап кую һәм аңа ирешү чараларын рациональ сайлау зарур. Сәяси тәртип сәяси һәм хокукый нормалар белән билгеләнгән чикләрдән чыгарга тиеш түгел. Әхлак нормалары турында да онытырга ярамый.

ДОКУМЕНТ

Америка сәясәт белгече ***М.Парентиның*** «Кайберәүләр өчен демократия» китабыннан.

Тавыш бирүдән читләшүчеләрнең күпчелеге халыкның азрак белемле һәм социаль активлыгы түбәнрәк катлавына кергәнлектән, аларның тавыш бирү хокукыннан файдаланмавы яхшырак та. Чөнки алар демагогиягә җиңелрәк бирелә һәм аларның активлашуы безнең демократик системага янар иде, дип уйлаучылар бар.

Мондый дәлилләрдә шикле фикер күренеп тора: янәсе, яхшырак белемле һәм югары керем алучы, тавыш бирүдә катнашучы гражданнар рациональрәк фикер йөртә һәм тар эгоизмга һәм расачыл һәм сыйнфый арталыкларга бирешми. Җанга җылы биреп торучы хорафат булган бу фикерне югары һәм урта сыйныф вәкилләре уйлап чыгарган һәм шуның белән үз-үзләрен тынычландыра.

Ә кайбер авторлар сайлаучыларның түбән активлыгы — «бәхет сәясәте» билгесе ул дип исбат итә: янәсе, кешеләр тавыш бирүгә нәкъ менә хәзерге хәл аларны тулы канәгатьләндергәнгә күрә битараф.

Сүз дә юк, сәяси проблемаларга (хәтта алар тормышларына турыдан-туры кагылса да) бөтенләй битараф кешеләр бар. Әмма тулаем алганда тавыш бирүдә катнашмаучы миллионлаган америкалылар иң мул тормышта яшәүчеләр түгел, ә ярлы һәм мохтаҗ кешеләрнең гадәттән тыш концентрациясе булган гадәтирәк һәм ачулырак катлауларда күзәтелә. «Бәхет сәясәте», кагыйдә буларак, күңел кайту сәясәте өчен бер ширма гына. Апатия дип кабул ителгән нәрсә чынлыкта кеше психикасының көчсезлек һәм аптыраудан яклану ысулы булырга мөмкин. Сайлауларда катнашмау тулы канәгатьләнү яисә гражданнар игелеге җитмәү нәтиҗәсе түгел, ә кешеләрнең үз тормышында очраткан сәяси чынбарлыкка карата тискәре реакциясе булып тора.

Документка сораулар һәм биремнәр

1. Гражданнарның сайлауда катнашмавын автор ничек бәяли? Ул моның төп сәбәбен нидән күрә? 2. Автор әйткән фикерләрне Россия сайлаучылары тәртибенә карата кулланып буламы? Сез ничек уйлыйсыз, Россия гражданнарының бер өлеше пассивлыгының сәбәпләре һәм нәтиҗәләре нинди?

ҮЗ-ҮЗЕҢНЕ ТИКШЕРҮ ӨЧЕН СОРАУЛАР

1. «Сәяси тәртип» дип нәрсәне атыйлар? Аның рәвешләре ничек аерыла? Мисал китерегез. 2. Сәяси тәртипнең этәргече нинди? 3. Протест кайсы очракларда була? 4. Электораль тәртип нәрсә белән характерлана? 5. Экстремистлык тәртибенең нәрсәсе белән куркыныч булуын аңлатыгыз. 6. Сәяси тәртипне җайга салу мөмкинлеге нинди?

БИРЕМНӘР

1. 2001–2003 елларда Европаның байтак шәһәрләрендә антиглобалистлар чыгышы полиция белән бәрелешләргә китерде; алардан соң витриналары ватык кибетләр, капланган һәм яндырылган автомашиналар, чүп-чар таулары калды. Ул хәрәкәттә катнашучыларның сәяси тәртибен ничек бәяләргә?

2. Параграф текстында китерелгән Г.Лебон әйткәннәрне Л.Н.Толстойның төркемгә биргән түбәндәге тасвирламасы белән чагыштырып карагыз: «Халык төшенчәсен яклаучылар ни генә дисә дә, төркем, яхшы кешеләр булса да, фәкать хайваный, җирәнгеч яклары белән якынайган, кеше табигатенең зәгыйфьлеген һәм рәхимсезлеген күрсәтүчеләр берләшмәсе ул». Төркемнең әлеге характеристикаларында нәрсә уртак? Алар ни белән аерыла?

3. 2003 елның 7 декабрендә Дәүләт Думасына сайлауга сайлаучыларның исемлеккә кертелгән саныннан 55,75% кеше килде. Сез ничек уйлыйсыз, Россия сайлаучыларының шактый зур өлеше сайлауда катнашмауның сәбәбе нидән гыйбарәт? Тавыш бирергә теләмәгәннәрнең сәяси тәртибенә үз бәягезне бирегез.

4. 2004 елның февралендә Дәүләт Думасы террорчылык өчен гомерлек төрмәгә ябу турында кара кабул итте. Террор өчен мондый иң югары җәза кертүне ни белән аңлатырга? Бу карарга үз бәягезне бирегез.

ЗИРӘКЛӘР ФИКЕРЕ

«Начар хакимият тавыш бирмәүче яхшы гражданнар тарафыннан сайлап куела».

ДжД. Натан (1882–1958), Америка тәнкыйтьчесе

§ 16. Сәяси элита һәм сәяси лидерлык

Элита — чынбарлыкмы яисә мифмы? «Җитәкче» һәм «сәяси лидер» төшенчәләренең аермасы бармы? Лидер булып туалармы яки аңа әвереләләрме?

Массакүләм мәгълүмат чараларында без еш кына «хакимлек итүче элита», «сәяси элита» дигән сүзтезмәләрне очратабыз. «Сәяси лидер» термины да киң таралган. Бу сүзләр нәрсәне белдерә? Атап үтелгән сүзтезмәләр җәмгыятькә сәяси йогынты белән бәйле. Безнең алда бу йогынтының ничек тормышка ашырылуын, сәяси элита һәм сәяси лидерларның сәяси тормышта нинди роль уйнавын ачыклау бурычы тора.

СӘЯСИ ЭЛИТА

«Элита» сүзе француз теленнән кергән, туры тәрҗемәсе — иң яхшы, сайлап алынган. Киң мәгънәдә җәмгыятьнең иң яхшы вәкилләрен яисә аның бер өлешен күздә тотканда кулланыла. Сәяси телдә «сәяси элита» төшенчәсе җәмгыятьнең башка өлешеннән йогынтысы, өстенлекле хәле белән аерылып торучы, дәүләт хакимиятеннән файдалану яисә аңа йогынты ясау белән бәйле карарлар кабул итүдә турыдан-туры һәм даими катнашучы төркемне яисә төркемнәр берлеген күрсәтә.

Элиталар теориясен булдыручыларның берсе итальян юристы һәм социологы Т.Моска (1858–1941), тарихның барлык этапларында хакимият һәрвакыт азчылык кулында, беркайчан да күпчелектә түгел, дип раслый. Ул бер азчылыктан икенчесенә күчәргә мөмкин, ләкин һичкайчан күпчелеккә күчми. Бу тәгълимат буенча җәмгыять идарә итүче, чагыштырмача аз санлы сыйныфка һәм идарә ителүче күпчелеккә бүленә. Моска элитага башка кешеләр белән идарә итәргә сәләтле затлар керә дип саный. Җәмгыятьнең башка өлешеннән

аны тупланганлык, оешканлык, матди, әхлакый һәм интеллектуаль өстенлек аерып тора. Элита үсешендә ике тенденция күренә. Беренчесе, аристократик, хакимлек итүче сыйныфның моны мираска алырга омтылышыннан гыйбарәт. Икенчесе, демократик, сәяси элитаны түбәнге катлаулардан идарәгә сәләтле затлар белән яңартудан тора.

Италиянең икенче бер галиме, икътисадчы һәм социолог В.Парето (1848–1923), җәмгыятьтә идарәче элитадан тыш оппозиция элитасы яки контрэлита барлыкка килә, дип яза. Аңа абруйлы, ләкин социаль статуслары һәм җәмгыятьтә яшәп килгән киртәләр аркасында идарә өлкәсенә юллары киселгән идарә эшчәнлегенә сәләтле кешеләр керә. Контрэлита хакимияткә омтыла һәм, хакимлек итүче сыйныф артка чигенә башлагач, элиталар алмашы була. Парето буенча, тарих — революцион тетрәнүләр чорында бара торган даими «элиталар циркуляциясе» процессы ул.

XX гасырда элита теориясе алга таба үсеш ала. Сәясәт белеме галимнәренең күпчелеге, карашларындагы аермага карамастан, сәяси элитаның төп билгесенә — сәяси карарлар кабул итүгә даими йогынты ясаучы кешеләр төркеменә керүгә игътибар бирә. Төрле илләрдә *сәяси элитага* дәүләт һәм хөкүмәт башлыклары, министрлар, парламент палаталары җитәкчеләре, парламент фракцияләре һәм комитетлары, сәяси партия лидерлары, төбәк җитәкчеләре (администрация башлыклары, закон чыгару җыелышы рәисләре, төбәкнең партия лидерлары), эре иҗтимагый-сәяси оешмалары җитәкчеләре һ.б. санала. Уннарча миллион халкы булган илләрдә сәяси элита берничә йөз яисә (аңа керүнең башка билгеләреннән файдаланганда) берничә мең кешедән торырга мөмкин.

Шул ук вакытта сәяси элитадан гайре төрле шартларда дәүләт сәясәтенә йогынты ясый алучы башка элита булуы да танылa. Барыннан да элек бу — *икътисади элита* (иң зур корпорация, банклар хуҗалары, эшмәкәрләр берләшмәләре җитәкчеләре һ.б.). Мәгълүм бер шартларда икътисади һәм сәяси хакимиятнең берләшүе олигархик идарә итүгә китерә. Халыкара хәлнең кискенләшүе шартларында *хәрби элитаның* (иң югары генералитет, хәрби округ командующийлары һ.б.) йогынтысы арта. Хәрби түнтәреш очрагында хәрби элита хакимиятне үз кулына ала. Билгеле бер чорларда *мәгълүмати элитаның* (күп тиражлы газета һәм журнал редакторлары, радио һәм бигрәк тә электрон массакүләм мәгълүмат чаралары ияләре, әйдәп баручы сәяси күзәтчеләр) йогынтысы көчәя. Сәяси карарлар кабул итү мөмкинлеге сәяси җитәкчеләр өчен документлар әзерләүдә җавап бирүче *административ элита* (дәүләт аппаратында югары вазифалар биләүче чиновниклар)

да бар. Билгеле бер мәсьәләләрне хәл итүгә тиешле проблемалар буенча белемгә ия *фәнни элита* да (әйдәп баручы галимнәр, эре фәнни үзәк җитәкчеләре) тәэсир итә ала.

Элита ничек формалаша (рекрутлаша) соң? Аңа керүче кешеләрне сайлап алу ничек бара? Сәясәт фәнендә сайлап алуның ябык һәм ачык системалары аерып карала. Традицион, авторитар-диктаторлык һәм тоталитар сәяси системалар өчен хас ябык системада сайлап алу югары җитәкчеләрнең тар даирәсе тарафыннан башкарыла. Бу очракта рекрутланучыларның яше, белеме, дәүләт аппаратының түбәнге катларындагы уңышлы карьерасы исәпкә алына. Мондый система элитаның халыктан аерылуына, аның өстенлекле кастага әверелүенә китерә. Демократик дәүләтләргә хас ачык система хакимиятнең төрле органнарына сайлауларның зур әһәмияте, аңа теләсә нинди иҗтимагый катлаулардан чыгучыларны кертү мөмкинлеге, югары конкурентлылык һәм рекрутланучыларның шәхси сыйфатлары мөһим булуы белән үзенчәлекле.

Элита теориясен эшләүнең башлангыч этабында ул демократия идеяләренә каршы куела («йә азчылык хакимияте, йә күпчелек хакимияте»). Аннан соң аларны кушарга маташалар. Бу омтылыш идарәче сыйныфның төрле төркемнәре булып торучы күпчелек элиталар барлыгын тануда; элиталар конкуренциясе (аларны сайлаучы сайлап ала бит) турындагы нигезләмәдә; элиталарның бер-берсен контрольдә тотуы идеясендә; элита составын демократик сайлаулар аша яңартуда чагыла.

Төрлечә якын килүчеләр булса да, сәясәт фәне хакимият карарлары кабул итүгә йогынты ясаучы идарәче элитаның актив ролен таный. Сәяси белемнәр галимнәре моны түбәндәгечә аңлата:

— кешеләрнең психологик, социаль һәм интеллектуаль яктан тигез булмавы;

— халыкның киң катлаулары сәяси яктан пассив булу;

— профессиональ идарәче хезмәтенең иҗтимагый әһәмияте;

— идарәче эшчәнлеге ача торган өстенлекләр алу мөмкинлекләре белән.

Хәзерге заман сәяси элитасының һөнәри эшлекле сыйфатларының кыйммәтен ассызыклап, тикшеренүчеләр бу сыйфатларның башка яхшы яклар, шул исәптән әхлакый сыйфатлар белән үрелеп бармаска да мөмкин булуын билгеләп үтә. Әгәр дә берәүләргә хакимияткә килү уртак муллыкка хезмәт итү белән бәйле булса, икенчеләре өчен еш кына алгы планга эгоистик омтылышлар чыга.

1917 елгы революция алдыннан Россия сәяси элитасы югары чиновниклардан торган социаль-идарәче катлаудан

гыйбарәт була. Соңрак СССРда партия-дәүләт бюрократиясе барлыкка килә, ул (хакимият белән бергә) үзенә өстенлекләр дә ала. Җитәкчелек эшенә күтәрү КПСС партия комитетлары тарафыннан тиешле вазифалар исемлеге (номенклатурасы) буенча тормышка ашырыла. Шуңа да совет сәяси элитасы «номенклатура» дип атала.

XX гасырның 90 нчы елларындагы тамырдан үзгәрешләр нәтиҗәсендә Россиядә яңа сәяси элита барлыкка килә башлады. Ул элеккеләреннән күпкә яшьрәк. Әгәр элек аның вәкилләре арасында техник һәм партия-сәяси белемле кешеләр күбрәк булса, яңа элита исә юристлар, икътисадчылар һ.б. белән тулыланды. Төрле социаль төркемнәрдән чыккан күпсанлы затлар белән беррәттән яңа элитага элекке номенклатура вәкилләре дә байтак керде. Номенклатур элемтәләрен саклаган дәүләт бюрократиясенең роле элеккечә үк зур. Тикшеренүчеләр Россия сәяси элитасының күпшәклеген, анда каршылыклы төркемнәр булуын, ил үсеше юлларына бердәм караш булмавын, коррупция яшәп килүен билгеләп үтә. Яңа элита формалаштыру процессы тәмамланмаган әле.

СӘЯСИ ЛИДЕРЛЫК

Тарихны өйрәнгәндә сез бик күп кешеләр, ә кайчакта тулы бер халыклар хуплаган һәм аларга ияргән эшлеклеләр турында белдегез.

Андый кешеләрне «лидер» диләр. Инглиз телендә «лидер» «җитәкче, әйдәп баручы» дигән сүз. Әйдәп баручы булгач, аңа иярүчеләр, ягъни аның тарафдарлары да була. Спортта «лидер артыннан куу» дигән гыйбарә бар. Теләсә кайсы кече төркемдә коллективта башкалар колак салучы, үзен барысы да яки күпләр хуплаучы кешеләр бар.

Лидер һәр оешмада бар. Күп кеше катнашындагы берникди эшчәнлек тә оештыру, җитәкчелек итүдән башка мөмкин түгел.

Искә төшерик: сәясәт — эшчәнлекнең аерым бер төре ул; анда зур социаль төркемнәрнең үз мәнфәгатьләрен яклау өчен дәүләт хакимиятен яулап алуга һәм аннан файдалануга юнәлтелгән мәнфәгатьләре чагыла. (Исегезгә төшерегез: сәяси эшчәнлек башка эшчәнлек төрләреннән нәрсәсе белән аерыла? Сәясәтнең субъектлары нинди?)

Лидер башка кешеләр тәртибенә йогынты ясый. Әмма барлык кешеләр дә, үзара хезмәттәшлек итеп, теге яки бу дәрәҗәдә бер-берсенә тәэсир итә. **Сәяси лидерлык** ул теләсә нинди йогынты түгел, ә беренчедән, *даими* йогынты; икенчедән, *лидердан объектка гына юнәлгән*; өченчедән, бөтен җәмгыятьне

яисә зур төркем кешеләрне үз эченә алган *киң* йогынты; дүртенчедән, лидер үз абруена таяна. Соңгы аерма безне «сәяси лидер» һәм «сәяси җитәкче» төшенчәләре чагыштырмасы турындагы мәсьәләгә якын китерә.

Хәзерге шартларда сәяси лидер, кагыйдә буларак, оешма (гадәттә, сәяси партия) яисә дәүләт җитәкчесе, ягъни сәяси җитәкче булып тора.

Сәясәт бөтен җәмгыять күләмендә тормышка ашырыла һәм дәүләт хакимиятеннән файдалану белән бәйле. Зур булмаган коллективтагы лидерлыктан аермалы буларак, заманча сәяси лидерлыкны сәяси оешмадан башка күз алдына китерергә мөмкин түгел. Дәүләтне дә кертеп, шундый оешмада сәяси лидер җитәкче вазифасын били, идарәче функциясен башкара. Сәяси җитәкченең статусы аның урынын, хокук һәм вәкаләтләрен формаль төстә беркетү белән бәйле: җитәкче кешеләргә үзенең шәхси абруе аркасында гына түгел, рәсми документларда булган, аңа башкалар өчен мәҗбүри карарлар кабул итү хокукы биргән үз урыны ярдәмендә дә йогынты ясый.

Абруйлы, җәмгыятьтә танылган сәясәтченең җитәкче вазифасын биләмәү очрагы да була. Аның торышын «формаль булмаган лидерлык» дип атыйлар. Мондый лидерның зур төркем кешеләргә йогынты ясау мөмкинлеге чагыштырмача зур түгел.

Башка төрле вазгыять тә булырга мөмкин. Карарлар кабул итәргә формаль хокукы булган җитәкченең абруе булмый, ышанычка, хөрмәткә ирешә алмый. Сәяси лидер — күпсанлы тарафдарлары, дәвамчылары, аңа ярдәм итәргә, аның артыннан барырга әзер затлары булган сәясәтче ул.

Шулай итеп, сәяси лидерлык зур төркем кешеләргә йогынты ясауда чагыла; ул, беренчедән, *лидерның шәхси сыйфатлары*, аның абруе, үз артыннан тарафдарларын ияртү сәләте белән, икенчедән, хакимияткә ия булуны күздә тотучы *формаль-вазифаи* статусы белән бәйле. (Мисал итеп, узган чордагы һәм хәзерге заманда сезгә мәгълүм сәяси лидерларны атагыз.)

СӘЯСИ ЛИДЕРНЫҢ РОЛЕ

Сәяси лидер, инде күргәнебезчә, әйдәүче сәяси фигура: дәүләт башлыгы, сәяси партия, җәмәгать оешмасы, хәрәкәт җитәкчесе булып тора. Аның роле, функцияләре нинди соң?

1. Лидер сәяси хәлне анализлый, җәмгыятьнең халәтен дөрес бәяли. Ул җәмгыятьтәге төрле төркем ихтыяҗларын сизгер тоя, аларны гомумиләштерә һәм үз эшчәнлегендә исәпкә ала. Шулай ук массаларның сәяси карашларындагы үзгәрешләрне үз вакытында күрү һәм сәясәтне корректировкалау бик мөһим.

2. Хәлне анализлау, төрле төркемнәрнең нәрсә көтүе һәм ихтыяҗлары нигезендә һәм үз идеалларына туры китереп, лидер максатлар формалаштыра, аларга ирешү чараларын билгели, хәрәкәт итү программасын эшли. Ул максатлар һәм билгеләнгән гамәлләр халыкның кызыксынган төркемнәре ихтыяҗларына җавап бирүе, реаль мөмкинлекләргә туры килүе турында кайгырта, оптималь сәяси карарлар таба.

3. Сәяси лидер хакимиятнең халык белән элемтәсен ныгытырга омтыла, үз сәяси позициясен аңлата, аңа массакүләм яклау тәэмин итә.

Сәяси лидер үз гамәлләренең этәргеч көчен җәмгыятькә ачу, эшләнгән программаны аңлауны тәэмин итү зарур дип саный. Ул массалар активлыгын программ бурычларны үтәүгә юнәлтелгән чаралар күрә. Бу вакытта дәүләт органнары, сәяси партияләр, җәмәгать оешмалары, тарафдарларының төрле төркемнәре хәрәкәтләрен яраштыру, билгеләнгән максатка хәрәкәт итү барышында алар арасында үзара хезмәттәшлекне җайга салу зур әһәмият ала.

4. Сәяси лидер үз оешмасының бердәмлеге, тарафдарларны туплау хакында кайгырта. Гомуммилли лидерның бурычы — җәмгыятьне таркалудан, гражданнар капма-каршылыгыннан саклау, тырышлыкны берләштерү, үзәктән качу тенденцияләренә, социаль яшәеш нигезләренең таркалуына каршы тору. Ул җәмгыятьтәге мөнәсәбәтләрне җайга салырга, төрле төркем, оешмалар, дәүләт хакимияте буыннары бәрелешендә арбитр функциясен үтәргә тиеш.

Аның бурычы — законлылыкны һәм җәмәгать тәртибен саклау, гражданнарны гаделсезлектән һәм законсызлыктан яклау.

5. Сәяси лидер, партия лидеры башка төркемнәр белән мөнәсәбәтләрдә билгеле бер иҗтимагый төркем исеменнән эш йөртә, бәхәскә керүчеләр белән сәяси әңгәмә алып бара, партияләр, оешмалар, хәрәкәтләр белән тышкы мөнәсәбәтләрне тормышка ашыра. Ил лидеры аның эчендә дәүләт исеменнән чыгыш ясый һәм илне халыкара аренада тәкъдим итә.

Атап үтелгән функцияләрне барлык сәясәтчеләр дә башкара алмый. Сәяси лидер бик күп сыйфатларга ия булырга тиеш, югыйсә аның эшчәнлеге уңышка ирешми. Ул үткен акыллы, анализлауга сәләтле, нык ихтыярлы, кыю һәм тәвәккәл булырга тиеш. Тарафдарлары лидердан намуслылык, иҗтимагый бурычына тугрылык, җәмәгать муллыгы турында кайгыртучанлык һәм гаделлек көтә. Әлеге сыйфатлар теләсә кемне бизәр иде, ә лидердан тагын да күбрәк таләп ителә. Ул әле аралашучан да булырга, килеп туган хәлне тиз һәм төгәл бәяләргә сәләтле, сәяси интуициягә ия булырга, проблемаларга яңача карый белергә тиеш.

Ул җәмгыятьнең үсеш тенденциясен тотып алу осталыгына ия булырга, киңәшчеләре тәкъдим иткән вариантлардан иң оптимален дөрес сайлап алырга тиеш.

Күренеп торган идарәче сәләте, белемнәр һәм компетентлык, башка фикерләргә дәлилле каршы тору сәләте, сәяси зирәклек, сыгылмалы акыл, карпма-каршы көчләр арасында маневрлау осталыгы булу зарур.

Кешеләргә хисси ярдәм итәрлек сыйфатлар: үз-үзен тоту осталыгы, үзенә игътибар җәлеп итү таланты, инандыру һәм ораторлык сәләте, юмор хисе шулай ук зур әһәмияткә ия.

Барлык сәяси лидерлар да атап үтелгән сыйфатларга ия түгел; әмма алар күбрәк булган саен, ул үз функцияләрен уңышлырак үти. (Сез ничек уйлыйсыз: элеккеге яки хәзерге сәяси лидерларның кайсы кирәкле сыйфатларга иң югары дәрәҗәдә ия?)

ЛИДЕРЛЫК ТИПЛАРЫ

Сәясәт турындагы фән — политологиядә *лидерлык типларын* билгеләүгә төрлечә якын килүләр бар.

Аларның берсе *лидерлыкның масштаблары* төрлелегенә нигезләнгән. Гомуммилли (милләт, бөтен халык) лидерларын; билгеле бер сыйныф яисә башка зур социаль төркем лидерларын; җәмәгать оешмасы яки хәрәкәте (барыннан да элек сәяси партия) лидерларын аерып карыйлар. Социаль төркем яисә сәяси партия лидерлары бөтен дәүләт (гомуммилли) масштабында йә аерым төбәктә (өлкәдә, республикада, җирлектә, штатта) йогынты ясарга мөмкин.

Икенче төрле якын килү лидерлык *стиле төрлелегенә* нигезләнә.

Демократик стиль лидерның үз функцияләрен үтәгәндә аңа ияреп баручыларның активлыгына таянуы, аларның фикерен исәпкә алуы, эшкә иҗади карашны үстерүе белән үзенчәлекле. Ул кешеләргә карата игелекле, тәнкыйть өчен ачык, хезмәттәшлек атмосферасы тудыра.

Авторитар стиль санкцияләр белән янауга нигезләнгән берүзе юнәлеш биреп йогынты ясауны күздә тота. Ул лидер ролен абсолютлаштыра, тәнкыйтькә, башкача фикер йөртүгә юл куймый.

Немец галиме М.Вебер (1864–1920) типологиясе киң танылды. Ул лидерлыкның өч тибын аерып карый: *традицион, легаль (закон нигезендә), харизматик.*

Традицион лидерлык күптәннән урнашкан гореф-гадәтләргә, әйтик, монархия дәүләтләрендә хакимиятнең атасыннан

улына мирас итеп калдырылуы тәртибенең какшамаслыгына нигезләнгән. Әмма гореф-гадәт буенча хакимлек алган барлык монархлар да милләтнең чын сәяси лидеры була алмый. Һәм, гомумән, лидерлыкның бу тибы тарихка китеп бара.

Күп кенә илләрдә аңа алмашка закон нигезендә (легаль) лидерлык килде. Мәгълүм бер законлы процедура нигезендә сайланган сәясәтче лидер була. Аның абруе сайлауларның демократик кагыйдәләр буенча ярыш һәм конкуренция шартларында узуына ышанычка таяна.

Аннан соңгы тип — харизматик лидерлык. «Харизм» сүзе грек теленнән алынган һәм «игелек, Ходай бүләге» дигәнне аңлата. Харизматик лидер экстраординар, ягъни гайре табигый, башкаларда булмаган яки зәгыйфь кенә күренгән сыйфатларга ия. Кагыйдә буларак, харизматик типтагы лидерлар кризис чорында, бик текә иҗтимагый борылышлар — революция, сугыш, эре социаль реформалар вакытында, социаль яңарыш бурычларын үтәүгә җәмгыятьнең бөтен көчен мобилизацияләргә кирәк чагында пәйда була. Харизматик лидерның абруе һәм йогынтысы аның аерым бер идарәчелек сәләтенә, барлык проблемаларны чишә алырлык талантына нык ышануна нигезләнгән.

Лидерлыкның бу өч төрен чагыштырып карау, аларның беренчесе — гореф-гадәткә, икенчесе — акылга (шуңа күрә кайчакта аны «рациональ-легаль» тип дип атыйлар), ә өченчесе — ышануга нигезләнә дип билгеләп үтәргә мөмкинлек бирә. Беренче ике типтагы лидерлар җәмгыять үсешенең тыныч чорында гадәти, көндәлек бурычларны хәл иткәндә яхшы. Харизматик типтагы лидерлар үзгәрешләрне алга куя, аларга үткәннәрне кире кагу, яңага тартылу хас.

Америка сәясәт белгече М.Г.Херманн сәяси житәкчелек характерына йогынты ясаучы факторларны бүлеп карый. Аның фикеренчә, бу факторлар мондый:

— лидерның төп сәяси инанулары;

— лидерның сәяси стиле;

— сәяси җитәкче урынын биләргә омтылучы лидерның мотивлары;

— лидерның басымга һәм стресска реакциясе;

— лидер беренче тапкыр сәяси җитәкче хәлендә калган хәлләр;

— лидерның элеккеге сәяси тәҗрибәсе;

— лидер үз эшчәнлеген башлагандагы сәяси климат.

Теләсә кайсы сәяси лидер эшчәнлеген әлеге факторлар күзлегеннән карап өйрәнү аңа чагыштырмача тулы характеристика бирү мөмкинлеге тудыра.

ГАМӘЛИ ЙОМГАКЛАР

1 Сәясәттә актив эш итүче лидерга карата үз мөнәсәбәтеңне билгеләүдә сәяси лидер өчен кирәкле сыйфатларны белү ярдәм итә. Сәяси лидерлар илдә барган вакыйгаларга сизелерлек йогынты ясаганлыктан, аларның барча халык һәм үзегез кергән социаль төркем мәнфәгатьләрен уңышлы якларга сәләтлеләрен хуплавы мөһим.

2 Сәяси лидерлар башка кешеләргә йогынты ясап кына калмый, кагыйдә буларак, җавап элемтәсенә дә мохтаҗлар. Әгәр сез зур иҗтимагый әһәмияткә ия проблема булуын аңласагыз һәм аны хәл итүнең файдаланылмаган ысулын яисә үзегез ышанган лидер гамәлләрендә җитди хата күрсәгез, үз фикерегезне аңа җиткерергә тырышыгыз. Моның өчен сез дәүләт органнарына мөрәҗәгать итүнең конституциячел хокукыннан файдалана, аерым бер партия лидер адресына хат юллый, йә аңа массакүләм мәгълүмат чаралары аша мөрәҗәгать итә аласыз.

3 Сәләтегезне бәяләргә тырышып карагыз: бәлки, үзегездә лидерлык башлангычлары табарсыз. Теге яки бу проблеманы хәл иткәндә инициатива күрсәтәсезме? Теге яки бу вазгыятьтә сез кабул иткән карарларның дөреслеге расландымы? Сезне башкалар хуплыймы? Нинди дә булса файдалы эш үтәү өчен бер төркем кешенең уртак тырышлыгын оештырырга туры килгәне бармы? Ул уңышлы барып чыктымы? Сүз төркемдә лидерлык турында бара. Сәяси лидер булып кешеләрне артыннан ияртү сәләтен тагын да үстергән, сәясәттә тирән белемле, социаль проблемаларны иҗади хәл итүче зат кына өлгерә ала.

ДОКУМЕНТ

Америка сәясәт белгече ***М.Г.Херманның*** лидерлыкның состав өлешләре турындагы хезмәтеннән.

Лидерлыкны билгеләү ысулларының күпчелеген өйрәнү дүрт төрле якын килүне бүлеп карарга мөмкинлек бирә.

Беренче ысул лидерның максатны билгеләвеннән һәм үзе яклыларга юнәлеш күрсәтүдән, аларга вәгъдә бирүе һәм үз артыннан ияртүеннән гыйбарәт. Лидерлыкка болай якын килгәндә, игътибар үзәгендә лидер һәм аңа хас сыйфатлар була. Әлеге лидерның нindилеген, аның стратегик мак-

сатларын белгән хәлдә, без аның җитәкчелек ролен ничек башкаруын да тасвирлый алабыз. Нәкъ менә шундый лидер имиджыннан «бөек кеше» турында күзаллау һәм аның җитәкчелек роленә аерым якын килү үсеп чыкты.

Икенче төрле якын килү тарафдарлары лидерны «коммивояжер» буларак кабул итә. Бу очракта лидерлык кешеләр ихтыяҗларына игътибарлы карашны һәм аларга әлеге ихтыяҗларны канәгатьләндерүдә ярдәм итүне күздә тота. Кеше ихтыяҗларына һәм теләкләренә сизгер караш кешеләрне сез аңа ярдәм итә алачагыгызга инандыру сәләте кебек үк мөһим. Бу караш нигезендә бар нәрсә дә лидер һәм аның тарафдарлары арасындагы мөнәсәбәтләрдән тора.

Өченче төрле якын килү лидерда «марионетка» күрүдән гыйбарәт. Ягъни лидер белән аның тарафдарлары җитәкчелек итә һәм аңа көч бирә, алар җепләрне тарткалыйлар. Лидер бу төркемнең агенты була, аның максатларын чагылдыра һәм аның исеменнән эш йөртә. Бу очракта җитәкчелек роле ничек тормышка ашырылганын аңлар өчен, лидер тарафдарларының ни көтүләрен һәм максатларын өйрәнү зарур.

Дүртенче төр якын килү лидерга «янгын сүндерүче» сыйфатында караудан гыйбарәт. Бу очракта җитәкчелек роле әйләнә-тирә чынбарлыкта ни булуына җавап рәвешендә барлыкка килә. Шуңа күрә, лидерлык феномены барлыкка килгән тирә-юнь чынбарлыгын өйрәнеп, без аның тамырларын аңлый алабыз. Әйләнә-тирә чынбарлык ихтыяҗ, каршылыклар булдыра һәм лидер белән аның тарафдарлары өчен мөмкинлекләр ача.

Әгәр дә урамда сорашып белешү үткәрсәң, мөгаен, көчле сәяси лидерга карата... барлык дүрт төрле якын килүне дә кертүләрен ачыкларга мөмкин булыр иде. Мондый лидер алдан күрү сәләтенә ия булырга, шул ук вакытта үз тарафдарлары теләкләренә сизгерлек күрсәтергә һәм аларны гамәлләр өчен уңайлы вакытта инанулары хакына эшләргә мәҗбүр итәргә сәләтле дә булырга тиеш.

Документка сораулар һәм биремнәр

1. Лидерны нинди сыйфатлар «бөек кеше» буларак характерлый? **2.** Документ авторы «коммивояжер» буларак кабул ителүче лидерга хас дип билгеләп үткән сыйфатларны атагыз. **3.** «Марионетка» булып күренүче лидерны нәрсә характерлый? **4.** «Янгын сүндерүче» дип аталган лидер

эшчәнлеге ни белән аерыла? **5.** М.Г.Херманн характерлаган сәяси лидерлардан кайсы тип, сезнең карашыгызча, яхшырак? Нигә? **6.** Сез гади кешеләр лидердан барлык дүрт төрле якын килүне дә көтә диган фикер белән килешәсезме? Үз карашыгызны дәлилләгез. **7.** Документта китерелгән классификацияне параграфтагысы белән чагыштырыгыз. Сәяси лидерлыкны аңлау өчен кайсы классификация мөһимрәк? Җавабыгызны дәлилләгез.

ҮЗ-ҮЗЕҢНЕ ТИКШЕРҮ ӨЧЕН СОРАУЛАР

1. Нәрсә ул сәяси элита? **2.** Нинди элита төркемнәре сәяси карарлар кабул итүгә йогынты ясый? **3.** Сәяси элита ничек рекрутлана? **4.** Кем ул сәяси лидер? Сәяси лидерлыкның төп билгеләре нинди? **5.** Сәяси лидерның төп функцияләрен санап үтегез. **6.** Сәяси лидер нинди сыйфатларга ия булырга тиеш? **7.** Традицион, легаль (закон нигезендә) һәм харизматик лидерлыкны чагыштырып карагыз. Бу тип лидерлыкларда нәрсә уртак, ә нәрсә аермалы?

БИРЕМНӘР

1. Үткәндәге яисә хәзерге сәяси лидерларның кайсы сезгә кызыклырак булып күренә? М.Г.Херманн санап үткән факторлар комплексына таянып, аларга характеристика бирергә тырышып карагыз.

2. У. Черчилль болай дигән: «Дәүләт эшлеклесенең сәясәтчедән аермасы шунда ки, сәясәтче алдагы сайлауларга йөз тота, ә дәүләт эшлеклесе киләчәк буын турында уйлый». Сез бу раслама белән килешәсезме? Җавабыгызны дәлилләгез.

3. Социологик сорашып-белешүләр Россия гражданнары тарафыннан югары бәяләнүче элита вәкилләре рейтингын (ягъни әһәмиятлелегенә саннарда бәя бирүне) билгеләргә мөмкинлек бирә. 2008 ел йомгаклары буенча рейтингның беренче юлын В.В.Путин биләде (сораштыруда катнашучыларның 69,61%), икенче урында — Д.А.Медведев (40,20%), элита вәкилләренең беренче унлыгына В.В.Жириновский (12,20%), С.К.Шойгу (11,36%) керде. Бу күрсәткечләрдән мөмкин булган нәтиҗәне чыгарыгыз.

4. 1996 елда сәяси лидерларның уңышка ирешү факторлары турында халык фикере ачыкланды. Катнашучыларның 53% «акыл, интеллект, белемнәр» дип атады, 48% «аның Россияне кризистан чыгару программасын» күрсәтте, 45% — «һөнәрилекне», 28% «ихтыяр, максатка омтылыш» диде, 38% — «гади кешеләр

хуплавы», 16% — «массакүләм мәгълүмат чаралары ярдәме», 20% «финанс структуралары булышлыгы» дип күрсәтте.

Әгәр сорашып-белешү сез дәреслектәге бу параграфны өйрәнгән көннәрдә булса, сезнең карашыгызча, халык фикере нинди булыр иде? Шәхсән үзегез санап үтелгән факторларны нинди эзлеклелектә куяр идегез? Бу исемлеккә уңышның нинди факторларын кертер идегез. Җавабыгызны шәрехләгез.

ЗИРӘКЛӘР ФИКЕРЕ

«Лидер ачыктан-ачык эшли,
босс исә ябык ишекләр артында.
Лидер үзе артыннан ияртә, ә босс идарә итә».

Т.Рузвельт (1858–1919), АКШ президенты

§ 17. Хәзерге Россиядә демографик вазгыять һәм тулы булмаган гаиләләр проблемасы

Тулы һәм тулы булмаган гаиләләр турында статистика нәрсә белә? Без, россиялеләрнең, ничәү икәнлеген белү нигә кирәк? Илдәге хәзерге демографик вазгыять нәрсә белән яный?

ХӘЗЕРГЕ РОССИЯДӘ ГАИЛӘ ҮСЕШЕ ТЕНДЕНЦИЯЛӘРЕ

Бүген гаилә һәм гаилә кыйммәтләре кризисы турында чаң сукмаган бер генә популяр басма яисә массакүләм мәгълүмат чарасы да юктыр, мөгаен. Бу яктан Россия дә мактана алмый. Гаиләнең хәле чыннан да шулай киеренкеме соң?

Статистик белешмәләр һәм социологик сорашып-белешүләр хәзерге Россиядә гаилә торышының шактый каршылыклы булуын күрсәтә.

Бер яктан караганда, теркәлгән никахлар саны артуы күзәтелә. 2001 елда ул алдагы елга караганда 11%ка арткан һәм соңгы елларда беренче тапкыр 1 миллионнан артып киткән. «өйләнешү базарында» вазгыять уңай кебек. Кияү һәм кәләшләрнең киң таралган яшь аермасыннан чыгып караганда (кияү кәләштән, кагыйдә буларак, 2 елга өлкәнрәк), 2001 елда бер потенциаль кәләшкә бер потенциаль кияү туры килгән.

Әмма 2002 елгы халык исәбен алу күрсәткәнчә, хатын-кызлар саны ирләр саныннан 10 миллионга артып китә

(77,6 млн һәм 67,6 млн). 1000 ир-атка 1147 хатын-кыз туры килә. Хатын-кызларның ирләрдән күбрәк булуы 33 яшьтән арткач күзәтелә.

Моңа соңгы халык исәбен алу буенча 16 яшьтән өлкәнрәк 1000 кешенең 210 ы беркайчан да никахта булмавын өстәп әйтергә мөмкин (1989 елда — 161); 572 кеше никахлы (1989 елда — 653); 114 тол (1989 елда — 110); 94 е аерылышкан (1989 елда — 72). (Китерелгән белешмәләрдән нинди нәтиҗә ясарга була?)

Демографлар өйләнешүчеләрнең яше артуны билгели. Алар бу фактны яшьләрнең гаилә тормышы өчен матди нигез булдыру, укуларын тәмамлау теләге белән аңлата. Мондый тенденция нык үскән илләрнең күпчелегенә хас, ул Россиядә ачык чагылыш таба.

Соңгы вакыттагы тагын бер тенденция — бөтен дөньяда аерылышулар саны арта. Россиядә көн саен уртача 3616 никах һәм 1534 аерылышу теркәлә, нәтиҗәдә 1288 бала ана-атаның берсеннән башка кала.

Аерылышуларның сәбәпләре арасында беренче урыннарны ир яки хатынның эчкечелеге яисә наркомания били, аннан соң каршылыклар һәм җәнҗаллар, бер-берсенең туганнары белән начар мөнәсәбәт һәм аларның яшь гаилә мөнәсәбәтләренә тыкшынуы, ир яки хатынның хыянәте, сексуаль канәгатьсезлек бара. Әйтелгән сәбәпләрдә уртак сыйфатны аерып күрсәтергә мөмкин: ул — ир белән хатында никахка тиешле социаль-психологик әзерлек, гаилә рольләрен башкару осталыгы булмау.

Тагын бер сизелерлек тенденция — гаиләдә беренче бала туу вакытына ата-ананың яше арта бару. Бала табуны соңгарак калдырып, хәзерге заман кешесе карьера ясап калырга, матди муллыка ирешергә омтыла. Индустриаль җәмгыятькә кадәрге җәмгыятьтә гаиләнең муллыгы андагы хезмәткәрләр санына турыдан-туры бәйле булса, хәзер вазгыять тамырдан үзгәрә.

Халык санының тотрыклылыгын тәэмин итү өчен һәр хатын уртача 2,5–3 бала табарга тиеш дип саный демографлар. Әмма мондый оптимистик саннар өчен нигез юк әле. Күпчелек очракта демографик хәл гаиләнең яшәп килгән тибы өстенлек итүгә бәйле.

Социологлар фикеренчә, хәзерге заман индустриаль җәмгыятендә типик гаилә моделе — тулы, нуклеар (латинча — *nucleus* — төш, үзәк) гаилә, никахлары теркәлгән ирле-хатынлы пардан һәм аларның балаларыннан тора, гаиләдә ике эшләүче бар. Уртача гаилә әгъзалары саны — 3,6 кеше. Хәзерге заман гаиләсе җәмгыять үсешендәге тирән үзгәрешләр китереп чыгарган җитди трансформация кичерә. Бер үк вакытта ул яшьләрнең тормыш планнарында мөһим урын алып тора.

Яшьләр мохитендә өйләнешүгә этәргеч бирүчеләр арасында мәхәббәт, «башкалар кебек эшлә» стереотибы, исәп-хисап өстенлек итә. Хәзерге яшьләр үзләре сайлаган парларда акыл, игелеклелек, тәртиплелек, ышанычлылык, тугрылыклылык, балаларга мәхәббәт, тыйнаклык, түземлелек кебек сыйфатларга өстенлек бирә. Тышкы күркәмлек һич тә беренче урында тормый. Хатын-кызларның идеалы эшлекле, гаиләне матди яктан тәэмин итәрлек, тактлы, юмор хисенә ия һәм зарарлы гадәтләре булмаган ирләргә йөз тота. Ирләр хатын-кыз идеалын тугрылык, тыйнаклык, йомшак күңеллелек, йорт җанлылык, әйбәт холык кебек сыйфатларда күрә.

Гаилә зурлыгы кимү, гаилә эчендәге бәйләнешләрнең йомшавы аның тотрыклылыгында тискәре чагыла. Моннан тыш гаилә институтында функциональ үзгәрешләр дә бара: хатын кызларның ике җирдә (эштә һәм өйдә) хезмәт итүе эффекты, муллык чыганагының характеры һәм күләмендәге үзгәрешләр белән бәйле рәвештә гаиләдә ирләрнең абруе төшү, гаиләдә тәрбия функциясенең кимүе.

ТУЛЫ БУЛМАГАН ГАИЛӘЛӘР ПРОБЛЕМАСЫ

Әгәр без хәзерге гаилә турында сөйләшүне идеаль гаилә моделе белән чикләсәк, хаклыкка хилафлык кылыр идек. Төрле белгечлекләр галимнәре «гаилә бердәмлегенең өзгәләнүен, гаилә әгъзаларының берсе яки күбрәге үзенең бурычларын төгәл үти алмаганга күрә, социаль рольләр структурасының бозылуын» билгеләп үтә.

Идеаль гаилә моделеннән тайпылуларның иң күп таралганнары сыйфатында түбәндәгеләр күрсәтелә:

— баштан ук гаиләнең бер әгъзасы булмаган гаилә төркеме (балалы ялгыз ана):

— ир яки хатынның аңлы аерылышуы аркасында таркалган гаилә; никахны юкка чыгару, бүлешү, аерылышу;

— тышкы сәбәпләр китереп чыгарган кризис кичерүче гаилә: ире яки хатыны үлү, төрмәгә ябылу һ.б.ш.;

— «буш кабык кебек» гаилә, ир белән хатын бергә яши, ләкин бер-берсе белән бик аз аралаша.

Демография өчен чагыштырмача яңа тенденцияләрнең берсе — никахтан тыш туган балалар арту. 1994–2000 елларда аларның өлеше барлык туучылар санынннан 19,6 дан 27,9%ка җитте. Никахтан тыш тудыручы аналар яше ике иң чик билгегә ия — 20 яшькә кадәр һәм 30–35 яшьләрдә. Беренче чик сексуаль мөнәсәбәтләр башлану яшенең түбәнәюен, никахка

кадәр көмәнле булуның артуын күрсәтә, ә икенчесе — күп очракта кайбер ирләр яки кайбер хатыннар ягыннан никахны теркәүдән баш тартканда аңлы рәвештә балага узу. Шунысы кызыклы: 2002 елгы халык санын алу белешмәләре буенча үзләрен кияүдә дип күрсәткән хатыннар үзләрен өйләнгән дип күрсәтүче ирләрдән 65 меңгә артып китә (1989 елгы халык санын алуда андыйлар 28 мең иде). Балаларын теркәлмәгән никахта тәрбияләүче күп кенә хатыннар үзләрен кияүдә дип, ә шул ук балаларның әтиләре — әле өйләнмәгән дип саный.

Бер яктан — никахтан тыш бала табуның артуы, икенчедән, теркәлмәгән ирле-хатынлыларның ишәюе никах һәм гаилә институтларының бүленү тенденциясен күрсәтә. Гаиләне өйрәнү белән шөгыльләнүче галимнәрнең әле бу тенденцияне аңлыйсы бар. Әмма шунысы күренеп тора: гаилә бәйләнешләренең таркалуы яки йомшаруы, илдә тулы булмаган гаиләләрнең артуы гаиләнең төп функцияләрен үтәвендә гаять тискәре чагылыш таба. Тулы булмаган гаиләдә матди проблемалар ешрак барлыкка килеп кенә калмый, тагын да куркынычрагы: тулы кыйммәтле гаилә мөнәсәбәтләре югала бара. Әти-әнисенең берәрсе булмаганда бала тулы кыйммәтле аралашмый, ялны бергә уздыру ихтыяҗын тулы канәгатьләндерми, психологик яклангалык тоя алмый.

Моннан тыш, тулы булмаган гаиләдә социальләшү функциясе өлешчә генә гамәлгә аша, чөнки бала гаиләле кеше ролен үзләштерүдә охшап үсү өчен уңай образдан мәхрүм. Гаилә тормышын оештыруда киләчәктә уңышсызлыкка юлыкмас өчен тулы булмаган гаиләдәге балаларга үз хаталарында һәм әти-әниләре ялгышлыкларында өйрәнергә туры килә.

Тулы булмаган гаиләләр репродуктив функцияне дә тулысынча үти алмый, бу исә, һичшиксез, гомуми демографик хәлдә чагылыш таба.

РОССИЯ ФЕДЕРАЦИСЕНДӘ ХӘЗЕРГЕ ДЕМОГРАФИК ВАЗГЫЯТЬ

Галимнәр зур шөбһә белән Россиянең демографик хәлендә шактый катлаулы тенденцияләр баруы турында сөйли. Аларның иң мөһимнәрен санап үтик.

Россиялеләр саны кими.

РФ халкы санын 145,2 млн кеше тәшкил итә. Бу күрсәткеч буенча безнең ил Кытай, Һиндстан, АКШ, Индонезия, Бразилия, Пакыстаннан соң 7нче урынны били. Әмма Россия бөтендөнья демографик иерархиясендә үз урынын югалта бара. 2001 ел ахырына дөнья халкы арасында Россия халкының өлеше

2,4% ка кадәр кимеде, һәм бу дәвам итә. 1989 елгы халык исәбен алу белән чагыштырганда халык саны 1,8 миллионга кимеде.

Россия халкы *XX гасырның 60 нчы еллары уртасыннан бирле артмый.*

Узган гасырда безнең ил халык санының торгызылуы «тарайган», ягъни үсешне тәэмин итмәгән берничә чор кичерде. Бу чорларның икесе бөтендөнья сугышлары елларындагы коточкыч үлемнәр белән бәйле. Массачыл репрессияләр дә үз сүзен әйтте.

Икенче бөтендөнья сугышыннан соң балалар үлеме тиз азайды, әмма бер үк вакытта бала туу күрсәткечләре дә кимеде. Ә 1960 еллар уртасыннан бала туу дәрәҗәсе халыкның гади торгызылуы дәрәҗәсеннән дә түбән төште. Хәзер Россия бу «тарайган» чорда туган балаларның үзләре ата-ана булуы нәтиҗәсен кичерә. 1990 елларда бала тууның кискен кимүе болай да авыр хәлне кыенлаштырды. Бүген хәтта әлеге кимүгә кадәрге, әйтик, 1965–1985 еллардагы күрсәткечләргә кайта алсак та, бу безнең ил халкының табигый уңай артуын торгызырга мөмкинлек бирмәс иде. 1930 еллар ахыры яки 1950 еллар башында Россия халкының яртысыннан күбрәге авылда яшәгән чорда булган югары күрсәткечләргә ирешү хәзер мөмкин түгел диярлек.

Нәкъ менә шуңа да Россия халкының тиз кимүенә каршы тору өчен файдаланырга мөмкин булган төп һәм гамәлдә бердәнбер механизм — ул иммиграция. Әмма аның да мөмкинлекләре чиксез түгел. Күпсанлы мигрантлар, бигрәк тә чит телле, башка мәдәни гореф-гадәтләр белән бәйле мигрантлар кабул итү җиңел процесс түгел; ә Россиядәге хәзерге икътисади хәл һәм социаль климат шартларында ул икеләтә авыр. Бүгенге миграция проблемалары — Россия XXI гасырда җавап табарга тиешле яңа проблемаларның берсе.

Нигездә халык аның табигый кимүе, ягъни үлүчеләр санының туучылардан күбрәк булуы аркасында, шулай ук чит илләргә *эмиграцияләгәнгә* кими бара.

2000 елда үлем дәрәҗәсе 1000 кешегә 15,3 кеше тәшкил итте. Иң киң таралган үлем очраклары арасында белгечләр кан әйләнеше, онкология, йөрәк-кан тамыры авырулары һәм бәхетсезлек очракларын атый. Россия халкының гомер озынлыгына алкоголизм һәм наркомания дә тискәре йогынты ясый. Үлемнең бу сәбәпләре сизелерлек яшәрә. Ирләр үлеме дәрәҗәсе хатын-кыз үлеме дәрәҗәсеннән 4 тапкыр, ә икътисади яктан нык үскән илләрдәгедән 2–4 тапкыр югары.

Хезмәткә сәләтле халыкның кимүе

Халык санын алу күрсәткечләре буенча хезмәткә сәләтле халык саны (ирләр — 16–59 яшьтә, хатын-кызлар 16–54 яшьтә)

61% тәшкил итте, хезмәткә сәләтледән яшьрәкләр — 18%, хезмәткә сәләтледән олыраклар 21% булды.

Шулай итеп Россиядә хәзер халык саны белән килеп туган вазгыятьне белгечләр *депопуляция* — тарайган торгызу һәм халык саны кимү дип атыйлар.

Депопуляциянең социаль нәтиҗәләре хезмәт потенциалы, халыкның икътисади активлыгы кимү, аның картаюы перспективасы белән бәйле. Халыкның картаюы үз чиратында социаль тәэминат үсешенә, өлкән кешеләргә медицина хезмәте күрсәтүгә өстәмә таләпләр тудыра. Хәтта икътисади нык үскән илләрдә, дә халык пирамидасында өлкәннәр өлеше артып киткәндә, хөкүмәт пенсия яшен арттыруга дучар. Халык картаюы процессының икенче ягы булып олы кешеләрнең ялгызлыгы, аларның яшь буыннардан читләшүе тора.

Депопуляция һәм балалар тууның кимүе *үсеп килүче буынның инфантильләшүендә* дә чагылыш таба. Балалар аз булган гаиләләрдә гадәткә кергән кирәгеннән артык игътибар бирү үз мәнфәгатьләрен генә белгән, җаваплылык хисе һәм мөстәкыйльлек җитмәгән эгоист тәрбияләү куркынычын арттыра. Җәмгыять үсеше өчен буыннар арасында бәйләнешларның өзелү перспективасын да уңай дип булмый. Тулы булмаган яки балалар аз гаиләдә буыннар теләктәшлеге, аларның үзара ярдәм итешүе һәм хезмәттәшлеге зәгыйфьләнә, уртак йорт эше әһәмиятен югалта.

Килеп туган демографик вазгыятьтән чыгу юлы бармы? Россия Хөкүмәте 2001 елның сентябрендә раслаган РФнең 2015 елга кадәр чорга рәсми демографик үсеш концепциясендә «Россия Федерациясенең демографик үсеше максаты булып халык санын тотрыкландыру һәм аннан соңгы демографик үсешкә алшартлар формалаштыру тора» диелгән.

ГАМӘЛИ ЙОМГАКЛАР

1 Хәзерге заман гаиләләре проблемасын өйрәнү сезгә үз тормыш планнарыгызны аңларга ярдәм итәр, анда, мөгаен, тулы кыйммәтле гаиләгә җитди роль биреләдер.

2 Гаиләдә бер генә бала белән чикләнеп калу тенденциясенең депопуляциягә этәрүен күздә тотарга кирәк. Ул әлеге баланың эгоист булып үсүе куркынычы тудыра. Депопуляция һәм балалар тууның кимүе милләт сәламәтлеге өчен тискәре нәтиҗәгә ия. Туучылар арасында беренче балалар күп булуы үзе генә дә халыкның психофизиологик характеристикасы начарлануны аңлата, чөнки баш бала аннан соңгыларына караганда сәламәтлек күрсәткечләре буенча зәгыйфьрәк.

3 Халыкның картаюы перспективасы алдан ук сезне олыгайгач кем карап тәэмин итүен кайгыртырга мәҗбүр итә. Буыннар арасындагы чагыштырмадан чыгып дәүләт пенсия белән тәэмин итүнең туплау системасына күчә. Әгәр дә илдә балалар саны кыскару тенденциясе сакланса, сезгә картлык көненә һаман күбрәк «мая тупларга» туры киләчәк.

4 Шуны да онытмау мөһим: озак яшәү өчен исәнлекне һәм тормыш ратуны озак еллар саклап бару зарур, ә монда тулы кыйммәтле бәхетле гаилә бик мөһим роль уйный.

ДОКУМЕНТ

2015 елга кадәр чорга Россия Федерациясе демографик үсеш концепциясеннән (*2001 елның сентябрендә* Россия Хөкүмәте тарафыннан расланган).

Россия Федерациясенең демографик үсеш бурычлары түбәндәгеләр: халыкның сәламәтлеген ныгыту һәм көтелгән гомер озынлыгын арттыру өлкәсендә.

— халыкның көтелгән гомер озынлыгын арттыру;
— сәламәт (актив) гомер озынлыгын арттыру;
— халыкның репродуктив сәламәтлеген яхшырту;
— хроник авырулар һәм инвалидларның тормыш сыйфатын яхшырту.

Балалар тууны кызыксындыру һәм гаиләне ныгыту өлкәсендә:

— балалар тууны арттыру өчен алшартлар булдыру;
— шәхеснең гармонияле тормыш эшчәнлеге буларак, гаилә институтын һәрьяклап ныгыту;
— яшьләрнең үз-үзләрен табулары өчен шартлар булдыру;
— гаиләне адреслы социаль яклауны, бала туганда матди ярдәм бирүне дә кертеп, тәэмин итү;
— Россия Федерациясе халкының табигый кимүен каплауның нәтиҗәле механизмнарын булдыру максатларында миграция агымнарын җайга салу;
— миграция агымнары күләмнәрен, юнәлешен һәм составын Россия Федерациясенең социаль-икътисади үсеше мәнфәгатьләренә туры килүенә ирешү юлы белән әлеге агымнардан файдалануның нәтиҗәлелеген күтәрү;
— мигрантларның Россия җәмгыятенә интеграцияләнүен тәэмин итү һәм аларга карата толерант караш формалаштыру.

Документка сораулар һәм биремнәр

1. Россия Федерациясендә демографик сәясәтнең төп максатларын атагыз. 2. Депопуляциянең тискәре нәтиҗәләрен кисәтүгә нинди чаралар юнәлтелә? 3. Концепция миграцияне җайга салу өчен күздә тоткан һәр бурычны килеп туган демографик вазгыять күзлегеннән бәяләгез.

ҮЗ-ҮЗЕҢНЕ ТИКШЕРҮ ӨЧЕН СОРАУЛАР

1. Гаилә үсешендә нинди тенденцияләрне уңайсыз дип бәяләргә мөмкин? Нәрсә ул тулы булмаган гаилә? Тулы булмаган гаиләләр саны арту җәмгыятьтәге демографик һәм социаль вазгыятькә ничек тәэсир итә? 2. Россиядәге хәзерге демографик вазгыять ничек характерлана? 3. Россиядә хәзерге демографик вазгыятькә нинди факторлар тискәре йогынты ясаган?

БИРЕМНӘР

1. Тулы булмаган гаиләләр индустриаль һәм постиндустриаль чорда җәмгыять үсеше үзенчәлекләренә туры килә дигән фикер яши. Сез шундый караш белән килешәсезме? Җавабыгызны дәлилләгез.

2. Түбәндәге таблица белешмәләрен анализлагыз, күрсәтелгән вакытта булган тенденция һәм аның демографик вазгыятькә йогынтысы турында нәтиҗә ясагыз.

Туган балаларның идеаль һәм реаль саны (бер анага).
Россия, 1991–2000 еллар

Ел	Балаларның идеаль саны	Балаларның реаль саны
1991	2,02	1,73
1992	1,59	1,55
...	...	...
1994	2,00	1,40
1995	2,22	1,34
1996	2,21	1,28
1997	2,06	1,23
1998	2,09	1,24
1999	2,09	1,17
2000	2,14	1,21

3. Россия Федерациясенең 2015 елга кадәрге чорга демографик үсеш концепциясендә: «Ил халкының үлем динамикасында гомуми тенденция хезмәткә сәләтле яшьтәге кешеләрнең гадәттән тыш күп үлүе белән характерлы, алар арасында 80% ы чамасын ирләр тәшкил итә. Ирләр арасында үлемнәр дәрәҗәсе хатын-кызлар үлеме дәрәҗәсеннән дүрт тапкыр һәм нык үскән илләрдәге шундый ук күрсәткечтән ике-дүрт тапкыр югары»,— диелә.

Мондый хәл нинди демографик нәтиҗәләргә китерергә мөмкин? Концепциядә тәкъдим ителүче нинди чаралар (документны карагыз) тискәре нәтиҗәләрне төзәтүгә юнәлтелгән?

4. Шагыйрь белән ризалашуыгызны яки килешмәвегезне белдерегез.

Должно быть, опасаясь вдовьих слез,
Ты не связал себя ни с кем любовью.
Но если б грозный рок тебя унес,
Весь мир надел бы покрывало вдовье.
В своем ребенке скорбная вдова
Любимых черт находит отраженье.
А ты не оставляешь существа,
В котором свет нашел бы утешенье.
Богатство, что растрачивает мот,
Меняя место, в мире остается.
А красота бесследно промелькнет,
И молодость, исчезнув, не вернется.
Кто предает себя же самого —
Не любит в этом мире никого!

У.Шекспир

ЗИРӘКЛӘР ФИКЕРЕ

«Әгәр сез киләчәк турында уйламасагыз, сезнең өчен ул булмый да».

Дж. Голсуорси (1867–1933), инглиз язучысы

§ 18. Россия Федерациясендә дини берләшмәләр һәм оешмалар

Дөньяви дәүләттә дин тотучылар оешмасы нинди хокукларга ия? Дини оешмаларны кемнәр төзи? Тоталитар секталар нәрсәсе белән куркыныч?

Мәгълүм булганча, Россия Федерациясе, РФ Конституциясенең 14 статьясында беркетелгәнчә, дөньяви дәүләт булып тора. Чиркәү дәүләттән аерылган. Ләкин бу дәүләткә дингә ышанучыларның уй-хисләре нинди булуы барыбер, ул дини даирәләрдә барган процессларга битараф дигән сүз түгел.

Дәүләтнең һәм дингә ышанучылар оешмаларының мөнәсәбәтләре хокукый принципларга корыла. 1997 елда кабул ителгән «Вөҗдан иреге һәм дини берләшмәләр хакында» Федераль закон зур әһәмияткә ия. Дәүләт үз гражданнарына индивидуаль рәвештә яки башкалар белән бергәләшеп теләсә нинди дин тоту, йә берсен дә тотмау, ирекле рәвештә дини һәм башка инанулар сайлап алу, алмашу, булдыру һәм тарату, алар нигезендә эш итү хокукы бирә. Бер үк вакытта берәү дә үзенең дингә мөнәсәбәте турында хәбәр итәргә бурычлы түгел һәм үзенең дингә мөнәсәбәтен, дин тотуын яисә дин тотудан баш тартуын, табынуда, дини йолаларда һәм церемонияләрдә, дини берләшмәләр эшчәнлегендә, дингә өйрәнүдә катнашуын билгеләгәндә мәҗбүр ителә алмый. Закон кече яшьтәге балаларны дини берләшмәләргә җәлеп итүне, шулай ук аларны үз ихтыярларыннан башка һәм ата-ана, йә аларны алмаштыручы затлар ризалыгыннан тыш дингә укытуны тыя.

Шулай итеп, законнар дин турындагы мәсьәлә кебек четерекле өлкәдә дә дингә ышанучыларга шактый киң хокуклар бирә һәм бер үк вакытта дөньяви дәүләт принциплары сагында катгый тора.

ДИНИ БЕРЛӘШМӘЛӘР

Федерация Советы катнашында әзерләнгән «Россия дини берләшмәләре» белешмәлеге буенча Рус православие чиркәве өлешенә барлык дини җәмгыятьләрнең яртысыннан күбрәге (12 меңнән 6709 ы) туры килә, алар дингә ышанучы россиялеләрнең якынча 75%ын берләштерә. Мөселман җәмгыятьләре — 2349, аларда дингә ышанучы россиялеләрнең 18%ы тора. Безнең илдә ислам тарафдарларының дини тормышы белән 43 диния нәзарәте җитәкчелек итә, алар Россия һәм БДБнең Европа илләре мөселманнары үзәк диния нәзарәтенә, Россиянең Европа өлеше мөселманнары диния нәзарәтенә, Россия мөселманнары диния нәзарәтләре Югары координация үзәгенә һәм Россия Мөфтиләр советына берләшә.

Моннан тыш Россиядә 113 будда җәмгыяте гамәлдә. Буддачыларның үзәк идарәсе 1946 елдан бирле эш итә. Яңа Россиядә будда оешмалары төрле төбәкләрдә: Калмыкиядә, Тывада, шулай ук Мәскәү, Санкт-Петербург, Анапа, Белгород, Ека-

теринбург, Казан, Краснодар, Ростов-на-Дону һ.б. шәһәрләрдә барлыкка килде.

Россиядә башка дини конфессияләр: Рим-католик чиркәве, старообрядчылар, Евангелие христиан-баптистлары, евангиечел дин христианнары — пятидесятниклар, җиденче көн адвентистлары, иудейлар, лютеран һәм башка күп оешмалар да теркәлде.

Россиядә «дини берләшмә» дип илебез территориясендә даими һәм закон нигезендә яшәүче затларның бергәләшеп дин тоту һәм тарату максатларында төзелгән ирекле берләшмәсе таныла. Мондый берләшмә әлеге максатларга туры килүче билгеләргә: дин тоту; табынулар, башка дини йолалар һәм церемонияләр үтәү; үзенең тарафдарларын дингә өйрәтү яисә дини тәрбия бирү эшчәнлегенә ия булырга тиеш.

Дини берләшмәләр дини төркемнәр һәм дини оешмалар рәвешендә төзелә ала. Шул ук вакытта законнар дәүләт хакимияте органнарында, дәүләтнең башка органнарында, хәрби частьларда, дәүләт һәм муниципаль оешмаларда дини берләшмәләр оештыруны тыя. Әлеге оешмаларда эшләүче затларга вөҗдан иреген үтәү тыелмавына игътибар итик, сүз фәкать учреждение һәм хакимият органнарында дини билгеләр буенча берләшмәләр төзүне тыю турында гына бара.

Дини төркем — илебез территориясендә даими һәм законлы нигездә яшәүче гражданнарның, башка затларның югарыда күрсәтелгән максатлар өчен төзелүче, үз эшчәнлеген дәүләт теркәвеннән һәм юридик зат хокукый сәләтен алудан тыш башкаручы ирекле берләшмә ул. Әгәр дини төркем эшчәнлеген тормышка ашыру өчен бина һәм башка мөлкәт кирәк булса, алар бу төркемдә катнашучылар тарафыннан уртак файдалануга бирелә ала. Дини төркемнәр табына, башка йола һәм церемонияләр үткәрә, үз тарафдарларын дингә өйрәтә һәм дини тәрбия бирә ала. Әгәр гражданнар дини төркемне киләчәктә дини оешмага әверелдерү нияте белән төзегән булса, алар җирле үзидарә органнарына аны оештыру һәм үз эшчәнлекләрен башлау хакында хәбәр итәргә тиеш.

Дини оешма, дини төркем кебек үк, Россия территориясендә законлы рәвештә даими яшәүче гражданнар һәм башка затларның ирекле берләшмәсе булып тора. Әмма аны төзү өчен юридик зат сыйфатындагы дәүләт теркәве таләп ителә. Теркәлгән дини оешмалар юридик законнарның бердәм реестрына кертелә.

Дини оешмаларны тапшырылган документлар нигезендә дәүләт теркәве юстиция органнары тарафыннан башкарыла; алар, җирле оешма теркәләме, әллә үзәкләштерелгәнеме икәнлегенә карап, беркадәр аерыла.

Җирле дини оешма 18 яшькә җиткән һәм бер җирлектә яисә бер шәһәр яки авылда даими яшәүче ким дигәндә ун кешене кертә ала. Мондый оешманы гамәлгә куючылар булып дини төркемгә берләшкән кимендә ун Россия гражданы булырга мөмкин, аларның җирле үзидарә органы биргән әлеге территориядә ким дигәндә 15 ел яшәп килүен раслаучы яисә шул ук динне тотучы үзәкләштерелгән дини оешма структурасына керүләрен раслаучы документы булырга тиеш.

Дини оешма уставында мәҗбүри төстә дини оешманың исеме, урнашкан җире, төре генә түгел, нинди дин тотуы һәм яшәп килгән үзәкләштерелгән оешманыкы булган очракта, аның исеме, максатлары һәм төп эшчәнлеге төрләре дә; оешу һәм эшчәнлеген туктату тәртибе дә; оешманың структурасы, аның идарә органнары, формалаштыру тәртибе һәм компетенциясе дә; оешманың акчасы һәм башка милкәте чыганагы, шулай ук әлеге дини оешма эшчәнлеге үзенчәлекләренә караган башка белешмәләр дә күрсәтелә.

Үзәкләштерелгән дини оешманың устав буенча кимендә өч җирле оешмасы булырга тиеш. Дәүләт теркәве турында гариза белән мөрәҗәгать иткән вакытка структуралары Россия территориясендә законлы нигездә кимендә 50 эшләп килгән үзәкләштерелгән дини оешмалар үз атамаларында «Россия», «Россиянеке» сүзләрен һәм шуннан килеп чыккан сүзләрне кулланырга хокуклы. Моннан тыш теләсә нинди дини оешма атамасында аның нинди дин тотуы хакында белешмә булырга тиеш.

Дәүләт үзендә дини оешманы теркәүдән баш тарту хокукын калдыра, законда шундый баш тарту өчен нигезләр санап үтелә. «Вөҗдан ирекe турында һәм дини берләшмәләр хакында» Федераль законның 12 статьясы теркәүдән баш тарту өчен нигез сыйфатында түбәндәгеләрне күрсәтә: дини оешманың максат һәм бурычлары РФ Конституциясенә һәм Россия законнарына каршы килүе (законның алар каршы килгән конкрет статьяларын күрсәтеп); бу оешманы дини дип танымау; устав һәм тапшырылган башка документларның РФ законнары таләпләренә туры килмәве яисә документларда булган белешмәләрнең дөреслеккә туры килмәве; юридик затларның дәүләт реестрында шундый атамалы элек теркәлгән оешма булу; гамәлгә куючыларның хокукы булмау. Дини оешманы теркәүдән баш тартуга суд тәртибендә шикаять белдерелергә мөмкин.

Моннан тыш, үз гражданнары хокукларын һәм ирекләрен тәэмин итеп, дәүләт, алар тарафыннан закон бозу очрагында, дини берләшмәләр эшчәнлеген туктату яисә дини оешмаларны бетерү вәкаләтенә ия. РФ Конституциясе, Россия законнары нор-

маларын кабат яисә тупас бозган; җәмәгать куркынычсызлыгын һәм җәмәгать тәртибен бозган; экстремистлык эшчәнлеген тормышка ашыруга юнәлтелгән гамәлләре, шулай ук тагын байтак кына хокукка каршы эшләре өчен суд карары буенча дини оешмалар юкка чыгарылырга мөмкин.

Әйтик, 1996 елга кадәр Мәскәүдә һәм Россиянең башка төбәкләрендә Аум Синрикё бүлекчәләре эшләп килде. Җәмгыятькә каршы эшчәнлектә гаепләү буенча бу корпорациянең Россиядә эш иткән җитәкчеләренә карата җинаять эше кузгатылды. 2004 елда Япониядә халыкара Аум Сенрикё дини корпорация лидеры Тидзуо Мацумотога (ритуаль исеме Сёко Асахара) үлем җәзасы чыгарылды. Шундый суд карары өчен нигез булып үтергеч газ зарин әзерләү һәм аны Асахара боерыгы буенча Токио метросында терактлар ясау өчен куллану факт-лары торды.

ДИНИ ОЕШМАЛАРНЫҢ ХОКУКЛАРЫ

Аларны шартлы рәвештә ике төркемгә бүләргә мөмкин. Беренчесенә *оешмалар өчен типик хокуклар* керә.

Дини оешмалар, дөньяви оешмалар кебек үк, милекче була ала. Алар милкендә биналар, җир кишәрлекләре, җитештерү, социаль, хәйрия, мәдәни-агарту билгеләнешендәге объектлар, дини билгеләнештәге әйберләр, шулай ук аларның эшчәнлеген тәэмин итү өчен кирәк булган акча һәм башка мөлкәт (шул исәптән тарихи һәм мәдәни ядкәрләргә кертелгәннәре дә) булырга мөмкин. Дини оешма милкендә булган мөлкәт үз акчалары исәбенә, гражданнар, оешмалар иганәләренә сатып алу яисә төзү юлы белән яки дәүләттән милеккә тапшырып булдырыла. Дини оешмалар милек хокукында чит илдә дә мөлкәт тота ала. Моннан тыш закон дини оешмаларның халыкара багланышлар һәм элемтәләр (шул исәптән хаҗ кылу максатында да) урнаштыру хокукын таный.

Дини оешмаларга эшмәкәрлек эшчәнлеге башкарырга һәм үз предприятиеләрен булдырырга рөхсәт ителә. Бу очракта мондый предприятиеләргә гражданлык һәм хезмәт хокукы нормалары кагыла. Ә дини оешма хезмәткәрләренә, шулай ук руханиларга РФ законнары нигезендә социаль тәэминат, социаль иминиятләштерү һәм пенсия тәэминаты карала.

Мәсәлән, Мәскәү янындагы «Софрино» заводы чиркәү кирәк-яраклары, шәмнәр җитештерә, махсус кием тегә. Бу предприятие 3 мең кешене эш белән тәэмин итә. Евангелие христианнарының Мәскәү чиркәве каршында «Серебрянское» ширкәте (элеккеге совхоз) эшләп килә, автомашиналар ремонт-

лау, тәрәзә рәшәткәләре ясау, арадашчылык хезмәте күрсәтү буенча «Вифания» фирмасы оештырылды. Бу предприятие керемнәренең өчтән бере чиркәүгә керә. Җиденче көн адвентистлары рухи үзәге Тула өлкәсенең Ока аръягы районында байтак кына җир кишәрлегенә ия, анда экологик чиста продуктлар җитештерәләр. Башка конфессия дини оешмаларының да уңышлы хуҗалык мисаллары байтак.

Икенче төркемне дини оешмалар эшчәнлегенең характеры белән бәйле *махсус хокуклар* тәшкил итә.

Беренчедән, дини оешмалар үзләренең эчке тәртип-кагыйдәләре нигезендә эш итәргә хокуклы.

Икенчедән, алар махсус рәвештә аллага табыну, дога кылу һәм дини җыеннар, дини олылау (хаҗ кылу) өчен билгеләнгән культ биналары, корылмалары һәм башка җирләр булдырырга һәм аларны карап тотарга хокуклы. Закон дәвалау-профилактика учреждениеләрендә һәм хастаханәләрдә, балалар йортында, картлар һәм инвалидлар өчен интернат-йортларда администрация махсус бүлеп биргән бинада дини йолалар үтәүне рөхсәт итә. Алар хөкемгә тартылган хокук бозучылар җинаять җәзасын уза торган учреждениеләрдә дә рөхсәт ителә. Шул ук вакытта сак астындагы затлар өчен дини йолаларны үтәүгә җинаять-процессуаль законнарның махсус таләпләрен үтәп кенә юл куела. Закон хәрби хезмәткәрләрнең аллага табынуда, дини йолаларны һәм церемонияләрне үтәүдә, хәрби уставларны исәпкә алып, тоткарлыксыз катнашуын күздә тота. Махсус килешенмәгән башка очракларда аллага табыну, дини церемония һәм йолалар, митинглар, тантаналы йөрүләр һәм демонстрацияләр уздыру өчен билгеләнгән тәртиптә тормышка ашырыла.

Өченчедән, дини оешмалар һөнәри, шул исәптән дини тәгълимат тарату, дини эшчәнлек белән шөгыльләнү максатларында чит ил гражданнарын чакырырга хокуклы.

Дини оешмалар шулай ук дини әдәбият, дини билгеләнештәге башка материаллар һәм әйберләр җитештерергә, сатып алырга, таратырга да хокуклы. Фәкать алар гына аллага табыну әдәбияты бастыру һәм культ билгеләнешендәге әйберләр җитештерү өчен оешмаларны гамәлгә кую хокукыннан файдалана.

Моннан тыш, фәкать дини оешмалар гына руханилар һәм дини персонал әзерләү өчен һөнәри белем бирү учреждениеләре булдыру хокукына ия. Әлеге учреждениеләрнең дәүләт лицензиясе булганда, мондый уку йортлары укучылары Россия законнарында каралган барлык хокуклар һәм ташламалардан файдалана.

Дини оешмаларның хәйриячелек һәм мәдәни-агарту эшчәнлеге закон белән аерым карала. Бу эшчәнлек турыдан-туры дини оешманың үзе тарафыннан да, әлеге максатлар өчен төзелгән оешмалар һәм массакүләм мәгълүмат чаралары тарафыннан да башкарыла ала.

Дини оешмалар Россия җәмгыятенең рухи-әхлакый нигезен, вөҗдан иреге, дин тоту иреге атмосферасын формалаштыруга сизелерлек өлеш кертә, РФндә дини тормышны үстерүгә уңай йогынты ясый, дини идеалларга һәм кыйммәтләргә фидакарьләрчә хезмәт итүгә тартылуны хуплый. Дини хезмәт итүнең төрле рәвешләре киңәя бара, Россиядә гамәлдәге диннәр һәм дини агымнар саны арта.

ДИННӘР АРАСЫНДА ТЫНЫЧЛЫК САКЛАУ ПРОБЛЕМАЛАРЫ

Дәүләт һәм җәмгыять дини берләшмәләр социаль хезмәт итүенең төрле формаларын актив хуплый. Дәүләт бюджетыннан храмнарны, тарихи һәм мәдәни ядкәр булган башка объектларны торгызуга, карап тотуга һәм саклауга акча бүлеп бирелергә мөмкин. Россиялеләр өчен истәлекле урын — Мәскәүдәге Поклонная гора монументы янында булган һәр кеше монда бер-берсеннән ерак та түгел православие, яһүди һәм мөселманнарның культ корылмаларына игътибар итә. Бу — Ватан өчен һәлак булганнарга баш ию урыны; аларны төрле дин тотулары да аера алмаган.

Дини берләшмәләр белән элемтәләрне тормышка ашыручы дәүләт органнары, бүлекчәләре системасы барлыкка килә, хезмәткәрләр штаты бар. Дин эшлеклеләре федераль һәм төбәк хакимият органнары каршындагы төрле консультатив советларга чакырыла.

Яңа Россиядә дини оешмаларның җәмгыять тормышына һәм сәяси процессларга йогынтысы үсә. Бу үсеш төрле конфессияләрнең күпсанлы хәйрия һәм шәфкатьлелек акцияләрендә, хокук яклауда, тынычлык урнаштыруда, экологик акцияләр уздырганда тырышлыкларны берләштерүдә чагылыш таба.

Күпконфессияле Россиянең тотрыклы һәм даими үсеше өчен диннәр арасында тынычлык саклау зарур. Шулай булмаса, безнең ил һәлакәт чигенә килер иде. Динара тынычлыкка һәм татулыкка янаучы «куркынычлык факторлары» нинди соң?

Беренчедән, дини түземсезлек, бигрәк тә ул дини антагонизм булып җитешкәндә. Күпсанлы һәм йогынтылы дини берләшмәләрнең ихтыяҗ һәм мәнфәгатьләрен исәпкә алганда,

беркем дә азчылыкның законлы хокукларын бозарга һәм дини хисләрен мыскылларга тиеш түгел. Компетентлы консультант ролен РФ Президенты каршындагы Дини берләшмәләр белән үзара хезмәттәшлек советы уйный ала, ул иң абруйлы 11 дини оешма лидерларын берләштерә. Төрле конфессияләр дини оешмалары хезмәттәшлеге күптөрле: ул хәйрия һәм шәфкатьлелектән алып уртак экологик һәм тынычлык саклау программаларына кадәр мәсьәләләрдә тормышка ашырылырга мөмкин.

Икенчедән, традицион булмаган конфессия һәм диннәр эшчәнлеге киңәю һәм аларга шулай ук киң каршы торуның килеп чыгуы, традицион булмаган конфессияләргә массакүләм мәгълүмат чараларында чыгыш ясау, мәгариф, хәйрия эшчәнлеге белән шөгыльләнү мөмкинлеге бирмәү.

«Яңа дини хәрәкәтләр» дип аталган агымнар (дөньяда 140 млн дин тотучы кеше алар яклы, ә Россиядә аларның саны төрле бәяләүләр буенча 300–400 меңгә җитә) бик төрле. Берәүләр хәйриячелек белән шөгыльләнә, акча һәм көчләренең күп өлешен якыннарына ярдәмгә сарыф итә, икенчеләре үзләренең җәмгыять эчендәге проблемаларын һәм дини гамәлләрне генә белә, җәмгыять тормышын һәм аның борчуларын күрми. Ә кайберләре күбрәге дини-фәлсәфи тәгълиматка яисә медицина-савыктыру системаларына охшаган, дини тормышның гадәти рәвешләрен аз калдыра.

Динне өйрәнүче галимнәр күп кенә традицион булмаган культларның, дини оешмаларның аерым тибын тәшкил итүен билгеләп үтә. Аларда, кагыйдә буларак, катгый эшләнгән дини тәгълимат юк, ә структурасы еш кына — авторитар лидерның өстенлеге белән аерылып торучы иерархия. Алар өчен рәсми танылган кыйммәтләргә һәм чиркәү идеалларына каршы булу хас. Бу җәмгыятьләрдә культ психик йогынты ясау һәм манипуляцияләү ысуллары белән бергә алып барыла. Мондый эшчәнлек индивидуаль һәм иҗтимагый аңга зарарлы, ә кайчак җимергеч тәэсир итә, шәхеснең социальләшүе бозылуга китерә. Әлеге культ тарафдарлары эшләрен, укуларын ташлый, гаиләдән китә. Мондый культ үрнәге булып 1993 елның октябрендә дөнья бетүен, Христосның Мария Дэви Христоста (оешманы төзүчеләрнең берсе Марина Цвигун шундый исем ала) яңадан гәүдәләнешен тәкрарлаган Белое братство Юсмалос тора.

Кайбер дини төркемнәр һәм общиналар экстремистик оешма билгеләмәсенә туры килә.

Сәясәтчеләргә, һичшиксез, төрле дини оешмалар аермасын исәпкә алырга, аларга үз мөнәсәбәтләрен булдырырга туры килә.

ГАМӘЛИ ЙОМГАКЛАР

1 Вөждан иреге принцибын тормышка ашыру һәркемгә теге яки бу дини оешмада тору яисә моңардан баш тарту мөмкинлеге бирә. Дини берләшмәдә, оешмада катнашыргамы яки юкмы икәнлеген сез үзегез хәл итәсез. Бу бик шәхси һәм ихтыяри эш.

2 Традицион булмаган культларның байтагы, бер яктан рухи юнәлеш эзләүче, икенче яктан — социаль протестка (шул исәптән дин мәсьәләләрендә дә) тартылучы яшьләргә исәп тота. Дини тәгълиматның асылы турында белемнәр җитмәү чын дини максатлардан ерак оешмага китерергә мөмкин.

3 Үзең өчен дингә ышанучылар берләшмәсендә торыргамы-юкмы икәнлеген хәл иткәндә тоталитар секта дип аталганнары нинди куркыныч тудыруын онытмаска кирәк. Алар өчен сугышчан-агрессив тәгълимат белән бергә үз әгъзаларын ныклы контрольдә тоту хас. Алар еш кына кешегә психологик йогынты ясау ысулы куллана, ә бу мораль һәм психологик сәламәтлек өчен куркыныч.

ДОКУМЕНТ

«Экстремистик эшчәнлеккә каршы тору турында» Федераль законнан *(2002 елның 25 июлендәге).*

1 статья. Төп төшенчәләр.

Әлеге Федераль закон максатлары өчен түбәндәге төп төшенчәләр кулланыла: экстремистик эшчәнлек (экстремизм):

1) җәмәгать һәм дини берләшмәләрнең йә оешмаларның, йә массакүләм мәгълүмат чараларының, йә физик затларның түбәндәгеләргә юнәлтелгән гамәлләрен планлаштыру, оештыру, әзерләү һәм башкару буенча эшчәнлеге:

Россия Федерациясе конституциячел корылышы нигезләрен көч кулланып үзгәртү һәм бөтенлеген бозу;

Россия Федерациясе куркынычсызлыгын какшату;

хакимият вәкаләтләрен яулап алу яисә үзләштерү;

законсыз кораллы формированиеләр төзү;

террорлык эшчәнлеген тормышка ашыру;

расачыл, милли яисә дини каршылыклар, шулай ук көч куллану яисә көч куллануга чакыру белән бәйле социаль каршылыклар тудыру;

милли абруйны түбәнсетү;

идеологик, сәяси, расачыл, милли яисә дини нәфрәт, йә дошманлык нияте, шулай ук кайсы да булса социаль төркемгә карата нәфрәт, йә дошманлык нияте буенча массачыл тәртипсезлекләр, хулиганлык гамәлләре һәм вәхшилек актлары башкару;

гражданнарның дингә, социаль хәленә, раса, милләт, нинди дингә яисә телгә каравына мөнәсәбәте буенча аларның өстенлеген йә кимчелеген пропагандалау...

9 статья. Иҗтимагый һәм дини берләшмәләрнең, башка оешмаларның экстремистлык эшчәнлеге башкарулары өчен җаваплылыгы.

Россия Федерациясендә максатлары яисә гамәлләре экстремистлык эшчәнлеге башкаруга юнәлтелгән иҗтимагый һәм дини берләшмәләр, башка оешмалар төзү һәм аларның эшчәнлеге тыела.

Документка сораулар һәм биремнәр

1. Нинди билгеләр аерым дини оешмаларны экстремистик буларак характерларга мөмкинлек бирә? **2**. Конфессия ара мөнәсәбәтләр өчен иң куркыныч билгеләрне күрсәтегез. **3**. Ни өчен дәүләт экстремистлык оешмаларына аларның эшчәнлеген тыюга кадәр җиткән катгый санкцияләр куллана?

ҮЗ-ҮЗЕҢНЕ ТИКШЕРҮ ӨЧЕН СОРАУЛАР

1. Россия Федерациясендә нинди дини оешмалар эш итә ала? **2.** Дини берләшмәләр ия булырга тиешле мәҗбүри билгеләрне күрсәтегез. **3.** Хакимият органнарында дини берләшмәләр төзүгә карата сезгә нинди закон нормалары билгеле? **4.** Дини оешмалар һәм учреждениеләр белән үзара хезмәттәшлек мәсьәләләрендә дәүләт алдында торучы төп проблемалар нинди?

БИРЕМНӘР

1. «Вөҗдан иреге һәм дини берләшмәләр хакында» Федераль законга преамбуланы (1 текст), шулай ук законга карата «Рус православие чиркәве социаль концепцияләре нигезләре»ндә китерелгән мөнәсәбәтне (2 текст) анализлагыз һәм тиешле нәтиҗә ясагыз.

1) РФ Федераль Җыены,

һәркемнең вөҗдан ирегенә һәм дин тотуга хокукын, шулай ук дингә һәм инануларга мөнәсәбәтенә бәйсез рәвештә закон алдында тигезлекләрен раслап,

РФнең дөньяви дәүләт булуына таянып,

Россия тарихында, аның рухи халәте һәм мәдәнияте барлыкка килүдә православиенең аерым ролен танып,

Россия халыклары тарихи мирасының аерылгысыз өлешен тәшкил иткән христианлыкны, исламны, будда һәм башка диннәрне хөрмәт итеп,

вөждан иреге һәм дин тоту иреге мәсьәләләрендә үзара аңлашуга, түзеп торучанлыкка һәм хөрмәт итүгә ирешүне әһәмиятлегә санап,

әлеге Федераль законны кабул итә».

2) «Хокукта җәмгыятьнең барлык әгъзалары өчен мәҗбүри әхлакый нормаларның беркадәр минимумы бар. Дөньяви законның бурычы — явызлык эчендә яткан дөньяны Ходай Патшалыгына әверелдерүдә түгел, ә аны тәмугка әверелдермәүдә».

2. Вакытлы матбугаттан түбәндәге юнәлешләр (бер яисә берничә): хуҗалык-икътисади, социаль-медицина өлкәсе, хәрбипатриотик эшчәнлек, мәдәни-агарту эше буенча хәзерге дини оешмалар эшчәнлеген характерлаучы материаллар сайлап алыгыз.

3. «Вөждан иреге турында һәм дини берләшмәләр хакында» 2002 елгы закон дини берләшмә эшчәнлеген туктатып тору өчен нигезләрдән түбәндәгеләрне атый:

«...гражданнар әхлагына, сәламәтлегенә закон нигезендә билгеләнгән, шул исәптән аларның дини эшчәнлеге белән бәйле рәвештә наркотик һәм психотроп чаралар, гипноз кулланып та, зыян китерү...

кешене үз-үзенә кул салуга яисә дини уй-ният буенча гомере һәм сәламәтлеге өчен куркынычлы хәлдә булган затларга медицина ярдәме күрсәтүдән баш тартуга этәрү...

дини берләшмә әгъзаларын һәм тарафдарларын, башка затларны аның мөлкәтен дини берләшмә файдасына читләштерүгә мәҗбүр итү;

гомеренә, сәламәтлегенә, мөлкәтенә зыян китерү белән янап, әгәр аны башкаруның реаль куркынычы булса, яисә көч кулланып йогынты ясау, хокукка каршы башка гамәлләр белән гражданның дини берләшмәдән чыгуына каршы тору...»

Әлеге гамәлләр кешенең нинди хокукларын боза? Күрсәтелгән хокук бозуларга юл куючы оешмаларны экстремистик буларак бәяләп буламы? Дини берләшмә эшчәнлеген туктатып тору турында нигезле карар кабул итү өчен нинди өстәмә мәгълүмат алырга кирәк?

4. Кешелекнең үткәнендә конфессия ара каршылыкларның бер чагылышы дини сугышлар булган. Сезгә тарихтан аларның нинди фаҗигале нәтиҗәләргә китерүе мәгълүм. Конфессия ара

дошманлык нигезендә кораллы бәрелешләр килеп чыгу куркынычын нинди чаралар белән кисәтергә мөмкин? Сезнең карашка, Россиядә төрле дини оешмалар арасында багланышлар үсешен характерлаучы фактларны атагыз.

ЗИРӘКЛӘР ФИКЕРЕ

«Үз аллалары йөзендә кеше үз портретын сурәтли».

Ф.Шиллер (1759–1805),
немец шагыйре һәм драматургы

БҮЛЕККӘ КЫСКАЧА ЙОМГАК

1 Ирек — һәрвакыт сайлау яисә шундый сайлау мөмкинлеге ул. Ирекле кеше карарны үз ихтыяры белән кабул итә. Әмма ирек һәрчак кешенең үз гамәлләре өчен җаваплылыгын да күздә тота. Шәхес иреге һәм җаваплылык — аның яшәешенең үзара бәйләнгән һәм бер-берсенең шарты булган ике характеристикасы ул. Россиядә ирекле кешеләрнең ирекле җәмгыятен булдыру — иң мөһим һәм иң катлаулы гомуммилли бурыч.

2 Иҗтимагый һәм индивидуаль аң — аңны оештыруның төрле дәрәҗәләре һәм ысуллары. Алар бер-берсе белән даими хезмәттәшлек итә. Сәяси тормыш, сәяси институтлар эшчәнлеге, сәяси вакыйгалар һәм сәяси карарлар социаль бергәлекләр — сыйныф, милләт, социаль төркем, шулай ук индивидлар тарафыннан төрлечә аңлана. Барлык бу сәяси күренешләр сәясәт турында күзаллауларда, кичерешләрдә, фикерләүдә чагылыш таба, «сәяси аң» төшенчәсе «сәяси белем» төшенчәсенә тәңгәл түгел. Бу кешеләр башындагы сәяси чынбарлык образы гына түгел, аңа карата мөнәсәбәт тә. Бу кешеләрнең объектив сәяси шартларга һәм үз эшчәнлекләре рәвешендә үз функцияләренә һәм рольләренә субъектив эчке мөнәсәбәт, әле аның да кызыксынганы, хислесе. Аның нигезендә — сәяси мөнәсәбәтләр, институтлар, нормалар, сәяси процесста катнашучылар өчен вакыйгаларның уңай яисә тискәре әһәмияте (гамәли кыйммәте, актуальлеге).

3 Идеология (киң мәгънәдә) — теоретик карашлар системасы. Аларда кешеләрнең чынбарлыкка һәм бер-берсенә карашлары, шулай ук социаль эшчәнлекнең максаты аңлап үзләштерелә һәм бәяләнә. Сәяси идеология әлеге социаль төркемнең сәяси тормышка карашларын үз эченә ала, төркемнең хакимияткә, аңардан үз мәнфәгатьләрендә файдалануга дәгъваларын нигезли. Бу төшенчәләр һәм идеяләр системасы, аларда сәясәтнең билгеле бер субъекты үз аңында сәяси

тормышны чагылдыра, үзенең сәяси позицияләрен аңлап белә һәм үз мәнфәгатьләре өчен көрәш юнәлешләрен күрә.

4 Сәяси тәртип — сәясәт субъектының социаль мохит, төрле иҗтимагый сәяси көчләр белән үзара эшчәнлеген характерлаучы гамәлләре һәм эшләре. Ул — нинди дә булса социаль әһәмиятле максатка, гореф-гадәтләр, кыйммәти юнәлешләр, шулай ук индивидның аңламыйча башкарган, эмоциональ халәте китереп чыгарган гамәлләре җыелмасы. Гамәлләрдә сәяси тәртипнең кыйммәти аспектлары аеруча ачык күренә. Реаль сәяси тәртиптә аңлашылучы һәм аңлашылмаучы рациональ һәм эмоциональ компонентлар катлаулы хезмәттәшлектә була. Тәртип интенсивлык дәрәҗәсе буенча корректлы, цивилизацияле мөнәсәбәтләрдән алып яратмау һәм игелексезлек, сүз белән мыскыллау, хәтта физик көч куллануга кадәр булырга мөмкин. Кешеләр аңында демократик кыйммәтләр урнашуы аларның күпчелек очракта демократик партияләргә һәм сәяси тәртипнең демократик, хокукый рәвешләренә йөз тотуын билгели.

5 Җәмгыять тормышында хакимлек карарлары кабул итүгә йогынты ясаучы идарәче элита актив роль уйный. Сәясәт белеме галимнәре моны түбәндәге сәбәпләр белән аңлата: кешеләрнең психологик, социаль һәм интеллектуаль тигезсезлеге; халыкның киң катлавының сәяси пассивлыгы; профессиональ идарәче хезмәтнең иҗтимагый әһәмияте; идарәче эшчәнлек белән ачкан өстенлекләр алу мөмкинлеге.

6 Сәяси лидерлык — теләсә нинди йогынты түгел, ул, беренчедән, даими; икенчедән, лидердан объектка берьяклы юнәлгәнлек; өченчедән, барлык җәмгыятьне яисә кешеләрнең зур төркемен үз эченә алган киң йогынты; дүртенчедән, лидер абруена таянган йогынты. Хәзерге заман шартларында сәяси лидер, кагыйдә буларак, оешма (гадәттә сәяси партия) яисә дәүләт җитәкчесе, ягъни сәяси җитәкче булып тора.

7 Демография — халыкның урнашуы, структурасы (яше, җенесе, тору урыны һ.б. буенча) һәм динамикасы (тууы, үлүе, миграциясе һ.б.) ул. Демографик сәясәт — дәүләт органнарының һәм халыкның яңадан торгызылуы процессларын җайга салу өлкәсендәге башка социаль институтларның максатка юнәлешле эшчәнлеге. XX гасыр ахыры — XXI гасыр башында Россия өчен халык санының кимү проблемасы иң кискеннәрнең берсенә әверелде. РФнең демографик үсеше максаты булып халык санын тотрыкландыру һәм аннан соңгы демографик үсешкә алшартлар формалаштыру тора.

8 Дини оешмалар Россия җәмгыятенең рухи-әхлакый нигезен формалаштыруга сизелерлек өлеш кертә, дини тормыш үсешенә уңай йогынты ясый. Дәүләт һәм җәмгыять дини

берләшмәләр эшенең төрле рәвешләренә актив булышлык итәләр. Күпконфессияле Россиянең тотрыклы үсеше өчен диннәр арасында тынычлык саклау зарур. Дини берләшмәләрнең дәүләт һәм гражданнар белән мөнәсәбәте хокукый нормалар белән җайга салына. Алар РФнең дөньяви дәүләт булуы; бер диннең дә дәүләт яисә мәҗбүри дин сыйфатында урнаштырыла алмавы; дини берләшмәләрнең дәүләттән аерылганлыгы һәм закон каршында бертигез булуы турындагы конституциячел нигезләмәләргә таяна.

ЙОМГАКЛАП КАБАТЛАУ ӨЧЕН СОРАУЛАР

1. Азатлыкның асылы нидән тора? Кеше иреге аның җаваплылыгыннан ни өчен аерылгысыз?
2. Иҗтимагый һәм индивидуаль аң нинди нисбәттә? Теоретик һәм гадәти аңның аермасы нидә?
3. Нәрсә ул сәяси идеология? XX гасыр вакыйгаларына йогынты ясаган идеологияләрнең һәркайсына хас сыйфатлар нинди?
4. Идеология һәм психология сәяси тәртипкә ничек тәэсир итә? Сәяси экстремизмның куркынычы нидә?
5. Сәяси тормышта массакүләм мәгълүмат чаралары нинди роль уйный?
6. Ни өчен сәяси тормышта сәяси элитаның роле зур?
7. Сәяси лидерлык нәрсә белән характерлана? Сәяси лидерның функцияләре нинди?
8. Безнең илдә демографик вазгыять нинди проблемалар тудыра? Аларны хәл итү юллары нинди?
9. Дини берләшмәләр төзү тәртибе һәм аларның дәүләт белән мөнәсәбәтләре нинди? Вөҗдан ирегенең әһәмияте нәрсәдә?

III бүлек

Кеше һәм закон

§ 19. Хокукны аңлауга заманча якын килү

Нигә кешеләр хокукны төрлечә аңлый? Нинди очракларда закон хокукка каршы килә? Идеаль хокук булдырырга мөмкинме? Сезнең сыйныф закон чыгару инициативасы белән чыга аламы?

10 нчы сыйныф курсыннан сезгә хәзерге заман хокук белемендә хокукны аңлауга төрле карашлар яшәп килүе мәгълүм. Бу күренеш гадәти. Хокукны тирәнтен өйрәнү өчен, әгәр хакыйкатьне табуга илтсәләр, барлык карашлар да кыйммәтле.

Хокук белгечләре безнең көннәрдә иң бәхәсле мәсьәләләрнең берсе хокук һәм закон нисбәте турында икәнлеген билгеләп үтә. Иң типик ике карашка мөрәҗәгать итик, алар белән танышу икесендә дә иң кыйммәтлесен һәм файдалысын ачыкларга мөмкинлек бирер.

ХОКУККА НОРМАТИВ ЯКЫН КИЛҮ

Ул «норма» дигән сүздән алынган, ягъни бу юридик кагыйдә, аның иң мөһим сыйфаты — **дәүләтнең мәҗбүр итүче көченә** нигезләнгән **гомуми мәҗбүрилек.** Мондый якын килү нигезендә хокук белән закон арасында фактик аерма юк. Дәүләт ихтыярын гәүдәләндергән норматив акт, закон — хокук шул инде. Норматив якын килү марксистик карашка тартыла, аның

буенча хокук хакимлек итүче сыйныфның Закон югарылыгына күтәрелгән ихтыяры ул.

Ләкин мондый караш белән барлык хокук белгечләре дә килешми. Әгәр дә хокук законнарга гына кайтып калса, законнан тыш хокук юк дип уйларга кирәк дип фикер йөртә алар. Дәүләт ирекле рәвештә теләсә нинди законнар кертә, гражданнарга теге яки бу хокукларны бирә һәм шулай ук җиңел генә тартып та ала. Дәүләт хокукны бердәнбер булдыручы, ул кеше хокукларының да чыганагы булып чыга; димәк, теләсә нинди дәүләтне (ә һәр дәүләттә законнар бар) хокукый дип санарга мөмкин.

Хокукка болай якын килү, ким дигәндә, дәүләт башбаштаклыгы куркынычы тудыра. Тулаем алганда, болай караганда, тәнкыйтьчеләр фикеренчә, «нәрсә ул хокук» дигән сорау асылда юк, чөнки аның өчен хокук ул — рәсми күрсәткеч, гамәлдәге позитив хокук кына (ягъни гамәлдәге законнар).

Шул ук вакытта норматив якын килү гамәли күзлектән караганда кулай. Анык бер эшне хәл иткәндә, юристлар (судья, прокурор, адвокатлар) закон нормаларына гына таяна ала.

Тулаем алганда, норматив якын килүгә карата хокук белемендә бертөрле генә бәя юк. Бер үк вакытта аның уңай ягын да, тискәре ягын да билгеләп үтәләр. Аларның кайберләрен тасвирлап үтик.

Уңай ягы шунда ки норматив якын килү, башкалардан аермалы буларак, хокукның төп, билгеләүче сыйфатын — аның нормативлылыгын, ягъни теге яки бу хәлдә ни кылырга мөмкин һәм тиеш икәнлеген төгәл билгеләүче нормалар системасы (гомуми мәҗбүри тәртип кагыйдәләре) булуын яхшырак күрсәтә. Әгәр дә норма чыннан да һәркем үтәргә тиешле (бернинди чыгарылмасыз) гомуми мәҗбүри таләп икән — бу җәмгыять өчен бик кулай.

Норматив якын килүнең тагын бер уңай ягы булып хокукый таләпне белдерүнең төгәллеге, бер генә мәгънәдә булуы, ягъни норманың формаль яктан билгеләнгәнлеге тора. Бу норматив актның эчтәлеген дөрес, башка мәгънәләрсез аңларга, аның таләпләренә таянырга мөмкинлек бирә.

Хокукны норматив аңлауның ачыктан-ачык тискәре ягына барыннан да элек, хокук эчтәлегендә гуманлык ягын санга сукмау керә. Әлеге караш кысаларында хокук ирек һәм гаделлек чарасы буларак каралмый, хокук системасында кеше хокукларының әйдәүче роле исәпкә алынмый. Димәк, юридик нормалар адресланучыларның төп мәнфәгатьләре урынына дәүләт мәнфәгатьләре куела.

Мондый санламау кеше өчен генә түгел, дәүләтнең үзе өчен дә куркыныч. Билгеле бер шартларда дәүләт искергән нор-

маларга таяна ала. Яисә тагын да яманы, гуманлык таләпләренә каршы килүче, консерватив һәм хәтта реакцион көчләр мәнфәгатьләренә җавап бирүче норматив актлар чыгара ала. Әйтик, мисал өчен, XX гасырның 30 нчы елларында СССРда Сталин диктатурасы шартларында халык «өч башак турында закон» дип аталган кешелексез норматив акт[1] кабул ителә. Аның асылы шунда: ачлык кичерүче кешеләргә уңышны җыеп алганнан соң да очраклы төшеп калган башакларны җыюны тыялар. Моны бозган өчен коточкыч җәза (атып үтерүгә кадәр) билгеләнә. Гуманлык эчтәлегеннән мәхрүм мондый «норматив актлар» Совет властена һәм дәүләткә ышанычны какшатырга мөмкин иде.

ТАБИГЫЙ ХОКУК: ИДЕЯДӘН ЮРИДИК ЧЫНБАРЛЫККА

Алдан ук билгеләп үтик: табигый хокукның нинди дә булса бердәм теориясе юк. Табигый-хокукый идеяләрне үз хезмәтләрендә төрле авторлар үстерә, алар арасында кешелекнең бөек акыл ияләре күп була. Шул ук вакытта бу тәгълиматларда байтак кына охшаш идеяләр, нигезләмәләр, нәтиҗәләр бар, бу табигый хокукның кайбер типик сыйфатлары турында сөйләргә мөмкинлек бирә. Бу идеяләр нигезендә һәр кеше *туганда ук* (башкача әйткәндә, табигый, тере организм, табигать кушканча) *билгеле бер хокук һәм ирекләр җыелмасына* ия була, алар аерылгысыз һәм гомер буена аныкы.

Табигый хокук тарафдарлары хокук ул законга тиңдәш түгел һәм зуррак нәрсәне аңлата дип уйлыйлар. Хокукны болай аңлаганда, закон хокукны чагылдыруның бер рәвеше генә. Аңлатып үтәбез.

Эш шунда ки, дәүләт тарафыннан урнаштырылган законнарны *табигый хокук* яклылар кешенең (закон чыгаручы, хөкемдар, дәүләт буларак) үз иҗат җимешенә кертәләр һәм *позитив хокук*, ягъни уңай, документаль чынбарлык буларак яшәүче хокук дип атыйлар. Әмма хокукның барлык рәвешләре дә кешеләр, дәүләт тарафыннан чыгарылмаган. Позитив хокук белән беррәттән теге яки бу закон чыгаручы, дәүләт ихтыярыннан бәйсез — табигый хокук та бар.

Тикшеренүләр күрсәткәнчә, антик чорда һәм борынгы христианлык вакытында ук *«табигый хокук»* һәм *«кешеләр*

---

[1] 1932 елның 7 августындагы законнан соңгы акт — СССР ҮБК һәм ХКСның «Дәүләт предприятиеләре, колхозлар һәм кооперация мөлкәтен саклау һәм иҗтимагый (социалистик) милекне ныгыту турында» карары күздә тотыла.

урнаштырган хокук» аерып каралган. Рим хокукында ике төрле термин: *jus* — хокук һәм *lex* — закон яшәп килүе дә кызыклы.

«Табигать буенча хокук» Яңа чорда чын-чынлап триумф кичерә. Рус хокук белгече И.А.Покровский (1868–1920) билгеләп үткәнчә, табигый хокук идеясе «Көнбатыш Европаның бөтен тарихы буйлап эзлексез бара», ләкин ул XVII һәм XVIII гасырларда — башлыча табигый хокук эпохасы исеме бирелгән чорда — ул аеруча тирәнлек һәм интенсивлык ала.

Буржуаз демократиянең беренче адымнары белән бергә табигый хокук теориядән *дәүләти-хокукый чынбарлыкка* әверелә. Бу чорда кабул ителгән һәм табигый хокук идеяләрен үз эченә алган, сезгә инде мәгълүм булган иң зур хокукый документларны искә төшерик: АКШта — Бәйсезлек декларациясе (1776) һәм Конституция (1787), Франциядә — Кеше һәм гражданнар хокуклары декларациясе (1789) һәм Конституция (1791). Дәүләт документлары эчтәлегенә кертелгән табигый хокук *гамәлдәге гомуми мәҗбүри* юридик нормага әверелде. Җәмгыять тормышының сәяси-хокукый өлкәсендәге мондый зур үзгәрешләрне хәзерге заман хокук белгечләре *хокукта беренче (антифеодаль)* революция (көч куллану мәгънәсендә түгел, ә яңа хокукый халәткә кискен, сикерү сыман күчеш мәгънәсендә) дип атыйлар.

Аннан соң озак вакытлы артка чигенеш чоры була. Тарих курсыннан сезгә инде билгеле булганча, XIX гасыр ахыры — XX гасырның беренче яртысы — гигант төстәге социаль һәлакәтләр — кризис, революция, бөтендөнья сугышлары белән билгеләп үтелә.

Ләкин тарих, мөгаен, сез инде сизгәнсездер, парадокслар ярата: нәкъ менә шул тетрәтүләр һәм бәлаләр кешелекне тиранлык режимнары урнаштыруның теләсә нинди мөмкинлеген булдырмаслык гамәлдәге (позитив) хокукны камилләштерү юлларын эзләргә мәҗбүр итте. Иртәме-соңмы, бу юллар табигый хокукны тануга китерергә тиеш иде. Һәм XX гасыр уртасында ул яңадан «ачылды», үзенең гуманлык билгеләнешен дәвам итте.

Юридик чынбарлык сыйфатында ныгып, табигый хокук байтак илләрдә демократик үзгәрешләрнең үзенә күрә бер рухи нигезенә әверелә. 1948 елда Гомуми кеше хокуклары декларациясе, аннан соң нигез итеп алынырлык хокукый документларның зур күләмле пакеты кабул ителә, алар барысы бергә Кеше хокуклары хартиясен тәшкил итә. Шул ук чорда күп кенә Европа илләре, бигрәк тә үзләрендә фашизмның бөтен рәхимсезлеген тойган илләр — Германия, Италия, Испания — үз милли конституцияләренә кеше хокуклары турында махсус

бүлекләр керттеләр, шуның белән аларга турыдан-туры юридик, җитмәсә, өстенлекле әһәмият бирделәр. Бу моментны хокукта *икенче (антитоталитар)* революция дип атыйлар, хәзер инде табигый хокук яңадан турыдан-туры юридик әһәмият алды. РФ Конституциясенә (1993) шулай ук кеше һәм гражданнар хокуклары һәм ирекләре турындагы бүлек кертелде.

Кешенең табигый, тумыштан, аерылгысыз хокукларына нинди хокуклар керә соң?

Бу сорауга җавап биргәнче, кеше хокукының нәрсә икәнлеген билгелик. Фәндә шундый билгеләмә бар: *кеше хокуклары* — шәхес яшәешенең норматив яктан рәсмиләштерелгән (ягъни төгәл рәсмиләштерелгән рәвештә гәүдәләндерелгән), аның ирекен чагылдыручы һәм тормышының, башка кешеләр, җәмгыять, дәүләт белән үзара мөнәсәбәтләренең зарури булып торган үзенчәлекләре ул.

Тирәнлеге һәм эчтәлеге буенча гаҗәеп билгеләмә бу. Кеше тормышы (яшәеше) чиксез күпкырлылыгында табигый хокукларның үзенчәлеге (асылы, аерымлану сыйфаты) нидән торуы аңлашыла башлый. Фәкать хокуклар гына аның ирекенең норматив рәсмиләштерелгән (ягъни нормада беркетелгән) чикләрен (ирек үлчәмен) билгели ала. Яисә, башкача әйткәндә, ирек фәкать бурычларны да эченә алучы хокук нормасы аша гына билгеләнә ала.

Әлеге билгеләмәгә таянып, кеше яшәешенең норматив рәсмиләштерелгән үзенчәлекләренә — аның хокукларына — **яшәүгә хокукны** һәм тормышны **саклауга һәм үстерүгә** ярдәм итүче бар нәрсәне: шәхес кагылгысызлыгына хокук, милек иясе булуга хокук, фикер, сүз, күченеп йөрү ирегенә хокук, үзеңнең идарәчеләреңне сайлау хокукын һ.б. кертәләр. Сезгә мәгълүм хокукларны тагын санап тормыйбыз. Шунысын гына билгеләп үтик: бүген хокукларны төп һәм конституциячелгә бүлү очрый. Әмма фәндә кешенең төп хокуклары — аның конституциячел хокуклары булуы турында җитәрлек дәлилле фикер бар. Димәк, алар белән танышу өчен безнең Конституциягә мөрәҗәгать итәргә кирәк.

ТАБИГЫЙ ҺӘМ ПОЗИТИВ ХОКУКНЫҢ ҮЗАРА БӘЙЛӘНЕШЕ

Позитив хокук, документаль чынбарлык буларак, дәүләт барлыкка килүгә пәйда була һәм фәкать язмача, дәүләт урнаштырган законнар һәм башка юридик документлар рәвешендә яши (мәсәлән, сез тарихтан белгән хокукый документларны: борынгы һинд Ману законнары, Хаммурапи

патша законнары, Римның XII таблица законнарын, Рус Правдасын, Наполеон Кодексын һ.б. искә төшерергә мөмкин).

Табигый хокук, хокук нормаларының объектив рәвештә беренче нигезе буларак, ул нинди дә булса юридик документта беркетелгәнме яки юкмы икәнлегенә карамастан, мөстәкыйль яши (барыннан да элек хокукый аңга йогынты ясый).

Табигый-хокукый якын килү тарафдарлары табигый һәм позитив хокукны чикләп карыйлар. Бер үк вакытта алар, әлбәттә, позитив хокукны, ягъни дәүләт кабул иткән законнарны кире какмыйлар. Проблема законның сыйфатыннан гыйбарәт: әгәр ул табигый хокук кыйммәтләренә җавап бирмәсә, һәм позитив хокук табигый хокукка нигезләнми, аның кыйммәтләреннән чыкмый икән, ул хокукый булудан туктый. Хокукның иң югары кыйммәте — кеше, аның табигый, тумыштан килгән, димәк, аерылгысыз хокуклары ул. Табигый-хокукый якын килүнең *төп идеясе* шул.

Димәк, табигый хокук позитив хокукның (законның) сыйфатын бәяләргә (критерие булырга) мөмкинлек бирә. Ул *закон* кеше мәнфәгатьләрен, аның хокукларын һәм ирекен *ни дәрәҗәдә саклавын* билгеләргә ярдәм итә. Хокукны табигый һәм позитивка бүлеп карауның мәгънәсе дә шунда. Әмма мондый бүленеш абсолют түгел. Хәзерге заман хокукында табигый хокукның позитив белән якынлашуы закончалыклы процессы бара. Җентекләбрәк карыйк.

Югарыда билгеләп үтелгәнчә, табигый хокук кеше ирекe дәрәҗәсен чагылдыра. Ирек үзе табигый-хокукый якын килү позициясеннән кеше активлыгы киңлеге, үзенең карашынча, үз ихтыярына һәм мәнфәгатенә туры китереп гамәл кылуның табигый мөмкинлеге, кешеләрнең табигать биргән булдыклылыгын гамәлгә ашыру мәйданы буларак аңлашыла.

Шуның белән бергә ирек *чиксез була алмый*, һәм моны табигый хокук тарафдарлары бигрәк тә ассызыклап күрсәтә. Андый ирек юк. Җайга салынмаган ирек һәрвакыт үзенең капма-каршысы — законсызлык, башбаштаклык, чиксез тәртипсезлеккә әверелә, ә бу исә кешене үз-үзен юк итү һәлакәтенә алып бара (сез үзегез дә чиксез «ирек» чагылышының байтак мисалларын китерә алыр идегез).

Ирекнең чиген (чамасын, масштабын) билгеләргә яисә, И.Кант (1724–1804) сүзләре белән әйткәндә, һәр кешенең ирекe башка барлык кешеләр ирекe белән үзара ярашуы чиген билгеләргә беренче чиратта тормышның үзеннән килеп чыгучы ике бөек социаль көйләгеч — хокук һәм әхлак сәләтле.

Ирекнең чикләрен төгәл билгеләү зарурлыгы табигый һәм позитив хокук арасындагы бәйләнешне өзелмәслек итүе турында нәтиҗә ясарга нигез бар. Үзенең фундаменталь социаль

роле буенча табигый хокук беренчел нигез, позитив хокукның башлангыч чыганагы булып хезмәт итә, аны даими төстә гуманлык, азатлык, гаделлек идеяләре белән баета. Үз чиратында позитив хокук бу идеяләргә гомуми, мәҗбүри рәвештә дәүләт тарафыннан сакланучы тәртип нормасы көче — закон көче бирә, шуның белән кешеләр теләгән ирекне чынбарлыкка әверелдерә.

Табигый һәм позитив хокукның (законның) үзара бәйләнешен күрсәтү өчен, Россиянең мәгълүм хокук белгече С.С.Алексеев сөйләгән суд эше мисалын китерик.

Бу тайгада, геологлар эшләгән җирдә була. Көннәрдән-бер көнне, елга буена чыкканда, геолог Петров (фамилияләр үзгәртелгән) каршы якта куаклар шытырдавын ишетә. «Аю!» дип уйлый ул. Һәм юкка гына да түгел, аюлар геологларны еш борчый. Вакытны сузмыйча, Петров мылтык алырга кайта, аңа тагын геолог Широков та кушыла. Ярга чыгып, алар бер үк вакытта томан аралаш күренгән кара тапка аталар. Аларның мылтыклары нәкъ бер үк төрле, бер үк кибеттән сатып алынган була.

Бу тарих фаҗига белән тәмамлана: икенче ярда алар аюны түгел, ә күрше геология партиясенең балык тоту коралларын җайлап маташкан башлыгын атып үтерә. Суд барышында аның бер генә пуля белән үтерелүе ачыклана, икенчесе, башлыкның кесәсендәге ракетница патронына бәрелеп, читкә оча. Кем пулясы үтерүен ачыкларга мөмкин булмый: икесе дә ата. Бу, икесе дә тупас саксызлык күрсәтсә дә, уйланып эшләнгән җинаять булмый, икенче пуля очраклы китә. Суд аларның икесен дә гаепле дип таба. Гамәлдәге закон күзлегеннән барысы да дөрес. Әмма Югары суд бу карарны юкка чыгара. Судьялар болай фикер йөртә: пуляларның берсе генә үтергән, димәк, геологларның берсе һич тә гаепле түгел. Һәм монда судьялар тарафыннан хокукның асылын тирән аңлау күренә — хокук *гаделлек* ул. Ә гаделлек гаепсезне азат итүне таләп итә. Тик кемне? Билгеләп булмый. Һәм икесен дә азат итәләр.

Хәзер «документаль чынбарлык» — позитив хокукка мөрәҗәгать итәбез: илебездә законнар булдыру процессы белән танышабыз.

РФдә ЗАКОННАР ИҖАТ ИТҮ ПРОЦЕССЫ

Законнар иҗат итү процессы берничә төп этаптан яисә стадиядән тора.

Беренче стадияне «закон чыгару инициативасы» дип атыйлар. Сүз Дәүләт Думасына *закон проекты кертү хокукы*

турында бара. Басым ясап әйтик, закон проекты фәкать Дәүләт Думасына кертелә. Шуның белән Конституция палаталар компетенциясен чикли: закон кабул итү процессы түбәндәге палата (Дәүләт Думасы) компетенциясенә, ә законны хуплау яисә кире кагу хокукы югары палата (Федерация Советы) компетенциясенә кертелгән.

Конституция закон чыгару инициативасы субъектлары даирәсен чикли (104 статья, 1 өлеш). Монда түбәндәгеләр кертелгән: РФ Президенты, Федерация Советы, Федерация Советы әгъзалары, Дәүләт Думасы депутатлары, РФ Хөкүмәте, РФ субъектларының закон чыгару органнары. Закон чыгару инициативасы хокукы шулай ук РФ Конституция Судына, РФ Югары Судына һәм РФ Югары Арбитраж Судына аларга караган мәсьәләләр (ягъни алар компетенциясенә кертелгән мәсьәләләр) буенча бирелгән. Шуның белән бергә һичкем парламентка закон чыгару тәкъдиме белән мөрәҗәгать итү хокукыннан мәхрүм түгел. Аерма шунда гына: тәкъдимнәргә карата парламент аны нишләтергә икәнлеген үзе хәл итә ала, ә закон чыгару инициативасын карарга бурычлы. Шунысын дә билгеләп үтик: кайбер закон проектлары тик РФ Хөкүмәте бәяләмәсе булганда гына кертелә ала (бу финанс закон проектларына кагыла — 104 статья, 3 өлеш).

Икенче стадия — Дәүләт Думасында закон проектын тикшерү. Ул этаплап башкарыла: башта — рәсми булмаган, ә аннары рәсми төстә тикшерү. Баштагы тикшерүне «парламент тыңлаулары» дип атыйлар, монда парламентарийлар фикере белән бергә дәүләт һәм җәмәгать эшлеклеләре, шулай ук белгечэкспертлар (юрист, политолог, икътисадчы, социолог һ.б.) фикерләре дә тыңлана. Аларның искәрмәләре һәм тәкъдимнәре булачак законның югары сыйфатына ирешергә булыша.

Дәүләт Думасында рәсми тикшерү регламент буенча өч тапкыр («өч укуда») уздырыла. Беренче уку вакытында закон проектының төп, принципиаль нигезләмәләре эшләнә (шул ук вакытта ул кире кагылырга да, хупланырга да мөмкин). Икенче укылышны иң җентекле, дикъкатле диярга мөмкин: проектны статьялап карау бара, кирәкле төзәтмәләр кертелә (бу этапта да закон проекты кире кагыла яисә хуплана ала). Өченче укылыш закон проектының түбәнге парламентта тикшерүне тәгәлли. Бу укылыш барышында депутатлар бернинди төзәтмә кертә алмый, алар бер генә карар чыгара — закон проектын хупларгамы яки хупламаскамы (закон проектының бер үк вакытта өч укуда да кабул ителгән чаклар була).

Өченче стадия — Дәүләт Думасында законны кабул итү. Законның төренә карап, аны кабул итү процедурасында аерма бар. Гадәти федераль закон кабул итү өчен депутатларның

гомуми санынннан гади күпчелек тавыш җитә (гомуми сан — 450 депутатның 50%ы плюс 1 тавыш). Федераль конституциячел закон ул квалификацияле күпчелек тарафыннан хупланса гына кабул ителә (тавышларның кимендә өчтән ике өлеше белән).

Дүртенче стадия — законны Федерация Советында кабул итү (аның саны — 178 депутат). Дәүләт Думасында кабул ителгән закон Федерация Советына керә, анда 14 көн эчендә каралып, кабул ителергә яисә кире кагылырга тиеш. Монда 106 статьяда бирелгән исемлек буенча (финанс, халыкара шартнамәләр, дәүләт чикләре, сугыш һәм тынычлык мәсьәләләре) Дәүләт Думасы кабул иткән федераль законнар гына каралырга тиеш. Ә аннан соң тавыш бирү процедурасы болай корыла: гадәти федераль закон, әгәр аңа депутатларның яртысыннан күбрәге тавыш бирсә, кабул ителгән дип санала; федераль конституциячел законны кабул итү өчен югары палата депутатларның гомуми санынннан кимендә дүрттән өче тавыш бирергә тиеш.

Бишенче стадия — законга кул кую һәм аны халыкка җиткерү. Парламент кабул иткән федераль закон РФ Президентына җибәрелә. 14 көндә ул аны карарга һәм имзаларга (йә кабат карау өчен кире кайтарырга) тиеш. Президент кул куйган закон игълан ителә. Игълан итүнең максаты — яңа законның эчтәлеген рәсми басмалар — «Российская газета» һәм «Собрание законодательств РФ» журналында бастырып чыгару юлы белән халык игътибарына җиткерү. Фәкать бастырып чыгарылган закон гына гамәлгә керә.

Президент закон эчтәлеге белән килешмәгән һәм аңа кул куюдан баш тарткан вазгыятьтә федераль закон палаталарга кабат карау өчен кайтарыла. Һәм әгәр кабат караганда да закон элек кабул ителгән редакциясендә Федерация Советы әгъзалары һәм Дәүләт Думасы депутатларының гомуми санынннан кимендә өчтән ике өлеше тарафыннан хупланса, ул Президент тарафыннан имзаланырга һәм игълан ителергә тиеш (107 статья).

ГАМӘЛИ ЙОМГАКЛАР

1 Шулай итеп, хокуклар кешегә тумыштан бирелә. Бу хокуклар иң югары кыйммәтләрне тәшкил итә. Аның белән дөрес эш итү — сезнең төп гамәли бурычыгыз. Сезнең өчен әлеге бурычны берәү дә хәл итә алмый. Әмма нәтиҗәләр өчен җаваплылык та беренче чиратта сезгә йөкләнә.

2 Югарыда бәян ителгәннәрдән өч төп гамәли бурыч килеп чыга: кеше хокукларын а) хөрмәт итәргә, б) үтәргә һәм

в) якларга кирәк. Хокукларны хөрмәт итү барыннан да элек аны төгәл үтәүдә чагыла. Ә үтәү байтак очракларда аларны яклау зарурлыгы белән бәйле. Әлеге бурычларны башкару бөтен гомер буена гаять шәхси тырышлыкны таләп итә.

3 Граждан буларак, сезгә хакимиятнең гамәлләрен күзәтеп торырга гына түгел, аның вәкилләре белән очрашырга да туры киләчәк. Хакимият гамәлләрен тик аларның кеше хокукларына, сезнең хокукларга мөнәсәбәте призмасы аша гына дөрес бәяләргә мөмкин. Ул гына да түгел, сезнең хакимият карарларын һәм гамәлләрен тикшереп тору, алар белән килешү яки килешмәү һәм кирәк булганда аларга судта шикаять белдерү хокукыгыз булуны онытмаска кирәк.

4 Сез җәмгыятьтә, сезнеке кебек үк хокуклары булган кешеләр даирәсендә яшисез. Димәк, сезнең хокукларны тормышка ашыру башка кешеләр хокукларын һәм ирекләрен бозарга тиеш түгел.

5 Сез законнар чыгару инициативасы субъектлары даирәсенә кермәсәгез дә, законнар чыгару процессында катнашу хокукыгыз бар. Граждан буларак, сез закон чыгару тәкъдиме белән (әгәр тәкъдим итәрлек әйбер булса) чыга аласыз.

ДОКУМЕНТ

Хәзерге заман Россия хокук белгече ***С.С.Алексеевның*** «Хокук: әлифба — теория — фәлсәфә» дигән хезмәтеннән.

Табигый хокук тәгълиматы, асылда, фәлсәфи-сәясәт фикере тарихында беренче иң гади, үтәли, гасырлар аша узган, саф акыл һәм фән таләпләре белән ярашып, хокукны кеше тормышының табигый башлангычы, табигый мохит, кеше яшәеше белән бәйләүгә юнәлтелгән идеягә әверелде.

Нәкъ менә шуңа табигый-хокукый карашлар хокукны чынлап та тирән фәлсәфи аңлатуларда башлангыч пункт кына түгел..., кешелек тарихындагы гуманитар фикернең иң мөһим казанышларының берсенә әйләнде, кеше рухының бөеклеге һәм үзенә күрә бер «ачыш»та булды.

Документка сораулар һәм биремнәр

1. Өзекнең төп фикерен формалаштырыгыз. **2.** Бөтендөнья фикере тарихында табигый хокук идеясе нигә гасырлар аша үтә алды? **3.** Алган белемнәрегезгә таянып, авторның

табигый-хокукый карашларның кешелек тарихында гуманитар фикернең иң әһәмиятле казанышына әверелүен расларга нинди дәлилләре булуын аңлатыгыз.

ҮЗ-ҮЗЕҢНЕ ТИКШЕРҮ ӨЧЕН СОРАУЛАР

1. Хокукка норматив якын килүнең асылы нидә? **2.** Табигый хокукның төп үзенчәлекләрен характерлагыз. **3.** Табигый хокук нинди юллар белән юридик чынбарлыкка әверелә? **4.** Табигый һәм позитив хокукның үзара йогынтысы нигә кирәк булуын аңлатыгыз. **5.** Табигый хокукның гуманлык мәгънәсе нәрсәдә? **6.** Закон чыгару процессы нигә этаплап алып барыла? Закон булдыруның төп стадияләре нинди?

БИРЕМНӘР

1. Гомуми мәҗбүри социаль нормаларның дәүләт мәҗбүрияте көче белән сакланучы, иҗтимагый мөнәсәбәтләрне юридик регламентацияләүне тәэмин итүче системасы буларак, позитив хокук билгеләмәсен анализлау нигезендә берничә бирем үтәгез:

1) әлеге билгеләмәдә хокукка норматив якын килүнең нинди сыйфатлары чагылыш табуын күрсәтегез;

2) әлеге билгеләмәнең хокукны хәзерге заман аңлавы асылы турында тулы мәгънә бирмәвен исбатлагыз;

3) хокукны аңлауга хәзергечә якын килү турында карашларыгыз нигезендә үз хокук билгеләмәгезне булдырыгыз (кыскалыгы мәҗбүри түгел, тасвирлама бирсәгез дә була: иң мөһиме, ул хокукны заманча аңлауның типик якларын чагылдырсын).

2. Ике гыйбарәне чагыштырыгыз:

«Гаделлектән башка бу патшалык (дәүләтләр) зур юлбасар банда булмыйча нәрсә булсын соң?.. Чын гаделлек булмаган җирдә хокук була алмый. Хокук буенча кылган эш кенә, һичшиксез гадел була. Ә гаделсезлек белән эшләнсә, ул хокук буенча була алмый» (Августин (354–430), христиан теологы).

«Хокукый фән позициясеннән караганда, нацистлар хакимлеге (сүз Германия фашистлары турында бара) астындагы хокук ул — хокук. Без бу хакта кайгыра алабыз, ләкин без моның хокук булуын кире кага алмыйбыз... Без аңа карата... агулы еланга караган кебек җирәнү хисе кичерергә мөмкин, ләкин аның яшәвен кире кагу мөмкин түгел» (Г.Кельзен (1881–1973), Австрия юристы).

Әлеге гыйбарәләргә сезнең мөнәсәбәтегез ничек? Үз карашыгызны аңлатыгыз. Үз бәяләмәгездә нинди позициядән чыгасыз?

ЗИРӘКЛӘР ФИКЕРЕ

«Гражданнар ирекләреннән файдаланучы халыкларда
һәр индивидум закон белән, һич югында,
бу кысылу башкалар хокукын саклау өчен
кирәк булган дәрәҗәдә, кысылган».

Ф.Стендаль (1783–1842), француз язучысы

§ 20. Россия Федерациясе гражданы

Кем РФ гражданы була ала? РФ гражданының Россиядә эшләүче һәм яшәүче чит ил гражданыннан нинди өстенлеге бар? Россия гражданлыгы алуга кемгә рөхсәт бирмәскә мөмкиннәр?

Сезнең белүегезчә, «граждан» сүзе төрле мәгънәләрдә кулланыла. Бу очракта без граждан турында гражданнар хокуклары, сәяси һәм башка хокуклар һәм бурычлар бирелгән, алар нигезендә гамәл кылучы индивид буларак сөйлибез. (Бу сүзнең башка мәгънәләрен дә искә төшерегез.)

Гражданлык институтының хокукый нигезләрен җентекләп карыйк.

РФ ГРАЖДАНЛЫГЫ

Юридик әдәбиятта «гражданлык» дип затның хокукый яктан әлеге дәүләтнеке булуы, ягъни дәүләт тарафыннан бу затны конституциячел-хокукый мөнәсәбәтләрнең тулы хокуклы субъекты итеп тану аңлашыла. Монархияле дәүләтләрдә «подданство» дигән термин кулланыла, ул формаль яктан монархка шәхси тугрылыкны аңлата, әмма безнең чорда фактта «гражданлык» төшенчәсе белән бертигез.

РФ гражданлыгы, аны алу нигезләренә карамастан, бердәм һәм тигез булып тора. РФ гражданы үз гражданлылыгыннан яисә аны үзгәртү хокукыннан мәхрүм ителә алмый. Ул РФдән читкә сөрелә яки башка дәүләткә бирелә алмый.

Дәүләт гражданнарга үз территориясендә булган вакытта аларның конституциячел хокукларын, ирекләрен яклауны гарантияли, чит илдә яклау һәм аклауны тәэмин итә. Моңа җавап итеп дәүләт гражданның, ул хәтта чит илдә булса да, билгеләнгән законнарны саклавын һәм конституциячел бурычларын үтәвен көтә. Шуны билгеләп үтәргә кирәк: бу үзара йөкләмәләр персональ һәм экстерриториаль характерда; алар

гражданның ил территориясендә озак булмавы яки аннан читтә яшәве очрагында да туктатылмый.

Кеше ничек итеп граждан була ясә, закон теле белән әйткәндә, гражданлык алу нигезләре нинди?

Беренчедән, гражданлыкны тумыштан алу. «Россия Федерациясе гражданлыгы турында» Федераль законның 12 статьясы нигезендә, әгәр аның туган көненә түбәндәгеләр булса, бала РФ гражданы булып санала:

а) ата-анасының икесе дә йә икесенең берсе Россия гражданлыгына ия булса (баланың кайда тууы мөһим түгел);

б) ата-ананың берсе РФ гражданлыгына ия, ә икенчесе гражданлыксыз зат булса яисә билгесез рәвештә булмаучы, яисә кайда икәнлеге билгесез булса (баланың кайда тууы мөһим түгел);

в) ата-ананың берсе Россия гражданы, икенчесе чит ил гражданы булып, әгәр бала РФ территориясендә туса, башка очракта ул гражданлыксыз зат була;

г) РФ территориясендә яшәүче ата-ананың икесе дә (яисә аларның бердәнбере) чит ил гражданы яки гражданлыксыз зат булса, бала Россия Федерациясе территориясендә туган шартларда, ә аның ата-анасы яки бердәнбере граждан булган ил балага үз гражданлыгын бирмәсә.

Икенчедән, гражданлыкка алу яисә натураллаштыру. 18 яшькә җиткән һәм хокук сәләтенә ия булган теләсә нинди зат, әгәр ул биш ел дәвамында өзлексез Россия территориясендә яшәсә, РФ гражданлыгына кабул ителү турында гариза бирергә хокуклы. Башка шартларга түбәндәгеләр керә: РФ Конституциясен һәм РФ законнарын һичшиксез үтәү; яшәү чарасының законлы чыганагы булу, рус телен белү.

Законнар кайбер категория чит ил гражданнарын һәм гражданлыксыз затларны гражданлыкка алуның гадиләштерелгән процедурасын да күздә тота. Сүз беренче чиратта күренекле фән, техника һәм мәдәният эшлеклеләре; югары квалификацияле белгечләр; РФ территориясендә сәяси сыену урыны бирелүче затлар, шулай ук билгеләнгән тәртиптә «качаклар» дип танылучылар турында бара.

Моннан тыш закон элеккеге СССР гражданлыгы булган һәм РФ территориясендә яшәгән Бөек Ватан сугышы ветераннары; Россия гражданнары белән никахта торган, шулай ук ата-анасының берсе генә булса да Россия гражданы булган затлар һәм Россия Федерациясе территориясендә яшәүчеләрнең мәнфәгатьләрен исәпкә ала. Россия гражданлыгын гадиләштерелгән тәртиптә РСФСР территориясендә туган һәм элеккеге СССР гражданы булган затлар алырга мөмкин.

Элек Россия гражданлыгы булган, әмма нииндидер нигезләрдә аны югалткан затлар аны торгызырга хокуклы.

«Гражданлык турында...» федераль закон гражданлык алуның башка нигезләрен: оптацияне, шулай ук баланы уллыкка (кызлыкка) алуны күздә тота. Оптация — территорияләр үзгәрү (ягъни Дәүләт чиге үзгәрү белән бәйле рәвештә) гражданлык алу рәвеше ул. Россия гражданы тарафыннан уллыкка (кызлыкка) алынган чит ил гражданлыгы булган бала да Россия законнары һәм әлеге дәүләт законнары нигезендә Россия гражданы була ала.

Россия законнары аерым бер хәлләрдә ике гражданлыкны, ягъни РФ гражданының чит ил гражданлыгы (подданствосы) булуын рөхсәт итә. Мондый хәл — һәрчакта кагыйдәдән чыгарылма; уртак кагыйдә буенча, аерым бер илнең гражданына башка дәүләт гражданы булу рөхсәт ителми.

Шунысын басым ясап күрсәтик: граждан һәм граждан булмаганнарның хокукый хәлендәге аерма һич тә соңгысын дискриминацияләүне аңлатмый. Дәүләт кеше хокукын аның гражданлыгына карамастан яклый.

РФ ГРАЖДАНЫНЫҢ ХОКУКЛАРЫ ҺӘМ БУРЫЧЛАРЫ

Кеше хокуклары һәм гражданнар хокукы еш кына бергә искә алына, әмма аларның эчтәлеге тәңгәл түгел. Алар арасындагы аерма нидә?

Исегезгә төшерәбез, **кеше хокуклары** башлангыч булып тора, алар барлык кешегә тумыштан, аларның үзләре яшәгән дәүләт гражданымы-түгелме икәнлегенә карамастан бирелгән. Яшәүгә хокук, ирекка һәм шәхси кагылгысызлыкка, шәхси тормышка һәм үз-үзеңне билгеләү, шәхесне реализацияләү, теләсә нинди законсыз катышудан бәйсезлеген тәэмин итү өчен шартлар булдыручы башка хокуклар шуларга керә.

Граждан хокуклары затка фәкать аның гражданлыгына карап беркетелгән хокукларны гына үз эченә ала.

Шулай итеп, теге яки бу дәүләтнең һәр гражданы гомумтанылган кеше хокукларына кертелгән хокукларның бөтен комплексына һәм, шуңа өстәп, әлеге дәүләттә танылган барлык граждан хокукларына ия. Үзегез дә аңлаганча, РФ гражданнарының гына безнең дәүләт эшләре белән идарә итүдә катнашырга хокукы бар. Бу гражданнарның референдумнарда һәм сайлауларда катнашу, дәүләт хакимияте органнарына сайланырга хокукын күздә тота. Әйтик, Россия гражданнары

гына депутат, судья, прокурор, тикшерүче, милиция органнары, дәүләт куркынычсызлыгы, таможня хезмәте хезмәткәрләре, хәрби хезмәткәр, диңгез кораблары һәм һава суднолары капитаны, дипкурьер була ала. Ниһаять, Россия гражданы гына ил президенты итеп сайлана, дәүләт серен тәшкил итүче белешмәләр белән эш итә ала.

Кеше хокукларын тәэмин итү буенча йөкләмәләр кабул итеп, дәүләт шул ук вакытта аңардан юридик нормаларда беркетелгән стандартларга туры килүче тәртибен дә таләп итәргә хокуклы. Шуңа дәүләт индивидларга үз таләпләрен бурычлар системасы аша формалаштыра, аларның үтәлеше өчен юридик җаваплылык чаралары билгели.

Бурыч — кешенең объектив зарури, тиеш булган тәртибе дияргә мөмкин. Конституциячел бурычларның бер өлеше дәүләттә яшәүче барлык затларга кагылуын билгеләп үтик. Мәсәлән, РФ Конституциясе һәркемнең билгеләнгән салым һәм җыемнарны түләве (57 статья); табигатьне һәм әйләнәтирә мохитне саклавы, табигать байлыкларына сак каравы (58 статья); тарихи һәм мәдәни мирасны саклау турында кайгыртуы, тарих һәм мәдәният ядкәрләрен саклавы (44 статья); балалар һәм хезмәткә сәләтсез ата-аналары турында кайгыртуы (38 статья) бурычларын күздә тота.

РФ гражданы хокукый статусын аңлауга аның кайбер конституциячел бурычларын җентекләп карау ярдәм итәр. Аерым алганда, Конституциядә Ватанны саклау РФ гражданының бурычы булып тора дип күрсәтелгән (59 статья).

ХӘРБИ БУРЫЧ

РФ гражданнары «Хәрби бурыч һәм хәрби хезмәт турында» Федераль закон нигезендә (1998 елның 21 июлендәге редакциядә, аннан соңгы чорда кертелгән үзгәрешләре белән) хәрби хезмәт үтәләр. Исегезгә төшерик, РФ гражданының хәрби бурычы түбәндәгеләрне үз эченә ала: хәрби исәпкә басу, хәрби хезмәткә әзерлек, хәрби хезмәткә чакырылу һәм хәрби хезмәт узу, шулай ук запаста булу, хәрби җыеннарга чакырылу һәм запаста булган чорда хәрби җыеннар узу.

Якын киләчәктә мәктәпне тәмамлаучы яшүсмерләргә кагылачак хәрби бурыч аспектларына тукталып үтик.

Иң элек шуны ассызыклыйк, 17 яше тулган елда яшь егет (1 гыйнвардан 31 марткача) тору урыны буенча район хәрби комиссариатында хәрби исәпкә басарга бурычлы. Ул повестка буенча билгеләнгән вакытта район хәрби комиссариатына килергә тиеш. Хәрби исәп кагыйдәләрен бозучы, чакыру буенча

хәрби комиссариатка тиешле сәбәпсез килмәүче кисәтелә яки административ штрафка тартыла.

(Хәрби хезмәткә мәҗбүри әзерлек нидән гыйбарәт булуын исегезгә төшерегез.)

Азат ителү яки чакырудан кичектерелү хокукы булмаган ир-ат җенесендәге 18 яшьтән 27 яшькәчә барлык гражданнар хәрби хезмәткә чакырыла. Хәрби хезмәттән читләшкән өчен җинаять җаваплылыгы билгеләнгән. Закон шулай ук ир-ат һәм хатын-кызларның хәрби хезмәткә контракт буенча керүен дә күздә тота.

Чакыру буенча хәрби хезмәт вакыты 12 ай тәшкил итә. Хәрби хезмәткә контракт буенча кергән гражданнар аны контрактта күрсәтелгән вакытта уза.

Ә яшь кеше сәламәтлеге буенча хезмәт итә алмаган очракта нишләргә? Әгәр аны хәрби хезмәткә яраксыз яки чикләүле генә яраклы дип тапсалар, ул хәрби хезмәттән азат ителергә мөмкин. Моннан тыш фәннәр кандидаты яисә фәннәр докторы дигән гыйльми дәрәҗәсе булган гражданнар хәрби хезмәткә чакырылмый. Шулай ук әтисе, әнисе, бертуган абыйсы, апасы хәрби хезмәт бурычларын үтәгәндә һәлак булган егетләр армиягә алынмый.

Закон хезмәткә чакыру яшендәге кайбер категория гражданнар өчен хәрби хезмәткә чакыруны кичектереп тору мөмкинлеген күздә тота. Моның өчен нигез булып вакытлыча сәламәтлек какшау проблемасы; чит кеше ярдәменнән башка тора алмаган туганы яки якын кешесен карау зарурлыгы; баланы әнисеннән башка тәрбияләү тора. Ике һәм аннан күбрәк баласы яисә өч яшенә кадәрге бер баласы булган граждан да кичектерүгә өметләнә ала һ.б. Башлангыч һөнәри, урта һөнәри яисә югары һөнәри белем бирү учреждениеләрендә эштән аерылып укый торган гражданнарга да — уку чорында, шулай ук гомуми белем учреждениеләрендә 18 яшьтән соң укучыларга (мәктәпне тәмамлаганчы) чакыру кичектерелә.

Шунысына да игътибар итегез: хәрби хезмәткә чакыруны күрсәтелгән кичектерү ике тапкырдан артык булмый (әлеге һәм күрсәтелгән типтагы белем бирү учреждениеләренең теләсә нинди икесендә югарырак дәрәҗәдә һөнәри белем алу өчен).

Хәрби хезмәт узу мәсьәләләре (вакыты, контракт төзү, кандидатлар сайлап алу тәртибе һ.б.) РФ Президенты Указы белән расланган Нигезләмә белән җайга салына (2000 елның 26 июнендәге редакциядә). Хәрби хезмәткәрләрнең хокукый хәле «Хәрби хезмәткәрләрнең статусы» Федераль законы (2000 елның 19 июнендәге редакциядә) билгеләнгән.

АЛЬТЕРНАТИВ ГРАЖДАН ХЕЗМӘТЕ

Югарыда бәян ителгәннәрдән чыгып, сорау туарга мөмкин: әгәр хәрби хезмәт гражданның инануларына яисә дин тотуына каршы килсә, бу очракта нишләргә?

Закон аңа хәрби хезмәтне альтернатив граждан хезмәтенә алмаштыру хокукы бирә.

Нәрсә соң ул альтернатив граждан хезмәте (АГХ)? Хәрби хезмәткә чакыру урынына гражданнар җәмгыять һәм дәүләт мәнфәгатьләрендә башкара торган аерым төр хезмәт эшчәнлеге ул. АГХ медицина һәм башка дәүләт учреждениеләрендә, шулай ук Россия Федерациясе Кораллы Көчләре оешмаларында, башка гаскәрләр, хәрби формирование һәм органнарда граждан персоналы сыйфатында тормышка ашырылырга мөмкин. Ул «Альтернатив граждан хезмәте турында» Федераль закон (2002 елның 25 июлендәге) белән каралган үзенчәлекләрне исәпкә алып, РФ Хезмәт кодексы белән җайга салына.

Шунысын да билгеләп үтик: альтернатив граждан хезмәтенә җибәрелүче граждан шөгыльләнергә мөмкин булган эш төрләре, һөнәре һәм вазифасы һәм аның үтү урыны турында мәсьәләне хәл иткәндә, гражданның белеме, белгечлеге, квалификациясе, элеккеге эш тәҗрибәсе, сәламәтлегенең торышы, гаилә хәле, шулай ук оешмаларның хезмәт ресурсларына ихтыяҗы исәпкә алына.

Мондый хокуктан файдаланырга уйлаган граждан аның «Хәрби бурыч һәм хәрби хезмәт турында» Федераль закон билгеләгән хәрби хезмәт вакытыннан 1,75 тапкыр артыграк булуын исендә тотарга тиеш. РФ Кораллы Көчләре оешмаларында граждан персоналы сыйфатында хезмәт иткәндә исә аның вакыты 36 һәм 18 ай тәшкил итә.

Граждан үзенең альтернатив хезмәткә хокукын ничек гамәлгә ашыра ала соң?

Барыннан да элек ул чакыру буенча хәрби хезмәтне АГХга алыштыру турында гаризаны үз вакытында бирергә тиеш (үзен чакыру вакытына кадәр кимендә ярты ел кала). Гаризада хәрби хезмәт нигә аның инануларына яисә тоткан диненә каршы килүен нигезләргә кирәк. Яшь кеше аның дәлилләрен расларга риза булучы затларны күрсәтергә хокуклы.

Хәрби хезмәткә чакыру комиссиясе тарафыннан хәрби хезмәтне АГХ белән алмаштыру турында карар чыгарылган гражданга, медицина таныклавына һәм хәрби хезмәткә чакыру комиссиясенең аны альтернатив хезмәткә җибәрү турындагы мәсьәлә хәл ителүче утырышына килү вакыты күрсәтеп, повестка тапшырыла. Килмәгән очракта ул хәрби хезмәткә чакырыла.

САЛЫМ ТҮЛӘҮЧЕНЕҢ ХОКУКЛАРЫ ҺӘМ БУРЫЧЛАРЫ

Җәмгыятьтә яшәүче һәм аның уңайлыкларыннан файдаланучы кешегә һәм гражданга алыштыргысыз таләпләрнең берсе булып законлы билгеләнгән салым һәм җыемнарны һичшиксез түләү тора. Исегезгә төшерәбез: салымнар ярдәмендә дәүләт оборона сәләтен һәм гражданнарның иминлеген тәэмин итә, бөтен җәмгыять мәнфәгатендә икътисадны, мәгарифне, фәнне, сәламәтлек саклауны үстерә.

Россия Федерациясе Салым кодексында (1998 елның 31 июлендәге) салымнар билгеле бер күләмдә һәм алдан ук күрсәтелгән вакытта түләнә дип билгеләнә. Салым түләүдән тайпылган һәм түләү тәртибен бозган салым түләүчеләр административ, ә аерым очракларда җинаять җаваплылыгына да тартылалар. Исегезгә төшерәбез: салым түләүчеләр дип РФ Салым кодексы нигезендә салым түләү бурычы йөкләнгән оешмалар һәм физик затлар таныла.

Салым түләүчеләр Федераль салым хезмәте органнарында исәпкә басарга һәм билгеләнгән тәртиптә үз керемнәренең (чыгымнарының) һәм салым салу объектларының исәбен алып барырга тиеш. Аларның салым органнарының урындагы затлары үз хезмәт бурычларын үтәгәндә каршы төшәргә хаклары юк. Салым түләүчеләр салым органына РФ Салым кодексында каралган очракларда һәм тәртиптә кирәкле мәгълүмат һәм документлар бирергә бурычлы.

Салымнарны һәм җыемнарны үз вакытында һәм тулы күләмдә түләү бурычы салым түләүчеләрнең законда билгеләнгән билгеле бер хокуклары белән үрелеп бара. Аларның кайберләрен карап үтик.

Салым түләүче түбәндәгеләргә хокуклы: гамәлдәге салымнар һәм җыемнар турында, салым һәм җыемнар хакындагы законнар, салым түләүчеләрнең хокуклары һәм бурычлары, салым органнары һәм вәкаләтле затларының вәкаләтләре турында түләүсез мәгълүмат, шулай ук салым һәм җыем хакындагы законнарны куллану мәсьәләләре буенча язмача аңлатма алырга. Алар законнарда билгеләнгән нигездә һәм тәртиптә салым түләү буенча өстенлекләрдән файдалана ала, салымны чыгару, өлешләп түләү яисә салым кредиты алырга мөмкин. Салым түләүче салым органнарының дөрес булмаган актларын һәм таләпләрен үтәмәскә; салым органнары һәм аның урындагы затлары гамәлләренә (гамәл кылмауларына) билгеләнгән тәртиптә шикаять белдерергә; салым серен саклауны һәм салым органнарының законсыз карарлары яки

аларның урындагы затлары гамәлләре (гамәл кылмаулары) белән китерелгән чыгымнарны тулы күләмдә кайтаруны таләп итәргә хокуклы һ.б.

Шуны билгеләп үтик: салым хокук бозулары өчен җаваплылык чарасы булып штраф рәвешендәге салым санкциясе тора.

ГАМӘЛИ ЙОМГАКЛАР

1 РФ гражданы буларак сезнең киң даирә хокукларыгыз бар, аларны саклау сезгә дәүләт тарафыннан гарантияләнә. Шуның белән бергә катгый белеп тору зарур: дәүләт сездән конституциячел бурычларыгызны, сез хәтта аннан читтә яшәсәгез дә, үтәүне таләп итәргә хокуклы.

2 Дәүләттән читтә вакытлыча (турист булып, чакыру буенча һ.б.) булганда яисә башка дәүләт территориясендә даими яшәгәндә дә, сез Россия ягыннан яклауга исәп тота аласыз. Чит илдә аның һәм граждан буларак сезнең мәнфәгатьләрне РФ дипломатик һәм консуллык учреждениеләре яклый.

3 Параграф текстында искә алынган федераль законнар эчтәлеге белән танышу, аларга үзгәрешләр кертүне даими күзәтеп бару файдалы, бу граждан буларак, сезнең хокук һәм бурычларыгызны яхшы белү өчен кирәк.

4 Яшүсмерләргә «Хәрби бурыч һәм хәрби хезмәт турында» һәм «Альтернатив граждан хезмәте турында» федераль законнар белән танышырга киңәш итәбез. Сезгә хәрби комиссариат повесткасын күрмәмешкә салышырга киңәш итмибез. Шул ук вакытта хәрби комиссариатка килү өчен берләнбер нигез булып үз кулыгыз белән кул куеп алган повестка (сезгә шәхсән тапшырылучы повесткага кул куймаска хакыгыз юк) торуны басым ясап күрсәтәбез. Теләсә кайсы башка кеше кул куйган яисә башка зат аша тапшырылган повестка, шулай ук телефон буенча килүне таләп итү бернинди юридик нәтиҗә бирми. Мондый очракта хәрби комиссариатка бармаган өчен сезне җаваплылыкка тарта алмыйлар.

5 Чакыру буенча хәрби хезмәтне АГХга алыштыру хокукыннан файдаланырга карар кылган яшь кеше аңа рөхсәт булмау мөмкинлеген аңларга тиеш. Хәрби хезмәттә булуның инануларыңа һәм дин тотуыңа каршы килү турындагы дәлилләреңне хәбәр итүче гаризаны үз вакытында бирергә кирәк.

ДОКУМЕНТ

«Россия Федерациясе гражданлыгы турында» Федераль законнан *(2003 елның 11 ноябрендәге редакциядә).*

9 статья. Балаларның гражданлыгы

<...>

2. 14 яшеннән 18 яшькә кадәрге баланың Россия Федерациясе гражданлылыгын алуы һәм туктатуы өчен аның ризалыгы кирәк.

3. Баланың Россия Федерациясе гражданлыгы, әгәр ул РФ гражданлыгы туктатылганнан соң гражданлыксыз зат булып калса, туктатыла алмый.

4. Ата-ана хокукыннан мәхрүм ителгән ата-ананың гражданлыгы үзгәргәндә, баланың гражданлыгы үзгәрми. Баланың гражданлыгы үзгәргәндә, ата-ана хокукыннан мәхрүм ителгән ата-анасының ризалыгы таләп ителми.

<...>

14 статья. Россия Федерациясе гражданлыгына гадиләштерелгән тәртиптә кабул итү.

<...>

2. Россия Федерациясе гражданлыгына гадиләштерелгән тәртиптә... чит ил гражданнары яисә гражданлыксыз затлар булган бала һәм хокукый гамәлгә сәләтсез зат кабул ителә:

а) ата-анасының берсе Россия Федерациясе гражданы булган бала,— бу ата-ана гаризасы буенча һәм икенче ата-ананың бала тарафыннан РФ гражданлыгы алуга ризалыгы булганда. Әгәр бала Россия Федерациясе территориясендә яшәсә, мондый ризалык таләп ителми;

б) бердәнбер ата-анасы РФ гражданлыгына ия булган бала,— әлеге ата-ана гаризасы буенча;

в) өсләреннән опека һәм попечительлек урнаштырылган бала яисә хокукый гамәлгә сәләтсез зат,— РФ гражданлыгы булган опекун яисә попечитель гаризасы буенча.

Документка сораулар һәм биремнәр

1. Параграфның төп текстына һәм китерелгән документка таянып, безнең илдә балалар гражданлыгын билгеләүче шартларны формалаштырыгыз. **2.** Үз фикерегезне әйтегез: балалар гражданлыгы мәсьәләләрен хәл иткәндә РФ законнары бала мәнфәгатьләрен максималь исәпкә алырга омтыла дип расларга мөмкинме? Үз җавабыгызда карашыгызны раслаучы кимендә өч дәлил китерегез.

ҮЗ-ҮЗЕҢНЕ ТИКШЕРҮ ӨЧЕН СОРАУЛАР

1. Нәрсә ул гражданлык? Россия гражданлыгының принциплары нинди? Гражданлык алу нигезләрен атагыз. **2.** Россия гражданлыгын алуның гадиләштерелгән процедурасы чит ил гражданнары һәм гражданлыксыз затларның нинди категориясенә карата кулланылырга мөмкин? **3.** Гражданнар һәм кеше хокукларының аермасы нидә? РФ гражданы хокукларын һәм аңа йөкләнгән конституциячел бурычларны атагыз. **4.** Нәрсә ул хәрби бурыч? **5.** Нәрсә ул альтернатив граждан хезмәте? Чакыру буенча хәрби хезмәтне АГХгә алмаштыру хокукына кем ия? **6.** Салым түләүчеләрнең төп хокуклары һәм бурычлары нинди?

БИРЕМНӘР

1. Дөнья илләре конституцияләрендә, халыкара-хокукый актларда урнашкан терминологияне кулланып, кеше хокуклары турында сөйләгәндә «һәркем хокукка ия...», «беркем дә мәхрүм ителә алмый...», «барысы да», «шәхес» дигән сүзләр кулланалар. Әгәр дә сүз әлеге дәүләт гражданнарының гына хокуклары турында барса, «гражданнар шуңа хокуклы» дигән төгәл формулировка кулланыла. РФ Конституциясенең 2 бүлегенең нинди статьяларында граждан хокуклары турында әйтелә? Алар нинди хокуклар? Алар шул ук бүлектә формалаштырылган башка хокуклардан нәрсәсе белән аерыла?

2. РФ Конституциясендә Ватанны саклау нигә гражданның бурычы да, вазифасы да дип атала? Нигә «бурыч» һәм «вазифа» сүзләре Төп законда янәшә тора?

3. Яшь кеше көзен хәрби хезмәткә чакырылырга тиеш иде. Ул чакыру буенча хәрби хезмәтне альтернатив граждан хезмәтенә алыштыру хокукыннан файдаланырга булды һәм көзге чакырылыш башлаганчы берничә көн кала хәрби комиссариатка гариза бирде. Сез ничек уйлыйсыз: аның үтенечен канәгатьләндерерләрме? Җавабыгызны аңлатыгыз.

4. Вакытлы матбугаттан Россиядә салым хокук бозуларын күрсәтүче мисалларны сайлап анализлагыз һәм салым хокук бозуларының иң гомуми сәбәпләрен формалаштырыгыз.

ЗИРӘКЛӘР ФИКЕРЕ

«Кешеләрдән яхшы гражданнар ясар өчен аларга үзләренең гражданнар хокукларын күрсәтү һәм граждан вазифаларын башкару мөмкинлеге бирергә кирәк».

С.Смайлс (1916–1903), инглиз язучысы

§ 21. Экологик хокук

Чүп базында яшәү кемгә ошый? Әйләнә-тирә мохитне сакларга мөмкинме? Әйләнә-тирә мохитне саклап, кеше үзен яклыймы?

Кешенең әйләнә-тирә мохиткә актив йогынтысы дөньяның күпчелек илләрендә, шул исәптән Россиядә дә хокукның яңа тармагы — әйләнә-тирә мохитне саклау хокукы барлыкка килүгә сәбәп булды. Россиядә ул «экологик хокук» дип атала. Йөзләрчә ел үскән сезгә мәгълүм тармаклардан (мәсәлән, җинаять җаваплылыгы хокукы) аермалы буларак, экологик хокук бик тиз, узган гасырның берничә дистә елында формалашты һәм бүген дә камилләшүен дәвам итә. Аның төп бурычы — әйләнә-тирә мохитне саклау проблемасын хәл итү.

ЭКОЛОГИК ХОКУКНЫҢ ГОМУМИ ХАРАКТЕРИСТИКАСЫ

Экологик хокукның билгеләмәсе белән сез таныштыгыз инде. Исегезгә төшерәбез: бу хокук җәмгыятьнең һәм әйләнә-тирә мохитнең үзара йогынтысы нәтиҗәсендә килеп чыга торган иҗтимагый мөнәсәбәтләрне җайга салучы хокукый нормалар җыелмасыннан гыйбарәт.

Иҗтимагый мөнәсәбәтләрнең бу өлкәсен (даирәсен) «экологик мөнәсәбәтләр» дип атау кабул ителгән.

Аңлашыла ки, әйләнә-тирә мохит объектларына караган, җәмгыятьтә барлыкка килүче теләсә нинди мөнәсәбәтләрне экологик хокукка кертеп булмый. Мәсәлән, җирне һәм суны алып карыйк. Алар экологик төшенчә сыйфатында гына хезмәт итмәскә дә мөмкин. Җир һәм су буйлап дәүләтләр яисә дәүләт субъектлары арасындагы чик узарга мөмкин. Җирнең һәм суның бу өлешенә карата дәүләтләр (яисә субъектлар) арасында мәгълүм бер мөнәсәбәтләр (кайчакта гаять киеренке) урнашырга мөмкин. Менә боларын «экологик мөнәсәбәтләр» дип булмый. Алар дәүләт хокукы нормалары белән җайга салынучы территориаль мөнәсәбәтләр.

Әлеге мисал белән без экологик мөнәсәбәтләрнең үз үзенчәлеге булуын басым ясап күрсәтергә телибез: бу әйләнә-тирә мохиттән файдалану, шулай ук әйләнә-тирә мохитне саклау (аннан файдалануның икенче ягы буларак) мөнәсәбәтләре.

Әйләнә-тирә мохит — экологик хокукның төп объекты. Әйләнә-тирә мохитне саклау турында Федераль закон (2002) аны табигать мохите, табигать һәм табигый-антропоген объектлар, шулай ук антропоген объектларның *компонентлары*

җыелмасы буларак билгели. Мондый җыелманы шартлыча түбәндәге схема рәвешендә күз алдына китереп була:

А — табигать объектлары
Б — табигый-антропоген объектлар
В — антропоген объектлар

Шулай итеп, табигать мохите (яисә табигать) табигатьнең үз объектларын да, табигый-антропоген объектларны да үз эченә ала. Барысы бергә җирдә яшәү шартларын тәэмин итүче җир, җир асты байлыклары, туфрак, су, атмосфера һавасы, үсемлекләр, хайваннар дөньясы һәм башка организмнар, шулай ук атмосфераның озон катламы һәм галәмнең җир тирәсендәге киңлеге табигать *мохитенең компонентларын* тәшкил итә. *Табигать объекты* законда табигый экологик система, үзенең табигый сыйфатларын саклаган табигать ландшафты һәм аны тәшкил итүче элементлар буларак аңлатыла. Табигый-антропоген объект (грекча *anthropos* — кеше + *genos* — туу) кеше тәэсире нәтиҗәсендә үзгәртелгән табигый объект яисә кеше тарафыннан булдырылган, әмма табигать сыйфатына ия булган объект (посадка-утыртмалар, бакча, урман полосалары һ.б.) буларак характерлана. *Антропоген объект* — кеше тарафыннан булдырылган һәм табигать объекты сыйфатларына ия булмаган (бина, юл, инженерлык челтәре һ.б.) объект ул.

Без законда беркетелгән әйләнә-тирә мохит компонентларын махсус рәвештә шулай җентекләп атыйбыз, чөнки монда экологик хокук объектлары турында уйлану өчен урын бар. Мисалга, әйтик, антропоген объектларны яисә җир тирәсендәге киңлекне алыйк. Экологик хокук нигә аларны экологик мөнәсәбәтләр даирәсенә кертә? (Уйлагыз, җавап эзләгез. Моның өчен барыннан да элек экологик мөнәсәбәтләрнең асылын искә төшерергә кирәк.)

Сезгә мәгълүм булганча, экологик хокук комплекслы структурага ия — табигый-ресурс һәм табигатьне саклау хокукы нормаларын берләштерә. Шуны ассызыклап әйтик: экологик хокукның структур компонентларын бер-берсеннән аерып карарга ярамый; файдалануны җайга салучы һәм саклауны

җайга салучы нормалар бер үк вакытта гамәлдә. Мәсәлән, җир бер үк вакытта файдаланыла да, саклана да.

Экологик хокук *чыганакларына* экологик мөнәсәбәтләрне җайга салучы нормалары булган барлык хокукый актларны кертәләр. Андый актлар күп. *Юридик көче буенча* (норматив-хокукый актның юридик көче ничек билгеләнгәнлеген исегезгә төшерегез) барлык экологик норматив актлар массивын (икенче төрле әйткәндә, экологик законнарны) *конституцияләргә, законнарга һәм законнан соңгы актларга* бүлеп карарга мөмкин. Федерация дәрәҗәсендә ул барыннан да элек РФ Конституциясе — экологик мөнәсәбәтләрне җайга салучы норматив актларның бөтен бер комплексы нигезе. Күп кенә федераль һәм гадәти РФ законнары арасында инде искә алынган «Әйләнә-тирә мохитне саклау турында» Федераль закон аерым урын алып тора. РФ субъектлары дәрәҗәсендә әйдәүче рольне шулай ук РФ субъектлары конституцияләре, ә аннан соң, РФ субъектлары законнары һәм башкарма хакимият норматив актлары уйный.

Экологик хокук нигезендә барыннан да элек «Әйләнә-тирә мохитне саклау турында» Законда беркетелгән мәгълүм *принциплар* ята (3 статья). Аларның иң мөһиме барлык экологик законнарның асылын чагылдыра: *кешенең уңайлы әйләнә-тирә мохиткә хокукын саклау.*

КЕШЕНЕҢ УҢАЙЛЫ ӘЙЛӘНӘ-ТИРӘ МОХИТКӘ ХОКУКЫ

Бу хокук гомумкешелек кыйммәтләренә, кеше һәм гражданның яшәеше нигезләренә кагылучы, аның матди һәм рухи тормышын саклау белән бәйле табигый хокукларга керә.

Экология мәсьәләләре буенча төп халыкара документларның берсе булып Рио-де-Жанейро шәһәрендә узган БМО Конференциясендә кабул ителгән «Әйләнә-тирә мохит һәм үсеш декларациясе» (1992) тора. 1 принцип сыйфатында бу Декларация болай игълан итте: «Тотрыклы үсеш тәэмин итү буенча тырышлыкта кеше турында кайгырту үзәктә тора. Алар табигать белән гармониядә сәламәт, нәтиҗәле яшәүгә хокуклы».

Безнең Конституция 42 статьяда гражданнарның экологик хокукын беркетте. Әлеге статья, асылда, өч мөстәкыйль, ләкин үзара аерылгысыз бәйләнгән кеше һәм граждан экологик хокукын үз эченә ала: 1) уңайлы әйләнә-тирә мохиткә; 2) аның торышы турында дөрес мәгълүматка һәм 3) экологик хокук бозулар белән сәламәтлеккә яисә мөлкәткә китерелгән зарарны каплауга хокук.

«Әйләнә-тирә мохитне саклау турында» Законда уңайлы әйләнә-тирә мохит «сыйфаты табигый экология системаларының, табигать һәм табигый-антропоген объектларының тотрыклы функцияләвен тәэмин итүче» мохит буларак билгеләнә. Шулай ук бу төшенчәнең фәнни билгеләмәсе дә бар. Әгәр мохитнең торышы экологик законнарда урнаштырылган, аның чисталыкка (пычранмаганлыгына), ресурс күләменә (бетмәслегенә), төрлелегенә һәм эстетик байлыгына кагылышлы нормативларга туры килә икән, ул уңайлы дип санала.

Объектив алганда, кеше яшәү өчен әйләнә-тирә мохиткә йогынты ясамыйча булдыра алмый — минераль ресурсларны чыгарырга, суны алырга, пычратучы матдәләрне каядыр ташларга һ.б. кирәк. Проблема шунда ки: мондый йогынтының фәнни нигезләнгән чикләре (нормалары) урнаштырылырга тиеш. Шул максатта экологик хокук хокукый документларда беркетелгән «экологик нормалау» дип аталган, ягъни мохиткә йогынты ясауның рөхсәт ителгән иң чик экологик критерийларын (нормативларын) урнаштыра.

Экологик нормалау таләпләрен беркеткән төп документ — «Әйләнә-тирә мохитне саклау турында» Закон. «Әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә нормалау» дигән V бүлектә экологик нормативлар системасы билгеләнгән, аларга түбәндәгеләр керә: әйләнә-тирә мохитнең сыйфат нормативлары, әйләнә-тирә мохитнең торышына иң *чик* рөхсәт ителгән зарарлы *йогынты ясау* (ЧЙЯ) нормативлары һәм табигать ресурсларын рөхсәт ителгән алу нормативлары.

Кыскача гына аңлатып үтик, сыйфат нормативлары — зарарлы матдәләрнең иң *чик рөхсәт ителгән концентрациясе* (ЧРК) һәм зарарлы физик йогынты ясауның иң чик рөхсәт ителгән дәрәҗәсе нормативлары ул (мәсәлән, атмосфера һавасында азот ике окисенең (NO_2) ЧРКсы 0,085 мг/м^3 тан артык булырга тиеш түгел, ә тоз кислотасы (HCl) — 0,2 мг/м^3 һ.б.).

ЧЙЯ нормативлары фактта әйләнә-тирә мохитнең сыйфат нормативларын үтәүне җайга салырга булыша, чөнки әйләнә-тирә мохиткә йогынты ясауның төрле чыганаклары өчен матдәләр һәм микроорганизмнар чыгарып ташлау һәм агызып чыгаруның иң чик рөхсәт ителгән нормативларын урнаштыра (23 статья).

Ә табигать ресурсларын (казылмалар, су, җир, урман, хайваннар дөньясы һ.б.) рөхсәт ителгән алу нормативлары аларның бетүен кисәтү максатында урнаштырыла. Мондый нормативлар яңадан торгызу мөмкинлекләрен исәпкә алып билгеләнә (26 статья).

Шуны билгеләп үтәргә кирәк: хокук белгечләре фикеренчә, барлык экологик норматив актлар да «Әйләнә-тирә мохитне

саклау турында» Закон таләпләренә туры китерелмәгән әле. Әйтик, «Җир асты байлыклары турында» Федераль законда җир асты ресурсларын рөхсәт ителгән алуны нормалаштыру турындагы таләп һаман юк әле. Галимнәр мондый хокукый бушлыкны ресурсларны чит илгә сату өчен чиксез чыгаруны тыюга дәүләт ихтыяры булмау белән бәйлиләр. Хәлнең болай торуы җәмгыять мәнфәгатенә туры киләме соң? Бигрәк тә киләчәк буыннар мәнфәгатьләренә? Илне, аның икътисадын мондый «ресурслау» үсеше кая алып бара? Экологик хокук килеп туган вазгыятькә ничек тәэсир итә ала? (Уйлагыз, үз дәлилләрегезне китерегез.)

Мәгълүматка хокук шулай ук шәхеснең төп хокукларының берсе булып тора һәм Кеше хокуклары гомуми декларациясендә игълан ителә. Инде билгеләп үтелгәнчә, РФ Конституциясе (42 статья) гражданның *әйләнә-тирә мохитнең торышы турында дөрес мәгълүматка хокукын* беркетә. Ул байтак федераль законнарда һәм барыннан да элек, «Әйләнә-тирә мохитне саклау турында» Законда күрсәтелә (11 статья).

Юридик төшенчә буларак *мәгълүмат* — аларны бирү рәвешенә бәйсез рәвештә, затлар, әйберләр, фактлар, вакыйгалар, күренешләр һәм процесслар турында белешмә ул. Әйләнә-тирә мохитнең торышы турында *дөрес* мәгълүмат булып әйләнә-тирә мохитнең *реаль*, бозылмаган торышын чагылдыручы белешмәләр тора. Беренче чиратта мондый мәгълүматка әйләнә-тирә мәгълүматны саклау һәм табигать ресурсларыннан файдалану өлкәсендә махсус вәкаләтләре булган дәүләт органнары ия.

Мәгълүматка хокук «Мәгълүмат, мәгълүматлаштыру һәм мәгълүматны яклау турында» Федераль законда (1995) конкретлаштырыла. Бу закон, беренчедән, мәгълүматтан файдаланучылар (алар оешма да, шулай ук граждан да булырга мөмкин) дәүләт мәгълүмат ресурсларына керүгә бертигез хокукка ия булуны урнаштыра (чикләнгән рөхсәтле мәгълүматтан гайре). Икенчедән, дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарына һәркем кирәкле мәгълүмати ресурслар булдыру һәм үз компетенциясе чикләрендә кулланучыларны мәгълүмати тәэмин итүне тормышка ашыру бурычы йөкләнә. Закон гадәттән тыш хәлләр турындагы мәгълүматка рөхсәтне чикләүне тыя, ул гражданнарның куркынычсызлыгын тәэмин итү өчен кирәк.

Илебез тарихын өйрәнүчеләр өчен сер түгел: безнең илдә күп еллар буена мәгълүмат тарату процессы дәүләтнең тоталь контролендә булды. Гражданнар тарафыннан дөрес мәгълүмат алу мөмкинлеге еш кына тулысынча юкка чыгарылды. Иң куркыныч мисалларга 1957 елда Чиләбе янында «Маяк» производство берләшмәсендә радиоактив матдәләр складындагы безнең тарихта иң зур һәлакәтне кертергә була. Халыкны үз

вакытында кисәтмиләр. Бүген радиациядән үлүчеләрне һәм зыян күрүчеләрне санап бетерү дә кыен. Алар меңәрләгән. Тарих 1986 елда Чернобыльдә кабатланды, монда хакимият АЭС реакторларының берсе шартлау турындагы мәгълүматны бер атна буе диярлек яшереп килде. Тоткарлык радиоактив нурларның корбаннары санының артуына китерде. Кеше хокукларын бозуның фаҗигале бәясе шундый.

РФ Конституциясе (41 статья, 3 пункт) урындагы затларның кеше тормышы һәм сәламәтлеге өчен куркыныч тудыручы фактлар һәм хәлләрне яшергән өчен җаваплылыгын билгеләде. Бу статьяның ничек эшләвен күзәтеп тору мөмкинлегебез бар.

ЭКОЛОГИК ХОКУКЛАРНЫ ЯКЛАУ ЫСУЛЛАРЫ. ЭКОЛОГИК ХОКУК БОЗУЛАР

«Әйләнә-тирә мохитне саклау турында» Закон гражданнарга *төрле ысуллар белән* үзләренең сәламәт әйләнә-тирә мохиткә хокукларын яклау мөмкинлеге бирә. Алар әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә эшчәнлек башкаручы *җәмәгать берләшмәләре* төзү хокукына ия; хакимият органнарына *шикаять, гариза* һәм *тәкъдимнәр* белән мөрәҗәгать итә, әйләнә-тирә мохитне саклау буенча җыелышларда, митингларда һ.б. катнаша ала. Ул гына түгел, гражданнар әйләнә-тирә мохиткә зыянны каплау турында судка дәгъва белән мөрәҗәгать итү хокукына ия.

Гражданнарның суд дәгъвасы хокукы — яклануның иң куәтле, универсаль чарасы. Шуның өстенә, әгәр дә граждан суд карарына канәгать булмаса, югарырак инстанция судына шикаять бирә ала. Россиядә хокукларын яклауның барлык законлы чараларын кулланып, аның гражданнары Кеше хокуклары буенча Европа *судына мөрәҗәгать итәргә хокуклы.*

Гражданнарның соңгы еллардагы активлыгы аркасында байтак кына мөһим прецедент булдырылды. Менә бер ачык мисал. 1998 елда РФ Югары Суды Россиянең күп кенә төбәкләре гражданнары һәм җәмәгать берләшмәләренең урман җирләрен беренче төркем (ягъни иң яхшы) урманнарында урман булмаган җирләргә күчерү турында РФ Хөкүмәтенең байтак күрсәтмәләрен дөрес түгел дип тану турындагы күмәк дәгъвасын карады һәм канәгатьләндерде. Шуны дә әйтеп үтәргә кирәк: экологик хокукны яклауның төп факторы булып аерым гражданнарның ихтыяры, тәвәккәллеге һәм кыюлыгы торды. Бу очракта алар җиңде. Әмма урманнар өчен көрәш һич тә тәгәлләнмәде әле (бу урында И.Ильф һәм Е.Петров романыннан «Батучыларга ярдәм эше — батучыларның үз кулындагы эш» дигән классик фраза искә төшә).

Экологик хокукны бозулар белән сәламәтлеккә яисә мөлкәткә *китерелгән зыянны каплатуга хокук* — уңайлы әйләнә-тирә мохиткә хокукны яклауның иң мөһим ысулларыннан. Зыянны каплауның мондый тәртибе барыннан да элек «Әйләнә-тирә мохитне саклау турында» Закон белән җайга салына. Бу документта кеше сәламәтлегенә һәм мөлкәтенә карата «зыян» төшенчәсе кулланыла. «Зыян» дип матди һәм матди булмаган уңайлыкны, шул исәптән гомерне һәм саулыкны теләсә нинди түбәнсетү (кысу, бозу) аңлашыла. Безнең законнарның төп принцибы дип гражданнар сәламәтлегенә һәм мөлкәтенә әйләнә-тирә мохитнең тискәре йогынтысы белән (шул исәптән хуҗалык һәм башка эшчәнлек нәтиҗәсендә дә) китерелгән зыянның тулы *күләмдә кайтарылырга тиешлеген* санарга мөмкин.

Күренеп тора, билгеле бер экологик бурычлардан башка экологик хокукларны тәэмин итәргә мөмкин түгел. РФ Конституциясе (58 статья) һәм экологик законнарның бөтен бер комплексы һәм гражданга **табигатьне саклауны, табигать байлыкларын сак тотуны йөкли**. Киң мәгънәдә караганда, әлеге бурычны *хокукый да, әхлакый* дип тә билгеләргә була. Цивилизацияле кеше өчен табигатьне кайгырту — гомуми культура чагылышы. Шул ук вакытта ул — хәзер яшәүче һәм киләчәк буыннар алдындагы әхлакый бурыч. Законнар белән билгеләнгән вазифаларны бозу *юридик җаваплылык* чаралары куллануга китерә.

Экологик хокук бозулар әйләнә-тирә мохитнең деградацияләнүендә төп сәбәпләрнең берсе булып тора. Безнең илдә мондый хокук бозулар саны шулкадәр күп (бөтен дөньядагы кебек үк), күпләр тарафыннан бу милли куркынычсызлыкка янау буларак бәяләнә. Прокуратура органнары аларны инде ел саен меңләп кенә түгел, йөзәр меңләп ачыклый. Шуңа да карамастан мохитнең сыйфаты начарлана бара. Шуны күрсәтү дә җитә: Россия халкының зур өлеше бүген стандартларга туры килмәүче су куллана. Диңгез суы законсыз төстә контейнерлар, авариядән соңгы яисә вакытын эшләп бетергән реакторлар ташлау, нефть продуктлары һ.б. түгү нәтиҗәсендә радиоактив матдәләр һәм калдыклар белән пычранган. Болар барысы да беренче чиратта *техноген хокук бозулар* нәтиҗәсе.

Гади гражданнар да калышмый. Әйтик, кеше гаебе белән килеп чыгучы урман янгыннары саны ел саен 40 меңгә җитә. Бер генә минутка булса да кешеләр чыгарган янгыннар утында меңәрләп һәләк булучы тере табигать, хайваннар, кошларниләр кичерүен күз алдына китерегез. Ау, хайваннар дөньясын саклау кагыйдәләрен бозу саны — дистәләгән мең, ә балык тоту кагыйдәләрен бозу йөзләгән меңнәр белән үлчәнә. Әле болар

прокуратура органнары ачыклаган очраклар гына. Белгечләр фикеренчә, чынында экологик хокук бозулар күпкә артык.

Нәрсә соң ул экологик хокук бозу? Хокук бозуның асылы, аның билгеләре сезгә инде мәгълүм. Экологик хокук бозу хокукка каршы тәртипнең бер төре, ягъни һәрвакыт экологик законнарны бозу булып тора. Аның төп билгесе менә шул инде.

Теләсә нинди экологик хокук бозу — гаепле гамәл (әйтик, урманны законсыз кисү, балыкны тыелганча тоту һ.б.) яисә *гамәл кылмау* ул (мәсәлән, җир асты байлыкларын саклау кагыйдәләрен үтәмәү һ.б.). Бу һичшиксез әйләнә-тирә мохиткә яисә кеше сәламәтлегенә зыян китерә һәм шуңа да иҗтимагый куркынычлы булып тора. Шулай итеп, **экологик хокук бозуны иҗтимагый куркыныч, зарарлы, әйләнә-тирә мохитне саклау турындагы закон нормаларын бозучы гаепле гамәл** дип билгеләргә мөмкин. Башка билгеләмәләр дә бар, ләкин монда мәгънә җитәрлек кадәр төгәл чагыла.

Экологик җаваплылык чараларын күздә тоткан законнар гаять күп. Кайбер норматив актларны гына атыйк. Барыннан да элек «Әйләнә-тирә мохитне саклау турында» Закон ул. 75 статьяда ул җаваплылыкның берничә төрен: мөлкәти (граждан-хокукый), дисциплинар, административ һәм җинаять җаваплылыгын урнаштыра.

Әйләнә-тирә мохитне саклау турындагы законнарны бозган өчен административ җаваплылык Административ хокук бозулар турында РФ Кодексы (КоАП РФ) белән каралган. Мәсәлән, 8 нче бүлектә, балык запасларын саклау кагыйдәләрен бозу гражданнарга хезмәт өчен түләүнең 10 нан алып 15 минималь күләменә кадәр күләмдә штраф салуга китерә, дип күрсәтелә (8.38 статья).

Дисциплинар җаваплылык чаралары РФ Хезмәт кодексында билгеләнгән (әйтик, 39 нчы бүлектә хезмәткәрнең эш бирүче мөлкәтенә китергән зыяны өчен матди җаваплылык карала). Җинаять җаваплылыгы чаралары РФ җинаять кодексында (РФ ҖК) билгеләнә. Монда 26 нчы бүлек тулысынча экологик җинаятьләргә багышланган; җинаять төрләре һәм җәза чаралары күрсәтелә. Мәсәлән, балыкны законсыз тоткан өчен (256 статья) билгеле бер очракларда штраф (хезмәт өчен түләүнең 200 дән алып 500 гә кадәр минималь күләме), йә төзәтү эшләре (2 елга кадәр вакытка), йә арест (4 тән алып 6 айга кадәр) карала. РФ Граждан кодексында юридик зат мөлкәтенә китерелгән зарарны каплау турындагы нигезләмәләр формалаштырылган (15 статья һәм 59 нчы бүлек). Шунда ук (59 нчы бүлек, 1074 статья) 14 яшьтән 18 яшькәчә балигъ булмаган яшүсмерләр китерелгән зыян өчен «гомуми нигезләрдә» җаваплы була, дип күрсәтелгән.

РФ ГКда билгеләнгән зыянны каплау турындагы гомуми нормалар «Әйләнә-тирә мохитне саклау турында» Законда конкретлаштырыла. Мәсәлән, 77 статьяда экологик хокук бозулар белән китерелгән зыянчы (пычрату, зәгыйфьләндерү, бозу, юк итү, табигать байлыкларын рациональ файдаланмау һ.б.) тулысынча кайтару принцибы беркетелгән.

Юридик җаваплылык төре (формасы) буенча экологик хокук бозулар, барлык хокук бозулар кебек үк, *гамәлләргә* һәм *җинаятьләргә* бүленә. Аерма, сез яхшы белгәнчә, әйләнә-тирә мохиткә һәм кеше сәламәтлегенә китерелгән зыян дәрәҗәсе белән билгеләнә.

Менә монда элеккеге җәмгыять белеме курсларында инде әйтелгән фикерне кабатлыйк: хокук бозуларның ике төре арасында бик нечкә, кайчакта тоеп та булмый торган чик уза. Экологик хокук бозулар да шундыйлардан. Әйтик, РФ КоАП нигезендә сирәк очрый торган һәм юкка чыгу куркынычы торган хайваннарны юк итү (8.35 статья) административ хокук бозулар, ягъни гамәлләр санына кертелә. Ә законсыз ау өчен, әгәр бу эш зур зыян китереп башкарылган икән, РФ ҖКның 258 статьясы нигезендә җинаять җаваплылыгы каралган. (Монда хокук бозу составының җитди аермасы кайда икәнлеге турында уйлап карагыз.)

Әлбәттә, әлеге чикне суд аша гаять төгәл билгеләү мөмкинлеге бар. Ләкин нигә эшне судка җиткерергә?

ГАМӘЛИ ЙОМГАКЛАР

1 Хәзерге заман кешесе чорның экологик императивларын (таләпләрен) күрмәмешкә салыша алмый. Дәүләтнең һәм җәмгыятьнең әйләнә-тирә мохитне саклау һәм торгызу буенча стратегик максаты — ул сезнең дә шәхси максат. Чөнки сез, һәр кеше кебек үк, тормыш сыйфатын яхшыртуга һәм сәламәтлекне саклауга мохтаҗ.

2 Сезнең шәһәрдә, районда һ.б. килеп туган экологик вазгыятьне танып белергә өйрәнү файдалы. Әйләнә-тирә мохиткә кайдан куркыныч янаганын һәм аның торышы турында дөрес мәгълүматны тоткарлыксыз алу мөмкинлеге булу-булмавын аңлау мөһим. Һәм, әлбәттә, хокукый нормаларны өйрәнергә кирәк, алар ярдәмендә дөрес мәгълүмат алырга, шулай ук бу куркынычка каршы торырга мөмкин.

3 Үзеңнең әйләнә-тирә мохиткә мөнәсәбәтеңне тәнкыйть күзлегеннән чыгып бәяләргә өйрәнергә кирәк. Үз тәртибеңне үз экологик вазифаларың күзлегеннән чыгып, намус

белән анализлау, әгәр кирәк булса, аңарда нәрсәнедер үзгәртү, нәрсәдәндер баш тарту кыюлыгы булдыру зарур. Беренче чиратта битарафлыктан, тупас кулланучылыктан котылу хәерле.

4 Әйләнә-тирә мохиткә безнең яклау нигә кирәклеген яхшы аңларга кирәк. Асылда, сүз сезнең сәламәт әйләнә-тирә мохиткә табигый хокукыгыз турында бара. Әмма бу хокукны якларга өйрәнергә кирәк. Нинди ысуллар белән? Эзләгез һәм табарсыз.

ДОКУМЕНТ

Россия Федерациясенең Экологик доктринасыннан *(2002 елда РФ Хөкүмәте тарафыннан хупланды).*

Экология өлкәсендә дәүләт сәясәтенең стратегик максаты булып табигать системаларын саклау, алар бөтенлегенә булышу һәм җәмгыятьнең тотрыклы үсеше, тормыш сыйфатын күтәрү, халык сәламәтлеген һәм демографик вазгыятьне яхшырту, илнең экологик иминлеген тәэмин итү өчен тормыш функцияләрен саклау тора. Ә моның өчен түбәндәгеләр зарур:

табигать системаларын, аларның биологик төрлелеген һәм, кешеләр җәмгыяте яшәешенең кирәкле шарты буларак, үз-үзен җайга салуга сәләтен саклау һәм торгызу;

табигатьтән рациональ файдалануны һәм табигать ресурсларына хәзер яшәүче һәм киләчәк буын кешеләренең бер үк хокукта ирешә алуын тәэмин итү;

халыкның тормыш сыйфатын һәм сәламәтлеген яхшырту өчен зарури шарт буларак, әйләнә-тирә мохитнең уңай торышын тәэмин итү.

Документка сораулар һәм биремнәр

1. Сез «доктрина» сүзен ничек аңлыйсыз? **2.** Экология өлкәсендә дәүләт сәясәтенең мәгънәсе нәрсәдә? **3.** «Илнең икътисади куркынычсызлыгы» формулировкасын аңлатыгыз. **4.** Дәүләтнең экологик максатына ирешү өчен нәрсә эшләргә кирәк? **5.** «Табигать ресурсларына хәзер яшәүче һәм киләчәк буын кешеләренең бер үк хокукта ирешә алулары» дигән фразаның мәгънәсе нидә? Сез ничек уйлыйсыз: нигә доктринаның бу позициясе дәүләтнең стратегик максатына ирешүдә төп шартка әверелде?

ҮЗ-ҮЗЕҢНЕ ТИКШЕРҮ ӨЧЕН СОРАУЛАР

1. Экологик мөнәсәбәтләрнең үзенчәлеге нидә? **2.** Әйләнә-тирә мохитнең состав өлешләре нинди? **3.** Нигә уңайлы әйләнә-тирә мохиткә хокук гомумкешелек кыйммәтләренә керә? **4.** Гражданнарның РФ Конституциясендә беркетелгән төп экологик хокукларын характерлагыз. **5.** Гражданнарның экологик хокукларын саклауның төп ысулларын атагыз. Нигә экологик хокукларны яклауның төрле алымнарын куллану мөһим? **6.** Экологик хокук бозулар өчен законнарда нинди җаваплылык төрләре каралган?

БИРЕМНӘР

1. Безнең илдә озак вакытлар: «Кеше — табигать патшасы», «Без табигатьтән мәрхәмәт көтеп ята алмыйбыз. Аңардан аны алу — безнең бурыч» дигән шигарьләр популяр булды. Бүген дә күпләр шуңа инана һәм үзләрен шулай тота.

Ә сезнең позиция нинди? Үз карашыгызны яклап дәлилләр китерегез. Бәлки, сез башка лозунглар тәкъдим итәрсез? Ниндиләрне? Аңлатыгыз.

2. Н.В.Гоголь әсәре герое Городничий, Петербургтан чиновник килгәнгә кадәр тиз арада шәһәрне төзекләндерергә ашкынып, иске койманы сүтеп атарга әмер бирә. Һәм кисәк кенә исенә төшерә: «Ах, Ходаем! Онытып та җибәргәнмен, ул койма янында кырык олаулык төрле чүп-чар түгелгән. Нинди халык инде бу: кая да булса ниндидер һәйкәл йә булмаса гап-гади койма куйсаң, шайтан белсен, каян әллә нинди әшәке ташып куялар! (Авыр сулый)».

Сездә «мондый гадәтләр һаман да яши» дигән хис юкмы? Үз фикерегезне дәлилләгез. Нигә гражданнарның мондый тәртибен «экологик хокук бозу» дип бәяләргә мөмкин?

3. Гражданин Крючков авыл хуҗалыгы берләшмәсеннән арендага җир ала. Актив хуҗалык итә. Җирдән төрлечә файдалана: бөртекле культуралар игә, куаклыкларны кисеп бакча ясый, буа казып үрдәкләр җибәрә. Рентаны вакытында түләп бара.

Крючков белән авыл хуҗалыгы берләшмәсе арасындагы мөнәсәбәтләр хокукның нинди тармаклары нигезендә җайга салына? Экологик мөнәсәбәтләр барлыкка килү турында сөйләргә нигез бармы? Дәлилләр китерегез.

4. Экологик культура бездә төрле рәвешләр ала. Мәсәлән, сыра һәм башка эчемлекләрне шешә «авызыннан» эчәргә яратучыларны ике категориягә бүләргә мөмкин. Берәүләре, савытны

бушатып, аны теләсә кайда ташлап калдыра. Аларны «саксызлар» дип атарга мөмкин. Икенчеләре савытны эчкән урыннарында тезеп калдыра. Аларны «кайгыртучан» дияргә була. Бу төркемнәрнең экологик культуралыгын сез ничек бәялисез? Нигә? Ә бәлки, кайсыдыр төркем тәртибендә хокук бозу билгеләрен күрәсездер? Дәлилләр китерегез.

ЗИРӘКЛӘР ФИКЕРЕ

«Әгәр дә кешеләр яңадан маймыл булырга теләсә, аларга агачлар җитмәячәк».

«Времечко» телевидение программасы афоризмы

§ 22. Гражданлык хокукы

Гражданлык хокукы мөнәсәбәтләренә кермичә генә яшәргә мөмкинме? Гражданлык хокукы мөнәсәбәтләрендә катнашучы булу нәрсәне аңлата? Хосусыйлаштырылган һәм хосусыйлаштырылмаган фатир арасында нинди аерма бар? Банкта кем исәп-хисап ача ала?

Гражданлык хокукы Россия хокук системасының иң катлаулы нормаларының берсе булып тора, һәм сез инде белгәнегезчә, ул шәхси хокук өлкәсенә карый. Безнең көндәлек тормышыбызның бик күп вазгыятьләре «гражданлык хокукы мөнәсәбәтләре» төшенчәсе белән бәйле; димәк, РФ Конституциясе һәм Гражданлык кодексы нормаларына нигезләнеп каралырга тиеш.

ГРАЖДАНЛЫК ХОКУКЫ МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ

Гражданлык хокукы мөнәсәбәтләре — гражданлык хокукы нормалары белән җайга салынган мөлкәти яисә шәхси мөлкәти булмаган мөнәсәбәтләр. Сез ниндидер кызыклы нәрсә уйлап чыгардыгыз, дустыгыз сездән музыкаль үзәк сатып алды, сезгә мирас калды йә хәзинә таптыгыз ди — барлык бу һәм бик күп башка конкрет тормыш хәлләре гражданлык хокукы мөнәсәбәтләре килеп чыгуга, аларның үзгәрүенә һәм туктатылуына нигез булырга мөмкин. Гражданлык хокукы мөнәсәбәтләрендә һәрвакыт хокук мөнәсәбәтләренең субъекты, объекты һәм эчтәлеге була. Аларга җентекләп тукталыйк.

Гражданлык хокукы мөнәсәбәтләрендә катнашучыларны **«гражданлык хокукы субъектлары»** дип атыйлар. Кат-

нашучыларның иң киң даирәсе — гражданнар, юридик затлар, дәүләт — субъект була ала.

Гражданнар (физик затлар), әгәр алар гражданлык хокукы сәләтенә һәм эшчәнлек сәләтенә ия булса, гражданлык хокукы мөнәсәбәтләре субъекты була. Сез инде белгәнчә, гражданлык хокукы сәләтенә барлык гражданнар ия, алар кешенең туган мизгелендә үк барлыкка килә һәм ул үлгәч туктала. Исегезгә төшерәбез: сүз законнарда күрсәтелгән хокукларга һәм бурычларга ия булу турында бара. Әйтик, безнең дәүләттә намусны яклау хокукына һәркем ия, ә сезнең намусны яклау хокукына фәкать сез генә ия. Шәхси милекчелек хокукына илнең барлык гражданнары ия, ә билгеле бер адрес буенча урнашкан өч бүлмәле фатир хуҗасы булу хокукына гражданин К. гына ия (әгәр фатирга милекчелек хокукы рәсмиләштерелгән булса).

Гражданлык хокукына сәләтлелек, исегездә булса — үз гамәлләрең белән граждан хокукларын тормышка ашырырга сәләтле булу. «Хокукка сәләтлелек» төшенчәсе үзе үк кешенең үз гамәлләрен аңлавын, аларга җитәкчелек итүен, аларны дөрес — шул исәптән хокукый күзлектән караганда да, бәяләвен күздә тота. Кеше кайчан чыннан да моңа әзер була? Әлбәттә, туган мизгелендә үк түгел инде. РФ Гражданлык кодексы (РФ ГК) хокукка сәләтлелекнең булуын һәм күләмен кешенең яшенә карап беркетә. Туганнан алып 6 яшенә кадәр бала тулысынча хокукка сәләтсез дип санала. Аннан соңгы яшь төркеме — 6 дан 14 яшькәчә — шулай ук тулаем алганда хокукка сәләтсез дип таныла, ләкин кайбер искәрмәләр белән: РФ ГКның 28 статьясы балаларга кайбер көнкүреш килешүләре төзергә, әти-әнисе биргән акча белән эш итәргә рөхсәт бирә (мәсәлән, кибеткә ашамлык алырга бару, үзенә уенчык сатып алу).

14 яшьтән 18 яшькәчә яшүсмерләр аерым категорияне тәшкил итә (моңа сез дә керәсез). Бу яшьтәге балигъ булмаганнарның хокукка сәләте РФ ГКның 26 статьясында карала. Сез укуыгызны дәвам итә яки эшкә урнаша аласыз һәм үзегезнең стипендия, хезмәт хакы һәм башка керемнәрегез белән мөстәкыйль эш итә аласыз, үзегезнең исемнән банкка керем кертергә мөмкин. Ә килешүләрне әти-әниегезнең язмача ризалыгы булса гына төзергә ярый. Сез балигъ булганчыга кадәр алар сезнең гамәлләрегез өчен җавап бирә: сез китергән зыянны (мәсәлән, кеше әйберен бозган яисә югалткан өчен) әти-әниегез белән бергә каплыйсыз. Шулай итеп, сез өлешчә хокук сәләтенә ия.

18 яшьтән граждан хокук сәләте Россия Федерациясенең барлык гражданнары өчен тулы күләмдә була. 16 яшьтән

18 яшькә кадәрге гражданнар, әгәр эшмәкәрлек белән шөгыльләнсәләр, хезмәт шартнамәсе буенча эшләсә яисә өйләнешсәләр, аерым тәртиптә тулы хокук сәләте алырга мөмкин.

Юридик затлар, ягъни коммерциячел һәм коммерциячел булмаган оешмалар, милекчелектә яки идарәләрендә аерылып торган мөлкәткә ия була һәм үз исемнәреннән гражданлык хокукы мөнәсәбәтләренә керергә мөмкин. Икмәк заводы, ювелир кибете, сезнең гомуми урта белем мәктәбе — алар барысы да юридик затлар. Гражданлык хокукларына ия булу һәм вазифалар үтәү сәләте юридик затны теркәү мизгеленнән барлыкка килә. Гражданлык кодексында юридик затларның төрле оештыру-хокукый рәвешләре каралган. Ләкин ул нинди рәвешле булса да, башка хокук мөнәсәбәтләре субъектлары белән аның тигез хокуклылыгы таныла, аның барлык гамәлләре исә гражданлык хокукы нормаларына туры килергә тиеш.

Россия Федерациясе, РФ субъектлары, муниципаль берәмлекләр гражданлык хокукы мөнәсәбәтләрендә катнашучы була ала. Алар аерым төркем тәшкил итә: бу — мәгълүм бер хакимият вәкаләтләренә ия оешмалар. Гражданлык хокукы мөнәсәбәтләрен җайга салучы Россия Федерациясе Граждан кодексы гражданлык хокукы мөнәсәбәтләрендә катнаша алучы дәүләтнең законнар иҗат итү эшчәнлеге нәтиҗәсе булып тора. Шул ук вакытта РФ Граждан кодексының 124 статьясы, дәүләт, аның субъектлары һәм муниципаль берәмлекләр «гражданлык законнары белән җайга салынучы мөнәсәбәтләрдә башка катнашучылар — гражданнар һәм юридик затлар белән **тигез башлангычларда** чыгыш ясый» дип күрсәтә.

Безне көндәлек тормышта чолгап алган бар нәрсә дә диярлек **гражданлык хокукы мөнәсәбәтләре объекты** була ала: әйбер, хезмәт күрсәтү, мәгълүмат, интеллектуаль эшчәнлек нәтиҗәләре, матди булмаган уңайлыклар (гомер, сәламәтлек, шәхес иреге, абруй, исем һ.б.).

Гражданлык хокукы мөнәсәбәтләренең эчтәлеге булып әлеге мөнәсәбәтләрдә турыдан-туры катнашучыларга кагылган хокуклар һәм бурычлар тора. Шул ук чакта хокуклар һәм бурычлар аерылгысыз бәйләнгән, бер үк вакытта барлыкка килә. Әйтик, сез велосипед сатып алдыгыз ди. Сез сатып алынган товарга хокукыгызны гамәлгә ашыра алсын өчен, сатучы ул товарны сезгә тапшырырга тиеш. Тагын бер мисал: кешенең сәламәтлегенә зыян китерелде ди. Зыян күрүченең зыян өчен компенсация алуга хокукы, ә зыян китерүченең компенсация түләү бурычы барлыкка килә.

Гражданлык хокукы мөнәсәбәтләре элементларын карауны тәгәлләп, сезнең игътибарга түбәндәге схеманы тәкъдим итәбез:



Хокук мөнәсәбәтләренең нидән гыйбарәт булуына бәйле рәвештә, гражданның билгеле бер мөлкәти һәм шәхси мөлкәти булмаган хокуклары барлыкка килә.

МӨЛКӘТИ ХОКУКЛАР

Иң гадәти хәл: дустыгыз мотоцикл сатып алды, димәк, мотоцикл аның милке булды. Шул мизгелдән дустыгыз үз мотоциклына *ия булу, аннан файдалану һәм аның белән эш итү* хокукы алды. Болар барысы да мөлкәти хокукларга керә. **Биләү хокукы** дустыгызга анык бер әйбернең хуҗасы булу хокукы бирә. **Файдалану хокукы** аңа бу машинада йөрү мөмкинлеге бирә. Мөлкәт белән **эш итү хокукы** мотоциклның алга таба язмышын хәл итәргә мөмкин: хуҗа аңардан үзе файдаланамы яисә башка кешегә йөрергә бирәме, бүләк итәме яки сатамы. Шулай итеп, мөлкәти хокуклар нинди дә булса *мөлкәткә ия булу сәбәбе буенча* яисә *аны бер заттан икенче затка тапшыру сәбәбеннән* килеп чыга.

Барыннан да ешрак гражданлык хокукы мөнәсәбәтләре объектына әйберләр әверелә. Дөрес, РФ Граждан кодексының 129 статьясы, барлык әйберләр дә гражданлык-хокукый алыш-биреш предметы була алмый, дип күрсәтә: әйтик, коралларның аерым төрләре, атом энергиясе гражданлык хокукы мөнәсәбәтләре объекты була алмый; көчле тәэсир итүче агулар әйләнеше дә чикләнгән. Безне чолгап алган әйберләр төрле-төрле, шуңа законнар әйберләрнең билгеле бер төркемнәрен күрсәтә, алар *бүленүче* һәм *бүленмәүче* була ала. Күз алдына китерегез: варислар йортны бүлешә, милекчеләрнең һәркайсына йортның билгеле бер өлеше беркетелергә мөмкин (йорт — бүленә торган әйбер). Ә автомобиль яисә магнитофонны ничек бүләсең? Алар бүленмәүче әйберләргә кертелгән. Моннан тыш әйберләр *күчемле* һәм *күчемсезгә* бүленә. Күчемсез мөлкәткә җир кишәрлекләре, торак йортлар, корылма, предприятеләр һ.б. керә. Күчемсез мөлкәт исемлегенә яхшы гына күчеп йөри торган әйберләр — һава һәм диңгез суднолары, космик кораблар һәм иярченнәр дә кертелгән. РФ Граждан кодексының 131 статьясы

нигезендә күчемсез мөлкәт белән алыш-бирешләрнең дәүләт теркәвенә алынуы очраклы түгел, сүз бик еш бәхәсләр кузгаткан, кайчакта алдашырга маташуга китергән әйберләр турында бара. Шул ук вакытта, мәсәлән, һава куыгы сатып алганда җитди документлар рәсмиләштерүне таләп итү көлке булыр иде, бу — күчемле әйбер, һәм сатып алынган товарга чек булу җитә.

Гражданлык мөлкәти хокук мөнәсәбәтләре булып акча һәм кыйммәтле кәгазьләр дә тора. Алар түләү чарасы сыйфатында йөри. Гражданлык хокукы мөнәсәбәтләре объекты, мөлкәт буларак, акчаның шактый үзенчәлеге бар. РФ Граждан кодексының 140 статьясы Россиядә законлы түләү чарасы «рубль» булуын күрсәтә. Чит ил валютасы әйләнеше махсус норматив-хокукый актлар белән килешенә. *Кыйммәтле кәгазь* (акция, облигация, вексель һ.б.) мөлкәти хокукларны раслаучы документ булып тора (РФ ГКның 142 статьясы). Мәсәлән, акция, инде сез белгәнчә, аның иясенең акционер җәмгыяте табышы бер өлешен дивидендлар рәвешендә алуга һәм акционер җәмгыятенә идарә итүгә хокукын беркетә. Әгәр дә предприятие зыянга эшләсә яисә акционер бу җәмгыять эшчәнлегендә катнашудан баш тартырга булса, ул акционер җәмгыятеннән акция бәясен кире кайтаруны таләп итә алмый. Аның каравы акционер акцияне башка затка сата яки акция бәясенә тиң компенсация алырга (шул исәптән — предприятие бетерелгән очракта да) мөмкин.

Шуңа игътибар юнәлтәбез: милекче мөлкәткә ия булырга, аннан файдаланырга һәм аның белән эш итәргә хокуклы гына түгел, ул шулай ук аны *тиешле хәлдә тотарга* да бурычлы. Өске каттагы күршегез фатирындагы ватык су краны кебек вак-төяк тә бик күп мәшәкать китереп чыгарырга мөмкин. Ягъни мөлкәт иясе булу хокукы йөкләгән җаваплылык турында да онытмаска кирәк. Безнең законнар башка гражданның милек хокукын бозарга мөмкин гамәлләр кылуны тыя. Мәсәлән, бик бирелеп футбол уйнаганда очраклы ваткан тәрәзә бәясен үзеңә яисә ата-анаң белән бергәләшеп (бу хокукый сәләткә бәйле) капларга туры килә.

ШӘХСИ МӨЛКӘТИ БУЛМАГАН ХОКУКЛАР

Шәхси мөлкәти булмаган хокуклар — гражданлык хокукларының гражданга тумыштан бирелгән, аңардан аерылгысыз аерым категориясе. Бу хокуклар мөлкәткә ия булу һәм аның белән эш итүгә бәйләнмәгән. Әйдәгез аларның кайберләрен карап үтик.

Һәр кешенең **яшәргә хокукы** бар. Әле генә туган нәни бала да шул хокукка ия. Яшәү хокукы үзе ике яклы. Безнең

һәркайсыбыз гомерне саклау белән бәйле мәсьәләләрне мөстәкыйль хәл итәргә хокуклы. Сүз принципта гомерне саклап калу турында гына бармый, ә аның нинди буласы турында да (мәсәлән, сүз җенесне үзгәртү турында барса) әйтелә. Яшәүгә хокукның икенче ягы булып гомер белән эш итү хокукы тора. «Кайнар нокталарда» ирекле төстә сугышырга барган кеше бик катлаулы карар кабул итә. Гомерен озайтырга мөмкин булган медицина катышуыннан баш тартучы авыру кеше дә шундый ук катлаулы мәсьәләне хәл итә.

Исемгә хокук безнең һәркайсыбызга үз исеменә ия булырга, аннан файдаланырга һәм аның белән эш итәргә мөмкинлек бирә. «Кешенең исеме» дигәндә аның үз исеме, әтисенең исеме һәм фамилиясе аңлашыла. Кайбер юристлар, имза да исемнең бер өлеше булсын, диләр. Кешенең исеме башта туу турында таныклыкка, соңрак паспортка язып куела. Билгеле бер вазгыятьләрдә кеше үз исемен яшерергә, псевдоним кулланырга һәм хәтта үз исемен үзгәртергә дә хокуклы. Ләкин исемне үзгәртү җәмгыятьтә яңа граждан барлыкка килде дигән сүз түгел. Аның исеме генә үзгәрде, ә кеше ия булган барлык хокук һәм бурычлары сакланып кала.

«Намусыңны яшьтән сакла»,— дип өйрәтә безне мәкаль. **Намус һәм абруйга хокукны** безгә Конституция һәм Граждандлык кодексы гарантияли. Бу хокук, бер яктан, үзең турындагы күзаллаудан файдаланырга мөмкинлек бирә: тирәндәге кешеләр синең намуслы, игелекле булуыңны, һөнәри оста икәнлегеңне белсәләр һәм хөрмәт итсәләр, бу рәхәт кенә түгел, ә чыннан да мөһим. Икенче яктан, безнең барлыкка килгән күзаллауны яклау хокукыбыз бар. Сез суд аша сезнең турыдагы игълан ителгән белешмәләрне (әгәр алар: а) сезне мыскылласа, б) дөреслеккә туры килмәсә, в) таратылса) юкка чыгаруны таләп итәргә хакыгыз бар. Әгәр бу белешмәләр массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарылса, аларны кире кагу да шул ук чараларда булырга тиеш. Мыскыллаучы белешмәләрне юкка чыгару белән бергә граждан зыянны каплауны һәм әхлакый зарарны компенсацияләүне таләп итәргә хокуклы.

Безнең һәркайсыбыз ия булган хокуклар арасында — индивидуаль кыяфәткә хокук, сәламәтлеккә хокук, шәхси тормыш серенә һәм аның кагылгысызлыгына хокук, башка хокуклар да бар. Әмма аларның асылы үзгәрми — алар гражданнарның шәхси мөлкәти булмаган хокукларын тәшкил итә.

ИНТЕЛЛЕКТУАЛЬ МИЛЕККӘ ХОКУК

РФ Граждан кодексының 128 статьясы, аларга карата гражданлык хокукы мөнәсәбәтләре барлыкка килүче граж-

данлык хокуклары объектлары арасында «интеллектуаль эшчәнлек нәтиҗәләрен, шул исәптән аларга гына хас булган хокукларны» атый. Сүз «интеллектуаль милек» дип аталган байлык турында бара. «Интеллектуаль» дигән сүз үзе үк шундый милеккә акыл, рухи эшчәнлекнең төрле нәтиҗәләре кергәнлеген әйтеп тора. Бу әдәби әсәр дә, автор башкаруындагы җыр да, фәнни ачыш та һ.б. булырга мөмкин. Сез диңгезләрдә йөзеп, башка кораблардагы алтыннарны талаган пиратларны беләсез инде; ә безнең чорда пиратлар бөтенләй башка төрле, һәм алар үзгә хәзинәләрне — ят фикерләрне, ят фильмнарны, ят язмаларны... тупларга тырыша.

Интеллектуаль милеккә хокук — интеллектуаль, беренче чиратта иҗади эшчәнлек нәтиҗәләренә шәхси мөлкәти булмаган һәм мөлкәти характердагы, фәкать авторныкы гына булган хокук. Шуңа игътибар бирегез: интеллектуаль милеккә хокук үзенә мөлкәти дә, мөлкәти булмаган хокукларны да кертә. Аларның кайберләренә тукталыйк.

Авторлык хокукы фән, әдәбият, сәнгать һ.б. Әсәрләре булдыру һәм алардан файдалану белән бәйле килеп чыгучы мөнәсәбәтләрне җайга сала. Шундый әсәр булдырган һәркем автор дип танылырга, әсәрне халыкка җиткерергә (мәсәлән, бастырып чыгару юлы белән) хокуклы. Китап киштәләрендә без үзебезгә ошаган автор китабын, музыкаль дисклар арасында яраткан төркем язмасын сайлап алабыз. Автор үз әсәрләрен бастырган яисә халык алдында башкарган өчен түләү алырга хокуклы. Китап та, яраткан җыр да интеллектуаль эшчәнлек нәтиҗәсе булып тора; димәк, бу әсәр авторларына хокукый танылу һәм аларның авторлык хокукын саклау тәэмин ителә.

Патент хокукы уйлап табулар, файдалы модельләр һәм сәнгать үрнәкләре булдыру һәм алардан файдалану белән бәйле рәвештә килеп чыгучы мөлкәти һәм алар белән бәйле шәхси мөлкәти булмаган мөнәсәбәтләрне җайга сала. Бу — уйлап табу эшчәнлеге нәтиҗәсе, шундый интеллектуаль милекне саклау махсус документ — патент алу аша тормышка ашырыла.

Әгәр сезгә мөһим ачыш ясарга яисә бик яхшы рәссам булырга насыйп икән, белеп торыгыз: сезнең талант халык тануын алып кына калмый, гражданлык хокукы нормалары аша үз хокукый раславын да табачак.

МИРАС АЛУ

Кешенең үлеме белән бергә аның барлык хокуклары да бетми әле. Алар мирас итеп калдырылырга мөмкин. Бу хокук алу юлларының берсе. **Мирас алу —** үлгән затның хокуклары

һәм бурычлары хокук нормалары нигезендә аның варисларына күчү ул.

Сүз күбесенчә мөлкәти хокукларны мирас итеп алу турында бара, бу аңлашыла да. Әмма шәхси мөлкәти булмаган хокукларны да тапшырырга була икән. Әйтик, күренекле язучының үлеменнән соң варислары аның архивында бастырырга әзерләнгән кулъязма таптылар һәм нәшриятка тапшырдылар ди. Алар нинди хокукларны тормышка ашыра? Мөлкәти генә түгел: башка хокуклар арасында алар әсәрне бастыру хокукын да тормышка ашыра, ә бу хокук мөлкәти булмаганнар санына керә.

Мирас калдыручы — һәрвакыт берәү генә, ә варислар берничә булырга мөмкин. Алар гражданда, оешма (юридик зат) да, дәүләт тә була ала. Варислар мирас калдыручының үлү көненнән 6 ай дәвамында мирасны алырга яисә аңардан баш тартырга тиеш.

Гражданлык хокукында мирас алуның ике төре бар: **закон буенча** һәм **васыять буенча**.

Закон буенча мирас алу ул юкка чыгарылмаган һәм васыятьнамә белән үзгәртелмәгән очракта хәрәкәт итә. Гамәлдәге законнарда закон буенча берничә чират варислар билгеләнгән. Үзеннән-үзе аңлашыла, беренче чират варисларына балалар (шул исәптән уллыкка-кызлыкка алынган), ире яки хатыны һәм ата-анасы (шул исәптән уллыкка-кызлыкка алучы) керә. Мирас калдыручының баласы хәтта ул үлгәннән соң туса да, шулай ук беренче чират варис була. Әгәр үлүченең мондый якын кешеләре булмаса, мирас алуга икенче чират варислар (мирас калдыручының бертуган ир һәм кыз туганнары, аның бабасы һәм әбисе) һәм аннан соңгы чираттагы варислар чакырыла. Мираска бер үк чиратның берничә варисы дәгъва белдергән очракта, махсус шартлар булмаса, алар мирасны тигез өлешләрдә бүлеп ала. Бәхәс килеп чыкканда, аларга суд органнары ярдәм итә.

Васыять (гражданның үлем очрагында) анык булган мөлкәт йә матди һәм матди булмаган башка мал белән эш йөртү акты булып тора. Уртак кагыйдә буенча, васыятьнамә мирас калдыручы тарафыннан имзаланырга һәм нотариус тарафыннан таныкланырга тиеш. Әмма васыять һәрвакытта да гамәлдә булмый. Мираста мәҗбүри өлешкә хокук та бар. Бу хокук буенча балигъ булмаган яисә хезмәткә сәләтсез беренче чират варислары (кем турында сүз барганын исегезгә төшерегез) үлүченең ихтыярына карамастан, аларга закон буенча мирас калганда тиешле булган өлешнең 2/3 сен мирас итеп алалар.

ГРАЖДАНЛЫК ХОКУКЛАРЫН ЯКЛАУ

Гражданлык хокукы хокукларның үзләрен урнаштырып кына калмый, аларны яклау алымнарын да билгели. *Гражданлык хокукларын яклау ысуллары* — субъектның бозылган гражданлык хокукларын торгызуга яисә бу хокукны тәэмин итүгә юнәлтелгән, законда каралган чаралар ул. Гражданлык хокукларын яклау ысулларының гомуми исемлеге РФ Граждан кодексының 12 статьясында бирелгән. Гражданлык хокукы мөнәсәбәтләре субъекты яклауның бер яки берничә ысулын кулланырга хокуклы. Аларның кайберләрен карап үтик.

Үз хокукларыңны хокукны *тану аша* якларга мөмкин. Күз алдына китерегез: машина хуҗасының аңа тиешле документлары юк (бәлки, алар югалгандыр). Машина хуҗасы аны сату, бүләк итү түгел, аңарда үзе дә йөри алмый. Кирәкле документларны рәсмиләштерү, ягъни милеккә хокукны таныту, килеп чыккан билгесезлекне бетерергә мөмкинлек бирә.

Хокукларны яклауның тагын бер алымы — *хокук бозуга кадәрге хәлне торгызу*. Бу милекчегә аның мөлкәтен законсыз чит биләүдән кайтарып бирү вазгыяте булырга мөмкин. Мәсәлән, торак бинаны үз белдекләре белән биләүче затларны куып чыгару яисә кышын берәүләрнең сезнең дачага урнашырга маташуы белән булган хәл.

Гражданлык хокукларын яклауның иң киң таралган ысулларының берсе — *зыянны каплату һәм түләүне эзләтеп алу*. Зарар күрүченең мәнфәгате зыянны акчалата компенсацияләү белән канәгатьләндерелә. Хокукны бозган өчен компенсация сыйфатында күпме таләп итәргә була? Шундый хәлне күз алдына китерик: сезгә кыйммәтле магнитофоныгызны ватып китерделәр. Компенсациянең күләме магнитофон бәясеннән 10 тапкырга күбрәк була алмас инде. Гадәттә ул китерелгән зыян күләмен (әйтик, төзекләндерү бәясен) исәпкә алып билгеләнә.

Билгеле бер мөлкәт белән бәйләнмәгән зарарны бәяләү катлаулырак. Сүз шәхси мөлкәти булмаган хокукларны бозу, ягъни *мораль зыян* турында бара. Мораль зыянны компенсацияләү, РФ Граждан кодексының 151 статьясында күрсәтелгәнчә, «судның хокук бозучыга күрсәтелгән зыянны акчалата компенсацияләүне йөкләргә мөмкинлегеннән» гыйбарәт. Бу вакытта суд зыян күрүче кичергән физик яисә әхлакый газаплану дәрәҗәсен һәм закон бозучының гаепле булу дәрәҗәсен исәпкә ала.

Гражданлык хокукы мөнәсәбәтләренең теләсә нинди субъекты үз гражданлык хокукларын *мөстәкыйль рәвештә*

дә, *тиешле дәүләт органнарына мөрәҗәгать итү аша* да яклый ала.

Сатып алучы, әгәр товарның ассортименты шартнамәгә туры килмәсә яисә сыйфатсыз товар тәкъдим ителсә, аны кабул итүдән һәм түләүдән баш тартырга хокуклы. Сезгә, мөгаен, тыштан матур, ләкин эшләми торган аудиоплеер ошамастыр. Гражданлык хокукы мөнәсәбәтләре субъекты буларак тимер юл, әгәр йөкне ташу өчен түләнмәсә, аны алучыга йөкне бирмәскә хокуклы. Болар барысы да — гражданнарның һәм оешмаларның, гражданлык хокукы мөнәсәбәтләрендә катнашучылар буларак, мөстәкыйль, дәүләт органнарына мөрәҗәгать итмичә эш итүе мисаллары.

Ә хәзер уртак милек хокукында фатир яисә йортка ия туганнарның үз өлешләре турында килешә алмаулары вазгыятен күз алдына китерик. Аларга үз хокукларын яклауны сорап компетентлы дәүләт органнарына, бу очракта судка мөрәҗәгать итү яхшырак; соңгысы эшнең барлык шартларын карап чыгарга һәм карар кабул итәргә тиеш.

Шулай итеп, үз хокукларыңны, шул исәптән гражданлык хокукларын да яклау мөмкинлеге һәм сәләте күп кенә хәлләргә бәйле: бер яктан — бу тулаем законнарның һәм суд системасының камиллеге, икенче яктан — үз хокукларыңны һәм бурычларыңны белү, ягъни һәркемнең хокукый грамоталылыгы. Хәзерге вакытта сезнең һәркайсыгыз билгеле бер гражданлык хокукларына ия, аларны бозарга берәүнең дә хакы юк. (Үзегезнең шәхсән нинди граждан хокукларына ия булуыгызны анализлап карагыз.)

ГАМӘЛИ ЙОМГАКЛАР

1 Үз гомерегездә сез даими төстә гражданлык мөнәсәбәтләрендә катнашучы булганлыктан, үз гамәлләрегезне гражданлык хокукы позициясеннән күрергә өйрәнүегез һәм аларны белеп бәяләвегез бик мөһим.

2 Барлык гражданлык хокукы мөнәсәбәтләре тигез хокуклылыкка нигезләнгән. Димәк, сез хокук мөнәсәбәтләренең башка катнашучылары белән (гражданмы ул, предприяте яки дәүләтме) тигез хокукларга ия.

3 Сезнеке кебек үк мөлкәти һәм шәхси мөлкәти булмаган хокукларга башкалар да ия. Башка бер граждан хокукларына кул сузу гражданлык хокукы җаваплылыгына китерә.

4 Үз хокукларыңны яклый белү (ә бу үзе бер фән!) бик мөһим, ә моны тавышлануга һәм үзара мыскыллауларга кадәр тәгәрәмичә, тыныч кына һәм лаеклы итеп башкарырга кирәк.

ДОКУМЕНТ

Васыять тексты. *Россия хокук белгече* ***Э.А.Абашинның*** «Васыять һәм бүләк итү шартнамәсе» дигән китабыннан.

Васыять

Мәскәү шәһәре **Вакыты**

Мин, Мәскәү шәһәренең Яшь ленинчылар урамы, 64 нче йортның 1 нче корпусы, 109 фатирында торучы Бычков Евгений Харлампиевич, әлеге васыятьнамә белән түбәндәге күрсәтмәләремне бирәм:

1. Шәхси милек хокукында минеке булган, Мәскәү өлкәсенең Мытище районындагы Хлебниково бистәсендә урнашкан 16 нчы йортны, барлык хуҗалык корылмалары белән, шулай ук шәхси милек хокукында минеке булган 1 600 кв.м. мәйдан биләгән җир кишәрлеген мин кызым Пятакова Нина Евгеньевнага һәм улым Бычков Евгений Евгеньевичка васыять итәм.

2. Шәхси милек хокукында минеке булган, 1992 елда чыгарылган, дәүләт номеры Р086НА, Кузьминка ЮХИДИ да исәптә торган «ОПЕЛЬ-Гольф» маркалы җиңел автомобильне улым Бычков Сергей Евгеньевичка васыять итәм.

3. Мин үлгән көнгә минеке булган барлык башка мөлкәтне, ул нидән гыйбарәт булса да, кайда гына урнашса да, хатыным Бычкова Ольга Юрьевнага васыять итәм...

Әлеге васыятьнамә бер үк көчкә ия ике нөсхәдә төзелде һәм имзаланды, аларның берсе 27 нче Мәскәү Дәүләт нотариаль конторасы эшләрендә саклана, ә икенчесе васыять итүче Бычков Евгений Харлампиевич кулына бирелде.

Имза ____________ **/Е.Х.Бычков/**

Документка сораулар һәм биремнәр

1. Китерелгән документны характерлагыз. **2.** Монда кем мирас калдыручы, ә кем — варис? **3.** Васыятьнамә кайчан үз көченә керә? **4.** Әгәр Е.Х. Бычков васыять калдырмаган булса, аның варислары кемнәр булыр иде? **5.** Күз алдына китерегез: васыять ителмәгән йортны мираска алучы варислар аны ничек бүлешү турында килешә алмады ди. Аларга нишләргә?

ҮЗ-ҮЗЕҢНЕ ТИКШЕРҮ ӨЧЕН СОРАУЛАР

1. Гражданлык хокукы мөнәсәбәтләренең билгеләмәсен бирегез. Аның эчтәлеге астында нәрсә аңлашыла? **2.** Гражданлык хокукы мөнәсәбәтләренә нинди үзенчәлекләр хас? **3.** Гражданлык хокукы мөнәсәбәтләренә үз мисалыгызны китерегез, аның субъектын (субъектларын), объектын, барлыкка килү нигезен һәм эчтәлеген аерып күрсәтегез. **4.** Гражданлык хокукы сәләтенең һәм гражданлык хокукы гамәле сәләтенең нәрсә икәнлеген аңлатыгыз. Үзегезне гражданлык хокукы мөнәсәбәтләре субъекты буларак характерлагыз. **5.** Мөлкәти хокук объекты нәрсә була ала? **6.** Сез нинди шәхси мөлкәти булмаган хокукларны беләсез? **7.** Интеллектуаль милеккә хокукның башка гражданлык хокуклары арасындагы үзенчәлеге нидә? **8.** Нәрсә ул мирас алу? Мирас калдыруның нинди төрләре бар? **9.** Гражданлык хокукларын яклауның ысуллары нинди?

БИРЕМНӘР

1. Түбәндә санап үтелгәннәрнең кайсы гражданлык хокукы мөнәсәбәтләре объекты була алуын нигезләгез: а) автомобильгә уйлап табылган яңа двигатель төре, б) автомобиль милекчесе заказы буенча документлар төзү, в) автомобиль турында шигырь, г) урланган автомобиль, д) автомобильне төзекләндерү.

2. Кочкин кибеттән концерт рояле сатып алды. Икенче көнне кибеткә Кочкинның хатыны килде һәм, «ире — авыру» дигән сылтау белән рояльне кире алуларын һәм акчаны кире бирүләрен сорады. Бу очракта кемнәр гражданлык хокукы мөнәсәбәтләре субъектлары булып тора? Аның эчтәлеге нидә? Бу вакыйга ничек тәгәлләнергә тиеш?

3. Бернард Шоу берзаман болай яза: «Әгәр сезнең дә алмагыз булса, минем дә алмам булса, һәм без аларны алмашсак, сездә дә, миндә дә берәр алма кала. Әгәр сездә идея булса һәм минем дә идеям булса, һәм без бу идеяләрне уртаклашсак, һәркайсыбызда икешәр идея була». Бу вазгыятькә гражданлык хокукы позициясеннән карасак, нинди хокуклар турында сүз бара?

ЗИРӘКЛӘР ФИКЕРЕ

«Матди байлыкларны җүләрләрчә куллану еш кына иң югары уңайсызлыкларга иң туры юл була».

Д.Дефо (1660 еллар тирәсе – 1731), инглиз язучысы

§ 23. Гаилә хокукы

Ирнең һәм хатынның хокуклары һәм бурычлары тигезме? Мәктәп укучысы «кесә акчалары» белән мөстәкыйль эш итәргә хокуклымы? Ата-анасы тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар турында кем кайгыртырга тиеш?

Сез инде «хокук тармагы» төшенчәсе һәм аерым тармаклар белән таныш. Бу параграфта сүз хокукның тагын бер тармагы — гаилә хокукы турында барачак.

Гаилә хокукын кешеләр арасында никах фактыннан, кан кардәшлегеннән, уллыкка-кызлыкка алудан, балаларны гаиләгә тәрбиягә алудан килеп чыгучы шәхси һәм аннан чыгучы мөлкәти мөнәсәбәтләрне җайга салучы хокукый нормалар бергәлеге буларак карарга кирәк.

Гаилә хокукының төп чыганагы — РФ Гаилә кодексы. Ул гаилә хокукларын саклауны гарантияли, гаилә эшләренә кемнең дә булса тыкшынуын тыя, гаилә вазифаларын үтәүнең хокукый механизмнарын беркетә.

РФ Конституциясе һәм Гаилә кодексы нигезендә гаилә законнары Россия Федерациясе һәм аның субъектларының уртак карамагында тора, соңгылары Россия Федерациясе субъектлары карамагына кертелгән сорауларны мөстәкыйль хәл итү мөмкинлегенә ия.

ГАИЛӘ ӘГЪЗАЛАРЫНЫҢ ХОКУКЫЙ БАГЛАНЫШЛАРЫ

Гаилә хокукы турында сөйләшүне берничә күренештән башлыйк. Ата-ана һәр иртәдә беренче сыйныфта укучы балаларын мәктәпкә илтә, ә дәресләрдән соң алып кайта. Әбиләре җәен оныклары белән дачага китә. Улы пенсионер әниләренә яңа мебель сатып ала. Мондый һәм шуңа охшашлы хәлләрне тәрбияле һәм гуманлы кешеләрнең нормаль гаилә мөнәсәбәтләре буларак кабул итәргә мөмкин. Әмма безнең бурыч аларда аерым хокукый мөнәсәбәтләр — гаилә хокук мөнәсәбәтләре күрү.

Гаиләне социаль институт буларак өйрәнеп һәм хәзерге чорда гаилә үсеше тенденцияләре белән танышып, сез фактта яшәп килүче, ләкин формаль теркәлмәгән гаилә берлекләре мәсьәләсенә юлыктыгыз. Хокукый (юридик) мәгънәдә мондый берлекне «гаилә» сүзе белән, ә шундый берлектә яшәүче ир һәм хатынны — өйләнешкәннәр дип атап булмый.

Никах мөнәсәбәтләре дәүләт органнарында закон нигезендә рәсмиләштерелмәгән килеш озак вакыт бергә яшәүне *«фактагы никах»* дип атыйлар. Кайбер гаилә парлары дини никахта

яшиләр. Ләкин факттагы никах та, дини никах та ир белән хатын арасында *хокукый мөнәсәбәтләр китереп чыгармый.*

Гаиләнең барлык әгъзалары төрле хокукый мөнәсәбәтләрен гражданлык хәле актларын язу органнарында (ЗАГС) закон нигезендә теркәлгән никах кына, ягъни *гражданнн никахы* барлыкка китерә. (Шуны билгеләп үтик: ЗАГС органнарында шулай ук бала туу, фамилия, исем һәм атасының исеме үзгәрү, шулай ук кешенең вафат булуы теркәлә.)

Юридик күзлектән караганда, *гаилә*, кагыйдә буларак, үзара никахтан (ир белән хатын), кан кардәшлегеннән (ата-ана һәм балалар, ир һәм кыз туганнар, башка якын туганнар), уллыкка-кызлыкка алудан яисә балаларны гаиләгә башкача урнаштырудан килеп чыгучы хокуклар һәм бурычлар белән бәйләнгән затларның бергә яшәүче *берләшмәсен* тәшкил итә.

Гаилә әгъзалары — никахтагы ир һәм хатын, ата-ана һәм балалар, уллыкка-кызлыкка алынганнар һәм алынучылар, үги ана һәм үги аталар, үги кызлар һәм үги малайлар һ.б. — *гаилә хокук мөнәсәбәтләре субъектлары* булып тора.

Гаилә әгъзаларының хокукый мөнәсәбәтләр китереп чыгаручы гамәлләре (мәсәлән, никахка керү, ир белән хатынның аерылышуы), шулай ук аларның әйберләре (әйтик, дача, хосусыйлаштырылган фатир) *гаилә хокук мөнәсәбәтләренең объектлары* булып тора.

Гаилә тормышындагы аерым бер гамәлләр һәм вакыйгалар (юридик әһәмиятле хәлләр) бәйле рәвештә яңа хокукый мөнәсәбәтләр барлыкка килергә мөмкин. Аерым алганда, мондый вазгыятькә картайган ата-ананың матди мохтаҗлыгы килеп чыгу, ир белән хатынның берсенең үлеме, уллыкка (кызлыкка) алуны кертергә мөмкин. (Бу вакыйгаларның һәркайсы нәтиҗәсендә гаилә әгъзалары арасында нинди анык мөнәсәбәтләр килеп чыгарга мөмкин булуын фаразлагыз.)

Гаилә әгъзаларының гамәлләре *хокуклы* һәм *хокуксыз* булырга мөмкин. (Нинди гамәлләрнең хокуклы, ә кайсыларының хокуксыз булуын искә төшерегез.) Мәсәлән, тиешле шартларны үтәп никахка керү яисә закон нигезендә баланы мәктәпкә кертү — хокуклы гамәлләр, ә үсеп җиткән балаларның хезмәткә яраксыз ата-аналарын караудан баш тартуы яки баланы карауга алимент түләүдән тайпылу — хокуксыз гамәл.

НИКАХКА КЕРҮ ҺӘМ АЕРЫЛЫШУ

Никах гаилә хокукы төп төшенчәләренең берсе булып тора. Ул ир белән хатынның ихтыяри, тигез хокуклы, гаилә коруга юнәлгән, алар өчен *шәхси мөлкәти һәм мөлкәти булмаган* хокуклар *һәм бурычлар* тудыручы берлеге булып тора.

Билгеле булганча, никах закон белән билгеләнгән мәгълүм кагыйдәләрне үтәп кылына. Әйтик, никах вакытында өйләнешүче ике затның да булуы мәҗбүри; кияү һәм кәләш гаилә берлегенә керүгә үзара ихтыяри ризалыкларын бирергә тиеш; алар закон чыгаручы тарафыннан 18 яшь итеп билгеләнгән никах яшенә җиткән булсын. (Җирле үзидарә органнары бу яшькә җиткәнче үк никахка керергә рөхсәт итәрлек саллы сәбәпләр турында сез параграфка документны укып белә аласыз.) Закон РФ субъектларына никах яшен киметү турында карар кабул итәргә мөмкинлек бирә. Бу хокуктан, аерым алганда, Мәскәү, Владимир, Рязань һәм башка өлкәләр файдаланды инде.

Никахны теркәү, кагыйдә буларак, кәләш һәм кияү ЗАГС органына гариза биргәннән соң бер айдан башкарыла. (Бу кагыйдәдән чыгарылмалар параграфка документта бар.) Бер ай зур вакыт түгел, ләкин ул бер-береңне яхшырак белергә, хисләреңне сынарга булыша. Никахны дәүләт теркәвен раслап, *«никах турында таныклык»* дип аталган документ бирелә һәм граждан хәле актлары кенәгәсенә язып куела, шулай ук ир һәм хатынның һәркайсы шәхесен таныклаучы документларга да язма кертелә.

Хәзер никахка керүгә киртә булган өч хәлне атап үтик. Беренчедән, закон якын кардәшләр — бертуган кыз һәм егет, әнисе һәм улы, әтисе һәм кызы, шулай ук уллыкка-кызлыкка алучы һәм алынучы арасында никахны рөхсәт итми. Шулай ук берсе генә дә башка теркәлгән никахта торучы затлар арасында өйләнешү мөмкин түгел. Һәм, ниһаять, затларның берсе суд тарафыннан психикасы бозылу нәтиҗәсендә хокук гамәленә сәләтсез дип танылса, никах рөхсәт ителми.

Гаиләне саклап калу аның әгъзалары өчен генә түгел, тулаем җәмгыять өчен мөһим булса да (килсә дә), хокук кешегә кемне дә булса яратуны яисә аның белән гомергә гаилә-никах мөнәсәбәтләрендә булуны йөкли алмый. Әгәр гаиләнең чынбарлыкта таркалуы күренеп торса, закон никахны өзүгә каршы килми. Никахны өзү ЗАГС органнарында яисә *суд тәртибендә* башкарыла.

Әгәр ир һәм хатын гаилә тормышын дәвам итеп булмау турында уртак карарга килсә, аларның балигъ булмаган уртак балалары булмаганда, никах ЗАГС органына ир һәм хатынның берсе генә булса да, аларның никахны өзү турындагы уртак гаризасы бирелгән көннән бер айдан соң никах өзелә («Гражданлык хәле актлары турында» Законның 33 статьясы). ЗАГС органнары шулай ук ир һәм хатынның берсе гаризасы буенча, аларның уртак балигъ булмаган балаларына карамастан, әгәр ир суд тарафыннан билгесез югалган яисә хокукый гамәлгә

сәләтсез яки өч елдан күбрәккә ирегеннән мәхрүм ителгән булса, никахны өзә алалар.

Никахны суд тәртибендә өзү ике очракта була: беренчедән, никахны өзүгә ир белән хатынның берсе ризалык бирмәгәндә; ир һәм хатынның икесе дә риза булып, уртак балигъ булмаган балалары үскәндә. Аналарны һәм балаларны яклап, закон иргә хатыны ризалыгыннан башка аның көмәнле вакытында һәм бала тугач бер ел дәвамында никахны өзү турында эш кузгалтуны тыя.

Суд ир һәм хатынны татулаштырырга омтылып карарга хокуклы. Әгәр татулаштыру процедурасы 3 ай дәвамында уңай нәтиҗә бирмәсә, суд никахны өзү турында карар кабул итәргә мөмкин. Никах суд карары үз көченә кергән көннән суд тәртибендә өзелгән дип санала.

Граждан хәле актлары кенәгәсенә һәм ир белән хатынның шәхесләрен раслаучы документларга никахны өзү турында язма, шулай ук бу хакта таныклык бирү ЗАГС органы тарафыннан башкарыла.

Кайбер очракларда никах суд тарафыннан «гамәлдә түгел» дип танылырга мөмкин. Мондый очракларга, аерым алганда, ир яки хатынның үзендә ВИЧ-инфекция (СПИД) җенси юл белән бирелүче венерик авыруы булуын яшереп калдыруы керә.

ИР ҺӘМ ХАТЫННЫҢ ХОКУКЛАРЫ ҺӘМ БУРЫЧЛАРЫ

Ир һәм хатынның хокуклары һәм бурычлары никахны дәүләт теркәве көненнән барлыкка килә. Никах берлегенә кергән ир һәм хатын *шәхси, мөлкәти булмаган*, шулай ук *мөлкәти хокук* һәм *бурычларга* ия булалар.

Ир һәм хатынның шәхси хокукларына нинди хокуклар керә соң? Һәркайсының шәхесе белән тыгыз бәйләнгән хокуклар. Алар юкка чыгарыла яисә чикләнә алмый. Мәсәлән, гаилә тормышының барлык мәсьәләләрен, беренче чиратта — балалар тәрбияләүне, ир белән хатын килешү һәм хокук-бурычларның тигезлеге нигезендә бергәләшеп хәл итәргә тиеш. Моннан тыш, ир белән хатын шөгыль һәм һөнәр, яшәү һәм булу урынын сайлаганда, шулай ук никахка кергәндә фамилия сайлауда тигез хокукка ия. Әйтик, никахлашканда ир белән хатын уртак фамилия сыйфатында ирнең (хатынның) никахка кадәрге фамилиясен сайлап алырга яисә үз фамилиясенә ире яисә хатыны фамилиясен өстәп куярга (әгәр никахка кадәрге фамилиясе икеләтелгән булмаса) мөмкин.

Ир белән хатын гаиләдә үз мөнәсәбәтләрен үзара хөрмәт һәм ярдәмләшү нигезендә корырга, гаиләнең иминлеге һәм

нылыгына булышырга, балаларының мул тормышы һәм үсеше турында кайгыртырга *бурычлы*. Үзара ярдәм матди генә түгел, мораль яктан да булышлыкта чагыла. Ул бигрәк тә ир белән хатынның берсе хезмәткә сәләтен югалтканда, мәсәлән, авырганда, гарипләнгәндә, көмәнгә калганда, кече яшьтәге, инвалид балалар караганда кирәк. Ир белән хатынның бер-берсенә матди ярдәме турындагы мәсьәлә безне аларның мөлкәти хокуклары һәм бурычлары өлкәсенә чыгара.

Ир белән хатынның мөлкәти хокукларын *ике төркемгә* бүлеп карарга мөмкин: ир һәм хатын милке аркасындагы мөнәсәбәтләрне җайга салучы хокуклар һәм бер-берецне матди карау буенча мөнәсәбәтләрне (алимент мөнәсәбәтләре) җайга салучы хокуклар. Мөлкәти хокуклар закон яисә никах шартнамәсе белән билгеләнә.

Закон нигезендә ир белән хатын уртак, берләшкән милеккә, ягъни алар бергәләп алган мөлкәткә *тигез хокуклы*. Уртак мөлкәткә, аерым алганда, савыт-саба, мебель, көнкүреш электр приборлары, автомобиль, торак, шулай ук ир һәм хатынның һәркайсы хезмәт эшчәнлегеннән, пенсиясеннән, акча кертемнәреннән, кыйммәтле кәгазьләрдән һ.б. алган керемнәре кертелә. Шул ук вакытта бу мөлкәтнең кем тарафыннан сатып алынуы һәм кем исеменә рәсмиләштерелүе мөһим түгел. Закон ир белән хатынның уртак милкенә, әгәр никах чорында бу мөлкәткә аның бәясен сизелерлек арттырган акчалар салынган булса, никахка кергәнчегә кадәр аларның һәркайсы булдырган мөлкәтне дә кертә. Мәсәлән, никахка кадәр ир һәм хатынның берсенеке булган дачаны төзекләндерделәр ди. Мондый ремонт әлеге дачаны уртак мөлкәткә әйләндерә.

Ир белән хатынның һәркайсы милкенә закон алар никахка кергәнче булдырган мөлкәтне (әгәр ир һәм хатын бу мөлкәтнең бәясен арттыручы кертемнәр ясамаса), шәхси куллану әйберләре (кыйммәтле әйберләр һәм башка зиннәтләрдән гайре), бүләкләр (хәтта алар икенче як тарафыннан бирелсә дә), шулай ук никах вакытында мирас алу хокукы буенча алган мөлкәтне кертә.

Никахны өзгәндә фәкать уртак мөлкәтне бүлешү турындагы мәсьәлә генә куела. Уртак мөлкәт, кагыйдә буларак, ир һәм хатын арасындагы килешү белән башкача каралмаса, тигез өлешләрдә бүленә. Шуны билгеләп үтү мөһим: хатыны уртак милектә тигез өлешкә хәтта мөстәкыйль эш хакы булмаса да хокуклы, чөнки ул йорт хуҗалыгын алып бара һәм балалар үстерә. Ә ир белән хатынның һәркайсы милке бүленергә тиеш түгел. Шулай ук балигъ булмаган балалар ихтыяҗларын канәгатьләндерү өчен сатып алынган әйберләр дә бүленми, алар балалар белән яшәячәк иргә яки хатынга тапшырыла.

Ир белән хатын бер-берсенә матди яктан булышырга *бурычлы*. Аерым хәлләр килеп чыкканда (инвалидлык яисә пенсиягә чыгу белән бәйле хезмәткә сәләтсезлек, шулай ук уртак инвалид баланы караганда, ир һәм хатынның *берсенең* матди мөмкинлеге булганда, икенчесе мохтажлык тойганда), икенче яктан алимент алу хокукы барлыкка килә. Шулай ук хатын көмәнлелек чорында һәм бала тугач өч ел дәвамында иреннән алимент алырга хокуклы.

Алимент түләү бурычының килеп чыгуы һәрвакытта да гаилә таркалу белән бәйле түгел. «Алимент» сүзе латинчадан тәрҗемәдә карап тору, ризык дигәнне аңлата. (Ир белән хатын арасындагы алимент йөкләмәләреннән тыш ата-ана һәм балалар алимент йөкләмәләре дә бар.) Матди ярдәм күрсәтүдән баш тарту очрагында алимент алу турында карар суд тарафыннан чыгарылырга мөмкин.

Ир белән хатынның мөлкәти мөнәсәбәтләрен билгеләүче законның гомуми нигезләмәләре *никах шартнамәсе* төзү юлы белән үзгәртелә ала. Никах шартнамәсе язмача рәвештә төзелә һәм нотариаль таныкланырга тиеш Бу шартнамә *ир һәм хатынның* никахтагы һәм никахны өзү очрагындагы *мөлкәти хокукларын һәм бурычларын* билгели. Ул никах чорында да, аны теркәүгә кадәр дә төзелә ала һәм якларның уртак килешүе буенча үзгәртелергә яисә өзелергә мөмкин. Ир һәм хатынның берсе таләбе буенча никах шартнамәсе фәкать суд тәртибендә генә үзгәртелә яки өзелә ала. Никах шартнамәсен өзү никахны өзүгә китерми, ә никахның өзелүе үзеннән-үзе никах шартнамәсенең өзелүенә алып бара (никах шартнамәсе текстында никах туктатылганнан соң да билгеле бер чор дәвамында гамәлдә булган хәлләр күздә тотылган очрактан гайре).

БАЛАЛАРНЫҢ ҺӘМ АТА-АНАНЫҢ ХОКУКЛАРЫ ҺӘМ БУРЫЧЛАРЫ

Бу хокуклар һәм бурычлар законлы рәвештә баланың конкрет ата-анадан тууы факты таныклануы нигезендә килеп чыга. Закон нигезендә *баланың төп хокукларына* барыннан да элек аның гаиләдә яшәве һәм тәрбияләнүе хокукы кертелә. Балигълык яшенә (18 яшь) җитмәгән затны закон бала итеп таный.

Шуны билгеләп үтик: балалар һәм ата-ана мөнәсәбәтләрен күп кенә хокук һәм бурычлар җайга сала. Аларга, беренчедән, баланың тумыштан ук исемгә, атасының исеменә һәм фамилиягә хокукы — димәк, ата-ананың балага исем, атасының исемен һәм фамилия бирү бурычы керә. Икенчедән, бу баланың

гаиләдә яшәү һәм тәрбияләнү хокукы — һәм, димәк, ата-ананың үз балаларын тәрбияләү бурычы. Өченчедән, баланың ата-ана һәм туганнары белән аралашуга хокукы — һәм ата-ананың, туганнарының бала белән аралашу хокукы. Ниһаять, баланың үз хокуклары яклануга да хокукы бар — һәм, димәк, ата-ана балаларының хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яклауга хокуклы һәм бурычлы. Бу гомуми хокукларны конкретлаштыруга берничә мисал китерик. Ата-ананың никахы өзелүе очрагында яисә алар аерым яшәгәндә, бала аларның һәркайсы белән, шулай ук һәр ике яктагы туганнары (әбиләре, бабайлары, ир һәм кыз туганнары) белән аралашырга хокуклы. Ун яшеннән бала гаиләдә үзенең мәнфәгатьләренә кагылган мәсьәләләрне хәл иткәндә үз фикерен әйтергә хокуклы. Ундүрт яшеннән ул исемен һәм фамилиясен үзгәртү хокукы ала.

Баланың мөлкәти хокукларына ул алган керемнәргә һәм бүләккә яисә мирас алу тәртибендә яки үз акчаларына алган мөлкәткә хокук керә. Бала, мәсәлән, хосусыйлаштыру нәтиҗәсендә йорт, фатир, бүлмә милекчесе булырга мөмкин. Закон нигезендә балигъ булганчыга кадәр бала үз мөлкәте белән мөстәкыйль эш итә алмый әле. 14 яшьтән 18 яшькәчә балигъ булмаган яшүсмерләргә, ата-анасы, уллыкка-кызлыкка алучы яисә попечителенең язмача ризалыгы белән алыш-биреш ясарга рөхсәт ителә. (Фәкать вак көнкүреш, нотариаль таныклауны яки дәүләт теркәвен таләп итмәүче алыш-биреш кенә керә.)

Югарыда аталган мөлкәткә идарә итүдән алынган керемнәр опека һәм попечительлек органнарының алдан бирелгән ризалыгы белән бала мәнфәгатьләрендә генә сарыф ителергә мөмкин. Баланың икенче мөлкәти хокукы — нормаль тормыш шартлары (көнкүреш, уку, ял һ.б.) тәэмин итү өчен ата-анасыннан һәм гаиләнең башка әгъзаларыннан карау алу хокукы. Балалары белән бергә яшәмәгән ата-ана аларны карауга, тәрбияләүгә, белем бирүгә акча бүлеп бирергә — алимент түләргә бурычлы.

Никахта ир һәм хатынның тигезлеге принцибы аларның балаларга карата мөнәсәбәтендәге хокук һәм бурычларына да кагыла. Ата-ананың икесе дә баланың сәламәтлеге, физик, психик, рухи һәм әхлакый үсеше, аларның төп гомуми белем алуы турында кайгыртырга бурычлы. («Мәгариф турында» Закон нигезендә безнең илдә төп гомуми белем алу мәҗбүри.) Ата-ана хокукларын тормышка ашырганда, ата-ана үз балалары сәламәтлегенә һәм үсешенә зыян китерергә тиеш түгел.

Күпчелек ата-ананың үз балаларын яратуына һәм аларга игелек теләвенә берниндн шик юк. Һәм, әлбәттә, әгәр дә кем дә булса ят кешенең аларның баласына сугарга яки ничек тә булса рәнҗетергә маташуына әти һәм әнинең реакциясен күз алдына

китерергә мөмкин. Әмма шул ук чакта байтак ата һәм аналар үз балаларына кул күтәрергә сәләтле. Күп кенә гаиләләрдә физик җәза бирү киң таралган күренеш. Бәлки, ата-ана максат әлеге чараларны аклый дип саныйдыр, ә максат — тәрбияләү. Ә бәлки, бу гамәлләрнең нигезендә үз тормыш тәҗрибәләре ятадыр. («Бала чакта мине дә кыйнадылар, бу файдага гына китте»?) Аларның балалары — үз милекләре, һәм аның белән нишләсәң дә ярый дип беләләрдер.

Әлбәттә, бала тәрбияләү җиңел эш түгел. Балалар да фәрештә түгел. Ләкин алар — кечкенә кешеләр, һәм шуңа да ата-ана калган авыр хәлләрдән аларның кешелек абруена хөрмәт белән — физик җәза, сүздә мыскыллау кулланмыйча чыгарга тырышырга кирәк. Тән җәзасы тәрбиянең нәтиҗәле ысулы түгел. Алар баланы бернигә өйрәтми, түбәнсетә, ярсыта, курку һәм җавап итеп рәхимсезлек тудыра. Балаларга карата тән җәзасы куллану кешенең төп хокукларын бозу булып тора.

Ата-ана тарафыннан үз вазифаларын үтәмәү яисә тиешенчә үтәмәү очрагында һәм хокукларыннан явызларча файдаланганда, бала үзенең законлы хокукларын һәм мәнфәгатьләрен якларга хокуклы. 14 яшенә кадәр бала яклау сорап опека һәм попечительлек органына мөрәҗәгать итә ала, ә бу яшькә җиткәч, турыдан-туры судка бирергә хокуклы. Әгәр ата-ана үз вазифаларын үтәүдән читләшә, аларның тәртибе балалар тормышына һәм сәламәтлегенә яный икән, суд карары белән алар ата-ана хокукыннан мәхрүм ителергә яисә бу хокуклары чикләнергә мөмкин.

Закон балигъ булмаган баланың нинди дә булса шәхси характердагы хокукый бурычларын күздә тотмый. Баланың ата-анага һәм туганнарына карата мораль характердагы бурычлары бар (тыңларга, булышырга, хөрмәт итәргә һ.б.). Балигъ булган хезмәткә сәләтле балалар ата-аналары турында кайгыртырга һәм аларга булышырга тиешләр. (Үзегезнең туганнарыгызны һәм өлкән дусларыгызны күздән кичерегез: аларның ата-аналары турында кайгыртучанлыгы һәм ярдәмнәре нидән гыйбарәт?)

АТА-АНА КАРАВЫННАН МӘХРҮМ КАЛГАН БАЛАЛАРНЫ ТӘРБИЯЛӘҮ

Опека һәм попечительлек закон нигезендә ата-ана каравыннан мәхрүм калган балигъ булмаган балаларны тәрбияләү өчен урнаштырыла (ата-ананың үлеме, авыруы, ата-ана хокукыннан мәхрүм итү нәтиҗәсендә һәм башка сәбәпләр буенча, шулай ук баланың шәхси һәм мөлкәти хокукларын һәм

мәнфәгатьләрен яклау өчен). Безнең илдә җирле үзидарә органнары опека һәм попечительлек органнары булып тора. Алар ата-ана каравыннан мәхрүм калган баланы балалар йортына, интернатка бирергә йә гражданнар гаиләсенә тәрбиягә тапшырырга һәм аны тотуны, тәрбияләүне һәм белем бирүне тикшереп торырга тиешләр.

Закон гаилә тәрбиясенә өстенлек бирә һәм аның төрле рәвешләрен: уллыкка (кызлыкка) алу, опека һәм попечительлек, гаиләгә алуны җентекләп билгели.

Уллыкка (кызлыкка) алу нәтиҗәсендә бала һәм аны тәрбиягә алган зат арасында, ата-ана һәм балалар арасында яшәп килгән хокукый мөнәсәбәтләр урнаша. Уллыкка (кызлыкка) алу, әгәр аның ата-анасы исән булса, суд тарафыннан «хокукка сәләтсез» дип табылмаса һәм ата-ана хокукыннан мәхрүм ителмәсә, алар ризалыгыннан башка мөмкин түгел. (Ата-ана ризалыгы, әгәр алар алты айдан артык бала белән бергәләшеп яшәмәсә, аны карау, тәрбияләүдән читләшсә, ә суд аларның булмавы сәбәпләрен «игътибарга лаек түгел» дип тапса, кирәк түгел.)

Закон *опекуннар* итеп (ягъни 14 яшенә җитмәгән балаларга опеканы тормышка ашыручы затлар дип) һәм *попечительләр* дип (ягъни 14 яшеннән 18 яшькәчә балаларга попечительлекне тормышка ашыручы затлар итеп) «балигъ булган, хокукый сәләтле затлар билгеләнә ала» дип урнаштыра. Опекуннар һәм попечительләр гадәттә ата-ана башкарган рольне кабул итәләр.

Опекун һәм попечительләрнең гамәлләре опека һәм попечительлек органнары тарафыннан тикшерелеп тора, алар хакында хисап алына. Опекун һәм попечительләр үз вазифаларын башкарудан үзләренең шәхси үтенечләре буенча да, опека һәм попечительлек органы таләбе буенча да азат ителергә, читләштерелергә мөмкин.

РФ Гаилә кодексы балалар тәрбияләүнең тагын бер рәвешен — *кабул иткән гаиләдә тәрбияләүне* формалаштырды. Бер генә баланы тәрбиягә алган гаилә шундый гаилә дип таныла. Кабул иткән ата-ана тәрбиягә кабул ителгән балага карата опекун (попечитель) хокуклары һәм бурычларына ия. Баланы үз гаиләсенә тәрбиягә алган кешеләр хезмәте өчен дәүләт акча түли.

ГАМӘЛИ ЙОМГАКЛАР

1 Сез — булачак ирләр һәм хатыннар, ата-аналар. Үз вазифаларыгызны җаваплы үтәргә, туганнарыгыз һәм якыннарыгыз турында кайгыртырга алдан ук өйрәнегез. Бу гадәткә керәчәк һәм гаилә тормышында кирәк булачак.

2 Гаилә хокукы нормаларын белү сезгә никахка керү һәм аны теркәү турындагы карар белән бәйле шатлыклы һәм җаваплы чорда ярдәм итәр. Шуны онытмагыз: хокукый мөнәсәбәтләрнең барлык төрлелеген фәкать рәсми теркәлгән никах кына бирә.

3 Исегездән чыгармагыз: закон бала хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яклау ягында тора. Әгәр ата-ана вазифалары үтәлмәсә һәм алар белән бергә яшәү бала мәнфәгатьләренә каршы килсә, ата-ананың хокукы чикләнергә яисә аңардан бөтенләй мәхрүм ителергә мөмкин. Мондый хәлдә һәрвакыт балалар иза чигә. Бар көчегезгә моны үз гаиләгездә дә, дусларыгыз һәм танышларыгыз гаиләләрендә дә булдырмаска тырышыгыз.

4 Зур кеше булгач, кайгырту һәм игътибарга мохтаҗ балалар турында онытмагыз. Бәлки, нәкъ менә сезнең гаиләдә үзләреннән ата-анасы баш тарткан малай һәм кыз тулы кыйммәтле тәрбия алыр. Әгәр дә киләчәктә сез ялгыз баланы тәрбиягә алырга булсагыз (ә бу бик катлаулы карар һәм гаять зур җаваплылык), алдан ук барысын да үлчәп карагыз, үз көчегезне һәм мөмкинлекләрегезне санагыз һәм дөрес бүлегез. Кызганычка каршы, шундый очраклар да була, күпмедер вакыттан баланы кире кайтаралар. Белеп торыгыз: бала өчен бу тагын бер фаҗига булырга мөмкин.

ДОКУМЕНТ

РФ Гаилә кодексыннан *(1995 елның 29 декабре).*

11 статья. Никахлашу тәртибе.

1. Никахлашу никахка керүчеләрнең шәхси катнашында, аларның граждан хәле актларын язу органына гариза бирүе көненнән соң бер ай узгач башкарыла.

Игътибарга лаек сәбәпләр булганда, никахлашуны дәүләт теркәве урыны буенча граждан хәле актларын язу органы никахлашуны бер ай узганчы ук рөхсәт итәргә мөмкин; ул шулай ук бу вакытны озайта да ала, ләкин бер айдан да күбрәккә түгел.

Аеруча хәлләр (көмәнлелек, бала туу, якларның берсе гомеренә турыдан-туры куркыныч янау һәм башка аерым хәлләр) булганда никахлашу гариза бирү көнендә үк башкарылырга мөмкин. <...>

12 статья. Никахлашуның шартлары.

1. Никахлашу өчен никахка керүче ир һәм хатынның

үзара ихтыяри ризалыгы һәм аларның никах яшенә җитүе кирәк. <...>

13 статья. Никах яше.

1. «Никах яше» дип унсигез яшь билгеләнә.

2. Игътибарга алырлык сәбәпләр булганда, никахка керергә теләүче затларның тору урыны буенча җирле үзидарә органнары әлеге затлар үтенече буенча уналты яшь тулган затларга никахка керергә рөхсәт итәргә хокуклы.

Аерым шартларны исәпкә алып, гайре табигый хәл рәвешендә никахка керү уналты яшькә җиткәч рөхсәт ителергә мөмкин булган тәртип һәм шартлар Россия Федерациясе субъектлары законнары белән билгеләнә ала.

14 статья. Никахлашуга каршылык тудыручы хәлләр.

Түбәндәгеләр арасында никахлашу рөхсәт ителми:

кайсы да булса бер зат инде теркелгән башка никахта торган затлар;

якын кардәшләр (туры өскә күтәрелүче һәм түбән юнәлештә төшүче туганнар (ата-ана һәм бала, әби-бабай һәм онык), тулы канлы һәм тулы канлы булмаган (уртак этисе яисә әнисе булган) ир һәм кыз туганнар);

уллыкка алучылар һәм алынучылар;

кайсы да булса бер зат суд тарафыннан психик авыру аркасында хокукый сәләтсез дип табылган затлар. <...>

27 статья. Никахны гамәлдә түгел дип тану.

1. Әлеге Кодекс статьялары... белән билгеләнгән шартларны бозганда, шулай ук фиктив никахлашканда, ягъни әгәр ир белән хатын яисә аларның берсе никахны гаилә төзү ниятеннән башка теркәгәндә, никах гамәлдә түгел дип таныла.

Документка сораулар һәм биремнәр

1. Никахлашуның ике төп шарты нинди? **2.** Нинди очракларда никах гариза биргән көнне үк теркәлергә мөмкин? **3.** Закон күпхатынлылыкны рөхсәт итәме? Гаилә кодексының дөрес җавап өчен нигез булып торган нигезләмәсен китерегез. **4.** Никахлашуга каршы булган хәлләр нинди? Аларның әһәмияте нидә? **5.** Нинди никах фиктив дип санала?

ҮЗ-ҮЗЕҢНЕ ТИКШЕРҮ ӨЧЕН СОРАУЛАР

1. Гаилә хокукы белән нинди мөнәсәбәтләр җайга салына?
2. Гаилә хокук мөнәсәбәтләре субъект һәм объектларын бил-

гелəгез? **3.** Никахлашуның шартлары нинди? Ə нəрсə аңа каршы килə? **4.** Ир һəм хатынның шəхси мөлкəти хокукларын атагыз. **5.** Никахта ир белəн хатынның тигезлеге принцибы нинди хокукларга кагыла? **6.** Никахны өзгəндə нинди мөлкəт бүленүен күрсəтегез. **7.** Гаилəдə баланың шəхси һəм мөлкəти хокуклары нинди? **8.** Ата-ана каравыннан мəхрүм калган балаларны тəрбиялəү кем тарафыннан һəм ничек итеп башкарыла ала?

БИРЕМНƏР

1. Өлкəн сыйныф укучылары Евгений (15 яшь) һəм Наталия (14 яшь), əти-əнилəренə берни əйтмичə, никахлашырга булганнар. Аларның никахы теркəлгəнме?

2. Ирле-хатынлы В. аерылыша һəм мөлкəт бүлешə. Алар балаларының китапханəсен бүлəргə тиешме? Җавабыгызны нигезлəгез.

3. Студентлар Игорь С. һəм Татьяна М. ике елдан артык бергə тора, аннан соң Татьянаның əти-əнисе мəҗбүрилəве аркасында никахларын терки. Бу никах гамəлдə түгел дип танылырга мөмкинме? Җавабыгызны параграфта китерелгəн нигезлəмəлəр ярдəмендə дəлиллəгез.

4. Балалары булмаган ирле-хатынлы М. əрлəшəлəр һəм ЗАГСка аерылышу турында гариза бирəлəр. Закон белəн гариза бирелгəн көннəн аны карауга чаклы билгелəнгəн бер ай эчендə алар татулаша һəм билгелəнгəн көндə ЗАГСка килми. Алар законлы никахта каламы?

ЗИРƏКЛƏР ФИКЕРЕ

«Өйлəнү — үз хокукларыңны яртылаш кимəтү
һəм үз бурычларыңны ике тапкыр арттыру дигəн сүз ул».

А.Шопенгауэр (1788–1860), немец философы

§ 24. Мəшгульлекне һəм эшкə урнаштыруны хокукый җайга салу

Кешегə хезмəт кенəгəсе нəрсəгə? Дустыңнан сине эштə алмаштырып торуны сорарга буламы? Əгəр авырсаң һəм эшкə бармасаң, табибка мөрəҗəгать итү мəҗбүриме? Кайда сыйфатлы белем алырга була?

«Эш», «хезмəт» дигəн сүзлəр белəн, үзегез белгəнчə, нинди дə булса матди һəм рухи кыйммəтлəр булдыруга юнəлтелгəн

теләсә нинди диярлек аңлы эшчәнлекне атарга була. Мисал итеп, әйтик кичке аш әзерләүне алып карыйк. Ашарга әзерләүне эш дип әйтергә буламы? Әлбәттә. Кичке ашны өйдә әниегез дә әзерли ала, әмма ул махсус чакырылган хуҗабикә яисә пешекчеләрнең бөтен бер коллективы хезмәте нәтиҗәсе дә булырга мөмкин, соңгысында сүз ресторанда сыйлану турында бара. Ялланган хезмәттән файдаланганда, эш турында хокук күзлегеннән карап сөйләү дөрестер.

ХЕЗМӘТ МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ

Кеше җәмгыяте үсеше тарихында хезмәтнең төрле рәвешләре мәгълүм: бу күрше общинасында эшләү дә, кол хезмәте дә, крепостной крестьян эше дә. Бүген сүз ирекле кеше хезмәте турында бара. Тиешле нигезләмә РФ Конституциясендә беркетелгән: «Хезмәт ирекле. Һәркем хезмәткә сәләте белән ирекле эш итәргә, эшчәнлек төрен һәм һөнәр сайлап алырга хокуклы».

Көн саен миллионлаган кеше эшкә бара, ә кичен эштән кайта. Юридик яктан караганда, «эшкә бару» билгеле бер юридик мөнәсәбәткә керүне аңлата, шул ук вакытта анда катнашучыларның хокуклары һәм бурычлары төгәл билгеләнгән булырга тиеш. **Хезмәт хокук** мөнәсәбәтләре — хезмәткәр һәм эш бирүче арасындагы хезмәт шартнамәсенә нигезләнгән һәм хезмәт хокукы нормалары белән җайга салынучы мөнәсәбәтләр ул. Безнең җәмгыятьтә хезмәт мөнәсәбәтләре РФ Конституциясе, РФ Хезмәт кодексы, «Россия Федерациясендә халыкның мәшгульлеге турында» РФ Законы һәм башка закон нормалары белән регламентлана.

Хезмәт мөнәсәбәтләрендә катнашучыларны **хезмәт хокукы** субъектлары дип атыйлар. Хезмәт мөнәсәбәтләренең бер ягы булып хезмәткәр — хезмәт шартнамәсе буенча эшләргә хокукы һәм мөмкинлеге булган физик зат тора. Россиядә гражданнар 16 яшьтән эшләргә хокуклы. Әгәр инде төп гомуми белем алган булсалар, 15 яшьтән дә эшкә барырга була. Нигә нәкъ менә 15–16 яшь? Хезмәткәрдән эштә шәхси катнашуы таләп ителә — бу хезмәт мөнәсәбәтләренең үзенчәлеге. Әгәр сез эшкә кабул ителсәгез, дустыгызга һәм әти-әниегезгә түгел, нәкъ менә сезгә эшләргә туры киләчәк. Хезмәт мөнәсәбәтләренең тагын бер үзенчәлеге — аның озакка сузылган характерда булуы. 15 яшь — кеше аерым бер эш төрен регуляр үти алу, үз гамәлләрең өчен җавап бирү мөмкинлеге булган яшь инде ул.

Алай да: әгәр дә кешегә әле 15 яшь тулмаган, ә ул үзенең көчен сынап карарга һәм эшли башларга тели. Укудан буш

вакытта бу 14 яшеннән үк мөмкин икән. Әмма эш җиңел булырга, сәламәтлеккә зыян китермәскә тиеш һәм моңа ата-ана ризалыгы кирәк була.

РФ Хезмәт кодексы (265–272 статьялар) балигъ булмаганнарны аерым төркемгә бүлеп карый, бер яктан аларны эшкә алганда билгеле бер чикләүләр куя, икенче яктан, аларга мәгълүм ташламалар ясый һәм гарантия бирә. 18 яшькәчә яшьләр хезмәтен куллану тыелган авыр эшләр һәм зарарлы, куркынычлы хезмәт шартлары булган эшләр исемлеге расланган. Бу җир асты эшләре; спиртлы, тәмәке әйберләре житештерү, сату белән бәйле эшләр; авырлык күтәрү белән бәйле эш төрләре; уен бизнесы һ.б. Балигъ булмаганнарны хезмәт командировкасына җибәрү, тиешле вакыттан тыш, төнге эшләргә, ял көннәрендә эшкә җәлеп итү тыела. Болар барысы да җәмгыятьнең яшьләргә хезмәткә хокукларын реаль тормышка ашырырга мөмкинлек бирергә, моның өчен кирәкле шартлар тудыруга омтылышы турында сөйли.

Нинди яшьтә булуларына карамастан, барлык хезмәткәрләр хезмәт хокукларына һәм бурычларына ия. Аларның кайберләренә тукталыйк. Куркынычсызлык һәм гигиена таләпләренә җавап бирүче эш шартларына хокук; хезмәт хакын үз вакытында һәм тулы күләмдә түләүгә хокук; ялга хокук; үз хезмәт хокукларыңны яклауга хокук төп хокукларга керә. Югарыда санап үтелгән барлык хокуклар бозылган хәлне күз алдына китерик. Ул чакта кемгәдер ишеге бер тупсада эленеп торган бинада, электр үткәргечләре ялангач эш урынында, атнага җиде көн эшләргә туры киләчәк, ә хезмәт хакын ярты елга бер бирәләр. Эш шартларын яхшыртуны дәгъваларга хезмәткәрнең хакы юк ди. Бу тасвирлама, әлбәттә, арттыру булыр, әмма чынбарлыкта төп хокукларның берсен генә бозу да яраткан эшеңне авыр сынауга әверелдерә.

Хезмәткәрнең бурычларына үз хезмәт вазифаларын намус белән үтәү, эш дисциплинасын саклау, предприятие мөлкәтенә сакчыл караш, эш нормасын үтәү керә. Ә хәзер... хезмәткәр үзенең төп бурычларын үтәмәгән хәлне сез сурәтләп карагыз. Мондый хезмәткәргә ничек карар идегез? Ул нинди җаваплылыкка ия? Бу, әгәр хезмәт дисциплинасы бозылса (эш калдыру, соңга калу һ.б.), дисциплинар җаваплылык, әгәр хезмәткәр гаебе белән кыйммәтле әйбер ватылса, матди җаваплылык; әгәр предприятиедән, әйтик, әйбер урланса, җинаять җаваплылыгы булырга мөмкин һ.б.

Хезмәт хокук мөнәсәбәтләренең икенче ягында эш бирүче — хезмәткәр белән хезмәт мөнәсәбәтләренә кергән физик зат яки юридик зат тора. Эш бирүчедә булган хокуклар хезмәткәрләрдән үз вазифаларын үтәүне, мөлкәткә сакчыл карауны

таләп итәргә, хезмәт кодексы нигезендә хезмәткәрләрне бүләкләргә, дисциплинар һәм матди җаваплылыкка тартырга һ.б. мөмкинлек бирә. Игътибар белән карасагыз, эш бирүченең хокуклары хезмәткәр бурычларының «көзгедә чагылышы» икәнлеген күрерсез. Ә эш бирүче вазифалары арасында сез законнарны һәм хезмәт хокукы нормаларын үтәү, хезмәткәрләргә аларның хезмәт өлешенә туры китереп, гадел эш хакы түләү, куркынычсыз һәм эш бирүченең төп хокук һәм бурычлары РФ Хезмәт кодексының 21 һәм 22 нче статьяларында беркетелгән.

Эш бирүче һәм хезмәткәр арасындагы килешү хезмәт шартнамәсе рәвешендә рәсмиләштерелә. Сез инде хезмәт шартнамәсенең ни икәнлеген һәм аның эчтәлегенә нинди шартлар кертелергә тиешлеген яхшы беләсез һәм РФ Хезмәт кодексының «Хезмәт шартнамәсенең эчтәлеге» дигән 57 статьясы белән таныштыгыз (10 нчы сыйныф өчен дәреслек, «Хәзерге заман Россия законнары» дигән 28 нче параграф). Хәзер эшкә урнашу мәсьәләсен гамәли яктан карыйк.

ЭШКӘ КАБУЛ ИТҮ ТӘРТИБЕ

РФ Хезмәт кодексы эшкә кабул итү якларның килешүе буенча, аларның игелекле ихтыяры нигезендә башкарыла дип билгели. Сезгә 18 яшь, газетада белдерү укыдыгыз һәм эшкә урнашырга килдегез ди. Ягъни якларның берсе (бу сез — хезмәткәр) хезмәт шартнамәсе төзергә әзер икәнлеген белдерде. Сезне, мөгаен, директор (кадрлар бүлеге башлыгы, кадрлар буенча баш менеджер һ.б.) кабинетына әңгәмәгә чакырырлар. Эш бирүче гадәттә юридик зат була, мәсәлән, «Оазис» сәүдә фирмасы, ә эш бирүченең вәкиле — предприятие администрациясе җитәкчесе яисә вәкиле, ул фирма исеменнән хезмәткәрләр белән хезмәт шартнамәләре төзи. Мондый әңгәмәгә **кирәкле документлар** әзерләү зарур.

РФ Хезмәт кодексының 65 статьясы нигезендә сез эш бирүчегә паспортыгызны, хезмәт кенәгәсен, дәүләт пенсия иминиятләштерүе таныклыгын, хәрби исәптә тору документларын (хәрби хезмәткә алынырга тиешле затлар өчен), белем алу һәм квалификация турында документлар күрсәтергә тиеш буласыз. Хезмәт кенәгәсе кешенең хезмәт эшчәнлеге турында төп документ булып тора. Аңа хезмәткәр, ул башкаручы эшләр, башка даими эшкә күчерүләр, биләгән вазифасыннан азат итү турында белешмәләр кертелә. Бу язмалар нигезендә хезмәткәрнең эш стажы санап чыгарыла. Хезмәт кенәгәсенә шулай ук эштәге уңышлары өчен бүләкләүләр турында да языла. Әгәр

дә сез эшкә беренче тапкыр урнашсагыз, хезмәт кенәгәсен сезгә беренче эш бирүче рәсмиләштерә.

Эшкә урнашканда сездән анкета яисә автобиография рәвешендә үзегез турында өстәмә белешмәләр бирүне сорарга мөмкиннәр. Хәзер эш бирүченең байтагы эшкә алганда тестлаштыру, вазифаны биләүгә конкурс үткәрәләр — бу эш бирүченең хокукы. Сез югалып калмадыгыз һәм үзегезнең коммуникатив, һөнәри күрсәткечләрегезне менә дигән итеп ачып салдыгыз, эшләргә теләгегезне күрсәттегезме? Менә хәзер инде эш бирүче шулай ук сезнең белән **хезмәт шартнамәсе** төзергә әзер.

РФ Хезмәт кодексының 67 статьясы нигезендә хезмәт шартнамәсе язмача төзелә, ике нөсхәдә бастырыла, аларның һәркайсына хезмәткәр һәм эш бирүче имза сала. Хезмәт шартнамәсенең бер нөсхәсе хезмәткәргә (сезгә) бирелә, ә икенчесе эш бирүчедә саклана. Хезмәт шартнамәсенә кул куйганчыга кадәр текстны игътибар белән укыгыз. Әгәр нинди дә булса сораулар килеп чыкса, аларны хәзер бирү яхшырак, шулай иткәндә үзегезнең игътибарсызлыктан зарланырга яки суд буенда йөрергә туры килмәс. Шартнамәгә тиешле шартлар — эш урыны, аның характеры, хезмәт өчен түләүдән башка өстәмә шартлар да кертелергә мөмкин. Шартнамә йә билгеле бер вакытка (биш елдан да артык түгел), йә билгеләнмәгән вакытка төзелергә мөмкин. Әгәр сезне сынау чоры белән алсалар, бу хезмәт шартнамәсендә язылган булырга тиеш. Сынау чоры өч айдан да артык булмый, оешма җитәкчеләре һәм аларның урынбасарлары өчен генә алты ай була. Сынау вакыты узса, ә хезмәткәр эшен дәвам итсә, ул сынауны үткән дип санала. Әгәр шартнамәдә сынау чоры турында пункт юк икән, димәк, хезмәткәр сынаусыз гына кабул ителгән. Хезмәт шартнамәсеннән гайре сез эшкә кабул итү турында гариза язасыз, хезмәткәрләрнең шәхси карточкасын тутырасыз. Предприятие сезне эшкә алу турында боерык рәсмиләштерә, аңа директор кул куя, сезгә хезмәт кенәгәсе дә булдырыла. Менә хәзер сезне эшкә кабул ителүегез белән котларга мөмкин.

Хезмәт шартнамәсе шартлары эш барышында үзгәртелергә мөмкин. Сез үзегезне бик намуслы, башкаручан хезмәткәр итеп танытсагыз, катлаулырак, җаваплырак урынга күчерергә мөмкиннәр. Бу факт инде гамәлдә хезмәт шартнамәсен үзгәртә. Сез укуыгызны дәвам итәргә булдыгызмы? Яклар килешүе буенча, сезнең укуда булуыгызны исәпкә алып, хезмәт шартнамәсендә эш режимы үзгәртелергә мөмкин.

Хезмәт шартнамәсен өзү мөмкинлеге — хезмәтне ирекле сайлау чагылышының тагын бер рәвеше ул. Хезмәт кодексының 80 статьясы нигезендә хезмәткәр, эш бирүчегә ике атна алдан язмача хәбәр итеп, хезмәт шартнамәсен өзү хокукына ия

(үз теләге буенча). Сез эшегезне үзгәртергә булдыгызмы? Гариза бирдегезме? Һәм... киресенчә уйладыгызмы? Бу шулай ук сезнең хокук — шартнамәне өзү турында кисәтүнең вакыты чыкканчы, сез үзегезнең гаризаны кире алу хокукына ия.

Хезмәт шартнамәсе эш бирүче инициативасы буенча да өзелергә мөмкин (РФ Хезмәт кодексының 81 статьясы). Моның өчен нигезләр җитәрлек — хезмәткәр тарафыннан үз вазифаларының бозылуыннан алып оешманың ябылуына кадәр. Хезмәт шартнамәсен өзү өчен хезмәткәрнең бер тапкыр (!) үз вазифаларын тупас бозуы, мәсәлән, эш көне дәвамында игътибарга лаек сәбәпсез тоташ дүрт сәгатьтән артык эш урынында булмау; эштә алкоголь, наркотик яисә башка токсик исерү халәтендә булу; хезмәтне саклау таләпләрен авыр нәтиҗәгә китерерлек бозу да җитә.

Эш урыныннан азат итү турындагы язма, хезмәт шартнамәсен өзү сәбәпләрен күрсәтеп, хезмәт кенәгәсенә кертелә. Ул хезмәткәрнең кулына соңгы эш көнендә бирелә.

Балигъ булмаганнар белән хезмәт шартнамәсе башка үзенчәлекләргә ия. Әйтик, алар өчен сынау чоры билгеләнә алмый, эш вакытын кыскарту (күпмегә икәнлеген исегезгә төшерегез) хакында килешенергә тиеш, эшләп чыгаруның киметелгән нормалары билгеләнергә мөмкин. Шул ук вакытта эш бирүче үз акчалары исәбеннән балигъ булмаган хезмәткәрләргә башкалар белән тигез хезмәт хакы түли ала. Балигъ булмаганнарның еллык түләүле яллары 31 календарь көн тәшкил итә һәм аларга уңайлы вакытта бирелә. 18 яшькәчә хезмәткәр белән хезмәт шартнамәсен эш бирүче инициативасы буенча өзү дәүләт хезмәт инспекциясе тарафыннан гына башкарыла ала (оешманы ябу очрагыннан тыш).

Эшне уку белән бергә алып барган хезмәткәрләргә өстәмә гарантия һәм компенсацияләр бирелергә тиеш, бу шулай ук беренче чиратта яшь хезмәткәрләргә кагыла. Бер үк вакытта югары сыйфатлы эшләү һәм яхшы уку җиңел түгел, әлбәттә. Эшләүче студентка ничек ярдәм итәргә була? Закон чыгаручылар укучыларга имтихан чорына түләүле өстәмә отпуск гарантияли. Бу тапламалар яшьләрне дәүләт ягыннан социаль яклау чагылышы булып тора.

ХАЛЫКНЫҢ МӘШГУЛЬЛЕГЕ. СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ ҺӘМ СОЦИАЛЬ ТӘЭМИНАТ

Россиянең базар мөнәсәбәтләренә күчүе белән Россиядә килеп чыккан проблемалар сезгә таныш инде, аларны илдәге икътисади хәлне анализлаганда өйрәндегез. Шуннан чыгып, сезнең белүегезчә, иң җитди социаль проблемаларның берсе

халыкны эш белән тәэмин итү булды. «Россия Федерациясендә халыкның мәшгульлеге турында» Закон нигезендә «мәшгульләр» төшенчәсе «хезмәткәр» төшенчәсеннән киңрәк трактовкалана.

Мәшгульлек — гражданнарның шәхси һәм иҗтимагый ихтыяҗларын канәгатьләндерү белән бәйле, Россия законнарына каршы килмәгән һәм аларга, кагыйдә буларак, хезмәт хакы, керем китерүче эшчәнлеге ул.

Закон кемне мәшгуль дип саный соң? Әлбәттә инде, эшләүче кешеләрне: йә хезмәт шартнамәсе буенча (әгәр эш даими булса), йә граждан-хокукый характердагы шартнамәләр буенча (әгәр эш эпизодик характерда булса). Мәшгульләр санына гомуми белем бирү учреждениеләрендә, һөнәри белем учреждениеләрендә (училище, колледж, институт, университетларда һәм башка мәгариф учреждениеләрендә) көндез укучылар керә. Сүз индивидуаль эшмәкәрлек эшчәнлеге белән шөгыльләнүчеләр, хәрби хезмәт үтүчеләр, альтернатив граждан хезмәтендәгеләр, эчке эшләр органнарында хезмәт итүчеләр һ.б. турында да бара.

Ирекле хезмәт принцибын саклап, законнар «гражданнарның мәшгуль булмавы аларны административ һәм башка җаваплылыкка тарту өчен нигез булып тормавын» да күрсәтә. Ләкин кешенең вакытлыча эшләргә теләмәве бер хәл. Аның төрле хәлләр: сәламәтлеге буенча, өлкән яшьтә булганга... эшкә урнаша алмавы бөтенләй башка. Мондый кешеләргә базар икътисады шартларында үзләрен иң кирәкле әйбер белән тәэмин итү дә җиңел түгел. Алар дәүләт ягыннан социаль яклауга мохтаҗ. Россия Федер иясе Конституциясенең 39 статьясы мондый яклауны гарантияли һәм аны социаль тәэминатка хокук дип атый.

Социаль тәэминат — картлар, авырулар, балалар, иждивениедәгеләр, туендыручысын югалтучылар, эшсезләрнең яшәү өчен зарур шәхси ихтыяҗларын канәгатьләндерү максатында матди байлыкларны бүлешү рәвеше ул.

Социаль ярдәм моңа законлы нигез булганда гына күрсәтелә. Социаль яклау программаларын финанслау махсус фондлар яисә дәүләт бюджеты исәбеннән башкарыла. Социаль ярдәм күрсәтү шартлары һәм тәртибе закон тәртибендә урнаштырыла.

Социаль тәэминат хокукы өчен төп мөнәсәбәтләр төре булып пенсия мөнәсәбәтләре тора. Аларны җайга салучы нормалар бик күп санлы һәм төрле. Пенсиянең кайбер төрләрен карап китик. Әгәр кеше озак һәм намуслы хезмәт куйса, ул картлык буенча пенсиягә хокуклы. Гамәлдәге законнар буенча бу хокук 60 яшькә җиткән ирләргә һәм 55 яшьтән узган хатын-кызга гаран-

тияләнә. Пенсиянең тагын бер төре — тиешле елларын эшләгән өчен. Бу билгеле бер эшчәнлек төре белән бәйле, монда хезмәткәр махсус хезмәт стажына ия. Хәрби хезмәткәрләр, дәүләт хезмәткәрләре, укытучылардан тыш мондый пенсия үз вәкаләтләрен үтәүне туктаткан Президентка да санала. Пенсия рәвешендә минималь социаль ярдәм инвалидларга — эшли алмаучыларга яисә сәламәтлегенең торышы буенча хезмәткә хокукы чикләнгән кешеләргә гарантияләнә. Шулай ук ата-анасының берсен яисә икесен дә югалткан балаларга 18 яшенә кадәр пенсия түләнә.

Социаль ярдәм пенсия рәвешендә генә түгел, *пособиеләр* рәвешендә дә күрсәтелә. Аларның иң киң таралганы — вакытлыча эшкә сәләтсезлек буенча пособие. Бу пособиене алу өчен нигез булып медицина учреждениесе биргән хезмәткә яраксызлык турындагы кәгазь тора. Димәк, әгәр сез авырып китсәгез, моны табиб беркетергә тиеш, шул чакта гына сезнең эштә булмавыгыз «прогул» дип саналмый, һәм сез үзегезгә тиешле пособиене алачаксыз. Вакытлыча эшкә сәләтсезлек кәгазе авыруга гына түгел, авырып киткән баласын карачы әни кешегә дә бирелергә тиеш.

Хезмәт хокукы һәм социаль яклау хокукы күзлегеннән хатын-кыз хезмәте аңа хас үзенчәлекләргә ия. Хатын-кызларның авыр эшләрдә, зарарлы һәм куркыныч шартлар белән бәйле урында хезмәтен куллану чикләнгән. (Шуңа охшашлы шартлар балигъ булмаганнар хезмәтен яклый.) Закон белән көмәнле хатыннар өчен өстәмә ташламалар һәм гарантияләр аерым каралган: алар белән хезмәт шартнамәсе эш бирүче инициативасы буенча өзелә алмый, аларга, бала тугач, өстәмә түләүле отпусклар һәм пособие бирелә.

Башкалар арасында эшсезлек буенча пособие түләү тәртибе дә урнаштырылган. «Россия Федерациясендә халыкның мәшгульлеге турында» Законның 3 статьясы нигезендә эшсезләр дип ниндидер бер чорда эшсез калган һәм мәшгульлек хезмәте дәүләт органнарында теркәлгән, яраклы эш эзләүче һәм аңа керешергә әзер хезмәткә сәләтле гражданнар санала.

Сезнең белүегезчә, РФ гражданнарын эшкә урнаштыру буенча төп вазифа Федераль халык мәшгульлеге дәүләт хезмәтенә йөкләнгән. Халык мәшгульлеге үзәкләре гариза белән мөрәҗәгать иткән гражданнарны теркәргә һәм аларга социаль ярдәм күрсәтергә бурычлы. Ул нидән гыйбарәт соң? Сүз беренче чиратта яраклы эшкә урнашуда яисә яңа белгечлек (квалификация) алуда ярдәм итү, ә бу мөмкин булмаганда — эшсезлек буенча пособие түләү турында бара.

Бүген пенсия һәм пособиеләр күләменә күп кенә хаклы ризасызлык сүзләре ишетергә туры килә. Әйе, бу дәүләт

күрсәткән минималь социаль ярдәм. Социаль тәэминат белән бәйле законнар киләчәктә дә камилләшә барыр дип ышанабыз.

ҺӨНӘРИ БЕЛЕМ

Хәзер эшкә урнашу проблемаларына әйләнеп кайтыйк. Сез эш бирүчегә күрсәтергә тиешле документлар арасында һәрвакытта белем турындагысы бар. Бу бик мөһимме? Монда дискриминация (хокукларны кысу) билгеләре юкмы? Закон турыдан-туры күрсәткәнчә, хезмәткәрнең әзерлек дәрәҗәсе белән билгеләнүче аерма яки өстенлекләр дискриминация түгел. Ул гына да түгел, законнар белән урнаштырылган һөнәри чикләүләр бар. Шундый гади генә вазгыятьне күз алдына китерегез, сез табиб янына күренергә килдегез, ә аның тиешле белеме юк. Шул ук нәрсә икътисадчыларга, педагогларга, юристларга... кагыла, бу исемлекне озак дәвам итеп булыр иде. Барлык бу һөнәрләр махсус әзерлек һәм квалификацияне таләп итә, аларны һөнәри белем системасында алырга мөмкин. Ә белем алуга хокук безнең дәүләттә беренче чиратта Россия Конституциясе һәм «Мәгариф турында» Федераль закон белән җайга салына.

Хокукый аңлаешта **мәгариф** — кеше, җәмгыять, дәүләт мәнфәгатьләрендә, граждан тарафыннан дәүләт билгеләгән белем дәрәҗәләрен констатацияләү белән бергә алып барылучы, максатка юнәлтелгән тәрбия һәм укыту процессы ул.

Хәзер мәгариф системасын реформалау бара. Бүген һөнәри белем бирүдә башлангыч, урта һәм югары баскычларны бүлеп карарга мөмкин. Башлангыч һөнәр учреждениеләренә училищелар, урта һөнәригә — техникум һәм колледжлар керә, югары һөнәри белемне институт, университет, академияләрдә алып була. Һөнәри белем бирүнең төрле формалары бар. Көндез укырга мөмкин. Бу уку рәвеше үзенең режимы буенча сезнең мәктәптә укуыгызга охшашлы. Көндез яки читтән торып, яисә көндез-читтән торып та укырга мөмкин. Болай укыганда дәресләр йә кичен, яисә атнага бер тапкыр, яки бөтенләй укучыларның үзлектән әзерләнүе нигезендә бара. Мондый уку формасы беренче чиратта эшләп укучыларга туры килә. Белемне экстернат рәвешендә дә алып була: экстерн расланган программалар нигезендә уку материалын үзләштерә һәм аттестация уза (имтиханнар һәм зачетлар бирә), болай эшләгәндә, материалны үзләштерүнең индивидуаль программасы төзелергә мөмкин. Заманча мәгълүмати технологияләр белемне дистанцион укыту рәвешендә алырга да мөмкинлек бирә. Һөнәри белем уку йортларына кабул итү, кагыйдә буларак, конкурс буенча сайлап алу шартларында бара.

Үзең укырга керергә теләгән мәгариф учреждениесе турында нәрсә белергә кирәк? Бу мәгариф учреждениесе, укырга керү кагыйдәләре һәм документлар бирү тәртибе турында барлык мәгълүматны әлеге уку йортының кабул итү комиссиясендә алырга мөмкин.

Беренчедән, учреждениенең мәгариф эшчәнлеге алып баруга хокукка лицензиясе булырга тиеш. Лицензия алу уку йортында укыту өчен нормаль шартлар булдырылуын, санитар һәм башка нормалар үтәлүен, педагогик коллектив булуын, укытучыларның тиешле квалификациядә икәнлекләрен күздә тота.

Икенчедән, бу уку йортының статусы дәүләтнекеме яки дәүләтнеке түгелме икәнлекне ачыкларга кирәк. Дәүләт уку йорты дәүләт бюджетыннан финанслана (тулысынча яисә өлешчә) һәм конкурс нигезендә бюджет урыннары булдырырга тиеш.

Теге яки бу белгечлек буенча укырга керер өчен фәннәр җыелмасын (ниләр бирелергә тиеш) һәм үтү баллын (имтиханнарны нинди билгеләргә бирергә кирәклекне) уку йорты үзе билгели.

Дәүләт мәгариф учреждениесе түләүле мәгариф хезмәтләре дә күрсәтә. Бу очракта студент, аңа 18 яшь тулмаган булса, аның ата-анасы уку йорты белән мәгариф хезмәте күрсәтү турында шартнамә төзи һәм укучының белем алуы өчен акча түли. Шундый ук шартнамә дәүләтнеке булмаган мәгариф учреждениеләренә укырга кергәндә дә төзелә. Бу очракта керү имтиханнары бирергә кирәкме, сезнең укуыгыз күпме торачак — бу мәсьәләләр уку йорты тарафыннан хәл ителә.

Өченчедән, укып бетергәч нинди диплом алуыгыз турында кызыксынырга кирәк. Дәүләт дипломы (яисә дәүләт үрнәгендәге диплом) яшәп килүче дәүләт мәгариф стандартларына туры килә (шулай булмаганда диплом сез алган белемнәрне расламый!). Мондый дипломны дәүләт аккредитациясе турында таныклыгы булган, ягъни аттестацияне уңышлы узган һәм чыннан да сыйфатлы белем бирүче уку йортлары гына бирергә хокуклы.

ГАМӘЛИ ЙОМГАКЛАР

1 Сезнең һәркайсыгызның эшкә сәләтегезне үзегез теләгәнчә файдаланырга хокукы бар. Машиналар конструкцияләү ошыймы? Чит телләр белән кызыксынасыңмы? Чәчәкләр үстерергә яратасыңмы? Шундый мавыгулар теләсә кайсы лаеклы һөнәри эшчәнлеккә

әверелергә мөмкин. Ә укуыгыз — бу киләчәктә кызыклы һәм абруйлы эш алуда тагын бер, бәлки, хәлиткечтер, шанс ул.

2 Сезнең өчен хезмәт мөнәсәбәтләрендә иң мөһим катнашучы — хезмәт коллективы булачак: сезгә бик күп төрле кешеләр белән уртак тел табарга туры килер — монда һөнәри генә түгел, коммуникатив тәҗрибә дә кирәк. Аралашу кагыйдәләре турында белгәннәрегезнең барысын да искә төшерегез. Хезмәт мөнәсәбәтләре озакка сузылган характерда була, шуңа да хезмәт коллективында дусларыгыз күбрәк булган саен яхшы.

3 Хезмәт кенәгәсенә карап, вакыты җиткәч, сезнең эшлекле сыйфатларыгызны күзгедәге кебек күреп булачак: бу документны хезмәткәрнең үз вазифаларын тупас бозу аркасында хезмәт шартнамәсен өзүләр турындагы язмалар бизәми, аның каравы рәхмәт белдерүләр, югарырак вазифага билгеләп куелу, мактаулы исемнәр һәм бүләкләр бирелү хакында язмалар аның күрке булып тора.

ДОКУМЕНТ

Һөнәри белем бирү өлкәсендә түләүле мәгариф хезмәтләре күрсәтү шартнамәсе үрнәге фрагменты. *2003 елда басылган* **«Түләүле хезмәт күрсәтүләр кагыйдәләреннән».**

2. Башкаручы, Заказчы, Кулланучы хокуклары

2.1. Башкаручы белем бирү процессын мөстәкыйль тормышка ашырырга, Кулланучыны арадаш аттестацияләүнең бәяләү системасын, рәвешен, тәртибен һәм эзлеклелеген сайлап алырга, аңа Башкаручы Уставында каралган чикләрдә кызыксындыру чаралары кулланырга һәм җәза бирергә хокуклы.

2.2. Заказчы Башкаручыдан әлеге шартнамәнең 1 нче бүлегендә каралган хезмәт күрсәтүләрнең тиешенчә үтәлүен оештыру һәм тәэмин итү мәсьәләләре буенча мәгълүмат бирүне таләп итәргә хокуклы.

2.3. Заказчы Кулланучының укуга тулаем һәм укыту планының аерым предметлары буенча аерым мөнәсәбәте, өлгереше, тәртибе турында мәгълүмат алырга хокуклы.

Кулланучы түбәндәгеләргә хокуклы:

— Башкаручы хезмәткәрләренә мәгариф учреждениесендә укыту процессына кагылучы мәсьәләләр буенча мөрәҗәгать итәргә;

— үз белемнәрен, осталыгын һәм тәҗрибәсен бәяләү, шулай ук бу бәяләүнең критерийлары турында тулы һәм дөрес мәгълүмат алырга;

— расписаниедә каралган дәрес вакытында Башкаручының белем бирү процессын тормышка ашыру өчен кирәк булган мөлкәтеннән файдаланырга.

Документка сораулар һәм биремнәр

1. Китерелгән документка бәя бирегез. Шартнамәнең предметы нидән гыйбарәт? **2.** Башкаручы, Заказчы, Кулланучы кемнәр була? **3.** Уку-укыту процессы өчен кирәкле мөлкәт дип нәрсә аңлашыла?

ҮЗ-ҮЗЕҢНЕ ТИКШЕРҮ ӨЧЕН СОРАУЛАР

1. Хезмәт хокук мөнәсәбәтләренә билгеләмә бирегез. Алар өчен нинди үзенчәлекләр хас? **2.** Хезмәт хокукы субъектларының төп хокуклары һәм бурычларын аерып, хезмәт хокук мөнәсәбәтләренә мисал китерегез. **3.** Эшкә кабул ителгәндә хезмәткәргә нинди документлар кирәк? Эш бирүче эшкә кабул иткәндә рәсмиләштерә торган документларны санап чыгыгыз. **4.** Хезмәт шартнамәсен төзү, үзгәртү һәм өзү тәртибе нинди? **5.** «Мәшгуль», «мәшгуль булмаган», «эшсез» төшенчәләре ни белән аерыла? **6.** Түбәндәгеләрне социаль яклау һәм социаль тәэмин итү мисаллары китерегез: а) пенсионерларны; б) балигъ булмаганнарны; в) хатын-кызларны; г) эшсезләрне. **7.** Үзегез белгән һөнәри белем учреждениеләрен атагыз. Алар ни белән аерыла? **8.** Сез сайлаган мәгариф учреждениесенең кабул итү комиссиясендә нинди документлар белән танышырга кирәк?

БИРЕМНӘР

1. Гражданка К. үзен биләгән вазифадан азат итүләрен сорап гариза бирде. Түбәндә санап үтелгәннәрнең кайсысы хезмәт шартнамәсен өзү өчен нигез булып тора ала: а) аның үз теләге; б) директорның аңа премия бирергә теләмәве; в) аңа 50 яшь тулганга һәм ул эшләп арыганга пенсиягә чыгу теләге; г) башлыкның бу гаризаны язуын соравы, чөнки ул йөкле; д) башка эшкә күчүе. Җавабыгызны аңлатыгыз.

2. Безнең җәмгыятьтә эшсезлеккә караш үзгәрә. 1999 елда Халыкара хезмәт оешмасы белешмәсе буенча Россиядә 10 млн чамасы эшсез (илнең икътисади актив халкының 14% ы тирәсе) бар иде, мәшгульлек органнары шуларның нибары 1/5 өлешен

теркәде. 2002 елның апрелендә эшсезләр саны икътисади актив халыкның 8,9% ын тәшкил итте, мәшгульлек органнарына кешеләр ешрак мөрәҗәгать итә башлады. Бу фактны хезмәт хокукы, социаль яклау хокукы һәм социаль тәэминат күзлегеннән карап шәрехләгез.

3. XX гасыр поляк шагыйре һәм философы Е.Лец болай дип язды: «Кеше машинадан шуңа да өстен, ул үзен-үзе сата да белә». Бу гыйбарәне хезмәт хокукы позициясеннән шәрехләгез.

ЗИРӘКЛӘР ФИКЕРЕ

«Теләсә нинди һөнәр моны белмәүчегә каршы заговор ул».

Б. Шоу (1856–1950), инглиз язучысы

§ 25. Процессуаль хокук: гражданлык һәм арбитраж процессы

Мәктәп укучысының судка мөрәҗәгать итәргә хокукы бармы? Улы әтисенә каршы шаһит булырга тиешме? Милиция тоткарлаган кешенең хокуклары нинди?

Алдагы бүлекләрдә сез хокукның берничә тармагы белән таныштыгыз. Алар тормышның һәм эчтәлекнең төрле өлкәләрендәге — гаилә, мөлкәти һ.б. хокукый мөнәсәбәтләрдә катнашучыларның хокукларын һәм бурычларын билгели. Юристлар бу өлкәләрне, процессуаль хокуктан аермалы буларак, матди хокук дип атыйлар.

Процессуаль хокук матди хокукны гамәлгә ашыру һәм яклау тәртибен регламентлаштыра (ягъни кагыйдәләрен билгели). Әйтик, фатирга милек хокукы — матди хокук. Бу хокукны судта яклау (фатирдан чыгарырга, басып алырга маташканда һ.б.) процессуаль хокук белән җайга салына. Җинаять һәм җәза турындагы законнар, ягъни җинаятькә каршы законнар,— матди хокук. Ә җинаять җаваплылыгына тарту, җинаять эшләрен карау һәм хәл итү тәртибен процессуаль хокук җайга сала. Эшләрне карау һәм хәл итү гамәлләренең тәртипкә салынган эзлеклелеген, ягъни процессны гәүдәләндергәнлектән, бу хокук **процессуаль** дип атала да инде.

Шулай итеп, хокук системасын түбәндәге схема рәвешендә күз алдына китереп була.

ХОКУК СИСТЕМАСЫ

МАТЕРИАЛЬ ХОКУК

- Конституцион хокук
- Гражданлык хокукы
- Гаилә хокукы
- Конституцион хокук
- Экологик хокук һ.б.

ПРОЦЕССУАЛЬ ХОКУК

- Граждан процессуаль хокукы
- Җинаять-процессуаль хокук
- Административ процесс
- Конституцион суд һ.б.

Процессуаль хокук нигезендә судлар гадел хөкемне тормышка ашыралар, ягъни граждан, җинаять, административ эшләрне карый һәм алар буенча карар кабул итә. Бу хакта без алга таба җентекләп сөйләшербез әле.

Әмма әлек шуны билгеләп үтәргә кирәк, судның үзәктәге һәм иң катлаулы бурычы булып хакыйкатьне ачыклау тора. Күпсанлы процессуаль кагыйдәләр башлыча шуңа юнәлтелгән, алар суд процессында һәр этапны, һәр гамәлне детальләп җайга сала. Шуны аңларга кирәк, монда сүз «вак-төяк формальлек» турында бармый, ә судта хакыйкатьне табу буенча бик күп буыннар тәҗрибәсен үз эченә алган гаять мөһим кагыйдәләр хакында бара. Процессуаль нормаларны бозу суд ялгышлыкларына илтә. Ә бу фаҗига булып әверелергә мөмкин. (Мәсәлән, заманында гөрләгән күпләп үтерүче Чикатило эшендә шулай була. Ул чакта бу үтерүләрдә берничә кеше «гаебен таный», ә берсе хәтта атып та үтерелә.) Шуңа да процессуаль кагыйдәләр җәмгыять өчен, гражданнар хокукын яклау өчен шундый зур әһәмияткә ия. Аларның кайберләре хәтта Россиянең Төп законы — РФ Конституциясенә дә кертелгән.

Эшләрне карау буенча судлар эшчәнлеге суд производствосы (анык бер эш буенча производство) дип атала. «Граждан процессуаль хокукы» һәм «җинаять процессы» терминнары — бу «граждан процессуаль хокукы» һәм «җинаять-процессуаль

хокук» төшенчәләренең синонимы. Әмма юридик әдәбиятта, массакүләм мәгълүмат чараларында бу терминнар шулай ук эшнең судка үтүен, эшнең суд утырышында каралуын билгеләү өчен һәм кайбер башка мәгънәдә кулланыла.

ГРАЖДАН ПРОЦЕССЫНЫҢ ТӨП ПРИНЦИПЛАРЫ

Граждан-хокукый бәхәсләр һәм аларны хәл итү тәртибе — граждан процессының (граждан-процессуаль хокукының) төп предметы. С.И.Ожеговның рус теле сүзлеге «бәхәс» («спор») сүзен «һәркем үз фикерен, үзенең хаклы булуын яклаучы сүз ярышы» дип билгели. Әлеге билгеләмә, асылда, граждан-хокукы бәхәсенә дә туры килә, анда һәр як үзенең хаклы булуын суд алдында исбат итә, ә соңгысы карар чыгара.

Югарыда инде әйтелгәнчә, граждан-хокукы бәхәсләрен хәл итү тәртибе **граждан процессуаль хокукы** — граждан эшләрен судта карауны һәм хәл итүне, шул исәптән процесста катнашучыларның процессуаль гамәлләре тәртибен һәм эзлеклелеген җайга салучы хокук тармагы тарафыннан билгеләнә. Граждан процессы кагыйдәләре РФ Граждан процессуаль кодексында (ГПК) тупланган.

Граждан суд производствосының принциплары, ягъни төп, баштагы нигезләмәләре шулай ук ГПКда күрсәтелгән. Кодексның 1 нче бүлеге шулай «Төп нигезләмәләр» дип атала да. Конкрет мәсьәләләр буенча күпсанлы кагыйдәләр нәкъ менә шулардан килеп чыга да.

Мәсәлән, теләсә кайсы кызыксынган затның бозылган хокукларын (яки дәгъваланучы), ирекләрен яисә законлы мәнфәгатьләрен яклауларын сорап судка мөрәҗәгать итү хокукы. Затның судка мөрәҗәгать итү хокукыннан баш тартуы гамәлдә булмый (ягъни, нинди дә булса шартнамәдә судка мөрәҗәгать итүдән баш тарту турында пункт булса да, бу пункт гамәлдә түгел). Аннан соңгы принцибы — барлык граждан-нарның закон һәм суд каршындагы бертигезлеге. Аннары — гадел хөкемне тормышка ашырганда судның бәйсезлеге һәм фәкать Федераль законга гына буйсынуы. Алга таба — суд тикшерүенең хәбәрдарлыгы: барлык судларда эшне тикшерү ачык, ягъни анда теләсә кайсы зат катнаша ала. (Сүз уңаеннан, әгәр мөмкинлегегез булса, нинди дә булса суд утырышында катнашу файдалы.) Шуны да әйтеп үтәргә кирәк, законда каралган аерым очракларда гына (дәүләт сере һ.б.) процесста катнашучылар гына булган ябык процесслар уздырыла. Якларның ярышуы һәм тигез хокуклылыгы принцибы судның

объективлык һәм гаделлек сакларга, процесска җитәкчелек итәргә тиешлеген, ә якларның процесста катнашырга тигез хокукларга ия булуын, үзенең хаклыгын исбатлавын, ягъни суд каршында ярышуын белдерә. Суд карарларының мәҗбүрилеге принцибы суд карары хакимиятнең барлык органнары, урындагы затлар, оешмалар һәм гражданнар өчен мәҗбүри дигән сүз. Иң югары суд инстанциясе — РФ Югары Суды Пленумыннан тыш теләсә нинди суд карарына шикаять белдерү мөмкинлеген искә төшереп үтик. (Хәтта аны да Кеше хокуклары буенча Европа судына биреп була.)

Граждан процессында суд нинди эшләр каравын шулай ук ГПК билгели. 22 статья аларны берничә категориягә бүлә, шуларның дүртесен атап үтик. Беренчедән, гражданлык, гаилә, хезмәт, торак, җир, экологик һәм башка хокукый мөнәсәбәтләрдән килеп чыгучы бәхәсләр буенча дәгъва эшләре. (Болар граждан суд производствосы өчен иң характерлы эшләр, һәм алар хакында без алдарак җентекләп сөйләшербез әле.) Икенчедән, судьялар суд боерыгы бирә торган эшләр, алар суд тикшерүеннән һәм якларны чакырудан башка гына кичекмәстән үтәлергә тиеш (мәсәлән, балигъ булмаган балаларга алимент алу буенча). Өченчедән, публикадагы хокукый мөнәсәбәтләрдән килеп чыгучы эшләр (хакимият органнары һәм урындагы затлар карарларын, гамәлләрен (гамәл кылмауларын) дәгъвалау турында, сайлау хокукларын яклау турында һ.б.). Һәм, ниһаять, дүртенчедән, аерым производство эшләре, ягъни, нигездә граждан производствосының гомуми кагыйдәләре буенча, ләкин законда каралган аерым бер үзенчәлек белән каралучы эшләр. Мәсәлән, юридик фактларны ачыклау турындагы (туганлык мөнәсәбәтләрен, ата булуны, үлемне һ.б. билгеләү), уллыкка-кызлыкка алу турында, гражданны хокукый сәләтсез, билгесез калган, үлгән дип тану турындагы эшләр һ.б.

ГПК шулай ук суд системасында кайсы суд беренче инстанциядә теге яки бу эшләрне карарга тиеш булуын, димәк, бәхәсләр килеп чыкканда кайсы судка мөрәҗәгать итәргә икәнлекне билгели. (Монда һәм алга таба «гомуми юрисдикция» судлары күздә тотыла. Алга таба аларны кыскартып, «гомуми судлар» дип атарбыз. Нинди судлар булуын искә төшерегез.)

Күпчелек эшләрне — район судлары, ә кайберләрен башка судлар карый. Мәсәлән, җәмәгать судьясы иң гади эшләрне, аерым алганда, хезмәткә түләүнең 500 минималь күләменә (МРОТ) кадәрге мөлкәти бәхәсләр буенча суд боерыгы бирү турындагы һ.б. тикшерә. (Шуны билгеләп үтик, җәмәгать судьялары институты революциягә кадәрге Россиядә булган, ә 1996 елда иң гади граждан һәм җинаять эшләрен карау өчен яңадан торгызылды.)

Уртак кагыйдә буенча гражданга дәгъва — ул яшәгән урында, ә оешмага ул урнашкан җирлек буенча белдерелә. Әмма бу кагыйдәдән чыгарылмалар да бар, әйтик, алимент турында дәгъвалар — дәгъвачының яисә җавап тотучының яшәү урыны буенча (дәгъвачы сайлавы буенча), күчемсез мөлкәт турында — ул урнашкан җирдә белдерелә.

ГРАЖДАН ПРОЦЕССЫНДА КАТНАШУЧЫЛАР

Граждан процессында катнашучылар — эштә катнашучы затлар һәм гадел хөкемгә ярдәм итүче (булышучы) затлар ул. Эштә катнашучы затлар — барыннан да элек бәхәстә катнашучы яклар, ягъни таләпләр куючы дәгъвачы һәм үз адресына таләпләр куелучы җаваплы зат. Өченче затлар дип аталучылар да (ягъни бу эштә үз мәнфәгатьләре булганнар), прокурор һәм башка затларны яклау яисә дәүләт яки җәмәгать мәнфәгатьләрен яклау хокукы булган затлар катнашырга мөмкин. (Мәсәлән, балалар турында бәхәс чыкканда, опека һәм попечительлек органы вәкиле.)

Процесста фәкать процессуаль хокукый гамәлгә сәләтле затлар гына катнашырга хокуклы. Гражданнар өчен ул 18 яшьтә бирелә (кайбер очракларда, мәсәлән, никахларын теркәгәннән соң, үз хокукларын балигъ булмаганнар да яклый ала). Юридик затларның хокукый гамәлгә сәләте аларны теркәгәннән соң барлыкка килә. (Гражданнарның граждан-процессуаль хокукый сәләте, ягъни үз хокукларын һәм мәнфәгатьләрен судта яклау хокукы тумыштан ук барлыкка килә, ләкин ул вәкилләр аша тормышка ашырыла. Аерым алганда, балаларның законлы вәкилләре булып аның әти-әнисе тора.)

Эштә катнашучы затларга закон киң процессуаль хокуклар, шул исәптән эш материаллары белән танышу, ходатайство белдерү (мәсәлән, документлар таләп итү, шаһитлар чакыру), дәлилләр бирү һәм аларны тикшерүдә катнашу, процесста катнашучыларга сорау бирү, карарга шикаять белдерү һ.б. хокуклар бирә. Шул ук вакытта аларга тиешле бурычлар да, мәсәлән, эшне тыңлау вакытында тәртип саклау, суд сорауларына җавап бирү һәм башка процессуаль нормаларны үтәүне йөкли.

Суд ачыклавына гадел хөкемгә ярдәм итүче затлар да — шаһитлар, экспертлар, тәрҗемәчеләр, белгечләр җәлеп ителә. Бу затларның хокуклары һәм бурычлары шулай ук закон белән билгеләнгән. Әйтик, шаһит суд чакыруы буенча килергә, судка белешмәләр бирергә, дөресен генә сөйләргә тиеш, ул белешмәләр

бирүдән баш тарткан өчен, ялган белешмә биргән өчен һ.б. җавапка тартыла. Шуны да билгеләп үтик, шаһит белешмәләре — исбатлауның бер төре. Кодекс башкасын да күздә тота. Хәтта аңа бөтен бер бүлекне багышлый, чөнки суд карары шуларга нигезләнә. Суд процессында дәлилләр һәм исбатлауның роле хәлиткеч.

Дәлилләр һәм исбатлау — судта хакыйкатьне ачыклауның процессуаль чаралары.

Дәгъвачы җавап бирүчене үзе сатып алган, ләкин, читтә яшәгәнгә, аңардан вакытлыча файдаланмаган фатирдан куып чыгаруны таләп итә. Ә кайтса, анда ниндидер таныш булмаган кеше — җавап бирүче яшәвен ачыклый. Җавап бирүче каршы төшә, янәсе, бу фатирны ул сатып алган һәм акчасын түләгән. Суд хакыйкатьне ничек табар? Кем хаклы икәнлеген ничек билгеләргә?

Закон исбатлауның нинди дәлилләрен күрсәтә? Болар якларның һәм өченче затларның аңлатмалары, шаһитлар күрсәткәннәр, язмача дәлилләр (документлар, корреспонденция һ.б.), әйбер белән исбатлаулар (предметлар), аудио- һәм видеоязмалар, эксперт бәяләмәсе.

Шуны билгеләп үтү мөһим, һәр як үз таләпләре нигезенә таянган кебек хәлләрне исбат итәргә тиеш. Бернинди дәлилләр дә алдан билгеләнгән көчкә ия түгел. Суд китерелгән дәлилләрне тикшерә, алар бу эштә рөхсәт ителерлекме икәнлегенә бәя бирә. Аерым очракларда закон теге яки бу исбатлауларга юл куймый. (Мәсәлән, язмача төзелергә тиеш булган заем шартнамәсен шаһитлар күрсәтүе юлы белән дәгъвалауга юл куелмый.) Аларның бу эш өчен әһәмияте бармы, дөреслеге, шулай ук җитәрлеге һәм җыеп алганда үзара элемтәләре бәяләнә. Суд өстәмә дәлилләр дә соратып алырга хокуклы. Бу чакта дәлилләр китерү өчен судья вакыт билгели. Мондый вакыт процессуаль вакытка керә.

Процессуаль вакыт, ягъни процессның дәвамлылыгын җайга салырга чакырылган процессуаль гамәлләр үтәү өчен бирелгән вакыт, юкса процесс бетмәс вакытка сузыла алыр иде. Төп гамәлләр өчен вакыт закон белән билгеләнгән (мәсәлән, суд тарафыннан дәгъваны карау өчен гомуми вакыт — 2 ай, карарларга шикаять белдерү өчен — 10 көн һ.б.).

Суд тиешле дип тапкан процессуаль гамәлләр өчен вакытны суд үзе билгели (мәсәлән, судка шаһитның килүе, документлар бирү һ.б.).

Югарыда бәян ителгәннәр белән танышканнан соң, сезгә судта эшләрне карау ничек баруын аңлау җиңелрәк булыр.

ЭШНЕҢ СУДТА УЗУЫ

Эш буенча производство ничек башлана? Суд аша бурычын эзләтеп алырга теләгән кешегә нидән башларга? Ә аның фатирын законсыз биләгән кешене ничек чыгарырга?

Эшнең башы булып дәгъва гаризасы, ягъни судка үз хокукыңны судта бәхәсне хәл итү юлы белән яклауны таләп итеп язган мөрәҗәгать тора. Әлеге документка формаль таләпләр ГПКда урнаштырылган. Әйтик, аңарда дәгъвачы, җавап бирүче, дәгъва предметы турында белешмәләр булырга тиеш, ягъни дәгъвачы нәрсә таләп итә (мәсәлән, бурычны кайтарып алырга), дәгъваның нигезләре, ягъни таләпләр нәрсә белән нигезләнә (бурычлының акча алуы һәм аны РФ ГКның 810 статьясы буенча кире кайтару йөкләмәсе белән), нинди дәлилләр китерелә (заем шартнамәсе, бурычлының распискасы). Дәгъва гаризасына тиешле документлар теркәлә (фатир турындагы бәхәстә бу шактый калын пакет булыр иде). Әгәр дәгъва гаризасы ГПК таләпләренә җавап бирә икән, судья аны кабул итә һәм эш кузгата.

Эш буенча производство ачу — бу суд процессының беренче этабы. Аннан соң тагын дүрт этап була — эшне суд тикшерүенә әзерләү, эшне тикшерү, карар чыгару һәм аны игълан итү, башкарма кәгазь бирү.

Беренче стадиядә судья эшнең судта каралырлыкмы икәнлеген тикшерә, дәгъвачының хокукый гамәлгә сәләтен карый, дәгъва гаризасының ГПК таләпләренә туры килүен белә, документлар теркәлгәнме, закон буенча кирәкле башка формальлекләр үтәлгәнме икәнлеге белән таныша.

Әзерлек стадиясендә судья дәгъвачының таләпләрен ачыклый һәм җавап бирүченең каршы фикерен белә, җитешмәгән документларны билгели һәм соратып ала һәм тикшерүне башлау өчен кирәк булган законда күрсәтелгән башка гамәлләрне үти. Катлаулы очракларда кирәкле дәлилләрне төгәлләштерү өчен яклар, өченче затлар, экспертлар һ.б. катнашында алдан бар утырыш уздыралар. Эшне әзерләнгән дип танып, судья эшне тикшерүгә билгеләү турында билгеләмә чыгара, утырышның көнен, вакытын һәм урынын билгели.

Эшне тикшерү суд утырышында бара. Аны бер судья үткәрә (юристлар әйткәнчә: «Суд бер судья составында эш итә»). Утырыш беркетмәсен секретарь алып бара. Эшне тикшерү (һәм тиешенчә суд утырышы) шулай ук берничә этап (стадия) уза, аларның эзлеклелеге һәм аларның һәркайсында процесста катнашучыларның гамәлләре ГПКда билгеләнгән.

Әзерлек этабы (стадиясе) судьяның утырышны ачуы һәм нинди эш каралырга (тыңланырга) тиеш булуын игълан итүе

белән башлана. Аннан соң якларның һәм чакырылган башка затларның килүе, килүчеләрнең шәхесләре тикшерелә. Судья яклардан аңа эшне тикшерүне ышануларын сорый, якларга хокукларын һәм бурычларын аңлата, үтенечнамәләр булу-булмавы белән кызыксына, әгәр булса, аларны карый, башка процессуаль гамәлләр башкара. (Шуны билгеләп үтәргә кирәк, судның бу һәм башка процессуаль гамәлләре законда каралган һәм аларның башкарылуы суд утырышы беркетмәсендә тамгалап куела. Беркетмәдә мондый язманың булмавы — карарны юкка чыгаруга сәбәп ул.)

Эшне асылы буенча карау судьяның бәхәснең мәгънәсе турындагы нотыгы белән башлана. Аннан соң яклар судьяның алар үз позицияләрендә каламы һәм эшне килешү белән төгәлләргә теләмиме икәнлеге турындагы сорауларына җавап бирәләр. Аннан соң эштә катнашучы затларның аңлатмалары, дәгъвачының, җаваплының һ.б. чыгышлары, суд һәм бер-берсенең сорауларына җаваплар тыңлана. Аннан соң эшнең торышын тикшерү була, шул исәптән шаһитлардан сорау алына, документлар тикшерелә һ.б. Аннан соңгы этап — суд фикер алышуы, ул башта дәгъвачы, аннан соң җаваплының һәм эштә катнашучы башка затларның чыгышларыннан тора. Чыгышлар тәмамланганнан соң, якларның һәркайсы фикер алышуларда әйтелгәннәргә бәйле рәвештә репликага хокуклы. Шуның белән тикшерү тәмам була, һәм суд киңәшмә бүлмәсенә карар кабул итү өчен чыгып китә. Тагын бер тапкыр искә төшереп үтәргә кирәк, карауның санап үтелгән этаплары да, аларның эзлеклелеге дә — судта хакыйкатьне эзләп табу буенча күп буыннар тәҗрибәсе җимеше ул. Нинди дә булса этапның төшеп калуы яисә хәтта аларның чиратлашуы бозылу гына да, эшнең ничек тәмамлануына йогынты ясый ала, ә кайчакта аны кардиналь үзгәртә. Шуңа да закон судларга процессуаль нормаларны катгый үтәүне йөкли. Күп очракларда процессуаль нормалар аркасында нәкъ менә суд яклаучы дип санала. Закон суд карарына куйган таләпләр дә шуңа булышлык итә.

Карарның структурасы, анда булырга тиешле мәсьәләләр кебек үк, ГПКда язып куелган. Иң мөһиме — карарның *законлы* (ягъни матди һәм процессуаль хокук нормаларына нигезләнгән) һәм *нигезле* (ягъни суд утырышында ачыкланган фактлар һәм дәлилләр белән нигезләнгән) булырга тиешлеге күрсәтелә.

Карар әзер булгач һәм имзалангач, судья яңадан суд залына керә һәм карар текстын укып чыга, аңа шикаять белдерү тәртибен аңлата, ягъни суд карарын игълан итү була.

Әмма суд кабул иткән карар тик 10 көннән соң гына (әгәр бу вакыт эчендә аңа карата шикаять белдерелмәсә) яисә шикаять

хәл ителү мизгеленнән *законлы көченә керә* (ягъни мәҗбүр итеп үтәлергә тиеш була).

Сез инде белгәнчә, теләсә нинди суд карарына шикаять белдерелергә һәм, әгәр ул законсыз яки нигезләнмәгән булса, юкка чыгарылырга мөмкин.

Законлы көченә кермәгән **карарларга шикаять белдерү** кассация дип аталган (латинча cassatio — юкка чыгару, юк итү) тәртиптә уздырыла: шикаять *кассация инстанциясенә* бирелә (ул — югары (шәһәр, өлкә һ.б.) судның *гражданлык эшләре буенча суд коллегиясе*).

Кассация инстанциясе фактларны ачыкламый, ә карарның законлы һәм нигезлеме икәнлеген генә тикшерә, ягъни ул матди һәм процессуаль хокук нормаларына нигезләнгәнме, эштә булган дәлилләр белән расланган эш торышы белән нигезләнгәнме икәнлеген белә. Кассация инстанциясе (өч судья составында) түбәндәгеләргә хокуклы:

1. Карарны үзгәрешсез калдырырга.

2. Карарны үзгәртергә яисә юкка чыгарырга: а) эшне яңадан карауга җибәрергә; б) яңа карар кабул итәргә; в) эш буенча производствоны туктатырга. Карау нәтиҗәләре буенча *билгеләмә* чыгарыла, ул кичекмәстән үз көченә керә. Ләкин хәтта законлы көченә кергән суд карарларына һәм кассация билгеләмәләренә дә *күзәтчелек тәртибендә һәм яңа ачылган хәлләр буенча* шикаять белдерергә була.

Күзәтчелек инстанциясе булып түбәндәгеләр тора: өлкә һәм башка шундый дәрәҗәдәге судларның президиумнары; РФ Югары Суды Президиумы һәм граждан эшләре коллегиясе. Күзәтчелек инстанциясенең бурычлары һәм вәкаләтләре кассация инстанциясенекенә охшаш. Карау нәтиҗәләре буенча *карар* чыгарыла.

Икенче һәм өченче инстанцияләрдә тикшерү тәртибе, табигый ки, беренчегә караганда күпкә гадиләштерелгән (әле өченче инстанциядә икенчедән дә күбрәк), чөнки фактларны, эшнең торышын ачыклыйсы юк. Әмма барлык гамәлләр һәм аларның эзлеклелеге ГПК белән катгый билгеләнгән, граждан процессы принципларына суд карарының эчтәлегенә таләпләргә туры килә. Эшне *яңа ачылган хәлләр* (ягъни эшне карау вакытында булмаган һәм мәгълүм була алмаган хәлләр) буенча яңадан карау эшне беренче инстанциядә караган шул ук судта, кызыксынган як гаризасы яисә прокурор тәкъдиме буенча башкарыла. Мәсәлән, гражданин М.ны фатир милекчесе итеп тану турындагы карар шул тәртиптә юкка чыгарыла, чөнки соңыннан карар кабул итү өчен нигез булган сату-алу шартнамәсенең ялган икәнлеге ачыклана.

АРБИТРАЖ ПРОЦЕССЫ

Арбитраж процессы — эшләрнең арбитраж судында узу процессы ул. Алар барлык төбәкләрдә булдырылган һәм нигездә икътисади бәхәсләрне, бизнес өлкәсендәге бәхәсләрне, шулай ук гомуми судларда каралучы эшләргә охшаш (мәсәлән, йорт хуҗасы булу фактын ачыклау) башка эшләрне карый. (Фәкать арбитраж судында каралучы эшләр дә бар, әлбәттә, мәсәлән, банкротлык турында.)

Арбитраж процессы кагыйдәләре **РФ Арбитраж процессуаль кодексында** (АПК) тупланган. Яхшырак аңлау өчен арбитраж процессын граждан процессының үзенчәлекле тармагы итеп карарга мөмкин. Суд производствосы, процесс принциплары, якларның хокуклары һәм бурычлары, исбатлаулар һ.б. гомуми судлардагы шундыйларга охшаган, аңлашыла ки, үзенчәлекләре дә бар.

Әйтик, арбитраж судьясы якларны килештерү буенча чара күрергә бурычлы. Килешү мөмкин булмаганда гына суд тикшерүе башлана.

Арбитраж процессында шикаять белдерүдә дә үзенчәлек бар. Беренче инстанция карары бер ай дәвамында икенче — апелляция (латинча appellatio —мөрәҗәгать, шикаять) инстанциясенә шикаятьләнергә мөмкин, анда ул яңадан карала.

Апелляция суды карары кичекмәстән законлы көченә керә. Аңа ике ай вакытта кассация инстанциясенә шикаять белдерелә ала. Кассация инстанциясе булып округ федераль арбитраж суды тора (берничә төбәккә бер). Алар гомуми судның шундый ук инстанциясенә охшаш эш итәләр, ягъни шикаять белдерелгән суд актының законлылыгын һәм нигезләнгән булуын гына карыйлар.

Кассация инстанциясе карары (беренче һәм икенче инстанциянең законлы көченә кергән суд актлары кебек үк) 3 ай дәвамында күзәтчелек тәртибендә Югары Арбитраж судта (ЮАС) шикаятьләнә ала. Шул ук вакытта яңадан карау иң мөһим эшләргә генә рөхсәт ителә. Алар ЮАС Президиумында карала һәм түбәндәгеләр булганда гына юкка чыгарыла яисә үзгәртелә:

— арбитраж судлар тарафыннан аңлатылганда һәм кулланганда хокук нормаларының бертөрлелегә бозылса;

— башка эш буенча карар кабул итүгә комачауласа;

— билгесез затлар даирәсенең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен бозганда.

Шуны билгеләп үтү мөһим, ЮАС Президиумының аерым бер эшләр буенча карарлары шуңа охшашлы эшләрне караганда юнәлеш булып хезмәт итә.

Арбитраж судларның карарларын (билгеләмәләрен һ.б.)

яңа ачылган хәлләр буенча яңадан карау гомуми судларда шундый яңадан карауга охшаш.

СУД КАРАРЛАРЫН ҮТӘҮ

Дәгъваны канәгатьләндерү турында карарның законлы көченә кергәннән соң гомуми суд та, арбитраж суды да дәгъвачыга **башкарма кәгазь** — карарны үтәү турында боерык бирә. Дәгъвачы башкарма кагәзьне мәҗбүри үтәү турында үтенеч белән *суд приставлары хезмәтенә* (РФ Юстиция министрлыгының судларда тәртип тәэмин итү һәм суд карарларын мәҗбүри үтәтү буенча органнарының үзәкләштерелгән системасы) бирергә хокуклы. Шуннан соң *башкару производствосы* башлана («Башкару производствосы турында» һәм «Суд приставлары турында» Федераль законнар нигезендә). Менә монда инде суд приставы, суд карарын үти барып, акчаны кире кайтара, мөлкәтне ала, фатирдан чыгара, башка гамәлләр кыла.

ГАМӘЛИ ЙОМГАКЛАР

1 Барча кешеләр дә суд яклавына, судка мөрәҗәгать итү хокукына ия; бу хокуктан хәтта язмача баш тарту да гамәлдә булмый.

2 Суд яклавы тәртибе турындагы белемнәр сезгә киләчәктәге зурлар тормышында юнәлеш алырга ярдәм итәр. РФ ГПКда «Граждан суд производствосын җайга салучы «Башкару производствосы турында» һәм «Суд приставлары турында» федераль законнарда сез әлеге тематика буенча үзегез кызыксынган сорауларга җавап таба алырсыз.

3 Катлаулы гражданлык, гаилә һәм башка суд эшләре килеп чыкканда адвокат ярдәменә таяну яхшырак булыр, авырып киткәндә дә катлауланулар китереп чыгару белән янаган үз-үзеңне дәвалауга караганда табибка мөрәҗәгать итү хәерлерәк бит.

ДОКУМЕНТ

Россия хокук чыганакларыннан өзекләр.

РФ Конституциясенең 46.1 статьясы

Һәркемгә аның хокукларын һәм ирекләрен суд яклавы гарантияләнә.

РФ Граждан-процессуаль кодексының 2 статьясы

Граждан суд производствосы бурычлары булып, гражданлык, хезмәт яисә башка хокук мөнәсәбәтләре субъектлары булып торган гражданнарның, оешмаларның... башка затларның бозылган яисә дәгъваланучы хокукларын, ирекләрен һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау максатларында граждан эшләрен дөрес һәм үз вакытында карау һәм хәл итү тора. <...>

РФ Арбитраж процессуаль кодексының 2 статьясы

Арбитраж судларында суд производствосының бурычлары булып: 1) эшмәкәрлек һәм башка икътисади эшчәнлек башкаручы затларның бозылган яисә дәгъваланучы хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау <...> тора.

Документка сораулар һәм биремнәр

1. РФ Конституциясенең 46.1 статьясының һәм ГПК белән АПКның китерелгән статьялары нисбәте нинди? 2. Кодексларның әлеге статьяларын чагыштырыгыз, ГПК һәм АПК бурычларында нәрсә уртак һәм нәрсә аермалы булуын күрсәтегез. 3. ГПК һәм АПКның нинди нигезләмәләре үз вакытында карау бурычларын гамәлгә ашыруын исегезгә төшерегез.

ҮЗ-ҮЗЕҢНЕ ТИКШЕРҮ ӨЧЕН СОРАУЛАР

1. Процессуаль хокук гадел хөкемнең нигезе булып тора, дип әйтү дөресме? Нигә? 2. Граждан һәм Арбитраж процессларда «эштә катнашучы затлар» кемнәр алар? 3. Нәрсә ул процессуаль хокуклар? 4. Судка граждан-хокукый бәхәсне карау турында үтенеч белән мөрәҗәгать итү өчен нинди документ төзелә, һәм аның эчтәлеге нинди? 5. Суд карары җавап бирергә тиеш таләпләрне атагыз. 6. Нинди документ нигезендә суд карары мәҗбүри үтәлә?

БИРЕМНӘР

1. Петрухин үз фатирын Зайцевка бер елга наемга бирде. Шартнамәдә ике як та барлык бәхәсле мәсьәләләрне фәкать сөйләшүләр юлы белән хәл итәргә, судка мөрәҗәгать итмәскә булдылар. Бер ел узды, тагын бер ай үтте, ә Зайцев фатирны бушатмый. Петрухин үз фатирын бушатыр өчен нишләргә тиеш?

2. Минаев җир комитеты акты нигезендә Семеновтан җир кишәрлеген судлашып алды. Бер елдан әлеге актның ялган булуы ачыкланды. Бу факт җир комитеты хезмәткәренең ришвәт алган

өчен хөкем ителү приговоры белән ачыкланды. Җир кишәрлеген кире алу өчен Семенов нинди гамәлләр кылырга хокуклы булуын күрсәтегез.

3. Граждан суд процессында катнашучылар схемасын төзегез. Граждан суд процессының төп стадияләре схемасын төзегез.

ЗИРӘКЛӘР ФИКЕРЕ

«Ibi jus, ubi remedium — хокук кайда,
аны яклау чарасы да шунда».

Борынгы Римда мәгълүм әйтем

§ 26. Процессуаль хокук: җинаять процессы

Яшүсмерне тоткарлаган милиционерлар бу хакта аның ата-анасына хәбәр итәргә тиешме? Тоткарланган кеше адвокат булуын таләп итәргә хокуклымы? Нәрсә ул җинаять эзәрлекләве? Кем ул антлы утырышчы?

Җинаять хокукы белән танышып, сез җинаять кодексы (РФ УК) нинди гамәлләрне җинаять дип белдерүен һәм алар өчен нинди җәзалар билгеләвен белдегез. Бу параграфта УК нигезләмәләре ничек гамәлгә ашырылуын, җинаятьчеләрне фаш итү, аларны судка бирү һәм җәза билгеләү кагыйдәләрен белерсез. Алга таба сүз барачак җинаять-процессуаль хокук тармаклары нәкъ шундый. Алдагы дәрес багышланган граждан процессы тик суд тикшерүенә генә кагылса, җинаять процессы исә судка кадәрге производствоны — җинаять эше кузгатылуны һәм алдан тикшерүне дә үз эченә ала. Һәм материал белән танышып, сез, мөгаен, үзегез караган яки укыган, җинаятьчеләр фаш ителгән һәм хөкемгә тартылган детективларны да исегезгә төшерерсез. Хәзер моның нинди законнар буенча баруын да белерсез.

ПРОЦЕССНЫҢ ТӨП ПРИНЦИПЛАРЫ ҺӘМ КАТНАШУЧЫЛАРЫ

Бер үк вакытта гаепсезне гаепләмичә һәм хөкем итмичә, җинаятьчене ничек фаш итәргә һәм судка тартырга? Җинаять производствосы һәм җинаять процессының — җинаять эшләрен тикшерү һәм хәл итү буенча эшчәнлекнең төп бурычы шул була инде.

Җинаять эзәрлекләве (ягъни фаш итү һәм гаепләү эшчәнлеге) тоткарлау, тентүләр, арест һәм башка мәҗбүри булса да хокук һәм ирекләрне чикләү белән бәйле. Шуңа закон процесста

катнашучыларның гамәлләрен, хокукларын, бурычларын судка кадәрге стадиядә дә (сорау алу, тикшерү), судта да җентекләп җайга сала.

Җинаять производствосы кагыйдәләре **Россия Федерациясе җинаять-процессуаль кодексында (РФ УПК)** тупланган. Анда нормалар гына түгел, процессуаль документ формалары белән — карарлар, беркетмәләр һ.б. 232 (!) кушымта да бар.

Кодекста җинаять суд производствосының башлангыч нигезләмәләре яисә төп принциплары беркетелгән. Беренче чиратта гаепләүгә тартылуның булмавы атала, ягъни гадел җәзага тарту, гаепсезләрне аклау кебек үк, җинаять суд производствосы билгеләнешенә җавап бирә дип ассызыклана. Законлылык принцибы тикшерү һәм суд органнарының барлык гамәлләре законга таянган булырга тиешлеген аңлата. Граждан процессындагы кебек үк, гадел хөкем фәкать суд тарафыннан башкарыла. Шәхеснең абруен һәм намусын хөрмәт итү турындагы постулатның әһәмияте турында аңлатып тору кирәкме икән? Ул тикшерү барышында да, судта да беркем көч куллануга, газаплауга, түбәнсетүгә, мәсхәрәләүгә дучар ителә алмый. Шулай ук шәхеснең кагылгысызлыгы игълан ителә, моннан берәүне дә УПКда күрсәтелгән нигезләрдән башка тоткарларга (арест) ярамавы, ә нигез булганда — суд карарыннан тыш та 48 сәгатьтән артык тоткарламау зарурлыгы килеп чыга. Аталган кагыйдәләрне бозу ачыкланганда, тоткарланучы кичекмәстән азат ителергә тиеш. Барлык очракларда да саке астында тоту шартлары гомергә һәм сәламәтлеккә куркыныч янауны булдырмаска тиеш. Шулай ук торакның кагылгысызлыгын искә алып үтик, бу тентүләр, документларны алу һ.б. суд карары буенча гына рөхсәт ителә дигәнне аңлата (аерым очраклардан гайре). Гаепсезлек презумпциясе аеруча әһәмияткә ия, аның асылы шунда ки, гаепләнүче приговорда гаебенең раслануына кадәр гаепсез дип санала, ә киресен гаепләү ягы исбат итәргә тиеш. Яклау өчен суд процессында якларның ярышулары бик зур әһәмияткә ия, монда гаепләүче дә, яклаучы да суд каршында бертигез, үзләренекен исбатлау өчен тигез хокуклардан файдаланалар һ.б. Һәм, ниһаять, тагын ике принципны билгеләп үтик: шик астындагы, гаепләнүче, хөкем ителүче затка яклануга хокук һәм суд, вазифаи затларның процессуаль гамәлләренә шикаять белдерү мөмкинлеге тәэмин итү. Бу һәм аталмаган төп нигезләмәләрнең һәркайсы бик мөһим, чөнки граждан хокукларын һәм хөкемнең гаделлеген гарантияләргә тиешләр.

Законда процесста катнашучылар (субъектлар) санап үтелә һәм һәркайсының хокуклары һәм бурычлары билгеләнә. Сез, әлбәттә, процесста катнашучылар турында күпсанлы фильмнардан беләсез. УПК катнашучыларны өч төркемгә бүлә.

Беренче төркем — гаепләү ягыннан катнашучылар. Болар барыннан да элек дәүләт органнары һәм урындагы затлар (җинаять производствосын алар үзләре уздыра һәм мәҗбүр итүнең процессуаль чараларын куллана да инде), соңгысы хакында без сөйләшербез әле. Суд йә бер генә судьялы, йә (авыр һәм аеруча авыр җинаятьләрдә) өч судья составында яки антлы утырышчылар катнашында була. Прокурор тикшерүгә һәм сорау алуга күзәтчелек итә һәм судта гаепләүгә булышлык итә. Тикшерүче алдан, ягъни судка кадәр тикшерү үткәрә. Сорау алу органы, сорап тикшерүче кичектергесез тикшерү гамәлләре, шулай ук катлаулы булмаган эшләр буенча тикшерү уздыра (гадәттә бу ЭЭМ, МЧС органнары һәм хезмәткәрләре, ләкин башкалары да була). Зыян күрүче зат та шул ук яктан чыгыш ясый.

Икенче төркем — яклау ягыннан катнашучылар. Бу шик астындагы кеше, ягъни җинаять кылуда шик астына алынган зат (аңа карата инде тоткарлау һәм кисәтүнең башка чаралары кулланылырга мөмкин инде, шулай да ул байтак хокукларга ия: үтенечнамә белдерергә, күрсәтү бирүдән баш тартырга, яклаучы таләп итәргә һ.б.). Гаепләнүче — гаепләү белдергән зат, ягъни аңа карата гаепләнүче сыйфатында җәлеп итү турында карар чыгарылган кеше. Яклау өчен аңа тагын да киңрәк хокуклар бирелгән. Әйтик, ул кулга алыну (арест) очрагында яклаучысы белән бергә-бер, шуның өстенә беренче сорау алуга кадәр үк, очрашырга хокуклы (бу очрашуларның саны һәм дәвамлылыгы чикләнми), тикшерү тәмамлангач, эш белән таныша ала, гаепләү актын алуга хокуклы. Эш судка тапшырылгач, ул хөкем ителүче дип атала һәм судта гаепләүче белән бер үк хокукта була (процесстагы яклау вәкиле буларак), шулай ук соңгы сүзен әйтергә хокуклы. Яклаучы — шик астындагы, гаепләнүче яисә хөкем ителүченең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклаучы зат. Гадәттә ул адвокат. Ул якынча үз клиенты кебек үк процессуаль хокукларга ия.

Өченче төркем, граждан процессындагы кебек үк,— процессны уздыруга ярдәм итүче затлар: шаһитлар, экспертлар, белгечләр, тәрҗемәчеләр, пүнәтәйләр.

Процессның төп элементы булып исбатлау тора, хөкем карары шуңа нигезләнә. Болар гаепләнүче, зыян күрүче, шаһит, эксперт күрсәтүләре. Закон исбатлауга шулай ук әйберләрне, тикшерү һәм суд гамәлләре беркетмәләрен, башка документларны, аудио һәм видео язмаларны да кертә. Тагын бер кат басым ясап әйтик, гаепне исбатлау бурычы гаепләү ягына йөкләнә. Закон бозып алынган исбатлауның законлы көче юк. Гаепләнүченең тануы гына җитми. Ул башка исбатлаулар һәм эш хәлләре белән берлектә генә бәяләнә. (Сезнең ишеткәнегез

бардыр, Сталин репрессиясе елларында гаепне тану «исбатлау патшабикәсе» дип саналган, һәм аңа җәзалаулар ярдәмендә ирешкәннәр.)

ПРОЦЕССУАЛЬ МӘҖБҮР ИТҮ ЧАРАЛАРЫ

Тоткарлау. Күз алдына китерегез: сез урам буйлап барасыз һәм тротуар янында ишекләре ачып куелган буш автомобиль торуын күрәсез. Сез, кызыксынып, эчкә күз төшерәсез, һәм шул мизгелдә янәшәдә патруль машинасы килеп туктый, ике милиционер сикереп чыга һәм сезне эләктереп алалар. Баксаң, әлеге автомобиль урланган булган икән, ә сез шунда торасыз... Сезне, әлбәттә, бүлекчәгә алып китәләр... Милиционерлар закон буенча эш итәләрме? Тоткарланучының хокуклары нинди? УПК прокурор санкциясеннән башка тоткарлауны экстремаль очракта гына рөхсәт итә. Бу чакта 12 сәгать эчендә прокурорга хәбәр итү мәҗбүри. Бу чараның шактый авыр булуын исәпкә алып, аны куллану УПКда аталган очракларда гына рөхсәт ителә: әгәр — зат җинаять кылганда тотылса, йә зыян күрүче яки шаһитлар аңа күрсәтсә, тору урыны билгеле булмаса, шәхесе билгесез булганда һәм кайбер башка очракларда гына.

3 сәгать эчендә тоткарлау беркетмәсен төзергә кирәк (хокукларын аңлату турында тамга салып), 12 сәгать дәвамында гаиләсенә хәбәр ителергә, кичекмәстән сорау алынырга тиеш. Тоткарлау вакыты 48 сәгатьтән дә артык була алмый. Тоткарланучыга байтак хокуклар гарантияләнә: үтенечнамә белдерергә, яклаучы таләп итәргә һ.б.

Гаепләнүчегә кулланылучы **кисәтү чаралары** шулай ук УПКда күрсәтелгән: китеп бармау (бу торак пункттан) хакында кул кую; шәхси поручительлек (ышанычка лаек кешенең); залог; өй аресты; сак астына алу һ.б.

Соңгысы, иң авыры, УПКда әйтелгәнчә, суд карары буенча гына, җәзасы 2 ел ирегеннән мәхрүм ителергә мөмкин булган җинаять кылынган очракта, йомшаграк чара куллану мөмкин булмаганда, шулай ук качарга, тикшерүгә комачауларга һ.б. мөмкин булган затларга карата гына кулланыла.Сак астында тоту вакыты — 2 ай, ул суд тарафыннан бик сирәк очракларда гына озайтыла ала.

СУДКА КАДӘРГЕ ПРОИЗВОДСТВО

Җинаять производствосы җинаять эше кузгатудан башлана. Закон җинаять эшенең сәбәбен, нигезен һәм рәсмиләштерелүен аера. Сәбәп булып җинаять турында гариза, гаепне танып килү,

башкарылган яисә әзерләнүче җинаять турында хәбәр тора. Нигез — җинаять билгеләренә күрсәтүче җитәрлек белешмә булу. Рәсмиләштерү — җинаять эше кузгатылу турында карар (прокурор ризалыгы белән башлангыч сорау алучы яисә тикшерүче тарафыннан чыгарыла).

Җинаять эше кузгатылганнан соң, **алдан тикшерү** — башлангыч сорау алу, тикшерү башлана. («Алдан» термины суд өчен тикшерү материаллары нәкъ менә алдан тикшерү характерында: алар суд утырышында тикшерелә һәм бәяләнә. Хәтта махсус стадия — «Суд тикшерүе» дә бар. Хөкем карары аның нәтиҗәләренә нигезләнә дә инде. Ләкин бу хакта соңрак.)

Тикшерүчеләр уздыручы тикшерү гамәлләрен 2 төркемгә бүлеп карарга мөмкин: беришесе — тикшерүче карары, икенчеләре суд карары нигезендә башкарыла. Беренчесенә түбәндәгеләр керә: сорау алу, күзгә-күз очраштыру; тану, мәҗбүри алу (ягъни предметларны, документларны һ.б. тартып алу). Суд карары нигезендә түбәндәгедәр үткәрелү: сак астына алу, өй аресты; торакта тентү һәм / яисә мәҗбүри алу; телефон һәм башка сөйләшүләргә контроль һәм аларны яздыру һ.б.

Бу гамәлләрнең һәркайсын үткәрү тәртибе УПК белән регламентлана, шул исәптән һәр гамәл кылганнан соң төзелергә һәм гамәлдә катнашучылар, тиешле очракларда пүнәтәй тарафыннан да имзаланырга тиешле беркетмә формасы да күрсәтелә. Гамәлне уздыру тәртибе беркетмә формасы бозылганда йә имзалары булмаганда беркетмә исбатлау дип танылмый.

Гаепләү өчен җитәрлек дәлилләр туплагач, тикшерүче гаепле сыйфатында җәлеп итү өчен карар чыгара. Моннан соң 3 көн дәвамында судка кадәрге гаепләү бирелергә тиеш. Затка бу хакта алдан ук хәбәр итәләр, аның яклаучы чакырырга мөмкинлеге калырга тиеш. Тикшерү тәмамлангач, тикшерүче гаепләнүчене һәм яклаучыны эш материаллары белән таныштыра. Эш белән танышу чорында үтенечнамә һәм гаризалар бирелә һәм хәл ителә. Җинаять эше материаллары белән танышу беркетмәсе төзелә. Шуны аерым билгеләргә кирәк, югарыда күрсәтелгән кагыйдәләрнең берсе генә үтәлмәсә дә суд эшне үз каравына алмаячак.

Монда бер мөһим хәлне искә төшерү урынлы булыр. Закон УПКда граждан хокукларын яклаучы принциплар игълан итеп һәм нормалар формалаштырып кына калмый. Бер үк вакытта гражданнарга карата мәҗбүриләү чарасын законсыз кулланган өчен урындагы затларның җаваплылыгы һәм мондый гамәлләрдән зыян күрүчеләрнең зарарны каплатуга хокукы да билгеләнә. Әйтик РФ УКның «Гадел хөкемгә каршы җинаятьләр» дигән 31 нче бүлегендә тикшерү һәм суд вакытында куркытулар йә көч куллану гамәлләре өчен, бөтенләй гаепсез-

ләрне җинаять җаваплылыгына тарткан, законсыз тоткарлаган, сак астына алган, сак астында тоткан, күрсәтүләр бирүгә мәҗбүр иткән өчен җинаять җәзасы билгеләнә. РФ ГКның 1070 статьясы нигезендә законсыз хөкем итү, җинаять җаваплылыгына тарту, сак астына алу, беркая китмәү турында имза алу нәтиҗәсендә китерелгән зыян, шул исәптән мораль зыян, урындагы затларның гаебенә карамастан, казнадан каплана. Дөрес, сак астына алу, әгәр ул кисәтү чарасы буларак кулланылса гына, зыянны каплату өчен нигез була ала дип билгеләнде. Шуңа күрә, мәсәлән, җинаять кылуда шикләнеп юкка гына тикшерү изоляторында тотылган, ә аннан соң җинаять составы булмаганга чыгарылган гражданка Т.А.Аликинаның дәгъвасын кире кагалар. Суд үз карарында, аңа карата кисәтү чаралары кулланылмады, ә 1070 статьяда тоткарлау искә алынмый, дип яза. Карар РФ Югары Судына кадәр барлык инстанцияләр тарафыннан хуплана. Әмма Т.А.Аликина шикаяте буенча Конституция Суды 2003 елның 4 декабрендәге Билгеләмәсендә аңлатканча, зыянны каплау өчен нигез булып законсыз тоткарлау да тора, чөнки рәшәткә артына законсыз утыртылган кеше, процессуаль рәвешкә карамастан, шулай ук интегә. Әмма без алдан карауны тәмамлауга килеп җиттек.

Танышудан соң тикшерүче гаепләү йомгагы төзи, анда гаепләнүче, җинаять турында белешмәләр, гаепләү формулировкасы, гаепләү һәм яклау дәлилләрен бәян итү һ.б. була. Документ эш белән бергә прокуратурага җибәрелә.

Прокурор тагын бер кат эшне тикшерә, ул гаепләү йомгагына үзгәреш кертергә, эшне тикшереп бетерүгә кире кайтарырга, ә нигез булганда эшне туктатырга хокуклы. (Эшне туктату нигезләре УПКда күрсәтелгән. Алар: гаепләнүченең җинаятьтә катнашы булмавы; җинаять вакыйгасы булмау (мәсәлән, гаепләүче үтергән дип саналган кеше исән-сау булып чыга); гаебе булмау; җинаять эзәрлекләве күптәнлек вакыты чыгу һ.б. (Шуны билгеләп үтү мөһим, шундый хәлләрдә эш бөтенләй кузгатылырга тиеш түгел.)

Әгәр прокурор гаепләү йомгаклавы белән килешә икән, ул аны раслый һәм эшне судка җибәрә. Гаепләү йомгаклавы күчермәсе гаеплегә мәҗбүри бирелә, ә аның вәкиленә һәм зыян күрүчегә сорасалар гына бирелә.

СУД ПРОИЗВОДСТВОСЫ (ЭШНЕҢ СУДТА ҮТҮЕ)

Ул эшнең судка керү мизгеленнән эзерлек стадиясе белән башлана. Бу стадиядә, граждан судындагы кебек үк, судья

эшнең асылда карауга әзер булуын берүзе хәл итә. Аерым алганда, түбәндәгеләрне ачыклый: гаепләү йомгаклавының күчермәләре тапшырылганмы; кисәтү чарасы юкка чыгарылырга яисә үзгәртелергә тиешме; шикаятьләр һәм үтенечнамә канәгатьләндерелә аламы һ.б.

30 көн эчендә, әгәр гаепләнүче сак астында булса, 14 көндә судья алдан тыңлаулар билгеләргәме (нигезе булса), эшне кире кайтарыргамы, туктатып торыргамы яисә туктатыргамы яки аны антлы утырышчылар катнашында карарргамы яисә суд утырышы билгеләргәме (әгәр эш карауга әзер булса) икәнлеген хәл итәргә тиеш.

Суд тикшерүе, нигездә, сез граждан процессында танышкан принциплар (хәбәрдарлык; ярышучанлык; якларның тигезлеге; беркетмә алып бару һ.б.) буенча уздырыла. Ул билгеләнгән вакыттан 14 көннән дә соңга калмыйча башланырга тиеш. Гаепләүче булып прокурор чыга. Яклаучы, кагыйдә буларак, адвокат. Суд бер судья составында эшли, ә авыр җинаятьләр очрагында — 3 судья.

Суд утырышы граждан процессындагы кебек үк стадияләр уза. Әзерлек өлешеннән соң суд тикшерүе башлана.

Суд тикшерүе прокурорның гаепләү йомгаклавын бәян итүеннән башлана. Хөкем ителүче аңа гаепләүнең аңлашыламы икәнлеге турындагы һәм ул үзен гаепле итеп таныймы дигән сорауларга җавап бирә. Яклар бер-берсенә сорау бирергә хокуклы. Аннан соң хөкем ителүчедән сорау алалар.

Аннары шаһитлар сорауларга җавап бирә. Судья аларның һәркайсының шәхесен ачыклый, һәркайсына хокуклары, бурычлары һәм ялган күрсәтмә биргән өчен җаваплылыгы аңлатыла (бу хакта алар беркетмәдә кул куя).

Шуны билгеләп үтәргә кирәк, шаһитлардан сорау алу бик гади нәрсә түгел. Юридик вуз студентларына җинаять процессы буенча бер лектор белән булган мисалны еш сөйләп күрсәтәләр: лекция башланыр алдыннан портфеленнән язмалар алганда ул очраклы гына бер әйбер чыгарып, кафедрага куя. Лекция тәмамланыр алдыннан бу әйберне алып куя һәм студентларга аның зурлыгын, рәвешен, төсен һ.б. тасвирларга тәкъдим итә. Болар язылган кәгазь битләрен җыйгач, ул әйберне яңадан урынына куя һәм кайбер җавапларны укый. Алар бер-берсеннән шулкадәр аерыла ки, залдагылар егыла-егыла көлә... Юристлар арасында шундый әйтем дә бар: «Шаһит кебек ялганлый». Һәм бу аңлашыла да: психик үзенчәлекләре төрле булганлыктан, төрле кеше вакыйганы төрлечә кабул итә. Шуның өстенә шаһит ялгышып кына калмый, үзе кызыксынган да була, ә кайчак куркытыла да. Шулай итеп шаһитларның күпсанлы күрсәтмәләреннән, җитмәсә, алар каршылыклы да булса,

хакыйкатьне ачыклау җиңел бурыч түгел. Шуңа шаһитлар күрсәтүләре башка исбатлаулар белән бергә бәяләнә, соңгылары шулай ук суд тикшерүе барышында өйрәнелә.

Суд тикшерүе тәмамланганнан соң якларның фикер алышуына (ягъни гаепләүче һәм яклаучы чыгышларына) күчәләр, аннан соң якларның репликалары башлана, анда һәркем башкалар дәлилен кире кага ала. Репликалардан соң хөкем ителүченең соңгы сүзе яңгырый.

Тикшерү хөкем ителүченең гаеплеме-түгелме икәнлеге турында һәм аңа җәза бирү йә тиешенчә аклау хакында суд карары чыгару белән тәмамлана. Карар чыгару һәм гадел хөкемне игълан итү граждан судындагы кебек башкарыла. Суд карары структурасы һәм формаль эчтәлеге шулай ук УПКда регламентланган.

Хөкем, граждан судындагы карар сыман, Россия Федерациясе исеменнән чыгарыла. Җәза РФ УК нигезендә билгеләнә. Хөкем, карар кебек үк, әгәр шикаять белдерелмәсә, 10 тәүлектән закон көченә керә. Шикаять белдерү тәртибе дә охшаш. Кассация тәртибендә шикаять өлкә, шәһәр һ.б. судының җинаять эшләре буенча суд коллегиясенә бирелә. Башка җинаятьләр граждан эшләрендәгечә үк инстанцияләр буенча шул ук тәртиптә уза.

Карар кебек үк, җәмәгать судьясы чыгарган хөкемгә (аның судына максималь җәза вакыты 3 елдан артмаган җинаятьләр генә кертелә, әле анысы да законда күрсәтелгән искәрмәләрдән гайре) кассация инстанциясенә кадәр апелляция тәртибендә шикаять белдерелергә мөмкин, ул чакта эш бер судьялы район суды составында яңадан диярлек карала. Хөкем яңа ачылган хәлләр буенча карарга охшашлы шикаятьләнә.

АНТЛЫ УТЫРЫШЧЫЛАР СУДЫ

Антлы утырышчылар суды иң демократик суд институтларының берсе дип санала, ул хөкемнең гаделлеген мөмкин кадәр югары дәрәҗәдә тәэмин итәргә чакырылган: унике кешедән торган коллегия судка тапшырылган исбатлауларны төрле яктан һәм бәйсезрәк бәяли ала. Хакимияткә дә, кызыксынган затларга да унике кешегә басым ясау авыррак. Хөкем ителүче бер судья башбаштаклыгыннан күбрәк якланган, һәр кеше кебек үк, ул да ярсырга, үзен начар хис итәргә, ә кайчакта хәтта кызыксынган яки куркытылган һ.б. булырга мөмкин.

Россиядә антлы утырышчылар суды край, өлкә һ.б. судлар компетенциясенә кертелгән аеруча авыр җинаятьләрне һәм фәкать гаепләнүче үтенече буенча гына карый.

Антлы утырышчылардан юридик белемле булу таләп ителми. Аларга эшнең хокукый мәсьәләләрендә тикшерену йөкләнми. Алар фәкать өч, ләкин иң мөһим мәсьәләгә җавап бирергә тиеш: 1) аны кылуда хөкем ителүче гаепләнгән гамәл булуы исбатландымы; 2) бу гамәлне хөкем ителүче кылган дип исбатландымы; 3) хөкем ителүче бу җинаятьне кылуда гаеплеме? Әгәр хөкем ителүче гаепле дип танылса, дүртенче мәсьәләгә җавап бирергә кирәк була: хөкем ителүче кызгануга лаекмы?

Антлы утырышчыларның бәйсезлеген, объективлыгын һәм аларга якларның ышанычын закон махсус чаралар белән тәэмин итә. Беренчедән, антлы утырышчыларны сайлап алу белән: судта булган гомуми исемлектән очраклы сайлап кимендә 20 кешелек алдан төзелгән исемлек ясала. Икенчедән, баш тарту хокукы белән: утырышчыга кандидат үз-үзен кире кагарга хокуклы, ә процесс якларның һәркайсы бер мотивацияләнгән, ике мотивацияләнмәгән кире кагу ясарга (мәсәлән, бирелгән исемлектән болай гына сызып ташларга) хокуклы. Өченчедән, коллегияне формалаштыру тәртибе: кире какканнан соң, барлык исемлектә калучыларның ундүрте генә калдырыла, аларның 12 се коллегия составын тәшкил итә, 2 се запаста була. Запастагылар шулай ук суд утырышында катнаша һәм коллегия әгъзалары составтан чыккан очракта, аларны алыштыра (югыйсә процессны туктатырга һәм яңадан башларга туры килер иде, чөнки эшне бар состав карарга тиеш). Ант бирү аеруча кызыклы, анда утырышчылар «намуслы һәм гадел эш итәргә, гаеплене акламаска, гаепсезне җәзага тартмаска» ант итәләр. Ант тантаналы шартларда бирелә: киңәшмә бүлмәсендә сайланган старшина утырышлар залында текстны укый һәм утырышчыларның һәркайсы: «Мин ант итәм»,— дип кычкырып әйтә. Барысы да аягүрә басып тыңлый. Чынлап әйткәндә, шулай ант итүдән «антлы утырышчылар» исеме килеп чыга да. Утырышчыларның объектив булуларына башка нормалар да этәргеч бирә. Мәсәлән, киңәшмә бүлмәсендәгеләрнең сер булуы (тикшерү барышын башкаларга сөйләүне тыю) һ.б.

Утырышчылар коллегиясе кабул иткән карар вердикт (латинча *vera dictum* — дөрес әйтелгән) дип атала. Санап үтелгән барлык чаралар нәкъ менә коллегия «дөрес әйтсен», ягъни гадел карар кабул итсен өчен кирәк.

УПКның кайбер башка нигезләмәләре дә шуңа этәргеч бирергә тиеш. Аерым алганда, утырышчыларның хокуклары турындагылары. Дөрес карар кабул итү өчен аларның хокуклары җитәрлек. Мәсәлән, барлык хәлләрне тикшерүдә, документларны, әйберләтә дәлилләрне карауда катнашу, язмалар алып бару һәм киңәшмә бүлмәсендә алардан файдалану һ.б. хокуклар.

Суд утырышы үзе гади судтагы принциплар буенча ук алып барыла, ләкин антлы утырышчылар катнашуыннан килеп чыккан үзенчәлекләр бар. Суд яклар катнашында утырышчыларга сорау битендә сораулар формалаштыра. Судья аны старшинага бирә, һәм барлык җаваплар шул кәгазь битендә теркәлә. Моннан тыш, коллегия киңәшмә бүлмәсенә чыкканчы, судья юлау сүзе әйтә, анда ул утырышта булганнарны йомгаклый, хөкем ителүче гаепләнүче законны, вердикт чыгару кагыйдәләрен, киңәшмә үткәрү, тавыш бирү тәртибен һ.б. аңлата. Шул ук вакытта судья хөкем ителүченең гаебе турында үз фикерен әйтергә хокуклы түгел.

Процесста үзәк урынны, үзегез дә аңлаганча, вердикт били. Аны суд залында антлы утырышчылар старшинасы игълан итә. Ул сорашу кәгазе буенча суд сорауларын һәм коллегия җавапларын укый. Вердикт, беркетмәгә кушып кую өчен, судьяга тапшырыла.

Аклау вердикты игълан ителгәндә, хөкем ителүче кичекмәстән сак астыннан азат ителә. Гаепләү вердикты игълан ителгәннән соң, яклар катнашында вердиктның нәтиҗәләре буенча фикер алышу уздырыла, һәм алга таба барысы да, хөкем карары чыгаруны һәм игълан итүне дә кертеп, барысы да гадәти судтагы кебек бара.

ГАМӘЛИ ЙОМГАКЛАР

1 УПК нормалары җинаятьчеләрне фаш итүгә дә, гражданнар хокукларын яклауга да юнәлтелгән. Моның өчен УПК мәҗбүриләү чараларын куллануны катгый регламентлый, гражданнарга киң хокуклар бирә. Әлбәттә, бу хокукларның барысын да һәм төрле нечкәлекләрне юристлар гына белә ала. (Күптән түгел тикшерүчеләр һәм прокурорлар УПК буенча биргән 900 сорауга җаваплар китап булып чыкты. Димәк, аларга да барысы да ачык түгел икән!) Ә сезгә кайберләрен генә булса да истә калдырырга кирәк. Мәсәлән, милиция, тикшерү һәм прокурорның теләсә нинди гамәлләренә шикаять булдырырга мөмкин. Мәҗбүриләү чараларын законсыз кулланган өчен гаепле җавапка тартыла. Шул ук вакытта зыян күрүче урындагы затларның гаебенә бәйсез рәвештә зыянны, шул исәптән мораль зыянны каплауны таләп итәргә хокуклы.

2 Балигъ булмаганны тоткарлаганда, милиция ата-анага хәбәр итәргә тиеш.

3 Һәм квалификацияле яклауга хокук бик мөһим: шунда ук адвокат булуны таләп итәргә кирәк (тоткарлау вазгыятенә

эләккән һәр кеше моны исендә тотарга тиеш). Беренче сорау алуга кадәр үк булса, тагын да яхшы.

4 Теләсә нинди хөкем карарына шикаять белдерергә була, әгәр ул нигезләнмәгән, законсыз һәм гаделсез булса, юкка чыгарылырга тиеш.

ДОКУМЕНТ

РФ Конституциясеннән.

2 бүлек. Кеше һәм граждан хокуклары һәм ирекләре.

«Хөкем итүне гамәлгә ашырганда федераль законны бозып алынган дәлилләрдән файдалануга юл куелмый». (50.2 статья)

«Җинаять кылуда һәр гаепләнүче,аның гаепле булуы федераль законда каралган тәртиптә исбатланганчы һәм закон көченә кергән суд карары белән билгеләнгәнче, гаепсез дип санала». (49.1 статья)

«Гаепләнүче үзенең гаепсезлеген исбатларга тиеш түгел». (49.2 статья)

«Беркем дә үз-үзенә, иренә яисә хатынына һәм даирәсе федераль закон белән билгеләнә торган якын туганнарына каршы шаһитлык кылырга бурычлы түгел». (51.1 статья)

Документка сораулар һәм биремнәр

1. Конституциянең әлеге статьялары төп мәгънәсен, төп идеяне нидә күрәсез? 2. Эчтәлеге буенча әлеге сатьялар процессуаль хокукка карый. Сез ничек уйлыйсыз, нигә бу процессуаль нигезләмәләр кодексларында гына калмыйча, Конституциягә, илнең Төп законына кертелгән? 3. Китерелгән статьялар нигезләмәләрен гамәлгә ашыручы җинаять процессы принципларын һәм кагыйдәләрен исегезгә төшерегез.

ҮЗ-ҮЗЕҢНЕ ТИКШЕРҮ ӨЧЕН СОРАУЛАР

1. Җинаять җаваплылыгы суд производствосы кагыйдәләре нинди законнар актында тупланган? **2.** «Гаепләнүче» терминын ачып бирегез һәм аңа УПК биргән төп хокукларны атагыз. **3.** Сез процессуаль мәҗбүр итүнең нинди чараларын беләсез? **4.** Сез тоткарлау турында нәрсә беләсез? Ул нинди очракларда кулланыла? Тоткарланучының нинди хокуклары бар? **5.** Тикшерү

гамәлләре нинди төркемнәргә бүленә? Аларның һәркайсына нәрсәләр кирә? **6.** Хөкем карары нинди өч таләпкә җавап бирергә тиеш? Бу таләпләрне шәрехләгез. **7.** Нигә утырышчылар антлы дип атала? **8.** Антлы утырышчылар коллегиясе нинди сорауларга һәм нинди документта җавап бирергә тиеш?

БИРЕМНӘР

1. Суд утырышында яклаучы, янәсе, тентү вакытында хөкем ителүчедә табылган, ләкин тентү беркетмәсенә кертелмәгән йокы даруы салынган тартмачыкны дәлилләр исәбеннән төшереп калдыру турында үтенечнамә бирә. Хөкем ителүче әлеге тартмачык аныкы булуын кире кага. Бу үтенечнамә буенча суд нинди билгеләмә чыгарырга тиеш? Нигә?

2. Тормыштан, әдәбияттан, фильмнардан сезгә мәгълүм булган җинаять суд производствосы принциплары гамәлдә тормышка ашырылган вакыйгаларны исегезгә төшерегез.

3. Тикшерүче гаепләнүче дачасында урланган иконалар саклануы турында хәбәр ала. Тикшерүченең процессуаль гамәлләре нинди булырга мөмкин?

4. Антлы утырышчылар катнашында суд утырышы барганда, аларның берсе авырып китә, һәм «ашыгыч ярдәм» аны хастаханәгә илтә. Утырыш дәвам итә аламы? Судья нишләргә тиеш? Бер үк вакытта ике яисә өч утырышчы авырса нишләргә?

ЗИРӘКЛӘР ФИКЕРЕ

«Ике якны да тыңламый торып, хөкем карары чыгарма».

Солон (б.э. кадәр 640–559 еллар), үз законнары белән мәгълүм Афина хакиме

§ 27. Процессуаль хокук: административ юрисдикция, конституциячел суд эше

Кибет директоры сатучыларга штраф билгели һәм сала аламы? Участок милиционерының шаярган яшүсмерне «куркытыр өчен генә» берәр тәүлеккә чоланга бикләп куярга хакы бармы? Тамбовта яшәүчегә Россия Конституция Судына мөрәҗәгать итү хокукы бирелгәнме?

Алдагы дәресләрдә сез граждан һәм җинаять хокук бозулары буенча суд эше белән таныштыгыз. Хәзер сүз административ хокук бозулар буенча эш турында, административ юрис-

дикция (латинча *iurisdictio* — хөкем итәргә — фактларга юридик бәя бирү, җәза билгеләү вәкаләтләре) турында барачак.

АДМИНИСТРАТИВ ЮРИСДИКЦИЯ

Административ хокук бозуларны карау һәм административ җәза билгеләү турында закон нормалары **Россия Федерациясенең Административ хокук бозулар турында кодексында (РФ КоАП)** тупланган.

Бу кодекс матди хокук та, процессуаль хокук нормаларын да үз эченә ала (УК һәм УПК берләштерелгән сыман).

Административ хокук бозулар турындагы хокук бозуларны карарга вәкаләтле органнар КоАПта билгеләнгән. Болар барыннан да бигрәк судлар, алар иң мөһим эшләрне карыйлар һәм административ җәза бирү турында башка органнар карарларына шикаять белдергәндә соңгы инстанция булып торалар. Аннары — балигъ булмаганнар эшләре буенча район комиссияләре, район административ комиссияләре. Җәмәгать тәртибен бозу буенча эшләрнең күпчелеген Эчке эшләр министрлыгы (ЭЭМ) органнары, аерым алганда милиция бүлекләре, ЮХИДИ һ.б. башлыклары (урынбасарлары) карый.

Җәмәгать тормышы эшчәнлегенең төрле өлкәләрендәге (транспортта, төзелештә, балыкчылыкта, янгын куркынычсызлыгында һ.б.) эшләрне карау бу өлкәләрдә дәүләт идарәсен, күзәтчелеген тормышка ашыручы органнарга (урындагы затларга) йөкләнгән. Аларга түбәндәгеләр керә: салым, янгын, санитар һәм башка инспекцияләре, балык саклау органнары, су, һава һәм башка транспорт белән идарә итүче ведомство органнары һ.б. Һәр ведомство махсус боерык белән мондый эшләрне карарга вәкаләтле органнарын һәм вазифаи затларын билгели. Бу карау ничек баруы турында алдарак сөйләшербез.

Административ җаваплылык субъектлары булып: гражданнар (16 яшьтән); урындагы затлар (оешма җитәкчеләре һ.б.ш.); юридик затлар тора ала. Шул ук вакытта Кодекста бер үк төрле хокук бозулар өчен, бу затларның кайсысы әлеге хокукны бозуына карап, штрафның төрле күләмнәре билгеләнгән. Мәсәлән, җир кишәрлеген үз белдегең белән биләгән өчен гражданнарга штраф хезмәт өчен түләүнең 5 тән алып 10 минималь күләменә (МРОТ) кадәр, ә урындагы затларга — 100 дән алып 200 гә кадәр МРОТ. Һәм, әлбәттә, тикшергәндә хокук бозучының гаебе, ягъни әлеге хокук бозу алдан уйлап яисә җинаятьчел саксызлык буенча башкарылуы исбат ителергә тиеш.

Хокук бозучыларга карата кулланылырга мөмкин булган **административ җәзалар** шулай ук КоАПта санап үтелә. Иң

йомшагы — кисәтү. Иң киң таралганы — штраф: гражданнар өчен — 25 МРОТка кадәр, урындагы затларга — 50, юридик затларга — 1000 МРОТка кадәр. Ә кайчакта (валюта, таможня һәм кайбер башка хокук бозулар) урындагы затларга — 200, юридик затларга — 5000 МРОТка кадәр. Шулай ук хокук бозу предметын (мәсәлән, контрабанда сигаретлары партиясе) тартып алу яисә *конфискацияләү, махсус хокуктан* (мәсәлән, машина йөртүче хокукы) *мәхрүм итү*. Административ кулга алу (мәсәлән, вак хулиганлык өчен 15 тәүлеккә кадәр), *Россия чикләреннән чыгарып җибәрү* (законсыз мигрантларны) дә мөмкин. Шуны әйтик, кисәтү һәм штрафлардан тыш барлык башка җәзалар фәкать судта билгеләнә.

Административ хокук бозулар турындагы эшләр буенча *хөкем эшен тәэмин итү чараларына* КоАПта аерым бүлек бирелгән. Эш шунда ки, кайбер очракларда махсус тәэмин итү чараларыннан башка җәза үтәтелә алмас, хәер, процесс үзе дә башланмас иде. Аларны кабул итү административ органнар хезмәткәрләренең эш үзенчәлекләреннән килеп чыга, аларга эчкечеләр, хулиганнар, браконьерлар һ.б. эш итәргә туры килә бит. Әйтик, әлеге чаралар арасында *бүлекчәгә китерү* бар. (Мәсәлән, аракы эчеп тавыш чыгаручыны.) Аннан соң *административ тоткарлауны*, әйтик, ирекләрен кыска вакытлы чикләүне атыйк. Ул 3 сәгатькә кадәр, сирәк очракларда — 48 сәгатькә кадәр рөхсәт ителә (чик бозу, арест билгеләнергә һ.б. мөмкин булган эшләр буенча). Тоткарланучы соравы буенча иң тиз арада аның туганнарына, эш һәм уку урыны буенча администрациягә, шулай ук яклаучыга хәбәр ителә. Балигъ булганнарны тоткарлау турында аның әти-әнисенә яки законлы вәкилләренә хәбәр итү *мәҗбүри*. Шулай ук *шәхси үзен һәм әйберләрен карау, транспорт чарасын һәм документларын тикшерү* күздә тотыла. Бу гамәлләр пүнәтәйләр катнашында башкарыла. Шәхси карап тикшерү шул ук җенестәге кеше тарафыннан үтәлә. *Медицина такымлавы* да кулланыла, мәсәлән, исерек булу-булмавы тикшерелә. (Юкса хокук бозучы исерек икәнлекне ничек исбатларга?) Шулай ук *товарга, транспорт чарасына* һ.*б. арест салу* каралган. Күрсәтелгән чаралар куллануның һәркайсына беркетмә төзелә. Шуны әйтеп китик, белә торып законсыз тоткарлау яисә кулга алу җинаять булып тора (РФ УКның 301, 305 статьялары буенча).

Административ хокук бозулар эшләре буенча *производствода катнашучылар* һәм аларның хокуклары КоАП белән УПКдагы кебек үк билгеләнә. Эшне караучы органнан тыш бу барыннан да элек хокук бозучы, ансыз эш бөтенләй булмас иде. (Шуны аңларга кирәк, монда «хокук бозучы» термины шартлы гына кулланыла, чөнки бу зат әле хокук бозуда гаепләнә генә.)

Аңа УПК буенча кебек үк хокуклар бирелә — эш белән танышырга, адвокат чакырырга, үтенечнамә белдерергә. Аңа, һичшиксез, эшне тикшерү урыны һәм вакыты һ.б. турында хәбәр ителергә тиеш.

Икенче мөһим катнашучы — хокук бозучы гамәлләре белән зыян китерелгән зат, зыян күрүче. Эш башкаруга УПК буенча сезгә инде мәгълүм категорияләр — шаһитлар, экспертлар, пүнәтәйләр, тәрҗемәчеләр җәлеп ителә. Прокурор да катнашырга мөмкин, ләкин бу инде аеруча катлаулы яисә әһәмиятле эшләрдә генә була. Әлеге затларның хокуклары һәм бурычлары аларның УПК буенча адашларыныкы кебек үк, ләкин билгеле инде КоАП үзенчәлекләре белән. Әйтик, шаһит ялган күрсәтүләр биргәндә җинаять җаваплылыгына түгел, ә административ җаваплылыкка тартыла. Ә бу инде бөтенләй башка нәрсә...

Исбатлау предметы, дәлилләр һәм *аларны бәяләү* УПКдагыга охшаш.

Административ хокук бозу турындагы эш буенча производство, җинаять хокук бозуындагы кебек *бернечә стадия* уза: эш кузгату, тикшерүгә әзерлек, тикшерү, карар чыгару һәм игълан итү, башкару. Кайбер катлаулы эшләр буенча *административ тикшерү* уздырыла.

Эш кузгату өчен сәбәп булып гамәлне турыдан-туры ачу тора. (Мәсәлән, ЮХИДИ инспекторы исерек йөртүчене туктата.) Гариза яки хәбәр алу да сәбәп була ала. Хокук бозу ачылганда беркетмә төзелә, менә шул эш кузгату була да инде.

Беркетмәнең эш өчен әһәмиятен исәпкә алып, закон аның эчтәлеген җентекләп регламентлаштыра (вакыты һәм урыны, беркетмә төзүче, хокук бозучы, шаһитлар турында белешмә, хокук бозу вакыйгасының вакыты һәм урыны, җаваплылыкны билгеләүче КоАП статьясы, хокук бозучы яисә, ул балигъ булмаса, аның законлы вәкиле аңлатмасы һ.б.). Хокук бозучыга, эштә катнашучы башка затларга КоАП буенча аларның хокуклары һәм бурычлары аңлатыла, бу хакта беркетмәгә язып куела. Беркетмәгә аны төзүче зат һәм үзенә карата эш кузгатылган зат кул куя. (Шуны исегездән чыгармагыз, беркетмә эшне аннан соңгы тикшерүдә төп документ булып тора. Әгәр дә сезгә нинди дә булса күңелсез хәлгә тарырга туры килсә һәм беркетмә сезгә карата төзелсә, аны карамый гына кул куярга ашыкмагыз. Дөрес язылганмы икәнлеген белү өчен игътибар белән укып чыгыгыз. Дөрес булмаса, кул куймагыз, беркетмәдә үк үзегезнең каршы фикерегезне язсагыз, тагын да яхшы.) Хокук бозуларның әһәмияте зур булмаганда (әйтик, трамвайда билетсыз барганда) беркетмә төзелми.

Эшне карауга әзерләнгәндә, урындагы зат материалларны законлылыгын һәм җитәрлеген тикшерергә бурычлы.

Карауның урыны һәм вакыты билгеләнә, шаһитлар чакырыла, өстәмә материал соратып алына һ.б. Ләкин барыннан да элек беркетмәнең законлылыгы тикшерелә, әгәр ул законсыз булса, җитди хаталар белән төзелсә, беркетмә төзүчегә кире кайтарыла.

Кагыйдә буларак, эшне карау хокук бозган районда була, ә кайчакта, хокук бозучы үтенече буенча, аның яшәү урынына да күчерелергә мөмкин.

Эшне карау тәртибе УПК буенча булганга караганда күпкә гадирәк, ләкин шулай ук законлы, нигезле һәм гадел карар чыгаруга юнәлтелгән. Утырышта нинди эш каралуы игълан ителә, кем һәм нинди закон нигезендә җавапка тартылуы әйтелә, якларның килүе тикшерелә, катнашучыларның хокуклары аңлатыла, административ беркетмә укыла, хокук бозучы дип уйланылган зат, зыян күрүче, шаһитлар тыңлана, дәлилләр тикшерелә һ.б. Утырышның беркетмәсе алып барыла. Карау тәмамланганнан соң, карар игълан ителә. Ул ике төрле була: 1) административ җәза бирү турында һәм 2) эш буенча производствоны туктату.

Карарга 10 көн дәвамында югарыдагы вазифаи затка яки судка шикаять бирелергә мөмкин. Шикаятьне карау беренче инстанциядәге кебек үк уздырыла. Шикаять буенча карарны да югарырак вазифаи затка яисә югарырак судка шикаятьләргә мөмкин.

Законлы көченә кергән карар барлык граждан һәм урындагы затлар өчен **мәҗбүри** һәм **мәҗбүр итеп үтәтелергә** тиеш. Мәсәлән, штраф 30 көн дәвамында ихтыяри түләнмәсә, аны мәҗбүриләп, хокук бозучының эш хакыннан басып калу яки милкәте исәбеннән кайтарып алалар. Конфискацияләнгән әйберләр (мәсәлән, чит илдән законсыз кертелгән сигарет партиясе) дәүләт кеременә тапшырыла һ.б.

КОНСТИТУЦИЯЧЕЛ СУД ЭШЕ БАШКАРУ

Конституция Судында (КС) суд производствосы шулай атала. РФ КСда ул РФ Конституциясе, «РФ Конституция Суды турында» Конституциячел закон һәм Конституция Суды Регламенты нигезендә алып барыла.

Төбәкләрдә конституция (устав) судлары эшне төбәк конституцияләре (уставлары) һәм үз регламентлары нигезендә алып баралар.

Шуны билгеләп үтик, башка суд системаларыннан (гомуми юрисдикция, суд-арбитраж) аермалы буларак, РФ Конституция Суды һәм төбәкләрнең шундый судлары бердәм вертикаль тәшкил итми: РФ Конституция Суды төбәктәгеләре өчен

югарыдагысы булып тормый, аларның карарларын яңадан карау хокукы юк.

Әмма федераль һәм төбәк судларының билгеләнеше бер үк: икесе дә конституциячел контроль суд органнары булып тора. Алар Төп законның иң югары акт булуын тәэмин итәргә, ягъни федераль (төбәк) законнарының һәм норматив актларның Конституциягә (Уставка) каршы килмәвенә ирешергә чакырылган. Моңа актның конституциячел булу-булмавын карау аша ирешәләр. Суд эшен алып бару һәр икесендә бер үк төсле.

Конституциячел суд эшен алып баруның **төп принциплары** башка судлардагыча,— бәйсезлек, хәбәрдарлык, ярышучанлык һ.б.

Конституциячел (Устав) судлары эшләрне үз инициативалары буенча карарга хокуклы түгел, ә фәкать эшләрнең әлеге категориясе буенча мөрәҗәгать итәргә хокукы булган орган (зат) мөрәҗәгате буенча гына карый ала.

Законның яки башка акт Конституциягә туры килүе турындагы (ягъни актның конституциячеллеге) мәсьәләне караганда, суд аның формасы, кабул ителү процедурасы һ.б. буенча туры килүен билгели. Башкача әйткәндә, Суд хокук мәсьәләләрен хәл итә, сәяси проблемаларны карамый, факттагы хәлләрне тикшерми (әгәр мондый тикшеренү башка органнар компетенциясендә булса). Мәсәлән, РФ Конституция Судына бер төркем журналист Дәүләт Думасына сайлаулар турындагы законның бер нигезләмәсе конституциячел түгел дип тануны сорап мөрәҗәгать итә. Бу нигезләмә депутатлыкка кандидат эшчәнлеге турындагы теләсә нинди мәгълүматны сайлау алды агитациясе дип билдерә. Болай якын килү фактта мәгълүматны тыю булып тора. Конституция Суды законның әлеге өлешнең конституциячеллеген, ягъни Конституциянең мәгълүмат иреге турындагы статьяга туры килүен генә тикшерә, иҗтимагый-сәяси аспектларга кагылмый. Суд Законның бәхәсле нигезләмәсен РФ Конституциясенә каршы килә дип таныды. Журналистлар яңадан мәгълүмат тарату, ә гражданнар мәгълүмат алу хокукына ия булды.

РФ Конституция Суды РФ Президенты тәкъдиме буенча Федерация Советы билгеләп куючы 19 судьядан тора.

РФ Конституция Судына мөрәҗәгать итү хокукы хәл ителергә тиешле мәсьәләнең характерына бәйле рәвештә РФ Конституциясендә билгеләнгән. Әйтик, законнарның яисә Федерация һәм төбәкләрнең хакимият органнары кабул иткән башка актларның Конституциягә туры килүе (ягъни конституциячеллеге) турында, әлеге органнар арасында вәкаләтләрне чикләү турында мәсьәлә буенча фәкать Федерациянең һәм

төбәкләрнең иң югары органнары гына мөрәҗәгать итәргә хокуклы. РФ Конституциясен аңлату буенча — Федерациянең иң югары закон чыгару һәм башкарма хакимияте органнары һәм төбәкләрнең закон чыгару органнары хокуклы.

Гражданнар һәм судлар РФ Конституция Судына фәкать инде кулланылган яисә кулланылырга тиешле законнарның конституциячеллеген тикшерү өчен генә мөрәҗәгать итү хокукына ия. Гражданнар исә бу хокукка әгәр тикшерелүче закон аларның конституциячел хокукларын бозса гына ия була.

Мәсәлән, гражданин З.Р.Шенгелия РФ Конституция Судына хөкем ителгәннәргә очрашуларны чикләүче Төзәтү — хезмәт кодексы кагыйдәләренә шикаять белдерә. Суд дәгъваланучы нормаларга яңа аңлатма бирә. Аерым алганда, күрсәтелгән чикләүләрнең адвокат белән очрашуга кагыла алмаганлыгы, юкса моның Конституциянең 48 нче статьясындагы һәркемнең квалификацияле юридик ярдәм алырга хокуклы булуын гарантияләүче нигезләмәсенә каршы килүе мөмкин булуы аңлатыла. Адвокат белән очрашулар башка законнар белән җайга салына, дип аңлата суд, ә алар адвокатлар белән очрашуның ешлыгын һәм дәвамлылыгын чикләмиләр. 2003 елның 26 декабрендәге бу Карарның әһәмиятен түбәндәге саннарны белгәндә генә дөрес бәяләп була. «Российская газета» мәгълүматларына караганда (2004 елның 14 гыйнварындагы саны), эш белән төзәтү колонияләрендә 700 меңгә якын кеше утыра, тәрбияләү колонияләрендә 16 меңнән арта, тикшерү изоляторларында һәм төрмәләрдә 150 мең кеше бар. Һәм әлеге карар аларның һәркайсы өчен мөһим.

КОНСТИТУЦИЯЧЕЛ СУД ЭШЕ АЛЫП БАРУНЫҢ ТӨП СТАДИЯЛӘРЕ

1. *Судка мөрәҗәгать итү*. Ул гомуми таләпләрне дә, һәр категория эш үзенчәлекләре буенча да таләпләрне үз эченә алган «РФ Конституция Суды турында» Законга туры килергә тиеш.

2. *Мөрәҗәгатьне секретариатның алдан каравы*. Мөрәҗәгатьнең урнаштырылган таләпләргә туры килмәве очрагында ул кире кайтарыла.

3. *Мөрәҗәгатьне судьяларның алдан каравы*. Бер яисә берничә судья КСта карау өчен юридик нигезләр турында бәяләмә бирә, ул пленар киңәшмәдә тикшерелә. Мөрәҗәгатьнең карауга кабул ителү-ителмәве дә шунда хәл ителә.

4. *Эшнең тыңлауга билгеләнүе һәм әзерләнүе, нотыкчы судьяның билгеләнүе* дә пленар утырышта була. Нотыкчы судья эшкә анализ ясый, карар проекты әзерли.

5. *Суд тикшерүе* башка судлардагы тикшерүгә охшаган, әмма тикшерү дәрәҗәсе башка: шуны әйтү дә җитә, якларның вәкилләре булып, җитәкче һәм адвокатлардан башка, юридик фәннәр кандидатлары һәм докторлары гына була ала...

Йомгаклау карары тикшерүдән соң киңәшү бүлмәсендә, ачыктан-ачык тавыш биреп, судьяларны аерым-аерым сораштыру юлы белән, тавышларның зур күпчелеге белән кабул ителә. (Фәкать РФ Конституциясен аңлату турындагы карар гына өчтән ике өлеш күпчелек белән кабул ителә.) Карар белән килешмәгән судья үзенең аерым фикерен бәян итәргә хокуклы, ул Карар белән бергә басыла. Бу конституциячел судьялар бәйсезлегенең мөһим элементы. Игълан ителгәннән соң, Карар барлык кызыксынган (эштә катнашкан) затларга, башкарма һәм закон чыгару хакимиятенең тиешле органнарына җибәрелә, хакимиятнең иң югары органнары рәсми басмаларында бастырып чыгарыла.

Конституция Суды Карары (билгеләмәсе) кичекмәстән үз көченә керә, ахыргы була һәм аңа шикаять белдерелә алмый. Конституциячел түгел дип танылган актлар яисә аларның аерым нигезләмәләре үз көчләрен югалта.

Конституция Суды Карарын күп кенә юристлар иң югары статуслы хокук чыганагына кертәләр, чөнки ул закон гамәлен юкка чыгарырга мөмкин, башка судлар, үз карарлары өчен закон нигезе буларак, аларга таяна ала. Шуның өстенә законның конституциячел түгел дип табылган һәм фактта юкка чыгарылган статьялары өлешендә генә мәҗбүри түгел. Гамәлдәге нормаларны аңлату да мәҗбүри булып тора. Моңа мисал булып, хөкем ителгән З.Р.Шенгелая шикаяте буенча кабул ителгән югарыда китерелгән карар хезмәт итә ала. РФ Конституция Суды тарафыннан Т.А.Аликина шикаяте буенча законсыз тоткарлаганда зыянны каплауга хокук турында ГКның 1070 статьясын аңлату да шуңа охшаш. Бу хакта без җинаять процессы белән танышканда сөйләшкән идек инде.

ГАМӘЛИ ЙОМГАКЛАР

1 Административ юрисдикция турындагы материалны укыгач, сез ясарга тиешле иң кулай (үзегез өчен дә, укытучылар өчен дә, әти-әниегез өчен дә) нәтиҗә: дәүләт урнаштырган кагыйдәләрне һәм законнарны бозарга — урамда тәртипсезләнеп йөрергә, юлны светофор кызыл янганда чыгарга һ.б. ярамый. Ә кемгә дәрес материалы гына аз булса, мөгаен, бер-ике мәртәбә милициядә утырып чыгарга туры килер.

2 Мәгълүм ки, милициягә аңлашылмаучанлык аркасында эләгергә мөмкин. Менә шунда бу белемнәрнең кирәге чыгар. Мисал өчен, милиция сезне тоткарлау турында кичекмәстән әти-әниегезгә хәбәр итәргә тиешлекне белеп тору.

3 Сезгә ягылган хокук бозуның һәркайсына, югарыда әйтелгән барлык кагыйдәләрне үтәп, беркетмә төзелергә тиеш. Беркетмәгә кул куйганчы, аны игътибар белән укырга һәм үзегезнең искәрмәләрегезне язарга кирәк.

4 Россия Федерациясе Конституция Суды турындагы нигезләмә белән танышу сезгә үзегезне Бөек Ил гражданы итеп тоярга ярдәм итәр. Бу илдә хокук һәм ирекләрне гарантияләүче Конституция генә түгел, Конституциянең барлык башка законнардан өстенлеген тәэмин итү механизмы да бар.

ДОКУМЕНТ

РФ Конституциясеннән

7 бүлек. Суд хакимияте

«Россия Федерациясе Конституция Суды гражданнарның конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата шикаятьләр буенча һәм судларның таләпләре буенча конкрет эштә кулланылган яисә кулланылырга тиешле законның конституциячеллеген федераль законда билгеләнгән тәртиптә тикшерә». (125.4 статья)

«Россия Федерациясе Конституция Суды Россия Федерациясе Президентының, Федерация Советының, Дәүләт Думасының, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең, Россия Федерациясе субъектлары закон чыгару хакимияте органнарының таләпләре буенча Россия Федерациясе Конституциясенә аңлатма бирә». (125.5 статья)

«Конституциячел түгел дип танылган актлар яисә аларның аерым нигезләмәләре үз көчләрен югалта; Россия Федерациясе Конституциягә туры килми торган Россия Федерациясе халыкара шартнамәләре гамәлгә һәм кулланылуга кертелми». (125.6 статья)

Документка сораулар һәм биремнәр

1. Конституциянең китерелгән нигезләмәләре төп мәгънәсен һәм әһәмиятен нәрсәдә күрәсез? **2.** Сез ничек уйлыйсыз, нигә нәкъ менә санап чыгылган органнарга РФ Кон-

ституциясен аңлату мәсьәләләре буенча РФ Конституция Судына мөрәҗәгать итү хокукы бирелә? Нигә мондый хокук башка органнарга, җәмәгать оешмаларына, гражданнарга бирелмәгән?

ҮЗ-ҮЗЕҢНЕ ТИКШЕРҮ ӨЧЕН СОРАУЛАР

1. Нәрсә ул административ юрисдикция? **2.** Аның кагыйдәләре нинди закон актында системалаштырылган? **3.** Нинди документ төзү бер үк вакытта административ хокук бозу (АП) турында эш кузгатуны белдерә? **4.** АП турындагы эшләр буенча нинди тәэмин итү чараларын беләсез, һәм алар нигә кирәк? **5.** Административ җәза бирергә кемнең хокукы бар? 6. Нәрсә ул актның конституциячеллеге?

БИРЕМНӘР

1. Кинотеатрдан чыгу юлында 16–17 яшьлек өч егет тора, шешәдән сыра эчә, кычкырышалар, үтүчеләргә бәйләнәләр, ә бер кызга хәтта сыра да сибәләр. Шул вакытта милиционер килеп чыга. Мөмкин булган хәлләрне һәм КоАП нигезендә аннан соңгы вакыйгалар процедурасын тасвирлагыз.

2. Смирновка почта буенча үз гаражын эксплуатацияләгәндә янгын куркынычсызлыгын тупас бозган өчен штраф салынуы турында карар килә. Әмма Смирнов кагыйдәләрне бозмаган, җитмәсә, аның гаражы да юк икән. Әлеге карарны чыгарганда КоАПның нинди нигезләмәләре бозылган? КоАП нигезендә Смирнов нәрсә эшләргә хокуклы?

3. Сез массакүләм мәгълүмат чараларыннан белгән РФ Конституция Суды яисә сезнең төбәк суды карарын исегезгә төшерегез.

4. Дүрт яшь кеше тыюлыктагы күлдән балык тота, учак кабызып, балык шулпасы пешерергә керешә (нәкъ менә «Балык тоту тыела!» дигән язулы такта янында ук). Һәм балык саклау инспекторы килеп чыга. КоАП буенча нинди хәлләр буласын тасвирлагыз.

ЗИРӘКЛӘР ФИКЕРЕ

«Азат булу өчен безгә закон колы булырга кирәк...»

Цицерон (б.э. кадәр 106–43 еллар), борынгы Рим сәяси һәм дәүләт эшлеклесе, философ

§ 28. Кеше хокукларын халыкара яклау

Гражданның үз дәүләтен судка бирергә хокукы бармы? Дәүләт җинаятьче кебек хөкем ителергә мөмкинме?

Тарих һәм җәмгыять белеме курсыннан белгәнегезчә, төрле эпохаларда кеше хокуклары эшчәнлеге һәм күләме төрлечә билгеләнде. XX гасыр башында исә кеше хокуклары аерым дәүләтләрнең эчке дәүләт хокукы белән генә җайга салынды.

Икенче бөтендөнья сугышы барышында кеше хокукларын һәм ирекләрен халыкара җайга салу ихтыяҗы барлык ачыклыгы белән күренде. Мәгълүм булганча, Берләшкән Милләтләр Оешмасы (БМО) сугыш елларында фашизм агрессиясенә һәм кешелеккә каршы кылган җинаятьләренә җавап буларак барлыкка килде. БМО максатлары исәбенә кеше хокуклары һәм төп ирекләренә хөрмәт үстерү һәм аны кызыксындыру турындагы нигезләмәләре кертелүе шуның белән аңлатыла да.

КЕШЕ ХОКУКЛАРЫН ҺӘМ ИРЕКЛӘРЕН БМО ЧАРАЛАРЫ БЕЛӘН ЯКЛАУ

Кеше хокуклары өлкәсендә Берләшкән Милләтләр Оешмасының функцияләре һәм вәкаләтләре гадәттән тыш күптөрле. Аның структур бүлекчәләре рекомендацияләр кабул итә, карарлар чыгара, халыкара конференцияләр чакыра, конвенция проектлары әзерли, тикшеренүләр үткәрә, аерым илләргә консультатив һәм техник ярдәм күрсәтә. Байтак очракларда алар БМО әгъзалары булган дәүләтләрнең БМО Уставы һәм башка халыкара килешүләр буенча алган йөкләмәләренең үтәлешен тикшереп тору функцияләрен дә тормышка ашыра.

Кешенең төп хокуклары һәм ирекләрен гомуми хөрмәт итүгә һәм саклауга ярдәм итү буенча БМО функцияләрен үтәүдә төп җаваплылык **БМОның Генераль Ассамблеясенә** һәм аның җитәкчелегендәге **Икътисади һәм Социаль Советка** (ЭКОСОС) төшә. Кеше хокукы мәсьәләләре гадәттә ЭКОСОС докладының тиешле бүлекләре һәм алдагы сессияләрдә Генераль Ассамблея кабул иткән карарлар нигезендә кертелә. Кайчакта алар шулай ук БМОның башка төп органнары, БМО әгъзалары булган дәүләтләр һәм аның Генераль секретаре тарафыннан тикшерү өчен тәкъдим ителә.

Кеше хокуклары өлкәсендә дә, башка мәсьәләләр буенча да Генераль Ассамблея кабул иткән тәкъдимнәр, БМО Уставы нигезендә, БМО әгъзалары булган дәүләтләр өчен юридик яктан

мәҗбүри түгел. Ләкин Оешма әгъзаларының барысы да яки зур күпчелеге тавыш биргән резолюцияләр барлык дәүләтләр — БМО әгъзалары өчен мәҗбүри булган билгеле бер халыкара хокук нормалары һәм принциплары яшәп килүен дәлилли ала.

1946 елда ЭКОСОС үзенең ярдәмче органы сыйфатында **Кеше хокуклары комиссиясен** гамәлгә куйды. Комиссия әгъзалары 3 елга бер сайлана. Комиссия ел саен алтышар атналык сессиягә җыела һәм үз карарларын шунда булган әгъзаларының һәм тавыш бирүдә катнашучыларның күпчелек тавышы белән кабул итеә. Төзелгән көннән башлап аның вазифаларына Кеше хокуклары турында халыкара билльгә; граждан ирекләре, хатын-кызларның хәле, мәгълүмат ирегә һәм башка шуңа охшаш мәсьәләләр турында халыкара декларацияләр һәм конвенцияләргә; азчылыкны яклауга; раса, җенес, тел яисә дини билгеләр буенча дискриминацияне кисәтүгә; кеше хокукларына кагылышлы теләсә нинди башка мәсьәләләргә карата Советка тәкъдимнәр һәм нотыклар әзерләү керде. Комиссия тикшеренүләр башкара, тәкъдимнәр ясый, мәгълүмат бирә һәм ЭКОСОС кушуы буенча башка эшләр башкара. Эре тикшеренүләр әзерләү гадәттә махсус нотыкчыларга йөкләнә. Тикшеренүләрнең тәмамлануы Комиссия тарафыннан төрле карарлар кабул ителүгә хезмәт итә.

Комиссиягә беренче кушылган эшләрнең берсе Кеше хокуклары турында халыкара билль булды. Исегезгә төшерәбез, хәзерге вакытта Билль түбәндәге халыкара килешүләрне үз эченә ала: Кеше хокуклары гомуми декларациясе; Икътисади, социаль һәм мәдәни хокуклары турында халыкара пакт; Граждан һәм сәяси хокуклар турында халыкара пакт; Граждан һәм сәяси хокуклар турында халыкара пактка Факультатив беркетмә; Граждан һәм сәяси хокуклар турында халыкара пактка үлем җәзасын юкка чыгаруга юнәлтелгән икенче Факультатив беркетмә.

Санап үтелгән халыкара документларның төп идеясен Икътисади, социаль һәм мәдәни хокуклар турындагы пактның преамбуласында беркетелгән түбәндәге принцип чагылдыра: «...ирекле кеше шәхесе, куркудан һәм мохтаҗлыктан ирекле идеал, әгәр һәркем үзенең икътисади, социаль һәм мәдәни хокукларыннан, үзенең сәяси хокукларыннан файдалана алырлык шартлар тудырылганда гына тормышка ашырыла ала».

Граждан һәм сәяси хокуклар турындагы пакт, кораллы бәрелешләр чорларын да кертеп, фундаменталь хокуклар һәм ирекләр теләсә нинди вазгыятьтә үтәлергә тиешле халыкара хокук принцибын беркетте. Гадәттән тыш хәл яисә хәрби хәл кертелү белән бәйле рәвештә кеше хокукларын беркадәр кысу принципта рөхсәт ителә, ләкин ул дискриминациягә алып

барырга, кешенең нигездәге хокукларын бозарга тиеш түгел, аларны барлык дәүләтләр, Пактта катнашучымы ул, юкмы, үтәргә тиеш. (Уйлап карагыз, дәүләттә дөньяның бер төбәгендә нинди вазгыять булуга карамастан, нинди хокуклар үтәлергә тиеш.)

1976 елда БМО тарафыннан **Кеше хокуклары комитеты** төзелде, ул монда катнашучы дәүләтләр үз гражданнарыннан сайлаган, «югары әхлакый сыйфатларга ия булган һәм кеше хокуклары өлкәсендә компетентлыгы белән танылган» 18 эксперттан тора. Комитетның төп функцияләренең берсе катнашучы дәүләтләрнең үз территорияләрендә кеше хокукларын гамәлгә ашыру буенча докладларын тыңлаудан гыйбарәт, бер үк вакытта катнашучылар кеше хокуклары һәм ирекләренең торышы турында гомуми мәгълүмат та, һәр хокукны гамәлгә ашыру турында мәгълүмат та бирә. Комитет нотыкларны тикшерә һәм билгеле бер искәрмәләр ясый, тәкъдимнәр кертә. Катнашучы аларны карарга тиеш һәм ясалган искәрмәләр буенча үз фикерен белдерә. Мондый процедура катнашучы дәүләт тарафыннан башка дәүләтнең үз йөкләмәләрен үтәмәве турында да башкарылырга мөмкин.

Аңлашыла ки, кеше хокукларын һәм ирекләрен беренче чиратта милли суд системасы якларга тиеш, ләкин ул кайчакта, граждан күзлегеннән караганда, гадел карар кабул итми. Бу очракта ул Кеше хокуклары буенча комитетка мөрәҗәгать итәргә мөмкин. Әгәр Комитет шикаятьне кабул ителерлек дип тапса (ягъни эшне хокук бозучы дәүләт судында хәл итү мөмкинлеге беткән дип билгеләсә), бу хакта тиешле дәүләткә хәбәр итә, соңгысы 6 ай дәвамында мәсьәләнең асылы буенча язмача аңлатма бирү мөмкинлегенә ия, моннан соң шикаять белдерүче дәүләт аңлатмасына үз фикерен белдерә. Үз эшчәнлеге чорында Комитет йөзләрчә шикаятьне карады һәм алар буенча үз тәкъдимнәрен бирде. Аларның күбесе дәүләтләр тарафыннан үтәлешкә кабул ителде. Нәкъ менә индивидуаль белдерүләрне тикшерү теге яки бу дәүләт законнары, суд һәм административ практикасының Граждан һәм сәяси хокуклар турында халыкара пакттагыларына туры киләме-юкмы икәнлеге хакында нәтиҗә ясарга мөмкинлек бирә. Комитет карарларын үтәп, үз законнарын Пактка туры китереп, дәүләт шуның белән киләчәктә кеше хокукларын мондый бозуларны булдырмау өчен шартлар тудыра.

БМО кеше хокукларын яклау, мәсәлән, хатын-кыз хокукларын, бала хокукларын яклау буенча башка органнар да төзеде. Шулай итеп, БМО органнары кеше хокукларының гомуми мәсьәләләрен дә, аерым алганда, кораллы бәрелешләр чорында кеше хокукларын яклауга караган махсус мәсьәләләрне

дә карый. Кеше хокукларын җинаятьчел бозган өчен җаваплылык мәсьәләләрен дә шул ук органнар тикшерә.

Әмма хәзерге вакытта БМО органнарының кеше хокуклары өлкәсендәге эшчәнлеге камиллектән ерак тора: оешмаларның төзелгән системасы бик зур, аның эшендә кабатлаулар күзәтелә, байтак мәсьәләләрне карау елдан елга чигерелеп килә. Бу оешмалар эшчәнлеге сессияләр белән алып барылганлыктан, алар кризис шартларында ашыгыч чаралар күрә алмый. Әлеге вазгыятьне хәл итү чарасы сыйфатында **БМОның кеше хокуклары буенча Югары комиссары**, шулай ук **БМОның качаклар хокуклары буенча Югары комиссары вазифалары** булдырылды, алар тыныч чорда һәм хәрби бәрелешләр вакытында кеше хокукларын яклау буенча БМОның гамәли эшләрен координацияли.

КЕШЕ ХОКУКЛАРЫН ЯКЛАУНЫҢ ЕВРОПА СИСТЕМАСЫ

Европа Советы иң өлкән төбәк оешмасы булып тора. 1950 елның 4 ноябрендә Римда аның әгъзалары Кеше хокукларын һәм төп ирекләрен яклау турында Европа конвенциясен кабул иттеләр, ул 1953 елның 3 сентябреннән гамәлгә керде.

Бу Конвенция нигезендә ике орган — **Кеше хокуклары буенча Европа комиссиясе** һәм **Кеше хокуклары буенча Европа Суды** төзелде. Аларга Конвенциядә катнашучы дәүләтләр тарафыннан үзләренең хокуклары бозылу турында дәүләтләр, аерым затлар, хөкүмәтнеке булмаган оешмалар һәм затлар төркеме белдерүләрен карау буенча вәкаләтләр бирелде. Аерым индивидлар, хөкүмәтнеке булмаган оешмалар һәм затлар төркеме үз петицияләрен турыдан-туры Судка җибәрә алалар. Шуңа бәйле рәвештә Кеше хокуклары буенча Европа комиссиясе бетерелде, һәм кеше хокукларын яклау буенча бердәнбер орган булып Суд калды.

Эшләрне карау өчен Суд 3 судьядан торган комитетлар, 7 судьядан палата һәм 17 судьядан зур палаталарны гамәлгә куя. Шикаятьләрнең кабул ителерлеге турындагы мәсьәлә 3 судьялык комитет тарафыннан хәл ителә. Бу оператив хәл ителергә тиешле шикаятьләр саны өзлексез арта баруы белән бәйле. Эшләр үзләре палаталар тарафыннан хәл ителә. Зур палаталар иң җитди мәсьәләләрне тикшерә, шулай ук аларга яклар бәхәсендә катнашучылар таләбе буенча тапшырылган эшләрне карый.

Суд карары катнашучы дәүләтләр өчен мәҗбүри, һәм аларның тормышка ашуын **Европа Советы министрлар комитеты**

күзәтеп тора. Шулай итеп, әлеге механизм, асылда, милләтләр өстендәге хакимият булып тора.

Европа Советына керүче теләсә кайсы ил, Европа конвенциясенә кушылып кына калмыйча, үз законнарына Кеше хокуклары буенча суд карарлары булдырган прецедент хокукыннан килеп чыгучы тиешле үзгәрешләр дә кертергә тиеш булачак.

Хәзер, Россия Европа Советына кергәч һәм Кеше хокукларын һәм төп ирекләрен яклау турында Европа конвенциясен ратификацияләгәч, Россия законнарын һәм юридик гамәлләрне Европа стандартларына туры китерергә кирәк. Мондый гамәл РФ Конституциясе белән күздә тотыла (15 статья, 4 пункт).

Европа куркынычсызлык һәм хезмәттәшлек оешмасы (ОБСЕ) эшендә дә кеше хокукларын яклауга җитди урын бирелә.

Перспективада, күрәсең, Европада яшәп килгән төбәк органнары бер оешмага берләшерләр, һәм аңарга бу кыйтгадагы барлык дәүләтләр керер. Әкренләп бөтен Европаның интеграцияләнүенә сәяси алшартлар өлгерә, бу исә һичшиксез бердәм Европа хокукый киңлеге барлыкка килүгә һәм кешенең төп хокукларын һәм ирекләрен нәтиҗәле яклау өчен бердәй шартлар булдыруга китерәчәк.

ҮЛЕМ ҖӘЗАСЫН ЮККА ЧЫГАРУ ПРОБЛЕМАЛАРЫ

Илләр арасындагы мөнәсәбәтләрнең үсеш динамикасы элек дәүләтләрнең эчке конпетенциясенә кергән күп кенә проблемаларның халыкара регламентацияләнә башлавын күрсәтә. Үлем җәзасын куллану турындагы мәсьәлә иң катлаулыларның берсе.

Кеше хокуклары гомуми декларациясе һәм Халыкара пактлар, һәркемнең яшәүгә хокукын игълан итеп, үлем җәзасын юкка чыгармады. Фәкать 18 яшькә кадәрге затлар кылган җинаятьләр өчен үлем җәзасын чыгару һәм аны көмәнле хатыннарга карата куллану гына тыелды.

Авыр җинаять өчен үлем җәзасы куллану мәсьәләсе хокукый гына түгел, әхлакый-фәлсәфи дә. Байтак кына үтерешләр алкоголь һәм наркотиклар белән исергән килеш, еш кына көтелмәгән факторлар йогынтысында башкарыла. Үтерүләр санының азы гына алдан уйлап башкарыла, шуңа да үлем җәзасы җинаятьчелекне туктатырга яисә кискен киметергә мөмкин дип раслау бик нигезле түгелдер. Гамәли эш үлем җәзасын куллану җинаятьләр санын киметмәвен күрсәтә, шул

ук вакытта аны бетерү җәмгыятьтә мөнәсәбәтләрнең гуманлашуына китерә, суд хаталарын булдырмаска мөмкинлек бирә.

1983 елда Европа Советы Кеше хокукларын һәм төп ирекләрен яклау турында Европа Конвенциясенә 6 нчы беркетмәне (үлем җәзасын бетерү турында) кабул итте. Беркетмәнең 1 статьясы болай ди: «Үлем җәзасы юкка чыгарыла. Беркем дә үлем җәзасына хөкем ителә яисә җәзалап үтерелә алмый». Беркетмәдә катнашучы дәүләтләр үз законнарында «сугыш вакытында яисә котылгысыз сугыш янагандагы» гамәлләр өчен генә үлем җәзасын күздә тота ала. Европа Советы әгъзалары булган дәүләтләрнең зур күпчелеге 6 нчы беркетмәне ратификацияләде һәм үлем җәзасына хөкем итми яисә аны гамәлгә ашырмый. Европа Советының Парламент Ассамблеясе Россиянең бу оешмага керүгә заявкасы буенча бәяләмәсендә аңа бер ел эчендә 6 нчы беркетмәгә кул куярга һәм Европа Советына керү вакытыннан 3 елдан да соңга калмыйча аны ратификацияләргә тәкъдим итте. 1997 елда Россия Беркетмәгә кул куйды.

6 нчы Беркетмәнең БМО әгъзалары булган күп кенә дәүләтләрнең үлем җәзасын юкка чыгару мәсьәләсе буенча позициясенә йогынты ясады. Бу БМО Генераль Ассамблеясенең һәркемнең яшәүгә хокукының үлем җәзасын тыю белән аерылгысыз бәйләнешен игълан итүенә һәм катнашучы дәүләтләргә үлем җәзасын бернинди искәрмәләрсез бетерүне һәм үлем җәзасы турында чыгарылган карарларны үтәмәүне йөкләвенә китерде. Бу карарны үтәүне тикшереп тору Кеше хокуклары буенча комитетка йөкләнде.

Әмма дөньяның барлык илләре дә бу карар белән килешмәде һәм аны гамәлгә ашырмады. Аеруча авыр җинаятьләр кылган өчен үлем җәзасы куллануга мораторияне бетерү турында бәхәсләр Россиядә дә менә берничә ел бара инде.

ХАЛЫКАРА ҖИНАЯТЬЛӘР ҺӘМ ХОКУК БОЗУЛАР

Индивид дәүләтара килешүләрдә беркетелгән хокукларга ия генә түгел, халыкара хокук принципларын һәм нормаларын бозган өчен җавап та тота. Хокукка каршы гамәлләрнең ике категориясен аерып карау кабул ителгән: халыкара хокук бозулар һәм халыкара җинаятьләр (аеруча куркынычлы хокук бозулар).

«Халыкара җинаять» төшенчәсенә «тынычлыкка һәм кешелеккә каршы җинаятьләр» һәм «халыкара хокукка каршы җинаятьләр»не кертәләр. Халыкара җинаятьләрнең өч төре

аерып карала: беренчесенә агрессия сугышы чыгаруга яисә алып баруга юнәлтелгән гамәлләр керә; икенчесенә — хәрби җинаятьләр (мәсәлән, басып алынган территорияләрнең тыныч халкын, тотыкларны, хәрби әсирләрне үтерү йә газаплау, торак пунктларны мәгънәсезгә җимерү); өченчесенә — кешелеккә каршы җинаятьләр. Хәрби җинаятьләргә Халыкара җинаять суды статусы 1949 елгы Женева конвециясен, шулай ук халыкара һәм халыкара булмаган кораллы бәрелешләрдә кулланылырлык башка законнарны һәм сугыш алып бару гадәтен җитди бозуларда чагылучы 50 дән артык төрле составны кертә.

Шуны әйтеп үтик, хәрби җинаятьләргә һәм кешелеккә каршы җинаятьләргә карата күптәнгелек срогы кулланылмый. Сез ничек уйлыйсыз, нигә?

Халыкара хокук бозу һәм җинаять субъекты булып, хәтта әгәр хокук бозу яисә җинаять аның тарафыннан дәүләт исеменнән түгел, ә шәхси зат буларак кылынса да, дәүләт тә, индивид та тора.

Күп кенә халыкара җинаятьләр өчен җаваплылык аларны кылуның урыны һәм вакытына бәйсез рәвештә килә. Шул ук вакытта аларның бу дәүләт законнары белән каралуы һәм әлеге затның аның гражданы яисә чит илнеке булуы мөһим түгел Халыкара хокук нормалары нигезендә теләсә нинди дәүләт мондый затларга җинаятьче буларак карарга тиеш. Әгәр индивид халыкара җинаять кылганда дәүләт исеменнән эш итсә, халыкара-хокукый җаваплылыкка дәүләт үзе дә тартылырга мөмкин.

ХАЛЫКАРА ҖИНАЯТЬ СУДЫ ВӘКАЛӘТЛӘРЕ

Күп очракларда халыкара җинаятьләр хөкүмәт әгъзалары һәм башка рәсми затлар тарафыннан кылына, һәм бу дәүләт судлары аларны җаваплылыкка тартмый. Күренә ки, халыкара җинаятьләр турындагы эшләрне караганда милли суд системалары беркайчан да нәтиҗәле орган була алмастыр. Бигрәк тә дәүләтләр тарафыннан оештырылган һәм аның вәкилләре башкарган җинаятьләрне караганда.

Соңгы унъеллыкта байтак халыкара җинаятьләр кылынды. 1993 елда БМО Куркынычсызлык Советы карары белән элеккеге Югославия территориясендә кеше хокукларын җинаятьчел бозуларда гаепле затларны суд эзәрлекләве өчен вакытлы **Халыкара җинаять трибунасы** оештырылды. Гражданнар сугышлары һәм халыкара бәрелешләр барышында Югославия һәм кешелеккә каршы җинаятьләр кылынган башка берничә дәүләт буенча трибунал эше җитди проблемаларны ачыклады, мәсәлән: җитәрлек финанслау булмау; кайбер дәүләтләрнең Трибунал

белән хезмәттәшлек итәргә һәм аның карарларына буйсынырга теләмәве.

Халыкара җинаять суды оештыру турындагы карар һәм аның Статутын кабул итү — дәүләтара мөнәсәбәтләрне һәм халыкара хокукны үстерүдә сыйфат ягыннан яңа этапның башы. Нацист җинаятьчеләре өстеннән Нюрнберг процессы заманыннан беренче тапкыр халыкара җәмәгатьчелек даими гамәлдәге югары суд инстанциясе булдыру турында карар кабул итте, бу суд хәрби җинаятьләрдә һәм кешелеккә каршы җинаятьләрдә гаепләнүләргә, аларның вазифаи хәленә карамастан, хөкем карары чыгара ала.

КЕШЕ ХОКУКЛАРЫН ҺӘМ ИРЕКЛӘРЕН ХАЛЫКАРА ЯКЛАУ МЕХАНИЗМНАРЫН ҮСТЕРҮ ПЕРСПЕКТИВАСЫ

XXI гасырга кергән дөньяда халыкара мөнәсәбәтләрнең җитди трансформациясе күренеп тора. Кеше хокукларын һәм ирекләрен нәтиҗәле яклау иң мөһим глобаль проблемаларның берсе буларак кабул ителә, аны хәл итү бөтен дөнья җәмгыяте тырышлыгын интеграцияләү шартларында гына мөмкин.

Барлык илләр законнары нигезенә гомумтанылган хокукый нормалар һәм принциплар салынырга тиеш, бу исә бердәй хокукый киңлек булдыруга китерәчәк. Бердәй хокукый киңлек булдыру — озак вакытка исәпләнгән максат. Аңа ирешү хокукның милли системаларын тулы унификацияләү дигән сүз түгел, ләкин килешенгән халыкара-хокукый нормаларны аңлатуга һәм куллануга бер үк төрле якын килү дигәнне белдерә. Нормаларның һәм принципларның мондый якынлашуы хокукның күп тармакларында бара, әмма моның нигезен кеше хокуклары һәм ирекләре, бигрәк тә граждан һәм сәяси хокуклар тәшкил итә. Әлеге киңлек Европаның берничә төбәк оешмасы кысаларында аеруча уңышлы төзелә.

Соңгы дистә елларда кеше хокукларына караган күп кенә халыкара хокук нормалары һәм принциплары төбәк оешмалары кысаларында конкретлаштырылды. Мәсәлән, аларга сайлау үткәрүгә, күппартияле системалар төзүгә, милекнең төрле рәвешләрен тануга кагылган нормалар, һәркемнең үз илен калдырып китүгә һәм әйләнеп кайтуга хокукы керә. Барлык дәүләтләр тарафыннан халыкара хокукның дәүләт эчендәге хокуктан өстенлеген тану аеруча мөһим. Мондый тану халыкара хокук принципларын һәм нормаларын дәүләтләрнең юридик һәм административ гамәлләрендә турыдан-туры куллануга этәргеч бирәчәк.

Глобаль хокукый киңлек булдыруның уңышлы баруы кеше хокуклары буенча халыкара контроль органнары эшчәнлеген оптимальләштерүгә дә, аларга аерым дәүләтләр адресына анык һәм мәҗбүри карарлар чыгару компетенциясе бирүгә дә бәйле. Моның өчен дәүләтләргә суверен хокукларының бер өлешеннән баш тартырга һәм кеше хокуклары буенча халыкара органнарга хакимият вәкаләтләре бирергә туры киләчәк.

ГАМӘЛИ ЙОМГАКЛАР

1 Кеше хокуклары башка хокукый принципларга һәм нормаларга караганда өстенрәк. Үз хокукларыңны яклауга һәм башкаларның хокукларын хөрмәт итәргә өйрәнергә кирәк.

2 Дөнья җәмәгатьчелеге тарафыннан үлем җәзасы кешенең иң төп хокукын — яшәү хокукын бозу буларак карала. Россиядә үлем җәзасын яңарту турындагы тәкъдимнәргә үз мөнәсәбәтеңне белдергәндә бу хакта истә тоту зарур.

3 Кеше хокукларының дәүләт, аның аерым вәкилләре яисә шәхси затлар тарафыннан бозылуы халыкара хокук нормалары белән гаепләнә. Халыкара җинаятьләр кылган өчен җаваплылык аның күптән булуына, җинаятьченең гражданлыгына һәм аның кайда кылынуына карамастан, йөкләнә.

4 Европаның теләсә кайсы иле, шул исәптән Россия гражданы үз хокукларын яклап Кеше хокуклары буенча Европа Судына мөрәҗәгать итәргә мөмкин, бу Судның карарлары хокук бозучы дәүләтләр өчен мәҗбүри.

ДОКУМЕНТ

Табигать мохитенә йогынты ясау чараларыннан хәрби яисә башка дошманнарча файдалануны тыю турында Конвенциядән (*1976 ел*).

Әлеге Конвенциядә катнашучы дәүләтләр,

...фәнни-техник прогрессның табигать мохитенә йогынты ясау өлкәсендә яңа мөмкинлекләр ача алуын танып...

табигать мохитенә йогынты ясау чараларыннан тыныч максатларда файдалану кеше һәм табигатьнең бер-берсенә тәэсир итүен яхшыртуга, бүгенге һәм киләчәк буыннар мәнфәгатьләрендә табигать мохитен саклауга һәм яхшыртуга китерү мөмкинлеген аңлап;

әмма мондый чаралардан хәрби яисә теләсә нинди башка дошманлык максатында файдалануның кешеләр иминлеге

өчен гадәттән тыш үтергеч нәтиҗәләре булырга мөмкинлеген аңлап...

түбәндәгеләр турында килештеләр:

1 статья

Әлеге Конвенциядә катнашучы һәр дәүләт җимергеч ысул, теләсә нинди башка катнашучы дәүләткә зыян китерү яисә зарар салу сыйфатында киң, озак вакытлы яки җитди нәтиҗәләргә ия табигать мохитенә йогынты ясау чарасыннан хәрби яисә башка дошманнарча файдалануны булдырмаска йөкләмә алалар...

2 статья

1 статьяда файдаланучы «табигать мохитенә йогынты ясау» термины табигать процесслары белән алдан уйлап идарә итү юлы белән җирнең динамикасын, составын яисә структурасын, аның биота, литосфера, гидросфера һәм атмосферасын да кертеп, яки галәм киңлекләрен үзгәртү өчен теләсә нинди чараларга кагыла...

Документка сораулар һәм биремнәр

1. «Табигать мохитенә йогынты ясау чаралары» термины астында дөнья җәмәгатьчелеге нәрсәне аңлый? **2.** Әлеге Конвенциягә кул куйган илләр нинди йөкләмә алды? **3.** Конвенциядә катнашучылар кабул иткән чикләүләр ни белән аңлатыла? **4.** Мондый Конвенция кабул итү зарурлыгын раслаучы анык мисаллар сайлагыз. **5.** Әлеге Конвенция белән якланучы кеше хокукларын һәм ирекләрен атагыз.

ҮЗ-ҮЗЕҢНЕ ТИКШЕРҮ ӨЧЕН СОРАУЛАР

1. БМОның нинди структур бүлекчәләре турыдан-туры кеше хокукларын яклау белән шөгыльләнә? **2.** Кеше хокуклары турында Билль үз эченә алган халыкара килешүләрне санап үтегез. Аларның төп принцибы нидән гыйбарәт? **3.** БМОның кеше хокукларын яклау бүлекчәләре һәм төбәк оешмалары нинди максаттан чыгып аерым гражданнарның шикаятьләре белән эшлиләр? Барлык шикаятьләр дә карауга алынамы? Нигә? **4.** Европа Советы кысаларында кеше хокукларын яклау ничек оештырылган? **5.** Индивидларның турыдан-туры Европа Судына мөрәҗәгать итү хокукы игълан ителгәч, Кеше хокуклары буенча комиссия нигә бетерелде? **6.** Нәрсә ул халыкара җинаять? Шуңа охшашлы нинди җинаятьләр сезгә мәгълүм? Халыкара җинаятьләр кылган өчен суд эзәрлекләвенең үзенчәлеге нидә? **7.** Халыкара җинаять судын оештыруның сәбәбе нинди? **8.** Сезнеңчә, кеше хокукларын халыкара яклауның гамәлдәге механизмы нәтиҗәлеме? Ни өчен?

БИРЕМНӘР

1. Менә берничә ел инде Россиядә аеруча авыр җинаятьләр өчен үлем җәзасын торгызу зарурлыгы турында бәхәсләр бара. Әлеге проблема буенча туганнарыгыз, дусларыгыз һәм танышларыгыз фикерен ачыклагыз. Үлем җәзасы яклылар һәм аңа каршыларның төп дәлилләрен формалаштырыгыз. Бу проблемага үз мөнәсәбәтегезне белдерегез һәм аны дәлилләгез.

2. Фаразлап карагыз, нигә бүген кеше хокукларын һәм ирекләрен яклау буенча Европа структуралары БМО структураларыннан нәтиҗәлерәк эшли? Соңгы елларда Европа Союзы кеше хокуклары өлкәсендә нинди проблемаларга юлыга? 3–5 проблеманы атагыз.

3. Бала хокуклары турында Конвенция түбәндәгеләрне тыя:

а) 18 яшькә җитмәгән затларга карата үлем җәзасы яисә төрмәгә гомерлек ябуны куллануны;

б) хәтта сугыш шартларында да 15 яшенә җитмәгән затларны хәрби хезмәткә чакыруны.

Һәр тыюның сәбәпләрен аңлатыгыз.

4. Кызыл Хач һәм Кызыл Ярымай оешмалары эшчәнлеге турында кыскача белдерү өчен материал туплагыз. Нигә бу оешмаларны нейтраль дип атыйлар? Аларның кеше хокукларын яклау ысуллары нинди? Сез алар эшчәнлегендә катнаша аласызмы?

ЗИРӘКЛӘР ФИКЕРЕ

«Тынычлык теләсәң — гаделлекне сакла».

Гаагада Тынычлык сараендагы язма

БҮЛЕККӘ КЫСКАЧА ЙОМГАК

1 Хокукның килеп чыгуы, асылы һәм билгеләнеше турындагы сорауларга җаваплар эзләү теоретик күзлектән дә, гамәли яктан да бик мөһим. Хокукка хәзерге заман төп якын килүләр исәбенә норматив һәм табигый-хокукый карашларны кертеп була. Аларның һәркайсының үз өстенлеге бар, һәркайсы илдә гамәлдә булган позитив хокук үсешенә йогынты ясый. Норматив якын килү хокукның төп, билгеләүче сыйфатын — аның нормативлылыгын басым ясап күрсәтә. Табигый хокук исә гамәлдәге хокукны гуманлык, ирек, гаделлек идеяләре белән баета һәм шуның белән гамәлдәге законнарның мәгълүм бер сыйфатына ирешергә мөмкинлек бирә — аларны хокукый итә.

2 РФ гражданлыгы, аны алу нигезләренә карамастан (тумышы яисә натуралаштырылуы буенча), бердәй һәм тигез булып тора. Дәүләт гражданнарга аларның конституциячел хокукларын һәм ирекләрен яклауны гарантияли. Җавап итеп ул гражданнардан билгеләнгән законнарны саклауларын һәм конституциячел вазифаларын үтәүләрен — салым һәм җыемнар түләүне, табигатьне саклауны, табигать байлыкларына сакчыл карашны, тарихи һәм мәдәни ядкәрләрне саклау турында кайгыртуны, балалар һәм хезмәткә сәләтсез ата-ана турында кайгыртуны көтә. РФ Гражданының бурычы һәм вазифасы булып шулай ук Ватанны саклау тора.

3 Хәзерге заман Россия хокук системасы берничә матди хокук тармагыннан гыйбарәт — экологик, гаилә, граждан һәм хезмәт. Атап үтелгән һәр тармак аерым бер үзенчәлеккә ия — хокукый мөнәсәбәтләрдә катнашучыларның җәмәгать тормышының теге яки бу өлкәсендә барлыкка килүче хокукларын һәм бурычларын билгели. Шуның белән бергә барлык тармаклар әлеге өлкәләрнең аерылгысыз бәйләнеше аркасында тыгыз хезмәттәшлек итә. Кеше даими, гомере буе тегеләйме-болаймы, гаилә хокукы белән җайга салынучы шәхси һәм аңардан килеп чыгучы мөлкәти мөнәсәбәтләргә керә. Кешеләрнең көндәлек тормышында бик күп вазгыятьләр мөлкәти яисә шәхси мөлкәти булмаган мөнәсәбәтләр, ягъни граждан хокукый мөнәсәбәтләре белән бәйле. Гражданнарның төп өлеше шулай ук хезмәт хокукы нормаларына нигезләнгән хокукый мөнәсәбәтләр белән бәйле. Һәм, әлбәттә, барлык кешеләр тегеләйме-болаймы экологик хокук мөнәсәбәтләренә керә, уңайлы әйләнә-тирә мохитне, моңа хокукка ия, шулай ук аны саклау һәм яклауга да бурычлы.

4 Процессуаль хокук матди хокукны гамәлгә ашыру һәм суд яклавы тәртибен регламентларга чакырылган. Процессуаль хокук нигезендә судлар гадел хөкемне тормышка ашыра — граждан, административ, җинаять эшләрен һ.б. карый.

Граждан процессының (граждан-процессуаль хокукының) төп предметы — граждан-хокукый бәхәсләр һәм аларны хәл итү тәртибе. Граждан процессы кагыйдәләре РФ Граждан-процессуаль кодексында бәян ителгән. Арбитраж процесс — эшләрнең арбитраж судларда узуы процессы, монда башлыча икътисади бәхәсләр карала. Ул РФнең Арбитраж кодексы нигезендә башкарыла. Җинаять процессы РФ җинаять-процессуаль кодексы нигезендә төзелә һәм җинаять эшләрен тикшерү һәм хәл итү буенча эшчәнлекне тәшкил итә. Административ юрисдикция административ хокук бозулар буенча суд эше була һәм РФнең Административ хокук бозулар кодексы базасында алып барыла. Шулай ук конституциячел суд эше, ягъни РФ Конституция

Судындагы производство була. Ул РФ Конституциясе, «РФ Конституция Суды турында» Федераль конституциячел закон һәм Конституция Суды Регламенты нигезендә башкарыла.

5 Кеше хокукларын халыкара яклау беренче чиратта БМО чаралары белән тормышка ашырыла.

Халыкара система белән беррәттән кеше хокукларын яклауның Европа төбәк системасы да яшәп килә. Ул барыннан да бигрәк, Европа Советыннан, шулай ук ул гамәлгә куйган Кеше хокуклары буенча Европа Комиссиясеннән һәм Кеше хокуклары буенча Европа Судыннан гыйбарәт. Суд карарлары барлык катнашучы дәүләтләр өчен мәҗбүри, ә аларның үтәлешен Европа Советы Министрлар комитеты күзәтеп тора. Европа Советына кергән һәр ил Суд карарын үтәп кенә калмыйча, үз законнарын да кеше хокуклары буенча аның таләпләренә туры китереп үзгәртергә тиеш. Кеше хокуклары мәсьәләләре Европада куркынычсызлык һәм хезмәттәшлек оешмасы (ОБСЕ) эшендә дә сизелерлек урын ала. Һәр граждан халыкара килешүләрдә беркетелгән хокукларга ия булып кына калмый, халыкара хокук нормаларын бозган өчен җавап та бирә.

ЙОМГАКЛАП КАБАТЛАУ ӨЧЕН СОРАУЛАР

1. Хокукны аңлауга заманча якын килүнең үзенчәлекләре нинди?
2. РФ гражданының төп хокукларын һәм бурычларын характерлагыз.
3. Хәрби хезмәтне нинди очракларда альтернатив граждан хезмәтенә алыштырырга була?
4. Юридик күзлектән караганда гаилә нәрсә ул?
5. Экологик хокук мөнәсәбәтләренең үзенчәлеге нидә?
6. Нигә кешенең уңайлы әйләнә-тирә мохиткә хокукы гомумкешелек кыйммәтләре исәбенә керә?
7. Гражданлык хокукы мөнәсәбәтләренең үзенчәлеге нинди?
8. Хезмәт хокукы мөнәсәбәтләренең үзенчәлеге нидә?
9. Нәрсә ул процессуаль хокук?
10. Граждан һәм арбитраж процессларының төп бурычларын характерлагыз.
11. Җинаять процессының төп бурычы нинди?
12. Административ юрисдикциянең төп бурычлары нидән гыйбарәт?
13. Конституциячел суд эшенең билгеләнеше нинди, башка суд системаларыннан ул ни белән аерыла?
14. Кеше хокукларын яклауның хәзерге заман механизмы нидән гыйбарәт?

§ 29. Киләчәккә караш

Киләчәкне алдан күреп буламы? XXI гасыр нинди булыр? Яңа гасырда үткән XX гасырдан мирас булып калган проблемаларны хәл итәргә мөмкин булырмы?

Менә берничә ел инде без XXI гасырда яшибез. «XXI гасыр нинди булыр?» дигән сорауга сез: «Без аны үзебез ничек күрәбез, шулай булыр. Инде XXI гасыр бара бит!» — дип җавап бирә алыр идегез. Ләкин барысы да алай гади генә түгел. Узган XX гасыр иҗтимагый үсешнең элек беркайчан күрелмәгән тизләнешен күрсәтте. Бер буын тормышы дәвамында гына да элеккеге вакытта йөзьеллыклар буе барган үзгәрешләр булды. Аннан соңгы елларда үсеш темпы акрынаер дип уйлау кыен. Хәзерге фән берничә дистә елдан кешеләр тормышы нинди булачагын бүген әйтеп бирә аламы? Ул төгәл җавапны бирми. Үсешнең төрле вариантлары булырга мөмкин. Әмма галимнәр, XX — XXI гасырлар чигендә дөнья процессы тенденцияләрен өйрәнеп, иң якын киләчәктә булачак кайбер җитди үзгәрешләрне фаразлый ала.

ҖӘМГЫЯТЬ ҺӘМ КЕШЕ XXI ГАСЫР ЯНАУЛАРЫ ҺӘМ СОРАУЛАРЫ КАРШЫНДА

XX гасыр урталарында ук җәмгыять үсешендә, әгәр алар дөньяның барлык илләре катнашында хәл ителмәсә, Җир шарындагы цивилизациянең һәлак булуы белән янаучы проблемалар барлыкка килүе ачык күренде. Аларны замананың глобаль проблемалары дип атадылар. XX — XXI гасырлар бусагасында элек билгеле булган проблемаларга яңалары өстәлде. Алар глобальләштерү процессы белән бәйле. Галимнәр, дәүләт эшлеклеләре барлык бу проблемаларны хәл итү юлларын эзли. Әмма XXI гасыр интеллектуальләргә һәм сәясәтчеләргә генә түгел, ә җирдә яшәүче барча кешегә чакыру ташлый. Кешелек җәмгыятенә янаган куркынычны уртак тырышлык белән юкка чыгару өчен барлык дәүләтләр, халыклар, җәмәгать оешмалары һәм хәрәкәтләре, һәр кешенең булган көчен берләштерү зарур. Нинди проблемалар хәл итүне сорый? Моның өчен нинди мөмкинлекләр бар?

Экологик проблемалар. Уку елларында сез алар белән география, биология, тарих, җәмгыять белеме дәресләрендә таныш-

тыгыз. Исегезгә төшерегез: әлеге проблемалар нидән гыйбарәт? Аларны хәл итү юллары нинди? Әлеге проблемаларның әһәмиятен мөстәкыйль бәяләү һәм аларны җиңү ысулларын билгеләү өчен сезнең белемнәрегез җитәрлек дип ышанабыз.

Атом-төш сугышы куркынычы. Сез тарих курсыннан белгән дөньяның иске системасы хәрби каршылыгы үткәндә калса да, һәм атом-төш коралын чикләү чаралары күрелсә дә, калган арсенал Җир шарындагы барлык тереклекне юкка чыгарырга җитә. Хакимияттә тышкы сәясәттә авантюрага хирыс агрессив көчләр торган илләрдә атом-төш коралы булдыру мөмкинлеге аеруча куркыныч. Хәтта локаль атом-төш конфликты да бик киң территорияләр өчен иң авыр нәтиҗәләргә китерү белән яный. Шуңа да атом-төш коралсыз, көч кулланусыз дөнья булдыру, халыкара конфликтларны хәрби түгел, ә сәяси чаралар белән хәл итү иң мөһим проблема булып тора. Бу безнең планетада тормышны саклап калуның зарури шарты.

Халыкара террорчылык. XX гасыр ахыры — XXI гасыр башында террорчылык эшчәнлеге сизелерлек көчәйде. Ул хәзер аерым бер террорчылар төркеме акцияләре белән генә чикләнми, ә халыкара масштабтагы эре оешмалар тарафыннан системалы төстә тормышка ашырыла, бөтен бер илләрне, бик киң төбәкләрне чолгап ала. Террорчылык актлары нәтиҗәләренең авырлык дәрәҗәсе артты. Әгәр элек террор корбаннары нигездә террорчылар күралмаган аерым затлар булса, хәзер исә — бернинди гаепсез меңләгән һәм ун меңләгән кешеләр. Террорчылык оешмаларының массачыл юк итү коралы — атом-төш сугыш кирәк-яраклары, химик агулаучы матдәләр, үтергеч авырулар йоктыручы биологик чаралар алу мөмкинлеге аеруча куркыныч тудыра. Мондый коралларга ия булу аларга бөтен бер дәүләтләрне һәм аларның хөкүмәтләрен куркытып торырга мөмкинлек бирер иде.

Террорчылыкка каршы көрәш дөнья җәмәгатьчелегенең тырышлыгын берләштерүне, террорчылык эшчәнлеге сәбәпләрен китереп чыгаручы сәбәпләрне бетерүне, дәүләтнең яклау функциясен активлаштыруны таләп итә.

«Өченче дөнья» илләренең икътисади артталыгын, ярлылыгын һәм хәерчелеген бетерү. Йөзләгән миллион кешеләр бу илләрдә йөзәр ел буе икътисади һәм социаль прогресс юлы буйлап барган илләрдәге тормыш дәрәҗәсеннән бик ерак торган шартларда яши. (Бу хакта география курсыннан алынган белешмәләрне исегезгә төшерегез.) Югары үсеш алган илләр халкы («алтын миллиард») җыелма дөнья продуктының 88%ын куллана, ә иң ярлы илләрдә яшәүче җир халкының биштән бер өлеше бу продуктның нибары 1,5 % ын файдалана. Нык үскән илләр һәм үсеп баручы дөнья арасындагы икътисади һәм мәдә-

ни үсеш аермасын, йөзләгән миллион кеше яшәргә мәҗбүр булган ачлык, хәерчелек һәм грамотасызлык шартларын бетерү — XX гасырдан мирас булып калган авыр проблемаларның берсе.

Социаль-демографик проблемалар. Алар барыннан да элек үсеп килүче илләрдә халык саны арту темпларының үсүе («демографик шартлау») белән бәйле. Бу дөньяның әлеге зонасында массачыл бәлаләр, ачлык, авырулар, нормаль торак булмау, грамотасызлык, эшсезлек сәбәпләренең берсе. Бер үк вакытта икътисади үсеш алган илләрдә аларда бала тууның буыннар алмашу һәм халык санын саклау өчен кирәк булган дәрәҗәдән түбән булуы аркасында демографик кризис күзәтелә.

Дөньяның төрле зоналарында бала туу дәрәҗәсенең төрлечә булуы зәгыйфь үсешле илләрдән уңайлырак илләргә миграция тудыра, монда инде әлеге ил телендә сөйләшмәүче һәм җирле гореф-гадәтләрне сакламаучы «кунаклар» проблемасы килеп баса.

БМО мәгълүматы буенча, 2000 елда безнең планетада яшәүчеләр саны 6 млрд булды, ә 2050 елга ул 10–12 млрд итеп фаразлана. Җир халкының тагын да үсүе, күп галимнәр фикеренчә, кешеләрнең яшәеше өчен кирәкле ресурсларының кискен җитмәүчелеген китереп чыгара. XXI гасырда кешелек алдында халык санын җайга салу проблемасы тора, дөньяның төрле төбәкләрендә уйланылган демографик сәясәтне тормышка ашыру мәсьәләсе куела.

Наркомания һәм наркобизнес. Наркотиклар кулланунын нәтиҗәсе аерым бер кеше өчен дә, җәмгыять өчен дә фаҗигале: шәхеснең декрадациясе һәм, шуның нәтиҗәсе буларак, аның ата-ана, хезмәткәр җәмгыять әгъзасы ролен үти алмавы; наркоманиянең милләт генофондына тискәре йогынтысы; наркотиклар сатып алу өчен акча табу максатында кылынучы җинаятьләр. Әмма наркобизнес җинаять эшчәнлегенең иң табышлы рәвешләренең берсе дә әле ул. Халыкара характердагы наркосәүдә үзенең коточкыч товарын күп илләр чикләре һәм территорияләре аша уздыра. Болар барысы да илләр һәм халыклар иминлегенә куркыныч тудыра һәм шуңа да хокукый, көч куллану, социаль һәм тәрбияви пландагы координацияләнгән гамәлләр, зур тырышлык таләп итә.

Иң куркынычлы авыруларны дәвалау һәм профилактикалау ысулларын эшләгәндә артта калу. Кешелек алдында СПИД күп сораулар куя! Галимнәр фикеренчә, бу авыру урта гасырларда Европада чума алып киткән гомерләрдән дә күбрәк тормышны өзү белән яный. Ул чикләрне белми, һәм аны беркем туктата алмый. Дәүләтләр инде бу авыруны йоктырган кешеләрдән башкаларга күчүдән сакланырлык чаралар күрергә

тиеш. СПИД белән авыручыларны дәвалау өчен кирәк булган кыйммәтле даруларга түләү өчен акча эзләргә кирәк.

Куркыныч авырулар эпидемиясе китереп чыгаруга сәләтле яңа төр микроорганизмнар пәйда була (мәсәлән, атипик пневмония, кош гриппы һ.б.). Еш кына аларның килеп чыгу сәбәпләрен ачыклап булмый. Яшәп килүче авыру чыгаручы микроорганизмнарның алдан әйтеп булмый торган мутацияләнүе мөмкинлеге, шуның нәтиҗәсендә аларның элек билгеле булмаган сыйфатлары ачыла дигән фаразлар әйтелә. Бу куркынычларга каршы тору өчен дөнья җәмәгатьчелегенең килештерелгән гамәлләре таләп ителә.

Фәнни-техник прогрессның куркынычлы нәтиҗәләрен кисәтү, алардан кешелеккә зыян китерерлек файдалану мөмкинлегенә юл куймау. Белгечләр геннар инженериясенең коточкыч явыз мөмкинлекләре турында кисәтәләр. Хайваннарны, ул гына да түгел, кешеләрне клонлаштыруның мөмкин булган нәтиҗәләре ахыргача ачыкланмаган. Фәнни-техник казанышларны тоталь контрольгә алу һәм кешеләр тәртибе белән идарә итү өчен файдалану мөмкинлегенең куркынычлыгы турындагы фикерләр бар. Мәгълүмати технологияләрдән файдаланып кылынучы җинаятьләр зур куркыныч тудыра. Бөтендөнья челтәренә җибәрелгән компьютер вируслары гаять зур зыян китерергә мөмкин, икътисади, хәрби, мәгълүмати куркыныч белән яный. Фәнни-техник прогрессның тискәре нәтиҗәләрен алдан күрә белергә, аны җәмгыять һәм кеше мәнфәгатенә юнәлтергә кирәк.

Сәнәгатьтә, энергетикада, транспортта зур масштаблы һәлакәтләр куркынычы. Чернобыль һәлакәте атом-төш объектларындагы авария нәтиҗәләре милли чикләрдән еракларга китәргә мөмкин булуын күрсәтте. Корбаннар саны бик күп. Атом-төш объектлары куркынычсызлыгын тәэмин итү чараларының әһәмияте арта. Химия производствосы, электр тапшыруы магистраль линияләре, нефть үткәргечләрнең куркынычсызлыгына контроль кирәк.

Мәдәнияткә, кешенең рухи үсешенә куркыныч янау. Хәзерге заман фәне наданлык, җинаятьчелек, наркомания, мәдәнияттән читләшүнең куркыныч тәстә арта баруын билгеләп үтә. Шулай ук матди куллану рухының кирәгеннән артык таралуы игътибарны җәлеп итә. Хәзерге заман технологияләренең үсеше матбугатта, телевидение экраннарында көч куллану, порнографияне пропагандалаучы, дини хисләрне мыскыллаучы, агрессив төркемнәр омтылышларын канәгатьләндерүче җәмгыятькә каршы мәгълүматның барлыкка килүен кисәтүне чынлыкта мөмкин булмаслык итә. Югары сәнгать, бөтендөнья мәдәнияте шедеврлары еш кына журнал битләрен-

нән, телевидение экраннарыннан примитив зәвыкка исәпләнгән массачыл мәдәният эшләнмәләре белән кысрыклап чыгарыла.

Хәзерге заман идеологияләре, дөнья диннәре кебек үк, XXI гасыр чакыруларына каршы торырлык җавап бирә алмады. Кеше аңын һәм тәртибен җимерүче экстремистик карашларны алга сөрүчеләр, дини секталар моңардан файдаланып калырга тырыша.

Алырга мөмкин булган мәгълүмат күләме кешенең аны кабул итү һәм куллану сәләтеннән күпкә узып китә. Кешеләр бер буын тормышы вакытында булучы яшәү шартларының тамырдан үзгәрүләренә җайлашырга өлгермиләр, менә шул стресс, юнәлешне югалтулар, дискомфорт хисе, шөбһә һәм тынычсызлык китереп чыгара.

Болар барысы да милли һәм дөнья мәдәнияте кыйммәтләрен җимерелүдән саклау һәм яклау турында, барлык мәгариф һәм тәрбия системасын модернизацияләү турында, җәмгыятьнең әхлакый нигезләрен ныгыту буенча армый-талмый эшләү зарурлыгы турында мәсьәләләрне алга куя. Кешенең үзенә, аның рухи байлыгына, җәмгыятьнең рухи тормышы катлаулана бару шартларында әхлак принципларын үтәү сәләтенә, алмашынып торучы дөнья чакыруларына мөстәкыйль җавап бирергә әзерлегенә дә күп нәрсә бәйле.

Шулай итеп, XXI гасыр бусагасында җәмгыятьтә куркынычлы тенденцияләр чалымланды. Ләкин аларның куркынычлы үсешеннән котылырлык юлын сайлау мөмкинлеге дә бар.

МӨМКИН БУЛГАН АЛЬТЕРНАТИВА

Глобаль куркыныч янауларны җиңү мөмкинлеген төп игътибарны цивилизация альтернатив үсеш юлларын эзләүгә бирүче галимнәр тикшерә. Яңа гасыр чакыруларына тәңгәл җавап бирү мөмкинлекләре нинди?

Барыннан да элек бу табигатьне саклау һәм табигатьне яңарту эшчәнлегенең нәтиҗәле ысулларын ачучы, глобаль ягулык-энергетика һәм матди-чимал балансын яңа нигездә торгызучы; сәнәгать һәм көнкүреш калдыкларын эшкәртү өчен чистарту корылмалары һәм җиһазларын конструкцияләүче; калдыксыз һәм энергияне сак тоту производстволарын проектлаучы; энергиянең альтернатив чыганакларыннан файдалану мөмкинлекләрен эзләүче; бирелгән сыйфатлары белән ясалма материаллар иҗат итүче фәнни тикшеренүләрне үстерә бару.

Аннан соң бу коралларны кыскарту буенча тырышлыкны эзлекле дәвам итү, атом-төш коралларының таралуына юл куймау, химик һәм биологик коралларны тулысынча юк итү,

халыкара куркынычсызлыкның ышанычлы системасын булдыру, дөнья илләре арасында тигез хокуклы, үзара файдалы мөнәсәбәтләрне үстерү.

Үсеп килүче илләрдә ярлылык һәм артта калганлык проблемалары бөтендөнья яңа икътисади тәртибен урнаштыруны таләп итә.

Бозылган глобаль демографик баланс икътисади яктан зәгыйфь үскән илләрдә бала тууны җайга салу чаралары үткәрү юлы белән торгызыла ала. Бу проблеманы хәл итү шулай ук халыкның гомуми мәдәнилеге үсешенә дә бәйле.

Наркотикларга бәйлелекнең киң таралуы куркынычын бетерү өчен, бер яктан — бик күп дәүләтләр хокук саклау органнарының килешенгән гамәлләре, ә икенче яктан наркоманиянең шәхси һәм социаль куркынычын аңлатуны үз эченә алган профилактика чаралары таләп ителәчәк.

Яңа йогышлы авыруларның барлыкка килү һәм таралу куркынычы тиешле фәнни-медицина тикшеренүләрен үстерү, яңа дару чаралары булдыру һәм аның белән мохтаҗларны үз вакытында тәэмин итү, эпидемияләрнең таралуына юл куймау буенча нәтиҗәле чараларны тормышка ашыру, Халыкара сәламәтлек саклау оешмасы аша барлык илләрнең тырышлыгын координацияләү шартларында түбәнәергә мөмкин.

Фәнни-техник прогресс казанышларын явыз ниятә файдалану куркынычына галим этикасы да, фәнни-техник мөмкинлекләрдән кешегә зыянга файдалануга киртә булырлык хокукый чаралар да каршы куела ала. Шул ук вакытта техноген һәлакәтләрне кисәтү, энергетика һәм сәнәгать объектлары куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча да чаралар күрелергә тиеш.

Җәмгыять үсешенең альтернатив юлын гамәлгә ашыруның иң мөһим шарты — җәмгыятьне, иҗтимагый мөнәсәбәтләрнең бөтен системасын гуманлаштыру, кешеләр тормышының рухи-әхлакый нигезләрен ныгыту. Мәдәни кыйммәтләр белән танышу мөмкинлеге, белем бирүнең сыйфатын күтәрү, шәхеснең үсеше, аның потенциалын тулы ачу һәм гамәлгә ашыру өчен шартлар тудыру шуңа ярдәм итәчәк.

ПОСТИНДУСТРИАЛЬ (МӘГЪЛҮМАТИ) ҖӘМГЫЯТЬ

Дөньяның иң нык үскән илләрендә (АКШ, Көнбатыш Европа илләре) бара торган үзгәрешләрне тикшерү күп кенә галимнәрне җәмгыятьтә аның үсешенең яңа этабына күчү турында сөйләргә мөмкинлек бирүче җитди үзгәрешләр баруы хакында нәтиҗәгә китерде. Бу башланып килүче этапны төрлечә

атыйлар, әмма иң киң таралганы — постиндустриаль җәмгыять. Аның алдыннан җәмгыять үсешенең ике этабы булды. Беренчесе — индустриягә кадәрге җәмгыять — авыл хуҗалыгына нигезләнде. Икенче этап — индустриаль җәмгыять — машина белән җитештерүгә нигезләнә.

Яңа, башланып килүче этап шуның белән характерлы ки, анда мәгълүмат, белемнәр, кеше интеллекты хәлиткеч факторга әверелә. Шуңа да күп галимнәр аны мәгълүмати җәмгыять дип атады. Постиндустриаль һәм мәгълүмати җәмгыятьне тикшеренүләрдә фаразланган яңа этап билгеләрен чагыштыру кайбер галимнәрне җәмгыятьнең бер үк халәте турында сүз баруы хакындагы нәтиҗәгә китерде.

Постиндустриаль (мәгълүмати) җәмгыятьтә иҗтимагый байлыклар һаман саен күбрәк мәгълүматка, белемнәргә ия булу дип аңлашыла. Җитештерү продукциянең күләменә түгел, ә сыйфатына, кулланучы ихтыяҗына йөз тота; хезмәт күрсәтү өлкәсе җитештерү тармагыннан өстен тора. Индустриаль производство шартларындагыга караганда күбрәк төрле эшчәнлек сәләтенә ия булган хезмәткәрләргә сорау нык арта.

Җәмгыятьнең социаль структурасында һөнәри белгечләр өстенлек итә. Постиндустриаль җәмгыять теориясен булдыручыларның берсе, Америка социологы Д.Белл басым ясап күрсәткәнчә, бу җәмгыятьнең иң мөһим принцибы булып «теоретик белемнәрнең гаять зур социаль әһәмияте һәм аның социаль үзгәрешләрнең юнәлеш бирүче көче сыйфатындагы яңа роле» тора. «Һәр җәмгыять белем нигезендә функцияли, әмма XX гасырның икенче яртысында гына фән һәм инженериянең технология асылын үзгәртүче кушылуы булды... Интеллектуаль технология оешмалар һәм предприятиеләр белән идарә итүнең төп инструментына әверелгәнгә, ул постиндустриаль җәмгыять өчен, индустриаль җәмгыятьтә машина технологиясе кебек үк әһәмияткә ия була дияргә мөмкин».

Мәдәнияттә дә үзгәрешләр бара. Европаның нык үскән илләрендә алар бигрәк тә ачык күренә. Информатиканың барлык казанышларын үзләштергән мәдәният Европа икътисадының торган саен әһәмиятлерәк тармагына әверелә бара. Тикшеренүчеләр европалылар аңында постиндустриаль җәмгыятьнең социаль кыйммәтләре һаман киңрәк таралуын билгеләп үтәләр. Тормыш сыйфатының үсүе, буш вакытның арта баруы акча керемнәре үсә баруга караганда көчлерәк этәргечкә әверелә. Иң мөһим проблема булып гражданнарның эшкә урнашуы түгел, ә аларда җитештерүчән эшчәнлеккә стимул формалаштыру тора. Уңышлы эшмәкәрнең җәмгыятьтәге урыны түгел, ә башкаларны үз гамәлләре һәм идеяләре белән җәлеп итүче кеше статусы җәмгыять тарафыннан таныла төшә.

Шуның белән бергә җәмәгать байлыкларының һаман күбрәк өлешен үзләштерүче, постиндустриаль кыйммәтләргә йөз тотучы «интеллектуаль сыйныф» белән кирәкле интеллектуаль һәм белем потенциалына ия булмаган, милли байлыкларның һаман әзрәк өлешен алучы, үзенең матди хәлен яхшыртудан башка максатлары булмаган түбәнге сыйныф арасында каршылыклар килеп чыга. Постиндустриаль җәмгыятьтә әлеге каршылыклар ничек хәл ителәчәген бүген әйтүе кыен.

Постиндустриаль җәмгыять теориясен танучы галимнәр бүген, аңа күчү өчен нигез булып яңа технологияләр һәм белемнәрдән бигрәк кешенең үзен үзгәртү тора, дип раслый.

Әлегә индустриаль булып торучы Россия җәмгыятенә милли үзенчәлекләрне исәпкә алган постиндустриаль үсешнең үз вариантын үтәргә туры киләчәк.

ГАМӘЛИ ЙОМГАКЛАР

1 Сезгә катлаулы, тиз үзгәрүчән җәмгыятьтә яшәргә туры киләчәк. Һәркайсыгыз алдында көнкүреш, гаилә, хезмәт, икътисади һәм сәяси мөнәсәбәтләр, мәгълүмат һәм мәдәният өлкәләрендә үзгәрешләр белән бәйле күптөрле проблемалар килеп чыгарга мөмкин. Үз проблемаларыгызны хәл итү ысулларын сезгә мөстәкыйль эзләргә туры килер. Дөрес чишелешне фәкать сайлап алу вариантлары турында иң тулы мәгълүматка ия булганда гына табарга мөмкин, алар конкрет җәмәгать шартларында гына яши. Бер үк вакытта үз сәләтеңне, гомуми белем һәм һөнәри дәрәҗәңне дә дөрес бәяләү зарур.

2 XXI гасыр чакыруларына уйланылган һәм нәтиҗәле җавап бирү хакимияттән һәм фәннән генә тормый, ул сезнең дә һәркайсыгызга бәйле. Байтак экологик, социаль-демографик, санитар-гигиеник проблемаларны, шулай ук авыруларны, наркоманияне профилактикалау, технологик куркынычсызлык, мәдәни кыйммәтләр белән танышу дәүләт дәрәҗәсендә генә бармый, гаиләдә, микрорайонда, эш урынында, аерым кеше эшчәнлегендә тормышка ашырыла.

3 Җәмгыять үсешендә мәгълүматның, белемнәр, интеллектның роле үсә бару тенденциясе күренеп торганлыктан, тормыштагы уңышыгыз, карьерагыз хәлиткеч дәрәҗәдә сезнең мәктәптән соңгы елларыгызны компетентлы белгеч булу өчен файдалана алуыгызга бәйле. Иң якын киләчәктәге җәмгыятьтә «катыргыга» (белем алуы турында берәр документка) гына ия булган кеше белән чыннан да югары квалификацияле һөнәр остасы арасындагы аерма торган саен күбрәк сизеләчәк.

4 XXI гасырда җәмгыятькә кеше эшчәнлегенең барлык өлкәләрендә белемнәргә һәм осталыкка ия булуның башка дәрәҗәсе кирәк булачак. Элек алынган белемнәр тормыш куйган сорауларга әзер җавап бирә алмый. Әмма булган белемнәрне үзгәртеп торучы дөнья турында яңа белемнәр эзләү өчен файдаланырга була. Производствода, фәндә, социаль сәяси үсештә килеп чыккан проблемаларны иҗади хәл итү таләп ителәчәк. Гасыр таләбенә фәкать иҗади эшчәнлек тәҗрибәсенә таянып, мәгълүматтан оста файдалана алучы, алынган белемнәрне яңа бурычларны хәл итү өчен куллана белүче, элек билгеле булмаган нәтиҗәле гамәлләр ысулларын эзләүче затлар гына туры килә.

ДОКУМЕНТ

Вакыт чакыруларына гуманистик җавап турында. *Италия галиме, халыкара Рим клубының беренче президенты* ***Аурелио Печчеиның*** «Киләчәк өчен йөз бит» хезмәтеннән.

Замана кешесе матди өлкә белән бәйле көндәлек мәшәкатьләре белән мәшгуль... Мондый кеше аны барлыкка китергән табигый дөньяга караганда үзе белгән яисә үзе булдырырга маташкан ясалма дөньяны якынрак күрә,— бу хакта мин язган идем инде. Ул барыннан да элек үзе тудырган нәрсә — хәтта ул консерв банкалардагы, шешәләрдә тотучы, катырып куючы, әзерләүче ризык белән кызыксына. Табигать икенче планга, бөтенләй артка кала. Аңа охшаган башка нәрсәләр дә бәясен югалта; алар шундый күп; ул алар белән аралашмый; ул башка эшләр белән шөгыльләнергә ашыга... Шулай да ул эчендә ниндидер бер бушлык үсүен сизә, ул үзен-үзе ачыкларга, үзенә, үзенең эшләренә зуррак әһәмият бирергә теләр иде. Ләкин аның фикерләве ялгыш һәм бу максатка начар хезмәт итә.

Яңа нигез салучы идея кирәк... Бу технологик гасырга яраклашкан яңа гуманлык әлегә кадәр кагылгысыз булып саналган принцип һәм нормаларны радикаль яңартырга һәм үзгәртергә тиеш; ул һәм рухи, һәм этик, фәлсәфи, социаль, сәяси, эстетик, иҗади тәртип кыйммәтләренең яңа системасы туугa импульс бирергә тиеш; алар бездә югары игелек һәм ихтыяҗ буларак мәхәббәтне, дуслыкны, үзара аңлашуны, теләктәшлекне, бергә янәшә яшәүне торгызырга сәләтле булсын; безне бу муллык һәм ихтыяҗлар бөтен дөньядагы туганнарыбыз белән тыгызрак бәйләсә, отышыбыз да зуррак булуны тоемларга мәҗбүр итәргә кирәк.

Бу яңа гуманлык шулай ук җитәрлек кадәр мәгърифәтле, көчле, сыгылмалы булырга тиеш, ул безгә матди революцияләрне контрольдә тоту мөмкинлеге бирсен, безгә социаль-сәяси революцияне ничек хупларга һәм тыныч, конструктив рәвешләргә юнәлтергә кирәклеген күрсәтеп, әлегә без аның ничек өлгерүен яисә шартлавын күзәтә генә алабыз, һәм безне беркайчан да, бернинди шартларда да рухның өстенлегеннән баш тартырга тиеш түгеллегебезне аңларга мәҗбүр итсен.

Документка сораулар һәм биремнәр

1. Бу өзекнең төп фикере нинди? Параграф текстында бу фикерне чагылдыручы расламаны табыгыз. **2.** Китерелгән текст XX йөзнең 80 нче елларында язылган. Ул безнең көннәрдә актуальме? Үз бәягезне дәлилләгез. **3.** XX гасыр техник прогрессы кешелеккә рухи өлкәдә нинди югалтулар китерде? Бу хакта Печчея фикерләрен XXI гасырның мәдәнният өлкәсендәге янаулары белән чагыштырып карагыз. Нәтиҗә ясагыз. **4.** Автор нинди югары байлыклар һәм ихтыяҗларны иң әһәмиятлесе дип саный. Нигә нәкъ шулар икәнлеге турында үз фикерегезне әйтегез. **5.** Сез авторның матди һәм социаль-сәяси революцияләр турындагы сүзләрен ничек аңлыйсыз? Аларны параграфның XXI гасыр проблемалары хакындагы нинди нигезләмәләр белән бәйли аласыз? Мондый багланышны аңлатыгыз. **6.** Нигә автор үз карашларын яңа гуманлык дип атый?

ҮЗ-ҮЗЕҢНЕ ТИКШЕРҮ ӨЧЕН СОРАУЛАР

1.Фән киләчәкне күрә аламы? **2.** XXI гасырның төп проблемаларын атагыз һәм характерлагыз. **3.** Һәр глобаль проблеманы хәл итүнең мөмкин булган юллары нинди? **4.** XXI гасыр башы җәмгыяте тормышында төп тенденция нидән гыйбарәт? Җәмгыятьнең үсеше яңа этабының галимнәр тәкъдим иткән исеме нәрсәне белдерә? **5.** Постиндустриаль (мәгълүмати) җәмгыять индустриальдән нәрсәсе белән аерыла? Үзгәреп торучы җәмгыятьтә уңышлы эшләү һәм яшәү өчен кеше нинди сыйфатларга ия булырга тиеш?

БИРЕМНӘР

1. Киләчәкне фаразлаучы галимнәр арасында аерым индивидларның, халык төркемнәренең, сәяси системаларның алдагы үзгәрешләргә яраклашуга әзерлеге турында мәсьәлә буенча

каршылыклар бар. Берәүләр гаять зур катаклизмнар гына җитди үзгәртеп коруларга этәргеч бирә ала дип саный. Икенчеләре, кешелек мөстәкыйль рәвештә, тышкы йогынтылардан башка да тамырдан үзгәрешләрне тормышка ашырырга мөмкин, ди. Ә сез ничек уйлыйсыз? Үз позициягезне дәлилләгез.

2. Нык үсеш алган илләрнең һәр кешесе үз гомерендә планетаның ресурсларын башка илләрдә яшәүчеләргә караганда 20–30 тапкыр күбрәк куллана. XXI гасырның нинди проблемалары әлеге фактка бәйле? Аны хәл итүнең мөмкин булган юллары нинди?

3. Түбәндә саналган билгеләрне ике төркемгә бүлегез, аларның беренчесендә — индустриаль җәмгыять сыйфатлары, ә икенчесендә постиндустриальнеке булсын:

— яңартылучы энергия чыганакларына йөз тоту һәм аларны актив эзләү;

— яңадан торгызылмый торган «табигать капиталын» (ташкүмер, газ, нефть һ.б.) исраф итү;

— фән һәм техниканың хәлиткеч тармаклары — механика һәм машина төзелеше, химия һәм химия индустриясе;

— фән һәм техника өлкәсендә хәлиткеч тармаклар — квант электроникасы, информатика, молекуляр биология, экологик белемнәр;

— рухи кыйммәтләргә һәм иҗатка йөз тоткан шәхес;

— җитештерү һәм куллануга; акча һәм хакимлек культына табынучы индивид.

4. Җәмгыятьтә фән һәм техниканың роле турындагы, бу өлкәләрдәге прогресс өчен кешелек түләячәк бәя хакындагы бәхәсләрдә төрле карашлар ачыкланды. Берәүләр фән һәм техника үз законнары буенча үсә, җәмәгать контроленә дә, сәяси җайга салуларга да карамый, диләр. Икенчеләре исә фәннитехник үзгәрешләр җәмгыятьнең ихтыяҗлары тарафыннан кушыла дип раслый. Бу бәхәсле мәсьәлә буенча сезнең фикерегез ничек? Аларны дәлилләр белән ныгытыгыз.

ЗИРӘКЛӘР ФИКЕРЕ

«Киләчәк өчен иң яхшы пәйгамбәр — үткәннәр».

Дж.Байрон (1788–1824), инглиз шагыйре

Йомгаклап кабатлау өчен сораулар һәм биремнәр

I бүлек. Кеше һәм икътисад

1. Сыйныфташларыгыз белән түбәндәге проблеманы тикшерегез: «Икътисадның хәл итүче ресурсы нәрсә: табигатьме, кешеме, җитештерү чараларымы, белемнәрме (мәгълүматмы)?» Үзегез сайлагыз һәм нигезләгез.

2. Икътисадчы Ф.А.Хайек болай дип яза: «Конкуренцияле җәмгыятьтә ярлыларның мөмкинлекләре байларныкыннан күпкә чикле, шулай да мондый җәмгыятьтә ярлы башка типтагы җәмгыятьтәге әйбәт матди хәлле кешедән күпкә ирекләрәк».

Сез бу раслама белән килешәсезме?

3. Сезнеңчә нинди хәл нормаль: такси йөртүче пассажирны эзләгәндәме яисә пассажир такси эзләсәме? Үз карашыгызны аңлатыгыз.

4. Базар икътисадында нигә супермаркетлар белән бергә кечкенә генә кибетләр эшләп килә? Алар ничек яши алганны аңлатыгыз.

5. Эшмәкәрлекны производствоның дүртенче факторы дип атыйлар. Уңышлы производство оештыру өчен нәкъ менә шушы фактор файдаланылган сезгә билгеле фирма яисә эшмәкәр эшчәнлеген мисалга китерегез.

6. «Һәртөрле коммерция — киләчәкне алдан күрергә тырышу ул»,— дип раслый инглиз язучысы һәм философы С.Батлер. Нигә автор эшмәкәрлек эшчәнлегенә шундый характеристика бирә? Эшкә алынганчы эшмәкәр нәрсәләрне исәпкә алырга, санап карарга һәм алдан күрергә тиеш?

7. С.Витте һәм П.Столыпинның дәүләтнең икътисад үсешенә йогынтысын көчәйтүне максат итеп куйган реформаларын исегезгә төшерегез. Дәүләт җайга салуының нинди ысуллары кулланыла, һәм алар нигә Беренче бөтендөнья сугышы алдыннан Россия икътисади үсешенә этәргеч биргән?

8. 2007 елда Россиядә автомобильләрне мәҗбүри иминиятләштерү кертелде. Машина хуҗалары арасында бу процессны яклаучылар да, аңа каршылар да булды.

Сез кайсы позицияне яклар идегез? Җавабыгызны дәлилләгез.

9. Яшь гаилә 1 млн сум торган бер бүлмәле фатир сатып алмакчы булды, ләкин акчалары моның яртысы кадәр генә иде. Гаилә банк займыннан файдаланырга карар бирде һәм елга 20% лы 3 елга исәпләнгән 500 мең сум кредит рәсмиләштерде.

3 елдан гаилә банкка нинди сумма акча бирәчәген исәпләп чыгарыгыз.

10. Кеше хезмәт базарында нәрсә сата? Ялланган эшчеләрне элек нигә пролетарий дип атаганнар, «нәселдән башка берние дә юк» дигән сүзләр нәрсәне аңлата? Хәзерге хезмәткәр XIX гасыр ялланган эшчесеннән нәрсәсе белән аерыла?

11. Шундый вазгыятьне күз алдына китерегез: сез салкын эчемлекләр җитештерү фирмасы җитәкчесе ди. Кышын сезнең продукциягә ихтыяҗ кими. Җитештерү чыгымнарын киметү өчен нинди чаралар күрерсез?

12. Танышларыгыз, туганнарыгыз, дусларыгыз саклаган акчаларын нәрсәгә әйләндерүе белән кызыксыныгыз: чит ил валютасы алалармы, кыйммәтле кәгазьләрме, озак файдаланудагы товарлар сатып аламы, банкта исәп ачалармы?

Тегене яки моны сайлауга өстенлек бирү сәбәпләрен һәм илдәге икътисади вазгыятьнең аңа йогынтысын анализлагыз.

13. Икътисади циклның төрле фазаларында: төшү, күтәрелеш, икътисади кризиста кулланучы чыгымнары структурасы үзгәрәме? Ничек итеп? Мисаллар китерегез һәм нәтиҗәләрегезне дәлилләгез.

14. «Кешенең бәясе — аның хезмәт хакы» дигән инглиз әйтеменең мәгънәсен ничек аңлыйсыз? Һөнәри уңышка ирешү шарты булып бер үк дәрәҗәдә акча һәм яхшы белемнәр тора дигән фикер белән килешәсезме? Җавабыгызны дәлилләгез.

II бүлек. Социаль-сәяси һәм рухи тормыш проблемалары

1. Рус-америка социологы П.Сорокин, ач торганда кешенең идеологиясе, әлеге шартларда ризык бирергә сәләтле ачлыкны бастыруга каршы килүче чаралар күрүне «хуплаучы» рефлексларны йомшарту ягына фикерләү, теорияләр, инануларның көчәюе юнәлешендә деформацияләнә,— дип яза.

Сез бу фикерне ничек аңлыйсыз? Болай раслауга мөнәсәбәтегез нинди?

2. Түбәндәге гыйбарәне анык фактлар белән раслый аласызмы: «Европаның Яңа тарихы чорында үсешенең генераль юнәлеше индивидны аның көндәлек тормыш эшчәнлеген төрле норма һәм билгеләмәләрдән азат итү булды»?

3. «Ирек» төшенчәсенең түбәндә китерелгән кайсы билгеләмәсе сезгә иң төгәле булып тоела:

1) ирек — төрле киртәләр һәм комачауларның булмавы;

2) ирек — зарурлыкка аңлы рәвештә бару;

3) ирек (ирекле ихтыяр) — теләсә нинди гамәлләргә китерергә мөмкин үзбашлык түгел, ә кеше тарафыннан мораль таләпләрне үтәгәндә даимилек, эзлеклелек, үз-үзеңне кызганмау;

4) ирек — тормышны чикләүләрдән һәм мәҗбүрләүдән азат итү?

4. Түбәндә китерелгән текст өземтәсендә тезис (төп идея) һәм дәлилләрне аерып күрсәтегез.

а) дөрес;

б) тикшерелүче.

«Байтак галимнәр һәр тарихи эпохага төп акыл көе һәм хисси мөнәсәбәтләр, үзенә күрә «вакыт рухы» туры килә дип уйлый. Ул мәгълүм бер тарихи чорның рухи атмосферасын билгели. Мәсәлән, классик Рим чорында гражданлык өстенлек итә, XVIII гасыр азагы Бөек француз революциясен әзерләү чорында мондый өстенлек ирекка бирелә».

Сез текст өземтәсендә китерелгән тезис белән килешәсезме? Үзегезнең өстәмә дәлилләрегезне китерегез.

5. Сез гыйбарә белән килешәсезме: «Җәмгыятьтә яшәп җәмгыятьтән азат булу мөмкин түгел»? Үз позициягезне нигезләгез.

6. XIX гасырның мәгълүм фикер иясе болай ди: «Юридик яктан танылган ирек дәүләттә закон рәвешендә яши... Законнар — уңай, ачык, гомуми нормалар ул, аларда ирек шәхескә бәйсез, теоретик, аерым индивид башбаштаклыгыннан бәйсез яшәү ала. Законнар җыелмасы — халыклар азатлыгы библиясе ул».

Бу әйтемне шәрехләгез.

7. Китерелгән текстны укып чыгыгыз, сорауларга җавап бирегез:

«Җәмәгать фикере ике мәгънәдә кулланыла: 1) әлеге җәмгыятьтәге билгеле бер социаль төркем һәм субкультура вәкилләре булган реаль санлы кешеләр хуплаучы фикер; 2) җәмәгатьчелекнең барлык вәкилләре арасында өстенлекле фикер.

Беренче билгеләмәгә караганда, җәмәгатьчелек фикерләре күбәү булырга мөмкин һәм аларның саны гетерогенлык дәрәҗәсенә һәм җәмгыятьтәге тигезсезлек дәрәҗәсенә бәйле. Икенче билгеләмәгә килгәндә, җәмәгать фикере җәмәгатьчелекнең күпчелек вәкилләренең уртак фикере, тикшерелүче проблема буенча карашларның зур санының ниндидер бер консенсусы гына...

Җәмәгать фикере шәхесләр арасындагы аралашу һәм массакүләм коммуникация чаралары аша булдырыла. Шул ук вакытта аның роле төрле җәмгыятьләрдә төрлечә...»

(Фролов С.С. Социология. М., 2003. 248 б.)

Әлеге текстта җәмәгать фикере ни иканлеге ничек билгеләнә? Сезнеңчә җәмәгать фикере һәм җәмәгать аңы үзара ничек бәйләнгән?

Хәзерге заман демократик җәмгыятьләрдә җәмәгать фикеренең нигә роле зур булуы турында үз карашыгызны әйтегез, бу нинди хәлләр белән тудырыла?

8. Л.Н.Толстой болай яза: «Теләсә кайсы диннең асылы фәкать бер сорауга җавап бирүдән гыйбарәт: мин нигә яшим һәм мине чолгап алган чиксез дөньяга мөнәсәбәтем нинди».

Сез язучы фикере белән килешәсезме? Җавабыгызны дәлилләгез.

III бүлек. Кеше һәм закон

1. Халыкара законнарда гражданлыкны билгеләүнең ике принцибы гамәлдә: «кан принцибы» һәм «туфрак принцибы». Беренчесе нигезендә баланың гражданлыгы ата-анасы гражданлыгы белән билгеләнә. Икенчесе буенча бала үзе туган территориядәге дәүләт гражданлыгы ала, ата-ана гражданлыгыннан бәйсез була.

Россиядә нинди принцип гамәлдә булуын билгеләгез.

2. Хәзерге заман Россия гаилә кодексында «гаилә башлыгы» дигән юридик төшенчә бармы? Гаилә хокукының төп принципларына таянып, үз җавабыгызны формалаштырыгыз.

3. Никахлашуның билгеләнгән шартларын бозганда, ул гамәлдә түгел дип танылa. Шундый хәл булырга мөмкин очраклар исемлеген формалаштырыгыз.

4. Никах шартнамәсе никахның мәҗбүри шарты булып торамы? Никах шартнамәсе ир белән хатынның мөлкәти булмаган мөнәсәбәтләрен, аларның балаларга карата хокукларын һәм бурычларын җайга салырга мөмкинме? Җавабыгызны нигезләгез.

5. Сез ничек уйлыйсыз, ата-ана хокукыннан мәхрүм ителгән яисә бу хокуклары чикләнгән затлар, хроник алкоголиклар яисә наркоманнар, шулай ук опекун (попечитель) вазифасыннан читләштерелгән затлар нигә опекун һәм попечитель була алмый?

6. Күчемсез мөлкәт белән эш итү буенча килешү ирле-хатынлыларның берсе тарафыннан икенчесенең наториаль расланган ризалыгы булганда гына төзелә ала. Нигә мондый таләп куела? Ул никахның нинди юридик нигезен иллюстрацияли?

7. Нигә ирле-хатынлы затларның алимент, торак, мирас хокуклары язылышу турында таныклыкны күрсәткәч кенә яклана?

8. СССРның элеккеге республикалары территорияләрендә рус телле халыкны дискриминацияләүнең күп кенә очраклары теркәлгән.

Кешенең кысрыкланган хокукларын яклауның берничә ысулын тәкъдим итегез.

9. Немец язучысы һәм галиме Г.К.Лихтенберг болай яза: «Киләчәккә нигез бүген салынырга тиеш». Ә Австрия философы Л.Витгенштейн болай раслый: «Киләчәк вакыйгаларны бүгенге вакыйгалардан китереп чыгару мөмкин түгел».

Әлеге гыйбарәләргә мөнәсәбәтегез нинди? Хәзергенең һәм киләчәкнең чагыштырмасын сез ничек аңлыйсыз?

Учебное издание

Серия «Академический школьный учебник»

***Боголюбов** Леонид Наумович*
***Городецкая** Наталия Ивановна*
***Матвеев** Александр Измайлович и др.*

ОБЩЕСТВОЗНАНИЕ

11 класс

Учебник
для общеобразовательных учреждений

БАЗОВЫЙ УРОВЕНЬ

(перевод с русского на татарский язык)

Уку-укыту басмасы

«Мәктәпләр өчен академик дәреслек» сериясе

***Боголюбов** Леонид Наумович*
***Городецкая** Наталия Ивановна*
***Матвеев** Александр Измайлович һ.б.*

ҖӘМГЫЯТЬ БЕЛЕМЕ

11 сыйныф

Гомуми белем бирү учреждениеләре өчен дәреслек

БАЗА ДӘРӘҖӘСЕ

Редакторы *М.Х.Вәлиев*
Корректоры *Ә.Ф.Әхмәдуллина*
Компьютерда биткә салучысы *В.М.Садыйкова*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 10.10.2010.
Форматы 60×90 1/16. Офсет кәгазе. «Школьная» гарнитурасы.
Офсет басма. Басма табагы 26. Тиражы 2530 д.
Заказ О-1424.

Татарстан Республикасы «ХӘТЕР» нәшрияты.
420111. Казан, Тельман ур., 5.
Хатлар өчен: 420014. Казан, Кремль, а/я 54.
Тел. (факс): (843) 264-67-96

«Татмедиа» ААҖ филиалы —
«Идел-ПРЕСС» полиграфия-нәшрият комплексы.
420066. Казан, Декабристлар ур., 2.

А

Россия Фәннәр академиясе
Россия Мәгариф академиясе
«Просвещение» нәшрияты

Мәктәпләр өчен академик дәреслек

БАЗА
ДӘРӘҖӘСЕ